

# Казан утлары

3.1986



# КОНКУРС!

Партиябезнең XXVII съезды әдәбият алдына яңа җитди бурычлар куйды. Аның карарларында әдәби әсәрләрнең югары идея-эстетик таләпләргә һәм заман ихтыяҗларына тулы җавап бирергә тиешлеге аеруча басым ясап әйтелә.

Соңгы елларда басылган әдәби әсәрләрне съезд карарлары яктылыгында профессиональ анализлауны һәм объектив бәяләүне яхшырту максатыннан чыгып, «Казан утлары» журналы редакциясе

## ИҢ ЯХШЫ РЕЦЕНЗИЯЛӘРГӘ АЧЫК КОНКУРС

игълан итә. Конкурс 1986 елның мартыннан алып 1987 елның декабренә кадәр дәвам итә. Конкурска килгән иң яхшы рецензияләр журналда басылып барачак. Рецензияләргә булган төп таләпләр шундый: алынган аерым әсәрнең яисә китапның тормыш һәм әдәбият өчен төп кыйммәтен, әһәмиятен ачу, үзенчәлеген билгеләү. Рецензияләрнең форма ягыннан төрле, уку өчен кызыклы, зур тәэсир көченә ия булуы һәм композицион яктан камиллеге мөһим. Рецензия язу өчен татар язучыларының татарча яисә бүтән телдә басылып чыккан проза, поэзия, драма, очерк, әдәби тәнкыйть һәм балалар өчен булган китапларын яисә аерым әсәрләрне алырга мөмкин.

Рецензияләрнең күләме машинкада 8—10 биттән артмаска тиеш.

Иң яхшы рецензияләр өчен түбәндәге бүләкләр биреләчәк:

I бүләк — 200 сум (берәү)
II бүләк — 150 сум (икәү)
III бүләк — 100 сум (икәү)

Конкурска язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең һәм киң катлау укучыларның катнашуын көтәбез!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

3

1986

## *Бу санда*

КПССның XXVII СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Г. МӨХӘММӘТШИН. Балтачлылар үрнәгендә . 3

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ 80 ЕЛЛЫГЫНА

С. ШӘКҮРОВ. Сәхнәнең кыл уртасында. *Повесть* . 7
Л. ШАКИРҖАНОВА. Ике хәбәр арасы. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
И. ГАНИЕВА. Тамчылар. *Шигырьләр* . . . . . 63
Г. БӘШИРОВ. И язмыш, язмыш. *Повесть* . . . 65
Р. ГАТАУЛЛИН. Безнең муза. *Шигырьләр* . . . 89
Р. ХИСМӘТУЛЛИН. Аягүрә. *Хикәя* . . . . . 93

Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Сасна. *Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме* . . . . . . . . 100
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Кырлайга сәяхәт һәм самавыр йөзлегенә язылган шигырь. *Истәлек-хикәя* . . 102
Р. ШАҺИЕВА. Тукай һәм сынлы сәнгать . . . 108

К. БУЛАТОВАГА 50 ЯШЬ

А. ГАФИЯТОВ. Печән өсте . . . . . . . . . . 113
К. БУЛАТОВА. Хәтер тәрәзәләре. *Шигырьләр* . . 115

Ә. РӘШИТОВКА 50 ЯШЬ

Ә. РӘШИТОВ. Автопортретка штрихлар. *Поэма* . 119

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Р. ГАЛИЕВ. Нефтьчеләр үзәге. (Әлмәт) . . . . 126
М. ЕЛИЗАРОВА. Бөгелмә егете . . . . . . . . 130

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. ХАФИЗОВ. «Яшел елан»га каршы . . . . . 135
М. РАФИКОВ, Р. КУКУШКИН. Тәрҗемә турында сөйләшәбез . . . . . . . . . . . . . 141

БИБЛИОГРАФИЯ

М. ФӘИЗУЛЛАЕВА. Еллар һәм җырлар . . . . 149
Л. САТТАРОВА. Сынлы сәнгать елъязмасы . . 150

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

И. ДИНДАРОВ. **Мәхәббәт һәм шигърият** . . . 152

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

А. ШАМОВ. **Үтәлми калган теләк** . . . . . . 154

СӘНГАТЬ

Т. ӘЙДИ. **Дәверләрне буйлап — киләчәккә** . . . 162
Р. ХӨСНЕТДИНОВ. **Моң чишмәсе** . . . . . 170

А. КЛЮЧАРЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

З. СӘЙДӘШЕВА. **Халык дөньясын сөеп** . . . . 175

ТАРИХЫБЫЗ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

М. ЮСУПОВ. **Беренче рус революциясендә татар хатын-кызлары** . . . . . . . . . . . . 177

БЕЗНЕҢ ӘХЛАК

С. ГӘРӘЕВА. **Тормышка гашыйк** . . . . . . 182

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . . 189

**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары** . . . . . . . . . . . . 191

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Решения XXVII съезда КПСС — в жизнь!» Интервью с зам. председателя Балтасинского райисполкома Г. МУХАМЕТШИНЫМ.
Повесть Г. БАШИРОВА «Судьба, судьба...». Повесть С. ШАКУРОВА «Артист». Рассказы Р. ТУХВАТУЛЛИНА и Р. ХИСМАТУЛЛИНА. Стихи Р. ГАТАУЛЛИНА.
8 Марта — Международный женский день: стихи Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, И. ГАНИЕВОЙ. Статья М. ЮСУПОВА о татарских женщинах, принимавших участие в Первой русской революции 1905—1907 гг.
Очерки М. ЕЛИЗАРОВОЙ, С. ГАРАЕВОЙ.
К 100-летию Тукая: рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА, статья Р. ШАГИЕВОЙ «Тукай и искусство».
В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Альметьевского горкома КПСС Р. ГАЛИЕВА.
В разделе «Литературная критика» статья С. ХАФИЗОВА «Против зеленого змия». Обсуждаем проблемы художественного перевода.
Рецензируются книги Х. Валиуллина, Г. Сулеймановой-Валеевой, Ш. Зигангировой.
В рубрике «Искусство» статьи Т. АЙДИ и Р. ХУСНУТДИНОВА.
Воспоминания А. ШАМОВА о Фатихе Кариме.
В номере отмечаются юбилеи А. Ключарева, К. Булатовой, А. Рашитова.
На наших обложках: о творчестве художника И. Зарипова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Г. Салихҗанова*, *А. Садыйкова*.

Производствога бирелде 2.01.1986 ел. Басарга кул куелды 26.02.1986 ел. ПФ 05077. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 62549. Заказ В-4. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

# БАЛТАЧЛЫЛАР ҮРНӘГЕНДӘ

Бөтен ил, партиябезнең XXVII съезды карарлары белән рухланып, яңа үрләр яуларга омтылган бу көннәрдә Татарстанның Балтач районы уңганнары да икеләтә тырышлык белән эшлиләр. Район игенчеләре һәм терлекчеләре, үзләре туплаган тәҗрибә нигезендә, алда торган җитди бурычларны үтәү, яңа үрләр яулау юлларын билгелиләр. Шушы уңайдан безнең хәбәрчебез халык депутатларының Балтач районы башкарма комитеты председателе урынбасары Гарифҗан МӨХӘММӘТШИНГА берничә сорау белән мөрәҗәгать итте. Түбәндә шул җавапларны урнаштырабыз.

**— Кайсы гына районга барсаң да, «Балтачлылар үрнәгендә...» дигән сүзләр ишетәсең. Сезнең уегызча, районда башкаларга үрнәк булырлык нинди яңалыклар тормышка ашырыла?**

— Безнең үзебездә, мәсәлән, «Арчалылар үрнәгендә...», «Тукайлылар үрнәгендә...» кебек сүзләрне еш ишетәсең. Башкалардан теләп өйрәнәбез. Һәр яңаны кулланырга, аңардан файда күрергә омтылабыз. Башкаларга да үрнәк булырлык сыйфатларның иң беренчесе, минемчә, менә шул — яңалыкка омтылу. Билгеле, башкалар ачкан яңалыкны үзебезгә сукырларча күчерү түгел, алардан иҗади файдалану турында сүз бара.

Соңгы елларда безнең терлекчелектә уңай якка зур үзгәрешләр булды. Мәгълүм ки, терлекчелектәге уңышларның нигезе — мул азык. Без терлек азыгы үстерергә һәм әзерләргә өйрәндек. Районда азык чөгендеренә зур игътибар бирүнең инициаторы булган орденлы механизаторыбыз Халит Шиһапов республика комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе белән бүләкләнде. Ул эшләгән Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз тәҗрибәсен өйрәнеп, районыбызның һәр хуҗалыгында чөгендер үстерү белән шөгыльләнүче даими звенолар оештырылды. Бригада, гаилә подряды кебек алдынгы алымнар да башлап шушы тармакта кертелде. Җыеп алынган чөгендернең бер өлешен түләү тәртибендә колхозчыларга да өләшәбез. Бу аларның үз хуҗалыгында терлек асрауны киңәйтүгә уңай йогынты ясый.

Хәзер бездән азык чөгендере үстерү серләрен республикабызның күп районнары, Мари республикасы, Киров өлкәсе хезмәтчәннәре килеп өйрәнәләр.

Терлекчелектә тагын бер яңалыкны телгә алырга кирәк. Безнең район терлекчелектә беренчеләрдән булып тулысынча ике сменалы эшкә күчте. Яшь терлекчеләр сменасыз эш турында өлкәннәрдән ишетеп кенә беләләр. Терлекчеләребез хәзер атналык ял көннәрен дә регуляр алалар.

Мондый үзгәрешләр социаль проблемаларны уңай хәл итү белән бергә, терлекчелектән продукция алуны арттырырга да ярдәм итә.

Соңгы елларда кырлардан да тотрыклы уңыш алабыз. Бусы инде игенчелектә яңалыкка йөз тоту нәтиҗәсе. Туфракны уңдырышлылыгын югалтмый торган ысуллар белән эшкәртүгә күчү, киң рәвештә химияләштерү, интенсив сортлы орлыклар чәчү, пар җирләрен киңәйтү, аларны мул туендыру һәм эшкәртү — менә ул яңалыклар. Без бу юнәлештә дә башкалар тәҗрибәсен тырышып өйрәнәбез, үзебез ирешкәннәрне башкалар белән теләп уртаклашабыз.

**— Игенчелектәге яңалыкларыгызга да тукталсагыз иде! Чөнки аңардан башка терлекчелек тә алга китә алмый.**

— Партиябез Үзәк Комитетының октябрь Пленумы (1984) караган мелиорация программасы — илебез өчен принципиаль яңа, авыл хуҗалыгын үстерүдә зур перспектив әһәмиятле мәсьәлә. Элегрәк без авылда мондый киң колачлы бурычларны кую һәм хәл итү турында хыяллана да алмадык.

Басуларны сугаруны гына алыйк. Бездә 4880 гектар сугарулы җир бар. Аларда тулысынча диярлек терлек азыгы культуралары игелә. Азык культураларының 24 процентын гына тәшкил итсәләр дә без шул җирләрдән терлек азыгының 40 процентын алабыз. Мин инде азык чөгендереңең терлекчелектәге әһәмияте турында әйткән идем. Ә бит без барлык чөгендерне сугарулы җирләрдә үстерәбез. Печән һәм башка тупас азыкның 60 процентын да шундый җирләр бирә.

Бүгенге көндә сугарулы җирләрнең һәр гектарыннан уртача 60 центнер азык берәмлеге күләмендә уңыш алына. Алдынгы хуҗалыкларда исә ул 95 центнерга җитә. Авыл хуҗалыгы өчен хәзерге этапта иң зур проблемаларның берсе булган терлекчелекне сыйфатлы мул азык белән тәэмин итүдә сугаруның әһәмиятен дәлилләү өчен бүтән саннар кирәкми, миңа калса.

Мелиорация буенча зур перспектив план төзелде һәм ул тормышка ашырыла. Сугару өчен иң уңай басулар билгеләнде, бу эшнең белгечләре хәзерләнә. 1990 елга сугарулы җирләрнең уңышын 80 центнер азык берәмлегенә җиткерү һәм барлык терлек азыгының кимендә яртысын сугарулы җирләрдән алу бурычын куябыз. Билгеле, сугару минераль ашламаларны киң куллану, орлыкчылык хәлләрен яхшырту кебек чаралар белән бергә алып барылачак.

Мелиорацияләүне киңәйтүнең зур экологик әһәмияте барын онытмыйк. Димәк, кайчандыр саксызлыгыбыз аркасында зарарланган болыннарыбыз яшәрер, сулыкларыбыз күбәер, гомумән, туган җиребез ямьлерәк, баерак булыр...

**— Болары бүгенге чор кешеләрен, бигрәк тә яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсенә дә кагыла. Шул җәһәттән мәктәп реформасының да районда ничек тормышка ашырылуына тукталып китсәгез иде!**

— Дөресен әйткәндә, без аңа алдан әзерләнеп тордык. Районда балалар бакчаларының киң челтәре бар. Алар мәктәпләр белән бергәләп алты яшьлек балаларны мәктәпкә хәзерлиләр. 1982 елда мәктәпкәчә яшьтәге рус булмаган милләт балаларын рус теленә өйрәтү буенча Россия Федерациясе семинарының безнең район балалар бакчалары базасында уздырылуы да тикмәгә түгел иде. Чукоткадан һәм Кавказдан, Кола ярымутравыннан һәм ерак Көнчыгыштан, Алтайдан һәм Якутиядән килгән делегатлар балаларыбызның белеменә һәм күнекмәләренә сокландылар.

Хезмәткә өйрәтү, һөнәрле итү, тәҗрибә эшен оештыру өлкәсендә Смәел, Карадуган һәм Яңгул урта мәктәпләренең эше үрнәк булырлык. Алар республикабызда гына түгел, Союз күләмендә танылдылар. Балаларга коммунистик тәрбия бирү юнәлешендә эзлекле эш алып барабыз. Мәктәп реформасы безгә әлеге матур эшләрне тагын да киңрәк колач белән алып барырга мөмкинлек бирде. Реформа кабул ителгәннән соң өч сигезьеллык мәктәпне урта мәктәп итеп үзгәрттек. Бездә хәзер гаиләдән аерылып интернатта торып укучы балалар бик аз, якын елларда бөтенләй калмаячак.

Һәр мәктәпкә база предприятиесе һәм хуҗалыгы беркетелгән, алар белән мәктәп коллективлары арасында эшлекле хезмәттәшлек булдырырга омтылабыз. Бу мәсьәлә килешүләр нигезендә башкарыла.

Мәктәпләрнең һәм мәктәпкәчә тәрбия оешмаларының материаль базасын ныгыту — һәрвакыт игътибар үзәгендә. Урта һәм сигезьеллык мәктәпләребез барысы да диярлек яңа, заманча биналарга урнашкан. Якын елларда тагын берничә мәктәп салыначак.

Балалар бакчалары төзүгә дә игътибар зур. Без һәр елны балалар бакчаларын арттыра барабыз. Үткән елны Сасна авылында 90 урынлы балалар

бакчасын төзеп бетереп, ә Норма авылындагысын 50 урынга киңәйтеп һәм 140 урынга җиткереп каршыладык. Балтачта — 140, Кече Лызи авылында 90 урынлы бакчалар салына, якын елларда Арбор, Чепья, Смәел, Шубан кебек авылларда да төзеләчәк.

Мәктәп реформасын тормышка ашырып, яшьләребезгә белем һәм тәрбия бирүне камилләштерүдә без киләчәк уңышларыбызның ышанычлы нигезен күрәбез.

**— Соңгы елларда авылларның социаль йөзен үзгәртү буенча бик күп үзгәрешләр башланды. Бу мәсьәлә сездә ничегрәк хәл ителә?**

— Мин гел авылда яшәдем. Тормышымны туган якларымнан ерakta күз алдыма да китерә алмыйм. Авыл кешесенең хыялларын, омтылышын, борчуларын аңлыйм. Авылның үткәнен, бүгенгесен беләм. Аның киләчәгенә ышанам. Бигрәк тә соңгы еллардагы уңай үзгәрешләр күңелне сөендерә. Бу ямьләнүне мин иң беренче чиратта кешеләрдә, аларның күңеле, кәефе сафлануда, омтылышлары һәм киләчәккә уйлары матурлануда күрәм. Җир кешесенең ышанычы артты, ныгыды.

Көнкүреш һәм хезмәт шартлары күзгә күренеп яхшыра. Хәзер безнең яшьләрне авылда калдырырга тырышу проблемасы бетеп килә диярлек. Алар җиргә үзләре омтылалар. Үткән бишьеллык дәвамында гына да районда 578 гаилә үз хисабына яңа (нинди генә әле!) йортлар салып чыгуы шул турыда сөйләмимени?! Бу гаиләләрнең иң зур күпчелеге яшь, соңгы елларда гына оешканнар. Шул ук чор эчендә 800 дән артык хуҗалык үз йортларын киңәйткән. Колхозлар хисабына — 152, дәүләтебез, төрле предприятие һәм оешмалар хисабына йөздән артык квартира төзелгән. Йортларыбызның кәрнизләрендәге, тәрәзәләрендәге, капка-коймаларындагы бизәкләре үк аларда яшәүчеләрнең якты омтылышларын ачык күрсәтә кебек.

Бездә һәр бишьеллык дәвамында гаиләләрнең 20—22 проценты яңа йортларга күчә. Һәр йөз гаиләнең 10 сында — автомобиль, 28 ендә — мотоцикл, 59 ында — кер юу машинасы, 78 ендә — суыткыч, 91 ендә телевизор бар. Һәр йортта газдан файдаланалар. Партиябез һәм хөкүмәтебезнең авыл кешесе, аның тормышы, көнкүреше, хезмәте турында кайгыртучанлыгы бу саннарда ачык чагыла.

Районыбызда юллар төзү тәмамланып килә. Аларга асфальт түшн башладык. «Гидромонтаж» трестының Зәй участогы ярдәме белән райондагы 13 нче зур күперне төзүгә керештек.

Әйе, авыл яңара. Әмма төзү оешмабызның берәү генә булуы, юл төзү эшендә беренче проблемага әверелгән асфальт заводының булмавы һәм бу мәсьәләдә «Татавтодор» идарәсе җитәкчеләренең безне аңларга теләмәве, пассажирларга транспорт хезмәте күрсәтүнең начар торышы һәм Татарстан транспорт идарәсе җитәкчеләренең аны яхшыртырга омтылмавы бу яңарышны шактый тоткарлый.

**— КПССның XXVII съездын Балтач хезмәтчәннәре нинди нәтиҗәләр белән каршыладылар?**

— Районыбыз барлык күрсәткечләр буенча бишьеллык планнарын вакытыннан алда һәм арттырып үтәде. 1985 елга аяк басканда ук без инде ике айга якын унберенче бишьеллыкның соңгы елы хисабына эшләгән идек. Ирешелгәннәр — инде кичәге көн. Уңышлар турында сөйләүдән уңыш артмый. Шуңа күрә дә без күбрәк кимчелекләребез, аларның барлыкка килү сәбәпләре, бетерү юллары турында, файдаланылмаган резервларыбыз турында күбрәк сөйләшәбез. Хезмәт активлыгын көчәйтү, дисциплинаны ныгыту, һәр коллективның югары нәтиҗәле эшләвенә игътибар аерата көчле. Алдынгы коллективлар белән янәшәдә әле планнарны үз вакытында башкара алмаган коллективлар да бар.

Хезмәт дисциплинасының җитмәве — безнең алга баруыбызны тоткарлый торган иң ямьсез күренеш. Бу — файдаланылмаган резервларыбызны эшкә җигәргә комачаулаучы төп сәбәп. Сәбәбен ачыклый һәм чараларын күрә барганлыктан, мондый гадәтләргә чик куя алачагыбызга ышанабыз.

**— Хезмәт уңышларына, сезнең уегызча, әдәбият һәм сәнгать нинди өлеш кертә?**

— Мәгълүм ки, көр күңел белән башкарылган һәр эш нәтиҗәлерәк, куанычлырак, җиңелрәк була. Ә күңел көрлеге халкыбызның рухи байлыгы булган әдәбият һәм сәнгатьтән килә. Шуңа күрә дә әдәбиятка һәм сәнгатькә бөтен җаны белән тартыла безнең хезмәтчәннәребез. Һәр авылда өлкәннәрдән башлап мәктәп балаларына кадәр берләштергән үзешчән сәнгать коллективлары бар. Субаш авыл гөсләчеләрен һәм биючеләрен, Сасна авылы тальянчыларын, Карадуган ягы җырчыларын республикабызда яхшы беләләр. Даими эшләүче агитбригадаларны терлекчелек фермаларында, кыр станнарында һәм ындыр табакларында, җәйләүләрдә еш очратасың.

Яшь әдипләребез һәм композиторларыбыз район культура йорты каршындагы «Янар чәчәк» берләшмәсендә иҗат серләренә өйрәнәләр. Шагыйрь Илдар Юзеев фатихасы белән оештырылган берләшмә членнарының иң уңышлы әсәрләре район һәм республика матбугатында еш күренә, Казан телевидениесе аша яңгырый. Мин бу очракта Нәҗип Әминов, Чулпан Сәйфиева, Наил Гарипов җырларын, Заһид Мәхмүтов хикәяләрен, Фәридә Шакирова, Алсу Гайфуллина шигырьләрен күздә тотам.

Иҗат союзлары белән без тыгыз элемтәдә. Шагыйрьләр, танылган артистларыбыз бездә еш булып, хезмәт ияләре белән очрашалар. Татар дәүләт академия театры белән элемтәбез нык. Алар кайчак премьераларын да бездә үткәрәләр. Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең Җәвәһирә Сәләхова оештырган сәнгать университеты бездә даими эш алып бара.

Сүз дә юк, безнең уңышларыбызда аларның да өлеше зур.

**— Сез үзегез дә шигырьләр язасыз бит... Үткән ел шигырь китабыгыз басылып чыкты. «Керим әле урманнарга» кебек җырларыгыз популярлашып китте. Шигърияткә ничегрәк килдегез? Әдәби-иҗат дөньясы белән ничек бәйләндегез?**

— Кеше үзенең кичерешләрен, борчуларын, уйларын күңелендә генә саклый алмый. Бераүләр аны җыр белән уртаклаша, икенчеләр музыка коралларында уйный. Шулай итеп үз хисләрен башкаларга ирештерә, җанын бушата, күңелен күтәрә. Мин үз хисләремне шигырь юлларына салырга күнеккәнмен. Әмма аларны кешеләргә күрсәтү, укучыларга тәкъдим итү турында уйламадым.

Иҗат эшләре белән килгәч, мәрхүм Габдрахман ага Минский белән район колхозларында берничә көн йөрдек, урман, елга, күлләребезне күрдек. Кешеләр белән сөйләштек. Кешеләргә мөгамәләсендә сабырлык һәм олылык, ә табигать белән аралашканда эчкерсез сабыйлык бар иде анда.

Китәсе көнендә Габдрахман ага миннән, ни өчендер, кинәт кенә: «Ә син, Гарифҗан, шигырьләр язмыйсыңмы?— дип сорады. Әллә аның карашы, әллә сорауның көтмәгәндә бирелүе сәбәп булды, мин аңа үз язмаларымны бирдем. Атна-ун көн узгач, миңа телефоннан Хәсән ага Туфан шалтыратты һәм үзенә кунакка чакырды. Габдрахман абый минем язмаларымны, үзе укыганнан соң, Хәсән агага биргән икән...

Бу көтелмәгән вакыйгалар хәзер дә күңел түремдә. Хәсән ага өендә булган онытылмас очрашулар, язганнарымны аның хуплавы күңелемне күтәрде. Ул очрашуларны гомеремнең иң бәхетле көннәре, күңелемнең иң якын хатирәләре дип саныйм. Ә Хәсән аганың яшел каралы каләме белән «бизәкләнгән» язмаларымны кулга алган саен, иң изге нәрсәгә кагылгандай булам, аның ап-ак чәчләре, мөлаем йөзе, сынаулы ягымлы карашы күз алдыма килеп баса...

**— Районташларыгызга зур уңышлар, үзегезгә яңа хезмәт куанычлары, иҗат шатлыклары телибез.**

— Рәхмәт.

**Сәет Шәкүров**

# СӘХНӘНЕҢ КЫЛ УРТАСЫНДА...

ПОВЕСТЬ

## Маяклы юлда

*Маяклы юллардан юлчы бара,*
*печән белән күмгән чанасын...*

Һади Такташ

Кышкы төн. Салкын. Кырдан җәяүле буран йөгерә, күктә тонык ай йөзә. Йөгерек болытлар айның акшарлы йөзен сыйпап-сыйпап узалар сыман. Ай әле болыт астына кереп югала, әле ялт итеп яңадан килеп чыга. Маяклы юлдан олаучы чанасы гына түгел, әйтерсең ай үзе дә болытлар дулкынында тирбәлеп йөгерә шикелле!

Печәнгә күмелгән олаучы чанасы, ара-тирә чайкалып, үрәчәсе белән әле уңга, әле сулга килеп бәрелә. Бер як табаны күтәрелеп, чана чак кына аумый кала. Ләкин олаучы шунда ук икенче як үрәчәгә ятып өлгерә һәм чана янә тигез юлга чыга. Шулчак олаучы кулындагы чыбыркысы белән атына сыпырып ала. Ат, пошкырып, терек-терек юртып китә. Аның борын тишекләреннән чыккан бүрек-бүрек пар йомгаклары, аттан курыккан ак куяннар кебек, читкә атыла. Чанада олаучыдан тыш янә бер яшь егет бар. Ул, чана башына җилкәсен терәп утырган да, артка карап бара. Өстендә күн тужурка. Башындагы йонлач кепкасын күзләренә кадәр батырып куйган. Муенында киң калын шарф. Ул, сиртмәле бишектә тирбәлгәндәй, артта сузылып калган киртләч юлга гамьсез караш ташлап, йокымсырап бара. Ләкин белә: аңа йокларга ярамый! Йокыга китсә, өшүе бар. Өстәвенә, олаучының үз-үзен тотышы күңеленә нindидер бер шик сала.

Шәһәрдән чыгып китүләренә инде кимендә дүрт-биш сәгать вакыт үтте. Нindидер рус, татар авылларын да уздылар.

Соңгы авылны узганда бер генә өйнең дә тәрәзәсендә ут яктысы күренмәде. Димәк, вакыт ярты төннән авышкан. Шул вакыт эчендә олаучы абзый аңа ник кенә бер сүз катсын. Юкса егет аның белән сөйләшергә бик тырышып карады. Олаучы абзыйга әледән-әле төрле сораулар биргәләп барды.

— Абзый, синең исемең ничек? Мин үзем Мәхмүт булам. Фамилиям Габдуллин.

Ә бераз баргач янә сорады:

— Абзый, бу кайсы авыл? Син үзең кайсы авылныкы буласың?

Ләкин безнең әлеге Мәхмүт дигән егетебез олаучы абзыйдан үзенең

бер генә соравына да җавап ала алмады. Олаучы, әйтерсең, чукрактелсез иде.

Ул Мәхмүтнең аяк очынарак, калын брезент өстеннән сүс баулар белән уратылган йөк өстенә менеп утырган да төлке толыбының йонлач якасы эченнән алга карап тик бара. Аның толып якасын, бүрек камасын, сакал-мыекларын, хәтта каш-керфекләрен дә ап-ак бәс сарган. Каш-керфекләре астыннан елтыр күзләренең очкыны чагылып-чагылып кала. Ни гаҗәптер, аның як-якка боргаланулары, хәтта артына әйләнеп каранулары нәкъ менә ай болыт астына кереп тирә-юньгә караңгылык иңгәч кенә кабатлана. Берничә мәртәбә ул шул караңгыда кулы белән печән астыннан Мәхмүтнең аякларын да капшап карады бугай. Әйе, әйе, нәкъ шулай, караңгыда капшады. Ә инде ай болыт астыннан чыгып, төн яктырып киткән арада, яңадан урынында катып кала. Күзләре дә ялтырамый. Гүя аның күзләре гел йомык. Чынлап та, ни төсле соң әле аның күзләре?.. Үтер, хәтерләми Мәхмүт. Чөнки алар кичен караңгыда, «Широкий двор» тыкрыгында очрашып сөйләштеләр.

Ә ни өчен кич белән? Ни өчен караңгыда? Башка олаучылар, шәһәргә якын бер авылда кунып, шәһәргә иртәнге яктыда килеп керәләр һәм шәһәрдән шулай ук иртәнге яктыда чыгып китәләр ди. Саклык өчен. Ә бу?.. Бу исә яктыда бөтенләй күренмәде дә. Юкса Мәхмүт көндезен «Широкий двор» ишегалдындагы крестьян йортына кереп: «Алмай ягына кайта торган олаучы юкмы?» — дип сорашып йөрде. Анда җавап бирүче булмады. Инде кемне булса да табарына өметен өзеп, «Широкий двор»-ның тар, караңгы тыкрыгына чыккач кына аны арттан берәү дәшеп туктатты:

— Сиңа, егет, Алмайның үзенә кирәкме соң?

— Әйе, үзенә, абзый.

— Мин Алмайга биш-алты чакрым каларак Идел аръягына борылам. Телисең икән Алмай аша урап үтәргә була. Тик инде аның ул вакытта хакы да башкачарак булыр.

— Хакын түләрбез, абзый, эш хакта тормас.

— Ә күпме түләргә чамаң бар?

— Күпме сорыйсың бит?

— Ун таңка.

— О, кыйбатрак икән шул. Ун таңкага көз көне безнең эти кышлаган үгез сатып алып кайтып суйды.

— Алайса син әнә шул кышлаган үгезеңә генә утырып бар инде.

— Тукта әле, абзый, тукта!

— Вакытым тар. Мин сине кызганып артыңнан чыккан булам тагы...

— Ярый, синеңчә булыр, ун таңка.

— Акчаңны алдан түлисең. Чанага утыргач ук. Юкса синең кебек тар балакларга ышансаң, авызыңны ачып та калырсың.

— Түлим абзый, түлим.

— Алмайда кемнәрең бар соң?

— Анда безнең театр, артистлар.

— Алай икән... Димәк, син дә артист булып чыгасың инде болай булгач?..

— Әйе, артист, яшь артист.

— Теге капкорсаклы кулаклар турында кәмит күрсәтеп йөрүчеме?

— Ничек туры килә бит, абзый.

— Әйе, ничек туры килә: я син аларны, яки алар сине... Ярый, иртәгә кич, караңгы төшкәч, мине Печән базарындагы мәчет чатында көтеп тор, яме?

— Нигә караңгы төшкәч? Нигә иртәнге якта түгел?

— Иртән мин базардан йөк төйим. Аннан үз эшләрем дә бар. Син ашыксаң, иртән кит. Ә мин, караңгы төшкәч кенә юлга чыгам,— диде дә

борылып китеп барды. Мәхмүт ни әйтергә белми аптырап калды. Шулай да икенче көнне кич, караңгы төшү белән, саквояжын күтәреп Печән базары чатына чыгып басты. Шунда ук выжылдап аның янына тимер табанлы чана килеп тә туктады.

— Акчаң әзерме?

— Менә, ал,— диде Мәхмүт.

Олаучы акчаны тиз генә бөтәрләп, кесәсенә тыкты.

— Әйдә, утыр, киттек. На, малкай!

Мәхмүтнең утыруы кая, олаучы, атына берне тамызып, кузгалып та китте. Кем бу, кая китә, кемгә утырып бара, Мәхмүт кызыксынмады. Олаучы, толыбына төренеп утырган килеш, кымшанмыйча диярлек барды да барды. Тик менә төн уртасы авышып, юлда җәяүле буран көчәя төшкәч, олаучы үзен ничектер сәер тота башлады. Як-ягына ешрак карана, куллары белән нәрсәдер капшана...

Кинәт чана үрәчәсе тирән бер чалуга килеп бәрелде! Мәхмүт чана башыннан очып төшеп кар өстенә тәгәрәп китте, ләкин шундук сикереп торып, кычкыра-кычкыра чана артыннан йөгерде.

— Тукта, тук-та, дим!

Кая ул! Олаучы борылып та карамады, атын чыбыркы белән чарлый-чарлый чаптырып, күздән югалды. Мәхмүт чана артыннан йөгергәндә, юлдагы саквояжына сөртенеп егылды.

— Ах, менә ничек!.. Димәк, чалудан файдаланып, ул аны чанадан төртеп төшергән. Акчасын алып качу өченме? Алайса нигә саквояжны ташлап калдырган? Аңлашылмый. Сәер кеше булып чыкты бит әле бу олаучы.

Мәхмүт, юл уртасына утырды да, тамагына килеп тыгылган төерен йота алмый кинәт кычкырып елап җибәрде.

Үксеп-үксеп, үпкә катыш үкенү, ачу, ачыргалану белән елады ул. Аның күптән, сабый вакытыннан бирле, инде болай елаганы юк иде. Әтисенә, әнисенә сабыйларча үпкәләп, аларның үгет-нәсихәтләрен тыңламыйча, әр-каргышларына колак салмыйча, алардан качып үзенең бу сәфәргә шулай кинәт чыгып китүенә үкенеп, өзгәләнеп елады ул. Аннан, кинәт кенә сикереп торды да, саквояжын кочаклап йөгерә башлады. Тирләп-пешеп чыкканчы, тәмам хәлдән тайганчы йөгерде. Ләкин кая йөгерә? Кай тарафка? Ни өчен? Бу турыда баштарак уйламады.

Күктәге айны күптән инде болыт каплаган. Шомлы караңгылык куерганнан-куера бара. Җил ыжгыра, аяк астында җәяүле буран котыра, юлга тыгызлап кар сала. Ачы җил күн тужурка аша җелекләргә үтеп керә.

Йөгерү түгел, атларлык та хәле калмады Мәхмүтнең. Ул алга сөрлекте һәм, юлдан читкә тайпылып, маяк төбенә өелгән тирән көрткә чумды. Маяк! Салам көлтәсеннән учма итеп бәйләп утыртылган маяк. Көрттән учманың очы күренеп тора. Мәхмүт маяк әйләнәсендәге карны казып кереп, маякны кочаклап, кар эченә ята. Шунда аңа кинәт җылы булып китә. Тәненә рәхәт ою тарала, кул-аяклары кызыша, үзе шабыр тиргә бата. Ләкин ул сизә: аңа маяк төбеннән чак кына да читкә тайпылырга ярамый. Әнә бит, әйләнә-тирә дөм караңгыга күмелде. Димәк, таңга ерак түгел. Таң белән кем дә булса чыкмый калмас, чыгар. Кем дә булса шушы маяклы юлдан узмый калмас, узар. Мәхмүт аңа каты итеп менә болай кычкырыр:

— А-а-а-у!

Ләкин бу ни хәл? Кычкыра — тавышы чыкмый. Бөтен дөнья тынып калган. Нәрсә бу? Тавышы югалганмы, әллә үз тавышын үзе ишетмиме? Әнкәй... Әнием!!! Әллә синең каргышың төштеме миңа?.. Шулай бик тиз? Әле бит кичә генә... Әнисе үзенең бердәнбер улын йөрәк ачыйгысы белән каргарга мәҗбүр булды. Гомерендә беренче мәртәбә каргады ул үзенең газизен. Өметләре киселгән, бүгенгесе һәм киләчәге кинәт чәлпәрәмә килгән ана нишләргә тиеш иде соң? Әтисе кебек дулап аның өстенә таш-

лана, аны уңлы-суллы яңаклый, кулыннан селтәп баскычтан тибеп төшерә ала идеме?

Ләкин кая ул? Әтисенең күзенә ак-кара күренми иде. Ул икенче катның парадный баскычыннан Мәхмүтне генә типкәләп төшермәде, артыннан аның барлык әйберен, кием-салымын, китапларын да урамга томырды. «Моннан соң бусагамны атлап керәсе булма!»

Һәм Мәхмүт китте. Аның китәр юлы күптән билгеләнеп куелган иде инде. Саквояжы күптән тутырылган. Ләкин ул болай китәргә теләмәгән иде. Татулык, ризалык белән, хушлашып-саубуллашып китәргә теләгән иде. Булмады...

Тукта?.. Ничек болай килеп чыкты соң әле бу? Нигә туып-үскән йортыннан, ата-анасыннан шулай кинәт аерылып китте Мәхмүт?.. Өстәвенә зур җәнҗал белән? Кинәт микән? Чынлап та, кайчан башлады соң әле бу — ата белән ул, ана белән бала арасындагы низаглар?.. Кичә генәме? Юк. Былтырмы? Былтыр гына да түгел. Күптән, бик күптән. Мәктәп елларыннан ук. Һәм ул еллар, юлдагы җәяүле буран кебек, менә хәзер яңадан аның күз алдыннан берәм-берәм йөгерешеп уздылар...

## Йөгерек уйлар кайта үткәнгә

Балачагы авыр елларга туры килүгә карамастан, Мәхмүт мохтаҗлыкның ни икәнен белмичәрәк үсте. Өстәвенә, гаиләдә бердәнбер бала буларак, ул гаять дәрәҗәдә иркә иде. Җаны теләгәнен ашады, күңеле теләгәнен киде. Кая теләсә — шунда барды, кемне якын күрсә — шуның белән уйнады. Аның дуслары арасында бай сәүдәгәр уллары да, итекче-читекче малайлары да, дворник балалары да бар иде. Дворник балаларына кыш көннәрендә кар көрәшә, язын тротуар бозларын ватыша иде. Арып, ачыгып, буялып-юешләнеп кайткан вакытларында әнисе сукрана башласа, әтисе сүз әйттерми. «Дәшмә, эшләсен, эшләп үссен. Эшнең гарьлеге юк, мин үзем дә эшләп кеше булдым»,— дия торган иде.

Чыннан да, аның әтисе Габидулла абзый Казан артындагы авылларның берсендә, көч-хәл белән очын-очка ялгап баручы крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә. Уникē яше тулар-тулмаста ул шәһәрдәге бер бай сәүдәгәргә йомышчы малай булып яллана. Унсигез яшенә кадәр ул бәйдә «чәче белән җир себерә». Аннан сәүдә эшенә өйрәнә. Үзлегеннән укып язу-сызу, санау-хисаплау кебек четерекле эшләрне үзләштерә. Башта приказчикның өйрәнчеге, аннан приказчикның үзе, һәм ниһаять, өлкән приказчик булу дәрәҗәсенә кадәр үсеп җитә! Моңа ул, әлбәттә, байның кече кызы Минзифа туташ ярдәмендә ирешә. Яшерен-батырын түгел, үзсүзле, наян Минзифа туташ үзләрендәге Габидулла атлы приказчикка яшьтән үк гашыйк була. Гашыйк булмаслык та түгел, Габидулла искиткеч чибәр егет! Буй-сын, төс-бит коеп куйган диярсең. Минзифа туташның әтисе Сафа бай, рус купецлары белән аралашып яшәгәнлектән, Ташаяк һәм Мәкәрҗә ярминкәләрендә кибетләр тота, үзенең приказчикларын европача киендерә. Эчтән жилетлы кара костюм-тройка, крахмалланган ак яка, ак манжет, кара бантик. Шуның өстенә кара кәләпүшен кырын салып та җибәргәч, күз явын алырлык була Габидулла приказчик. Шаян, җор, хәтта мутлык та бар үзендә. Борын астындагы каш каләме кебек сызылып киткән тар гына кара мыегын сыпырып, күз кысып та җибәрсә — үл дә кит...

Шуңа күрә чытыр ябышты Минзифа туташ егеткә. Түгәрәк сакаллы, кырпу бүрекле бер бай сәүдәгәргә тотып бирүләреннән куркып, мәсьәләне кабыргасы белән куйды: я аны үзе теләгән Габидулла приказчикка бирәләр, я ул туган апасы Гөлчирә туташка ияреп Мәкәрҗә ярминкәсенә китә дә анда туган апалары белән бергә театр уйнап йөрүче озын чәчле мыексыз бер җәдиткә кияүгә чыга.

Алла сакласын берүк, Сафа бай бу хурлыкны күтәрә алачакмы соң? Дөньялар болганып тора. Әнә, Кабан күле мәдрәсәсеннән бер төркем шәкертләр, үзләренең хәлфәләрен мәсхәрәләп, мәдрәсәне ташлап чыккannар. Учительски школада урысча укып йөрүче жыен тар балак, гәҗит белән тамак туйдыручы җәдитләр, курсистка кызлар, Шәрык клубына җыелып музыйкан уйныйлар, җырлыйлар, театрлар куялар икән. Әнә, Сафа байның агасы Мөхәммәтҗанның бердәнбер кызы Гөлчәһрә шунда йөреп бөтен нәсел-ыруны хур итте. Башта музыйкан өйрәнеп, җырлаган булып йөрде. Торә-бара театр уйнарга ук катнаша башлады, ахырында шома табанлы бер ач артистка кияүгә чыгып үзе дә артист булып китте. Әйтте Сафа бай агасы Мөхәммәтҗанга, еландай телләрен чыгарып әйтте: «Йөртмә кызыңны ул тирәдә, бирмә кыз балага ирек»,— диде. Юк, тыңламады агасы, көлде генә. Хәзер, шул Гөлчәһрә тутасына ияреп, Минзифа да театрларга йөри башлаган. Дөрес, ул әлегә шул көяз приказчик Габидулла белән бергә йөри ди театр дигәннәренә. Алла сакласын, хәзерге яшьләргә ышаныч юк, әгәр дә аның теләгенә каршы килә башласаң, китәр дә барыр шул Мөхәммәтҗан аганың азгынына ияреп. Монысы — мәсхәрәнең дә мәсхәрәсе булачак.

Ә инде бай кызларының приказчикка кияүгә чыгуы бер аларда гына булган эш түгел. Андый хәлләр калада байтак булгалый. Аннан килеп, приказчигы да төшеп калганнардан түгел. Бармагыңны сузсаң — терсәге-ние белән кабып йотарга тора. Андыйларга ышанырга мөмкин, андыйларда өмет зур. Шулай уйлады Сафа бай һәм, аллага тапшырып, кызы Минзифаны үзенең приказчигы Габидуллага кияүгә бирергә булды. Болай эшләү аның өчен икеләтә отышлы иде.

Беренчедән, төпчек кызын заман шаукымына ияреп китүдән саклап кала, икенчедән, үзенең коммерция эшен арзанлы һәм ышанычлы хезмәткәр белән тәэмин итә.

Ләкин байның бу җименә алай бик җиңел генә капмады Габидулла приказчик. Илтифат итеп үз гаиләләренә алулары өчен кулын күкрәгенә куеп рәхмәт әйтте һәм шунда ук үз шартларын да куярга онытмады: киләчәктә бер түбә астында яшәү яшьләр өчен дә, олылар өчен дә уңай булмас, шунлыктан аларның беренче уллары, ягъни Сафа байның оныгы дөньяга килү белән үк аерым йорт салып, аларны башка чыгару һәм көтеп алган онык исеменә калада бер кибет ачып, Габидулла кияүгә мөстәкыйльлек бирү шарты иде. Шәп бит, әй! Болай булгач Сафа бай үзе салган җимгә үзе үк килеп капты дигән сүз. Ләкин нишләмәк кирәк, килешми чара юк. Шунлыктан озакка сузмыйча, никах укыттылар һәм шаулатып туй да иттеләр. Ләкин өметне, киләчәкне үзенә баглаган беренче бала алай тиз генә килмәде дөньяга. Ниләр генә эшләмәделәр, кая гына җитмәделәр. Духтырда, профессорда, багучыда булуларның файдасы күренмәде.

Ниһаять, никахтан соң нәкъ биш ел үткәч, дөньяга көтеп алган ир бала — Мәхмүт туды. Вәгъдә буенча Аккомасты урамында Габидулла приказчикка ике катлы йорт салып бирделәр һәм Балык базары рәтендә бакалейный ачтылар. Шул көннән башлап Габидулла приказчик булып түгел, ә мөстәкыйль хуҗа булып үз кибетендә җиң сызганып сәүдә итәргә кереште.

Революция дулкыннары аны берничә елга тынып торырга мәҗбүр итте. Ләкин озакка түгел. Тиздән, НЭП башлану белән үк, Габидулла үзенең сәүдә эшен яңадан һәм яңача җәелдереп җибәрде.

Габидулла белән Минзифаның Мәхмүттән башка бүтән балалары булмады. Шунлыктан Габидулланың бөтен өмете Мәхмүттә иде. Ул аңарда үзенең ярдәмчесен, озак һәм авырлык белән булдырылган дәүләтенең таянычын, инанган эшенең дәвамчысын күрәсе килгән иде. Ләкин... Ләкин ул дигәнчә барып чыкмады.

* * *

Мәктәптә укыган елларында ук Мәхмүткә кәмит уены — театр җене кагылды. Барысына да шул Минзифаның тутасы Гөлчәһрә белән аның ире артист Ашманский сәбәпче булдылар.

Мәктәпкә кергәнче үк Мәхмүт туган апасы Гөлчәһрә ханымга ияреп театрга йөрде. Сәхнә артында артистлар белән шаярды, грим бүлмәләрендә туган апасының, Ашман җизнәсенең грим салганнарын, киенүләрен кызыксынып күзәтеп тора торган булды. Кайвакыт җизнәсе аңа күзгә алдында парикларын кидереп, Мәхмүтнең кечкенә битенә сакал-мыеклар ябыштырып күрсәтә. Мәхмүт күзгедәге кыяфәтенә карый да эче катып көлә. Ә инде спектакль башлангач, Мәхмүтне сәхнә читенә урындык куеп, шунда утырталар. Ул шунда сәхнәдә барган күренешне балаларның үзләренә генә хас булган җитдилек белән, пәрдә төшкәнче тын да алмыйча диярлек карап утыра. Ә инде өенә кайтып йокларга яткач, театрда күргәннәрен, хәтта спектакльнең үзе аңлаганча эчтәлеген әнисенә пышын-пышын сөйләп чыга. Әтисенең моңа ачуы килә. «Йөртмә баланы шуларга ияртеп, җүнлегә булмас бу!» — дип әнисенә кисәтү ясый. Ләкин кая ул! Кич булдымы, Мәхмүтнең күзләре тәрәзәдә. Бүген тагы театр буламы, туган апалары аны бүген дә театрга алып бараларммы?..

* * *

Ашманскийларның өйләре Аккомастында, Мәхмүтләрдән өч-дүрт йорт аша гына иде. Алар анда Гөлчәһрәнең әтисе белән әнисе кинәт бер-бер артлы үлеп киткәч, Мөхәммәтҗан картның башка балалары булмаганлыктан, нигез таралмасын дип, Төркстан кадәр җирдән кайтып урнашырга мәҗбүр булдылар. Төркстан шәһәрләренең берсендә алар, җирле театр оештырып, әйбәт кенә төпләнеп яши башлаганнар иде.

Ашманскийларның яшьлек еллары «Сәйяр», «Нур» труппаларында баш өстендә түбә күрергә мохтаҗ булып, ачлы-туклы һәм ярым-ялангач хәлдә Россия шәһәрләре буйлап халыкка спектакльләр күрсәтеп йөргәнлектән, үзләренең шәхси тормышларын корып, бала тудыру һәм бала үстерү бәхетенә ирешә алмадылар. Шунлыктан алар балаларны аеруча яраталар иде. Җәй җиттеме, барлык күрше-колан, туган-тумача балалары шуларның ишегалдында чыр-чу килә. Балаларның үз телләрендә, үзләрен балалар белән тиң итеп, аларның дуслары булып, кайвакыт балаларча җитдилек белән көнкүреш һәм әхлакый мәсьәләләр турында сүз алып баралар, «фикер уртаклашалар», «киңәшәләр», ә кайвакыт әйлән-бәйлән уйныйлар, җырлыйлар, бииләр.

Бу, үзеннән-үзе оешкан «ишегалды балалар бакчасы» алар тормышының китек бер почмагын тутыра кебек иде.

Мәхмүтнең исә бу «бакча» үзенеке. Ул монда башлап йөрүче, хуҗа. Ләкин туган апалары аңа «хуҗа» булып масаерга, мактанырга, үзен башка балалардан өстен тотарга ирек бирмиләр, һәрдаим аның итәгеннән тартып, колагына пышылдап кына торалар.

Ләкин шулай да аңа монда рәхәт. Ул монда бәхетле. Монда ул үзен һавадагы кош шикелле сизә, хыяллары күккә аша. Аның әллә ниләр эшлисе килә. Тора-бара аны түгәрәк уйнау, җырлау-биюләр генә канәгатьләндерми башлый. Чөнки бу вакытта Мәхмүт һәм аның иптәшләре шактый үсә төшкәннәр иде инде. Балалар бакчасына йөрү яшеннән узып, яңа ачылган «совет мәктәбе»нең кайсы беренче, кайсы икенче сыйныфында укый башлаганнар иде.

Көннәрдән бер көнне Мәхмүт җизнәсеннән: «Ашман абый... (аны бөтен балалар да шулай дип атыйлар. Театрдагы дуслары, белеш-танышлары, күрше-коланнары да Ашман дип кенә йөртәләр. Аның чын исемен әйткән дә, белгән дә кеше юк.) Ашман абый, әйдә, театр-театр

уйныйбыз. Син минем этием буласың, ди, туган апа әнием, Тәнзилә минем сеңлем булыр. Башка балаларга да роль табарбыз... Нигә, кызык ич?!»

Әйе, кызык. Кызык кынамы соң? Белә бит Ашманскийлар, күрәләр, тоялар: алар ишегалдына йөри торган балалар арасында гаҗәеп сәләтләре бар. Хискә, хыялга байлар. Музыканы ишетәләр генә түгел, бөтен күңелләре белән тоялар. Шул ук Мәхмүтне генә алыйк: нинди талантлы малай. Фантазер. Берәр нәрсә уйлап чыгарып сөйли башласа, тыңлаучыларны гына ышандырып калмый, үзе дә шуңа ышанып, күреп, ишетеп сөйли... Ә күзләр!.. Сөйләгәндә күзләре ничек януын күрсәң иде син аның. Әйтерсең, чын артист! Тәнзиләсе тагын, Нәсимәсе, Хафизы, Сәлиме?.. Ныклабрак уйласаң, бу балалар безнең театрыбызның киләчәге булырга мөмкин. Нигә, шулай түгелмени? Үз театрының бүгенгесе, киләчәге өчен яна белүче артист буларак шулай уйларга тиеш түгелмени алар? Ул көнне кич буе шул турыда уйлап, сөйләшеп, бәхәсләшеп, хыялланып чыкты Ашманскийлар. Ә иртәгесен...

Иртәгесен иртүк торып театрдан ике сәхнә эшчесе алып килде дә Ашманский, ишегалдындагы зур сарайдан Мөхәммәтҗан картның хәзер инде кирәге беткән арбаларын, чаналарын, тарантасларын, камыт-дуга һәм башка сбруйларын ишегалдына чыгарып өйдерде. Сарай түренә сәхнә ясатты. Сәхнә артында бераз урын калдырыл, аңа арт яктан ишек уйдырды. Янәсе, «артистлар»ның грим бүлмәсе.

Тамаша залы турында да онытмады Ашманский. Аңа да шактый урын калдырып, озын-озын эскәмияләр кадаклатты. «Театр» бинасы булгач, тамашачысы да булыр. Әйтик, «артистлар»ның энеләре, сеңелләре, абыйлары-апалары, әгәр бик телиләр икән, әни-этиләре, әби-бабайлары килер. Әйдә, килә бирсеннәр. Күңел иркен булса, урын табылыр.

Ике көн эчендә «сәхнә» һәм «тамаша залы» эшләнеп тә бетте. Тышкы яктан сарайның капкасына зур хәрефләр белән «Театр» дип язып та куйды Ашманский. Шул арада Гөлчәһрә ханым үзенең әле «Сәйяр»дан ук калган иске күлмәкләрен сүтеп, пәрдә һәм ак марля кисәкләреннән сәхнәнең ян-якларын, дивар-түшәмнәрен каплау өчен чаршау, кашага кебек нәрсәләр текте. Шулай итеп, «ишегалды театры»ның бинасы үзенең беренче тамашачыларын кабул итәргә әзер!

Ләкин тамашачыларга кадәр хәл итәсе мәсьәләләр байтак иде әле. Шуларның беренчесе һәм иң мөһиме — репертуар. Балалар өчен әле ул вакытта сәхнә әсәрләре язылмаган. Алардан «Беренче театр»ны уйнатып булмый. Нишләргә?

Күп уйлап тормады Ашманскийлар, икәүләшеп Габдулла Тукайның «Таз малай»ын сәхнәләштерергә керештеләр. Мәхмүт капка төбенә чыгып бер сызгыруга, «труппа» җыелып та өлгерде. Башта аларга Гөлчәһрә ханым әсәрне кычкырып укып чыкты. Балалар эчләре катып көлә-көлә тыңладылар. Аннан Ашман абыйлары рольләрне бүлеп бирде. Таз малайны — Тәнзилә, Хәлфәне Мәхмүт уйнарга тиеш булды.

Башланды репетицияләр. Мөхәммәтҗан байның элеккеге ат сараенда балалар көне буе чыр-чу килеп торды.

Ниһаять, зарыгып көткән көн килеп тә җитте. Спектакль башланырга бер ун-унбиш минут кала, «тамашачылар» килә башлады. Аларны ишегалдында, зур кунакларны каршылаган кебек, Гөлчәһрә ханым үзе каршы алды. Кунаклар утырышып бетеп, зал тынып калгач, сәхнә алдына Ашманский чыкты:

— Хөрмәтле эти-әниләр, апалар-сеңелләр, әбиләр-бабайлар! Бүген без сезгә сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның «Таз малай» исемле әсәре буенча эшләнгән беренче спектаклебезне күрсәтәбез.

Ашманский кайсы рольне кем уйнаячагын әйтеп чыкты, артта музыка (гармун һәм мандолина) уйный башлады. Ике бала ике яктан пәрдәне тартып ачты. Спектакль башланды.

Башкаручылар ничек кенә тырышмасыннар, барыбер сәхнәгә чыгу белән, тамаша залыннан үзләренең якыннарын эзләп табарга тырыштылар. «Мин ничек. әйбәт уйныймны?» — дигән сыман аларга карап, эчтән генә мактанып алдылар. Тамаша залыннан да әледән-әле: «Кара-кара, монысы безнең Гомәр ич! Кара, тегесе Зәйтүнә түгелме соң, малай булып киенгән?» — кебек сүзләр ишетелеп торды.

Ләкин, ничек кенә булмасын, беренче спектакль күңелле узды.

Спектакльдә Мәхмүтнең әтисе Габидулла белән әнисе Минзифа ханым да бар иде. Ашманскийлар театрдан үзләренең дус артистларын да чакырганнар иде. Спектакльдән соң алар тиз генә кайтып китмәделәр. Беседкадагы самавыр янында бик озак үзләренең спектакльдән алган тәэсирләре белән уртаклашып утырдылар. Артистларның һәркайсы Мәхмүтне башыннан сыйпап мактады һәм киләчәктә аннан зур артист чыгачагы турында әйтте.

Габидулла ага табында бу «афәриннәр»гә кәефе килгән кебек, мыек астыннан елмаеп кына утырса да, өйгә кайткач мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Житте,ша!.. Моннан соң баланы ул шома табаннар янына жибәрмисең. Әртист чыга имеш. Чыкмый торсын! Күп күргән мин ул ач әртистләрне Мәкәржә ярминкәсендә, күп туйдырган «обжорка»га алып кереп. Инде мин гомер буе үз өемдә, үз әртисемне туйдырырга тиеш буламмыни?... Вакытын кая куярга белмәсә, әнә, минем янга кибеткә жибәр, аз-азлап сәүдә эшенә өйрәнер, кул астына керә башлар. Хәзер приказчик та, хезмәткәр дә тота торган заман түгел. Киләчәктә ул дәвам иттерергә тиеш минем эшне.

Ләкин ничек кенә дуламасын, Мәхмүтне барыбер кибеткә йөртә алмадылар. Качып-посып булса да, Ашманскийларның «ишегалды театры»на йөрүен дәвам итте Мәхмүт.

Әмма әтисе Габидулла да тешләгән жиренннән өзмичә туктый торганнардан түгел иде. Бер көнне, көпә-көндез, кибетен бикләп Ашманскийларга килде. Күңеле сизгән икән — сарайда мәж килеп «театр» уйныйлар. Сәхнәдә Мәхмүт тавышы. Ачудан әтисенең йөзе зәңгәрләнеп килә, күзләрен кан баса. Акны-караны күрмәс дәрәжәгә житеп, эчтән элгән сарай ишеген жен ачуы белән ике якка каерып ача да, эскәмияләрдә утырган карт-корыны, бала-чаганы як-якка бәреп, туп-туры сәхнәгә менә. Куркуыннан югалып калган Мәхмүтне колагыннан эләктереп уңлы-суллы яңаклый. Аннары жилтерәтеп алып чыгып китә. Бу хәлне күреп, өнсез калган Ашманскийлар, тиз генә үзләрен кулга алып, аңа ташланалар: «Бу нишләвегез, Габидулла кияү?! Акылдан шаштыгызмы әллә, жибәрегез, үтерәсез бит баланы!»

— Якын килмәгез! Үзегезне тотып яңакларга да күп сорамам, әгәр моннан соң да баланы аздырып йөрисе булсагыз. Шуны белегез: бүгеннән соң ул монда аяк та басарга тиеш түгел. Һәм үзегез дә минем бусагадан атлап керәсе булмагыз!

Алар «Шүрәле» спектакленең беренче премьерасын уйныйлар иде. Көтмәгәндә... Әйтерсең, аяз көнне яшен сукты, барысы да сүтелде, таралды, челпәрәмә килде.

Ул көнне Мәхмүт төне буе йоклый алмый елап чыкты. Ачынып, әрнеп, гарьләнеп елады ул. Бу хәлдән соң иптәшләренең күзенә ничек күренер?

Бу хәлләрдән соң Мәхмүтнең әтисе генә түгел, аның дуамаллыгын күргән башка әти-әниләр дә балаларын бүтән монда жибәрмәячәкләр иде. Һәм шулай булды да. Ләкин балалар күңеленә Ашманскийлар салып өлгергән очкын сүнмәде. Ул үзенең килер көнен көтеп, күңел түрендә тыныч кына пыскып яши бирде.

* * *

Ул көн озак көттермәде. Килде.

Мәхмүт дүртенче класста укый иде. Мәктәпнең ике залын бергә куштылар да, бер башына сәхнә ясап, клуб иттеләр. Клубта төрле түгәрәкләр, шул җөмләдән драма түгәрәге оештырылуы турында да игълан чыгарып элделәр. Билгеле, Мәхмүт беренчеләрдән булып үзен драма түгәрәгенә алуларын сорап пионерлар вожатыена мөрәҗәгать итте. Түгәрәккә бишенче-җиденче класс укучылары гына чакырылганлыктан, вожатый Мәхмүтне язмады. Моңа кадәр канатланып йөргән Мәхмүт еларга җитеште.

— Мәктәпкә бер ел соңарып бирүләренә мин гаеплемени? Мин Таз малайны да, Шүрәлене дә уйнадым.

Вожатый көлеп җибәрде. Мәхмүтне кочаклап алып башыннан сыйпады:

— Елама, җүләрем минем, тынычлан. Алабыз, алабыз сине! Менә, исемлекнең башына ук язып куям.

Шулай итеп, мәктәп драма түгәрәгенә йөри башлады Мәхмүт. Түгәрәк белән ул вакытта җиденче класста укучы бер яшүсмер җитәкчелек итә иде. Һади Такташның «Күмелгән кораллар»ын өйрәнә башладылар. Мәхмүткә малай ролен бирделәр.

Мәктәптә уздырылган кичә-концертларда күпме декламация ятлап сөйләде ул кышны Мәхмүт. Бер генә кичәдән дә калдырмыйлар иде аны. Икешәр-өчәр мәртәбә сәхнәгә чакырып чыгаралар. Билгеле инде, һаман бер үк декламацияне кабатламый Мәхмүт. Чыккан саен яңаны сөйли. Каян таба да, кай арада ятлап өлгерә диген син аны?

Чыннан да, шул кадәр матур, кызыклы, сөйләр өчен ансат булган шигырьләрне эзләп табу җиңел эш түгел иде Мәхмүткә. Ләкин аның туган апасы, Ашман җизнәсе бар. Әтисе ничек кенә тырышмасын, Мәхмүтне алардан барыбер аера алмады. Әтисеннән качып, бакча-коймалар аша йөрүен дәвам итте. Бары тик аларда гына таба иде ул үзенә кирәк җан азыгын, күңел рәхәтлеген.

Үз заманының шагыйрьләре белән дә бик дус яшәде Ашманскийлар. Әйтик: Такташ, Кутуй, Туфан, Борнаш кебек шагыйрьләр белән бер-берсенә чәй мәҗлесләренә йөрешеп, төннәр буе түгәрәк өстәл артында иҗади бәхәсләр алып бара торганнар иде. Гөлчәһрә ханым үзләренең кечкенә энеләре турында да сөйли торган иде шагыйрь дусларына. Алардан энесе өчен махсус шигырьләр язып бирүләрен үтенә иде.

Шулай көннәрдән бер көнне Мәхмүт аларга килгәч:

— Менә, кичә Такташ абыең сиңа нинди матур шигырь бүләк итте. Укып кара, ошыймы? — диде.

Ошамыймы соң! Такташ абыйсы язсын да, ошамасын!

Мәхмүт шигырьне кат-кат укыды, аны ятларга ук кереште. Шунда аңа Ашман абыйсы:

— Тукта, Мәхмүт, син бер вакытта да шигырьне алай тиз ятларга ашыкма. Башта аның мәгънәсен аңларга, әйтергә теләгән фикерен тотып алырга тырыш. Шигырьнең һәр юлына, хәтта һәр сүзенә фикер салынган була. Син аның аһәңен, музыкасын бөтен җаның-тәнең белән тоярга, шигырьнең эчке дөньясына үтеп керергә тырыш. Шул вакытта гына син аны дөрес аңлап, түкми-чәчми, тыңлаучының күңел түренә илтеп җиткерә алырсың.

Ашманский, дөньясын онытып, үзе дә арып хәлдән тайганчы, еш кына шигырь уку техникасының четерекле якларын төшендерергә керешә:

Кыш, буран, салкын һава,
Яфрак кадәрле кар төшә.

Дикцияне, ирен хәрәкәтләрен чарлау өчен бу юлларның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен Ашман абыйсы җентекләп аңлата. Кар бөртеге... Нигә

ул көчле җил белән тартыша? Нигә, җиңел генә җил иркенә бирелеп, билгесез бушлыкка очып китми? Нигә фәкать җиргә төшәргә тартыша? Җиргә төшеп җирне сугару өчен. Ул сугарган җирдә бодай, чәчәкләр, һиһаять, урманнар үсеп чыккан. Аның максаты зур, изге. Шуңа күрә аны көчле җилләр каядыр очыртып юкка чыгара алмый. Ул барыбер җиргә төшә.

Мәхмүт мәктәп драма түгәрәгенә йөрүенең беренче елында ук уңыш казанды. Аны «артист» дип кенә йөртә башладылар. Мәхмүт өчен хәзер шуннан да зур бәхет юк.

Икенче елны, Мәхмүт бишенче класска күчкәч, мәктәп драма түгәрәге җитәкчесе әле Казанда узган ел гына ачылган театр техникумына укырга керде. Әле бишенче класста гына булуына карамастан, бертавыштан аны драма түгәрәгенең җитәкчесе итеп сайлап куйдылар. Чөнки ул барсыннан да дәртлерәк иде. Аңа ышаналар, аны тыңлыйлар, аны яраталар.

Менә шунда инде аның эшчәнлеге ныклап башланды. Үзе уйнады, үзе спектакльнең режиссеры, үзе художнигы булды.

Гәрчә дүртенче генә класста укыса да, Тәнзиләне дә алды ул драма түгәрәгенә. Чөнки Тәнзилә өлкән класс кызларына караганда әйбәтрәк уйный, ул да Ашман абыйсының мәктәбен үткән һәм шуның өстенә... ул Мәхмүткә нәрсәсе беләндер якын. Бик якын. Көн саен мәктәпкә барышлый Мәхмүт аны капка төпләрендә көтеп ала һәм кайтканда өйләренә кадәр озатып куя.

Мәхмүтне тора-бара «түгәрәк» сүзе генә канәгатьләндерми башлый. Ул, вожатыйлар белән киңәшеп, мәктәп директорының фатихасын ала һәм драма түгәрәге исемен «мәктәп театры» дигән исемгә алыштыра.

Алтынчы-җиденче классларда инде алар «мәктәп театры»ның афишаларын, катнашучыларның, режиссер, художник, композиторларының фамилияләрен күрсәтеп афишалар чыгара башлыйлар.

Хәтта алар мәктәп театрының күп кенә артистларына исемнәр дә биреп бетергәннәр иде инде. Берсе «мәктәп театрының атказанган артисты», икенчесе «мәктәп театрының атказанган сәнгать эшлеклесе», өченчесе... Ә Мәхмүт үзен афишага «Мәктәп театрының художество җитәкчесе һәм баш режиссеры — мәктәпнең атказанган сәнгать эшлеклесе Мәхмүт Абдуллин-Аккомский» дип бастыра иде. Балалыкмы?! Була бирсен. Шул балалык хыялы канатында очынып яшәде дә инде Мәхмүт мәктәптә уку елларында.

## Беренче мәхәббәт

Көтмәгәндә аңа тагы бер канат өстәлде. Җиденче класста укый иде Мәхмүт. Шулай бер көнне кичке репетициядән Тәнзиләне капка төпләренә озатып куйгач һәм инде капканы ачып керә башлагач, Мәхмүт кинәт аның җиңеннән тартып алды.

— Тәнзилә, тукта әле.

— Нәрсә?

— Ни... нәрсә димәкче идем соң әле?..

— Яратам димәкче идеңме?

— Каян белдең?

— Мин аны күптән... күптән сизәм бит инде, Мәхмүт.

— Ә син?

— Мин дә...

Шунда Мәхмүт үзе дә сизмәстән, Тәнзиләнең бит уртасындагы мәхәббәт чокырыннан тиз генә үбеп алды да, үз кыюлыгыннан үзе ук оялып өйләренә йөгерде. Тәнзилә капка баганасына сөялеп аның артыннан карап калды.

Гаҗәп түгел: бер-берсенең кайнар кулларыннан тоткан хәлдә айга карап, бәлки, бераз сөйләшеп торасы килгәндер Тәнзиләнең. Мәхмүттән

бер яшькә кечерәк булса да, буйга җитеп килә торган кыз бит инде Тәнзилә. Ә ул әнә качты. Оятыннан качты. Икенче көнне дә күренмәде Тәнзиләгә, өченче көнне дә. Күренмәсә соң, күренмәсен. Тәнзилә дә күренмәячәк. Бүген әнә, репетиция була дип, игълан язып куйган. Тәнзилә өчен язган инде ул игъланны. Чөнки репетиция көне игълансыз да билгеле. Аларның клубта айлык эш планы эленеп тора. Тора бирсен, Тәнзилә бүген барыбер репетициягә килмәячәк. Мәхмүткә үч итеп. Күрми торсын әле ул да Тәнзиләсен...

Соңгы дәрес бетүгә Тәнзилә класстан беренче булып чыгып йөгерде. Өйләренә кайтып җиткәнче артына әйләнеп карамыйча йөгерде Тәнзилә. Артыннан Мәхмүт куып килә кебек тоелды аңа. Кайтып җиткәч, капка баганасына сөялеп, Борнай мәчете чатына карап алды. Янәсе, Мәхмүт килмиме? Юк. Артта берәү дә юк иде. Килмәсә килмәсен. Ул да бармаячак, беркайчан да!

Тәнзилә, кечкенә капканы тибеп ачты да томырылып өйләренә кереп китте. Кергән уңайга букчасын, бишмәтен кая җитте шунда ташлады да караватына барып йөзтүбән капланды.

Шундук, хафаланып, янына әнисе килеп җитте.

— Ай алла, ни булды? Әллә авырыйсыңмы?

— Башым авырта.

— Кая, тастымал чылатып бирим...

— Кирәкми, бер нәрсә дә кирәкми.

Шулай бик озак ятты Тәнзилә. Кинәт чыңгылдап капка ябылды, Тәнзилә урыныннан сикереп торды: «Килде!»

Тыштан ук сукрана-сукрана әтиләре кайтып керде.

— Капкагызны нигә ябып йөрмисез, сезгә әйтәм.

— Ябык иде, җил ачкандыр,— диде әнисе.

Әтиләре эштән арып кайткан.

— Кая, ашап алмыйбызмы? — диде.

— Булды, картым, әйдә чык, утыр. Кызым, син дә утыр, капкалап ал, җиңеләеп китәрсең.

— Минем ашыйсым килми,— диде Тәнзилә.

— Башы авырта, ис тигән ахры, мәктәпләрендәге мичләрен иртә томалыйлар да...

Әйе, шулайдыр, ис тигәндер. Эх, әни кеше, әни кеше... Белсәң иде кызыңа нинди ис тигәнен!

Шулвакыт кемдер урамнан акрын гына капка шакыды.

— Кайсы булыр икән?

— Туктагыз, миңа ул,— дип Тәнзилә сикереп торды.

Аралыктан әнисенең шәлен эләктереп капка ачарга чыгып йөгерде. «Кем бар?» — дип тә тормады ул. Капканың келәсен күтәреп, төбенә кадәр ачып җибәрде. Каршында Мәхмүт басып тора иде.

— Бу нишләвең инде синең, Тәнзилә?!

— Ә син соң?.. Син, син үзең? — диде дә Тәнзилә шәленә уралып капка баганасына сөялде һәм сулык-сулык еларга тотынды. Мәхмүт иләп кенә аның иңнәреннән алды.

— Гафу ит, Тәнзилә... Әйе, мин үзем гаепле.

— Эх син, җитмәсә...

— Моннан соң... Моннан соң гел бергә йөрербез.

— Репетициягә барабызмы?

— Юк, таралдылар. Мин үзем тараттым аларны... син булмагач.

— Әйдә, өйгә керик.

— Сезгәме?

— Безгә булмый, кемгә булсын?

— Юк, юк, мин кермим. Анда бит синең әтиең...

— Булса соң. Курыкма, безнең әти үз кеше ул, колактан тартып яңакламый.

Тәнзилә Мәхмүткә, сүз әйтергә дә ирек бирмичә, кулыннан сөйрәп өйгә алып кереп китте.

— Менә, таныш булыгыз, безнең Мәхмүт дигән егетебез шушы була инде.

— Һо-о-о, кунак!.. Әйдә, әйдә, егет, түргә, табынга уз.

— Юк, рәхмәт, мин яңа гына өйдән, табын яныннан кубып килдем.

Белә бит Тәнзилә — ялганлый Мәхмүт. Ул өенә дә кермәгән, ашамаган да. Өенә керсә, әтисе бит аны яңадан чыгармаячак.

— Әйдә, алайса, Мәхмүт, без әчке бүлмәгә керик. Әнкәй, син безгә ашарга́ шунда бир.

— Юк, юк, минем ашыйсым килми.

— Минем килә. Мин әле мәктәптән кайткач ашамаган идем,— дип, Мәхмүтне әчке бүлмәгә алып кереп китте.

— Менә шушындый кечкенә генә өйдә яшибез инде без, Мәхмүт. Җиһазларыбыз да юк.

— Нигә кирәк?

— Булса кирәк булыр иде дә, юк шул. Әткәй үзе генә эшләгәч, житкереп булмый,— дип, олыларча житдилек белән сөйләп китте Тәнзилә.

— Менә, балакайлар, капкалап алыгыз,— Тәнзиләнең әнисе өстәлгә ике тәлинкә кыстыбый китереп куйды.

— Рәхмәт, әнием. Әйдә, Мәхмүт, утыр.

— Юк, минем ашыйсым килми.

— Килә, килә. Бик килә. Утыр!

Тәнзиләнең әнисе тагын әйләнеп керде.

— Менә сезгә сөт. Кыстыбый сөт белән тәмле була ул, дип өстәлгә ике стакан сөт кертеп куйды. Комод тартмасыннан кызыл башлы өр-яңа тастымал чыгарып Мәхмүткә сузды.— Кунакка тастымал куярга оныткансың, кызым,— диде дә, үзе шунда ук урта ишекне ябып чыгып китте.

— Әйдә, житеш. Бездә кыстату юк, алдыңа куйганны бетерәсең.

— Шулкадәрленеме?

— Әйдә, әйдә, күп сөйләнмә, аша.

Ашады Мәхмүт. Алдына куйган кыстыбыйның сыныгын да калдырмый ашап бетерде. Аннан сөт эчте. Нинди тәмле! Аның мондый тәмле ризыкны һичкайчан ашаганы юк иде шикелле. Тәнзилә табынны жыеп алды да урта ишекне шакыды.

— Әнкәй, бире кер әле.

Әнисе кергәч ул тагы да кычкырыбрак, теге яктагы әтисе ишетелерлек итеп:

— Менә, Мәхмүт мине киногa чакырырга килгән. Әткәйдән сора әле, рөхсәт итәр микән? — диде.

— Итәр, итәр, нигә итмәсен. Әллә нигә бер иптәшләрең белән киногa барырга да рөхсәт итмәгәч, нинди ата була ди ул. Әтисе, ишетәсеңме, кызың әнә киногa барырга рөхсәт сорый.

— Ишетәм, барысын ишетәм.— Аннары ул карчыгына пышылдап: — Мә, кызыңа акча бир. Егетнең әтисе киногa акча бирмәс. Сәүдәгәр саран була ул,— диде.

Тәнзиләгә әнисе сандык төбеннән кара плюш пальто һәм ак оренбур шәле чыгарып бирде.

— Мә, кеше алдына чыкканда адәм рәтлерәк киенеп бар.

— Кирәкми, әнием, кимим, синеке бит болар...

— Элек минеке булса, хәзер синеке булыр. Житкән кыз булып киләсең бит инде син хәзер, аллага шөкер. Ә миңа ишегалды тирәсендә йөрер өчен нәрсә дә ярар.

Киенеп бетеп өйдән чыгып барганда Тәнзиләнең әтисе Мәхмүтне туктатты:

— Кара аны, егет, өйдән килеп алдың кызымны, өйгә үк кайтарып та куй. Икенче килгәндә йөз аклыгы була ул.

Алар өйдән чыгып киткәндә түбәләре күккә тигән иде. Кулга-кул тотынып «Чаткы» кинотеатрына барып җиткәннәрен сизми дә калдылар.

Кинотеатр ишек төбенә җиткәч, Тәнзилә Мәхмүткә акча сузды:

— Мә, билет ал.

Алса да алды Мәхмүт акчаны Тәнзилә кулыннан, алмаса да алды. Аның башка чарасы юк иде. Ләкин әченнән аңа бурычлы булып калмаска, вакыты җиткәч, бише белән кайтарырга дип ант итте.

Кинога кереп утырып, залда ут сүнгәч, Тәнзиләнең кайнар кулын эзләп тапты Мәхмүт һәм кино беткәнче аны үзенең учында тотты. Тәнзилә кулын кире алмады. Аларның икесенә дә рәхәт иде бу минутта. Әйе, чиксез рәхәт иде. Бәхетле иде алар. Экранда нәрсә барганын да юньләп күрмәделәр, кино беткәнне дә сизми калдылар.

Кайтып җитәселәре килмичә, аерылышу минутларын якынайтырга теләмичә, юри акрын гына кайтты алар. Ә инде Тәнзиләләр капка төбенә кайтып җитеп хушлашканда, кайнар иреннәр бер-берсенә якынаеп, инде тиям-тиям дигәндә генә, кинәт Ашманскийлар капка төбеннән:

— Мәхмүт, син кайда йөрисең, җүнсез! — дип өзгәләнеп кычкырган тавыш, аларны сискәндереп, икесен-ике якка аерып җибәрде.

— Бар, йөгер, сине әниең эзләп килгән,— диде Тәнзилә һәм тиз генә кереп капканы әчтән бикләде.

Мәхмүтнең өстеннән салкын су койган кебек булды. Ул тыны бетеп, буыннары калтырап, Ашманскийларның өй түрендәге рәшәткәсенә килеп ябышты.

— Кайда йөрим, иптәшләрем белән кинога бардым.

— Әтиең кайтып керсә, үтерә бит мине, балакай...

Өйгә кайткач та тынмады Мәхмүтнең әнисе.

— Шул сабынчы Корбан кызы белән бармасаң ул кинога... Үз тиңең юкмыни синең?

— Нинди тиң?

— Әнә, Зәйнәп ахирәт кызы — Мөршидә.

— Нигә ул миңа?

— Ничек нигә? Мең мәртәбә әйттем бит инде! Бишектә чакта ук синнән колагын тешләттереп куйдык...

— Тешләтмәгез иде.

Бүлмәсенә кереп бикләнде дә, дәрес хәзерләргә утырды Мәхмүт. Кат-кат укып та дәресе башына кермәде. Күзләренә йокы да кермәде.

Ә тәрәзәдә — тулган ай. Мәхмүт торып форточканы ача. Форточкадан бүлмәгә яз һавасы, язгы сулыш агылып керә. Әйе, тиздән гөрләвекләр ага башлар. Мәхмүт белән Тәнзилә Иделдә боз кузгалганын карарга төшәрләр. Аннан күп тә үтмәс, яз аларга чәчәкләр алып килер. Канәфер, чия, шомырт чәчәкләре. Ап-ак чәчәкләр... Шул ак чәчәкләр арасыннан ялт итеп балкып Тәнзилә килеп чыгар. Нишләтәсең син Мәхмүтне, Тәнзилә?

* * *

Ниһаять, ул көн дә килеп җитте. Мәхмүт соңгы имтиханын биреп мәктәп ишегалдына чыкты. Ишегалды тулы кояш. Әйтерсең, аның кояшны беренче мәртәбә күрүе. Ул күзләрен кысып кояшка карый. Аннан мәктәп бакчасына күз төшерә. Бакча түрендә фәкать бер генә алмагач ап-ак чәчәккә күмелеп утыра. Каян килгән? Соң бит инде. Алмагачлар чәчәгеп күптән койды бит инде. Ә бу шау чәчәктә. Үзе елмая. Мәхмүткә карап елмая. «Тәнзилә!..» Бакча түрендә ап-ак күлмәктән, чәчләренә ап-ак ефәк бантиклар үреп, бер көлтә ак чәчәкләр кочаклап Тәнзилә басып тора. Мәхмүт дөньясын онытып аңа ташланды.

— Тәнзилә! Мин сине ничек сагындым!

— Мин дә, Мәхмүт!

Алар бер-берсенә текәлеп караган хәлдә бакча түрендә бик озак

сүзсез тордылар. Аннары Тәнзилә Мәхмүтнең битеннән йомшак кына сыйпап алды.

— Мескенем, ябыгып, агарып калгансың бит...

Алар житәкләшеп Тәнзиләләр капка төбенә кадәр сөйләшеп кайттылар. Әйтерсең, ел буе күрешмәгәннәр. Капка төбенә кайтып житкәч, Тәнзилә кинәт туктап калды.

— Син башта өеңә кайтып кил, Мәхмүт!

— Юк. Минем бүген синең янда гына буласым килә.

— Алайса, әйдә, өйгә керәбез. Бүген без әнкәй белән, синең имтиханнарыңны биреп бетерү хөрмәтенә, гөбәдия пешердек.

— Рәхмәт. Тик башта Ашман абыйларга кереп шатлыгыбызны уртаклашып чыгыйк.

Ашманскийлар аларны колач җәеп каршы алдылар:

— Я, тизрәк сөйлә, тилмертмә безне...

— Имтиханнарны биреп бетердем, Ашман абый.

— Ә нәтиҗә, нәтиҗә ничек?

— Яхшы.

— Алайса, менә сезгә иртәгә буласы премьерага чакыру билеты. Икегез янәшә утырып бер рәхәтләнеп карагыз әле. Имтиханнардан соң бу сезгә бик яхшы ял булыр.

— Премьерага син, Мәхмүт акыллым, менә шушы күлмәк белән галстукны тагып барырсың. Бу безнең сиңа имтиханнарыңны яхшы тапшырганың өчен бүләгебез булыр.

— Рәхмәт, туган апа, рәхмәт, жизни.

— Ә сиңа, Тәнзилә...

— Юк, юк, мин бит имтихан бирмәдем. Минем имтиханым киләсе елга.

— Киләсе елгысын киләсе елда карарбыз. Ә хәзергә менә сиңа минем иң яраткан шарфым. Премьерага шуны урап барырсың.

— Рәхмәт инде, алайса...

— Ә хәзер — табынга!

— Юк, юк, безне анда әнкәй көтә. Ул гөбәдия пешереп куйды.

— Алайса, барыгыз инде, гөбәдия суынгач тәмле булмый ул.

Ашманскийлардан Тәнзиләләргә кайтып гөбәдия белән сыйлангач, алар Кабан күленә төшеп көймәдә йөрделәр. Мәхмүт ишкә, Тәнзилә мандолинада уйнады. Мәхмүт ишкән уңайга мандолинага кушылып акрын гына, сузып кына, тәмләп кенә җырлады. Кич житте, караңгы төште. Мандолина тынып калды. Мәхмүт кулындагы ишкәкләр дә, канатларын җилпеп, Кабан күле көзгесен үбеп-үбеп алудан арыдылар булса кирәк, күл өстендә иләп кенә тирбәлеп, көймә кырыена елыштылар. Сихри күл өстенә төшкән ай яктысында, көймәдәге ике шәүлә акрын гына бер-беренә якынаеп, икесе бер булып, тынып калдылар. Ә үз иркенә куелган көймә, сизелер-сизелмәс тирбәлеп, күлнең чирәмле ярына килеп орынды...

## Капитан булыргамы?

Күңелгә мәңгегә уелып кала торган мондый очрашулар ул җәйне еш булды. Бәхетле җәй булды ул Мәхмүт өчен. Җидене бетереп, мәктәптән таныклык алу белән үк, гаризасын илтеп биргән иде Мәхмүт театр техникумына. Менә хәзер кабул итү имтиханнарына барыр көн килеп житте. Өйдәгеләр бу турыда бернәрсә белми иде әле. Нишләргә? Әйтергәме? Әтисе хәзер кибеткә чакырып битәрләмиме. Аның үз эше хөртигә әйләнеп бара. НЭП чоры үтте. Күтәрә алмаслык налог китереп салдылар. Эчендәге барлык мал-мөлкәте белән кибетен сатып, налогларыннан арынды да Габидулла абзый, Бакалтайдагы утын складларына каравылчы булып эшкә керде. Малыннан аерылганга да башкалар шикелле «аһ орып» йөрмәде.

Шундый вакытта ничек итеп, театр техникумына укырга керәм, дип әйтергә кирәк аңа. Ә әйтми ярамый, сорар бит ул иртән торып киткән вакытларда. Кая барасың, дияр. Ни дип җавап бирерсең? Юк, тәвәккәлләргә кирәк... Мәхмүт куркып кына әтисе бүлмәсенең ишегенә килде. Шакыды. Дәшми. Тагын шакыды, тагы дәшми. Шуннан соң акрын гына ачып эчкә узды. Әтисе күзләренең агын әйләндереп аңа текәлде.

— Ни бар?

— Миңа укырга керергә кирәк иде бит, әти.

— Кирәк, кирәк. Бик кирәк. Менә минем шикелле каравылчы булып каласың килмәсә, укы инде син.

— Димәк, рөхсәт?

— Рөхсәт. Ә кая кермәкче буласың?

— Кая дип... Шунда инде...

— Капитан булыргамы? Шәп!.. Ап-ак пароход өстендә, ап-ак кием нән Мәхмүт Габидулла улы Габдуллин пароход йөртә. Ата-бабаның төшенә дә кермәгән пароходны... Шәп. Молодец! Ниһаять, аңлагансың икән минем әйткәннәрне.

Әйе, булган иде аның әтисе белән бу турыда сөйләшү. Сөйләшү генә түгел, пароход өстенә алып менеп, Мәхмүткә капитан күперчеген күрсәткән дә иде ул. «Менә, улым, дәү үскәч, син дә шушы күперчеккә басып, пароход йөртерсең, капитан булырсың»,— диган иде. Әйе, шулай диган иде. Күптән, бала вакытта ук. Ә хәзер... Хәзер Мәхмүтне пароход та, капитан күперчеге дә кызыксындырмый. Хәзер Мәхмүтнең күз алдында сәхнә һәм театр гына. Шуңа күрә ул әтисенең соравына курка-курка гына җавап бирде:

— Юк, әти. Минем капитан буласым килми. Мин... Театр техникумына...

— Ә!? Юк, аңа рөхсәтем юк!

— Минем башкага күңелем тартмый.

— Тартмаса, эшкә керерсең. Әртист булып, эшләмичә уйнап йөргәнче, заводка кереп берәр һөнәр алырсың, ичмаса.

— Әти, дим...

— Бетте. Яп ишекне!

Менә сиңа аңлаштылар! Әнисе белән сөйләшеп тә, бер нәрсә барып чыкмады. Әнисе каршы да килмәс иде бәлки, ләкин әтисеннән уза алмый. Мәхмүткә дә әтисе киңәшеннән чыкмаска киңәш бирә. Тагы шуңа өстәп, әнисенең үз үтенече бар. Үтенеч кенә дә түгел — гозер. Әгәр дә Мәхмүт әнисен санласа, алла хакы өчен ул сабынчы Корбан кызы тирәсендә чуалмасын, күкрәк сөтен имезеп үстергән бердәнбер әнисен хурлыкка калдырмасын, нәсел-нәсәп исеменә тап төшермәсен. Колак тешләтү — вәгъдәләшү дигән сүз. Ә вәгъдәсен бозган кеше беркайчан да һәм беркем белән дә бәхетле булмаячак.

Мәхмүт, башына тимер таяк белән суккан кебек, чалыш-чолыш атлап, өеннән чыгып китте. Нишләргә? Кая барырга, кем белән киңәшергә?

Ашманскийларга керергәме? Мәхмүт парадный баскычы өстендәге болдырга кырын күз ташлап алды. Болдырның вак-вак бүлемнәрдән торган тәрәзәсенә әтисенең олы гәүдәсе капланган. Өйдән чыккач, улы кай якка борылыр, кемнәргә таба юл тотар икән, дип күзәтә. Әгәр уңга борылып, Ашманскийларга таба юнәлсә, шунда ук артыннан барып Мәхмүтне дә, гөнаһсыз Ашманскийларны да пыр туздырачак, мәсхәрә итәчәк. Тәнзиләләргә дә барырга ярамый. Әнисе кухня тәрәзәсендә. Дөрес, ул әтисе кебек артыннан барып Тәнзиләләр ишеген бәреп кермәячәк. Ләкин рәнҗиячәк, елаячак. Соңгы вакытларда аның әнисе болай да бик бетереште. Ничектер кечерәеп, бөрешеп калды. Түгәрәк ак йөзләре кибеп саргайды, яңаклары эчкә батты, алсу иреннәре күгәреп, күз чокырлары тирәнәйде. Мал хәсрәте өстенә, анага бала хәсрәте дә өстәлде. Сизә бит ана... Бердәнбер баласының уй-хисләре кай тирәдә чуалганын,

аның киләчәктә нинди борылыш ясарга торганын сизә. Ә ул борылыш Мәхмүтне кая алып барып чыгар? Монысын бит әле Мәхмүт үзе дә белми. Бәлки, тагы бер мәртәбә ныклап уйларга кирәктер? Бәлки, алар хаклыдыр? Һәрхәлдә, ата-ана үз баласына начарлык теләмәс.

Шулвакыт кинәт, салкынча һаваны ярып, Үсиядә пароход кычкыртты. Мәхмүт пароход тавышы килгән якка борылып, кызу-кызу атлап китеп барды.

«Үсиягә юл тотты бу. Ниһаять, малайга барып җитте ахры»,— дип уйлады Мәхмүтнең әтисе һәм болдырдан бүлмәсенә кереп китте.

Мәхмүт, чыннан да, Үсиягә юнәлде. Ләкин нәрсә дә булса уйлап түгел, юк. Кинәт пароход кычкыртканга сискәнеп, куркыныч төш күреп уянган кеше кебек, һичбер уйсыз, фикерсез, хәтта кая барганын да белмичә, товар станциясен Үсия белән тоташтырган урта дамба буйлап барды да барды һәм ахыр чиктә, үзе дә сизмәстән, ерак Үсиягә килеп чыкты. Идел өстендә акчарлаклар оча. Ниндидер елак тавыш белән кычкырып-кычкырып алалар. Гүя алар Мәхмүткә хәбәр салалар: «Уян, уян!» Мәхмүт яңадан үзен баскан авыр уйларын селкеп калдырып, дебаркадерлар буйлап һаман алга, Идел агымына каршы югарыга таба китте. Зур бер дебаркадерның сыгылмалы күпереннән халык төркеме, бер-бер артлы тезелеп, пароходка агыла. Мәхмүт, шул төркемгә кушылып, ап-ак пароход эченә юнәлә. Пароходка кергәндә аны туктаталар.

— Сезнең билетыгыз?

— Миңа капитанны күрергә кирәк.

Һәм аны берсүзсез пароход эченә кертеп җибәрәләр. Ул түбән палубаның уртасында туктап кала. Нигә кирәк булды соң әле аңа капитан? Нәрсә сорамакчы булды соң әле ул капитаннан? Капитан булу өчен нишләргә кирәк, дипме? Ул аны үзе дә белә. Игумныйда елгачылар техникумы бар. Шунда кереп өч ел укыйсың да — менә сиңа коеп куйган капитан! Ә пароход нигә кирәк булды аңар? Үз-үзен кызыктыру өченме? Имеш, кара, нинди матур. Аккошмыни! Идел дулкынына төшен куеп, сизелер-сизелмәс кенә чайкалып тора. Ә эче... Кырмыска оясымыни — мәш килә. Халык, халык, халык! Мәхмүт беренче каттагы палубаның коридоры буйлап түргә үтмәкче иде. Кая ул! Аяк басарга да урын юк. Капчыклар, зур-зур төенчекләр, такта чемоданнар өстендә кайсы ята, кайсы утыра, кайсы бала имезә. Кайсы кабыгын-чүбен аяк арасына ташлый-ташлый кипкән балык кимерә, кайсы калай кружкадан өрә-өрә кайнар чәй эчә, кайсы авызына кара икмәк белән яшел суган тутыра, кайсы калтырый-калтырый шешә авызыннан «мәй» чөмерә. Тавыш-кычкырыш. Балалар елый, хатыннар чәрелди, ирләр сүгенә.

Палубада эссе, бөркү. Аста пар казаны шаулап тора. Матрослар йөгерә-йөгерә трюмга капчык ташыйлар. Берсе шунда Мәхмүтне төртеп җибәрә:

— Нәрсә авызыңны ачтың, кит юлдан!

Мәхмүт трюм капкачы өстенә өйгән ящикларга килеп бәрелде. Күзләре югары палубага менә торган ике баскыч арасындагы стенага төштеләр. Ә стенадан аңа Габдулла Тукайның алтын рам эченә куйган зур рәсеме карап тора.

Мәхмүт аптырап калды. «Габдулла Тукай». Ул монда каян килгән? Менә бит, ул бары әһәмият кенә бирмәгән булган. Пароходның дебаркадердан чыгып торган койрыгында «Габдулла Тукай» дип язылган иде. Димәк, бу пароход Габдулла Тукай исемен йөртә. Әйе, әйе, Тукай. Әнә ул. Уйчан, моңлы күзләр. Юка ирен кырыйлары кыймылдап-кыймылдап алалар кебек. «...Кар төшә... кар төшәм дип, тартыша...» Ә син, Мәхмүт әфәнде, әнә шул кар бөртеге кадәр дә түгелмени соң инде дөньяда? Син тартыша алмыйсыңмыни? Үзең теләгән җиргә төшү өчен тартышырлык көч юкмыни синдә?

Ә нигә тартышырга? Ул бит монда үзе теләп килде. Әтисе бит аның

капитан булуын тели. Ә нигә булмаска? Начармыни? Әнә, өстән бер капитан төшеп килә. Ап-ак кительдән. Ап-ак фуражкасына алтынсу йөгертелгән кокарда беркетелгән. Ул эре генә атлап чыкты да, дебаркадерның козырегына беркетелгән зур кыңгырауга бәрде. Ул арада пароход өч мәртәбә сузып-сузып кычкыртып та җибәрде. Матрослар пароход белән дебаркадер арасындагы басманы тартып алдылар. Дебаркадер шкиперы юан бүкәнгә эләктерелгән канатны ычкындырды. Пароход белән дебаркадер арасында Идел суы ургылып-ургылып кайнарга тотынды. Мәхмүт беравыкка югалып калды. Нишләргә? Китә бит, китә... аяк астыннан җир китә, дебаркадер белән бергә, зур-зур ташлар түшәлгән яр китә. Амбарлары, лабазлары, трамвайлары белән бергә ерак Үсия китә. Ниһаять, Казан китә.

Мәхмүт, тиз генә өненә килеп, ишеккә йөгерә. Ишекнең челтәрле барьерын аркылы тартып өлгергәннәр инде. Мәхмүт, сикереп, барьер өстенә менә һәм инде шактый ерагая башлаган дебаркадерга ыргыла. Кара-кучкылланып кайнаган упкын өстеннән очып, бер кулы белән дебаркадерның аркылы киртәсенә тартыла. Икенче кулы, гәүдәсе һәм аяклары упкын өстендә асылынып кала. Шул мизгелдә дебаркадер шкиперы Мәхмүтнең сыңар кулыннан эләктереп алып өскә сөйрәп менгерә.

— Син нәрсә, үләсең килдемени?

— Рәхмәт. Болай булгач, үлмибез инде без, абый. Югарыдан, пароход күперчегеннән, алтын кокардалы капитан, авызына ялтыравыклы җиз рупор куеп, ачу белән:

— Болван! — дип кычкыра.

Мәхмүтнең башына нәрсә беләндер китереп оралар шикелле. Идел буе тынып кала. Аннан дебаркадердагы халык кычкырып көлә башлый.

— Ха-ха-ха!

Мәхмүт хурланып ярга йөгерә. Колакта һаман капитанның карлыккан тавышы яңгырый: «Болван!»

Ничек инде кешегә шундый ямьсез сүз әйтергә кирәк? Житмәсә әле капитан. Бәлки ул капитан да түгелдер. Алай дисәң, ул бит капитан күперчегендә басып тора. Шулай ярыймыни инде? Юк, юк, Мәхмүт капитан булмаячак. Пароходның янына да барачак түгел Мәхмүт. Анда этәләр-төртәләр, кычкыралар-сүгенәләр.

Театрда бит беркайчан да алай кычкырмыйлар. Артистлар беркайчан да кешене ямьсез сүзләр белән мыскыл итмиләр. Житте. Җебемә... Үз язмышыңны үзең теләгәнчә хәл итәргә тиеш син! Ә ничек итеп? Иртәгә имтиханнар башлана. Әтисе каршы. Нишләргә? Аларга әйтмичә генә китәргәме?

* * *

Әчке кичерешләре нинди генә авыр булмасын, ул имтиханнарын менә дигән итеп биреп чыкты. Бигрәк тә махсус фәннән — актерлык сәләтлегеннән ул бөтенесен таң калдырды.

Коридорда аны Ашманскийлар белән Тәнзилә көтеп тора иде. Ул шатлыгыннан Ашман абыйсын кочаклап, елап ук җибәрде. Татлы елау белән елады Мәхмүт, рәхәт елау белән. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел. Бу бит аның хыялларының тормышка аша башлавы дигән сүз. Бу бит аның киләчәк бәхетенә беренче адымын атлау дигән сүз.

Ашманскийдан соң ул туган апасының бит уртасыннан үбеп алды да, бер читтә кыяр-кыймас кына басып торган Тәнзиләгә табан атлады.

— Син дә мондамыни, Тәнзилә?.. Рәхмәт сиңа!

— Ә кайда булырга тиеш идем соң мин бүген?.. Менә килдем әле. Күрим, дидем. Миңа да бит бу баскычларны атлап менәргә күп калмады. Бер генә ел.

Әйе, бу шулай... Шулай булырга тиеш. Үзләренең киләчәк тормышларын бөтенләе белән театрга багышларга дип сүз куештылар ич алар. Менә Ашман абыйлары белән Гөлчәһрә апалары кебек. Анысына Мәхмүт

шикләнми. Тиздән беренче сентябрь. Ул көн дә килеп житәр. Ә нәрсә күрсәтер ул көн Мәхмүткә? Менә нәрсә борчый аны хәзер...

* * *

Ул көн килеп тә житте. Иртүк торып Мәхмүт тәрәзәгә карады. Тышта вак янгыр сибәли. Ертык болытлар Борнай мәчетенең манарасына тиеп-тиеп үзалар. Ниндидер басынкы, карангы көн. Юынып кереп табынга утырды Мәхмүт. Әтисенең дә йөзе карангы — нәкъ бүгенге сытык көн кебек. Әнисе дә турсайган. Алар арасында нидер булып алган ахрысы бүген. Мәхмүт дәшми-нитми генә ашап-эчте дә, бүлмәсенә кереп киенгәннән соң калын дәфтәр тотып ишеккә юнәлде.

— Хуш, син кая киттең инде?

— Техникумга.

— Нинди техникумга дип сорыйм мин синнән?!

— Театр техникумына.

— Бармыйсың.

— Әткәй, мин бала түгел инде — студент. Шулай булгач, зинһар, мина үз язмышымны үземә хәл кылырга ирек бир.

— Алайса шул иркенне инеңә ас та, теләсәң кая кит. Өйгә кайтып керәсе булма!

— Ярый, кайтмам.

— Миннән бер тиен акча сорыйсы булма! Теләсәң кайда һәм теләсә ничек тамагыңны туйдыр!

— Сорамам.

— Вон!

— Рәхмәт!

Мәхмүт акрын гына тышкы ишекне ябып баскычтан төшеп китте. Капкадан чыкканда аңа ян тәрәзәдән әнисенең йөрәк ачысы белән кычкырып елап жибәрүе ишетелеп калды.

Мәхмүтнең беренче уку көне әнә шулай башланды. Ашкынып көтеп алган олы юлына шулай озатып калды аны туган йорты.

Аның каравы икенче дөнья аны колач жәеп каршы алды. Ишектән кергәч, коридорның буеннан-буена сузылган кызыл комачка: «Рәхим итегез, яшь студентлар — булачак артистлар!» дип, эре хәрефләр белән язылып куелган иде. Белдерү тактасында беренче курска кабул ителүчеләрнең исемлеге эленгән. Исемлек башында — Габдуллин Мәхмүт. Моңа ничек куанмассың да ничек горурланмассың!

Беренче дәресләр сизелми дә үтеп китте. Яшь студентлар бер-берсе белән танышып, өстән-өстән генә булса да дуслашып та өлгерделәр. Соңгы дәрес бетү белән алар гөр килеп класстан чыктылар да, төркем-төркем булып, кайсы тулай торакка, кайсы ашханәгә, кайсы өйләренә таралдылар. Тик Мәхмүт кенә коридорда берүзе басып калды. Кая барырга? Бары тик хәзер генә аның башында шундый сорау туды. Чынлап та, аның барыр урыны юк иде. Ул кире борылып коридор башындагы тәрәзәгә килде. Маңгае белән тәрәзәнең салкын пыяласына терәлеп, уйга калды: Нишләргә?.. Өйгә кайтса, әтисе куып чыгарачак. Әллә Ашман абыйларына кайтыргамы? Юк, юк, аларны борчуга салырга ярамый. Ә бәлки Тәнзиләләргәдер?.. Булмаганны. Ичмасам, чаттагы ашханәгә кереп ашап чыгасы иде. Ләкин кесәсендә ник бер тиен акча булсын. Әтисеннән вак-төяк өчен бераз акча сорамакчы булып яткан иде ул кичтән. Ә иртән... О, юк инде, бүгенге иртәне исенә төшерәсе килми аның. Узар әле. Нинди генә авыр булса да, узар. Әнә бит, урамда тормыш үз агымы белән бара. Кешеләр барысы да каядыр ашыгалар. Араларында, бәлки, Мәхмүттән дә авыррак хәлдә калучылар бардыр. Ләкин бирешмиләр, сиздермиләр бит. Нигә Мәхмүт кенә борынын салындырырга тиеш соң әле? Әнә бит, директор әйтте жыелышта, иртәгәдән

башлап стипендия хисабына көненә өч мәртәбә ашата башлыйбыз, диде. Иртәгә кадәр генә түзмимени Мәхмүт? Түзә, әлбәттә. Тик менә тулай торакта гына урыннар аз, диде. Читтән килүчеләрнең барысына да җиткереп булмас, диде. Казанда таныш-белешләре, туган-тумачалары булган кешеләр шунда урнашып тора алмасламы хәзергә, диде. Ә бит ярты Казан Мәхмүтнең таныш-белешләре белән тулган. Шулай булгач...

Шулвакыт кемдер арттан килеп акрын гына аның иңбашына кагып алды. Борылып караса, каршында Ашман абыйсы елмаеп басып тора иде.

— Нигә уйга калдың? Кирәкми. Андый гына хәлләр була ул дөньяда.

— Нинди хәлләр?

— Ярый, ул турыда калсын.

— Сез беләсезмени?

— Әтиең кереп безне пыр туздырды. Сез генә гаепле, ди. Ул дөрес әйтә: без сәбәпче булдык синең бу юлны сайлавыңа. Ләкин без дөрес эшләдек. Киләчәк исбат итәр. Әйдә әле...

— Кая?

— Керик әле минем белән.

Ул Мәхмүтнең кулыннан җитәкләп беренче катка алып төште дә директор кабинетына алып керде.

— Менә шушы егет инде ул.

— Беләм, бу егетне мин яхшы беләм.

— Без аны бик теләп үзебездә генә тотар идек, ләкин ярамый. Әтисе тынгы бирмәячәк.

— Аңлыйм, аңлыйм,— директор телефон трубкасын алды... — Кем бу? Миңа комендантны чакырыгыз. Вакыйф, синме? Запас урыннарың калдымы әле синең анда? Шулаймы? Алайса хәзер сиңа беренче курс студенты Габдуллин килер. Аны шуларның берсенә урнаштыр. Урын-җир һәм башка кирәк-яракның барсын да бирегез.— Директор, телефон трубкасын куйды да, кечкенә бер кәгазь язып Мәхмүткә сузды.— Менә сиңа тулай торакның адресы, хәзер үк шунда бар.

Мәхмүт шатлыгыннан нишләргә белмәде.

— Рәхмәт сезгә, иптәш директор.

— Рәхмәтен, әнә, Ашман абыеңа әйт. Аның хакына гына булды бу. Югса, без шәһәр балаларына тулай торактан урын бирмибез.

Ашман абыйсына борылганда, аның күзләрендә яшь иде инде.

Шулай итеп, Мәхмүт тулай торакта торып укый башлады.

Акчага да аптырамады Мәхмүт. Авылдан килгән берничә таза егет белән сөйләшеп, ял көннәрендә баржа бушаттылар. Бу турыда ул Ашманскийларга да һәм Тәнзиләгә дә әйтмәде.

Бер ялда шулай, октябрь ахыры иде шикелле, тулай торакка килде Тәнзилә. Мәхмүт юк. Бүлмәдә бер егет гармун тартып утыра.

— Мәхмүт кая? — дип сорады Тәнзилә аннан.

— Нигә ул сезгә, мин барында? — дип шаяртып җавап бирде егет.— Утырыгыз, туташ, Мәләкәсский булам мин — атаклы гармунчы. Җырлыйсызмы, уйныйм? — диде.

— Юк,— диде Тәнзилә, кырт кисеп.

— Әллә биеп күрсәтимме? — дип елмайды егет.

— Мәхмүт кая,— дип сорыйм мин сездән?

— Мәхмүт тю-тю инде ул, тю-тю... Онытыгыз аны сез һәм дикъкатегезне менә миңа җәлеп итегез,— дип, ул Тәнзилә каршына басып реверанс ясады.

— Маймылланмагыз, зинһар, сезгә әле артист булырга бик иртә.

— Шулаймыни?

— Мәхмүт кая?

— Бик кирәкмени инде ул сезгә?

— Бик кирәк.

— Алайса әйтим инде — Үсиядә.

— Нишли ул анда? — диде гаҗәпсенеп Тәнзилә.

— Идел карый. Иделдә ап-ак пароходлар. Пароход артыннан акчарлаклар кышалар. Идел дулкынына түшләрен тидереп-тидереп алалар. Нинди хозур!

— Шундый көндәме?

Егет тәрәзәгә карады.

— Ах, черт возьми, көн бозылган икән шул. Нәрсә ул анда ява, кармы, бозмы?

— Мәхмүт кая? Тилмертмәгез мине, әйтегез, зинһар?!

— Әйттем бит инде Үсиядә, баржадан тоз бушаталар.

— Шаяртмагыз.

— Дөресе шул. Акча кирәк бит менә сезнең кебек чибәр туташлар белән киного йөрергә. Пирожный-мирожный, башкасы... Мин үзем дә алар белән идем. Тик менә бил кузгалып китте дә... Шул вакыт ишек ачылып, аннан Мәхмүт кайтып керде.

— Тәнзилә!..

— Кайда йөрисең инде син, Мәхмүт?

— Ничек кайда? Менә, мунчадан кайтып киләм.

— Беләм бит мин. Миңа бит бу иптәшең...

— Зәкәрия минем исемем.— Ул Мәхмүткә борылды.— Дөрес әйтә бу туташ. Мин аңа синең кайда мунча керүеңне сөйләдем инде. Ә нигә яшерергә? Алар өчен бил бөгәбез бит без. Ашарыбызга җитмиме безнең, кияребезгә юкмы, шушындый көндә Үсиягә төшеп тир түкмәсәк?

Мәхмүт аңа ачулы караш ташлап:

— Син бар әле, кем, Мәләкәс, бераз йөреп кайт әле,— диде.

Ул гармунын култык астына кыстырып чыгып китте һәм шунда ук ишекне яңадан ачып:

— Мәхмүт, кара аны, әгәр дә теге, кичәге кызың да килсә, анысын минем янга — кызыл почмакка җибәр. Берүзеңә икәү артык күп булыр ул,— дип шаркылдап көлеп ишекне япты. Коридорда Мәләкәс егетенең аяк тавышлары тынгач, Мәхмүт Тәнзиләнең кулыннан алып, өстәл янындагы урындыкка утыртты.

— Нигә килдең? Мин бит сиңа ял көннәрендә килеп йөрмә, мин өйдә булмыйм, дидем.

— Ә нигә кирәк булды ул сиңа ял көннәрендә ял итмичә, шундый авыр эштә үзеңне ватарга?

Мәхмүт шаркылдап көлеп җибәрде:

— Бердән, ул син уйлаганча ук авыр түгел, икенчедән, эш кешене ватмый — чыныктыра гына. Ә өченчедән...

— Өченчедән нәрсә?

— Беркөн әни килгән иде. Елый, кайт, ди. Кайтмасаң, әтиең киемнәреңне бирмим дип әйтә, ди. Анда кайтып миңа барыбер тынычлык булмаячак. Тиздән кыш җитәр, өс-баш аласы бар...

— Шулай да, кайтсаң ничегрәк булыр икән, Мәхмүт? — диде Тәнзилә.

Мәхмүтнең тулай торакта яшәве Тәнзиләгә дә ошап бетми иде. Өйләрендә торса, алар кичләрен ешрак очраша алырлар иде, киного, театрга йөрерләр иде. Ә болай... Алла сакласын! Аның шиген раслаган шикелле, кинәт ишек шакыдылар.

— Керегез.

Гаять чибәр кыз ишектән башын тыгып:

— Гафу итегез, безнең Мәләкәсский өйдә юкмыни? — дип сорады.

— Кызыл почмакта ул.

— Тагы бер мәртәбә гафу сорыйм.

Кыз һич урынсызга кычкырып көлде дә ишекне япты.

— Әнә бит нинди чибәр кызлар бар монда,— дип көрсенеп куйды Тәнзилә.

— Җүләрем минем, әллә көнләшәсеңме?

— Көнләшерсең дә... — Тәнзилә, кызарып башын иде дә, Мәхмүткә сыенды. Мәхмүт аны чәчләреннән сыйпап, күкрәгенә кысты.

— Нинди генә чибәр булмасыннар, миңа синнән дә чибәре, синнән дә якыны юк. Миңа синнән башка беркем дә... беркем дә кирәкми, Тәнзилә!

Алар ул көнне кичкә кадәр бергә булдылар. Кичен театрга бардылар. Театрдан соң Мәхмүт Тәнзиләне өенә, үзләренең Аккомастына кадәр озатып куйды. Капка төбендә байтак кына сөйләшеп торганнан соң, Тәнзилә:

— Ярый, рәхмәт, бар кайт инде, туңгансыңдыр,— дип, Мәхмүтне кочаклап үпте дә өйләренә кереп китте. Мәхмүт алай бик тиз генә борылып китә алмады Аккомасты башыннан. Курка-курка гына үзләренең өенә — үзе туган нигезгә килде. Тәрәзәләр караңгы, моңсу. Алар Мәхмүткә ничектер үпкәләп карыйлар төсле. Әнисе әле аның йокламыйдыр да. Түшәмгә карап, ак мендәргә кайнар яшен агызып, улын сагынып ятадыр. Менә хәзер ул торыр да тәрәзәгә килер. Өй түрендәге рәшәткәгә ябышып торган улын күрер дә: «Улым!» — дип кычкырып җибәрер.

Чү, кычкыра түгелме? Кемдер кычкыра түгелме?

Мәхмүтнең колак төбендә генә нидер зыңгылдап, аның башы әйләнеп китте. Ул, баскан урынында чайкалып алды да, кинәт борылып тыкрыкка йөгерде. Арттан кемдер куа төсле тоелды аңа. Ул, артына әйләнеп карарга да куркып, йөгерде дә йөгерде. Трамвай-фәлән дә көтеп тормады. Кайтып яткач та, бик озак йоклый алмады. Керфекләрен йому белән күз алдына әнисе килеп баса. Ике кулын сузып: «Улым, кайт, бәгырем, тилмертмә мине...» — дип пышылдый.

Төштә генә түгел, өндә дә еш килде әнисе тулай торакка. Килгән саен тәмле ризыклар пешереп алып килде. Әтисе бикләп куйган киемнәрен берәм-берәм Мәхмүткә ташыды. Һәр килгәнендә шул бер үк сорауны бирде: «Кайчан кайтасың?» Ахырда Мәхмүт түзмәде. Кышкы каникул көннәрендә, тулай торактагыларның күбесе ялга таралгач, урыныннан сикереп торды да, аннан-моннан гына киенеп урамга чыкты. Урам тын. Салкын. Ай яктысында Мәхмүт, каткан ботинкалары белән шыгыр-шыгыр кар таптап, каядыр бара да бара. Бара торгач, ул бер капкага килеп терәлде. Күтәрелеп караса, үзләренең капкасы! Мәхмүт куркып артка чигенде. Нишләргә? Борылып кире йөгерергәме, әллә акрын гына шакып караргамы? Белә ич Мәхмүт, сизә: әнисе аның йокламыйча көтеп ята. Әле кичтән генә килде ич ул аның янына тулай торакка. Елады. «Шундый шыксыз зур бүлмәдә берүзең калгансың, өстеңдә дә бер генә кат, туңарсың, авырырсың, кайт өйгә, балакаем»,— дип елады. Һәм менә ул кайтты. Әнисен кызганып кайтты. Шулай гынамы? Әнисен кызганып кынамы? Бу йорт бит аның туган йорты. Монда аның өчен һәр нәрсә газиз. Хәтта капка баганаларына кадәр. Мәхмүт капка баганасындагы пәке белән юнган киртекләрне капшый. Аның үзе юнган киртекләр. Кечкенә вакытта ул капка баганасына сыланып баса иде дә, баш очыннан күмер белән сыза иде. Сызыкны пәке белән киртекләп юна да читкә китеп карый. Әнә аның буе никадәр булган! Аңа бу йортның бөтен җире газиз, изге. Ул шуларны сагынып кайтты. Ачыгыз, кертегез! Кертегез аны үзенең туган өенә! Ул үзе дә сизмәстән капканы шакыды.

— Кем бар?!

Әтисенең югары баскычтан ишетелгән ачулы тавышы Мәхмүтне капка баганасына сеңеп, тынсыз калырга мәҗбүр итте. Шунда ук әнисенең өзгәләнүе ишетелде: «Ач, зинһар, туңдырма». Әтисенең мыскыллы җавабы яңгырады: «Нәрсә, зимагурың кайттымыни?» Әнисе елап ялварды: «Ач дим, минем хакка ач!» Әтисенең: «Бар, үзең ач. Мин аны үз кулларым белән ачып кертә алмыйм»,— дип, каты итеп өй ишеген бәреп, кереп китүе ишетелде. Әнисе йөгереп төшеп капканы ачты. Мәхмүт бөрешеп өйгә керде. Әтисе урынына барып яткан иде инде, ул дәшмәде. Әнисе улының киемнәрен чишендереп алды. Мәхмүт тиз генә үз бүлмәсенә кереп ятты. Урыны җәюле иде, җылы иде. Әнисе аны як-ягыннан юрган белән төрде: «Син туңгансың улым, җылын, җылын!» Мәхмүт сабый чагындагы кебек эреп йокыга китте.

Иртәгесен ул торып, тулай тораклагы гадәте буенча, чыгып зарядка ясады, юынып кереп табынга килеп утырды. Элек ничек булган булса, бүген дә шулай. Дөрес, әтисе берничә мәртәбә сүз әйтергә талпынып карады. Ләкин әнисе шундук аның фикерен икенчегә борырга өлгерде. Ахырда ул барысына да кул селтәде булса кирәк. Мәхмүткә артык дәшмәде, аны күрмәмешкә салышты. Шул кайтудан Мәхмүт үз өендә торып калды.

Кышкы каникул беткәч, ул укуын дәвам итте. Аңа, нигә анда укыйсың, нигә тегендә бармыйсың, дигән кеше булмады. «Җаны теләгән — елан ите ашаган»,— дигәндәй, үзе теләгәч, әйдә, артист булсын,— дип килеште бугай әтисе дә. Хәзер инде артист дигәннәре дә начар яшәми, диләр. Элеккеге кебек күчеп йөрмиләр, калада гына уйныйлар. Кеше рәтендә хезмәт хакы алалар. Әнә Ашманскийлар бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгелләр ләбаса...

## Авылга йөз белән

Мәхмүт җәйләрен гел авылда уздырды. Авылның табигатенә, аның эчкерсез гади кешеләренә тәмам мөкиббән киткән иде ул. Шуңа күрә Мәхмүт, өченче курсны тәмамлаган язны, «культура бригадасы» составында авылга барырга дигән фикергә килде. Ул елны, партиянең «Авылга йөз белән» дигән чакыруына җавап итеп, Татарстан мәгариф халык комиссариаты шәһәр интеллигенциясеннән — артистлар, язучылар, музыкантлар, студентлардан торган унар-уникешәр кешелек махсус культура бригадалары төзеп авылларга җибәрде.

Ул бригадалар авыл халкына аң-белем таратырга: лекцияләр укырга, яңа төзелгән колхозларда комсомол ячейкаларының эшләрен җанландырырга, клубларны, кызыл почмакларны бизәргә, аларда үсешчән түгәрәкләр төзеп, аларга ярдәм итәргә, стена газеталары чыгарырга; көндезләрен бригадаларга — ындыр табакларына, басуларга йөреп җанлы газеталар өчен материаллар җыярга, кичләрен шуларны концертларда күрсәтергә тиешләр иде.

Бу гаҗәеп күпкырлы, четерекле, җитди һәм шул ук вакытта кызыклы да булган эш Мәхмүтне бөтен барлыгы белән үзенә тартты. Ул көннетөнне белмәде. Йөгерде-чапты, тирләде-пеште, язды-сызды, ындыр табакларында колхозчыларга булышты — орлык суырткычларын әйләндереште. Ә инде көндезге ял вакытларында колхозчыларга шигырьләр укыды.

Мәхмүтнең шулай ихлас күңелдән янып йөрүен күреп, район җитәкчеләренең берсе, быел районда даими эшли торган колхоз театры төзеләчәген әйтте һәм аңа шул театрның артисты булып калырга тәкъдим итте. Булачак театрның директоры да һәм художество җитәкчесе дә билгеләнгән. Алар хәзер анда — Алмай авылында оештыру эшләре белән мәшгуль икән.

Мәхмүтне бу тәкъдим бик кызыксындырды. Ул район җитәкчесенә, аның әле тагы алты ай укыйсы калганлыгын, киләсе елның март башында диплом алгач, әгәр инде соң булмаса, бик теләп ул театрда эшләргә риза икәнлеген белдерде.

Район җитәкчесе, бу мәсьәләне урында хәл кылу өчен директор исеменә язу язып, Мәхмүткә тоттырды да аны үзенең тарантасына утыртып Алмайга җибәрде.

Театрның базасы итеп табигатьнең гаҗәеп матур бер почмагына утырган Алмай авылы билгеләнгән иде. Авылның читендә Иж елгасы буендагы наратлыкта, элек янәшә-тирәдә генә түгел, бәлки бөтен өязгә мәшһүр булган байларның икешәр катлы матур-матур йортлары, озын-озын ташпулатлары урнашкан. Хәзер инде ул байларның күбесе чит илгә качкан, монда калганнары әллә кайчан Солавкига озатылган иде.

Алмайда Мәхмүтне театрның художество җитәкчесе колач җәеп кар-

шы алды. Ул Мәхмүтләр мәктәбендә укып, мәктәпнең драма түгәрәге белән җитәкчелек иткән, аннан театр техникумына укырга кереп, техникумны узган ел ук бетереп чыккан Әнвәр Кәримов иде.

Әнвәр башта Мәхмүтне директор белән таныштыру өчен аның квартирасына алып китте. Директор ике катлы агач йортның өске катындагы кечкенә генә бер бүлмәсендә тора икән. Аларны мәһабәт гәүдәле, куе коңгырт чәчен җилкәсенә кадәр үк төшереп артка тараган, зур авызлы, калын иренле шактый олы яшьләрдәге бер агай аяк өсте басып каршы алды.

— Хәбиб Шәрәпов булам мин. Рәхим ит, чибәр егет, әйдә, түрдән уз. Менә бу минем хәләл җефетем, дөресрәге, булачак театрның концертмейстеры, хормейстеры һәм просто артисткасы Рафига ханым булыр,— дип, үзеннән шактый яшь булган, кыска чәчләрен өчпочмаклы кызыл косынка белән урап бәйләгән, туктаусыз елмаеп тора торган яшел күзле бер ханым белән таныштырды.

Тышкы кыяфәтенә караганда Рафига ханым чегән хатынына охшыйрак төшкән иде. Үткер, җитез, кыскасы, чәчрәп тора. Сүзгә дә күршегә керә торганнардан түгел икән.

— Ә бу безнең директорыбыз гына түгел, землемерыбыз, агрономыбыз да, барсын бергә җыеп әйткәндә — хыялмейстерыбыз була,— дип Хәбиб аганың иңеннән кагып алды. Шуннан алар бер-берсенә карашып бүлмәне тутырып бер рәхәтләнеп көлделәр.

— Җыеп әйткәндә, Рафига ханымның сүзләрендә дөреслек бар,— диде Хәбиб ага, җитди кыяфәткә кереп.— Без монда театр гына түгел, кечкенә бер ферма булып та оешырга торабыз бит әле. Райбашкарма комитеты безгә, шушы утар белән бергә, берничә дисәтинә җир бүлеп бирде. Ат, арба-чана, сука-тырма кебек нәрсәләр белән тәэмин итте. Бүген иртәдән бирле шул җирне үлчәп, кайда нәрсә чәчәргә, нәрсә утыртырга икәнен планлаштырып йөрдек. Үзең иккән иген икмәген күкрәгеңә терәп бер кисүләре ни тора! Ярый, болары соңыннан.— Ул Мәхмүтнең язуын тагы бер кабат укып чыкты.— Димәк, безгә килергә булдыгыз? Рәхим итегез, хет бүгеннән. Әнә безнең каршыда берүзеңә бер бүлмә. Өйләнгәнме?

— Юк,— диде Мәхмүт, кызарып.

— Кызарма, кызарма, өйләнү ир-егет өчен зарури нәрсә. Әнә, Әнвәр Казаннан өч кыз алып кайтты. Теләсәң кайсын сайлап ал.

— Юк, аның үзенең техникумда сүз куешкан кызы бар,— диде Әнвәр, Мәхмүткә ярдәмгә килеп.

— Үзеңеке белән килсә бигрәк яхшы. Ишәябез дигән сүз. Безгә кызлар да, егетләр дә кирәк. Безнең хәзергесе көндә, менә Рафига апагызны кушып, нибарысы дүрт хатын-кызыбыз һәм Әнвәр белән мине кушып алты ир кешебез бар. Аларның да икесен пристаньга симәнә алырга җибәрдек.

Аннан алар, Әнвәр белән икәүләшеп, Мәхмүткә үзләренең биләмәләрен күрсәтеп йөрделәр: менә бу йорт гаиләле артистларга, монысы — кызлар тулай торагы, монысы — егетләрнеке.

Бу зал исә репетицияләр үткәрү өчен. Ә инде ишегалдындагы зур таш сарайны алар җылытып, сәхнә, грим бүлмәләре бүлдереп, өч йөз урынлы театр бинасы итеп корырга исәплиләр. Әлбәттә, бу әле киләчәктәге хыял, хәзергә әле аларның андый зур эшкә тотынырга вакытлары да, кешеләре дә һәм мөмкинлекләре дә юк.

«Хыялмейстер» агасының бу планнары Мәхмүткә дә бик ошады һәм ул киләсе елның март башында туры монда килергә сүз бирде.

Җәй ахырында бригада, үзенә йөкләтелгән эшләрне тәмамлап, Казанга кайтты. Бу вакытта Ашман абыйсы үпкә авыруы белән урын өстендә ята иде. Кайткан көнне үк Мәхмүт аның хәлен белергә килде. Ашман абыйсы Мәхмүтнең килүенә бик шатланды. Хәлсез куллары белән Мәхмүтнең учын кысып, аның авылдан алып кайткан тәэсирләре турында сөйләвен үтенде.

Мәхмүт барсын да сөйләде. Алмай авылында оешып килә торган колхоз театры, аның директоры Хәбиб Шәрәпов һәм Шәрәповның киләчәк хыяллары турында да сөйләргә онытмады. Техникумны тәмамлагач, эшкә аларга барырга сүз биреп кайтуы турында да әйтте.

Хәбиб Шәрәпов исемен ишеткәч, Ашман абыйсының хәлсез иреннәре сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйдылар. Эчкә баткан тонык күзләре яктырып китте:

— Булыр, булыр аннан. Ул элек тә шулай, хыялга бай кеше иде. Без аның белән Азин дивизиясе политбүлеге труппасында бергә эшләдек. Дуслар идек.— Ул арып, озак кына күзләрен йомып хәл алып ятты да, бүленеп калган фикерен дәвам итте:

— Без Төркстан фронтына киткәндә үк инде ул, авыл театры төзү турында хыялланып калган иде. Аның кул астына барып эләксәң, әрәм булмассың. Тик әйт аңа: иген игүне инде ул игенченең үзенә калдырсын, ул сезнең эш түгел. Сезнең эш — игенче күңеленә рухи орлык чәчү. Сез чәчкән орлык — ул авылның матур киләчәге. Моннан да изге бурыч бар микән артист өчен?.. Эх, авырмасам ... — ул кинәт буылып ютәлли башлый. Гөлчәһрә ханым тиз генә килеп аның башын күтәрә, аркасыннан тагы бер мендәр белән терәтеп куя, аңа дару эчерә. Ул тынычланып, күзләрен йомып йокыга киткән кебек була, ләкин Мәхмүт утырган урыннан кузгала башлауга, хәлсез кулы белән аңа китмәскә ишарә ясый. Озак хәрәкәтсез ятканнан соң күзләрен ачып Мәхмүткә тутырып карый да, елмаеп куя:

— Билгеле, сине Казаннан җибәрмәскә тырышырлар. Театр сине үзендә калдырачак. Уңайлы шартлар вәгъдә итәчәкләр һәм, гомумән, син монда калсаң, тиз үсәчәксең. Синең киләчәгең зур. Ләкин артист, әгәр дә ул чын артист-художник булса, беренче нәүбәттә халыкның киләчәге турында кайгыртырга тиеш. Син монда да кирәк, бик кирәк. Ләкин тегендә — авылда, кирәгрәк! Төшендеңме инде?

— Төшендем, Ашман абыем, бик төшендем.

— Төшенсәң, рәхмәт. Ярый бар, кайт инде. Мин аз гына черем итеп алам...

Мәхмүт кайтып үз бүлмәсенә бикләнде дә, мендәренә йөзтүбән капланып, тыела алмыйча елады. Аннан, аркасына әйләнеп, түшәмгә карап ятты. Күз алдына ап-ак чырайлы Ашман абыйсы килеп баса. Ябык иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып аның колагына акрын гына пышылдый: «Әгәр артист — чын артист булса...» «Син авылда кирәгрәк!»

Таң атканчы Мәхмүт күзләрен йомарга куркып, йоклый алмыйча ятты. Аннан арып, хәлдән таеп, чишенмәгән дә килеш йокыга китте.

Кояш та чыкмаган иде булса кирәк әле, ишек шакыдылар. Мәхмүт сикереп торып ишекне ачты. Ишектә әнисе басып тора иде.

— Бар, түбәндә сине Корбан кызы...

Әнисе соңгы сүзләрен әйтеп тә бетермәде, Мәхмүт яшен суккан шикелле атылып чыгып, парадный баскычыннан түбәнгә тәгәрәде. Парадный ишекләрен ике якка бәреп ачты да урамга чыкты. Урамда Тәнзилә басып тора иде.

— Ни бар? Ни булды?..

— Юк... — диде Тәнзилә бөтен гәүдәсе белән калтырап.— Ашман абый... — дип үксеп Мәхмүткә ташланды.

Мәхмүт башы әйләнеп, чайкалып китте. Шактый вакыт сүзсез-хәрәкәтсез баскан урынында катып калды.

Ашманскийны Яңа бистә зиратына, Габдулла Тукай, Кариевлар янына күмделәр.

Шулай итеп, татар театрына нигез салышкан, аны авыр еллар аша, бүгенге ирекле көнгә үз җилкәсендә тартып килгән артистларның берсе, 42 яше тулар-тулмас, дөнья куйды.

Әмма аның гомере бушка узмады. Ул үзенең кыска гына гомерендә

киләчәк өчен зур өлеш кертергә өлгерде. Мәхмүт һәм Тәнзиләләр күңелендә мәңге сүнмәс ялкын кабызып китте.

* * *

Чыгарылыш комиссиясе Мәхмүтне бертавыштан театр труппасына билгеләде. Ләкин Мәхмүт, комиссия әгъзаларын гаҗәпкә калдырып, аннан катгый рәвештә баш тартты. Ул гына да түгел, Мәгариф халык комиссариатыннан Алмай колхоз театрына билгеләнү турында язу алып кайтып, юлга әзерләнә башлады. Кайчан юлга чыгасын әйтеп Алмайга телеграмма да сукты. Ләкин... Китәсе көннәрдә генә менә шул «ләкин»нең иң зурысы һәм һич көтелмәгәне килеп басты.

Мәхмүтнең әти-әнисе аның артист булуы белән риза иделәр инде. Ул елларда театр һәм артистлар шәһәр халкы алдында шактый абруй казанып өлгерде. Күпләр артистларны ниндидер бер илаһи зат дип санайлар иде. Менә шул илаһи затның ата-анасы булу үзе бер мәртәбә иде шикелле. Ләкин аларның бу өметләре көтелмәгәндә челпәрәмә килде.

Көннәрдән бер көнне Мәхмүт кайтты да үзенең иртәгә бөтенләйгә китәсен хәбәр итте. Авылга, авылның да җәһәннәм читендәге бер караңгы почмагына. Адәм мәсхәрәсе! Шушы тамаша йорт-җирне ташлап, картаеп килә торган көннәрендә аларны япа-ялгыз калдырып? Өйләнеп, йортка хуҗа буласы, ата-анага игелек күрсәтәсе урында, ташла да кит, имеш.

Әнисе Минзифа түти шактый бирешә төшкән иде бу елларда. Килен хезмәтенә мохтаҗ иде ул. Үзенең бердәнбер килене итеп Мөршидәдән башканы күрми дә, күрергә теләми дә иде. Алар ахирәте белән һаман шул турыда хыялланып яшиләр иде. Мөршидә, театр техникумына укырга керә алмагач, башка уку йортларына керү турында уйламады да. Кыз балага нигә кирәк? Тугызны бетерде дә бирнә әзерләргә утырды. Артистка булмаса, артист хатыны булачак. Начармыни? Әнә, артист хатыннары театр фойесында ничек киенеп йөриләр. Ложаларда гына утырып карыйлар спектакльләрне. Спектакль беткәч, эшләпәле артист ирләре белән фаэтоннарга гына утырып кайтып китәләр. Кемнәр генә кызыгып калмый алар артыннан.

Артист хатыны булу турында аның аз гына да шиге юк иде. Бу инде хәл кылынган. Бирнәсе, бүләкләре, хәтта, колак сөенечләренә кадәр әзерләнеп куелган. Ничек кенә өметләнеп йөрмәсен теге песи борын, Мәхмүт барыбер аныкы булмаячак. Мәхмүтнең әнисе шулай дигән үзенең ахирәтенә. Мәхмүт укып бетерүгә, яучы җибәрәбез, дигән. Гөрләтеп туй итәбез, дигән.

Әйе, шулай дигән иде Минзифа түти. Инде ул көннәр килеп җитте генә дигәндә, Мәхмүтнең китәм дигән хәбәре аның башына кинәт күсәк белән китереп суккан кебек булды. Ул сүзсез калып иренә карады. Әти кешенең чигәсендәге кан тамырлары бүртеп чыккан иде. Күзен кан баскан иде әтисенең. Ул кулына нәрсә булса да алып, Мәхмүткә ташлану өчен як-ягына карана иде. Минзифа, куркып, аның кулларына ябышты. Авыз ачарга ирек бирмичә аны этkәләп-төрткәләп бүлмәсенә алып керде.

— Син сабыр ит әле, картым. Син утыр әле шунда, тавышсыз-тынсыз гына. Мин тиз генә барып, Мөршидәнең үзен алып килим,— диде дә, киенеп, чыгып йөгерде.

Мәхмүт үз бүлмәсендә китапларын, язмаларын барлап, кайберләрен китап шкафына, кайберләрен идәндәге зур кәрзингә тутыра иде. Хәзергә ул әле аларның үзе белән берсен дә алмаячак. Алмайга барып урнашкач, бер вакыт табып, кайтып алыр әле ул аларны. Хәзергә билгеле бер тәртипкә китереп, бикләп китәргә кирәк. Кая кирәк анда тузгып ятмасыннар.

Шулвакыт аның ишегең шакыдылар. Кем булыр икән? Әнисе ишек шакып тормый, әтисенең гомумән бу ишекне ачып караганы юк. Мәхмүт, нидәндер шикләнеп, теләр-теләмәс кенә: «Керегез!»,— диде.

Үзеннән алда борынны ярып керә торган хушбуй исләре аңкытып, бүлмәгә Мөршидә килеп керде.
— Мөмкиндер бит?..
— Кергәч мөмкин инде.
— Бәлки, урын тәкъдим итәрсез?
— Утырыгыз.
Мөршидә затлы күлмәкләренең итәкләрен күтәрә төшеп, күрсәтелгән урынга килеп утырды.
— Гаҗәпме?
— Шулайрак.
— Кайчан да булса бер керергә тиеш идем бит инде мин бу ишекләрне ачып. Шулай булгач, нигә сузарга?
— Аңламыйм!
— Аңламасаң күр — менә мин килдем.
— Шуннан?
— Шул. Бөтенләй килдем. Бүгеннән синеке булырга дип килдем. Кабул итеп ал.
— Мондый нәрсәләр белән шаярмыйлар, Мөршидә туташ.
— Нинди шаяру булсын? Мин бит синең ярәшелгән кәләшең.
— Кем ярәшкән? Кайчан? Кайда?
— Әти-әниләр ярәшкән. Без кечкенә чакта ук ярәшкәннәр. Син минем колагымны тешләгәнсең. Бу — йола. Ата-бабадан калган йола. Бу йоланы бозган кешеләр беркайчан да... беркайчан да бәхетле булмыйлар, ди. Ә минем бәхетсез буласым килми.
Ул, елап, Мәхмүтнең муенына сарышты. Мәхмүт, муеныннан аның кулларын алып, урынына утыртты һәм, иплән кенә, һәр сүзенең мәгънәсенә басым ясап:
— Акылыңа кил, Мөршидә. Син бит совет мәктәбе бетергән кыз, яхшы беләсең, бергә булу өчен, бәхетле булу өчен мәхәббәт кирәк. Мәхәббәтне көчләп муенга тагып булмый, бу — ахмаклык! — диде дә, инде кабарып килә торган ачуын яшерергә теләп, тәрәзәгә борылды.
— Димәк, безнең әти-әниләр ахмак булып чыга,— дип Мәхмүткә якынайды Мөршидә.— Әгәр дә бик беләсең килсә, алар безнең бәхетебез өчен тырышалар. Ә син?..
— Бәхетне һәркем үзе табарга тиеш, Мөршидә.
— Шәп инде, синең үзең тапкан бәхетең өрдең исә егылырга тора.
— Егылса, торгызырбыз, шуның өчен дә ул — мәхәббәт!
Мөршидә хурлыгыннан буылыр дәрәҗәгә җитте:
— Мәхәббәт!.. Каян килгән ди ул артистка мәхәббәт?.. Бүген берсе, иртәгә икенчесе белән себерелеп?!.
Мәхмүт, үз-үзен онытып, аяк тибеп кычкырды:
— Мөршидә!.. Син минем үземне теләсә ничек хәкарәт ит. Ә менә артистка тимә. Артист ул — илаһи зат. Артист ул минем өчен — Ашман абый. Ә Ашман абыйның изге исеменә тап төшерергә мин беркемгә дә рөхсәт итмәм!
Мөршидә шашып көләргә тотынды:
— Ха-ха-ха!.. Шул изге булганга күрә чахотка белән кәкрәеп катты.
Мәхмүт, яшен суккандай, өнсез калды. Күз аллары караңгыланып, буыла башлады. Нидер кычкырмакчы булды, тавышы чыкмады. Аннары гына кискен хәрәкәт белән ишеккә күрсәтте:
— Чыгып китегез!!!
Мөршидә зәһәрләнеп ишеккә типте. Ишек ике якка шапылдап ачылды. Коридор ягыннан тыңлап торган ике ахирәт, маңгайларын тотып, идәнгә чүктеләр. Мөршидә ярсып әнисенә ташланды:
— Син?! Сине тыңлап... Синең аркада шушы мәсхәрәгә калдым. Куралмыйм!.. Сине дә, үземне дә куралмыйм!.. Асылынам, хәзер үк асылынам,— дип кычкырды да, парадный баскычыннан дыңгырдап төшеп китте.

Әнисе башта сикереп торып кызы артыннан ишеккә ташланды:
— Кызым, балакаем, тукта!..
Аннары, кире борылып, чагарга әзерләнгән елан шикелле ыслап Минзифа өстенә килде:
— Шушы гыйбат токымнары белән туганлашырга йөрдек бит без, адәм мәсхәрәсе. Моннан соң урамыбыздан узасы булмагыз, хәерчеләр, тфү!..— дип ишекне бәреп чыгып китте.
Минзифаның өстеннән кайнар су койган шикелле булды.
— Я, алла! Бу хәлгә төшергәнче, җаннарымны гына алсаң ни булган!
Мәхмүт аңына килеп әнисенә ташланды:
— Әнкәй... Әнием, тор, тынычлан...
— Кит. Якыныма килмә. Син минем балам түгел!
Әйе, шулай диде. Хәтерли Мәхмүт, барсын да хәтерли: әтисенең шашкан кыяфәтен дә, бугазыннан буып алган көчле кулларын да, әнисенең йөрәк өзгеч тавышын да хәтерли. Аннары инде урам. Җил ыжгыра, буран котыра. Җил, юлдагы кар белән бергә, аның китапларын, дәфтәрләрен урам буйлап очыртып йөртә. Мәхмүт йөгерә-йөгерә китап битләрен, чәчелгән кәгазьләрен җыя. Каяндыр шунда Тәнзилә килеп чыга. Ул бер кочак китап күтәргән. Мәхмүт китапларын. Аларны ул Гөлчәһрә апаларына ташый. Мәхмүт каяндыр саквояжын табып ала. Аннары алар, Тәнзилә белән икәүләшеп, китаплар тутырылган авыр кәрҗинне Ашманскийлар ишегалдына сөйриләр... Аннан караңгы тыкрык. Караңгы, тар тыкрыкта кара толыпка уралган зур бер гәүдә. Гәүдәсе бер, ә йөзе күренми, тавышы гына ишетелә. Каяндыр гөбе төбеннән бүселеп чыккан калын тавыш:
— Сиңа, егет, Алмай ягына кирәкме? — ди.
Бу кичә иде. Кичә кич иде. Ә бүген? Бүген кая соң ул? Бүген нигә караңгы? Караңгы һәм тыгыз. Эссе. Бөркү. Чишегез, чишегез аның изүләрен, ачыгыз якасын. Бумагыз, урамагыз аны!
Кемнеңдер көчле куллары аны нәрсәгәдер урый, төрә. Авызына ниндидер салкын, ләкин шундук тамакны яндырып ала торган сыекча коя. Ул сыекча, аның бугазын яндырып, аяк бармакларына кадәр төшә башлый. Аны ялкыны-ние белән каядыр сөйриләр. Ул юл кырыендагы салам маякка чытыр ябыша. Аны көч-хәл белән йолкып алалар. Кулында бер уч салам йолкынып кала. Аны саламы-ние белән күтәреп алып каядыр илтеп салалар. Аның баш очында нәрсәдер шыгырдап кузгалып китә. Ул дыңгыр-дыңгыр килеп ниндидер караңгы бушлыкта тирбәлә. Дыңгыр-дыңгыр... шыгыр-шыгыр... Бишекмени! Сиртмәле бишек. Мәхмүт, шул сиртмәле бишектә тирбәлеп, сабый чагындагы кебек эреп йокыга китә.

## Ят өйнең кешеләре

...Мәхмүт басылып, тыны бетеп, шабыр тиргә батып уянып китте. Өстенә кат-кат өйгән авыр юрганнарын күтәреп ташлады. Алар каядыр түбәнгә барып төштеләр. Ул күзләрен ачты — түшәм. Кулын уңга суздыморжа. Акшарланган эссе моржа. Кулны пешерә. Астына җәйгән киезне капшап карады — кирпеч. Киез астында эссе кирпеч. Кулын сулга сузды — стена. Сап-сары нарат бүрәнәләрдән торган стена. Бу нинди җир? Ул кайда ята? Мәхмүтне ниндидер шом биләп ала һәм ул калтыравыклы зәгыйфь тавыш белән:
— Әнкәй! — дип кычкырып җибәрде.
Түбәннән тоныкына ягымлы тавыш килде.
— Әү, улым, әү!..
Кем бу? Әнисеме, түгелме? Охшаган да, охшамаган да.
Кемдер түбәннән аның аяк очына үрмәли. Кытыршы бармаклары белән аякларын капшый:

— Өстеңне ачып ташлагансың бит, балакай.
— Миңа эссе.
— Эссе булмыйча. Синең эчең яна. Эчеңә төшкән суык ялкын булып тышка чыга.
— Мин кайда?
— Мич башында.
— Кем өе бу? Кем мич башы?
— Безнең үзебезнең өй бу, үзебезнең мич башы.
— Ә сез кем?
— Мин үзем Фатыйма. Фатыйма әби, диләр мине. Бөтен авыл Фатыйма әби, ди, балам.
— Ә кайсы авыл бу?
— Имәнлек. Имәнлек диләр, балакаем, безнең авылны.
— Алмай түгелмени?
— Алмай түгел шул. Синең Алмайга барышың идемени? Әйтәм, өч тәүлек буена: «Алмай, Алмай,»— дип саташып ятасың.
— Өч тәүлек? Мин монда өч тәүлек ятаммыни инде?
— Шулай, улым, нәкъ өч тәүлек саташып ятасың.
— Ә ничек мин монда килеп кердем соң? Кем мине монда китерде?
— Аларын сөйләсәң, озак инде, өзлегерсең. Берәр нәрсә кабасың килмиме?
— Юк, минем эчәсем генә килә, әбекәй.
Фатыйма әби аңа түбәннән бер чокыр сузды:— Мә, кара миләш төнәтмәсе. Эч, эч, синең өчен төнәттем мин аны. Файдасы тияр, шәт, иншалла.
— Әби, миңа монда бик эссе.
— Хәзер, балам, хәзер түр сәкегә урын җаям дә...— дип мич яныннан китеп барды Фатыйма әби. Ул урын-җир белән маташканда, ишектән кемдер кайтып керде.

— Нишлисең, нигә туздырасың ул урын-җирне?— диде ишектән кергән хатын-кыз. Аның хуҗа хатыны икәне һәм бу өйдә аның рөхсәтеннән башка бернәрсә дә эшләнергә тиеш түгеллеге тавышыннан ук аңлашылып тора иде.
— Уянды. Эссе ди, монда төшеп ятасы килә.
— Кая, мин үзем,— диде дә хуҗа хатын, чишенә-чишенә мич аралыгына килде.— Хәлең ничек соң, чибәр егет,— дип Мәхмүтнең кулларын, маңгаен тотып карады.— У-у-у, бар әле кызуың бар. Иртә булмас микән?
— Монда бик эссе, зинһар, төшим инде мин,— дип кузгала ук башлады Мәхмүт.
— Тукта, тукта, үзең генә төшә алмассың. Кая, әбекәй, җәеп бетердеңме урынын?
Мәхмүт аякларын салындыруга, ул аның аркасыннан кочаклап, җиңел генә күтәреп алды да, зур сәкедәге урынга китереп салды. Аннан Мәхмүтнең өстенә калын юрган ябып, аякларын төрде.
— Исемең ничек синең?
— Мәхмүт.
— Менә бит. Башта без сине Ижауга баручы ар егете дип торабыз. Бактың исә, син үзебезнең татар егете икәнсең. Исемең дә матур, үзең дә чибәр, ничек шул хәлгә очрадың соң син?
— Нинди хәлгә?
— Кырда, коточкыч буранда адашып калгансың бит. Әгәр Гайнетдин абыең очрамаса... Әнә үзе дә кайтты, гомере озын булыр.
Эчтән чыпта белән тышланган ишек ачылуга, бусагадан йөгереп кергән салкын пар башта идәннән сәкегә үрмәләде, аннан шап итеп ишек ябылуга, кире идәнгә сөрлекте һәм идән буенча акрын гына таралып, сыеклана барып, юкка чыкты. Ишек төбендә башы түшәмгә тияр-

тимәс торган олы бер гәүдә пәйда булды. Ул әүвәл башындагы мескен бүреген салып чөйгә элде. Бүрек кыршавы белән бастырып куйган әрекмәндәй колак яфраклары бушанып, иркенәеп, җәелеп китте. Пәке белән кырган башы ничектер кечерәеп калгандай булды. Ул, калын иренле авызын колакларына кадәр җәеп бер елмайды да, билендәге билбавын чишеп сүтте, аннан шактый каешлана башлаган сары тунын салып чөйгә элде. Мич янындагы бүкәнгә утырып аягыннан киез итекләрен салды. Хатыны аңа мич куышыннан бәйләгән җылы оекбаш алып бирде. Ул чолгау өстенә шул оекбашны киеп куйды да, бүкәннән торып, сәке кырыена килде.

— Нихәл, егет, кузгалдыңмы? Вакыт, вакыт,— диде. Аннан ул почмак якка борылды. — Сәке түренә дә үзе төшеп ятмагандыр бит?

Почмактан Фатыйма әби чыгып янсәкегә килеп утырды.

— Сәке түренә дә үзе үрмәләр әле боерган булса, урамга да чыга башлар, иеме, улым,— дип Мәхмүткә карап.

— Сез бу йортның хуҗасы буласызмы?— дип сорады Мәхмүт олы гәүдәле кешедән.

— Әйе, шушы йортның хуҗасы булам.

— Әйтегез әле, Гайнетдин абый, сез мине кайда очраттыгыз һәм ничек мин бу хәлгә төштем?

— Ничек бу хәлгә төшкәнсеңдер, анысын белмим, энем...

— Мәхмүт, Мәхмүт икән аның исеме,— дип, иренә ярдәмгә килде хатыны почмак як чаршавыннан башын тыгып.

— Ә-ә, очраттым мин сине, Мәхмүт энем, беләсеңме кайда...

Шул вакыт ишегалдында котырынып эт өрә башлады һәм капка ачылган тавыш ишетелде. Мәхмүт калтыранып почмакка сеңә төште.

— Шул... Шул эт өрә,— дип куркып юрган итәге белән йөзен каплады. Эт өргән тавыш, кар күмеп киткән басудагы ачы җил сызгыруы, эссе тыгызлыктан буылу белән бергә чәңгелдәп, миенә сеңеп калган иде.

— Ул эттән курыкма син, энем, ул эткә рәхмәт әйт. Ул эт булмаса, мин күрми узып киткән буладырыем әле үзеңне.

Өйалдында кемдер кыштырдады, ишеккә типкәләнгән шикелле булды. Гайнетдин абзый торып ишек ачты.

— Кайсы икән ул анда, ишек тә ача алмый дисәм, үзебезнең Фәезхан икән әле. Әйдә, түрдән уз, утыр,— дип ишектән кергән унбер-унике яшьлек бер ак чырайлы чибәр генә малайның кулыннан тотып, йөзлеккә китереп утыртты Гайнетдин абзый. Аннан Мәхмүткә борылып:— Бу безнең авылның укытучы малае була,— дип аңлатты.

— Ә-ә-ә, бу синмени әле, улым? Кунак булып килдеңме? Әллә йомыш беләнме?

— Йомыш беләнием, әби.— Фәезхан дигән малай суыктан шактый ук җебеп кергән борынын тартып алды.

— Йомышың миңа идеме?

— Сиңа ие, әбекәй.

— Әтиең Габделбәр җибәрдеме?

— Шул җибәргән ие. Гел мине йөгертәләр, үзләре оялалар да,— дип үпкәләгән сыман тагы борынын тартып алды Фәезхан.

— Сине йөгертми, кемне йөгертсен инде алар. Син бит аларның бердәнбер тыңлаучан улы.

— Шул тыңлаучанлыгым аркасында әле хәзер генә бабайдан эләкте үземә,— дип зарланды Фәезхан.

— Кит аннан!— Гайнетдин абзый җитди кыяфәт белән гаҗәпсенгән булып башын чайкап куйды.

— Ни өчен сукты соң ул сиңа, улым?— Фатыйма әби малайның башыннан сыйпап алды.

— Шул инде... Әти сүзен тыңлап, бабайның чапанын чәлдергән идем, этиләргә театр уйнарга. Күреп алды да...

— Инде әтиеңнәр чапансыз нишләр?

— Йөрмәсләр театр уйныйбыз дип, олыларны мыскыл итеп...

Малай бу сүзләрне Фатыйма әбинең фикеренә җайлашырга теләп, дөресрәге, шул юл белән аның карашын белергә теләп әйтте шикелле. Ләкин Фатыйма әбисе моңа тискәре караштa түгел икән. Ул Фәезханның иңеннән кочып алды да болай диде:

— Юкны сөйләмә, улым. Нигә олыларны мыскыл итү булсын, ди ул андый уеннар? Бабаң да алай уйламасын. Ул хәзрәт кеше, башкалар шикелле надан түгел, белергә тиеш. Андый уеннар безнең бик борынгы заманнардан ук калган. Борынгы бабаларыбыз шундый уеннар уйнап халыкның күңелен ача торган булганнар, халыкка төрле гыйбрәтле хәлләрне күрсәтеп биргәннәр.— Ул, башын түбән иеп, бераз уйланып торды.— Ни хәл итәсең, элек-электән бигрәк караңгы як шул безнең яклар,— дип көрсенеп урыныннан торды. Аннан, түр як идәндәге зур сандык янына килде дә, Фәезханга борылып:

— Әтиеңә бу юлы нәрсәләр кирәк инде, улым? — дип сорады.

— Шулар ук. Теге юлы биргән әйберләрегез: такыя, кесәбикә, тәңкәләр тезгән күкрәкчә... аннан, аннан...— Малай тагы нәрсәләр кирәген исенә төшергән арада, Фатыйма әби тәрәзә өстенә кыстырган зур ачкыч белән борып сандыгын ачарга тотынды. Бу гаҗәеп сандыкның йозагы ачканда-япканда нindидер кызыклы музыкаль авазлар чыгара иде.

— Мә, улым — дип, Фатыйма әби Фәезханга зур гына бер төенчек сузды.— Менә, барысы да шунда, узган юлы син китергән килеш, чишмәгән дә идем.

— Рәхмәт, әбекәй.

— Кая инде, болай булгач, чапанын да үзем биреп торыйм,— дип сандык төбеннән зур гына бер чапан чыгарды Фатыйма әбисе.— Менә Гайнетдин абыеңның бабасыннан калган чапан бу. Бохарада укып кайтканда шуннан ала кайткан иде, кирәге чыкмады. Үзен дә мулла итмәделәр, улы да теләмәде, мәрхүм. Ә инде монысы — улының улын әйтәм, кул гына селти,— дип кеткелдәде Фатыйма әби, оныгы Гайнетдингә карап.

— Син инде аны, әби, Фәезханга бүләк ит. Бабай кадәр бабайны мулла итмәгәнне, мин наданны берәү дә мулла итмәс. Ә менә Фәезхан...

— Юк инде, мин мулла булмыйм, беләсең килсә.

— Ә кем буласың соң?

— Әртис булам,— дип Фәезхан әбисенең кулыннан чапанын тартып алды да, кош тоткандай ишектән чыгып йөгермәкче иде, түрдә яткан, аңа таныш булмаган егет аны туктатты:

— Тукта әле, энем... артист...

— Мин әле артист түгел, булачакмын гына.

— Бик әйбәт. Алайса таныш булыйк, менә мин үзем, инде булып җиткән артист, дөресрәге, кесәмә артист дипломы салган егет...

Фәезхан аны бүлдереп, бусагадан түргә ташланды:

— Син? Әртисме? Чын әртисме?

— Дипломы булгач, чын буладыр инде. Ләкин кызганыч, мин бүген сезнең спектакльне карарга бара алмыйм. Юкса бик күрергә теләр идем дә... менә бит, авырыйм... Ә менә әтиеңне күреп сөйләшәсе иде...

— Әйтәм, әтигә хәзер үк кайтып әйтәм. Әгәр күрше авылга бара алмасалар, бүген үк килер.— Аннан ул Фатыйма әбисенә борылды.— Менә шатлык, ә? Безгә әртис... Чын әртис килгән!— дип канатланып чыгып йөгерде. Өйдәгеләр бар да малайның кыланышыннан рәхәтләнеп көлеп калдылар. Аннан Мәхмүткә борылдылар.

— Менә ничек... Син әртис егетмени әле?

— Болай булгач, була алмамдыр шикелле.

— Юкны, сөйләмә, нинди булмау ди ул? — Фатыйма әби әлеге музыкаль сандыгын чыңгыл-чыңгыл итеп бикләде дә, ачкычын тәрәзә өстенә куеп, сәке түренә — Мәхмүтнең баш очына ук менеп утырды.

— Кая, килен Әсхәбҗамал, ашың буламы? Бераз кайнар шулпа капса, кунак та сихәтләнә төшәр иде.

— Хәзер, әби, токмач салдым,— дип, Әсхәбҗамал түр сәкегә зур гына ашъяулык китереп җәйде.— Гайнетдин, син дә юынып ал, юлдан кайткан кеше, ачыккансыңдыр.

— Бара алмадым, буран,— ул елмаеп Мәхмүткә борылды.— Мәнә сине алып кайтканнан бирле өч көн буе буран котыра. Күрше урыс авылыннан духтыр алып килеп күрсәтмәкче идем үзеңне, тагы булмады.

— Рәхмәт. Хәзер инде җиңеләям кебек, азапланып йөрмәгез. Сезгә бу кадәресе өчен дә...— Мәхмүт кинәт буылып ютәлли башлады.

— Улым, Гайнетдин, тот әле, күтәребрәк тор әле бераз! Мин мендәрен рәтлим. Менә шулай, мендәргә терәп, күтәребрәк утырт, ютәлләмәскә әйбәт була ул.

Алар Мәхмүтнең артына мендәрләр кыстырып, утыртып ук диярлек куйдылар. Аннары Фатыйма әби үзенең төнәтмәсен эчерде. Мәхмүтнең сулыш юллары киңәеп киткән кебек булды. Ул иркенрәк һәм җиңелрәк сулый башлады.

— Сез, Гайнетдин абый, сөйләп бетермәдегез бит әле...

— Әйе шул. Теге артис малай килеп керде дә...

— Кызык егет,— диде Мәхмүт.

— Һәй, син аларның кызыкларын менә театр уйнаганда барып күрсәң икән...— дип, бик тәфсилләп сөйләп китмәкче иде дә Әсхәбҗамал апа, Гайнетдин абзый шып туктатты.

— Син торып тор әле Әсхәбҗамал, бар ашыңны булдыр, монда ач карынга театр тыңлап булмас. Аннан килеп, менә Мәхмүт энекәшнең дә театр хәлләре турында беләсе килә.

— Алар театры турында да бик беләсем килә минем. Чөнки мин үзем дә...

— Сөйләрбез, анысын да сөйләрбез, бүген кич безнеке, тик менә кәефең генә начарланып китә күрмәсен,— дип, Гайнетдин абзый Мәхмүтне ничек очратуын сөйли башлады...

* * *

...Табынга аш килде. Мәхмүт беренче мәртәбә кулына кашык алды. «Чынлап та, котылды бит егет болай булгач, котылды.» Гайнетдин абзый, өрә-өрә агач кашыктан кайнар шулпа йотарга азапланган Мәхмүткә карап, әнә шулай үзалдыңа елмаеп алды.

— Шулай да мина бер нәрсә аңлашылмый. Үзен ыспай гына киенгән нәзберек кала егете, безнең ул Качкалак чокырындагы маяк төбенә каян килеп чыктың соң син, буран котырган кышкы салкын төндә?— дип, Мәхмүткә сораулы караш ташлады.

— Һәй, абый, аларның барысын да сөйләсәң...

— Сөйләр әле, сөйләр. Хәзер борчыма син аны, өзлектерерсең егетне,— диде Фатыйма әби.

Мәхмүт шулай да сөйләде. Әкренләп, хәл җыя-җыя барсын да сөйләде. Кем булуын, кая баруын, һәм ни өчен баруын.

Әсхәбҗамал түти хәйран калды.

— Әй, егет, егет, карап торырга үзең акыллы гына күренәсең. Бактың исә, шыр тиле икәнсең, кем әйтмешли...

— Чү, җүләр, нигә кешегә шулай дип әйтәсең?

— Әйтми ни, кала кадәр каланы, шундый йорт-җирне ташлап, җәһәннәм астындагы Алмайга — дөм-караңгы авылга китәме ата-анасына бердәнбер бала? Театр дигән, булып, җитмәсә...

— Юкны сөйләмә син, килен, димәк, ул үзе сайлаган шөгылен ярата. Яратып эшләгән эштән дә ләззәтле ни бар дөньяда? Менә син үзеңнең иреңне генә ал: атыннан-юлыннан аерып, көн саен мунча кертеп, балда-майда гына йөздереп тотып кара әле син аны өендә, торыр микән? Һич тормый. Көн диме, төн диме, буран диме, мәхшәр диме, чыга да

чаба атын жигеп. Чөнки ул шуның белән яши, шуннан үзенә азык ала.

Әсхәбҗамал түти һаман үзенекен сукалады:

— Ямщик чапмаса да житәрлек безнең иккән азыгыбыз, өч иманага, аллага шөкер. Аның юлында тапканы шул юлында кала бирә, өйгә бер тиенге дә кайтмый, белеп тор!

Фатыйма әби рәхәт бер көлү белән кеткелдәп алды.

— Һәй-й-й, килен!.. Локма бер карын азыгы белән генә яши алмый бит адәм дигән зат, аңа әле жан азыгы да кирәк,— дип бу мәсьәләгә нәтижә ясап куйды.

Аштан соң мич артындагы чикерткә сайравын тыңлап байтак кына сүзсез утыргач, үзен борчыган мәсьәләне уртага китереп салды Гайнетдин абзый.

— Кем булыр икән?.. Кешене шулай, явне үлсен дип, төннәрен түгел, көндезләрен дә юлчылар як-ягына каранып уза торган ул Качкалак чокырына ташлап китүче явыз кем булды икән? Беләсе иде...

— Хәзер инде аны каян беләсең, эш узгач,— дип почмак яктан Әсхәбҗамал түти аваз салды.

— Бу егет әз генә төсмерләсә белеп булыр иде, табып булыр иде ул явызны. Бәлки, нәрсәсе белән булса да хәтерендә калгандыр, әйтик киеме, төсе-бите, тавышы?..

— Юк шул, хәтерләмим,— дип ачынды Мәхмүт.— Карангыда очраштык. Төсен-битен күрсәтмәде. Ә киеме... Киеме шул... толып, кама бүрек, алыптай гәүдә.

— Сакаллы диден бит син аны?

— Сакаллы. Көрәктәй сакаллы, йонлач кашлы.

— Менә-менә...

Почмак яктан Әсхәбҗамал түти шаркылдап көлеп жибәрде.

— Тотты безнең хыялый болай булгач, якасыннан ук эләктереп алды! Әз иде сакаллы, йонлач кашлы кешеләр бу дөньяда. Әнә, безнең авылда гына да ни чаклы алар...

— Безнең авылда да бар иде ул андый албасты, атканнардыр инде үзен явызның.

— Әбекәй дөрес чамалый, бу шул токымнан булырга тиеш. Синең әртис булуын, кая баруың белән кызыксынды диден бит? «Я син аны, яки ул сине»,— дип әйтте дисең.

— Шулай диде.

— Менә, менә, шул токым, әбекәй әйткән шул албасты токымы,— дип сөйләп китте Гайнетдин абзый.

Албасты дигәннәре шушы авылның бер кулагы булган. Узган кыш Солавкига сөргәннәр үзен. Әмма ул юлдан качып кайтып, төнлә үз йортына тыштан йозак салып ут төртә. Аның йортына Урал заводларыннан килгән егермебишмеңчене урнаштырган булганнар икән. Йорт яна башлау белән үк әлеге кеше тәрәзәдән сикерә. Өй почмагында саклап торган албасты аны сәнәк белән кадап үтерә. Бу явыз нәкъ менә шул токымнан булырга тиеш. Олаучы эше түгел бу. Олаучы үзе тунса туна, үзе өшесә өши, ләкин юлаучысын чәчми-түкми, исән-имин килеш кирәк жиренә илтеп тапшыра.

Гайнетдин абзый хикәясен тәмамлап почмакка, хатыны Әсхәбҗамал жәйгән урынга кереп ятты. Мәхмүт эчкә баткан күзләрен түшәмгә текәп уйга калды: егермебишмеңче... Узган ел алар йөргән якларда да егермебишмеңче колхоз председателен кулаклар ерткычларча кыйнап үтергәннәр иде. Егермебишмеңче!.. Бу сүз үзе генә дә явыз албасты токымын дер калтырата. Инде алар авылга яңалык алып килүче артистны да егермебишмеңче белән бер сафка куеп, аны да юк итү юлына басалар икән, димәк, алар артисттан да куркалар. Димәк, хәзер, менә бүген, авылга артист та кирәк. Димәк, ул дөрес юлда һәм бу юлдан аны берничк каршы көч тә бора алмас. Эх, тизрәк савыгып аякка басасы иде!

# Тагын юлга!

Иртән кызарып кояш чыга. Март кояшы. Тышта якты, тын. Суык. Көн уртасы якынайганда, кояш авыл өстенә үк килеп, үзенең көчле нурларын җиргә сибә башлый. Түбә карлары эреп, нигезгә тамалар. Тора-бара ул тамчылардан бозлы уклар хасил булып, түбәдән салынып-салынып төшәләр. Ат тизәге түшәлгән урам юлларында чыпчык эчәрлек кар сулары хасил була. Алар, кояш нурында зәгыйфь кенә төтәп, ерганак ера башлыйлар. Гөрләвекләр авылга яз алып килә. Кешеләр кар күмеп киткән салам түбәле базык өйләрдән тышка — ишегалдына, урамнарга сибеләләр. Йөзләрдә елмаю һәм өмет. Бала-чага, күтәртмәле чабаталардан, чыр-чу килеп гөрләвектә «көймә» агыза.

Урам юлларыннан чана белән узу инде авырая. Чана табаннары юл тизәгенә, тирескә, салам көлләренә ябышып чанага җигелгән атның корсак асларыннан ак күбекләр сыгып чыгара. Басу юлларыннан да җырлап шумый хәзер чана табаннары. Юл карлары йомшак, ат тояклары бата, чана табаннары ябыша. Кыскасы, соңгы чана юллары. Юлда ялгыз олау. Чанасын печән белән күмгән. Чана башына, атка арты белән, юлаучы утырган. Ул яз кояшына иркәләнеп, күзләрен кыса төшеп, эченнән нидер көйли-көйли тирбәлеп бара. Олаучы үзе чана мөгезенә тотынып, яннан җәяү атлый. Олы гәүдәсе белән терәп чананы тирән чалуларга төшеп китүдән саклый. Ара-тирә, инде шактый өшәнгән атына чөңгереп-чөңгереп ала:

— На-а-а, бахбай!

Олы гәүдәле олаучы — безнең киң күңелле Гайнетдин абзыебыз. Чана түрендә озак һәм каты авырудан агарып, ябыгып, ничектер чандыраеп калган егетебез Мәхмүт утыра. Алар, менә икенче тәүлек инде, юлда. Көн кичкә авышып бара. Кояш язгы зәңгәр күк түреннән түбәнгә тәгәри башлады.

Күп тә калмады шикелле инде. Гайнетдин абыйсының чамалавына караганда, ул «җәһәннәм астындагы» Алмай авылына барып җитәргә күп тә калмады. Һәрхәлдә, бүген кояш баеганчы барып керергә тиеш алар. Алданрак та барып җитәргә була иде, юл авыр, куып булмый, ат өшәнә. Әле кире кайтасы да бар бит Гайнетдин абыйсының.

Нишләмәк кирәк, озак кунак булырга туры килде бит Мәхмүткә Иманлеледә. Февраль бураннарында алып кайтып салган иде Мәхмүтне Гайнетдин абыйсы Фатыйма әбисенең мич башына, инде менә март ахыры. Авыруы каты булды шул егетнең. Аякка басканның соңында да тиз генә йөреп китә алмады. Билгеле инде, аны ул хәлендә мондый ерак юлга чыгарып җибәрмәделәр. Гәрчә ул үзе көн саен китәм, китәм, дип өзгәләнсә дә, аны сабыр булырга, борчылмаска үгетләделәр. Савыгып җитмәс борын юлга чыгып өзлегүеннән курыктылар.

Мәхмүт Иманледән калага да берничә хат язган иде. Әнисенә, Гөлчәһрә апасына һәм әлбәттә, Тәнзиләгә. Хатларында ул үзенең авылда авырып ятуы турында ләм-мим бер сүз әйтмәде. Килеп җиттем, эшлим, театр белән авылларда йөрибез, төп адресым билгеле булмый торып, миңа җавап салмагыз, дип язды. Авыруы турында әйтеп аларны борчыйсы килмәде. Бигрәк тә Тәнзиләсен. Ул белеп алса, хәсрәтеннән үзе авыруга сабышыр иде.

Алай гына да түгел, җәяүләп Иманлегә чыгып китәр иде. Юлда тагы буран чыгып, ул да адашса?.. Салкын тидереп ниндидер авылда, билгесез кешеләрдә газапланып ятса? Гайнетдин абыйлары кебек изге җаннар гел очрап тормас бит... Әйбәт хатлар гына язды ул Тәнзиләгә. Аның күңелен күтәрерлек итеп. Шуңа күрә ул Тәнзиләсен һәрвакыт шат, көләч һәм бәхетле итеп күз алдына китерде. Менә, хәзер дә ул аның белән кебек. Әнә, чана артыннан йөгерә, аннан килеп үрәчәгә баса,

печән өстенә тәгәри, имеш. Мәхмүт аңа үрелә, тотмакчы була. Тәнзилә аны үчекләп янадан юл читенә сикерә. Язгы юеш карны йомарлап Мәхмүткә ыргыта. Мәхмүт шаркылдап көлеп җибәрә:

— Ха-ха-ха!

Гайнетдин абзый гаҗәпсенеп аңа карый.

— Нәрсә, күреп тә алдыңмыни?

— Кемне?

— Кемне түгел, Алмайны дим.

— Күренәмени?

— Әнә Алмай.— Гайнетдин абый дилбегәсен кулына алып, урәчәгә менеп утырды.— Әнә, наратлы тау башында элеккеге Алмай байларының ташпулатлары.

Мәхмүт борылып алга карады.

— Әйе шул... Шул үзе. Шул ташпулатларга урнашкан инде Алмай театры... Безнең театр.

## Кара баганалар...

Иж күперен чыгып, Наратлы тауга менүгә, ат кинәт туктап калды. Гайнетдин абзый алга карап, беравык ничектер сәер кыяфәткә кереп, сүзсез торды. Йөзе тагы да карала төшеп, күзләрен төссез томан каплады. Аннан, ничектер азап белән, калын иреннәрен кыймылдатыр-кыймылдатмас кына пышылдап:

— Ут төрткәннәр, ә...— дип сузып куйды. Бу сүзләр Мәхмүтнең тәнен электр тогы кебек куырып үтте, йөрәгенә ук булып кадалды.

Ул беравык сүзсез калды, аннан бар көчен туплап чанадан сикереп төште дә сөртенүдән карга тезләнде. Аның каршында әле узган яз гына Хәбиб абыйсы белән карап йөргән таш сарай иде. Көзен Хәбиб абыйлары аны театр бинасы итеп үзгәртеп, барлык репетицияләрен шунда алып барулары, хәтта инде ул бинада берничә спектакль уйнаулары турында да язган иде. Һәм менә каршында түбә-түшәмнәре янып җимерелгән, ишек-тәрәзәләре күмергә әйләнгән таш кыса. Буш тәрәзә өлгеләре аркылы Иж тавы астына төшеп күмелә барган март кояшының кып-кызыл шәүләсе күңелгә куркынычлы шом сала. Кара-кучкыл кыса эчендә утырып калган мич морҗалары кара багана булып күккә текәлгәннәр. Монда нәрсә булган? Яумы? Бөтен дөнья янып, адәм заты кырылып беткәнме әллә?

Шомлы тынлык. Җил дә исми, чыбык та селкенми. Мәхмүт акрын гына башын күтәрә, күккә карый. Күктә караңгылык куера. Кара-кучкыл морҗалар күк караңгылыгына тоташалар. Буш тәрәзә өлгеләрендәге кызыл комач урынына караңгылык тула. Тезләнгән җирендә оеп китә язган Мәхмүт көч-хәл белән торып аякка баса. Йөзен юлның икенче ягына бора. Я, хода! Нәрсә бу? Каршы якта ике катлы агач йорт бар иде бит әле. Югарыда Хәбиб абыйлары һәм Әнвәр Кәримов квартирасы, аста кызлар һәм егетләр бүлмәсе... Мәхмүт тә шунда яшәргә тиеш иде.

Ә хәзер? Хәзер ул йорт юк. Аның урынында янып күмергә әйләнгән бүрәнә башлары һәм морҗалар... Янган чыршы кәүсәләре кебек корымлы, шәрә морҗалар. Җил дә, давыл да юк, ә алар тирбәләләр шикелле...

— Мәхмүт! — Баскан урынында чайкалып, як-якка сөрлегә башлаган Мәхмүтне култыгыннан эләктереп алып, чана башына китереп утыртты Гайнетдин абыйсы.— Сиңа нәрсә булды?

— Юк, юк, зарарсыз... Мин хәзер, хәзер...

Шул вакыт кисәү агачлары, бүрәнә башлары өеме артыннан берәүнең тавышы ишетелде.

— Сез кемнәр, кая барышыгыз?

Караса, янган йортның ишегалды түрендә, җиргә сеңеп бара торган тагы бер кечкенә кенә агач йорт бар икән. Шуның ишегеннән бер әби чыгып боларга якынайды.

— Монда килгән идек без, әртисләр янына,— дип, Гайнетдин абый кулларын җәеп әбигә сораулы караш ташлады.

— Юк шул инде алар... Күрәсез, ни тамаша ясап ташладылар явызлар...

Мәхмүт кинәт айнып китте.

— Кемнәр? Кемнәр аларны шулай итте?!

— Кем белгән аларны. Берсен тотканнар ди бугай инде.

— Ә Хәбиб абый?..

— Бүлнистә ул, үлгәндә калды. Хәзер исән ди бугай инде. Сез авылга барыгыз. Ерактан киләсегез булса кирәк, күрәм, атыгыз да бик өшәнгән. Хәбибрахманның җәмәгате Рафига кызым хәзер авылда тора. Әнә генә, моннан күренеп тора, кара-каршы ике йорт. Ул сезгә барсын да сөйләр. Мин бит аларның каравылчысы идем. Ярый әле, ходай кушып, минем куышым исән калды.

* * *

Рафига ханым, тәрәзәдән күреп алуга, капка төбенә йөгереп чыкты.

— Килдегезме? Хәбиб абыегыз көтте инде сезне, көн саен көтте. Ә мин, дөресен әйтим, ышанмаган идем. Берәүләр безне ташлап киткән вакытта, икенчеләр киләме соң, дип уйладым.

— Хәбиб абыйның хәле ничек?

— Кергәч, барсын да өйгә кергәч, сөйләрмен.— Ул капка төбендә басып торган яшь кенә бер чибәр кызга борылды: — Зәйтүнә, ач капканы.

Кыска чәчле, кыска итәкле әлеге кыз өр-яңа урыс капканы төбенә кадәр ачты. Ят ишегалдына керергә икеләнеп торган Гайнетдин абзыйны күреп, Рафига ханым атның йөгәненнән әләктереп алды да үзе җитәкләп алып керде. Ул арада түрдәге өйдән йорт хуҗасы үзе килеп чыкты. Рафига ханым белән Зәйтүнә Мәхмүтне өйгә алып керделәр. Хуҗа кеше белән Гайнетдин абзый атны туарып җылы лапаска кертеп бәйләделәр, өстенә җәймә капладылар.

— Суынсын бераз, соңыннан чыгып сугарырбыз, ашарына салырбыз,— дип, хуҗа кеше Гайнетдин абзыйны үз өенә җитәкләде.

Авылда кичке аш вакыты җиткәнлектән, Рафига ханымның самавыры кайнап чыккан, табыны әзер иде. Өйгә керү белән Мәхмүткә мич башыннан алып җылы киез итек бирделәр. Зәйтүнә аралыктан кечкенә ләгән чыгарып ишек төбенә куйды да, комганнан җылы су салып торды. Аннан табынга утырдылар. Өйгә кергәннән бирле Мәхмүт берничә мәртәбә Хәбиб абыйсының хәле һәм, гомумән, Алмайда нигәр булуы турында сорарга тырышып караса да Рафига ханым: «Соңыннан, барсы да соңыннан»,— дип ул турыда авыз да ачырмады. Ерак юлдан туңып, ачыгып килгән кешенең күңелсез хәлләр сөйләп кәефен җибәрәсе килмәде булса кирәк. Алар Зәйтүнә белән икесе дә мөмкин кадәр шат күренергә тырыштылар. Аны хәзинәдә бары белән сыйладылар, шаярдылар, көлделәр. Ләкин боларның берсе дә Мәхмүтне юата алмады. Әледән-әле аның күз алдына очлары күккә ашкан шыксыз шәрә морҗалар килеп басты, баягы әбинең «үлгәндә калды Хәбибрахман» дигән сүзләре яңгырап торды. Аның тамагыннан ризык үтмәде. Ахыр чиктә ул алдындагы тәлинкәсен читкә этәреп куйды да: «Тилмертмәгез мине, сөйләгез, зинһар»,— дип Рафига ханымның күзләренә текәлде. Рафига ханым йөзен читкә борды.

— Ярый, тынычлан, хәзер сөйлим. Ә син бар, Зәйтүнә, әбидән кунакларга урын-җир алып чык,— дип, үзе табынны җыярга тотынды.— Безнең бит урын-җирләребезгә кадәр янып бетте.

Зәйтүнә, бер кочак урын-җир күтәреп, чыгып та җиткән.

— Лампаны да күтәрә төшсәң икән, Зәйтүнә. Күңелгә караңгылык сирпеп утырмасын. Сез дә, әле сөйләмәс борын, калтырап төшмәгез. Алай куркырлык бернәрсә дә юк... Иң мөһиме — Хәбиб абыегыз савык-ты, бүген-иртәгә өйгә кайтырга тора, ә калганы бар да узгынчы. Без-нең өчен көтелмәгән бернәрсә дә юк һәм булмады да. Без көтә идек аны, байтактан көтә идек...— дип, сөйләп китте Рафига ханым.

## Рафига ханым хикәясе

...Безнең Алмайга килеп урнашуыбызга атна-ун көн дә үтмәгән-дер. Син безнең, әлеге шул янган йортның өске катындагы бүлмәбезне беләсең. Аның ян тәрәзәсе Иж күперенә төшә торган таш юлга карый. Узган елның март ахырлары иде. Ләкин былтыргы яз көттереп килде. Көннәр салкын торды, чана юлы апрель урталарына кадәр өзелмәде. Төн уртасы җитеп килә иде. Без Хәбиб абыең белән, гадәт буенча, ярты төнгә кадәр укып ятканнан соң, утны сүндергән идек, кинәт тышта, нәкъ безнең тәрәзә каршында мылтык шартлады. Сикереп торып тәрә-зәгә ташландык. Карыйбыз: җигүле ат, чана үрәчәсенә менеп баскан алыптай зур гәүдә. Ул, тәрәзәдән безне күрүгә, кыска мылтык тоткан кулын күтәреп янә ике мәртәбә һавага атты да, икенче кулындагы төен-чеген безнең тәрәзәгә таба ыргытып, атын чыбыркылый-чыбыркылый, Иж тавыннан түбәнгә төшеп юк булды. Без Хәбиб абыең белән бер-беребезнең күзләренә карап, нишләргә белмичә аптырап тордык. Аннан Хәбиб абыең: «Безгә нидер тапшыруы булды бу бәндәнең, төшеп алырга кирәк»,— дип киенә башлады. Ә мин әйтәм, нигә мылтык атты, дим.

— Күрәсең, безне йоклый дип белгән, үзенчә хәбәр салуы,— дип ишеккә юнәлде Хәбиб абыең. Мин аның кулына килеп ябыштым. «Төш-мә! Икенчесе ишек төбендә саклап торадыр, харап итәр»,— дим. «Бул-маганны»,— дип, кулын гына селтәде Хәбиб абыең. Әлеге кеше ташлап киткән төенчекне тиз генә алып та менде. Ак киндергә төреп, мунчала белән урап бәйләнгән, кечерәк кенә бер төенчек. Үзе шактый авыр. Утны яндырып төенчекне сүтеп карасак... ни күзләребез белән күрик — яңа суйган яшь бозау башы! Суынырга да өлгермәгән хәтта. Парлары чыгып тора кебек. Мин куркуымнан кычкырып идәнгә сеңдем. Хәбиб абыең шаркылдап көлеп җибәрде. Ул һәрвакыт шулай: курку-шом, шик-шөбһәне, үзенчә көлеп тарата, шуның белән мине тынычландыра иде.

— Тукта, ачу китереп көлмә ичмасам, көләрлекме соң монда хәл?— дим.

— Еларлык та түгел,— ди бу.

— Алайса әйт: кем иде ул һәм менә моны ничек аңларга?

— Хәзер беләбез аны... Менә монда кош теле кадәр генә хат та язып тыкканнар...

Ул төенчек эченнән бөти кебегрәк бер нәрсә тартып чыгарды һәм кә-газь кисәгендәге сүзләрне укый башлады.

«Мелла Хәбибрахман! Әгәр дә сез газиз башыгызның ышбу мәхлүк бозау башы кыяфәтенә керүен теләмәсәгез, һич кичекми үзегезнең шай-тан өерен таратып, бу тирәдән бөтенләйгә китеп барыгыз. Тиздән бу йортның үз хуҗалары кайтачак, тиздән сезләрнең көне бетәчәк. Без һәр адымыгызны күзәтеп торамыз. Сез бу тирәдәге бер генә авылда да үзегезнең шайтан вәсвәсәсен тарата алмаячаксыз. Сезнең һәр тамаша-гыз — бер баш торачак. Адәм башы бозау башы гына түгел — ул кыйм-мәтрәк. Сез ахмак имәс, шәт аңларсыз. Сезгә фәкать изгелек теләп, иске дустыгыз...»

Хәбиб абыегыз хатны укып та бетермичә тәрәзәгә ташланды.

— Бу бит ул!.. Шул үзе...

— Кем?

— Шушы йортның хуҗасы. Баядан бирле хәтерли алмый баш ватам. Кем булды соң әле бу, шундый таныш гәүдә, дим? Әле менә хатны укыгач... Хәтерлисеңме, теге вакытта без синең белән шушы Иж буена килеп чатыр корган идек?..

Хәтерләмимме соң? Бик хәтерлим. Гражданнар сугышының кызган чагы иде. Бу тирә аклар кулында. Без, Азин дивизиясенең политбүлеге каршындагы театр труппасы, Әгерҗе тирәсендәге татар авылларында спектакльләр куеп йөрибез. Бер көнне Хәбиб абыең белән мине штабка чакыртып алдылар. Безнең бер концертны Азин үзе караган иде. Анда без Хәбиб абыең белән чегәнчә парлы бию биедек. Азиннең башына бер кызыклы фикер килгән: безне чегәннәр итеп киендереп, аклар тылына җибәрү!

Хәбиб абыең сакал-мыек ябыштырды, парик киде. Башында чегәннәр генә кия торган кара киез эшләпә, өстендә озын җиңле, озын итәкле кызыл сатин күлмәк, җиңсез кыска кара жилет, соры чикмән. Киң шаравар балакларын биек үкчәле, ялтыравыклы күн итек кунычларына тагып кигән. Коеп куйган чегән! Ә миңа инде киенеп тә торасы юк. Мин болай да чегән кызына охшаган идем. «Чегән арбасыннан төшеп калган татар кызы»,— дип үчеклиләр иде мине.

Шул, киттек. Ат арык, Хәбиб абыең арба артыннан, әледән-әле чөңгергәләп, җәяү атлый, ә мин брезент бөркәвеч астында акрын гына тирбәлеп, йокымсырап барам. Юлда ул-бу булмады. Берничә җирдә акларның җайдаклы солдатлары туктатып сораштырып карадылар. Имеш, каян киләсез, кая барасыз? Билгеле инде, чегән кая барсын? Арып калган атын этеп-төртеп дигәндәй, үзенең алга киткән таборын куып бара. Документмы? Рәхим ит! Әле патша заманында ук губернатор үзе кул куйган... Бер генә шәһәргә дә, бер генә авылга да кермәскә. Ягъни, читләтеп, әйләнеп узарга. Туктаган җирдә чатыр корып тәүлектән артык яшәмәскә. Туктаусыз алга барырга. Ә кая барырга? Анысын губернатор үзе дә белми.

Шул, әлеге Иж буена, аның Камага коя торган бугазының биек ярына туктап чатыр кордык. Көндезен елга өсте тыныч. Ә инде кич җитеп, караңгы төшкәч, аклар паром белән теге яктан бу якка гаскәр, корал күчерә. Безнең бурыч — шуларны санап тору һәм кайтып командованиегә җиткерү.

Караңгы төшү белән, Иж ярына урнашып, төн буе күзәтү алып бардык. Ә иртән, чатырны сүтеп атны гына җиккән идек, янәбызга зур гәүдәле, түгәрәк кара сакаллы бер татар килеп чыкты. Кыяфәтенә, киеменә караганда — бай кеше. Шәп киенгән, үзен хуҗаларча эре тота. Русча чиста сөйли бу: «Монда нишләдегез?» «Атыбыз арды, төн кундык». «Инде кая барасыз?» «Үзебезнең таборны эзләп барабыз». «Һе, алай икән... Бу тирәдән бит, берниндн таборның да узганы булмады. Әйдә әле, миник әле тегендә...» «Кая?» «Әнә теге тау башындагы утарга». «Анда безгә ни калган?» «Бәлки калгандыр, әнә, офицер әфәнде үзе дәшә».

Чыннан да, тау башында ак офицер басып тора иде. Башка чара юк, Хәбиб абыең әлеге бай артыннан шунда юнәлде. Мин, «әткәй!» дип, елап аңа ташландым. Хәбиб елмаеп миңа күз кысты: «Елама, кызым, мин хәзер килермен, нишләтерләр алар минем шикелле хәерче чегәнне?»— диде дә әлеге кеше артыннан менеп китте. Мин акрын гына, бер агачтан икенчесенә поса-поса, алар артыннан тауга үрмәләдем. Хәбибне, әлеге шул без торган ике катлы йортка алып кереп киттеләр. Янәшә тирәдә адәм заты күренми. Йорт эчендә дә хәрәкәт юк. Күрәсең, йоклыйлар. Әле иртә, яктырып кына килә иде. Мин курка-курка йортка якынлаштым. Кинәт шул вакыт югары катның бакчага карый торган бер тәрәзәсе чылтырап коелды, тәрәзә рамнары артыннан Хәбиб үзе дә бакчага сикерде. Мин бакча рәшәткәсенә ташландым. Хәбиб мине тиз генә рәшәткә аркылы күтәреп алды да, кулымнан җитәкләп әчкә, бакча

түренә йөгерде. Түрдә бакча коймa белән тотып алынган, ә койманың теге ягы урманга терәлгән. Без тиз генә коймa аркылы сикереп, урманга кереп югалдык. Безнең арттан куучы кеше булмады. Хәер, безне куарлык башка уяу кеше дә булмагандыр ул йортта. Ә боларын Хәбиб абыең берүзе дә хәл итә... Әлеге шул югары катның без торган бүлмәсенә алып керәләр Хәбиб абыеңны. Без утарга күчеп килгәч, таныш бүлмә, истәлекле, дип, шул бүлмәне сайлады ул. Теге чактамы? Ишектән керүгә тегеләрнең якасыннан эләктереп ала да бу, берсен-берсенә китереп бәрә. Тегеләр «дык» итеп икесе ике стенага сеңәләр. Әчке яктан ишекнең келәсен эләктерә дә бу, тәрәзәдән сикерә. Аңа нәрсә ике кеше? Галәмәт көчле иде ул. Революциягә кадәр күчмә цирк труппасында акробатик этюдлар күрсәтеп йөри идек без аның белән.

Туры килгәндә көрәшә дә иде ул циркта. Шулай бервакыт, Сарытау шәһәрендә, Хаҗи-Моратның үзе белән көрәште. Екты Хаҗи-Моратны Хәбиб абыең, тәки екты... Ә инде революциядән соң Ижауда театр труппасы төзедек. Шунда без өйләнештек тә. Аннан Азин дивизиясе һәм әлеге вакыйга...

Хәбиб абыеңның хәтер капчыгы тирән бит аның. Тәки шул Алмай утарының элеккеге хуҗасы булып чыкты теге былтыр безгә мылтык белән янап, бозау башы ташлап киткән төнге олаучы. Сөргеннән качып кайткан. Бер ел буе шактый шом салды инде ул бу тирәгә, явыз. Шактый этлек эшләде. Үзе түгел, ялчыларыннан эшләтә. Үзе, каядыр яшеренеп, тирә-якка коткы салып ятты. Ялчылары аша колхозга керүчеләрне өркетүме дисең, авыл активларына, комсомолларга почмактан һөҗүм итүме дисең, берсеннән дә чирканмадылар. Ә безнең артисткаларыбыз белән ниләр генә кыланмадылар алар...

Почмак яктан Зәйтүнә кинәт калтыравыклы аваз салды:

— Апа!

— Синең турыда түгел, юк, юк. Теге узган ел Әнвәр алып килгән ике кыз турында әйтәм әле. Төннә спектакльдән кайтып яткач, фатирларына бәреп керәләр дә...

Кызлар бирешми, әлбәттә: тешләшәләр, тырнашалар, каравыл кычкыралар. Хуҗа хатын почмак тәрәзәсен алып урамга чыга. Авыл яшьләре килеп җиткәндә тегеләр инде качып өлгерәләр. Кызларның бит-куллары җәрәхәтләнгән, тәннәре күгәреп, киемнәре ертылып беткән була.

Ә икенче көнне кич, күрше авылга баргач, спектакльгә җыелган халык яныннан ниндидер билгесез бәндәләр мыскыллы такмаклар җырлап узалар:

Әртискәнең кочагы,
Кичләрен — кайнар чагы,
Таң алдыннан суына,
Соңга калма — шул гына!

Такмакчылар җиңел кошовкага төялгән булалар. Авыл яшьләре, артларыннан куып карасалар да, тота алмыйлар.

Шул хурлыкка түзә алмыйча, әлеге ике кыз театрны ташлап китәргә мәҗбүр булдылар. Әйбәт кызлар иде, талантлы кызлар, саф кызлар. Театрны ташлап китәрлек сәбәп тә юк иде шикелле. Киттеләр. Ә менә безнең Зәйтүнә...

Почмак якта Зәйтүнә өзгәләнеп пышылдады:

— Апа-а!

— Юк, юк, Әнвәрне әйтәм мин. Әнвәрнең үзен... Үлгәндә калды бит. Ул керәсе мунчаның миченә тавык тизәге салганнар. Көчкә коткардык. Инде килеп менә бу соңгы хәл: февральнең соңгы төне иде... Коточкыч җил, буран, давыл. Без айдан артык авылларда спектакльләр куеп йөреп, батып-чумып, туңып-өшеп кайтып кына төшкән идек ул кичне. Ерактан кайттык, арылган-ватылган. Шунлыктан бернәрсә сизми йоклаганбыз. Ә алар, башта ике бинага да чиләкләп керосин сибеп чыкканнар, аннан ут төрткәннәр.

Без уянганда каршы як бинаның түбәсе янып, җимерелеп төшкән иде инде. Безнең йортның тәрәзә пыялалары шартлап, өйгә тәтен бәреп керә башлаган иде. Шунлыктан бернәрсәбезне дә ала алмыйча, өстебезгә ни очраса, шуны эләктереп тышка ташландык. Хәбиб абыең белән Әнвәр һәм тагы ике егетебез башта безне, хатын-кызларны, ут эченнән урамга тәртеп-тәртеп чыгардылар. Аннары Хәбиб абыең килеп чыкты. Аның килеп чыгуы булды, якында гына мылтык шартлады. Нәкъ узган елдагы кебек шартлады. Хәбиб абыең чайкалып көрткә ауды. Мин кычкырып аңа ташландым. Ишектән Әнвәр белән теге ике егет килеп чыктылар. Алар чоландагы әйберләрне ташымакчы булганнар икән. Ләкин өйалды түшәме янып өсләренә җимерелеп төшкән, киемнәренә ут капкан. Карда ауныйлар, бер-берсенә кар сибәләр. Мин: «Хәбиб абыегыз үлә бит»,— дип кычкырдым. Шунда алар Хәбибне, кайсыдыр эләктереп чыккан бер толыпка урап, читкә сөйрәделәр. Тирә-юньгә утлы кисәү башлары сибелә. Ә Хәбиб абыегез кычкыра: «Минем белән маташмагыз, костюмнарны... театрның костюмнарын коткарыгыз!» — ди. Каршы як бинаның складында безнең еллар буе җыеп килгән төрле костюмнар, реквизит, бутафория әйберләре саклана иде. Ләкин кая ул! Безнең ул складыбыз янып бетә язган иде инде. Күп тә үтмәде, җигүле атлар белән Алмайдан янгын сүндерүчеләр, авыл советы һәм колхоз җитәкчеләре, комсомол-яшьләр килеп җиттеләр. Беренче атка Хәбиб абыең белән мине утыртып больницага алып киттеләр.

Бәхеткә күрә, больница якын булды. Элеккеге больница шушы Алмайдан бер генә чакрымда икән. Алып керүгә Хәбиб абыеңны операция өстәленә салдылар. Ядрә сул иңбашын үтеп чыккан. Сөяккә тимәгән, тик менә нервы тамыры гына... Төзәлә инде бәгырькәем, сул кулы гына әлегә хәрәкәтләнми. Менә иртән янына барырбыз.

Ә теге явызларны берәм-берәм тотып утыртып бетерделәр. Барлыгы алты кеше булган. Хәбиб абыегызга шул Алмай утарының элеккеге хуҗасы үзе аткан. Шушы көннәрдә районда судлары булачак, Хәбиб абыегызның больницадан чыкканын гына көтәләр.

Ярый, йоклагыз, арыттым бугай мин сезне. Минем хикәямнең сөйләргә яраганы шуның белән тәмам.

* * *

Ә сөйләргә ярамаганы? Анысы да булмы? Ләкин инде Мәхмүт анысын сорап борчымады. Сөйләргә яраса, бер сөйләр, ярамаса, үзендә калыр. Ә хәзер йокларга кирәк. Алар Гайнетдин абыйсы белән икесе түрдәге агач караватка менеп яттылар. Рафига ханым утны сүндереп, почмак якка, Зәйтүнә янына чыгып ятты. Ләкин берсенең дә күзенә йокы кермәде. Шундый коточкыч хәлләрне күз алдыннан кичергәннең соңында ничек йокламак кирәк? Сизә Мәхмүт, Гайнетдин абыйсы да йоклый алмый ята. Бер яктан икенче якка әйләнә, көрсенә. Аннан Мәхмүтнең колагына үк пышылдап:

— Дөньяда сезнең Хәбиб абыегыз шикелле кешеләр дә буламыни? — дип куя.

— Була. Үзләренең гомерләрен олы максатка — халык бәхете өчен көрәшкә багышлаган кешеләр әнә шундый була, Гайнетдин абый!..

Иртән таң белән тордылар. Гайнетдин абзый кайтып китәргә әзерләнде. Рафига ханым белән Мәхмүт больницага барырга җыендылар. Ләкин Гайнетдин абзый атын җигеп, толыпларын алырга кергәч, чыгып китәргә теләмәгәндәй түбән карап, бер урында таптанып торды.

— Нәрсә, Гайнетдин абый, әйтер сүзең бар иде мәллә?

— Бар иде шул...

— Әйт, әйт, тарсынма.

— Әгәр мөмкин булса... Әгәр яраса, мине дә алып бармассыз микән бүлнискә? Шул кешене бер күрәсем килә.

Мәхмүт Рафига ханымга карады.

— Мөмкин, ник мөмкин булмасын, әйдәгез, рәхим итегез. Безнең Хәбиб кече күңелле кеше ул. Кешеләрне ярата. Сезне күргәч ул бик шатланачак, әйдәгез! — диде.

Алар Гайнетдин абзый атына утырып больницага киттеләр.

Больница коридорында аларны Хәбиб агалары көтеп тора иде инде. Ул шифаханә киемнәрен салган. Өстендә өр-яңа френч, галәфи чалбар, аякларында хром итекләр, башында фуражка, билендә киң каеш. Рафига ханым, аны бу кыяфәттә күргәч, аптырап калды.

— Син нәрсә, комиссар булдың мәллә?

— Булырсың, дөнья булгач, комиссар да булырсың. Райбашкарма председателе үзе җибәргән. Күн тужуркасы да бар әле.

— Рәхмәт төшкере. Безне дә бит башкарма комитет киендерде. Барыбыз да яланөс калган идек бит. Ә теге куркаклар... Театрны шушы хәлдә ташлап китү... Башыма сыймый.

— Ярый, алар турында соңыннан.— Хәбиб ишек төбендә таптанып торган Мәхмүткә борылды.— Килеп җиттең? Мин сиңа ышанган идем... Ашманскийның энесе килер, ул килми калырга тиеш түгел дип ышанган идем. Ышанычымны акладың, рәхмәт! — Ул сыңар кулы белән Мәхмүтнең иңбашыннан кочаклап алды, аннан Гайнетдин абзыйга борылды.— Ә бу иптәшне кем дип беләбез?

— Бу... бу минем... Гайнетдин абый,— дип, аны кулыннан алып алга чыгарды Мәхмүт.

— Ә-ә-ә, Гайнетдин! Гайнетдин шушы буламыни инде? Беләм, беләм, бик беләм! Безгә сезнең турыда Мәхмүт язган иде.— Ул Гайнетдин абзыйның кулын кысты.— Кем икәнең, нинди милләттән, дусмы-дошманмы икәнең белми торып кешенең тормышын коткарып калу, бу — бик күркәм сыйфат. Рәхмәт. Сез әйтеп бетергесез изгелек эшләгәнсез. Сез китмисездер бит әле?

— Китәм. Минем инде китеп барышым. Миңа һич тоткарланырга ярамый. Юл бетә. Сезне күрәсем килеп кенә монда сугылдым әле. Менә сез нинди икәнсез...

— Ә сез нинди дип уйлаган идегез?

— Ниндидер... бөтенләй башка төрле кеше итеп күз алдыма китергән идем. Ә сез, әнә, гап-гади кеше икәнсез. Нәкъ үзебезнең кеше. Әйдәгез, мин сезне өегезгә кайтарып куйыйм да...

Хәбиб Шәрәпов больница хезмәткәрләренең барысы белән дә берәм-берәм кул биреп күрешеп чыкты, аларга әчкерсез зур рәхмәтен белдереп баш иде. Алар барысы да капка төбеннән кул болгап, озатып калдылар.

Өйләренә кайтып җиткәч, Гайнетдин абзый белән тагы кабат-кабат рәхмәтләр әйтеп саубуллаштылар. Мәхмүт Гайнетдин абыйсын басу капкасына кадәр озата барды. Басу капкасы төбендә Гайнетдин абзый атын туктатып, чанасыннан төште дә, Мәхмүтне кочаклап алды.

— Нәрсә, каласыңмыни инде?

— Калам, Гайнетдин абзый.

Гайнетдин абзыйның күзләрендә яшь иде.

— Бигрәкләр дә явыз кыланганнар бит... Тагы әллә ниләр булмагае.

— Булмас, Гайнетдин абый, тыныч бул. Барсын да кулга алып бетергәннәр бит инде. Шушы көннәрдә судлары булачак, ди.

— Суд белән генә калырга түгел, атарга кирәк аларны, атарга! Ярый, сау бул, авырга килерлек булса, туры үзебезгә кайт. Габделбәрләр белән бергә эшләрсең, чакырып калды бит. Ә мин инде, Мәхмүт туган, шушындый заманда ат койрыгына тагылып, кибәк суырып йөрмәм, ничу, кайтам да колхозга гариза бирәм, менә шул!

Ул соңгы кабат Мәхмүтне кочып, күкрәгенә кысты да, чанасына утырып китеп тә барды. Мәхмүт, басу капкасы төбендә, ерагая барган олаучы чанасына карап бик озак басып торды.

# Биштәр аскан дүрт җәяүле

Әле апрель башы гына булуга карамастан, котырып яз килә. Кояш, күк гөмбәзе түбәсеннән торып, үзенең алтын нурларын сибә. Ул нурлар басу карларын кәрәзләндереп эретә. Кардан арынган басу калкулыкларыннан акрын гына тетенсыман сыек пар күтәрелә. Басу сыртыннан олы юл үтә. Кыш буе тапталып тыгызланган, инде бозга әверелгән юл кары гына яз кояшына бирешми. Ул, тимер юл полотносы кебек, буйдан-буйга ялтырап ята. Шул тегәрҗеп кебек сузылган ялтыравыклы юлдан дүрт җәяүле бара. Алда ике ир һәм арттарак ике хатын-кыз. Алар, ничектер сизелер-сизелмәс бөкрәя төшеп, авыр биштәрләр асканнар. Дүртесе дә таякка таянган. Ашыкмыйча гына, әледән-әле таяклары белән юлга төрткәләп, аның ныграк һәм катырак урыннарын сайлап, акрын гына баралар да баралар.

Алмай театры янгач, Татарстан Мәгариф халык комиссариатыннан Хәбиб Шәрәпов исеменә хат килеп төште: театрны Кама аръягындагы районнарның берсенә күчерергә. Тәгаен кайсы районга икәнен театр, урындагы шартлардан чыгып, үзе хәл кылырга тиеш. Менә хәзер «театр», эшләр өчен үзенә уңайлы шартлар булдыра алырлык урын эзләп, язгы кар суларын ера-ера бара да бара. Бара торгач арып, юл читендәге түмгәккә биштәрләрен куеп, ял итәргә утыралар. Хәбиб агалары, аларның күңелен күтәрү өчен, шундук сүзгә керешә:

— Менә сез, артистлар, дөресен генә әйтегез әле: нәрсә ул театр? — Билгеле инде, Хәбиб агаларыннан узып, бу сорауга берсе дә җавап бирергә ашыкмый. Шуннан соң Хәбиб агалары үтә җитди кыяфәткә кереп, үз соравына үзе җавап бирә: — Театр ул таякка таянган дүрт адәм, дүрт биштәр... менә шулай эшләр, тора-бара нишләр,— дип, сүзен шаярту белән тәмамлый.

Барсы да рәхәтләнеп бер көлеп алалар.

— Зарар юк,— ди Хәбиб агалары,— моннан авыррак хәлләргә дә төшкән бар, моны гына җиңәрбез. Тик минем, шушы хәлләрдән куркып, театрны ташлап киткән егетләребезгә, кызларыбызга йөрәгем әрни. Мин бит аларга ышанган идем.

Ә театр таралмас. Театр булыр! Театр тагы да зуррак һәм көчлерәк булып оешыр. Моңа Хәбиб агаларының ышанычы зур һәм шул ышанычны ул Мәхмүт белән Зәйтүнәгә дә сеңдерергә тырыша. Хәер, ул алардан шикләнми. Аларга ышана. Шулай булмаганда, шушы язгы пычракны ерып, аның артыннан барыр идемени алар? Ару-талуга һәм ачыгуга карамастан, нык ышаныч белән баралар.

— Минем биштәремдә бер умачлык он калды. Бүген кич, кунарга туктаган авылда, шуны тугылап ашарбыз да, аннан без нишлибез инде, балалар? — Хәбиб Шәрәпов сынау катыш караш белән Мәхмүткә текәлде.

— Ничек, нишлибез? Авылга тукталабыз, дисез бит. Ул авылның кешеләре бардыр бит? Ә без дүрт кенә бөртек булсак та, «театр». Нәрсә булса да эшләрбез.

— Дөрес, энем Мәхмүт. Дөрес сукалыйсың! Синең белән яшәп була. Хәзер мин үземнең хәтер җәгърафиямне күз алдыма җәеп карадым да, шундый фикергә килдем: безгә хәзер, алдыбызда торган үр сыртына менеп җиткәч, олы юлдан сулга борылырга кирәк. Дүрт чакрым баргач, Ык буенда зур гына бер Өчнарат дигән авыл бар. Мин бит бу тирәнең аркылысын-буйга үткән кеше. Мине беләләр. Бүген Өчнаратта кунарбыз да, иртәгесен көне буе программа әзерләп, кичен концерт бирербез.

— Нинди концерт? — дип сүзгә катнашты Рафига ханым.— Концерт өчен музыка коралыбыз да юк бит хәзер.

— Булыр. Өчнаратта минем таныш мастерым бар. Гармун ясаучы. Анда нәрсә булса да булмый калмас. Күңелегезне төшермәгез, башыгызны югары күтәрегез, без бит артистлар, ниһаять. Киттек!

Биштәр аскан дүрт җәяүле — дүрт артист, дүрт хыялый — язгы сулар ерып, Өчнаратка якынаеп килә. Кич җиткән. Ә юлчылар, Ык буеның кичке матурлыгына да дикъкать итми, моржалардан чыккан төтен белән тирә-юньгә таралып, борыннарны кытыклап кергән тәмле аш исләрен дә сизмичә, атлыйлар да атлыйлар. Аларның уенда, хыялында — фәкать иртәгесе көн. Иртәгә буласы кичә, иртәгә буласы концерт. Ничек итеп шуны оештырырга да, ничек итеп халык алдында йөзгә кызыллык китермичә, шуны ерып чыгарга?!

## Яңа йортның иске кешеләре

Өчнарат аларны хуп күреп каршы алды. Авыл советы председателе — Латыйпов дигән кеше — Хәбибнең Азин дивизиясе буенча сугышчан дусты булып чыкты. Алар кочаклашып күрештеләр. Рафига ханым да читтә калмады. Ул да Латыйповны яхшы белә икән. Латыйпов аларны шунда ук үзенә алып китәргә, мунча ягып кунак итәргә булды. Ләкин Шәрәпов гафу үтенеп, аның тәкъдимен кире какты. Үзләренең хәзерге хәлен, Өчнаратта ни өчен тукталуларын һәм иртәгә булачак кичәнең программасын әзерләү өчен нинди дә булса бер аулаграк, тынычрак урын табып бирүләрен сорады. Мунчаны да иртәгә ягуларын үтенде. Шуннан соң Латыйпов, Өчнарат колхозы председателен — әле күптән түгел генә армиядән кайтып эшли башлаган Хәйри исемле егетне чакыртты.

Алар шундый фикергә килделәр: бу дүрт кешелек коллективны Мохтар картка урнаштырырга. Мохтар картның ишегалды түрендә, бакча эчендә зур, кара-каршы ике йорт. 15-16 яшьлек кызы белән икесе генә эчтәге аш өендә торалар икән. Ә түр өй — кунак өе буш тора. Аннан килеп, булыр дигән фикер әйтте Хәйри. Чөнки, яшерен-батырын түгел, хәзергесе көндә колхоз амбарында язгы чәчүгә дип әзерләп куйган чәчүлек орлыгыннан башка нәрсә юк. Ә кунакларга икмәк, он, ит-май дигән нәрсәләр кирәк булачак. Мохтар карт, әлбәттә, колхозның уңышын җыеп алгач кире кайтарып бирү шарты белән, кунакларны кирәк кадәр үзе тәэмин итәчәк. Итми хәле юк. Чөнки ул бүгенгесе көндә авылның иң бай кешеләреннән берсе. Тирә-юньдә дан тоткан су тегермәне хуҗасы. Узган ел, авылның башка кулаклары белән бергә Солавкига сөрергә торганда гына, аның хатыны үлеп китте. Егерме беренче ачлык елында алган яшь хатыны. Мохтар карт яшь хатынның иярә килгән кызы Гөлбану белән япа-ялгыз кала. Шуннан соң авыл халкы, инде җитмешкә җиткән ялгыз картны кызганып, халыктан имза җыеп, аны сөргеннән алып кала. Мохтар картның урыны да тыныч. Авылдан читтә, су буенда, колхоз тегермәне янында. Ә Мохтар карт шул үзенең элеккеге тегермәнендә каравылчы вазифасын үти. Тегермән хәзергә эшләми. Юл өзеге булганлыктан, тегермәнгә килүче юк. Теләсәң ничек һәм теләсәң ни кадәр уйна, җырла, бие. Кыскасы, никадәр кирәк, шул кадәр репетиция үткәр. Кирәк икән төне буе. Мохтар карт ишетмәячәк, ул эчке өйдә. Өстәвенә колакка да саграк. Ә кызы... Кызы шат кына булачак. Гөлбану кебек яшүсмер кызга җыр-гармун булса, ул биеп кенә йөриячәк.

Еракта, елганың борылып киткән җирендәге таллыкта, тегермән сыман нәрсә күренде. Шул тегермән янындарак бер йорт та бар шикелле. Бер-берсенә карашып алдылар да, капкага юнәлделәр. Латыйпов капканы акрын гына ачты да, «керегез» дип, ымлап, эчкәре узды. Барсы да берәмберәм ишегалдына керделәр. Ишегалды түрендә кара-каршы ике өйне зур өйалды тоташтыра. Өйалды эченнән сулык-сулык елаган кыз бала тавышы ишетелә. Гармун тоткан яшь кенә бер егет өйалды ишегенең түбәндәге — мәчеләр кереп-чыгып йөрү өчен калдырылган тишегенә иелеп, эчтәге кызны юата:

— Гөлбану, елама... Елап ни файда? Үләргә дә кирәкми. Үлдең —

бар да бетте дигән сүз. Шушы яшеңнән кара гүргә кереп ятарга җүләрмени син? Әнә, кара, дөнья нинди матур. Яз килә, яз! Агачлар бөреләнә. Су буендагы таллар песи чыгарганнар. Әнә, өй түбәсендә пар сыерчык гөрләшә. Безнең дә шул сыерчыклар шикелле гөрләшеп яшәр чагыбыз бит, Гөлбану... Һәм яшәрбез дә! Мин сине беркемгә дә бирмим. Менә хәзер лом белән ишекне каерып ачам да...

Эчтән өзгәләнеп кычкырган тавыш ишетелде:

— Кирәкми. Кайтып керсә ул мине үтерәчәк.

— Тиеп кенә карасын. Мин анымы?.. Мин ул кулакны... Узган ел шуңа имзамны бирдем бит мин, җүләр. Сине кызганып, сине дә аның белән бергә сөрерләр дип курыктым. Ә хәзер... Хәзер инде мин аның батрагы түгел. Хәзер мин аның бугазыннан алачакмын.

— Кирәкми, Рәхи-мул-ла!

— Ни хакы бар аның сине ялгызыңны бикләп китәргә?

Рәхимулла лом эзләп лапаска ташланды һәм шулвакыт өй почмагына поскан Латыйповны күреп алды.

— Коткарыгыз, коткарыгыз аны тизрәк, ул үз-үзенә кул салмакчы...

Латыйпов, күз ачып йомганчы, лом белән ишекнең йозагын каерып ташлады. Аның артыннан Рәхимулла, Хәйри, Мәхмүт өйалдына бәреп керделәр. Андагы кыз, куркып, караңгы почмакка сеңде.

— Килмәгез, якын килмәгез!

— Курыкма, кызым!

— Китегез, миңа тынычлап үләргә ирек бирегез!

— Ни сөйлисең син, җүләр! Совет власте кешегә үләргә юл куямыни? Совет власте сиңа яшәргә ирек биргән. Тукта хәзер үк елаудан!

Рафига белән Зәйтүнә әлеге кызны җитәкләп эчке өйгә алып кереп киттеләр. Латыйпов, түрдәге кунак өенең ишеген ачып, Шәрәповка мөрәҗәгать итте:

— Менә ул сезгә тәкъдим иткән өй... Әйдәгез, керегез әле бирегә.

Шәрәпов ачык ишекнең бусагасында туктап калып, эчкә күз салды: менә ичмасам кунак өе дисәң дә, кунак өе. Искиткеч чиста, зур. Стеналары сап-сары. Идәндә зур келәм. Идән уртасында түгәрәк өстәл. Өстәл әйләнәсендә затлы урындыклар. Бер почмакта ялтыравыклы кафель плитәләр ябыштырылган түгәрәк галанка миче.

— Әйдә, узыгыз, тартынмагыз.

— Мин кереп тормыйм, хуҗа өйдә булмагач, миңа ашау-эчү мәсьәләсен хәл кылырга кирәк,— дип, колхоз председателе Хәйри китә башлады.

— Тукта, бергә барабыз,— дип Латыйпов аны туктатты да, Рәхимуллага борылды: — Әйт әле, монда нинди театр уйный идегез?

— Әгәр сез килеп чыкмасагыз, була иде монда театр.

— Мохтар карт үзе кая? Ул нигә кызын бикләп киткән?

— Кызы... Хатыны итәргә йөри ул аны, әгәр беләсең килсә. Кайчаннан бирле беркая чыгармый өендә бикләп асрый. Ә Гөлбану әнә елый да елый, аның хатыны булганчы мин асылынып үләм, ди.

— Ә нигә шуны белә торып, безгә — авыл советына хәбәр итмәдең?

— Мин үзем дә аны бүген генә белдем. Мохтар карт киткәч кенә. Үзе өйдә вакытта ул мине бу тирәгә якын да җибәрми.

— Ә үзе кая киткән соң?

— Күрше авылга. Имеш, күрше авыл мулласын алып килеп никах укыта да, шуның белән вәссәләм.

— Ашыкма, энем, алай гына булмый ул хәзер. Монда бит власть бар, совет власте. Килеп карасын мулласы властьтан узып.

Шәрәпов Мәхмүтнең иңеннән алды.

— Менә, Мәхмүт, сиңа әзер тема. Әйдә, аякларыңны сал да, әнә түрдәге өстәлгә утырып яза башла. Скетчмы дип әйтим, бер пәрдәлек драмамы... Тик трагедиягә генә барып житмәсен. Ике гашыйк, бер золым... Ләкин хәзерге гашыйклар золымны җиңәргә тиешләр. Башта Гөлбану-

ның үзен чакырып сөйләт — үткәнен, хәзергесен, киләчәк хыялларын. Аңладыңмы?

— Аңладым да...

— Ач карынга бик аңлашылып та бетмәс. Әйдә, Хәйри, без тиз генә ашау-эчү мәсьәләсен хәл кылыйк,— дип Латыйпов аш өенең ишеген барып ачты.— Кызым, Гөлбану, бу апалар-абыйлар безнең авылның зур кунаклары булалар. Әртистләр алар. Иртәгә аларның театрын син дә карарсың. Сезнең кунак өе вакытлыча алар карамагына тапшырыла. Хәзер без ит, май, йомырка, он китерербез. Ә син күп итеп бәрәңге пешер. Бармы бәрәңгегез? То-то. Мохтар карт кайтса, туп-туры миңа җибәр. Авыл советына. Аның белән мин үзем сөйләшермен. Әйдә, Хәйри, киттек.

— Мин дә сезнең белән...

— Арыган килеш йөрмә инде син, Хәбиб дус.

— Минем арырга хакым юк. Миңа гармун ясаучы Хәкимулланы күрергә кирәк.

— Минем абыйнымы? Әйдәгез, үзем алып барам.

Иңенә гармун аскан яшь егет Рәхимулла — гармун ясаучы Хәкимулланың туганнан туган энесе булып чыкты.

## Мәхмүт кулында — каләм...

Мохтар картның аш өендә хатын-кызлар мәш килә иде. Ярып пешергән ярмалы бәрәңге тирә-юньгә тәмле ис бөркеп тора. Ашъяулыкта зур бөтен икмәк, коштабакта кушуч-кушуч итеп йомарланган ике кисәк ак май. Хәбиб агаларының ишектән керүгә авызы колакларына җитте. Борынны бәреп кергән бәрәңге исе тамак төбен кытыклап алды. Кинәт аның күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп киткән сыман булды. Ләкин ул бу хәлен сиздермәскә тырышып, мөмкин кадәр көр тавыш белән:

— Һооо-о-о! Никадәр нигъмәт! Кай арада һәм ничек итеп? — дип, Рафига ханымга мөрәҗәгать итте.

— Менә Гөлбану сеңел инде. Кулында ут уйный. Бер кулы белән сәке астыннан бәрәңге чүпләп, икенче кулы белән аны шунда ук юып, ярып казанга салып торды. Икмәк белән майны Хәйри китертте. Ит, күкәй һәм он күтәреп Латыйпов үзе килеп җитте. Аныкына тимәдек. Аны Гөлбану чоланга чыгарып бикләде. Иртәгә иртән коймак изәрбез, күкәй тәбәсе пешерербез. Шулай бит, Гөлбану акыллым?

Гөлбану оялып башын түбән иде. Шәрәпов килеп аның иңеннән сыйпады:

— Рәхмәт, сеңелем, игелек күр, бәхетле бул.

Рафига ханым учак алдыннан җылы су салган комганны алып аралыктагы ләгәнгә илтеп куйды.

— Әйдә, кулыңны ю да табынга утыр.

— Утыр дип, күрәсез бит — мин үзем генә түгел,— ул ишек төбендә басып торган Рәхимулланың кулыннан алып түргә әтәрде.— Таныш булыгыз, безнең яшь артистыбыз Рәхимулла Әкбәров.

— Шулаймыни!.. Нигә аны башта ук әйтмәдең? Әйдә, әйдә, энем, рәхим ит, төкле аягың белән! Зәйтүнә, ал кулындагы әйберләрен, урнаштыр.

Рафига ханым белән Зәйтүнә Рәхимулланы икесе ике яктан чишендерергә, әйберләрен урнаштырырга керештеләр. Шул арада Шәрәпов кулларын юып табынга килеп утырды.

— Кая соң, нигә Мәхмүт утырмый?

— Мәхмүттән язучы ясагансың бит үзең. Син киткәннән бирле теге өйдә башын да күтәрмичә пьеса язып утыра. Ашарына да шунда гына чыгарып бирдек.

— Башыңа төшсә, башмакчы буласың, ди. Иртәгә кичкә репертуар кирәк. Кем язып бирә аны безгә, техникум бетергән башы белән бер төндә ул да язмагач. Өстәвенә әзер сюжет туры килде. Прототиплары янында гына, сорашсын, сөйләшсен. Әйдә, Рәхимулла, менә минем янымa утырып аша да, аннан Мәхмүт янына керерсең.

— Прототипларның берсе каршы бит әнә. Мәхмүт чакырган иде дә, якын да бармады. Язмагыз, ди.

Шулвакыт почмактан Гөлбану аваз салды:

— Юк, юк, язмагыз! Яза күрмәгез, абый! Минем турыда язып мәсхәрә итә күрмәгез мине. Аннан соң мин кеше күзенә ничек күренермен?

— Кем әйтте әле аны, синең турыда яза дип? Кил әйдә, утыр табынга, менә, Рәхимулла янына утыр. Ул сиңа аңлатыр.

Рәхимулла исемен ишеткәч, Гөлбану кычкырып ук елап казан артындагы аралыкка кереп китте. Рәхимулла табыннан торып аның янына килде. Аралыкта Гөлбану өзгәләнде:

— Кит, кит, якын килмә! Бар әнә, артистларың белән кит!

Ах, менә ничек?.. Кем әйтмешли, имәндә икән чикләвек.

Табындагылар бер-берсенә караштылар. Хата киткән. Хаталык Шәрәповның үзендә булган. Төзәтергә, хәзер үк төзәтергә кирәк. Шәрәпов табыннан торып аралыкка килде. Аралык авызында ни дип әйтергә дә белмичә бер урында таптанып торган Рәхимулланың кулыннан алып, алгы якка чыгарды да, үзе аралык түрендәге почмакка сеңгән Гөлбануның янына кереп, аның чәчләреннән сыпырып юатырга тотынды:

— Кем әйтте әле аны сиңа, Рәхимулла үзе генә китә дип? Без бит аның белән болай сөйләштек...— Ул Рәхимуллага борылып күз кысты.— Без Рәхимулланы театрга синең белән бергә алабыз. Ул безнең белән син китсәң генә китә. Ул бу турыда синең белән сөйләшергә, сине безнең театрның артисткасы булып китәргә үгетләргә тиеш иде. Син нәрсә, Рәхимулла, Гөлбануга бу турыда әйтмәдең? Ай-яй-яй, егет! Гөлбану — син безнең театрның артисткасы булып китәргә ризамы?

Гөлбану, балаларча көрсенеп, яулык чите белән күз яшьләрен сөртеп алды.

— Артисткасы ук дип инде...

— Нигә? Без сине укытырбыз, өйрәтербез. Син ни дә булса беләсеңдер бит?

Гөлбану нәрсә дип әйтергә дә белми аптырап торганда, Рәхимулла аңа ярдәмгә килде.

— Җырлый ул, Хәбибрахман абый, бик матур җырлый. Аның кебек җырлаучы безнең авылда юк. Ул «Галиябану»ны былтыр безгә килгән артистлардан яхшырак җырлый.

— Менә бик яхшы. «Галиябану»ны куярбыз. Берегез Галиябануны, берегез Хәлилне уйнарсыз.

— Бии дә әле ул, Хәбибрахман абый, узган җәй сабан туенда шундый биеде, бөтен авыл шаккатты,— дип өстәде Рәхимулла.

— Биисең дәме? Анысын кайда өйрәндең тагы?

Гөлбану, Рәхимуллага карап алып, кыюлана төште.

— Үзебезнең лапаста. Әни исән чакта кубыз уйнап торып өйрәтә иде,— дип җавап бирде.

— Менә шәп, менә әйбәт! Сиңа ничә яшь әле?

— Уналты, көзгә уналты тула,— диде Гөлбану.

— Менә, бик әйбәт. Көз көне үзеңә паспорт алып бирербез. Ә хәзер...— Ул Гөлбануны җитәкләп түргә алып чыкты.—Егез, дусларым, тәбрик итегез үзен. Булачак артистка Гөлбануны тәбрик итегез һәм бүгеннән, менә шушы минуттан, үзегезнең арагызга алыгыз.

— Төкле аягың белән!

Гөлбану куркып тәрәзәгә карады. «Шулай дисез дә, бит... Әгәр дә ул кайтып керсә?» — диган шомлы уй йөгерде аның башына.

* * *

Ә ул, чыннан да, кайткан иде. Өйдәге бу тамашаны бакча тәрәзәсенең түбән өлгесе аша күзәтеп тора иде Мохтар карт. Аның гәүдәсе калтырый, тешләре тешкә тия, йодрыклары үзләреннән-үзләре йомарланалар. Нишләргә? Нигездәге ташны алып тәрәзәгә бәрергәме? Туфраксага яшерелгән ике көпшәле ау мылтыгын алып, барсын да кырып салыргамы? Өйалды ишегенә тыштан йозак салып, өйгә ут төртергәме? Юк, боларның берсе дә ярамый. Ахмаклык. Тәрәзәдән таш бәреп нишлисең? Күп дигәндә шул кире беткән кызның күзен чыгарырсың. Аннан үзеңне тотып алырлар да бәйләп озатырлар. Ау мылтыгын ничек алырга? Туфраксага өйалдыннан менәргә кирәк, ә өйалды ишеге эчтән бикле. Ут төртеп ни файда? Алар тере кешеләр бит. Тәрәзәләрне бәреп булса да чыгачаклар. Ә синең өең яна да бетә — вәссәлам! Юк, боларның берсе дә ярамый. Акыл белән эш итәргә кирәк, салкын баш белән. Кайнарланып үз-үзеңне генә пешерәсең, бары шул. Анда кереп күренергә дә ярамый, монда туңып торудан да мәгънә юк. Җелекләренә кадәр суык үтте аның. Ни гомер тора бит инде ул шушы чия төбендә. Ул күрше авылдан кайтканда караңгыланып кына килә иде әле. Күрше авылда да юлы уңмады. Күрше авыл мулласы да шүрләде. Имеш, башта авыл советында язылмый торып аның никах укырга хакы юк. Төннәр буе Мохтар картның кунак өендә ачы бал чөмереп ятканда бар иде ул мулланың хакы. Ә хәзер авыл советыннан уза алмый, чалмалы шайтан! Авыл советы... Тукта әле... Бая ул кайтканда авыл советы персидәтеле Латыйпов монда иде бит.

Колхоз башлыгы да монда иде. Димәк, алар керткәннәр бу узгынчы шайтан токымнарын аның өенә. Димәк, алар барысын да белә. Димәк, теге эттән туган кыз аларга барсын да сөйләгән. Кара, алар тирәсендә ничек сырпаланып йөри? Үзләре белән алып китәбез, диләрме? Күрербез!

Ул чия төбеннән үрмәләп чыкты да, арт бакча аша тегермән буасына төшеп, олы юлга таба юнәлде. Караңгы. Күзгә төртсәң бер нәрсә күренми. Ләкин ул бара. Чамалап бара. Елга буендагы тар гына ерганакны да, кечкенә генә түмгәкне дә хәтерли ул. Җитмеш ел гомерен шунда уздырган елга буеннан ул күзен йомып та бара ала. Ә олы юлга чыккач, Мохтар карт кая барасын белә. Бик яхшы белә. Ашыкмасыннар әле. Мохтар карттан котылдык, дип шатланмасыннар. Мохтар карт диләр аны!

* * *

Бу төндә Мохтар картның кара-каршы ике өендә дә ут сүнмәде. Түрдәге кунак өендә Мәхмүт язып утырды, эчтәге аш өендә исә гармун, музыка, җыр яңгырады. Иртәгә кич булачак концерт программасына репетиция барды. Программага Рәхимулла белән Гөлбану чыгышларын өстәргә дә онытмадылар. Үзләренең репертуарын яңартуны кирәк тә тапмадылар һәм аңа вакытлары да юк иде аларның. Рәхимулланың гармунда уйнау техникасын һәм Гөлбануның җырын чарладылар алар. Гөлбануның тавышы көчле, моңлы, чишмәдәй саф иде. Ул башта тарсынып, оялып кына башласа да, тора-бара үзләшеп, кыюланып һәм ачылып китте. Үзенең ят кешеләр алдында басып торуын онытты. Табигать баласы, табигатьнең үзеннән алган моңын, аһ-зарын, елга, әрәмә, тау, урман, кошлар тавышына кушып, алардан көнләшеп, аларны узарга тырышып, табигатьнең үзенә чәчә-сибә иде... Бу илаһи аһәңне табигать, кайтаваз итеп, аның үзенә кайтара шикелле. Ул шулардан илһамланып, канатланып оча, сайрый иде. Ул һәрвакыт шулай булды. Бала вакытыннан ук. Табигать кочагына чыгып китәр иде дә, анда чәчәкләр җыеп, күбәләкләр куып, кошлар сайравын, урман шаулавын

тыңлап җырлар да җырлар иде. Кошларга охшарга тырышып сайрар иде, урман шавын басарга тырышып кычкырыр иде:

— Ау-уу... Ау-уу!..

Аннан үз авазын үзе тыңлар иде. Тагы кычкырыр иде, тагы җырлар иде, тагы сайрар иде. Төрле-төрле аваз, төрле-төрле аһәң-моң өстәлер иде аның тавышына. Күрәсең, табигать кочагында чарланган аның тавышы.

* * *

Таң атып килгән вакытта Мәхмүт тә үзенең әсәрен язып тәмамлады. Барысы да талчыккан булуга карамастан, бу егерме битлек драманы шундук бергәләп укыдылар. Әсәр, чыннан да, тетрәткеч булып чыккан. Финал, Шәрәповның кисәтүенә дә карамастан, фаҗига белән тәмамлана. Ләкин Шәрәпов моңа каршы килмәде. Аның шулай тәмамлануы табигый да һәм отышлы да иде. Бар да Мәхмүтне мактадылар. Теле матур, образлар, характерлар коеп куйган кебек. Вакыйга мавыктыргыч, ул диалогтан диалогка үсә-җәелә бара һәм, югары ноктасына менеп җитеп, чишелә-шартлый. Әсәрнең логикасы көчле, ышандыра. Әйтерсең, аны тәҗрибәле драматург язган. Бу беренче тәҗрибәсен Мәхмүт, һичшиксез, дәвам итәргә тиеш, аннан киләчәктә чын драматург чыгачак, диделәр.

Юк инде, кадерле дусларым минем, Мәхмүт драматург булмаячак. Мәхмүт сәхнәне каләмгә алыштырмаячак. Ул аның эше түгел. Аның белән язучылар шөгыльләнсеннәр. Мәхмүт — артист. Артист булып туган һәм артист булып калачак та. Әгәр дә... язмыш, ниндидер көтелмәгән сәбәпләр аны сөекле сәхнәсеннән аермаса. Юк, юк!.. Бу мөмкин түгел. Мондый куркыныч уйларны куарга! Хәзер үк баштан чыгарып ташларга. Йокларга. Бераз гына йоклап алырга да, аннан репетициягә тотынырга. Ул язган әле ярты эш кенә. Ә инде аннан спектакль туса... Әйе, әйе, спектакль, чын мәгънәсендә спектакль!

Мәхмүт, шул татлы хыяллары белән изрәп, тәмам яктырып җиткәч кенә йокыга китте.

* * *

Кичке караңгы төште. Өйдә ут алыр вакыт җитте. Гөлбану, татлы хыялларыннан арынып, урыныннан сикереп торды да түшәмгә эленгән җиделе лампага үрелде. Шулвакыт ян тәрәзәдә ниндидер шәүлә чагылып китте. Гөлбану куркып идәнгә чүкте.

— Кемдер бар анда?

— Кая? — Рәхимулла тәрәзәгә ташланды. Нәкъ шулвакыт өйалды ишеген шакыдылар. Рәхимулла йөгереп чыгып ишекне ачты. Ишектә Латыйпов басып тора иде.

— Кунаклар кая?

Кунак өеннән Шәрәпов чыкты.

— Монда без.

— Хәзер генә райком секретаре шалтыратты. Шелтәли. Сездә, понимаешь, ике көннән бирле артистлар ята икән, ә сез районга хәбәр итмисез, ди. Анда сезне эзләп, сезнең иптәшләрегез килеп чыккан.

— Нинди иптәшләр?

— Әртистләр. Синең үзеңне телефонга чакырдылар. Әйдә, тизрәк.

Өйалдына Рафига ханым белән Мәхмүт тә килеп чыкты.

— Туктагыз, без дә сезнең белән.

— Ә сез нәрсәгә?

— Ничек инде нәрсәгә? Ул нинди артистлар икәнен безнең дә беләсебез килмимени?

— Юк, Рафуш, сез хәзер үк мәктәпкә барыгыз. Мәхмүт, син тагы бер мәртәбә сәхнәне карап чык. Декорация, бутафур кебек нәрсәләр киртәсенә керерлек булсын. Мин туры шунда кайтам. Кайткач сөйләрмен.

— Юк, башта безгә кайтабыз. Минем карчык аш әзерләп көтеп

калды анда. Ә сез барыгыз да безгә бара торыгыз,— диде Латыйпов.

— Соңыннан, Латыйпов, соңыннан. Спектакльне уздырмый торып, ашау турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Киттек.

Алар капкадан чыгып киткәндә, өйдәгеләр бар да киенеп өлгергән иде инде. Капка ябылган тавышка Гөлбану сискәнеп китте.

— Рәхимулла, Латыйпов абый капкадан кергәндер бит ул?

— Капкадан кермичә каян керсен?

— Алайса бакчада кем иде?

— Берәү дә юк. Мин карадым бит.

— Син караганда чия төбенә посып өлгергән иде инде ул.

— Ул сиңа күренгән генә. Курыкканга куш күренә, ди.

Мәхмүт Гөлбануны тынычландырырга тырышты.

— Ә син курыкма, Гөлбану. Ул карт кайтса да, бернишли алмаячак. Бүгенге спектакльдән соң халык аны бөтенләй авылдан ук куар әле. Әйдә, киттек. Биклә ишегеңне.

Алар урамга чыкканда тәмам караңгыланып җиткән иде инде. Мохтар картның бакча коймасын узып туры сукмакка борылганда, Мәхмүткә арттан кемдер коймага поса-поса килә кебек күренде. Ул шундук туктады да:

— Рәхимулла, сез бара торыгыз, мин хәзер куып җитәрмен,— дип, юл буендагы таллыкка кереп калды. Таллыкка посып юлны күзәтте. Кем булыр икән? Әгәр дөрес күргән булса, менә хәзер койма почмагыннан килеп чыгарга тиеш ул кеше. Юк, күренми. Әллә ялгыштымы? Рәхимулла әйтмешли, курыкканга куш күрендеме? Алай дисәң, Мәхмүт тамчы да курыкмый. Гөлбану шикелле куркак кыз бала түгел бит ул. Егет кеше. Бүредән курыксаң, урманга барма, ди. Шул бүреләр белән көрәшергә дип олы юлга чыкты да ул. Почмактан барып карыйсы, артта беркемнең дә булмавына ышанасы, урынсыз шикләрен таратасы килде аның. Койма почмагына килеп җитүгә янә туктап калды. Ниндидер шомлы тынлык. Ул, коймага сыланып, акрын гына почмактан үрелеп карады. Теге яктан аның маңгаена терәлеп диярлек... мылтык көпшәсе карап тора иде. Каяндыр калкып чыккан икенче бер бәндә үзенең көчле куллары белән Мәхмүтнең иңеннән алды.

— Әйдә, әйдә, алга чык. Нигә үрелеп кенә карыйсың?

Тегесе дә Мәхмүт каршына чыгып басты һәм көпшәсе киселгән кыска мылтыгын билбавына кыстырды.

— Ул бу нәрсәкәйнең ни дип аталганын белми.

Мәхмүт аларга исе китмәгәндәй итеп:

— Беләм, обрез,— дип җавап бирде.

— Белсәң, бик әйбәт. Батыр егет икәнсең. Шулай да, үзеңнән өлкән абзыйларыңның сүзенә колак сал әле син, энем. Яшисең киләдер бит?

— Бик килә!

— Килсә, хәзер үк мәдрәсәгә бар да, андагы үзеңнең шайтан токымыңа аңлат: бүгеннән бу авылда һәм бу төбәктә бернинди шайтан вәсвәсәсе таратып йөрмәскә. Бүген бер генә адәм дә мәктәп бусагасын атлап керергә тиеш түгел. Эчтән бикләнегез дә үзегезнең манаткаларыгызны җыеп алыгыз. Ә иртән таң белән тәртәгезне кире борыгыз.

— Без тәртәләп түгел, җәяү.

— Бигрәп шәп. Юкса... Караңгы почмактан барыгызны да берәмберәм чүпләп бетерәчәкбез. Аңлашыламы?

— Аңлашыла.

— Аңлашылса, хәзер исән калуың өчен безгә рәхмәт әйт тә йөгер. Я, нигә катып калдың?.. Йөгер диләр сиңа!

Мәхмүт таллыкка җиткәч, артына борылып карады. Әлеге адәмнәрдән җилләр искән иде. Мохтар карт бакчасы артында ераклаша барган тояклар шапылдавы гына ишетелеп калды. «Качтылар. Янап, куркытып, үз максатыбызга ирештек дип качтылар инде алар үзләренчә».

Гажәп, Мәхмүт нишләптер курыкмады. Башта да курыкмады, хәзер дә курыкмый. Үлем белән күзгә-күз очрашкач, курку кача күрәсең адәм баласыннан. Ә менә алар үзләре курка. Курыкмасалар караңгыда шулай кача-поса йөрер идемени алар? Курыкмасалар, качып китәрләр идеме? Нишли ала ди әле ул ач бүредәй төнге ауга чыккан ике кеше? Мәхмүт бит ялгыз түгел. Аның иптәшләре, фикердәшләре бар. Күп алар. Алар ягында — бөтен авыл, ил, халык! Шулай булгач, нигә куркырга тиеш ди әле ул алардан? Бу турыда әйтеп, иптәшләренә дә шом салмаячак ул. Авыл советына да хәбәр итмәс. Аның алдында бүген зур сынау тора. Беренче мәртәбә халык алдына чыгып, беренче спектакльне уйнау. Моннан да зур, моннан да изге бурыч бар микән? Бу турыда беркем дә белмәскә тиеш. Иптәшләре бар көчен салып спектакль уйнасын, халык дикъкать белән тыныч кына спектакль карасын. Үзең дә тынычлан, Мәхмүт, берни сиздермә. Шулайрак уйлады Мәхмүт һәм, кызу-кызу атлап, читән буенда аны көтеп торучы иптәшләренә килеп кушылды.

— Нигә озакладыгыз, Мәхмүт абый?

— Юк, юк, бернәрсә юк... Әйдәгез, киттек!

Алар тыкрык буйлап авыл урамына менеп киттеләр. Рафига ханым аңа якын ук килеп акрын гына пышылдады:

— Шулай да нәрсә булды?

— Кичә Хәбиб абый алып кайткан каз ите эчемә ярамады ахры.— Аннан ул Рәхимуллага борылды: — Тарт гармуныңны, Рәхимулла, гармун моңы халыкны спектакльгә чакыру булып яңгырасын! Ә эченнән: «Чакыру гына түгел, бу аларның янавына җавап та булып яңгырарга тиеш»,— дип уйлады.

Мәхмүтләр килеп җиткәндә мәктәп әйләнәсендә халык шактый җыелган иде инде. Алар, эчтән бикле ишекне шакып ачтырдылар да, тиз генә кереп башта сәхнәне карап, барлап чыктылар. Сәхнә дигәне мәктәп коридорының бер башында, яңа ярган калын такталарны бүкәннәргә тезеп эшләнгән биеклек иде. Ул арттагы стенага барып терәлә. Сәхнәнең ян-якларында берәр ишек. Алар — уку бүлмәләренең ишекләре. Ул бүлмәләр хәзер артистларның киенү-чишенү, бизәнү-гримлану бүлмәләре итеп җайлаштырылган. Сәхнә ишегалдын сурәтли. Бер як бүлмә ишегенә болдыр баскычы куелган, икенче ишек капка ролен уйный. Түрдә койма. Койма буенда сиртмәле кое бурасы. Сәхнә пәрдәсенә кемнеңдер чүпләмләп сугылган чыбылдык-чаршавын тартканнар. Боларның барысын да көндез килеп Мәхмүт үзе эшләтеп киткән иде. Залга шау-гөр килеп халык тула башлады. Ул арада авыл советыннан Шәрәпов та кайтып җитте. Рафига ханым аңа сораулар яудыра башлады.

— Я, кем чакырган? Нәрсә диделәр? Анда нинди артистлар килгән?

Шәрәпов бу сорауларның барсына да берьюлы җавап бирергә ашыкмады. Андый вакытта тилмертә инде ул, Рафига ханымның тәкатен талкый.

— Ашыкма, Рафуш, ашыкма... Мин дә бит синең шикелле артист, минем дә бит киенәсем, гримга утырасым бар.

— Син киенә-киенә сөйлә.

— Мин киенә башлау белән үк образга керәм. Бу очракта инде син мине дөньяви сораулар белән алҗытма.

— Хәбиб дим!

— Җитте. Син мине образдан чыгарасың.

— Кем чакыртканын гына әйт, ичмасам.

Шәрәпов җитди кыяфәткә кереп, эре генә җавап бирде:

— Кем булсын?.. Райком секретаре, билгеле. Аннан башка кем инде телефонга чакыртып, урам буенча йөгертә ала.

— Нәрсә ди?

— Менә анысын әйтми торам инде, җаный. Анысын әйтсәм, сез барыгыз да хыял диңгезенә чумып, образдан чыгачаксыз.

— Тилмертмә кешеләрне.

Шәрәпов берәм-берәм барысының да йөзенә күз йөртеп чыкты. Барсының да йөзе түземсезлек белән аңа төбәлгән, барсы да аның сүзен авызыннан тартып алырлык булып торалар иде.
— Нәрсә, бу сорау барыгызны да кызыксындырамыни?
Барысы өчен дә Мәхмүт җавап бирде:
— Билгеле, кызыксындыра.
— Алайса җавап бирәм, тыңлагыз: ниһаять, безгә дә бәхет елмаерга тора, дусларым! Ниһаять, безгә дә күктән көткәнне җирдән бирә шикелле.
— Чакрым ярымнан урамыйча, турыдан-туры гына әйт, зинһар!
— Ниһаять, безнең дә эшләр урыныбыз, торыр куышыбыз, тотып ашарга үз икмәгебез була шикелле.
— Нәрсә? Тагы икмәк чәчәбезмени?.. Я ходай!
— Юк, чәчмибез. Чәчкән икмәкне үзебезнең хәләл акчабызга сатып алып ашыйбыз.

— Боргалама, зинһар!!!

— Кыскасы, район театрны үз карамагына ала. Райком секретаре Мәгариф халык комиссарнаты белән сөйләшеп, бу мәсьәләне хәл кылып куйган. Безнең карамакка район клубы тапшырыла һәм торак өчен ике катлы зур бер йорт билгеләнә. Иртәгә иртүк килеп җитәргә кушты секретарь.

— Районга унбиш чакрымнан артык юл барасы бар. Җәяү, саз ерып ничек иртүк барып җитмәкче буласың анда?
— Мин дә шулай дигән идем, райком секретаре көлә генә. Бетте инде ул сезнең өчен саз ерып җәяү йөрүләр, Хәбибрахман абый, ди. Без сезне тарантаста гына йөртәчәкбез, ди.
— Дугага кыңгыраулар да тагарга кушмагандыр бит?
— Булыр әле, җаный, булыр. Кыңгыраулы пар атларда йөрер көннәре дә булыр артистларның... Аннары хискә, пафоска бирелеп, шигырь укый башлады:

Җиктереп пар ат, киттем Казанга туп-туры карап...

Бар да рәхәтләнеп көлешеп алдылар. Аннан Рафига ханым:
— Җитәр сиңа, хыялый, күктән җиргә төшәргә вакыт,— дип, Шәрәповның аркасыннан шапылдатып алды.— Ярый, район театры булып оештык ди. Ә... артистлар? Артистлары кайда?

— Көтәләр. Анда, районда көтәләр.
— Кемнәр?
— Әнвәр Кәримов. Үзе белән киткән әлеге ике егетне, кыш көне киткән теге ике кызны да табып алып килгән.
— Син шуларга ышанасыңмы? Бер ташлап киткән кешеләр тагы китмәс дип уйлыйсыңмы?
— Ышанам. Артист — балга кунган чебен шикелле ул. Театрның, сәхнәнең тәмен белеп алдымы, аннан мәңге аерыла алмый. Ә инде театрдан бер китеп, аның сагышын татып, аннан башка яши алмаячагына инанып театрга яңадан кайткан артист ул инде фанатикка әйләнә.
— Безнең күзгә ничек күренербез, дип уйлый икән соң синең ул фанатикларың?
— Менә монысы инде алар өчен иң авыры. Сизәм, телефоннан елый Кәримов. Җаны газаплана, җаны телгәләнә. Басу капкасына чыгып, тезләнеп каршы алачакбыз, зинһар, кичерегез генә, ди. Үтенәм, дусларым, авыр сүз әйтеп, ачулы караш ташлап, аларның җәрәхәтен әрнетә күрмәгез. Бер нәрсә булмаган шикелле итеп күрешегез. Кочаклашыгыз, үбешегез. Шулай тәэсирлерәк, нәтиҗәлерәк булыр.
Бүлмәгә Латыйпов килеп керде.
— Халык җыелып бетте, башламыйбызмы?

## Кемнәр гомерен саный күке?

Ниһаять, көтеп алган минутлар килеп тә җитте. Курку-калтырау, шик-шөбһәләр аша өмет багълаган минутлар. Мәхмүт сәхнәдән торып, пәрдә аша залны күзәтә. Мәктәп коридоры халык белән шыгрым тулы. Коридорга чыга торган бүлмәләрнең дә ишекләре ачык. Ул ишекләрдә дә халык дөмбәчләп тутырган шикелле. Шул ишекләрнең берсендә ниндидер таныш шәүлә чагылып киткән кебек булды Мәхмүтнең күзенә. «Юк, юк, булырга тиеш түгел. Бу тагы шул, курыкканга куш күренү». Мәхмүт, чаршауны аралап, сәхнә алдына эленгән лампага үрелде. Шулвакыт коридор стенасындагы күкеле сәгать аваз бирде:

— Күк-күк...

Мәхмүт сискәнеп артка чүкте. Залда берәү: «Кемнеңдер гомерен саный бу күке»,— дип куйды. Халык үзара шаулап алды. Мәхмүт Рафига ханымга ишарә ясады: «Башлагыз!» Сәхнә алдына Рафига ханым чыгып басты.

— Тынычланыгыз, иптәшләр. Ул сәгатьне вакытлыча туктатып торсагыз икән. Без әле яшь башларга җыенып кына торабыз, безнең гомерне санарга кирәкми.

Шулвакыт залдан икенче берәү:

— Алып ташлагыз ул кулак сәгатен стенадан! — дип кычкырды.

— Сәгатькә тимәгез инде сез, иптәшләр. Ә менә залдагы утны кысарга кирәк булыр,— дип елмайды Рафига ханым.

Кайсыдыр шунда коридор уртасына эленгән утызлы лампаның фитилен кысты. Зал караңгыланып калды. Шуннан файдаланып, коридор ишегенең яңагына сөялгән кыска кожанлы ике кеше стена буенча алга елыша башлады. Аларны Рафига ханым да күрми, аларга залдагы халык та әһәмият бирми иде. Рафига ханым сәхнә каршына эленеп, зал ягыннан газеталар белән капланган лампаларның фитилен күтәрде. Сәхнә алды ялт итте. Шәһәр театрындагы прожекторлармыни! Аннан Рафига ханым бер кулын күтәреп, залга ишарә ясады. Зал кинәт тынып калды. Рафига ханым зур дәрт белән сөйләп китте:

— Хөрмәтле иптәшләр! Кадерле тамашачылар! Без сезгә бүген «Фаягөл» исемле бер пәрдәлек спектакль күрсәтәбез. Аны безнең яшь артистыбыз Мәхмүт Габдуллин язды. Фаягөл ролен артистка Зәйтүнә Насыйрова башкара. Фазылҗан ролен артист Мәхмүт Габдуллин үзе уйный. Хөрмәтулла ролендә артист Хәбиб Шәрәпов, хәзрәт ролендә артист «икс». Ягъни, билгесез кеше уйный. Спектакльдән соң зур концерт булачак. Концерттан соң шушы залда артистка Зәйтүнә Насыйрова авыл яшьләренә яңа җырлар, биюләр, күмәк уеннар өйрәтәчәк. Теләгән кешеләр: егетләр-кызлар, апалар-абыйлар, бабайлар-әбиләр, һәм... бишектәге бәбиләр, рәхим итегез! — Зал рәхәтләнеп, шаркылдап көлеп алды. Аннан Рафига ханым янә кулын күтәрде.— Шушының белән рөхсәт итегез бүгенге кичәбезне башлап җибәрергә!

Рафига ханым эчкә узды, Мәхмүт «башлагыз» дип кул изәде, сәхнә артында ике гармуннан берьюлы көчле аккорд яңгырады. Болар Шәрәпов белән Рәхимулла иделәр. Аларга Гөлбануның көчле аһәңе кушылды, ул өзгәләнде, талпынды, гүя тилмереп кемнәрнедер ярдәмгә чакырды, аннары ерагайганнан-ерагая барып, тынып калды. Шушы тынлыкта салмак кына пәрдә ачылды.

Сәхнәдә — егет белән кыз. Сәхнәдә ике гашыйк. Ләкин алар читлектәге ике аккош кебек. Аларны бер-берсеннән сәхнә уртасындагы биек койма аерып тора. Кыз койманың эчке ягында, егет тышкы якта. Ул үзенең аһ-зарын җыр белән койма аша аңлата. Кыз да аңар җыр белән җавап бирә. Гүя ул аны үзенә чакыра. Кызның ягымлы тавышы, моңы егеткә канат бирә. Ул, гүя, шул канатлар белән җилпенеп, койма аша кыз ягына очып төшә. Кыз аның кочагына ташлана, әмма өнгә килеп

читкә тайпыла. Егет килеп аның кулларыннан ала, үзенә тарта, йөзләр-йөзгә якынаялар... Фаягөл үз-үзен онытып Фазылҗан кочагына тәмам сеңеп беткәч, капкадан Хөрмәтулла карт кайтып керә. Керә дә... аларны шул кыяфәттә күреп, баскан урынында катып кала. Аннан яшелле-зәңгәрле тавышлар чыгарып, ике йодрыгын күккә күтәреп, кычкыра башлый:

— Тотыгыз зиначыларны!!!

Егет белән кыз, сискәнеп, икесе ике якка ташланалар. Хөрмәтулла карт күсәк алып егет өстенә килә башлый, кыз өзгәләнеп кычкыра:

— Кач... Фазылҗан бәгърем, кач тизрәк!

Егет, күз ачып йомганчы, койма аркылы сикереп юк була. Аннан Хөрмәтулла карт кызга борыла һәм күсәге белән аңа кизәнә.

— Син мине мәсхәрә иттең, ашаган табагыңа төкергән нәрсә.

— Сук, сук күсәгең белән. Үтер мине, хәзер үк үтер! Әниемне вакытсыз кабергә тыктың, болай газаплаганчы инде минем дә җанымны ал.

Хөрмәтулла туктап кала. Озак итеп кызга карап тора. Аннан күсәген бер читкә ташлый.

— Юк. Мин сине үтерми торыйм әле. Үтерер өчен асрамадым бит мин сине еллар буе. Мин сине иң элек ефәккә күмәм. Барлык мал-мөлкәтемне, байлыгымны сиңа яздырам. Син яшь, син чибәр. Син бай хатыны булырга тиеш. Менә шушы йортның хуҗасы булып калырга тиеш син мин үлгәч. Ә мин күп тормам инде... Күп тормам, балакаем! Мине рәнҗетмә. Мин исән чакта син минеке бул!

— Ни сөйлисең? Мин синең кызың лабаса!..

— Үги... Үги кызым. Үги кызга никах дөрес ди хәзрәт әйтә.

— Юк, юк, беркайчан да! Минем вәгъдәләшкән егетем бар.

Хөрмәтулла карт карлыккан тавышы белән тагын тирә-якка төкерек чәчә.

— Ул хәерче белән син нишләрсең? Кайда торырсыз? Нәрсә ашарсыз, ни киярсез? Ә менә мин үлгәч, бай хатын булып калгач андый этрәкләрнең менә дигәнен сайлап алырсың. Бай хатынга сөлек кебек егетләр киләчәк. Ә хәзер син минеке бул, минеке, бары тик минеке генә!

Ул, кызның беләгеннән эләктереп, өйгә сөйри башлый. Кыз карыша, тартыша, кычкыра-өзгәләнә. Хөрмәтулла карт аның ай-ваена карамыйча биленнән күтәреп ала да, кычкырта-кычкырта өйалдына алып кереп китә. Анда кызның йөрәк ачысы белән кычкырганы ишетелә, аннан ул тынып кала. Болдырга йозак тотып Хөрмәтулла килеп чыга.

— Беркая да бара алмассың. Хәзер мин мулла алып килеп никах укытам да, аннан — вәссәләм! Аннан син инде минем никахлы хатыным, синең карышып маташырга хакың юк!

Ул, йозак белән өйалды ишеген бикли дә, ашыгып капкадан чыгып китә. Сәхнә бермәлгә тын кала. Тамаша залы да тына. Тик ара-тирә кемнәрнеңдер көрсенүе, кемнәрнеңдер шылык-шылык борын тартып елавы гына ишетелә. Аннан өйалдында нәрсәдер дөберди, кыз көч-хәл белән ыңгыраша башлый. Тышкы яктан койма буена егет килә. Койма ярыгы аша ишегалдын күзәтә. Ишектәге йозакны күреп ала.

— Киткән. Өстеннән бикләп каядыр киткән.

Тамаша залыннан кемдер:

— Кер инде, нәрсә торасың катып! Койма аша сикереп кер дә, коткар баланы,— дип кычкыра.

— Дәшмәгез, ярамый.

Халык арасыннан кыска кожанлының берсе аваз сала:

— Нигә ярамасын? Нигә күрәләтә кыз баланы җәберләргә юл куясыз?..

— Җәмәгать!

Өйалдыннан Фаягөлнең зәгыйфь тавышы ишетелә:

— Фазылҗан, коткар!..

— Бар инде, бар, үлә бит!

— Тәртип!..

Шулвакыт капкадан Хөрмәтулла белән бергә ап-ак сакаллы, тубалдай чалма кигән карсак буйлы, юан корсаклы мулла килеп керә. Тамаша залыннан янә шул ук тавыш:

— Менә, килделәр дә...

— Кертмәгез үзләрен, кертмәгез!..

Кыска кожанлының икенчесе стенадан сәгать герен алып кесәсенә сала.

— Нәрсә шаккаттыгыз? Сөйрәп төшерегез дә, бирегез кирәкләрен!

— Кузгалмагыз, бу бит театр.

— Театр дип, шул явызларга юл куябызмыни инде, җәмагать?

— Утырыгыз урыныгызга!

— Син нәрсә яклыйсың, үзең авыл советы була торып?

— Житте дим, бирегез әртистләргә уйнарга.

— Ярый, уйнап карасыннар, Ул-бу булса, кара аны!

Беравыкка зал тынып кала. Хөрмәтулла карт ишекне ача.

— Әйдә, менә бирегә рәхим ит, хәзрәт.

Хәзрәт? Монысы кем тагы, хәзрәт дигәне? Аларның башка артистлары юк иде шикелле. Рәхимулла түгел бу. Кыяфәте аңа охшамаган. Рәхимулла сәхнә артыннан гармун уйнап тора. Монысы кем булыр икән? Шул турыда баш ватты тамаша залында тын гына утырган Хәкимулла. Хатыны ягына да борылып-борылып карады ул. Ләкин хатыны каян белсен, Хәкимулла үзе белмәгәнне. Тукта, тукта... Рафига ханым ич бу. Әй, егетләр, хәзрәт-түти булган бит бу тәмам.

Өй эченнән салмак кына, ниндидер калтыравыклы борын тавышы белән, көйләп, никах сүрәсе укый башладылар. Сүрә көчәйгәннән-көчәя барды, һәм ул иң югары ноктасына менеп җиткәндә генә, койма ярыгына сеңгән Фазылҗан, ике йодрыгын йомарлап, ниндидер кыргый тавыш белән кычкырып, коймага китереп бәрде дә, җиргә тәгәрәп үкси башлады:

— Харап итәләр бит башкайларыңны, Фаягөл!

Зал яңадан кузгалды. Кыска кожанлылар бер-берсенә карап елмаешып алдылар: «Нәкъ вакыты». Бу кешеләрнең сәер кыяфәтен күреп Хәкимулла шикләнә төште. Алар, умартага таяк тыккан кебек, болай да тузгый башлаган халыкны кабындырып җибәрергә маташалар иде.

— Нәрсә сез, җәмагать, карап торып?!.

Аларга ияреп бер төркем халык алга омтылды. Хәкимулла урыныннан сикереп торды:

— Туктагыз!

Шулвакыт өйалды ишеген бәреп, болдырга Фаягөл килеп чыкты.

— Юк, юк, беркайчан да!

Зал аягүрә басып тынып калды. Фаягөл ишегалды түренә йөгерде. Ишектән Хөрмәтулла карт чыгып аңа ташланды.

— Тукта, тукта диләр сиңа!

— Юк, юк!

Һәм... һәм шул вакыт Фаягөл йөрәк өзгеч тавыш белән кычкырып ишегалды түрендәге коега сикерде! Сәхнә артында коточкыч итеп күк күкрәде. (Рафига ханым зур бер табак калайга гөбе пешкәге белән бәрә иде.) Гармунда көчле аккорд яңгырады һәм аңа сәхнә артыннан Гөлбануның аккош тавышын сурәтләп өзгәләнүе кушылды: «кый-гак, кый-гак!..» Аннан кемдер:

— Харап иттек... Бөтен авыл белән карап торып харап иттек бит, балакайны! — дип кычкырып елап җибәрде.

— Эх, Фаягөл, Фаягөл!..

— Нинди Фаягөл булсын? Үзебезнең Гөлбану балакай иде бит ул!

— Эх, явыз, явыз!.. Нинди баланың җанын кыйды бит!

— Ә без шуны бөтен авыл белән яклап калган булдык.

— Куарга! Хәзер үк авылдан куарга шул ата кулакны.

Кыска кожанлылар, тузгыган халык өерен әйдәп, сәхнәгә ташланалар.

— Әйдәгез, милициягә тотып бирәбез үзен!

— Туктагыз!

— Туктамагыз, тотыгыз, бәйләгез!!!

Зал шаулый, дулый, менә-менә көчле давыл булып сәхнәне дә, артистларны да өереп алып китәр дәрәҗәгә җитә. Беренче рәтләр сәхнәгә сикереп менеп кое авызына капланган Шәрәпов — Хөрмәтуллага ташланалар. Мәхмүт алар арасында бая Мохтар карт коймасы буенда биленә обрез кыстырган кыска кожанлыны күреп ала. Кинәт аның башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китә. Бер мизгелгә ул нишләргә белмичә югалып калган кебек була. Аннан тетрәнеп, җан ачысы белән кычкырып кыска кожанлыга ташлана, аның кожанын төймәләре белән бергә умырып ала да билбавына кыстырган обрезын тартып чыгара. Икенче кожанлының сәгать гере белән Шәрәповның башына кизәнгәнен күреп, гәүдәсе белән Шәрәповны капларга өлгерә. Сәгать гере Мәхмүтнең баш түбәсенә туры килә. Ул ике кулы белән обрезны кысып тоткан килеш йөзтүбән идәнгә ава. Беренче кожанлы Мәхмүт кулындагы обрезга үрелә. Алар артыннан сәхнәгә сикереп менгән Хәкимҗан аны якасыннан умырып алып читкә селти. Шулвакыт алыптай гәүдәсе белән халыкны як-якка бәргәләп, сәхнәгә Хәйри очып менә һәм обрезны тартып алып югары күтәрә: «Якын килмәгез!» Түшәмне күтәреп чөяр дәрәҗәдә көчле шартлау яңгырый. Сәхнәне төтен баса. Шашкан кыяфәттә сәхнәгә бәреп менгән халык кинәт туктап, бер урында катып кала. Шул вакыт сәхнә артындагы эчке бүлмәнең тәрәзә пыялалары чалтырап коела.

— Качтылар, тәрәзәдән төшеп качтылар!

Хәкимулла ватык тәрәзәдән бакчага сикерә. Аның артыннан Хәйри, Рәхимулла һәм тагы берничә комсомол активы тәрәзәдән сикереп әлеге ике кешене куа китәләр.

Зәйтүнә идәндә хәрәкәтсез яткан Мәхмүткә ташлана.

— Үтерделәр!

Сәхнәгә менгән халык акрын-акрын артка чигенә. Алар каршына Латыйпов менеп баса.

— Зур ахмаклык эшләдегез бит, җәмәгать!

— Без бит, чын дип белеп... Без бит менә бу баланы коткарабыз дип...

Шәрәпов — Хөрмәтулла паригын, сакал-мыекларын кубарып, Мәхмүт күкрәгенә башын куеп тыңлый:

— Сулышы бар. Аңын югалткан булса кирәк. Кузгатырга ярамый. Аны хәзер аз гына да кыймылдатырга ярамый. Доктор, доктор кирәк!

— Хәзер!

Латыйпов, артыннан бер төркем кеше ияртеп, авыл советына, телефонга йөгерә.

# Лена Шакирҗанова

## Ике хәбәр арасы

I

Аз да түгел, күп тә түгел —
Бары ике хәбәр арасы:
«Сугыш» — бәргәләнде карт барабан.
«Җиңү!» — яшь быргылар авазы.

Аз да түгел, күп тә түгел —
Сугыш белән Җиңү арасы...
Өй борынча үз корбанын даулап,
Өстерәлде сугыш арбасы.

II

Кара янды ап-ак каен,
Яраланды ап-ак таем.
Күбәләкне өтте яшен,
Чишмәкәем түкте яшен.
Албасты зат таптап үтте
Хәтфә келәм аланымны.
Таң төсеннән кан төсенә
Манды миләш-баланымны...
Ил ишеген ватып керде
Чакырылмаган хәтәр кунак.
Хәрби кием киде гүя
Һәрбер агач, һәрбер куак...
Болынымда биеп йөргән
Бал-гөл исле шаян җилем,
Тончыгып сугыш көленә,
Ташлап китте туган җирен.
Ике хәбәр арасында
Каннар акты елга-елга.
Ике хәбәр арасыннан
Әнкәм атлый егыла-егыла...
Хәсрәт төяп, кара көймә
Агып китте Идел буйлап.
Агып китте өзелеп көткән,
Килеп җиткән бәйрәм-туйлар...
Ике хәбәр арасында
Эленеп калды ал яулыгым.
Ватык сугыш арбасында
Тумый калган балам елый...
Ятим бер моң сугылып йөри
Хәрабәдән — хәрабәгә.
Ядрә тиеп янып ята
Өчпочмаклы сәлам-хәбәр...
Ике хәбәр арасында
Кысылып калды гүя дөнья.
Сүнмәсен тик Ил учагы —
Як син аны, көн як, төн як!
Акрын гына таң сызыла,
Колак салам бер тавышка:
«Nach Osten»ны күмеп китте
«Көнбатышка!» «Көнбатышка!..»
Күпне күргән каскаларда
Биш канатлы йолдыз яна.
Шул йолдызның яшәү көчен
Исбат иттек без дөньяга...
Тамыры белән җирне капшап,
Сулыш алды сулган каен.
Акбүз атка әверелеп,
Үсеп җитте юаш таем...
Ике хәбәр арасында
Җирдән бизә язган язны
Кайтарды Җиңү авазы —
Канга манып елын яздык:
Кырык бердән — Кырык бишкә
Күпер салды күпме гомер.
Кисәүләнгән кәүсәләрдән
Яшьнәп чыкты ябь-яшь бөре...

III

Аз да түгел, күп тә түгел —
Бары ике хәбәр арасы:
«Сугыш!»—
бәргәләнде карт барабан,
«Җиңү» — яшь быргылар авазы.
Берлин капкалары уртасында
Кысылып калды сугыш арбасы.
Үзгәртергә бераз туры килде
Европаның иске картасын...
Арба калды, ә капкалар илне
Бүлеп куйды аргы-биргегә.

«Әйләндерсәң арба тәгәрмәчен,
Кайтмас микән тарих киргегә?»—

Аръягына посып шул капканың,
Рейган әнә ниләр кылына:
Арбаны ул хәзер канат тагып,
Чыгармакчы йолдыз кырына...

Чү! Кагылма минем йолдызыма,
Йолдызларга инде орынма!!
Сугыш сүзе белән Йолдыз үзе
Баса алмас мәңге янәшә.
Тормыш белән үлем беркайчан да
Алмаган күк Җирдә ярәшә!..

IV

Тоныкланган Йолдыз иле:
Җирдән яман хәбәр килде.
Кем уйлаган йолдызларга
Кагылыр, дип сугыш җиле?!
Таң йолдызы бакты Җиргә:
— Нәрсә булды сиңа, Кешем?
Моннан торып ишетмәсәң,
Әйтим микән әллә төшеп?
Без — йолдызлар кайсы чакта
Башны җуеп атылсак та,
Гел бер дога, гел бер теләк:
«Җирне сакла!» «Җирне сакла!..»
Кара төндә адашканда,
Маяк булып уңнан, сулдан.
Яктыртабыз армый-талмый,
Язмасын, дип Кеше юлдан.
Балкышабыз, ялык-йолык
Җемелдибез Сиңа карап.
Төн чыгабыз Сине саклап,
Ах! Үзеңне итмә харап!!

...Йолдыз иле. Йолдыз җиле
Җиргә беркөн җитте килеп.
Йолдыз җиле кагылганда,
Балам төшләр күрә көлеп...
Ак каеным дип уйлана
Ягылып төн карасына?
«Тегe арба кереп китсә
Җидегән Йолдыз арасына?..»—
Челтер-челтер Җидегән чишмә
Серен сөйли күбәләккә.
«Таңда җилләр тыныч иссә,
Дөнья бигрәк түгәрәк лә...»—
Кешнәп куя кашка таем,
Ак йолдызы маңгаенда...
«Таңнар нигә шулай моңсу
Була икән май аенда?..»—
Ник соң әле әнкәемнең
Таң йокысын ачты дөнья?
Уйга талган чал чәчләре
Ал чәчкәле ястыгында...

Ә йолдызлар күк гөмбәзен
Күк томанга төреп кенә,
Берәм-берәм югалалар,
Югалалар эреп кенә...
Шул йолдызлар арасында
Синең дә бит үз йолдызың,
Уян, Кешем! Уйлан, Кешем!
Уйнат, Кешем, таң быргысын!!
Җир шарының уртасына
Элеп куй син бәллүр бишек.
Берәм-берәм һәммә йолдыз
Кунак булсын шунда төшеп...
Ә мин мәңге калыйм Җирдә,
Очсын әнә ал яулыгым
Йолдызлардан йолдызларга,
Имин хәбәр, сәлам булып!

*1985.*

## Илсөяр Ганиева

# ТАМЧЫЛАР

*

Йөрәк тавышым китсен еракларга,
Юлдаш булсын барыр юлымда:
Кызлар моңы, күк күкрәве белән
Кылыч зыңы булсын җырымда.

*

Кемдер сусый язгы моңнарга,
Кемдер сусый һәрчак назларга,
Мин, яралы толпар — җилер идем,
Һай, сусадым назлы язларга.

*

Урманнарда яшел буранмыни,
Шаулый һәрбер яфрак, һәр ылыс;
Башка чакта күңел шаулы минем,
Шаулы урманнарда ник тыныч?

*

Табигатьтә — ул язылган закон,
Күрәсең ул шулай, йоладан:
Мәңгелеккә киткән Тукай, Такташ...
Мәңгелеккә кайткан яңадан.

*

Ачы буран и дулады —
Мәңгелек хаким сыман.
Кар астында чишмә чылтырый —
Чыныккан ятим сыман.

*

Әллә яшьлек, әллә исәрлек белән
Китте инде вак-вак хаталар,—
Гомер узгач инде шул хаталар
Тау-тау булып үрчеп яталар.

Сөенегез, әкәм-төкәм, суалчаннар,
Сөенегез, давылланып яңгыр килә:
Кемдер сыкрый кагыла-сугыла давылларда,
Җебенәләр хәшәрәтләр, көлә-көлә...

Алтын балдак бүләк итәлмәдең,
Яшьли йөртә алмадым кулымда.
Урак ярасыннан кигән йөзек
Мәңгелеккә калды җырымда.

Бар дөньяга бирә матурлыгын,—
Балаларга бирә анасы;
Мең газапта туа Җир-ананың
Җиңү дигән батыр баласы.

Күңелләрдә нинди гүзәллек бар,
Барсы мәхәббәтнең җимеше,
Әллә йөрәкләрдә бу мәхәббәт —
Барлык игелекнең инеше?

Чын бәхет ул — кемгәдер кирәк булсаң,
Син кирәкле — кемгәдер терәк булсаң.

Тормыш учагын һәркем дә көйрәтә:
Тырышкан дөрләтә,
Белмәгән өйрәтә.

## Гомәр Бәширов

# И ЯЗМЫШ, ЯЗМЫШ...

ПОВЕСТЬ

I



Пароход Курьягә кояш чыкканчы ук килеп житте. Атамның энесе — Билал абый каршы алырга ат жибәргән икән. Шулай итеп, мин авылга бик иртә кайтып төштем. Ләкин никадәр иртә кайтсам да, әнинең мунчасы өлгергән иде инде.

— Читләрдә бик озак йөрдең. Сиңа бүген чык тамчысыдай ару булырга кирәк. Бар, әүвәл башта чистарынып чык! — диде әни.

Мунчадан кайтышлый төз лапастан узганда кичә генә суелган тәкә тиресенә орына яздым. Ак өйгә керсәм, күзләрем камаша язды. Тәрәзәләргә ап-ак пәрдәләр, матчаларга кашага, тәрәзә араларына кызыл башлы сөлгеләр эленгән. Тәрәзә төпләре тулы чәчәкле гөл. Чаршау белән бүлеп алынган почмак якта ястык-мендәр өелгән купшы карават көтеп тора.

Әни мине аркамнан сөеп кеткелләп алды.

— Былтыр «укыйсым бар» дип чыгып тайдың иде дә менә бу юлы каптың инде. Хәзер инде ычкынды юк сиңа, ю-у-у-к.— Аннары кинәт йөзе житдиләнеп, тезенә сугып алды.— Әй, улым, туйдым бу ялгыз тормыштан, чистый гарык! Менә моннан! — дип тезеп китте дә кулын тамак астына куеп күрсәтте.

Минем әни элек-электән йорт башы булып гадәтләнгәнлектән, кайтып керүем белән мине дә башым-аягым белән үзенә буйсындырды. Мине ничек өйләндерүне дә алдан ук һәммәсен уйлап, көйләп куйган булып чыкты.

— Жомга көн — бәхет китерә торган якты көн. Никахыгыз бүген булыр дип уйлаштык. Бүгеннән дә калдырырга ярамый, Хәмдүнәң дерә дә ашыктыра. Аның баш очында козгыннар очкалый башлаган.

Бу хәбәр мине сискәндереп жибәрде, минем тамагымнан үтмәс булды. Хәмдүнә бит минем ярты жаным, аем, кояшым. Бу дөньяларда мин аннан башка яши дә алачак түгел. Мин шул минутта ук аны алып кайтырга дип кыбырсый башладым.

— Ул нинди козгын? Кем ул муены астына киләсе бәндә? Кайсы дошманы? — дидем.

Әни тынычлыгын бозмыйча гына жавап бирде:

— Кызма әле син, улым. Сүз кешенең исеме белән йөрми, я тәмсезгә китә башлар. Мондый изге эштә шарт та шорт сындырып бер нәмәстә дә майтарып булмый. Тыңла гына син! Тыңла!

— Ярый, тыңлыйм. Тик син дә истән чыгарма, әлеге козгын дигәнең бездән өлгеррәк булып чыкмасын!

— Юк, әле эш узмаган. Нәкъ көне. Шуның өчен бүген дип кистереп әйтәләр дә ич сиңа!

Шулай һәммәсен дә алдан күрүе өчен эчемнән әнигә рәхмәтләр укыдым.

— Чәйдән соң Билал абыеңа барырсың. Аңа әйт: җомгадан чыгышына хәзрәтне безгә алып килсен! — диде әни.

Билгеле, мин никах тыңлап утырачак кеше түгел. Хәмдүнә дә комсомолка. Әмма янача туй итик! дип киселеп төшсәм, эшне бозармын да Хәмдүнәдән колак какмагаем дип эчемнән генә тындым. Билал абый белән берәр хәйләсен табарбыз әле!..

Әни ашыкмыйча гына дәвам иттерде:

— Аннары түбән очка Мәрфуга йортына төшәрсең. Һәммәсе сөйләшенгән, килешенгән. Хәмдүнә төенчекләре белән сине шунда көтәр.

Әни, сүзеннән туктап, нидер мин белмәгәнне әйтергә җыенгандай сәер генә итеп миңа карап бераз икеләнеп утырды. Ләкин нигәдер әйтмичә калырга булды. Мин аның нәрсәне әйтми калдыруын соңыннан гына исемә төшердем.

— Ходай кушып шул уйлаганча гына булсын иде инде, матавыклар гына чыкмыйча. Җомга намазына азан әйткәч, Хәмдүнәне дә, җиңгәсен дә, бер-ике иптәш кызын да ияртеп безгә кайтасыз.

— Ә Хәмдүнәнең атасы?

— Анысы Билал абзаң эше.

Әни, күзләре белән эзләнеп тапты да, ишек янындагы чөйгә элгән маузерга ишарә итте.

— Ул нәмәрсәңне үзең белән алып бармыйсың! — диде.

— Аны йөртергә рөхсәт кәгазем бар бит минем. Эчке кесәдә генә булыр...

— Юк, юк, алмыйсың!

— Дошманнар бетеп җитмәгән бит әле, әни. Бәлки миңа берьюлы өч-дүрт контр ташланыр?!

— Барыбер! Мондый изге эштә мылтык шартлату беркайчан да яхшыга алып бармас.

Ишектән чыгып барганда иңбашыма кулын салып янә бер киңәшен әйтте:

Билал абыеңның ачы бал белән сыйлый торган гадәте бар. Бүген авызыңа да алма!

Сугышларда йөреп, Мәскәүдә укып кайткан егерме бер яшьлек егетне әни карчыкның мондыйларга да өйрәтеп маташуы мәзәгрәк тоелды. Мин көлеп кенә уздырмакчы булдым.

— Бик кыстаса... бик аз гына, берәр тустаган гына ярыйдыр ла инде,— дидем.

Әни чын-чыннан ачуланып бармак янады.

— Ичмасам тамчысы да ярамый! Кара син аны! Ишетсен колагың! Син бүген кыз куенына керәсе егет, андый белән шаярмыйлар! Мин уйлап чыгармаган, бабайлардан калган гадәт!

Нишләмәк кирәк, әни — әни инде ул, аның сүзе — закон!

## II

Турысын гына әйткәндә, әни мине үзган ел ук өйләндерергә җыенып беткән иде. Сөйгәнем Хәмдүнә белән дә вәгъдәләшеп куйган идек. Ләкин, армиядә хезмәтем тулуга, уком [1] мине укырга җибәрергә кирәк тапты.

[1] Уком — өяз комитеты.

Бу карарны мин дә чын күңелдән шатланып каршы алдым. Укырга китәм бит! Кая? Мәскәүнең үзенә! Кемгә тигән мондый бәхет? Ул елларда әле Казанда укучыларны да бармак белән генә санарлык иде. Тик менә ничек итеп укып та кайтырга. Хәмдүнәне дә кулдан ычкындырмаска?

Ул хакта Хәмдүнә дә ишетеп өлгергән икән, кич белән очрашкач ул мине бик салкын каршы алды. Төрпә генә итеп:

— Жиде-сигез еллык гыйлем дә житмәгәч инде! — дип куйды.

Миңа Хәмдүнәне ничек тә ышандырырга кирәк иде. Мин аның кулларын кысып янына утырдым.

— Ул бит искечә, Хәмдүнәкәй, мәдрәсә белеме, хәзер ул гына житми. Хәзерге заманда яңа белем дә кирәк: революция, сыйныфлар көрәше, совет власте турында...

Сөйгәнем янымнан торып китте. Башын иеп уйланып торды да кинәт миңа таба борылды:

— Ә мин? Алай бик яраткач, вәгъдәләр дә бирешкәч, нигә мине оныттың?.. Син Мәскәүләрдә укып кайтканнан соң абыстайда алган иске гыйлем белән мин сиңа ярамый башласам?! Ә?

Хәмдүнәнең күзләрендә мөлдерәп торган яшь иде. Аннары, дулкынлануым белән мин кергәч тә игътибар итмәгәнмен: ул мин бүләк иткән чия төсле йон күлмәген киеп, колагына мин алып биргән яшел фирүзә кашлы көмеш алкаларын тагып килгән. Бөтен барлыгымны татлы бер шатлык тойгысы биләп алды. Хәмдүнә мине жанын бүлеп бирердәй булып сөя! Ул минсез яши алмый, мин — ансыз! Юк, дошман үзенә карата алмый аны!

Хәмдүнәне иңбашыннан кочып алдым. Кинәт башыма бәхетле уй килде.

— Син дә укырсың, жаным, син дә! Мин иртәгә үк сөйләшеп китәрмен. Шәфкать туташлары хәзерли торган алты айлык курсларда укырсың.

— Чынлапмы? — Хәмдүнә күзләрен сөрткәләде дә миңа текәлде.— Шуннан соң? Аннан ары ничек?!

Беләм инде, ни әйтүемне көткәнен алдан ук сизеп торам.

— Шуннан соңмы? Шуннан соң... өйләнешәбез!

Кызый, минем ике кулымны кысып, йөземә текәлде.

— Тәгаенме? Вәгъдәме?

— Хак сүз инде, Хәмдүнәкәй, комсомол сүзе! — дидем.

Хәмдүнә, нидер эзләгәндәй як-ягына каранды да, ишек янындагы шкафтан чуар ашъяулыкка төргән ярты арыш икмәге алып килде. Тыны кысылгандай шыпыртлап:

— Сүзең хак булса, икмәк алып ант итәсең! — диде.

Бу «ант» дигән сүздән башта миңа ниндидер искелек бәреп тора кебек' ишетелде. Карт-коры гына үти торган ниндидер дини хорафат кына түгелме икән бу? Комсомолга ант итәргә ярыймы? Шунда гына исемә төште: гражданнар сугышына китәр алдыннан ант эчтек бит? Анда: «Революция дошманнарына каршы жаныбызны да аямыйча көрәшергә ант итәм»,— дигән сүзләр дә бар иде. Әһә, ярый икән. Икмәкне кулыма алып, чын күңелдән ант иттем.

Хәмдүнә елмая-көлә минем күкрәгемә сыенды.

— Ходаем, изге сәгатьләрдә генә була күрсен. Инде жаным тынычланды, мин сиңа ихлас күңелдән ышанам.

Хәмдүнәнең комсомолка башы белән ходайны телгә алуы башта колагымны тырнады. Әмма көчле кичерешләр ул шикне басып китте. Хәмдүнә бит, дөресен генә әйткәндә, бу сүзне аллага ышанудан әйтми, аны алмаштырырга башка сүз булмаганга, болай гына әйтә.

Шул минуттан башлап мин үземне ничектер житдиләнеп, хәтта бераз олыгаеп киткәндәй хис итә башладым. Хәзер инде әнине, үземне кайгырту белән генә эш бетми, күкрәгемә сыенган менә бу газиз жанны да үз өстемә алам, аның бәхетле булуына да мин жаваплы!..

Хәмдүнә тагын шыпыртлап:

— Унбер ай бик озак бит. Әти генә бүтән кешегә бирәм дип азапламаса ярый инде...— диде.

Минем үземнең күңелдә дә андый шик юк түгел иде. Бу хакта мине комсомол ячейкасындагы иптәшләрем дә искәрттеләр. Хаҗи бай тирәсендәге куштаннар, элек бөтен авыл яшьләрен үз кубызларына биетеп өйрәнгән сугыш чукмарлары комсомол ячейкасына каныгалар, аның турында төрле гайбәтләр тараталар, халык арасында дәрәҗәсен төшерергә тырышалар икән. Ячейканы оештырып җибәрүче, аңа һәрдаим булышып торучы булгангамы, миңа да теш кайрыйлар икән.

Хаҗи байларның болай да комсомолларга ачуы бар иде. Әле күптән түгел безнең комсомол отряды Кама буенда яшеренеп яткан бер банданы тар-мар иткәндә аларның күрше авылдагы кияүләре дә килеп капкан иде. Менә шуларның һәммәсе өчен дә бездән үч алырга чамалап йөриләр, имеш. Ничек итеп? Мине үтерепме, кыйнапмы, Хәмдүнәне үзләренә каратыпмы? Әллә башка берәр этлек эшләмәкчеләрме?..

Мин ни дә булса әйтергә өлгермәдем, ишектән атылып-бәрелеп Хәмдүнәнең сеңлесе килеп керде. Керә-керешенә, тыны-көне бетеп кычкырып җибәрде:

— Түтәй, качыгыз! Хәзер сезне тоталар!

Хәмдүнәнең төсе китте, мин дә сагайдым.

— Ничек «тоталар?» Кемнәр?

Сеңлесе ишек янында тыпырдап, тотлыга-тотлыга белгәнен әйтте:

— Югары оч егетләре! «Ата комсомол Дәйни кызларны аздырып йөри, никахсыз торырга котырта. Хәмдүнә янына куна кергән!..» диләр, монда киләләр! Тизрәк!

— Каян белдең?

— Койма ярыгыннан тыңлап тордым!..

Шунда ячейкадагы иптәшләрнең искәртүләре хәтергә килде. «Әһә! Менә ничек хур итмәкче булалар икән комсомол членнарын!»— дип уйлап алдым. Юк, без үзебезне алай мыскыл иттермәбез!

Мин нindидер бер чарасын эзләгән арада, Хәмдүнә мине сулыш эчендә тәрәзәдән ишегалдына төшерде.

— Йөгер! Ындыр артына элдерт тә чокыр буйлатып юкка чык! Кеше күзенә күренәсе булма! — дип кисәтте.

Бер уйлаганда янымда маузерың була торып шул биш-алты кулак токымыннан качып маташу егетлек тә түгел сыман, хурландыра да! Икенче яктан, Хәмдүнә кызганыч, аның абруена пычрак ташлатырга һич тә ярамый. «Егет белән тотканнар!»— дигән яманатын чыгарсалар, кыз баланың гомеренә китә торган хурлык!

Аннары әле бит шунда берочтан комсомол өстенә дә пычрак ташламакчы булалар. Юк, башы бозыклар! Анысы да барып чыкмас!

Мин ындыр артына чыгып әлеге иңкелгә төштем. Ләкин Хәмдүнә әйткәнчә «юкка чыкмадым», үзән буенча югары очтагы дус егетемә йөгердем. Аяк асты чокыр-чакыр, кычыткан баскан, абынам да сөртенәм, тагын торып йөгерәм.

Арт якларыннан атылып барып кердем дә дустымны печәнлектән тартып төшердем.

— Ал гармуныңны, әйдә урамга! — мин әйтәм.

Шиһап дустым, күзләрен угалап, йокылы-уяулы мыгырдап маташа:

— Ни җомга, ни шимбә... Бөтен авыл йокыга талган...

— Еракка китәм, урам әйләнеп авыл белән бер саубуллашасым килә...

— Нәрсә уйныйм? — ди Шиһап.— «Атма ла наганың...» ярыймы?

— Юк, андый елак мещан көе кирәкми. Читкә китәм дим бит, озакка китәм. Туган яклардан аерылышу, сагыну шикелләрәк, шундый юньләрәк берәр көй тап инде.



*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

Шиһап дустым тальянын ыңгыраштырып көй эзләгән арада сулыш кабу да бетте, тамакны да кыргалап алдым. Мәчет турысыннан гармун тартмыйча шыпырт кына уздык та, Чокыр Әхмиләргә җиткәч, гармунга кушылып җырлап җибәрдем:

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде каласыз.
Киткәннәрне онытмагыз,
Кош та онытмый баласын...

Йортларда тычкан күзе тикле дә ут күренми, чөнки керосинның бик кадерле чагы, халык шәфәкъ сүнү белән йокларга ята. Әмма күңелем белән сизеп барам, без буш урамга җырламыйбыз, тыңлаучылар күп. Җәйге төннең соры пәрдәсен бөркәнеп йокыга oeгандай шыпырт кына яткан караңгы йортлар безне һәммәсе дә бик яратып тыңлый. Ак келәтләрдә кызлар тыңлый, сугыштан кайтмаган ирләрен сагынып йоклый алмыйча интегүче яшь тол хатыннар тыңлый. Безнең җырлар карт-карчыкларның күңеленә дә җаннарын җылытып шифалы моң булып агыла.
Шиһап та, йокысыннан тәмам арынып күңел нечкәлекләрен кушып уйный башлады. Без анын белән озынрак көйгә күчтек.

Бакча артларымда салкын чишмә,
Иртәләрен торып юынам.
Газиз башкайларым, ай, сау булса,
Бер кайтырмын диеп юанам.
Болыннарда елкы көтүе,
Ай, авыр ла аерылып китүе...

Инде бая Хәмдүнә белән очрашкан йортка да ерак калмады. Салмак кына атлап урамның уртасыннан төшеп киләбез. Күз алдымда гел Хәмдүнә генә. Ул минем ни сәбәпле җырлап урам әйләнүемне дә белеп, дулкынланып тора, һәр җырымны йотып алырдай булып, йөрәк-бәгырьләре белән йотлыгып тыңлыйдыр. Хәзер инде мин дә кайнар мәхәббәтемне җырыма салып, ялкынлы тойгыларымны Хәмдүнәнең йөрәк дулкынына тоташтыргандай, аның берүзе өчен генә җырлый башладым.

Болын буйларында үрдәк атсаң,
Уң канаткайларын өздермә;
Дошман сүзләренә колак салып
Яшьләй сөйгәнеңне биздермә...

Тагын бераз баргач, чама белән Хәмдүнә җингәсе турындарак, төнге каравылчының шакылдавыгы тавыш биреп алды:
— Шакы-шокы, шакъ, шакы-шокы, шакъ!..
Нәрсәгәдер ачуланган кырыс, кискен тавыш биреп, кемнедер искәртә иде каравылчы. Ул да түгел, койма буеннан тавышсыз-тынсыз гына берничә кара шәүлә узып китте. Минутында ук күңелдә шик туды: Хәмдүнә сеңлесе әйткән теге Хаҗилар очыннан җанҗал чыгарырга килгән бәндәләр түгелме икән? Юньле кеше төн урталары якынлашып килгәндә шулай кача-поса нишләп йөрсен?
Озак та үтмәде, шакылдавыгы белән тавыш биреп төнге каравылчы үзе үк килеп чыкты. Бүген төнге каравылда үзебезнең урамның иң өлкән кешесе Гайни абзый икән. Очратуына шатлангандай, минем иңбашыма сугып алды.
— Әйтәм бит Дәйни җырлый дип! Сон, синең тавышны аермаска инде! Ә югары очныкылар әллә ниләр лыгырдыйлар!
Билгеле, мин берни дә белмим!..
— Нәрсә бар, Гайни абзый? Сиңа бәйләнәләрме әллә?! — дигән булам.
— Җанҗал чыгара яздылар бит әле!
— Төн уртасында ниткән җанҗал тагын ул? Кемнәр?

— Кем булсын, шул югары очлар ич! Җыен тегендиләр! Өере белән килеп ябырылдылар да Мәрфуга киленгә бәйләнәләр. «Синең ак өеңә Хәмдүнә комсомолны куна керткән. Дәйни кызларны аздырып йөри. Давай чыксын монда!»— дип акыралар. Мәрфуга килен әйтә: «Ниткән сүз ул? Кыранга килмәгәнне! Барыгыз, кереп карагыз. Тапмасагыз, бәбәкләрегез чәчрәп чыксын, язык башыгызга килеп кадалсын!»— ди. Акыруын акыралар да бит, ә кереп карарга йөрәк җитми. Кергәнче чыгарыңны уйла, диләр бит. Шулай тарткалашып торганда Дәйниебез авыл уртасында җырлап җибәрмәсенме! Синең җырлаганны ишетүе булды, Мәрфуга тегеләрне — табагач белән! Аның теләнә эләксәң, исән-аман ычкынырмын димә! «Аһ, сез, җыен дәргяһтан[1] сөрелгән бәндәләр, җыен әрәмтамак, хөрәсән ялкаулары! Гайбәт җыярга калдыгызмыни инде?! Эзегез булмасын бу тирәдә!»— ди бу. Чистый адәм көлкесе булып шыпырт кына таймасыннармы!

Рәхәтләнеп бер көлештек. Мин — шатлыктан, тегеләр — югары оч егетләреннән.

Гайни абзый үз юлы белән китте. Безгә дә бу тирәдә озак тоткарланырга ярамый иде. Төннең дә күзе-колагы бар, диләр бит.

Әмма болай гына китеп барырга аяк тартмый иде әле. Йөрәкләребез нindидер яшерен токлар белән тоташкандай бөтен барлыгым белән сизеп барам: Хәмдүнә читлектәге кош сыман, әле бер тәрәзәгә, әле икенчесенә атыла, ачык тәрәзә аша урамдагы һәр аяк тавышын, акрын әйтелгән һәр сүзне йотып алырдай булып тыңлый, ул җанын тынычландырырдай җылы сүз көтә иде. Мәрфуга җиңгиләр турысыннан узганда мин аңа шундыйны җырладым да:

> Мәскәү урамнары фанар, фанар,
> Фанарларга утны кем ягар?
> Җанкай белән кавышкан көннәрдә
> Дошман эчләрендә ут янар.

Хәмдүнәнең сабыйлардай көлә-елмая мендәрен кочаклап күз йомуын күргәндәй булдым да шуның белән тынып калдым. Шиһап та гармунын култык астына кыстырды. Үзен йокыдан уятып алып чыгу белән әлеге җәнҗал арасында нindидер бәйләнеш барын Шиһап сизенде булса кирәк. Кайтканда нидер сорарга теләгәндәй миңа ничә мәртәбә карап та алгалады. Ләкин төпченмәде.

— Я, күңелең булдымы инде?— дип кенә әйтте.

Чын күңелдән рәхмәтләр әйтеп, иптәшемнең кулын кыстым.

— Һи, шундый дусларың барында! Тагын бер ышандым, егет икәнсең! Туйда урының түр башында булыр!— дидем.

### III

Мәскәүдә безне көне-төне укыттылар. Россиянең төрле почмакларыннан җыелган йөзләп кеше идек без. Күбебез гражданнар сугышында катнашкан, я булмаса Чонда, Чекада эчке дошманнарга каршы көрәштә чыныккан төрле яшьтәге егетләр.

Яңа гына НЭП башланган айлар иде. Революция елларында ярыкка посып калган элекке сәүдәгәрләр, завод-фабрика хуҗаларының, шулар тирәсендә туенып яшәүче элекке спецлар, җыен чит элементның яңадан терелә башлаган ифрат четерекле айлар иде бу.

— Әһә! Большевикларның көймәсе комга терәлдеме? Терәлде!— дип куанышты алар.— Сатарга товар, ашарга икмәк, яндырырга керосин калмады. Бер нәрсә юк, шәп-шәрә! Большевиклар байлардан башка, элекке спецлардан башка бернәрсә дә майтара алмыйлар, хуҗалыкка

---

[1] Дәргяһтан сөрелгән — каһәрләнгән, кеше арасыннан куылган.

житәкчелек итә белмиләр. Безнең кулда хәзер тормышның тоткасы! Без тапсак була, без тапмасак — утыз икеңне шүрлеккә эләсең!.. Менә ничек кире кайта ул Микулай заманнары!..

Безне менә шул контр карашларның нигезсез икәнлеген тормышның үзендә расларга, большевикларның, революция ясый белгән шикелле үк, оста хуҗалык итәргә дә сәләтләре җитәчәген эшебез белән күрсәтергә өйрәттеләр. Яңача ничек хуҗалык итәргә, кооператив сәүдәсен ничек оештырырга? Завод-фабрика, трест, синдикат, картельләр нәрсә алар? Дөньяда дебет-кредит, сальдо кебек четерекле сүзләр дә бар икән. Төрле сыйныф дөньяга, тормышка төрлечә карый икән, һәркайсының үзләренә күрә фәлсәфәләре, тарихлары бар икән. Менә шулар һәм тагын бик күп нәрсәләр хакында безгә ак сакаллы профессорлар, наркомнар, зур оешмаларның җитәкчеләре лекцияләр укыдылар, семинарлар уздырдылар. Көне буена укыйбыз, кичләрен китапханәләрдә казынабыз. Тик ял көннәрендә киногa барып кайтырга гына бер-ике сәгать вакыт кала иде.

Хәмдүнә хатларында сабырсызлык торган саен көчәя барды. Соңга таба ул инде түземлекнең ахыр чигенә барып җитүен сиздерә башлады. Соңгы хатында хәтта: «Казанга кереп торма, туп-туры авылга кайт, нигә икәнен соңыннан белерсең»,— дигән юллар да бар иде. Бу хат эчкә шом салды. Күрәсең, атасы икенче кешегә кияүгә бирүне ашыктыра башлагандыр...

Беренче хатларында укырга керүе хакында язган булса да, соңгы хатларында ул турыда ләм-мим берни булмады. Монысы да сәеррәк иде.

Кайтканда Казанга кермичә генә узу мөмкин булмады. Мәскәүдән алып кайткан кәгазьләрем белән туп-туры наркомфинның коллегия утырышына килеп кердем. Кайсыдыр бүлекнең җитәкчесе — пенснэ кигән өлкән яшьтәге бер кеше — үзенең НЭП белән берничек тә килешә алмавын белдереп ята, үзенчә ныклы дәлилләр белән ышандырып сөйли иде.

— НЭП Россиядә капитализмга юл ача. Менә күрерсез, озакламыйча эре буржуазия, элекке байлар, сәүдәгәрләр, банкирлар баш калкытачак, авылны вак буржуазия стихиясе, кулаклар басып китәчәк. Болай булса, без революция казанышларын саклап кала алмыйбыз,— диде.

Җыелышны алып баручы кеше — нарком ярдәмчесе тегеннән:

— Бу сезнең соңгы сүзегезме?— дип сорады.

— Әйе, мин андый политиканы яклый алмыйм,— диде әлеге кеше.

Җитәкче мәсьәләне кыска тотты.

— Алай икән. Инде шуннан нәтиҗә: партия политикасының дөреслегенә ышанмаган кеше мондый авыр сыйнфый көрәш фронтында безгә юлдаш була алмый. Бигайбә. Безнең сафка яңа көчләр килә,— диде ул.

Шул утырышта мине әлеге бүлекнең башлыгы итеп билгеләделәр, коллегия члены итеп сайладылар, эшкә керешкәнче берничә көнгә эни янына кайтып килергә рөхсәт иттеләр.

Пристаньга төшкәндә Печән базары тирәсеннән узышлый мондагы үзгәрешләргә хәйран калдым. Бу нинди ярминкә?! Чат саен кибет, капка төбе саен кырык тартмачы. Бу тирә халкы сату-алуга шулкадәр хирыс икән, искитмәле! Күреп торасың, өсте-башы аламә-сәләмә, шулай да ул да «кылт-мылт» итә. Кибете, кырык тартмасы, юньле товары юк икән, чорт с ним! Әнә, капка астына урындыгын алып чыккан да шуның өстенә өч кәтүк машина җебе, Микулай заманыннан калган кызыл башлы шырпы, бер әчмуха такта чәй, бабасыннан калган өч эскәк тезеп куйган. Янәсе, ул да кешедән калышмый, ул да сәүдәгәр!..

Базар уртасындагы талчукта, шәт, мең сатучы кайныйдыр. Аларның инәренда, кулларында ни генә юк! Революция елларында конфискациядән яшереп калган кыйммәтле кызыл товар дисеңме, мамык шәлләр,

резина галошлар, өр-яңа чиккән читекләр, ефәк яулыклар, затлы туфлиләр, тагын әллә ниләр.

Ул да түгел, янында зур эшләпәсенә әллә нинди ялтыравыклы каурыйлар, чебен кәгазьләре тезеп куйган, иңенә, беләкләренә төрле төстәге тасмалар, челтәрләр аскан озын буйлы, кызыл борынлы кеше тамак төбе белән ниндидер сәер сүзләр такмаклап уза:

— Молтый пирес, сахарин, чәйни сода, нафталин...

Икенче яктарак аңа охшатып, бер кулына бизмән, икенче кулына кәрзин тоткан тагын берәү көйләп йөри:

— Кемгә өрек, кемгә хөрмә, кемгә әлү каклары!..

Печән базарының бер башында «обжорный» ачып җибәргәннәр. Урам уртасына тезелеп киткән бихисап өстәлләрдә керосинкалар янып тора, һәртөрле өйрәләр, токмачлар, сумсалар пешеп тора, самоварлар кайнап тора, алдына ак алъяпкыч япкан итләч тәнле түтиләр ул ризыкларны тәлинкәләргә сосып, кунакларны сыйлап тора. Урам ашханәсенең граммофоны бөтен базарны шаулата...

Урам кырыенда туктап мин боларга беравык гаҗәпләнеп, уйланып тордым. Шунысын да искәрдем: болары алыш-бирешнең күренеп торган өске ягы гына, ыбыр-чыбыр, вак-төяге генә иде. Болары әллә ни куркыныч түгел. Бу табыш колларының аллалары, нэпман дигән комсыз яңа токымның утаманнары, кыйммәтле сигаретлар суыргалап, кемнедер көтеп, бер-берсе белән колактан-колакка гына сөйләшкәләп, киңәшкәләп, читтәрәк, «Сарай» рестораны тирәсендәрәк әйләнгәлиләр. Бу шома әфәнделәрнең Мәскәүдә, Себердә, тагын әллә кайларда «үз кешеләре» бар, алар миллионнар белән эш итәләр. Кооперативларга дип җибәрелгән ситсы товарны, керосинны, сабыннарны, шикәрне бу чибәр кешеләрнең вагоны-вагоны белән «сулагай»га борып җибәрергә кодрәтләре җитә. Уен түгел, уйландыра иде бу. Мин әнә шуларны да истә тотарга тиеш идем.

Бактың исә шул ук яңалыклар мине авылда бик авырттырып, бөтенләй уйланмаган яктан китереп сугарга көтеп тора икән.

## IV

Менә шул ук урамнан, шул ук йортка унбер айдан соң яңадан барам. Минем өстә яшел френч белән зәңгәр галифе, аркылы-торкылы чалыштырган яңа портупей. Бөтенесенең күзе миндә. Кайберәүләр сугышта хәбәрсез югалган уллары түгелме икән дип өмет белән карыйдыр. Кайберәүләр минем узган ел гына куркыныч банданы тар-мар итүгә җитәкчелек итүемне дә онытмагандыр әле. Ә минем башта хәзер бөтенләй башка нәрсә, бүтән җыр...

Урамда кемнәр беләндер очраштым, күрештем. Миннән Мәскәү хәлләрен сораштылар. Уен түгел бит, унбер ай Мәскәүнең үзендә укып, бөтенесен үз күзе белән күреп кайткан егет! Мин аларга нидер сөйләдем. Әмма болар һәммәсе дә колак яныннан гына үтеп китте, мин җаным-тәнем белән Хәмдүнә янына ашыктым. Аның үзен генә түгел, хәтта усак яфраклары лепердәгәндәй йомшак, ягымлы тавышын, бераз иркәләнеп, көйләбрәк сөйләвен дә сагынган идем.

Әнинең һәммә ягын да алдан ук сөйләшеп, көйләп куюын белеп торсам да, Хәмдүнә җиңгәсенең йортына якынайган саен, йөрәгем ешрак тибә башлады. Каян беләсең бит! Чыгып китәр алдыннан гына Гасыйм абзый кызын келәтенә бикләп куйган булса? Көт тә тор, булыр ул дуамалдан! Аның кирелеген бөтен авыл белә. Алай булганда, ничек тә хәйлә корып, кызны урлап китәргә туры килер...

Шундый уйга килеп кенә торганда, күңелне аннан да хәвефлерәк икенче болыт килеп каплады. Әгәр кызыйны миннән биздергән булсалар? Мин югында өстемә нинди генә пычраклар өймәгәндер дисең дошманнар! Ул хәерче, аты юк, арбасы юк, аннан гайре барчасы юк, фәлән

дә фәсмәтән... Менә анысы кара кайгы булачак, бала чактан ук башланган яшьлек мәхәббәте янып-көеп кара кисәүгә әвереләчәк...

Әнә ул йорт, әнә ул урамга караган ак пәрдәле өч тәрәзә! Чаттан борылганнан бирле сихерләнгән сыман шул тылсымлы тәрәзәләрдән күземне ала алмыйм. Җаным түзми, тизрәк беләсем килә: Хәмдүнә жаный шундамы? Килгән булса, мине сөюе хак булса, бу минутларда аның да күзе тәрәзәдә булырга тиеш!

Әйе, шулай булып чыкты да! Чаттан борылып ун-унбиш адым атлавым булды, ак пәрдәнең бер чите бәләкәй генә күтәрелеп китте. Хәмдүнә, шул! Шатлыгымнан аз гына кычкырып җибәрмәдем. Килгән, мине көтә, мәңге минеке булырга дип килгән!

Хәмдүнә мине мөлдерәп торган унҗиде яшьлек матурлыгы белән тәрәзә янында каршы алды. Килеп керүемә кочагыма ташланырмы дисәм, юк, түзде! Күзләре җелт-җелт итте, иреннәре тетрәнеп-тетрәнеп куйды, кулларын кая куярга белмәде. Белеп, күреп торам, аңа яшьлек дәртен йөгәнләп торулар җиңел түгел! Шулай да үзен-үзе тыйды, горурлыгын җибәрмәде. Нәкъ Хәмдүнә үзе иде бу, нәкъ минем горур, тәкәббер Хәмдүнәм! Шушы гүзәллекнең сихеренә бирелеп, мин аңа омтылдым.

Әлеге йомшак, ягымлы тавышы белән, бәләкәй генә көйли төшеп:

— Һа, Мәскәүләр кайткан икән! Исәнме, Зәйни абый!— диде, битләре алсуланып китте. Ул минем кулларымны кысып, көлә-елмая, йөзем белән тәрәзәгә борды.

— Кая әле, күзем туйганчы рәхәтләнеп бер карыйм әле... Тфүтфү, тагын да матурланыбрак, мәскәүләнеп, шомарыбрак кайткансың димме шунда!

— Булгандыр инде!— дигән булам.— Мәскәү хәтле Мәскәү безнеңише авыл малаен бәләкәй генә шомартмыйча калмагандыр...

Мин юк арада Хәмдүнә тагын да түгәрәкләнә, матурлана төшкән. Аның дәртле яшьлеге тәмам өлгереп, тулып тора, күзләреннән, йөзеннән чиксез мәхәббәт ялкыны бөркелә. Мин түзә алмадым, аны күкрәгемә кыстым. Хәмдүнә миңа кыз чагының иң соңгы көненә кадәр күз карасыдай саклап килгән бөтен яшьлек назы белән күкрәгемә сыенды. Ак өйдә бүтән беркем булмаса да, тавышы белән түгел, фәкать сулышы белән йөрәк түреннән чыккан кайнар хисләрен пышылдарга тотынды:

— Шундый сагындым, җаным, шундый сагындым, күзләремне йокы алмыйча таңнар аттырдым, төшләремдә гел синең белән саташтым. Инде беттем, түзә алмыйм, үләм инде, үләм, үләм дигәндә генә, чак кына кайтып җиттең!..

Кочагыма сыенган шушы тиңсез бәхетемне кемдер тартып алмагае дигәндәй, аны йөрәгемә кыса бирдем. Бу бәхет хәзердән алып бөтен гомерем буена минеке булачак, моннан соң сәгать саен, минут саен шушы сихерле мәхәббәт тавышына рәхәтләнәчәкмен. Кайнар хисләремне белдерергә бүтән бер сүз дә таба алмыйча: «Хәмдүнәм, кадерлем!»— дип кенә пышылдадым.

Бала чактан ук яратышып йөрсәк тә, бергә буласыбыз көн кебек ачык булса да, моңарчы безнең үбешү түгел, юньле-рәтле кочакланышканыбыз да юк иде шикелле. Ягымлы бер күз карашы да, бер-беребезнең кулыбыздан тотып янәшә утыру да бик җитә, ул да безнең өчен зур бәхет иде. Хәзер менә якынаер чаклар җиткән иде, күрәсең. Хәмдүнә миңа песи баласыдай сыйпалды, беркайчан да күреп туймастай булып озак-озак күзләремә текәлеп торды.

Бер борылганда чаршау кырыеннан кече яктагы сандык өстендә зур төенчек күземә чалынды. Хәмдүнә әйберләре иде ул. Димәк, нәкъ әни әйткәнчә, һәммәсен алдан уйлашып куйганнар. Хәмдүнә миңа «ябышып чыгарга» дип килгән, ул өенә кире кайтмаячак.

Сөйләшеп сүзебез бетәчәк түгел иде, ә вакыт дигәнең су шикелле агып кына тора. Әнә, Мәрфуга түтәйнең ак битле карт сәгате унберенче яртыга сукты. Төштән соң авыл советына барып, никахыбызны теркәп,

законлаштырып кайтасы да бар бит әле. Һәммәсенә нибары ярты көн генә калып бара. Кыз бала үзе сүз башламас, җайлап кына Хәмдүнә белән киңәшә башларга вакыт иде.

Сәгатькә ишарә итеп:

— Сәгатьләр келт-келт итәдер, уникеләр җитәдер,— дидем.

Уникедә азан әйтеләчәген искәртүемне Хәмдүнә, рәхмәт төшкере, бер сүздән аңлады. Дога сүзләрен әйткәндәй шыпыртлап:

— Хәерге белән,— диде.

— Исәп шулай инде, Хәмдүнәкәй,— дидем мин,— син инде күңеленә авыр ала күрмә, бүген язылышсак, миңа берсекөнгә үк китәргә туры килер. Мине өч кенә көнгә җибәрделәр...

— Ә мин?— диде Хәмдүнә.

— Нишләмәк кирәк, сиңа хәзергә әни янында калып торырга туры килер. Үзең беләсең, урак өсте дә җитеп килә. Уракны әни карчык өстенә ташлап китү ярамас. Аннары...

Хәмдүнә мин әйткәнне тыңлап та бетермәстән, иңбашыма кулларын салып, ялынырга тотынды.

— Зәйни җаным, алып кит мине дә үзең белән, ә? Минем синнән каласым килми! Ә?! Зәйни дим?! Минем калада торасым килә!

Үзенчә, Хәмдүнә сүзе дә нигезсез үк түгел иде. Шул хәтле сагынышып кавышканнан соң бер-ике көннән үк аерым яши башлау беребезгә дә җиңел буласы түгел. Шулай да урак өстендә әнине ялгыз калдыруга мин берничек тә риза була алмый идем.

— Уйлап кара әле, Хәмдүнәкәй! Карап торган ике имана арыш җире инде ул. Мин аны әни карчык өстенә калдырып китә алмыйм, Хәмдүнәкәй, рәхимсезлек була бу! Ә сиңа күп булса, бер атналык эш ул. Урак бетү белән кайтып алырмын! — дидем.

Һәммә ягын алдан уйлап куйганмы, ничекме, Хәмдүнәнең моңа җавабы әзер булып чыкты:

— Нигә шуның аркасында гына авылда калырга? Вакыты җиткәч күз күрер. Уракны әти кайгыртыр.

— Аларның да урак урыр чаклары узган бит инде.

Хәмдүнә уйлап та тормастан:

— Нигә үзләре урып маташсыннар? Сезнекен дә, үзебезнекен дә әти яллап кына урдырыр! Аңа чүп тә түгел ул!— диде.

Хәмдүнәнең әни янында калмас өчен төрле сылтаулар табып торуы миңа ошамый башлады. Аннары... яллап урдырулар. Кул алмаш уру, бер-беренә булышлык итү, өмә белән урдыру бар. Актык чиккә җитмәгәндә, бездә игенне яллап урдырмыйлар.

Хәмдүнәнең элек сөйләшүе дә ягымлырак, теле дә йомшаграк иде шикелле, каршы әйтү гадәте дә юк иде сыман...

Күңелем нидер сизенеп, Хәмдүнәгә сыныйрак карадым. Килә-килүемә мәхәббәт нурыннан күзем чагылып, өстен-башын бөтенләй күрмәгәнмен икән. Хәмдүнә баштанаяк затлы ефәккә төренгән... Нindидер ялтыравыклар да күп күренә... Ярар, кияүгә чыкканда шулай кирәктер...

Менә сиңа! Казанда минем хатын белән яшәрлек фатирым да юк бит әле. Кая алып барыйм мин аны?

Үпкәләтмәскә тырышып кына Хәмдүнәгә шуны төшендерәсем килде.

— Син авылда бик иркен яшәргә гадәтләнгән кызый. Хәзер алып барсам, сиңа кысан бүлмәдә иза чигәргә туры киләчәк. Әллә беразга сабыр итәсеңме? — дидем.

Хәмдүнәнең моңа да исе китмәде.

— Ә син ул ягына баш ватма! Әйтик кенә, әти безгә менә дигән я фатир, я йорт алып бирәчәк!

Бу мине бик гаҗәпләндерде. Менә сиңа мә! Шундый зур урында эшләп тә, мин дә фатирны ансат кына табуыма ышанмыйм, ә бер авыл агае... Икенче ягы белән минем хуҗалык эшләрендә булдыксызлыгыма кинaя дә иде бу.

— Ни сөйлисең? Гасыйм абзый алып бирәме? Казандамы? — дидем.

Мондый вак нәрсәләр турында баш ватып торасы килмәгәндәй, Хәмдүнә кулын кына селтәде.

— Һи, белмисең әле син! Безнең әтинең хәзер кулы озын, әллә кайларга тикле сузыла. Әйтәм бит, я йорт сатып ала эти, я юньле фатир табып бирә!

Мин телсез калдым. Менә сиңа мә! Каян килгән авыл агаена Казанда йорт сатып алырлык зур акча? Уракны да яллап кына урдырмакчы! Башыма шомлы уйлар кереп тулды. Гасыйм бозык юлга басып, кооперативны имә башлаганмы әллә? Сельпога кайткан товарларны биш бәясенә спекулянтларга сатып ятамы? Башкача каян килсен аңа андый зур сума?!

Күңелем сизенә: нидер бар, ниндидер бозыклык, гаделсезлек эшләнеп ята, ул бозыклык безнең ике арадагы керсез саф мәхәббәткә дә яный башлаган кебек иде инде.

V

Шушы шомлы сорауларга җавап таба алмыйча азапланып утырганда өй алдында «Эһе-эһем» дип тамак кырдылар. Ишектән йортның хуҗабикәсе Мәрфуга түтәй үзе килеп керде. Өсте-башы гел бәйрәмчә, аягында чигүле читек, башында җете ак батист яулык. Шыгыр-шыгыр басып шаян елмаеп миңа ике кулын сузды.

— Кая әле мин әйтәм, Мәскәү егетен мин дә күреп калыйм. Нигә шул тиклеләр сагындырды икән ул? Безнең Миндәлә ягыннан искән җилләр күңеленә сагыну хәбәрләре салмадымы икәнни?.. Исәнме, саулыкмы, энем-җаным?! Эшләрең уң булдымы, бик матур гына йөреп кайттыңмы?

— Ярыйсы гына, Мәрфуга түтәй.

Өс-башыма күз салды да башын селкеп куйды.

— Салдат дисәм, хәзер алай әйтмиләр бугай? Бик тә салдатка охшагансың.

— Вакыты белән солдат та булырга туры килгәли, Мәрфуга түтәй, дөнья бит бу! — дидем.

Мин әле ул вакыттагы гадәт буенча зәңгәр галифе белән яшел френчны, күн итекне салмаган идем.

Хуҗабикә әнинең хәлен сорашты, сөйләнә-сөйләнә түргә узып чаршау читен тартып куйган булды, ишек янындагы шкафтан чынаяклар тартып алды.

— Менә бит заманалар! — диде ул. — Шәйхи абыегыз сугышка чыгып киткәндә, сез бот буе бала гына идегез бит әле! Менә хәзер, тефүтефү, шөкер, күз генә тимәсен, кызарып пешкән җиләктәй чагыгыз!

Хәмдүнә миңа карап кыюсыз гына елмаеп куйды. Мәрфуга түтәй, күрәсең, ялгызлыктан туйгандыр, аның сөйләшәсе килә иде.

— Сезгә карыйм да, үземнең яшь чакларымны искә алам. Һай, вәйраннар булдыра минем яшьлегем! Өйләнешеп өч атна гына бергә торып калдык, шуннан бирле менә гел тол, тол! Бу сезнең иң бәхетле чорыгыз, балакайлар, белегез кадерләрен! Гөрләшегез, киңәшегез! Аннары, менә азан әйткәнче, бер чәйләп алыйк. Шул сылтау белән мин дә, тол хатын икәнемне онытып, сезнең янда беразга гына булса да җанымны җылытып калырмын.

Ул шкафтан, аш тәлинкәләрен түбәләмә тутырып, шәфәкъ нурыдай алсу-саргылт әфлисуннар, һәйбәт хәлвә, затлы кәгазьләргә төрелгән кыйммәтле конфетлар күтәреп килде. Хәмдүнә кинәт нигәдер уңайсызланып кашларын җыерды. Бу ризыкларны миңа күрсәтергә уңайсызлангандай, өстәлгә арты белән килеп басты. Әмма Мәрфуга түтәй моны ошатмады.

— Бәй, нигә яшерәсең? Урланган әйбер түгел лә! Туй алдыннан дип анаң үзе китерде. Үз кибетегездә булгач күрмәгән, ашамаган ризыкларың түгелдер...

«Үз кибетегез!» диме? Мин, үз колагыма үзем ышанмыйча, тораташ булып каттым. Сельпо рәисенең, шундый аңлы кешенең үз кибетен ачып нәпманга әверелүенә ничек ышанырга? Юк, юк, булмас! Ялгыштыр, бутыйлардыр. Чәй янына утыргач та, шул газаплы сорау башымнан чыкмады. Ахыр чиктә сорашмыйча түзә алмадым.

— «Үз кибетегез» дигәннән... Ялгыш ишеттемме соң? Сельпо кибетен әйтәсезме әллә? — дидем.

Мәрфуга түтәй миңа карап көлеп үк җибәрде.

— Һи, син тагын! Мәскәүләрдә йөреп авыл хәлләрен бөтенләй үк онытып бетергәнсең икән! И, сельпога тагын мондый байлар ризыгы! Каян килсен ул безгә? Әле крачин белән сабынны, шырпы белән тозны да урам буенча чиратлар торып, ызгыша-талаша, әллә нидә бер генә алабыз.

Нигә белмим, ди, мин авылдагы хәлләрне? Бик беләм! Халык хуҗалыгының ул еллардагы хәлен Мәскәүдә безгә җентекләп аңлаттылар, үзем дә күреп торам. Сугыш артыннан сугыш, алар өстенә Идел буенда ачлык белән тиф. Халык хуҗалыгы таркалган, завод-фабрикаларның күбесе эшләми. Авыл керосин урынына чыра яндыра, авылга тозны потлап кына, шырпыны тартмалап, ситсыны исемлек буенча гына җибәргән еллар.

Белгәнгә күрә бу нәрсәләр ят булып күренде дә.

Хәмдүнә һаман да шат күңелле, уенчак иде әле. Ул, шикләнерлек берни дә юклыгын сиздерәсе килеп, иһаһайлап көлеп җибәрде:

— Әй, олы хәл итеп телгә алган буласыз шуны! Безнең эти, ичмасам, бер дә алай нечкәләп маташмый. «Кызыл гаскәр» бармы? Бар! «Кызыл сукачы», «Кызыл командир» дип йөриләрме? Йөриләр! Шулай булгач нәмә дип «Кызыл купис» та булмасын икән? — ди ул.

Хәмдүнәнең комсомолка була торып шуны да аера белмәве, житмәсә, авызын ерып утыруы миңа ошамады. «Моның уен эш түгеллеген аңласаң, көлмәс идең, кычкырып елар идең!»— дип уйлап алдым.

Шулай да минем аңа каты бәрелергә телем бармый иде әле. Кызып китүдән үземне тыя төшеп:

— Алар икесе капма-каршы ике нәрсә бит! Кызыл командир белән куписны янәшә куеп буламыни? — дидем.

Хәмдүнә кына яккан кызыл тырнакларын караштырган булды, ниндидер гаебе бар сыман кыенсынып кына миңа да күз салгалады.

— Мин бит эти сүзен әйтәм. Ул шулай ди: «Нигә буржуйлар белән элекке купислар гына балда-майда йөзәргә тиеш әле? Сәвит хөкүмәте безнең өше прастуй халыкны да шулар шикелле үк баету өчен чыгарды ул «нип» дигән законны»,— ди.

Тукта әле? Ни булган Хәмдүнәгә? Нәрсә сөйләнә бу кызый? Комсомолка сүземени бу?! Бу бит дошманнар фикере!

Мин аңа гаҗәпләнеп карап тордым. Кием-салымында да ниндидер ялтыравыклар күбәйгән... Нәрсәдер булган. Мин Мәскәүдә укыган арада Хәмдүнә бик нык үзгәргән. Кием-салымы гына үзгәреп калса әле...

Мәрфуга түтәй Хәмдүнә әйткәнне көтә, анысының үз теле белән әйтеп бирергә йөрәге житми иде ахрысы. Бу хәл мине борчуга салды.

— Нәрсәнедер бутамыйсызмы? Гасыйм абзый сельподагы хезмәтен шаяртып «кызыл купис» дип йөртәме әллә? — дидем.

Хәмдүнә түбән карап сүзсез генә башын чайкады. Мәрфуга түтәй түзмәде, Хәмдүнәгә шелтәле караш ташлады да аның өчен үзе әйтеп салды.

— Ярар, качышлы уйнама инде, андыйны итәк астына яшереп калып булмый! Матур киенергә, тәмле ашарга яраттыңмы? Дөресен әйтергә дә йөрәгең житсен! Чыны, энем-җаным, шул: Гасыйм абый сөйләнеп кенә калмады, үз кибетен ачты. Бакали дигәнне. Үз келәтендә.

Мин телсез калдым. Зиһеннәрем чуалып китте. Башка сыймаслык яман хәбәр иде бу. Моның ике арадагы мәхәббәткә куркыныч янавы җаныма килеп кергәч, үземне кая куярга белми башладым. Башымда береннән-бере четереклерәк мең сорау туды. Ни сәбәпле Гасыйм шундый паразитлар юлына баскан? Комсомолка була торып нигә Хәмдүнә атасына нэпман булырга юл куйган?

Мин үземне Хәмдүнә урынына куеп карадым. Әгәр дә атам исән булып, ул шулай кибет ачарга теләсә, мин аңа ирек бирер идемме? Һич юк! Якын да җибәрмәс идем, тешем-тырнагым белән каршы төшәр идем. Көчем җитмәсә, йортны ташлап китәр идем. Ә Хәмдүнә нишләгән? Мин аңа сорау бирмичә булдыра алмадым?

— Син үзеңнең комсомолка икәнлегеңне онытмадыңмы?

Ул башын боргалады, үпкәләргә җыенган иркә баладай иреннәрен бөрештерде.

— Ә нишләгән? Кибет ачарга ярамыймыни? Сату итәргә сәвит үзе ирек куйды түгелме соң? — диде.

Менә, ишетмәсәң-ишет! Комсомолка дигәнем оппортунист теле белән сөйләшә башлаган түгелме?

Башыма төрле өметсез уйлар, шөбһәләр кереп тулды. Моңа кадәр җыен чит элементларга, кулакларга, контрларга каршы җаныбызны аямыйча көрәшеп йөрүләребез җилгә очкан кебек тоелды. Ничек була инде бу?! Әле патша заманыннан калган соры кортлардан арынып җитмәгән, менә сиңа мә! Аларның яңалары борын төртеп чыга! Кайда диген? Күз алдыбызда! Үзем димләп комсомолга керткән, иң ышанычлысы дип ианнып йөргән, җаным сөйгән комсомолка йортында! Тукта әле, нәрсә бу? Монда дошман кулы уйный түгелме? Ул сездән көчлерәк булып чыкты түгелме? Сөйгәнемә сәерсенеп карап алдым. Мин Мәскәүгә киткәнче спектакльләр уйнаган, кичәләрдә ут чәчрәтеп шигырьләр укыган кайнар йөрәкле комсомолкамы соң бу? Нишләп шулай үзгәргән, ни сәбәпле? Шуңа аптырап тагын сорашып карадым:

— Ни бит инде, аңлый торгансың, шундый хәрәм табыш артыннан куа торгач, Гасыйм абзый иртәме-соңмы соры кортлар, чит элементлар ягында булып чыгачак бит. Синең дә яхшы исемең пычрана!

Хәмдүнә миңа беренче мәртәбә төксе караш ташлады, мин әйткәнне кырт кисеп кенә кире алып ыргытты:

— Безнең әти беркайчан да соры корт булмас! «Кызыл купис»мын ди ул, файдага сатмый, ипилек-тозлык кына эшли...

Комсомол секретаре чагым булса, мин аннан туп-туры сорар идем: «Алайса Казанда безгә сатып аласы йортка әллә ничә меңне атаң каян алып түли? Син тагып килгән бу алтын кисәкләре нинди акчага алынган?..»

Ләкин мин бит әле кияү буласы кеше идем, алай каты бәреләсем килмәде. Бәлки, эшләр алай ук тирәнгә китмәгәндер әле? Шул хакта уйлаганда аңлашылмый калган тагын бер нәрсә исемә төште.

— Мин киткәндә син бик дәртләнеп укырга кермәкче булып калган идең. Хатларыңда нигәдер ул турыда бер сүз дә булмады,— дидем.

Хәмдүнә уңайсызланып читкә карады:

— Мин бит анда аз гына укып калдым.

— Нишләп алай?

— Әйтергә дә уңайсыз инде, монда мин үзем дә гаепле. Бер-ике ай укыгач ук, үземә булышырга кирәк дип, әти өйгә алып кайтты...

Алай... Уйландырырлык иде бу хәлләр. Мин аннан тагын белешкәләп карадым:

— Атаңның кибет ачуын нигәдер миннән дә яшергәнсең. Бу хакта язмадың бит!

Хәмдүнә кыенсынып башын иде. Ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Курыктым...— диде.
— Нәрсәдән?
— Кибетче кызы икәнемне ишеткәч, миннән бизәрсең, яратмый башларсың дип.
Бу беркатлы оланны кочагыма аласым, тынычландырасым килде. Ярата бит ул мине, өзелеп ярата!.. Ләкин нәрсәдер мине җибәрми, нидер сөйгәнемә кулымны сузарга ирек бирмичә тоткарлап тора иде... Нәрсә соң әле ул? Әйе, әтисенең нэпманга әверелүен яшереп, коммунистка кияүгә чыгарга җыену — алдашу бит ул, ике арадагы саф яшьлек мәхәббәтенә хыянәт итү!
Икенче яктан... беренче мәхәббәтне саклап калу хакына әллә ул хыянәтне гафу итәргә дә ярыймы икән? Бизмәннең әле бер ягы тарта, әле икенче ягы... Мин нишләргә белмичә арлы-бирле сугылам.
Нәрсәнедер онытып торам ахрысы, нәрсәнедер юксынуымны сизә башладым. Менә шул күңелем эзләгән нәрсә исемә килер дә һәммәсе дә ачыкланыр, мин бу газаптан котылырмын кебек тоела башлады. Нәрсә генә иде соң әле ул?!
Кинәт каяндыр, еррактан мине Мәскәүгә озатып калган элекке Хәмдүнә күренде. Аның өстендә кайтарма якалы, путалы чия төсле гади генә йон күлмәк, сары гәрәбәдән муенса, башында артка чөеп бәйләнгән кара бөрчекле ак яулык иде. Ул Хәмдүнә белән безнең серләребез бер, мин аны бала чагыннан ук күреп, белеп, яратып үстем, аңа җанымны ярып бирергә дә әзер идем... Менә кемне юксына бит күңел!..
Бәлки миңа моңарчы сихерләп йөрткән мәхәббәт тылсымыннан айнымаска, әнә шул элекке Хәмдүнәгә өйләнергә кирәктер? Монысын күрмәмешкә салышып?...
Ләкин алай да булмый иде. Чөнки теге Хәмдүнә кайдадыр күләгәдә калып тора, ә чыны, хәзергесе — менә ул, янымда гына. Аны күрмичә, аңа карамыйча мөмкин түгел, ә күтәрелеп карадыңмы, пыяладай ялтырап торган кыланчык ефәк күлмәгенең тешкә тия торган кыштырдавы ишетелә, чегән хатыннары кия торган яссы бөҗрәдәй зур алтын алкалары, кара алтын йөгерткән көмеш беләзекләре, алтын балдаклары күзгә бәрелә. Утыра лабаса ефәккә төренеп, алтыннары белән ялтырап, үзеннән-үзе бик тә канәгать булып!.. Җитмәсә мине үчекләгәндәй, күз алдыма Казанның Печән базары, андагы обжорка, шундый ук ялтыравыклы ефәккә төренгән, колагында да, түшенә дә мул итеп алтын кисәкләре аскан нэпманшалар килеп басты.
Иң матур хыялларым, якты өметләрем берьюлы җимерелеп төште. Һич көтелмәгән, истә-оста булмаган, гомер буена үкенечкә калачак аяныч хәл иде бу. Рәхимсез язмыш безнең белән явыз уен уйнаган, элекке Хәмдүнәне, беркатлы, хәйләсез, эшчән авыл кызын «сары иблис»нең тәти курчагына әверелдергән!..
Нишләргә иде соң миңа, башымны ташка орыргамы?
Минем бу хәлне бик авыр кичерүемне күреп Хәмдүнә дә хафага төште, каршыма тезләнеп еларга житешкән хәлдә сорашырга кереште.
— Абау, нигә бөгелеп төштең? Нигә сөмсерләрең коелды? Авырыйсыңмы әллә? — дип сорады.
Мин башымны гына чайкадым. Ни әйтә алыйм? Йомшак кына итеп әйткән сүзем дә аның йөрәгенә барып кадалачак иде.
Миннән бер сүз дә чыкмагач, Хәмдүнә ялынып күзләремә текәлде.
— Зәйни абый, җаным, азаплама, әйт инде бер сүз!
Турысын әйтеп бирергә дип башымны күтәрсәм, күзләребез очрашты да алдымда яңадан элекке Хәмдүнә пәйда булды, тагын әйтергә телем бармый башлады.
— Начар безнең эшләр, Хәмдүнәкәй, бик начар!— дип кенә әйтә алдым.
Кызый беренче мәртәбә сискәнеп китте, каушавыннан иреннәре дерелдәп алды.

— Ходаем, нигә алай дисең? Авызыңнан җил алсын! Әстәгъфирулла, тефү-тефү диген!

— Догалар белән генә төзәтүдән узган инде,— дидем.

— Берни дә аңламыйм! Нәрсә булды соң әле? Минем турымда берәр гайбәт ишеттеңме әллә? Нахак ул, нахак!— дип өзгәләнде Хәмдүнә.

Гүя ни генә булса да миннән аерылмаска тырышкандай, Хәмдүнә кулларыма килеп ябышты.

— Ай аллам! Нишләдең син, ә?! Әллә сине пәри алмаштырдымы? Аңламыйм, башым түнде. Әллә югыйсә Мәскәүдә укып кайткачтыннан авыл кызы ошамый башладымы, мине тиң күрмисеңме?

Мин аның кулларын сыйпап тынычландырырга тырышып карадым.

— Юк ла инде, Хәмдүнәкәй. Синнән башкалар турында уйлап та караганым юк,— дидем.

Шуның белән ике арада сүз өзелде.

Кайчаннан бирле зарыгып, түземсезләнеп көтеп алган шатлыклы бәйрәмебез өстенә ниндидер кара хәсрәт канат җәйде. Хәзер инде моны Хәмдүнә дә ачык сизә башлады. Ләкин хәзергә ул аны минем узгынчы бер кәефсезләнүем дип кенә аңлый, ул фаҗиганың безнең арага үтә алмаслык чокыр булып сузылуын башына китерми иде әле.

Табында күңелсез тынлык урнашты. Мәрфуга түтәй, моңа борчылып, ике арадагы салкынлыкны бетерү өчен тырышып-тырышып мине кыстарга тотынды.

— Әйдә, ашап кына утыр әле, кияү-җаным. Менә, хәлвәсеннән, әфлисуныннан авыз ит. Син хәзер безнең үз кешебез лә! Әйдә, кыстатма!

Һа! Үз кеше имеш, кияү имеш... Юк, бу сүзләр хәзер инде миңа төс түгел, алар миңа берничек тә бәйләнеше булмаган чит, ят сүзләр булып ишетелде.

Тамагымнан ризык үтмәс булды. Җиде-сигез елга сузылган сугыштан, тәмам җелекләрне суырган мәрхәмәтсез ачлыктан соң авыл халкының бик бетәшкән, ипигә дә туймаган чагы иде. Мин кайткач, әнинең токмач җәяргә оны җитмәгәнлектән, онны ашка болай гына туглавы, сахарин салып кишер чәе эчүебез күз алдыма килде.

Бу ризыкларга минем кулым бармый, юк, юк! Бүтәннәр ачлы-туклы торганда, нэпман кияве булып спекулянтлар тапкан ризык белән сыйланып утыру, минем өчен халыкка хыянәт итү сыман, намусым күтәрми торган вөҗдан газабы иде.

Мәрфуга түтәй безнең араларның бозыла баруын сизгәч: «Әйдә, үзегез яратышкан, үзегез килешерсез дә әле!» дигәндәй, икебезне генә калдырып аш өенә чыгып китте. Шуны гына көткәндәй, Хәмдүнә минем муеныма сарылды, элек әйткән кискен сүзләрен оныттырырга тырышып, төрлечә юмаларга тотынды:

— Зәйни абый, җаным, болай булмый бит! Ничәмә-ничә еллар яратышып йөргәннән соң хәзер генә бозылышсак, кеше ни әйтер! Уйлашыйк әле...

Шунда мин җан өшеткеч бер нәрсә сиздем: Хәмдүнәнең йомшак, кайнар беләкләре хәзер мине элекке шикелле рәхәтләндерми, алар миңа уңайсызлый гына иде. Безнең арадагы кайнар хисләргә җан биздергеч салкынлык иңгән, мин Хәмдүнәдән ераклаша башлаган идем. Шунда беренче мәртәбә гомерлек бәхетемнән аерылуымны, бик кадерле җан рәхәтеннән үземне-үзем мәхрүм итүемне аңладым. Иң ачы югалту газабы иде бу... Шулай да мин инде вөҗданым чыгарган хөкем карарына каршы килә алмый идем.

— Язмыш, Хәмдүнәкәй. Шулай килеп чыкты бит. Атаң харап итте безнең бәхетне, атаң! — дидем мин.

Хәмдүнә ачулы күзләре белән миңа текәлде.

— Ничек харап итте? Кибет ачыпмы? — диде.

— Әйе, нэпман булып, чит элементлар ягына авышып, синең дә исемеңне пычратып...

Хәмдүнә тыны кысыла язып:

— Бәй, нәмәкәй сөйләнәсең? Син бит этиГә өйләнмисең, миңа өйләнәсең! — диде.

Ул да түгел, Хәмдүнә сикереп торып биленә таянды да унҗиде яшьлек сылу гәүдәсе, нечкә биле, калку күкрәге белән каршымда бөтереләргә тотынды.

— Менә кара, күр! Миңа ни булган? Тагын ни кирәк?! Кемгә дип үстердем мин бу зифа буйларымны, калын толымнарымны, нечкә билләремне?! Сиңа дип, яшьлегемне сиңа гына бүләк итәрмен, сине генә бәхетле итәрмен дип! Әйт, кай җирем ошамый?

Инде дә матур иде Хәмдүнә! Күзеңне аерып алмаслык сылу, чибәр, бөтен барлыгыннан йөгәнсез яшьлек дәрте бәреп тора иде. Мин тетрәнеп киттем. Сикереп торып кочагыма алудан көч-хәл белән генә тыелып калдым.

— Ай, Хәмдүнә, ничек телең бара?! Беләсең бит!..

Кызый күзләрен мөлдерәтеп яңадан минем каршыма килеп тезләнде.

— Нишләттең син мине? Нигә шул тикле башымны әйләндердең? Өйләнәсе булмагач, нигә шулай сихерләдең?! Ходаем, ятсам — син, торсам — син! Сагынып акылларымнан шаша яздым бит! Син булмагач нигә кирәк миңа бу яшьлегем? Кемгә кирәк?! Нишләп ташлыйсың мине? Нигә яшьлегемне вәйран итәсең?!

Мин, күтәрелеп карарга кыюлыгым җитмичә, башымны идем. Ничек аз гына булса да юатырга? Нинди ягымлы сүзләр табарга, ничек аңлатырга?!

— Дөнья икегә аерылды бит, Хәмдүнәкәй! — дидем мин.— Без синең белән Сак-Сок шикелле тауның икебез ике ягында булып чыктык. Юлларыбыз киселде.

Кызый тагын да ярсыйрак төште.

— Шул каһәр төшкән кибет аркасындамы? — дип кычкырды. Аннары зәһәрләнеп кычкыра-кычкыра кулларындагы беләзекләрен, колагындагы алкаларын берәм-берәм йолкып алып идәнгә ыргытырга тотынды.

— Мондыйлардан котың чыккан икән, менә, менә, кадалып киткен нэпманнарың! Чүпкә әйләнсен алтыннары! Син булмагач, болар миңа ни пычагыма?

Әй, адәм баласының алдан күрергә көче җитмәгән ышанычсыз, мәкерле язмыш! Синең әледән-әле безнең башка аударып торган явыз шаяруларыңны да шулай ансат кына йолкып алып читкә ыргытып булсачы!

Хәмдүнә моны ярсып, шундый каһәрләнеп эшләде, шунда беренче мәртәбә күңелемә шик төште. Бәлки мин ялгыша торганмын? Бәлки бала чактан ук башланып киткән бу беренче мәхәббәтнең кадерен белергә кирәктер, аны әрәм итмәскәдер? Бәлки Хәмдүнә бөтенләй үк бозылып та бетмәгәндер әле? Өйләнергә дә нэпманчылык кыланышларын башыннан куып чагарырга, укытырга, үзебезчә тәрбияләргә кирәктер?

Минем инде күңелем йомшый ук башлаган иде, Хәмдүнә үзе үк мине яңадан айнытып җибәрде.

— Белдем инде, сиздем, син мине яратмагансың, алдашып кына йөргәнсең! Син революцияң белән әниеңне генә яратасың!..

Бу сүзләре минем җан җиремә килеп бәрелде. Минем иң изге тойгыларымны мыскыл итү иде бу! Мин урынымнан сикереп тордым.

— Ничек телең бара?! Ул мине тудырган, тәрбияләп үстергән анам бит, иң газиз кешем! Аннары...

Хәмдүнә каршыма басып күкрәгенә төртеп күрсәтте.

— Ә мин кем? Мин аннан да газизрәк түгелмени?

— Әни әни инде ул, аны беркем белән дә тиңләп булмый! Ана бер генә!

— Менә шул-шул! Мин икенче сорт, әйеме? Әгәр син мине бәләкәй генә яратсаң, үзең белән калага алып китәр идең. Шул кортка көен көй-

ләп, чабаталар киеп урак урырга калдырмас идең! Шундый зур нәчәнник була торып!..

Юк, ялгыш күрмәдем бугай, «шул кортка» дигәндә Хәмдүнәнең ирен почмакларында моңарчы беркайчан да күрмәгән явызлык, көнчелек бизәкләре кабынып алды. Бу минем башыма китереп суккандай булды. Өйләнешкәч, минем анам аның да иң якын кешесе, кадерле әнкәсе булырга тиеш иде бит! Булачак киленнең хәзер үк иреннәрен бөрештереп «шул кортка» дип кимсетеп әйтүе минем йөрәгемә барып тиде. Пуляны суырып алсаң да тәндә эзе кала. Әнә шул пуля шикелле иде бу явыз караш!

Житте, бетте! Кырыеннан ташырлык булып мөлдерәп торган түземлек касәсенә иң соңгы тамчы булды бу. Ягымлы, йомшак телле, күркәм холыклы элекке Хәмдүнә үлде, юкка чыкты. Аның урынына тормышның татлы ширбәтен генә суырып яшәргә өйрәнеп килүче усал телле, көнче мещанка калкып чыкты.

Аерылышу минутлары якынаюын хәзер инде икебез дә сизәбез. Ләкин күңелләр моңа риза түгел, яшь йөрәкләр әле һаман да берсенә-берсе омтыла, аерылуга бөтен көче белән каршы тора иде.

Шунда мәдрәсәдә укыган елларымда хәтергә сеңеп калган китап сүзе исемә төште: «Әгәр дустың дошман ягына авыша икән, ул дустыңны шунда ук оныт»,— диелгән иде анда. Әйтүе ансат та бит...

Беренче мәхәббәтемнең шундый һәлакәткә дучар булуына бәгырьләрем көеп утырганда, никах мәҗлесенә барырга дип киенеп-ясанып Мәрфуга түтәй килеп керде.

— Я, сезнең хәлләр кай тирәдә? Азан әйтте! — диде.

Кемнеңдер китереп сугуын көткәндәй, Хәмдүнәнең бөтен гәүдәсе бөрешеп килде, мөлдерәгән күзләре миңа текәлде.

Йөрәгем җылый, телем көч-хәл белән генә әйләнә. Шулай да беренче мәхәббәтемә соңгы хөкемне мин үзем чыгарырга тиеш идем.

— Соң инде, Мәрфуга түтәй. Безнең араны хәзер бернинди азан да төзәтә алмый,— дидем.

Хәмдүнә сискәнеп китте. Аның бит урталарындагы алсу матурлыгы юкка чыкты, күзләрендәге мәхәббәт нурлары сүнде. Ул беравык күзләрен йомып хәлсезләнеп торды да акрын гына килеп кулларын иңбашыма салды, күкрәгемә сыенып алды.

— Менә Таһир белән Зөһрә язмышы... безне дә эзләп тапты. Күрешә алмасак, бәхил бул,— диде.

Хәмдүнәнең иреннәре тетрәнеп китүе, яшьле күзләрендәге үпкә, рәнҗү мине әллә нишләтеп җибәрде. Язмышның безгә рәхимсез булуын, яшьлек мәхәббәтебез намена гафу итүен үтенмәкче, тагын ниләрдер әйтмәкче булып аңа таба омтылдым. Ләкин ишек минем борын төбемдә генә шап итеп ябылды. Хәер, мәхәббәт үзенең капма-каршы тискәре сыйфатына — нәфрәткә әверелә башлаган минутлар иде бу. Мин аның күңелен берничек тә йомшата алмаячак идем инде.

Чыгып барганда лапас астындагы бүкәнгә чапкан балтага күзем төште. Безнең авылның бер кешесе, урманда бармагын елан чаккач, секунд та уйлап тормастан шул бармагын балта белән чабып өзгән иде. Мине дә язмыш чагып алды бит, житмәсә, тәнемнең иң газиз әгъзасын, йөрәгемне чакты. Эчемдә кайнаган утка түзә алмыйча мин дә бармагымны бүкәнгә куйдым. Тик шул чак иптәшләрем белән һич куркусыз бик хәтәр штык атакаларына баруым, әле күптән түгел генә төрле контрларга, бандаларга каршы сугышып йөрүем күз алдыма килде. Балтаны ачу белән читкә ыргыттым. Ир-егет гамәле түгел иде бу!

## VII

Өйгә ничек кайтуымны ачык кына хәтерләмим. Исерек кеше сыман аңкы-миңке килеп булса да, ничектер кайтканмын. Капкадан керүемә әни тавышына аңыма килдем. Ул коты чыгып:

— Нишләден? Бу ни хәл? Кыйнап кайтардылармы әллә? — диде.
Мин башымны гына чайкадым.
Ул ниндидер көтелмәгән хәл килеп чыгуын сизенеп, капкага карады, борчыла башлады.
— Хәмдүнәң кая? — диде.
Мин кулымны селтәдем.
— Килмәде...
— Ник килмәде? Ничек килмәде? Сөйләшенгән бит!
— Җиңгәсендә калды...— дидем мин.
Әни, өстемә очып кунардай булып җилтерәп, каршыма килеп басты.
— Тукта әле, син нәрсә лыгырдыйсың? Тиле бәрән орлыгы ашамагансың ич!
— Ничек булган, шуны әйтәм. Килми ул, килми!
— Ай алла! Ничек килмәсен инде? Шулай сөйләштек ләбаса! Бәлешләрем, ашларым да өлгерде, менә хәзрәт тә килеп җитәр, туганнар да җыелыр. Никах укытабыз бит, уен түгел, ишетәсеңме, никах, никах!
Мин анам каршына килеп баш идем.
— Әни! Син мине теләсәң нишләт. Тик мин Хәмдүнәгә өйләнә алмыйм. Булмый...
Әни шаккатып беравыкка тынсыз калды, күлмәк җиңен бер сызганды, тагын төшерде. Ниһаять, тыны кысылып, сүзләрен бүлә-бүлә, ачуыннан ярсып, миннән җавап алырга кереште:
— Ә? Нәрсә?! Ул ниткән сүз? Ничек булмый? Шунча еллар яратышып йөргәннән соң ничек бүген генә ярамас булды әле ул, ә?!

Мин аңа аңлатырга тотындым.
— Ай, әни, ялгышасың! Син яраткан элекке күндәм Хәмдүнә юк ул хәзер. Ул сиңа килен булырга ярамый! Ярамый! Аңлыйсыңмы?
Әни минем сүземне кырт кисте:
— Юк, тыңламыйм да, аңламыйм да, ичмасам колагыма да керми! Өйрәтмә мине, кемнең нинди килен буласын мин үзем беләм! Бар булгач, бар! Алып кайт! Хәмдүнәсез күземә дә күренәсе булма!

Нишләргә иде соң миңа?! Хәмдүнәнең аны чүпкә дә санамавын, әле килен булып төшкәнче үк «шул кортка» дип кимсетеп сөйләвен әйтергә телем бармый, бу аның йөрәгенә яра булып төшәр иде.
— Әни, зинһар, көчләмә мине, мин кибетче кызына ялынучы түгел! Булмый! — дидем.
Әни, терсәкләрен тырпайтып ишек алдында арлы-бирле ярсып йөрде дә, каяндыр таяк табып, мине кыйнарга тотынды. Үзе җылый, үзе тирги-тирги минем аркамны дөмбәсли:
— Менә сиңа, юньсез малай, менә, менә! Ходаем, нинди уңган киленне кулдан ычкындырдың! Ир-ат акылы кайчан керер икән сиңа?! Юньсез!..
Әйтәсе дә юк, миңа бик нык эләкте. Әни мине кулларының хәле беткәнче, ачуы басылганчы кыйнады.
Сугышларда булып кайткан тап-таза егетнең орчык тикле генә бер карчыктан кыйнатып торуы бер караганда сәеррәк тә күренергә мөмкин. Әмма минем газиз анам иде бит ул. Әни кешенең үз баласын акылга утыртыр өчен төрле чара кулланып каравы мөмкин түгелмени?
Шуның өстенә, мин үземне бөтенләй үк гаепсез дә санамый идем. Бала чактан ук башланып киткән, чык тамчысыдай саф яшьлек мәхәббәтен, кешелекнең иң мокатдәс бу рухи байлыгын бер селтәнү белән харап итеп ташлау ничек җәзасыз калсын?! Әле ул гынамы? Ата-ана йортыннан кияүгә чыгарга дип җыенып киткән кыз баланың төенчеген күтәреп кире кайту хурлыгына да бит мин гаепле!..
Кирәк иде миңа андый җәза, кирәк иде!
Кыйнап арганнан соң, әни сулышы кабудан уфылдап, билләрен тотып, баскычка барып утырды да күз яше белән җылады. Бу хәлне әнинең

минем кебек үк авыр кичерүен күреп, мин аны чын күңелдән кызгандым.

Әни минем бердәнбер газиз кешем иде. Әтиебез герман сугышында үлеп калганнан бирле без аның белән ярлылыкның да, ачлыкның да бөтен газабын иңгә-иң торып бергәләп күтәрдек. Баштарак, мин сабый чакта, бөтенесенә әни берүзе янып-көйде. Барлык авыр эш аның өстендә булды, ул йокысыз төннәрен минем киләчәгем турында уйланып уздырды. Бәләкәй генә исәя төшкәч, мин — ныгып та җитмәгән бала — җилкәләремә авыр тубал асып чәчү чәчтем, яланаяк тырма тырмаладым, кечкенә арба белән урманнан коры-сары ташыдым. Хәзер инде, үсеп җиткәч, әни мине икебез дә яраткан уңган кызга өйләндереп, карт сөякләренә аз гына ял бирергә, искереп килгән шушы ярым ятим йортта чыр-чулы балалар тавышы ишетергә өметләнгәндер. Ә хәзер аны яңадан шыксыз ялгызлык, йокысыз озын төннәр көтеп тора.

Мин әнинең янына утырып иңбашыннан кочып алдым. Әмма ул минем кулларымны чөеп кенә ыргытты. Хәмдүнәдән мәхрүм калу өстенә әнине дә рәнҗетүем йөрәгемне телгәли иде.

— Әни, син алай бик кайгырма инде. Мин Казаннан тегесен-моны-сын алып кайтырмын да уракны өмә белән урдырырбыз. Кышка мин сине үз янымa, Казанга алырмын,— дидем.

Элекке ягымлылыгы, җан җылысы күз яшьләре белән юылып төшкән иде ахрысы, кырыс күзләре белән миңа карап-карап торды да ниндидер куркыныч янагандай кычкырып куйды:

— Ә антың?

Мин аптырап калдым:

— Нинди антны әйтәсең икән? — дидем.

Әни минем шундый зур хәлне онытуыма бик гаҗәпләнеп:

— Соң, хода бәндәсе! Нинди булсын? Син бит теге китүеңдә Хәмдүнәгә өйләнәм дип ант иткәнсең! Ипекәй алып! Акылың кая синең? Антың үз башыңа төшсә нишләрсең?!

Мин эсселе-суыклы булып киттем. Антым! Намусымны уртага салып, җанымны ярып биргәндәй, чын күңелдән биргән вәгъдәм! Бабайлар «вәгъдә — иман» дигәннәр. Минә шул үтәлмәгән антым, үткен кылыч төсле куркыныч булып, хәзер өстемдә асылынып тора.

— Коммунист та булдың, тагын әллә кемнәр дә. Тик бу кылган эшләрең бер дә акыл утырткан ир кеше гамәле түгел!

Хәзер әни Хәмдүнәне кулдан ычкындыру өчен генә борчылмый, антымны бозган өчен мине ниндидер куркыныч көтүе аны хафага салган иде.

Әнинең хөкеме кискен иде. Әмма мин дә вөҗданыма каршы килә алмый идем бит!

— Җаным ничек тели, шулай эшләдем,— дидем.

Әни башын гына чайкады.

— Ай-һай! Җаным тели дигәч тә... Бу яңа тормышта шарт-шорт мылтык шартлатулар озакка бармас ич. Киләчәктә гомер итәргә вәгъдә, ант, мәхәббәт, намус шикелле нәмәстәкәйләр дә кирәк булып чыгар. Ә син?!

Әни искечә ярыйсы гына белем алган кеше, күп нәрсәне иске китапларда язылганчарак аңлый, аның маңгайга терәп биргән сорауларына җавап бирү ансат түгел иде.

— Нигә, ул син әйткәннәр хәзер дә, яңа тормышта да бар бит, әни. Тик аларны хәзер яңача аңларга кирәк инде, революция кушканча!

Әни, бөтен гәүдәсе белән миңа борылып, туп-туры күзләремә текәлде.

— Бар булгачыннан, алайсам, ник боздың антыңны?! Хәмдүнә мескеннең күз яшен ничек күтәреп йөрерсең? Бүген антыңны боздың, мәхәббәтеңә вәгъдәсез булдың, иртәгә аннары, алла сакласын, җаныңны сатарга да ерак калмый. Беләсеңме син кая таба тәгәрисең?!

Хәмдүнәнең күз яшьләре болай да минем бәгъремә кайнар тамчы-

лар булып көйдереп тамалар иде. Аның өстенә минә тагын әни! Ничек аңлатырга, ничек? Әгәр дә мин аның каршында антыма хыянәт итүче ике йөзле хаин булып калсам, бу әнигә гомерлек вөҗдан газабы булачак, авылдашлары алдында аның йөзенә кара тап булып төшәчәк. «Әнә ничек алдап китте коммун улың!» — дип битенә бәреп әйтәчәкләр.

Йөрәгем сызланса да тыныч булырга тырыштып:

— Син борчылма, әни, мин мәхәббәтемә хыянәт итмәдем, антымны да бозмадым! — дидем.

Әни миңа ачуланып:

— Нәмәкәйгә башымны катырасың? — дип әйтеп салды.— Алайсам, нишләп өйләнмисең?

— Мин бит элекке Хәмдүнәгә өйләнермен дип ант иткән кеше, монысына түгел,— дидем.

Әни ни әйтергә дә белмичә тезенә сугып алды.

— Тукта әле, карап-карап торам да... Мәскәүдән кайтканнан бирле бик манерлап сөйләшә башладың әле син! Безнең авылда ике Хәмдүнә юк. Ул ниткән тегесе дә, ниткән моныс тагын?!

— Алай да була икән ул! — дидем мин. Әнинең үзенә сорау бирдем.— Әйт әле, әни, сиңа килен нәрсәгә кирәк?

— Ай алла, минә тагын — иске авыздан яңа сүз! Олан, сабый! Миңа гына кирәкмени? Әүвәл башта синең үзеңә хатын кирәк! Егермедән узгач та тырай тибеп, тегендә дә монда сугылып гомер итмәссең. Күзлебашлы булырга вакыт!

— Анысы шулай, китапча әйткәндә, миңа хәләл җефет кирәк. Ә сиңа килен нигә кирәк? Нинди килен кирәк?

Әни кулларын җәеп җибәрде.

— Карале моны! Миннән сорый! Син шуны да белмәскә әллә! Күз алдыңда бит!

— Шулай да?

— Күреп торасың лабаса! Бу яшькә җиткәч, минем берүземә йортны сөйрәп бару җиңел дип беләсеңме әллә?! Урагын ур, мал-туарын кара, утынын әзерлә, өй эшләрен кайгырт... Аннан да бигрәк, төп ояны миннән соң да кемдер җылытырга тиештер бит инде!

— Син дә, мин дә яраткан элекке Хәмдүнә нәкъ әнә шул төп ояны җылытасы кыз иде инде. Ә моныс... ю-ук! Уракта да кача бу, бүтән эшләргә дә бил бөгәргә исәбе юк!

— Бәлеш, нишләгән ул? Ничек көн күрмәкче була?

Белеп, сизеп торам, моны әнигә әйтү яхшы түгел иде. Ничә елдан бирле чын күңелдән яратып, аның йортка сөекле, уңган килен булып төшәчәгенә ышанып йөргән элекке Хәмдүнәнең тискәре ягын фаш итү әнигә йөрәк ярасы булачак. Әмма әйтергә телем бармаса да хәзер ничек яшерәсең?

— Аның нәфесе зурдан. Ул Казанның үзендә генә, әтисе алып биргән шәп йортта яшәргә генә риза. Анда да зур нәчәлник бичәсе булып кына.

Әни ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Үз теле белән әйттеме? — дип сорады.

— Әйе.

Шунда сүз киселде. Барлык хыяллары җимерелеп, өметләре өзелгән хәлдә әни күз алдында картаеп, гәүдәсен көч-хәл белән сөйрәгәндәй авыр атлап аш өенә кереп ауды. Өйгә, мәет чыккан йорттагыдай, күңелсез авыр тынлык иңде.

Күземне йокы алмыйча, йөрәгемә ут капкандай, төне буе талаулап чыктым. Яшьли сөйгән яшь матурым, җан сөйгәнем — әнә генә ул, югары очта гына. Көндез каршымда бөтерелүләре күз алдымнан китмичә төн буена азаплады. Ә хәзер мин аны йөрәгемнән кырып ташларга тиеш идем.

Ни җаным белән, ничек итеп?!

Иртәгесен көтү куганда бөтен авылны шаккаттырып яңа хәбәр таралды:

— Хәмдүнәне Хажи байның кече улына ярәшкәннәр!..

Мин сискәнеп киттем. Күңелемдә Хәмдүнәгә рәнҗү кузгалды. Әле бит беренче мәхәббәтнең йөрәкне сызлатып, авырттырып торган чагы гына. Ни җаны белән шундый газаплы минутларда сөймәгән кешесе кочагына ташлана ала ул?! Яратмый бит Хәмдүнә ул кәрләне, бала чактан ук җене сөйми!

Бу хәбәрне әни дә бик авыр кичерде. Хәмдүнәнең бу акылсыз кылынышына чын күңелдән ачынып, еларга җитешеп сукранырга тотынды:

— Ай алла, хәрәпләр булган икән, балакай, әрәмләр генә булган икән! Ул каруннарга төсмени ул бала!? Асырау булып гомере уза икән! — Арлы-бирле сугылып йөрде дә мине битәрләп ташлады: — Менә күрдеңме инде? Сиңа ачу итеп шул карсакка чыккан ул, син алмаган хурлыктан, юри, үч итеп!..

Мин шул көнне үк Казанга чыгып киттем.

## VIII

Аннан соң байтак еллар үтте. Тормышлар ел саен катлаулана барды, элекке белемнәр җитми башлады. Миңа финанс-экономика институтында укып чыгарга туры килде. Эшемне дәвам иттерергә яңадан шул ук наркоматка кайтардылар.

Хәмдүнәләрнең дә Казанга күчеп килүләрен ишеткән булсам да ничектер очрашмадык. Шулай да мин аны бөтенләй күрмәдем дип тә әйтә алмас идем. Үзен үк, бөтен барлыгы белән үк түгел, билгеле, бер ягын куе чәч алкасы каплап торган ак маңгаен, коңгырт зур күзләрен, шул күзләр өстендәге бик иркә, нәфис булып дугайланып төшкән кашларын. Алар я поездга утырганда озатучылар аркасына ышыкланган урыннан, я циркта, театрда-мазарда бер генә сулышка ялт итеп күземә чалынып кала торганнар иде. Кайчагында берәр зур җыелышта, я концерт залында кемнеңдер очлы әйбер кебек үткен карашы сиңа төбәлүен сизәсең. Шул тарафка сак кына, өркетмичә генә күз салсаң, тагын әлеге шул ак маңгай, үзенә суырып алырдай булып йотлыгып караучан коңгырт күзләр. Андый чакларда, әһә, шөкер, әле исән-сау икән, картаймый икән, дип куанып куясың.

Тормышта тагын мондый хәлләр дә була икән.

Бер көнне командировкадан кайтып эшли торган бүлмәмә керүгә, секретарь бер ханымның миндә йомышы барын әйтте. Минем бик ашыгыч докладка әзерләнәсем бар иде.

— Әнә, инспекторга кертегез, ул хәл итәр,— дидем.

— Ул ханым өченче мәртәбә килә инде, сезне күрер идем дип әйтә ул,— диде секретарь.

Бераздан ишек ачылган тавышка күтәрелеп карасам, ишек төбендә — Хәмдүнә! Ул миңа текәлгән, мин — аңа. Мин каушабрак калдым. Ничек әле бу? Истә-оста югында... Теге вакытта аерылышканнан соң беренче мәртәбә... Шәһәрчә киенгән озынча буйлы чандыр гына ханым. Күзләрен зур ачып миңа текәлгән дә телсез калып тик тора. Аның шушы сүзсез-өнсез текәлеп торуында куркумы, шикләнүме, нindидер аңлавы кыен булган шомландыргыч бер хәвеф бар иде. Бу мине борчуга салды. Шушы кыенлыктан котылу өчен мин аңа:

— Исәнме, Хәмдүнә! Әйдә, утыр, рәхим ит! — дидем.

Ул сихерләнгән сыман миннән күзен алмастан сак кына килеп каршыма утырды. Ярым шыпыртлап:

— Үз күзләремә үзем ышанмыйм. Менә бер көн килеп теләкләрем кабул булды, сине дә күрер көннәрем бар икән! — диде. Миңа таба үрелеп карап торды да гаҗәпләнеп башын селекте.— Бәй, чәчеңә чал керә башлаган түгелме соң?! — диде.

Хәмдүнәнең мине һаман да үзенең сөйгән егете кебек якын итүе тора-бара бик тирәнгә алып керергә мөмкин иде. Мин ул хәтәр сукмакны читләтеп узмакчы булып шаянрак телгә күчтем.

— Теге вакыттагы унҗиде яшьлек егет булып каласы иде дә бит... Алай булмый икән шул. Тормыш!..— дидем. Әңгәмәне аның ягына борып җибәрергә омтылдым.— Үзең нихәл соң? Хезмәтең, тормышың ничегрәк? — дип сорадым.

Мин әйткәннәрне Хәмдүнә колагы яныннан гына уздырды. Кулын гына селтәп:

— Әй, миңа ни булсын? Минем турыда түгел әле сүз! — диде. Берәрсе кереп бүлдермәгәе дигәндәй, ишеккә карый-карый, мөлдерәгән күзләрен миңа төбәп, үзенекен пышылдарга тотынды: — Узган атнада сине әллә кайда сәфәрдә итеп, бик куркыныч итеп төшемдә күрдем. Зерә дә курыктым, салкын тиргә батып уяндым. Төн йокыларым качты. Киткәнче бер күреп калыйм ичмаса, дип килдем, әйтер сүзләремне әйтеп калыйм дип...

Хәмдүнәнең болай шомланып сөйләве мине хафага салды. Нигә шулкадәр борчыла, нигә: «күреп калыйм» ди? Шулай да тыныч булырга тырыштым:

— Нигә алай дисең әле, Хәмдүнә? Син дә хәзер Казанда яшисең дип ишеттем. Берәр ерак сәфәргә чыгарга җыенасыңмы әллә? — дидем.

Ул икенче төрле уйларга һич тә урын калдырмыйча кистереп:

— Юк, мин түгел, син чыгасың ул хәтәр сәфәргә, сине көтә хәвефле юллар! — диде.

Хәмдүнәнең шунча еллар узганнан соң да оныта алмавы, әле һаман да мине кайгыртып яшәве, беренче мәхәббәтне искә төшереп, күңелне нечкәртеп җибәрде. Әмма шул ук вакытта уңайсыз да булып китте. Арабыз күптән үк өзелгән кебек иде. Минем инде әллә кайчаннан бирле үз оям, гаиләм, балаларым бар. Хәзер инде йөрәк яраларын яңадан кузгату икебезгә дә газап кына булачак. Шунда әни әйткәннәр исемә төште. «Тән җәзасы белән генә котыла алмассың. Җан җәзаларын да татыйсың бар әле синең!» — дигән иде ул. Кыен булса да таш бәгырьгә әверелә алмыйм, Хәмдүнәне рәнҗетәсе килми иде.

— Сәфәрдә итеп күрдем дисеңме? Мин ул сәфәрләрнең төрлесен башымнан кичергән кеше. Син борчылма, Хәмдүнә, берни дә булмас,— дидем.

— Ай, Зәйни абый, алай димә! Кече атна көн күргән төш дөрес булып чыга ул! Сине бит әллә нинди чит-ят җирдә тешен ыржайтып, усал ат куып йөрде. Күпме тырыштым, миңа тоттырмый, ыржаеп гел сине куа! Менә тешләде, менә таптап узды дигәндә генә котым чыгып уянып киттем! — Шул куркыныч атны күз алдына китергәндәй, Хәмдүнәнең бөтен гәүдәсе куырылып килде.— Мин бик куркам, теге бозган антың түгелме икән ул! Беләсеңме нәрсә ул төштә күргән ат? Үлем ул, газраил ул!..

Тагын шул ант! Хәмдүнәнең миңа төбәлгән яшьле күзләрендә курку да, мәхәббәт тә, күреп каласы килү дә — тагын әллә нәрсәләр дә бар иде. Бу мине бик дулкынландырды, элекке хисләр яңадан уянды.

Күзләреннән күреп, күңелем белән сизеп торам — никадәр кайнарланып расларга җыенсам да Хәмдүнә минем: «Юк-бар нәрсәләргә ышанып үзеңне газаплама», диюемә ышанмаячак. Ничек тынычландырырга, бу куркыныч шикне ничек аның башыннан алып ташларга?!

Башка чарам юк иде, мин бу четерекле мәсьәләне тирәнәйтмичә читләтеп кенә узып китәргә тырыштым.

— Сәфәр дигәннән, син шикләнеп торма, Хәмдүнә, мин бу биш-алты ай эчендә беркая да командировка-мазарга чыкмыйм. Тыныч бул... Үзең турында берни дә әйтмәдең бит әле. Тормышың дигәндәй, ничегрәк? Исәнлегең?..

Һаман да миннән күзен алмыйча, мин әйткәннәргә ышаныр-ышанмас Хәмдүнә көрсенеп куйды.

— Тормышың дип... бара инде ул тормыш. Аның ниндие юк? Кара сакалың кая барсаң да, үзеңнән калмый диләрме? Җан сөйгәнең барында алтын тауларына да кызыкма икән дә... яшьлек шул, юләрлек... Ә бу нәрсә? Тыштан салган ямаулык, әйтергә оят: түшәктә гел янәшә өчәү ятабыз. Янымда ул, күңелемдә бүтән...— Хәмдүнә авызын яулыгы белән каплап иелеп төште.— Берәү белән гомер итеп тә күңел түрендә яшертен бүтәнне саклау яхшы да түгел инде ул, газаплы да... Онытa алмагач, нихәлләр итим соң?! Ник шунда кочаклап үпмәдең ичмасам? Бәлки мин сиңа бирегеп тә калган булыр идем...

Ишектән чыгар алдыннан саубуллашып кулымны кысканда, Хәмдүнәнең чырае кинәт яктырып китте. Күзләрендә, ирен кырыйларында, бөтен йөзендә, ерактагы елдырым нурлары төсле бераз моңсу куаныч бизәкләре балкыды. Мин хәйран калдым, дулкынланып алдым. Шушы берничә минутлык очрашу да аны бәхетле иткән иде.

Еллар буена сүнми-сүрелми торган мәңгелек мәхәббәт, ихтимал, менә шулдыр инде. Бәлки ул теләсә кемдә булмый да торгандыр. Хәмдүнә, күрәсең, шундый затлардан берседер. Теге чакта Таһир белән Зөһрәне, күрәсең, тикмәгә генә телгә алмагандыр...

И язмыш, язмыш! Нинди син — усалмы, әллә мәрхәмәтлеме? Нигә син адәм балаларын күбрәк авырлыкларга дучар итеп сыныйсың, ә киресенчә — яхшылыкны мулрак өләшеп түгел? Бәлки син шушындый рәхимсез кылануларың белән безнең кешелек сыйфатларыбызны — кыюмы, куркакмы, үз намусыбызга тугрылыклымы, түгелме икәнлегебезне сынап карыйсың булыр? Беләсеңме икән син, әгәр төенне чишә алмасаң, аны бит чабып өзмичә хәлең юк!

Әллә син адәм балаларын шулай иң авыр мәхәббәт газабына дучар итеп, бу бөек хиснең кадерен белергә кирәклекне исләренә төшерергә телисеңме?

*1985.*

## Рәдиф Гатауллин

### Безнең Муза

Шагыйрьләргә тик илһамчымы син,
Татар кызы?! Күпме ярасын
Бәйләдең бит илнең! Әле озак
Безгә бергә-бергә барасы:
Сине, ак калфаклы алиһәбез,
Сынауларның көтә яңасы...

Борынгының Афродитасымы?—
Син Тукайның бәлки Зәйтүнәсе —
Әрнүләрнең горур Музасы.
Тарих аша синең йөрәктә ул
Килә назның сабыр туташы —
Язмышларның тугры юлдашы!

Күпме шагыйрьне син алып килдең
Татар Парнасының тәхетенә.
«Зәукың» өчен түгел, хисең һаман
Тоташ ил җанына, бәхетенә:
Безнең тулпарда син таккан чуклар
Бәйгеләргә барган чагында.
Гамь дибез еш — җәрәхәтле хәтер
Гасырлардан кайтып чагыла,
Ул синең дә тере — җаныңда...

Татар кызы, Муза, Алиһәбез,
Әле озак бергә барасы.
Ахыргача бул син моң туташы,
Ахыргача ил, җыр ярасын
Син ябарсың наз-яулыгың белән...
Чор, җир тетри...
Безгә — барасы!

### Туганнар

Әнкәй, син моңаеп әйтә идең:
— Туганнардан да бар туйганнар...
Туймас иделәр дә, алар шул, дип,—
Әзрәк кенә... баеган булганнар.

Мин дә уйлыйм бүген: кемнәр алар
Туганын чит күргән туганнар?

Яңа Кабил белән Һабил мәллә
Гаиләдә? Илдә, Җирдәме?
Нигә туйган? Баеганга булса,
Байлык әллә хокук бирәме
Туганыңны хәтта онытырга?!
Андыйларга тагын ни кирәк?
Ни бар юкса туганыңнан газиз,
Җирдә — туганлыктан изгерәк?

Кем алдарак туган, әлифбасын
Кем укыган, башлап, яшәүнең,
Җыр-дастаннар язган иң беренче,
Кем кабызган әүвәл фән шәмен,
Әдәбият нигезләрен салган?—
Кемнең күпме өлеше хакында
Бер туганнар — халыкларда әллә
Бәхәс бара? Ә бит, барсында
Бүлешергә күпме байлыгы бар:
Матдиме, я, рухи, мәгънәви...
Туганнан, юк, туймас баеганга —
Уртак бар шатлыгы, бар гаме...
Әнкәй, ник моңаеп әйттең икән:
«Туганнар, дип... баеган булганнар».
Баемаган, ярлыланган булыр,
Туганнарын җуйса туганнар! —
Баемаган...

## Ак һәм кара. 1911 ел

Әллә нигә йөзе балкый — ахры,
Бер тантана кичерә уенда:
Күз карашы майлы... Чыгып килә
Шыпырт кына серле урыннан
Һәм доносчы шундый да шат бүген,
Алан-йолан карый як-ягын.

... Ә «Болгар»да Тукай шигырь яза,
Белми кемнең кайдан кайтканын:
Ишми ишаннар соң нигә аңа?! —
Ул халкына өндәү-шигырь яза,
Алдан күреп бәхетен, ак таңын...

●

Югары ул — Тукай биеклеге!..
Кайсы тауга исемен бирәсе?—
Таулар юк шул бездә,
үрләр генә...
Ә рухта — тау биек... Күрәмсең:
Илаһи тау анда! Биеклеген
Үлчи, әйтә алган юк әле...
Кем колачлый, иңли алыр аны?!—
Ул бит Тукай тавы — югары...
Күренерме безгә түбәтәе —

Башка таулар белән сөйләшсә?!
Тик нигезе җирдә,— тиңнәренә
Биеклектән таулар эндәшә...
Безгә — кул җитмәслек!
Сүз кузгата
Кем аңа тиң булу турында?!
Тукай! Ахыргача аны аңлау —
Бу да бәлки хыял-уй гына?!
Ә омтылсак һәм аңласак икән!
Акыл аек, йөрәк сау булып...
Таулар юк шул, исемен бирү өчен,
Туган җирем тиңсез бай булып...

Чын горурлык рухта бәлки:
Кала
Иң биеге Тукай-тау булып!

●

Н. Н.-га

Их, ичмасам... сез калсагыз икән
Ваклыклардан өстен, югары...
Күпме җаннар юкса (мохит тармы?!)
Көчерәйтте үзен, югалды...
Ичмаса сез ерак торсагыз соң
Гайбәтләрдән, дөнья чүбеннән...
Алтын булсаң буялмыйсың — хаклык
Калка хәтта чорлар төбеннән.
Кала алган бар бит — һаман да пакь,
Тидермәгән һич кер-тузанны.
«Өстен вә кул җитмәс...» Тукай кебек!
Җиңел кичкәнме ул дөньяны?!
Сез табынган Лермонтов бит яза:
«Бер давылсыз диңгез буламы?!»
Якты көн күзеннән кем яшеренгән,
Олы җаннар даусыз торганмы?!
Арсагыз соң — биеклеккә китеп
Мөмкин ләса «вәхи алырга»?—
Ят эшме ул Минә, Арафаттан,[1]
Юк, Машуктан кайткан «хаҗи»га?!
Хәсән Туфан сезгә үрнәк шәхес:
Бөек җан ул —•ниләр күрмәгән:
Хәтәр чорлар... нинди якты җырлар!—
Кешеләргә хисе сүнмәгән...
Юк, шагыйрьгә килешмидер һәр шик,
Ачу, уйны җырда калкыту —
Каршылыклы рухны фаш итү?!
Таш бар, бәрсәң — Иблис якынайса...
Нигә рухка аны баш итү?!

Җирдән, тузаннан без яратылган,
Юк үзеңнән качу, югалу...
Ләкин рухың оча алса икән
Хәттә җирдән биек юл алып:
Их, чын шагыйрь өстен калса икән,
Горур булып җырда, югары...

[1] Гарәбстандагы таулар. Автор.

«Карадагынай урман уртасында
Төлке уйный торган орлар бар...»
Әй, халкымның тиңсез күңел фонды,
Синдә күпме алтын җырлар бар!
Тыңлыйм да мин, елыйм: яшьләремдә
Бик ерактан килгән моңнар бар...

Мин дә, мин дә эзлим алтын җырлар,
Табармынмы? Сызган юллар бар.
Ләкин сизәм, һаман җыр алтыны
Табылмаган... Бакыр сырлар бар
Маңгаемда, чәчтә көмешләр бар,
Өметләрем — сизгер кыллар бар...

Уйга калып йөрим чит җирләрдә:
Урманнар бар, алан, орлар бар.
Тынлык белән ялгыз калсам, тоям:
Туган җирдән агыла — моңнар бар,—
Алтын җырлар шулар белән килер,
Килсә миңа — беләм, юлда алар.
Ә хәзергә елыйм, оялмыйча:
Ил күңеленнән мирас җырлар бар!

Ак сафари...
Онытмадыңмы — тик
Актан киенеп мине көткәнең?!
Ак күлмәгең, йөгереп мин керүгә,
Дулкынланып, тетрәп китә иде...
Таң-сәхәрдә бәхет эзләп киттем,
Алып китте хыял-җилкәнме?—
Дәрьяларга салды... бүлмәң калды,
Калды ак сафари — үткәнем...
Еллар узган саен, уй-дулкында
Нәни көймә, гүя, хәтергә
Сугыла шул бүлмәң:
Кемнәр анда?
Ак хыялмы тетри хәзер дә?!
Ә без тормыш дигән җәй агымга
Алмаштырдык язгы хисләрне,—
Аерылганда, истә, ак сафари
Элеккечә тетрәп китмәде —
Тыныч идең...

Каралтмадыңмы соң
Еллар белән син ак җилкәнне?!
Әллә төсе аның бүтәнме?
Искә аласыңмы
Ак сафари —
Ак күлмәктән мине көткәнне?!

Хатларың күптән имзасыз:
Ахырда — «Сагынып, Мин...»
Болай да онытылмас димсең
Кадерле синең исем?!

Ә мин белми торсам: кем син?
Убылып гүя хәтер:
— Кемнән хат? — Шул хакта озак
Уйланып йөрсәм хәзер?!

«Хәтерләтә кемнедер бик,
Язуы шундый таныш»...
Һәм азак, юрап кемгәдер,
Мин җавап язсам ялгыш?!

Аңардан ләкин хат килмәс!
Очрашсак үзе белән,
Яшерен ым, мәгънәләр көтсәм?!
Ул узса сүзсез генә?!

Хатыңны укыйм һаман да
Язгансың: «Сагынып, Мин...»
Исемдә исемең! Көнозын
Кабатлыйм кабынып мин
(Ә бәлки, табынып, дим.)

...Бу җавабым кемгә? Тик син
Аңларсың... Сагынып, Мин.

**Рахмай Хисмәтуллин**

# АЯГҮРӘ

ХИКӘЯ



Урамда кешеләрнең кайнаган чагы. Аяк астында нинәрсә барына игътибар итүче юк: ашыгалар, кабаланалар, чабалар. Кеше ташкыны, ярларына сыеша алмый аккан елга сыман, урам диварларына килеп-килеп кагыла.

Чатларның берсендә, ташкынга ияреп өлгерә алмыйча, аксаклап барган ир кинәттән егылып китте. Кулыннан таушалган сумкасы ычкынып, аннан сабын-мунчалалары чәчрәп сибелде. Ташкын, әз генә дә аңа игътибар итмичә, ага бирде. Исерек ахры, дип уйладылар. Ир, тотынып тормакчы булып (аның бер аягы бөтенләй бөгелми иде), тупас, олы йодрыклары белән асфальтка таяна-таяна, үрмәли-мүкәли стенага таба елышмакчы иде. Әмма үзәк урам ташкыныннан атылып чыккан тонган күзле, колга буйлы исерек аны озын сыйраклары белән бәрдереп узды. Аксак, тәрәген югалтып, таш йорт диварына баш түбәсе белән килеп төртелде. Неон рекламалар тетрәп куйды сыман, гүя йортлар-урамнар әйләнде, күкнең тәрәүләре сыкрап, дөпелдәп ауды. Аксакның башы нидәндер авыртып зыңлады... Ул, башын тотып, куырыла-җыерыла диварга сыланды.

...Үтеп баручы карт белән карчык, башы канап яткан ирне күргәч, чәчелгән әйберләрне егылучының сумкасына тутырдылар.

— Ни булды сезгә? — дип сорады карчык.

Аксак дәшмәде.

— Ул аңын җуйган ахры.— Карчык чиста ак кәгазь салфетка белән ирнең канлы пеләш башын сөртте, икенчесен ярасына япкандай итте.

— Исеректер бу, Дженни, киттек әйдә.— Карт шулай дия-дия хатынын ашыктырды.

...Исерек дими ни дисеннәр! Кайда ул элекке зифа гәүдә, киң күкрәкләр? Аксап йөргәнгә күрә гәүдәсе гарипләнеп бер якка янтаеп калган. Авыр хәсрәтләр киң җилкәле ирне сыгып төшергән, аркасын бөкрәйткән. Сул кашының яртысы кызыл җөй генә. Элекке елмаючан якты коңгырт күзләр — тонык, төссез, кызганыч моң тулы...

Дәһшәтле урам ташкыны күпме агылгандыр, бәлки бер көн, ә бәлки гасыр буе... Аксакның моңарчы дөнья белән алыш-биреше юк иде. Әмма бераздан ул үтә бер сәер халәттә калды: аңа дөнья ачылып киткәндәй булды, аның башында нәрсәдер яңа, кайный, яңара сыман. Кеше үзенең нинди хәлдә икәнен әле белми, берни аңлый алмый иде.

Контузиядән соң ябылган хәтер бигенең ачылуы, каты бәрелүдән хәтернең кайтуы һәм колакның ишетә башлавы иде бу!

Тор, бәндә, тизрәк тор, этләрең янына ашык, югыйсә сине эзли чыгулары ихтимал. Бот итеңә кайда икәнеңне хәбәр итеп торган радиомаяк тегелгәнен белмисең шул син...

Кеше, стенага сыенган хәлендә, хәйран калып, уянган аңына иярде. Иң әүвәл аңы җуелган мизгел хәтердә яңарды... Чәнечкеле тимер чыбык, карлы яңгыр... Башында берни дә юк. Өстендә буй-буй кием. Ул — әсирлектә. Ул күктән очып барган самолетларга нидер кычкыра. Кайдадыр якында гына сызгырып-улап, җанны суырып, гөрселдәп бомба төште... Аннары бетте... Аны каядыр алып китәләр, ул кычкырмакчы була, ләкин тавышы чыкмый. Менә аңа аталар да аталар, күкрәгеннән тишкәләп бетерәләр...

Кеше менә шушы мизгелне аермачык тойды. Әмма моңа хәтле булган вакыйгаларга аның аңы әле үтеп керә алмады. Аңарчы да ул инде берничә тапкыр үлеп терелгән кеше иде.

...Мәскәү яны. Эңгер-меңгер. Зәңгәр күктән ак болытлар агыла да агыла. Ә ул кар өстендә чалкан ята. Чәрдәкләүче пуля калак һәм бот сөяген ватып үткән. Күкрәк тирәсенә, балтырларга тулып кан укмаша, ката бара, кысып бәйләгән сыман, сулышны буа. Кырык бердәге декабрь суыгының бу кадәр мәрхәмәтсез буласын кем белгән? Салкын, үзәккә үтеп, йөрәкне менә-менә туктатып калдырыр сыман. Ул көч-хәл белән аваз салды:

— Терелләр... бармы?

— Ы-ы,— дип ыңгырашты янында гына берәү,— үлүемне... әти... әнигә... хәбәр... ит...

Бу казах дустының соңгы сүзе булды. Нәкый, борылып, аның йөзенә карады: иптәшенең чырае башта нык кына каралды, аннары әкренләп агара башлады. «Менә ничек үлә икән кеше».

Караңгы төште, тирә-якны салкын, үле тынлык төреп алды. Чү, тән тын түгел икән! Әнә, каядыр этләр өргән, немецча сөйләшкән тавышлар ишетелә башлады. Әнә, алар якынаялар... «Сволочьлар, үлгәннәргә дә тынгылык бирмиләр... Якынаялар. Юк, болай яту, тере килеш алар кулына әсирлеккә эләгү һич тә ярамый. Тоткынлык — үлемнән түбән! Аягүрә үлүең мең артык!» Ул күтәрелергә талпынып карады, булдыра алмады. Әнә, аны кызганып, алка-алка ак болытлар арасында, салкын канлы бөҗра әчендә, китек ай елый. Әллә каян җыр ишетелгәндәй була. Җыр, куәтле дулкын булып, аны калкынырга чакыра. Бар иде бит, Нәкый, синең егәрле чакларың. Хәтерлисеңме Сабан туен? Мәйдан уртасыннан сөрән салдылар:

— Самат батыр белән кем тагын көч сынашырга тели?!

Син мәйдан уртасына йөгереп кердең. Каршыңда мичкә кебек юан Самат басып тора иде. Моңарчы аны беркем дә ала алмады. Шунда син батырның күкрәгенә кереп, тезләнеп суырып та алдың, аркасына китереп тә салдың. Әй шаулаган иде мәйдан!

Яралы Нәкый әллә нигә ачы елмаеп көлеп җибәрде һәм ярсып, мылтыгына таянып, дуамалланып аягүрә торып басты. Үтерсәләр үтерсеннәр, әсир генә итмәсеннәр! Аягүрә! Аягүрә!! Автоматлар тырылдады, солдат күкрәген нидер яндырып үтте, ул тагын җиргә ауды. Этләр өрүе, сөйләшүләр тынды, әйтерсең лә алар аның җанын алыр өчен генә кубарылганнар иде. Хуш, бәхил бул, дөнья, әсир генә итмә!

Ләкин бераздан ул аңына килде, үлем аны тагын читләтеп узган иде.

Каяндыр төтен исе, авыл... яңа пешкән ипи исе килде... Әһә-ә, үзебезнең яктан! Әнә, безнең самолетлар дошманнар өстенә очып үтте. Торып басарга кирәк!

Аккаенга асылып меңгән кебек
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым...

Яшьлекнең анты яңгырый ич, кузгал! Төтен... татлы.. Кузгал! Ләкин гәүдә тыңламый. Ул азап чигеп, тырмашып, бер якка авышты, мылтыгына үрелде, аны җиргә терәп, тотынып күтәрелмәкче булды, көче җитмәде. Шуышырга, тырнак белән тырнанып булса да шуышырга! Анда яшәү. Ул шуышты... Ул бөтен дөньяны әйләнеп җир шарын урап шуыша иде сыман. Аһ, хәл китте. Морҗасыннан татлы төтен исе, ипи исе бөркеп торган иң кырый йорт та чиксез ерак шул. Инде капкага җитәм, кагылам, тотынам!

Котылам! дигәндә ул тәмам хәлен җуйды, бармагын да селкетә алмас булды, тынды, бетте. Иә, хода! Бу авылның бер генә кешесе дә аның үлеп ятканын тоймый, сизми микәнни соң?..

* * *

Аксак артыннан әле һаман килеп җитмәделәр. Ә урам кайнавында. Тау-ташлар астыннан җәһәннәм елгасы бәреп чыккан сыман, канга батып хәтер ачыла иде. Әсирлек. Атыш. Әйе, аның күкрәген тишкәләп бетерделәр. Ә ул аткан якка таба көлеп бара да бара, танкларны, пулеметларны тибеп кенә очыра. Ул бара, ул көлә, ул кычкыра һәм... ул егыла. Аның өстенә ят формалы чит ил солдатлары иелә, иреннәре селкенә — нәрсәдер әйтәләр булса кирәк...

Нәкыйнең сөйлисе, кычкырасы килә, ә ул берни дә ишетми, дәшә дә алмый иде инде.

Солдатлар аны күз күрмәгән якларга алып китте.

Беләсе иде... Хәтерлисе иде шуннан соң ни булганын. Ул сәерсенеп урам гөжләвенә колак салды: урам кайный... Ни бу? Әллә колак кына шаулыймы?

— Э-э-ых! — Ул шомланып, аптырап үз авазын тыңлады. Ни булды аңа? Нәрсә бу, нинди тавыш бу? Каян килә? Ә аның этләре кая соң? Аң тагын да ныграк хәрәкәтләнде, хәтердә сусау купты. Тәнен калтыратып бизгәк тотты. Әллә ничә еллык билгесезлек мең төрле сораулар рәвешендә алга басты. Нәкый, үтә гаҗәпләнеп, әкрен генә үз гәүдәсен, киемнәрен капшый-капшый тотып карады. Нәрсә бу? Ул әллә йоклый идеме соң? Кая бара соң ул? Җанны ачыттырып аның үз җанын тоясы, аңлыйсы килде. Ул, кешеләрнең сөйләшеп үтүләренә гаҗиз калып, аяклары атлаган уңайга агымга иярде. Гүя аны икенче «мин»е җитәкләп алып китте! Ул аны ашыктырды, каударлады. Гүя «мин» аны кемнәрнеңдер эзләп чыгуларыннан курка иде. Шул «мин» аны троллейбуска алып керде. Кызганыч, Нәкый кешеләрнең сөйләшүләрен аңлый алмады. Шәһәр читенә җиткәч, яшерен «мин» аны автобуска күчереп утыртты. Автобус кыр һәм урманнар буйлап, таулар аша бик озак барды. Кара урман уртасында теге сәер «мин» аны «син шушында идең»,— дия-дия автобустан төшерде. Чәнечкеле койма янындагы абзар этләр авазыннан шаугөр килеп тора иде. Капка төбендә аны, башын игәндәй итеп, каравылчы каршылады. Юк, әле аны эзләргә чыкмаганнар иде.

Нәкыйнең аңы түгел, гүя тәне сизә иде. Монда аңа бөтен нәрсә дә таныш: менә бу кечкенә будка да, менә бу шашынып өргән этләр дә, менә бу будка эчендәге такта карават та. Ул шушында әнә теге усал тавышлы этләрне ашата иде, менә шушы караватта йоклый, шушында яши иде. Ул үзе караган этләрнең шушы чәнечкеле койма буйлап чабулап йөрүләрен абайлый иде. Ә менә койма эчендә ни бар, нишлиләр — ул берни дә белми, белә дә алмый иде. Шәүләләр генә күз алдында: противогаз кигән солдатлар, борыннарын тоткан кешеләр, цистерналар, ашыгыч ярдәм машиналары...

Нәкый боларның берсен дә белә алмавы, чукрак һәм хәтерсез булуы белән үтә яшерен дәһшәтле яңа корал сынау полигонын саклый торган этләрне ашатырга ифрат та яраклы җан иясе иде. Исемсез, әмма номерлы, радиомаяклы җан иясе.

Ул, гадәтенчә, ит түшкәләре чабып, эт оялары буйлап ашарларына салып чыкты да, будкага кереп, караватына чалкан ятты. Аны берни белән дә аңлатып бирә алмаслык ачы тойгылар чорнап алды. Аның ниндидер аждаһа оясында, тәмуг казанында яшәве чынбарлык булган ич! Ул моны аңсыздан да тоеп яшәгән икән. Әмма боларны берничек тә, беркемгә дә белдерү мөмкин түгел. Буылыгыз, ятим тойгылар!

Нәкый шунда гына мәңгелек әсирлектә черүен аңлагандай булды. Кинәт аның үз хәленә булган эчке протесты, каргышы ачы газ сыман бугазыннан тотты: «Синме, Нәкый? Синме бу?..» Җанга юаныч табарга кирәк, юаныч... Тукта, ул бит елга янына барып, суга карап торырга ярата иде. Табарга шул суны! Ул, каравылчыга күренмәскә тырышып, этләр абзары артын-

нан уратып чыкты да автобуска утырды. Элекке «мин»е катыш бүгенге «мин»е кая алып китәр икән аны?

Ә күктә алка-алка ак болытлар йөзә...

...Теге чакта Мәскәү янында хәле мөшкел иде аның. Иә хода, бу авылдагы бер генә кеше дә аның үлеп ятканып тоймый, сизми микәнни? Туган авылы — керәшен-татар аралаш Сәрәпәледә булса, сизәрләр иде. Анда бит төнге йолдызларга, салкын айларга хәтле мәрхәмәтле иде. И кайларга китеп югалдыгыз сез, ул бәхетле чаклар, аулак өйләрдә үткән гүзәл вакытлар! Гармунчы Нәкый чая кызлар арасында егетләр солтаны иде. Чибәрләрнең чибәре Анукае шунда аңа өздереп карый-карый җыр әйтер иде:

Биеккәй тауларның, әй, башында
Алтын үлчи, диләр бер егет.
Алтын үлчәсә дә гадел үлчи,
Бардыр ул егеттә бер өмет.

Ике баласы белән зарыгып көткән сөекле Анукаен ул башка беркайчан да кочып үбә алмас микәнни? Туган җирендә яшел чирәмнәргә чалкан төшеп, язгы кояшларны, зәңгәр күкләрне, назлы җилләрне тыңлап, тын гына бер ята алмас микәнни?

Шыгырдап ишек ачылды. Иң татлы җырдай, ана тавышыдай ягымлы ишетелде ул. Өйдән кеше чыкты, яшәү чыкты, җылы чыкты! Нәкый үзе дә сизмәстән бар көченә ыңгырашып җибәрде. Кеше каушап, тыңланып торды да кар өстендә яткан кара шәүләгә таба атлады. Курыкмыйча атлады! Рәхмәт сиңа, Кеше!

Ул, бер карт булып, солдатның кием-погоннарына хәтле тикшереп, үзебезнеке икәнен тәмам ачыклады. Күтәрмәкче иде, булдыра алмады, борылып кире өенә кереп китте.

А-а-а, бетте, тәмам бетте!.. Салкын төндә үлеп баручы аң дөньяга соңгы үпкә-рәнҗү белән өметсезлек упкынына мәтәлде. Их син, хәсрәт Нәкый, журналист буларак, син гомерең буе кешеләрнең гуманизмы турында язган булдың. Ә алар сине күрә торып салкын кар өстендә катырып үтерәләр. Исән чагыңда кешеләр ярата иде бит сине югыйсә.

Керфекләргә соңгы күз яшьләре ябышып катты...

Әйе, аны иптәшләре, сәләтле журналист булганы өчен генә түгел, нур сибеп торган мөлаем бер тыйнаклыгы өчен, чыннан да, бик яраталар иде. Ул беркайчан да үзен күрсәтергә омтылмый иде. Байлыкка сикереп төшмәде, данга исе китмәде. Һәм шунысы гаҗәп — иң авыр чакларында бу дөньяның иблисе дә, фәрештәсе дә, әллә нинди тәкәбберлеге дә гел аңа тартыла, кайгы-хәсрәтләрен уртаклашырга аңа сыена иде. Аның янында низаглар эри, кешелексезләр шәфкатьләнә шикелле иде.

Ә менә кая соң, кешем, синең шәфкатең?

Ишек кабат шыгырдап ачылды. Карт, карчыгын ияртеп, яңадан чыгып килә иде. Алар солдатны көч-хәл белән күтәреп өйләренә алып керделәр. Кечкенә өй уртасында калай мич дөрләп яна иде. Ах, җылыкай! Картлар җыерчыкланып каткан куллары белән аның өшегән тәннәрен удылар, яраларын бәйләделәр. Карт бик ябык, шыр сөяк кенә иде. Тик төпкә баткан зәңгәр күзләре елтырап тора да, чал озын мыек чылгыйлары, көчле кош канатларына охшап, картны очырып китәргә гайрәтләнә сыман. Ә сул як бит очында миңе елмаеп торган түгәрәк йөзле карчык шактый хәлле, таза иде әле. Ниндидер җылы, рәхәт шулпаны, солдатның башын күтәртеп, калаклап авызына каптырдылар. Нәкыйнең башы әйләнде, капкан бер ризыкны коса барды. Каршыдагы картларның йөзе, каралган түшәмнәр, стеналар әйләнде, җаны укшыды. Һәм ул... бу изге күңелле кешеләргә берни дә әйтә алмыйча аңын җуйды.

...Шыгыр-шыгыр. Урман, сап-сары күк. Ул чалкан бара. Кар өстеннән язмыш чанасы шуа, Нәкыйне каядыр алып баралар...

* * *

...Чукрак чактан калган тоемлавы аны лабиринт сыман корылмалар янындагы тукталышта автобустан төшерде. Бу корылмаларны үтеп, калкулыкка менгәч, сихри ай нурында көмеш дәрья җәйрәп ята иде. Ул кайчандыр шушы зур су ярына килә иде. Шуның дулкынлануына карап, җанын тынычландыра иде сыман.

Яр буе тулы утларын балкыткан кораблар, кораблар. Ак күбеккә баткан ярсулы иксез-чиксез зур су! Нәрсә сөйли, ни хәтерләтә соң бу күренеш? Кайсы кабиләдән, кайсы гасырлардан килә аңа бу шомлы, дәһшәтле авазлар? Каян бу үзәк өзгеч аклык моңы?

Әдрән диңгез, шаулы диңгез,
Даулы ул диңгез.
Тирәләре таулы диңгез,
Бик таулы диңгез...

Карасу зәңгәр күктән җанны сискәндереп, үкендереп, алка-алка ак болытлар агыла... Кайсы илдә икән ул? Кайсы кыйтгада? Нинди әсирлектә икән ул? Ник аны иреккә чыгарып йөртәләр, ник тотмыйлар аны? Беләсе иде: ни турында шаулый бу су? Күкләрне һәм җирләрне тоташтырып, ак болыт һәм чал диңгезне давылландырып, биектә-биектә нинди симфония шаулый ул?

Хәлен җуйган син бөркеткә,
Ай, син бөркеткә шифа бир, изге диңгез...

Аңа яшәү алып килгән бу тетрәндергеч симфонияне кайчандыр ерак тыл госпиталендә ишеткәнен ул хәтерли, әмма төгәл билгели алмый аптырый иде.

* * *

Шул госпитальдә чагында ул яшәүгә сусау тулы әллә нинди сихри музыка авазлары астында аңына килгән иде. Музыка аны төпсез упкыннан югарыга чакыра. Анда Сәрәпәле урманнарының шау-шулары да, чишмәләренең челтерәүләре дә, әнисенең һәм Анукаеның ягымлы күкрәк тавышлары да, аны үлем тырнагыннан тартып алган шәфкать туташларының елмаюлары да, сабыйлар елавы да, ата-аналарның зар-интизар булып улларын сугышка озату сагышлары да, төнге атака-һөҗүм тетрәнүләре дә — барысы бергә бер дәһшәткә кушылып, дулкын-дулкын җанга бәреп, ярсып яңгырый иде. Музыкада сугыш һәм тынычлык, яшәү һәм үлем канга-кан бәрелешә иде. Операциядән соң бары тик шул музыка гына тәнгә кан кертте. Башта күз кабаклары ачылыр-ачылмас селкенде, аннары аяк-кулларның барлыгы тоелды. Нинди ак түшәм бу? Музыка, язгы нур төяп, ачык тәрәзәдән ургылып керә иде. Я, илаһым, нигә күңелгә шулкадәр якын, таныш соң ул? Нишләп соң аңарда «Шахта»лар да, «Салкын чишмә»ләр дә, алай гына түгел, «Дубинушка»лар да ут өертеп барысы бергә яңгырыйлар. Бер музыкада шулай берьюлы тау җимерердәй куәтле төрле көйләр бергә сыя ала микәнни, раббым! Таныш та, ят та башка бер дөньядан, ай-йолдызлардан, әллә нинди теге дөньялардан түгелме соң бу сихри авазлар?! Яткан урыннан суырып калкытырга тели алар: «Тор, Нәкый, тор! Әнә анда, сугыш кырларында, иптәшләрең үлеп ятканда синең монда ышыкта калырга хакың юк. Тор, Нәкый, бас аягүрә!»

— Зинһар, үлә калсам, мине шушы музыканы уйнатып җирләсеннәр иде. Башка берни дә кирәкми...

— Юк, син хәзер үлмисең инде, солдат. Синең кебек каты яралылар инде күптән үлеп беттеләр. Ә син 15 көн аңсыз ятып та яңадан терелдең. Болай булгач, син яшисең инде,— ди колак төбендә ягымлы хатын-кыз тавышы.

— Ә кайдан килә бу музыка?

— Капка баганасындагы репродуктордан,— ди әлеге назлы тавыш.

Ничек соң бу музыка тәннең һәр күзәнәген көрәш, яшәү дәрте белән ту-

тыра ала?! Еллар үтәр. Нәкый концлагерьда ятканда гына үлемне җиңәргә көч биргән бу көйнең Чайковскийның алтынчы симфониясе — давыл симфониясе икәнлеген белер!

Ә әлегә музыка яшьлекнең нәкъ үзе булып яңгырый иде. Бу инде теге саташкан авазлар, хыялның хәлсез эзләнүе түгел, ә менә нәкъ яшьлектәге давыллы чорларны искә төшерә иде.

Тормыш... Үлем...
Анда давыл симфониясе,
Анда үзенә башка тавышлар...

Нинди шашкын, бәхетле вакытлар бар иде. Казан урамнары тар иде. Пединститутта укый иде ул, телләр өйрәнә иде. Такташча озын чәчләр. Билбау буып, түбәтәйне кыңгыр салып, тальян гармун тартып, Казан урамнарына хуҗа булып йөргән ул чаклар, кайда сез?! Такташ — кумир. Бөтен дөньясында аның кебек шагыйрь юк һәм була да алмый. Аның шигырьләрен яттан белмәгән студент — студент түгел. Белмим дип кара, шунда ук тукмап ташлаулары ихтимал. Такташ бөек, хыялый яшьлекнең давыл хәбәрчесе, яңа мәхәббәт җырчысы. Аңа иярми мөмкин түгел. Зәңгәр күзләрен моңга тутырып сәхнәгә чыгып басса, аңа гашыйк булмый мөмкин түгел. Аның тавышында — нәкъ менә бүген яңгыраган давыл симфониясе аккордлары...

Еллар үтәр. Тормыш мең төрле газаплар китерер, ләкин беркайчан да бу газаптай моңлы газап, үлеп терелү газабы булмас кебек иде шикелле. Әмма бу тормышның дәвамы чиксез икән. Нәкыйны тагын фронт юллары суырып алды...

Аяныч, Нәкый аягүрә басып сугышып үлә алмады. Сугыш ахырга таба якыная иде. Эсэсчыларның да койрыкларына ут каба иде, ахры. Алар Нәкыйне оныттылар. Ә Нәкый үлемен көтеп ята иде әле. Нәкъ шул вакытта, союзник гаскәрләренең бомбасы төшеп, тоткыннар барагы күккә очты. Нәкый контузия алды. Аны билгесез тарафка алып киттеләр. Ул беркем уйлап таба алмаслык афәткә, исән килеш үлеп яшәү төрмәсенә ябылуга, чукраклыкка, хәтерсезлеккә дучар булган иде...

* * *

Нишләп бу диңгез төне шулай бик тиз үтеп китте соң әле? Күктәге алка-алка болытлар да каядыр таралып, качып беткән. Күк тулы зәңгәр сагыш, диңгез тулы зәңгәр моң гына торып калган...

Аны хәзер теге әтле дөньядагылар эзләп тә таба алмаслар мөгаен. Әллә аңа кая китсә дә ярый микән соң?

Нәкый ялгыша иде. Тәнендәге радиомаягы аның кайдалыгын хәбәр итеп тора иде.

Еракта-еракта эт өргән тавышлар ишетелде кебек...

Инде менә ничә еллар буе дәшми торган Усал Дөнья телгә килде. Ят ил, чит ил иде бу. Тик әнә яр буендагы кораблар арасында аның өчен ниндидер бер туганлык, якынлык бар сыман. Ул моны җаны-тәне белән, күңеленең илаһи тоемы белән сизә... Әнә, әнә, каяндыр җанга якын авазлар ишетеләндәй була. Әйе, ниндидер бер корабтан сихри җыр авазлары яңгырый иде.

Нәкый, әлбәттә, аның җанга якынлыгын тоя, әмма нинди сүзләр, нинди көй икәнлеген аңлый алмый. Нәкый туган телкәе стихиясенә кайта алмый азапланды. Җыр җанның җиденче катын актара иде.

Идел ярларына нурлар сибеп,
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты Туган илем,
Бәхет биргән җирем — Татарстан.

Шулай да «Татарстан» сүзе таныш иде аңа. Ул пирс буйлап, титаклап атлый-атлый, шул авазлар килгән корабны эзләде. Тирләде, янып-пешеп чыкты, ниһаять, моңга якынайды, тик сүзләрен аңлавы барыбер кыен иде аңа. Ерак микән аның газиз туган җире? Әнә, корабны да тапты бугай ул:

тик ни дип язылган соң аңа? Беренче хәрефе бик якын билге — кызын хәтерләттеме ул: әйе, әйе, «м» — «Мәдинә» исемле кызы бар иде бит аның. Икенчесе ни соң: Ану-у-укай, әйе: «у» була. Өченчесе, сагыну, дигәндәге «с» була, ахры. Ә дүртенчесе... ана, дигәндәге «а» бит. Я, ничек була инде: м-у-с-а. Икенче сүзе ничек була икән тагын: җ-җаным, ә-энием, Л-ләйсән, и-илем, Л-ленин... Җәлил... була бугай. Кем икән ул? Ә-ә... шагыйрь исеме бит бу: Му-са Җә-лил. Ничек әле: Такташмы? Шуның белән бергә йөргән шагыйрь исеме бит бу. Моң шуннан агыла, кабат-кабат җырлаталар:

Идел ярларына нурлар сибеп...

Ул бөтен барлыгы белән корабка төбәлде. Бар дөньясын оныткан мондый минутларда аны этләре чалбар балагыннан тартып уяталар иде.

Һау-һау-һау! Этләр өере якынайганнан-якыная. Күрче, әллә үзе караган этләре аны шулай эзли чыкканнармы? Ул бит инде күптән алар янына кайтырга, ашарларына салырга тиеш булгандыр.

Әйе, этләр радиомаяк аша аны эзләп киләләр иде.

Дәһшәтле кораллар ясый торган заводларга, алар урнашкан базаларга, алар сынала торган полигоннарга «күрмәүчеләр, ишетмәүчеләр, дәшә алмаучылар» кирәклеген Нәкый белми иде әле. Хәзер дөньяга үз исемен оныткан, хәтерен җуйган эт ашатучылар кирәклеген, нәкъ аның кебек милләтсез, ватансыз, робот кебек кешеләр кирәклеген ул төшенми иде әле!!! Дөньяның микроб һәм бомбаларга ныграк төренгәнен, курогына тияр-тимәс торган соңгы афәт-һәлакәт бар Җир шарын чорнаганын ул аңлый алмый иде әле.

Ырылдап эт өргән авазлар якыная. Нәкъ ул төшкән тау ягыннан бер өер этләрне бауга бәйләп, алдан чаптырып, күзен һәрчак кан баскан каравыл башлыгы төшеп килә иде.

Һау-һау-һау! Этләр ярсыганнар, котырганнар. Хәзер алар аны вакытында кайтмаган һәм ашарларына бирмәгән өчен өзгәләп-өзгәләп ташлаячаклар. Һау-һау-һау! Беттең син, җир корты. Өф-ф! Һәм этләр умырып үтәчәк сине. Син беркайчан да туган илеңне күрә алмаячаксың! Кү-рә ал-мая-чак-сың!..

Җилләр шулай дип исте, таулар шулай дип кычкырды, диңгез шулай дип ыңгыраšты... Ләкин тәндә ниндидер бер бөек инстинкт өстенлек итә иде: юк, аягүрә омтылыш мәңгелек, аны беркем дә, берни дә, беркайчан да үтерә, юкка чыгара алмаячак! Әнә музыка чакыра, ашыктыра: «Сикер океанга! Сикер океанга!»

Инстинктның җиденче катында кайчандыр укылган фикер өстенлек итте: «Байлыгыңны югалттың — әз генә югалттың, вөҗданыңны югалттың — бик күпне югалттың, Ватаныңны югалттың — барын да югалттың. Дөньясына туасың да калмаган...» Шул бөек акыл да котылгысыз итеп боерды:

— Сикер океанга! Сикер океанга!!!

Этләр, ажгырып-ярсып, пирс буйлап туп-туры аңа якынаялар иде инде. Ә корабтан, шаштыру дәрәҗәсенә җиткереп, тылсымлы моң яңгырый:

Идел ярларына нурлар сибеп...

Нәкый палубадагыларга кул болгады, нәрсәдер кычкыргандай итте. Күрделәр түгелме соң? Әнә бит аңа таба борылдылар. Этләр белән ара ун метр чамасы гына калды. Шулчак дөнья икегә ярылды. Ул җан-фәрманга титаклап йөгереп килеп, пирс ярына сикереп менде һәм шаулап-кайнап, үкереп торган океанга ташланды!

— У-у-ээх!!!

Теплоходтан коткару шлюпкасы төшерелде. Ерактан ук яр буен күзәтеп торган порт сакчылары да моторлы көймәдә кеше сикергән урынга атылдылар.

Ике арада давыллы упкын.

Упкын уртасында Кеше!

Дулкын бәрә, дулкын бөтәрли! Ә Кешегә аягүрә, бары тик аягүрә калырга кирәк!

Тукайның 100 еллыгына




Шагыйрьнең әнисе Мәмдүдә Зиннәтулла кызы күмелгән Сасна авылы (хәзерге Балтач районы Сасна Пучинкәсе) зираты.

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

# САСНА

Ил язмышын яклап кан койган, шәһит киткән уллар тудырган аналарга җир йөзендә һәйкәлләр кирәк. Дөньяга шагыйрь тудырган аналарга җир йөзендә һәйкәлләр кирәк. Татарстанның чик буендагы ерак почмагында Сасна (Сасна Пучинкәсе) дигән бер авыл бар. Балтач районына керә. Әйләнә-тирәсендә удмуртлар, керәшен татарлары, берничә чакрым узып, чикне ашсаң — марилар. Балтачлылар бик кадерләп тота бу авылны: Тукай биографиясенә бәйле бердәнбер авыл бит ул Балтачта.

Мәмдүдә дөньяда нибары егерме алты ел яши. Шул кыска гомерендә күпме хәсрәт, күпме газап! Аның тормышында бер генә якты көн булдымы икән? Башта, яшьлеге чәчәк атканда, аны үзеннән егерме ике яшькә олы, ике бала белән тол калган иргә кияүгә бирәләр. Мөхәммәтгариф абзый дөнья куйгач, Мәмдүдә үзенең йөрәк парәсе бәләкәй — өч яше дә тулмаган Габдулланы кеше кулына калдырып тагын кияүгә чыгарга мәҗбүр була: ул заманда шулай, ялгыз хатын ятим бала белән көн итә алмый. Бу юлы Мәмдүдә үзеннән кырык биш яшькә олы Мөхәммәтшакир муллага кияүгә чыга, Саснага күчеп килә. Юньле кеше булган ул Мөхәммәтшакир абзый, һичшиксез, юньле булган: азмы-күпме яшәүгә ул ат җибәреп бәләкәй Габдулланы Саснага алдыра. Үги әтисе күрешкәндә ятим малайны кулына алып сөя, аңа «чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып» бирә, бала куанып бетә алмый. Үзен-үзе белә башлаганнан бирле иң беренче җылы караш бу, иң беренче игътибар бу Габдуллага. Ләкин кара язмыш Габдулладан моны да күпсенә, бу рәхәт бер ел да бармый, Мәмдүдә бәләкәй улын соң мәртәбә үбә дә дөнья куя. Нәкъ егерме ел узгач, шагыйрь Тукай бу мизгелне искә алып үзенең бөтен балачагына тулы характеристика биргән түбәндәге юлларны яза:

> Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
> Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

...Мөхәммәтшакир мулланың өенә каршы урдә, бер җир буе гына ераклыкта бик борынгы зират шаулап утыра. Сасна — Казан ханлыгы чоры авылы дип сөйли халык. Әнә шул чал зиратка 1890 елның январь салкынында дөньяга шагыйрь тудырганын белмичә күзләрен йомган бәхетсез Мәмдүдәнең җеназасын алып китәләр. Аз, бик аз гомер бирелгән аңа! Әнә бит Мөхәммәтшакир абзый якты дөньяда нәкъ 97 ел яши! Шуның чиреген генә нигә Мәмдүдәгә өстәмәгән бу тереклек дөньясы! Сабый Габдулла бу фаҗиганы инде аң белән кабул итә: әнисенең җеназасы артыннан ул яланаяк, яланбаш чыгып, январь карына бата-чума зиратка таба йөгерә: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» Ләкин зират юлы — бер генә якка...

Халкыбызга бөек шагыйрь тудырып, яшьли дөньядан киткән Мәмдүдә кабере өстенә Казан артының гадәте буенча топольләр утыртканнар. Бераздан, ихтимал, үз бакчасы кырыннан алыптыр, Мөхәммәтшакир абзый монда тал да китереп төрткән. Ул агачлар инде карт, бик карт. Теге тал инде үз авырлыгын үзе күтәрә алмыйча, Мәмдүдә кабере өстенә иелгән. Казан артының бу ерак почмагына яз килгәндә күккә ашкан аксыл биек топольләр, Мәмдүдә кабере өстендәге кабер ташына башын игән карт тал март җиленә кушылып кинәт кенә ыңгырашып алалар, җиргә шагыйрь тудырып киткән дөньяның бу гүзәл хатынына бишек җыры җырлыйлар. Бу җырда Мәмдүдәнең бөек улы шагыйрь Тукай тавышы да бар:

> Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,—
> Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

## Рафаил Төхфәтуллин

# КЫРЛАЙГА СӘЯХӘТ ҺӘМ САМАВЫР ЙӨЗЛЕГЕНӘ ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬ

ИСТӘЛЕК-ХИКӘЯ



Мин туган авыл Яңа Иябаш соңыннан «Тукай-Кырлай» дип аталып киткән Яңа Кырлайга терәлеп үк диярлек торса да, мин ул авылны шактый соң, әйтергә кирәк, «Шүрәле»не чатнатып яттан сөйләп йөри башлагач кына килеп күрдем.

Миңа яшь тулып узгач бугай, укытучы әтиемне Күлле-Киме авылындагы икенче баскыч мәктәпкә эшкә күчергәннәр. Кимедә мин, букча асып, мәктәпкә йөри башладым. Ләкин беренче сыйныфны, хәзергечә әйтсәк, беренче классны да тәмамларга өлгермәдем, салкын кыш уртасында Кышкар авылына күчеп киттек.

Җәй житте. Элекке мәдрәсә бүлмәсендә беренче сабакларны алып бетереп, без авыл артындагы Завод тавы итәгенә, зур гына буалы инеш буйларына сибелдек. Беркөнне сабакташым Фаил әйтә куйды:

— Иртәгә Тукай-Кырлайга барып кайтам. Сабан туена. Апаны да сагындым. Җизнине дә.

Бер дә исе-хушы китми генә, уен арасында гына әйтеп салды Фаил бу хәбәрне.

Минем исә колаклар үрә торды, йөрәккәйләрем леп-леп килә башлады. Исеме китапларга кергән Кырлайга барам, ди бит! Шунда ук күңелдә шигырь юллары кабатланды. Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай диләр; җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр... Тагын әле, сабан туена ди бит! Кышкарда әле сабан туе күрмәсәм дә, Күлле-Киме сабантуйлары күңеллелекнең иң югарысы булып, иксез-чиксез булып хәтергә сеңгән.

— Кем белән барасың, Кырлайга?

— Һи! Миңа кем кирәк? Чыктым-киттем.

— Юлда берәр атлы абый утыртыр әле дисеңмени?

Фаил бөтенләй егетләрчә итеп, теш арасыннан гына сытып чыгарып төкереп куйды.

— Үземнең пар атым барында, нигә миңа атлы абый? — Ул мәгънәле генә аякларына суккалап алды. Әйтә торам, алма апаны бик сагындым.

Минем йөрәк лепелдәпме-лепелди. Шулай җәяүләп кенә барып була микәнни ул китапта язылган Кырлайга? Аннары әле... Олылар сөйләвеннән беләм, мин дөньяга килгән Яңа Иябаш Кырлайга бөтенләй якын гына. Өстәвенә әле, минем дә бит, нәкъ Фаилнеке кебек, Иябашта әнинең сеңлесе Фәсәхәт апам белән Габделхәй җизнәм бар. Минем дә бит Фәсәхәт апамны — һәрвакыт ягымлы, якты йөзле, ачулану-каш җыеруның ни икәнен дә белми торган Фәсәхәт апамны күрәсем килә. Габделхәй җизнине дә күрәсем киләме, анысын белмим, ә менә Фәсәхәт апаны бик күрәсем килә. Сагыну дигәннәре шулай буладыр инде ул.

— Фаил малай! Син юлын беләсеңмени Кырлайның?

— Һи! Күземне бәйләп җибәр — барып җитәм.

— Күзеңне бәйләп тормыйк, син болай гына күрсәт миңа Кырлай юлын. Кайчанрак кузгалабыз?

Кызык бу сабыйлык хатирәләре. Кинодагы кебек, бер күренештән икенчесенә, ераклык-якынлык аралары белән һич хисаплашмастан, ялт кына күчә дә тора. Ничегрәк үттек без ул ун-унике чакрымлык араны, безнең бу сәяхәткә әти-әниләребез ничегрәк карады? — болары, үтер, аз гына да

истә калмаган. Хатирәләр инеш буендагы сөйләшүдән сабан туеның ифрат чуар-колга башындагы чигүле сөлгеләре, апа-әбиләрнең кулмәкләре, чуклы-чаклы атлары күз явын алган күренешләренә күчә. Аннары, шул бик истә. Биленә кызыл билбау буган, яшел кәләпүшен кырынрак салган бабай нидер әйтеп аваз салуга, мәйданга малайлар йөгерешеп чыкты. Көрәшергә чыккан-нар икән. Ни арада өлгергән, карасам, Фаилем дә шулар арасында. Ләкин көч сынашырга теләгән малайлар артык күп булдымы, әллә көтек кенә буйлы Фаилгә ышанып бетмәделәрме, ул арада үсмерләр, аннары егетләр бил алыша башлады да, дустым, иренен бияләй кадәр салындырып, мыш-мыш яныма килеп утырды, кулындагы алсу күкәйне шак итеп маңгаена бәреп ватты.

Керфекләрең генә талмасын, карар кызыклар берсе өстенә берсе өстәлә торды. Әмма берзаман, инде көрәш тә, йөгереш бәйгеләре дә тәмамланып, мәйдан шактый сыегая башлагач, минем эчне ачы гына бер хәсрәт кимерергә тотынды. Фаилгә рәхәт, апа-җизниләренә керә дә, сабантуй сыйлары белән туйганчы сыйланып, ята да йоклый хәзер. Миңа нишләргә соң? Моннан ерак та булмаска тиешле ул Иябашка кай юлдан барырга да Фәсәхәт апа белән Габделхәй җизни өен ничек эзләп табарга?

Шунда, әйтерсең лә, башкаема килеп төшкән бу хәсрәт төерчеген әллә кайдан гына күреп торган диярсең, Фәсәхәт апам, тулган айдай балкып, каршыма гына килде дә чыкты.

— Ай, энем җаным, ничек килдең монда? Кем белән?

Хатирәләр кинотасмасы шушында тагын бер сикереш ясый. Иртәгесен мин Тукай-Кырлайда, кичә Фаил күрсәтеп үткән капка төбендә басып тора идем. Таныш булмаган өйгә барып керергә кыюлык җитмиме, келәгә үрелмим. Хәер, өйгә керергә бик атлыгып та тормыйм. Сихри шигырь булып китапка язылган бу авылның һәр өен, һәр сукмагын, чирәмлектә миңа таба хәтәр генә өселдәп-өселдәп куючы ала казның һәр сары-йомшак бәбкәен хәтеремә сеңдерергә теләгәндәй, тирә-юнемне йотылып күзәтәм. Күңелдә — ерактан гына ишетелгән матур җырдай, шигырь юллары кабатлана:

> Ул авылның, һич онытмыйм, һәр ягы урман иде;
> Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.

Шунда җыр кисәк кенә тукталып кала. Карачы, бер дә алай «һәр ягы урман» түгел ич бу авылның. Дөрес, без килгән яктан бераз уңдарак, шактый ерақта булса кирәк, күкселләнеп урман күренә, ә калган өч тарафка күзләрең талганчы текәлеп тор — һичнинди урман-фәлән шәйли алмыйсың. Әллә ул яклардагы урманнарны инде кисеп бетерделәр микән? Алай урманы киселеп беткән якларга карыйсы да килми, тизрәк ерактагы күксел урман ягына таба борылам. Күңелдәге җыр акрын-акрын тагын зыңлый башлый:

> Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
> Күз ачып-йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.

Фаилдән сорыйсы булыр әле, кайтышлый әнә шул урман аша үтә торган юл юк микән Кышкарга таба? Әкәмәт тә шәп булыр иде ул, «күз ачып-йомганчы» гына җыеп алып, өйгә бер чиләк җиләк күтәреп кайтып керсәң.

Ләкин без өйгә алай бер чиләк җиләк күтәреп кайтып кермәдек. Кайтыр юл бөтән бер ягы белән бик истә.

Тәпили торгач арылгандыр, төбеннән чишмә кебек кенә инешчеге агып торган яшел яр буена ял итәргә утырдык. Озатканда Фәсәхәт апа «сабан туе күчтәнәче» дип, миңа шакмак ашъяулыклы бер төенчек тоттырган иде. Шул төенчек икебез урасында яшел чирәмдә ята хәзер. Дөресен әйткәндә, юлга чыкканнан бирле тынгылык бирми инде миңа бу төенчек. Җәяүлегә инә дә авыр, дигәндәй, кулларны да талдырып бетерде, аннары, ниләр төйнәлгән икән ул ашъяулыкка? — шуны да бик беләсе килә. Өстәвенә әле, Фаил дә сәер генә карап-карап куя төенчегемә. «Җүләр! Юлга төенчек күтәреп чыккан. Минем күк ике кулны селти-селти генә тәпиләүгә ни җитә»,— дия иде бугай бу караш.

Яр буена җәйләп утыруга, мин төенчекне чишеп җибәрдем. Кабартмалар, сумсалар, тагын әллә нинди тәм-томнар. Исләре шунда ук борынны кытык-ларга тотынды. Иртән Фәсәхәт апа кыстый-кыстый сыйлап чыгарса да, тәпили

торгач, карын ачып өлгергән икән, авыздан сулар килә башлады. Ашъяулыкны Фаилгә табарак этәреп:

— Әйдә, җитеш әле, тарсынып утырма,— дидем мин Фәсәхәт ападан откан сүзләрне кабатлап.

Җиләкне күз ачып-йомганчы бер чиләк җыю бәхетенә ирешмәсәк тә, әйтергә була, ашъяулыкны күз ачып-йомганчы ялт иттердек. Мин дә Фаил кебек ике кулны селти-селти генә кайтам хәзер. Хәер, кулларны гел селтәп кенә бармыйбыз, кулларга эше табылып кына тора. Юл буендагы зуррак ташларны әйләндереп салабыз да, шуның кап-кара эзендә ап-ак борма-борма үләннәрне, бераз куркынычрак кыяфәтле кортларны, тишегенә шуышучы кызыл селәүчәннәрне озаклап күзәтәбез. Солы басуы буйлап үтә башлагач, яшькелт саламнан сыбызгы ясап кычкырту китте. Рәхәт!

Ләкин бер рәхәтнең бер михнәте, дип юкка гына әйтми икән олылар. Инде Завод тавы да күренә, кайтып җитәргә күп тә калмаган иде. Шунда минем кесәгә йомарлап тыккан әлеге ашъяулык гаять тә авырая башлады. Карасана, мин ул төенчекне өйдәгеләргә алып кайтып бирергә тиеш булганмындыр бит?! «Үзеңне сыйладым, болары белән эти-әниеңне, апаң белән энеңне дә сыйла»,— дип әйтүе булгандыр ул Фәсәхәт апаның. Шулайдыр ул. Инде: «менә сезгә сабан туе күчтәнәчләре», дип буш ашъяулык чыгарып салсам, ни әйтерләр миңа?

Ярар, нихәл итәсең, булганы булган, булганны кире кайтарып булмый. Иң дөресе, әгәр тегеләй-болай нитә калса, тиз генә кереп качар өчен, «җир тишеге» дигәннәрен алдан ук эзләп табып куясы булыр.

* * *

Караңгы өйалдына караңгы уйлар белән кайтып керсәм дә, өй ишеген ачуга, шунда ук яктылык бөркелде. Төшлектән авышкан кояш ян тәрәзәдән безнең өйгә үк сикереп керергә җыена сыман, ә түрдәге зәңгәр, сары чәчәкле кәнәфидә тагы да матуррак чәчәкле киңчә күлмәге, зур гына җемелдек алкалары, ак яулыгы астыннан аз гына күренеп торган көмеш чәчләре белән балкып, Сәрвиниял апа утыра иде.

Сәрвиниял апа — олыларча әйтсәң, Сәрвиниһал — безгә кардәш тиешле. Әниләре дәү әни белән бертуганнармы, әллә туганнан-туганмы, ачык кына белгәнем булмады. Иң кирәге ул түгел, иң кирәге аның безгә килүе иде. Бигрәкләр дә күңелле була безгә Сәрвиниял апа килсә! Гел әнә шулай нур белән тула өебез ул килсә. Алай гел кояшлы көннәрдә генә килеп тормый ул үзе. Болытлы кышкы көннәрдә килә, кичләтеп кенә килеп кергәне бар — өебез барыбер яктыра, өйдә гөр-гөр сөйләшү аз гына туктамый. Кызыклы хәлләр дә сөйли бугай, олылар еш кына көлешеп алалар. Олылар көлешә, ләкин безнең дә көлгәнне хәтерләмим. Безнең өчен кызыгы кичен йокларга яткач башлана. Почмак якта, безнең белән бергә куна Сәрвиниял апа. Ятып бетмәс борын ук әйтә башлыйбыз: «Сәрвиниял апа, теге әкият бетмәде бит әле»,— дибез. Апабыз ялындырып тормый, башы үткән килүендә, юк, аннан элекке килүендә, юк, аннан да элек... хәтерләмим дә инде, башы кайчан башлангандыр, әнә шул кызыклы озын әкиятне сөйли башлый. Кызыклы дигәч тә, һич тә көлкеле түгел. Йокыларыңны бөтенләйгә килмәскә качырып бетерердәй үрмә-үрмә маҗаралы, үзең дә сизмәстән юрган астына посканнан-постыра торган куркынычрак та әкият.

Бүген дә шул очы-кырые һич төгәлләнми торган тылсымлы әкиятне тыңлыйбыз икән! Минем караңгы өйалдындагы караңгы уйларымны яп-якты өй эчен тагы да балкытып утырган Сәрвиниял апа әнә шулай бик тиз оныттырды.

Ләкин Сәрвиниял апа ул кичне әкият сөйләмәде. Җәйге озын көндә төн кунып ятасы килмәгәндер инде, үзе әйткәнчә, «икенде белән ахшам арасында» Яңа Кишетенә кайтып китте.

Әмма ул көн әкияттән дә битәррәк бер сөйләшү белән хәтергә һич онытылмаслык булып сеңеп калган.

Минем Кырлай сабан туеннан кайтуымны белгәч, Сәрвиниял апа бәйгеләрнең ничегрәк үтүе, кайда кунуым, монысын белгәч, Фәсәхәт апа белән Габделхәй җизнинең хәл-әхвәлләрен сорашып китте. Монысына минем җавабым «әйе-әһе»дән артмады — әгәр сүз иярә сүз чыгып, хәерсез күчтәнәч тә фаш ителсә, нихәлләр итәрсең? Әлеге «җир тишеге» дигәннәрен дә эзләп табарга өлгермәдем, җитмәсә... Юк, андый нәмәрсәнең кирәге чыкмады. Сәрвиниял апа сорап куйды:

— Тукай каеннарын да күрдеңме соң анда, Кырлайда?

Юк, күрмәгән идем. Күрсәтүче дә булмады, андый каеннар барлыгын бөтенләй дә белми идем.

Сәрвиниял апа әнигә карап сөйләп китте:

— Баһар, син хәтерлисеңдер инде минем Кәшифә ахирәтне? Бигрәк яшьләй ятим калды бит мескенкәем. Әллә ай буе икәүләшеп җылаштык. Беркөнне Кәшифә әйтә миңа: «Сәрвиниһал,— ди,— син җыр, бәет чыгарырга оста, минем әни турында да берәр җырмы, бәетме чыгар әле»,— ди. Ярар, дидем. Уйлап йөрим, беркөнне кулыма каләм дә алып утырдым. Язам да сызам, язам да бозам. Һич кенә дә күңелдәгечә чыкмый, ходайның хикмәте. Ахирәтнең дөньяга сыймас моң-хәсрәтен тамчы да китереп булмый. Шуннан соң, беркөнне, нинди йомыш беләндер, Кырлайга бардым. Кайтышлый, Тукай каеннарын карап үтим әле дип, Иябаш очы урамына борылдым. Килсәм, Баһар җаным, йөрәккәем әллә нишләпләр китте. Син, Баһар, хәтерлисеңдер, ул каеннар икәү иде бит, пар иделәр. Килсәм, шул пар каен ялгызга калган, янындагысы юк. Әллә, мин әйтәм, Тукай вафат булгач, моның берсе сагыштан кибеп-корып, шуңа кистеләр микән әллә, дим. Булмас димә, кеше кайгысына бигрәкләр дә сизгер диләр бит ул каеннарны, җанашларымны. Шулай уйлавым булды, ике күземнән чишмә күк яшь акты китте. Мин инде, ахирәтнең кайгысын уртаклашып җылый-җылый, күз яшем корып беттеме дисәм... Теге җырдагы кебек:

Минем түккән күз яшемдә
Инде балыклар йөзә...

Шулаймы дисәм, юк икән, корыйсы юк икән ул моң-хәсрәт күз яшьләренең. Менә шунда, ходайның хикмәте, Тукай шигыре исемә килде дә төште.

Бар күңеллрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы.

Шушы шигырь хәтеремә килүе булды, ходайның хикмәте, елаудан туктадым. Менә, мин әйтәм, Кәшифә ахирәт үзенең хәсрәте турында миннән җыр чыгартмакчы, Тукай бичара күптән әйтеп калдырган икән ич инде адәм башына мәңге төшкән, мәңге төшәчәк мондый ачы хәсрәт турысында. Тукайдан да уздырып әйтеп биреп буламы соң инде, җә? Шуннан соң... Инде дә моңлы шигырь үзе, име, ә мин җүләр нишләде диген? Күңелләр бушанып, аяк атлауларым җиңеләеп китте, өйгә кайтып җиткәнне сизми дә калдым. Кайтуга әйтеп бирәм ахирәткә Тукай шигырен, дим. Шулай бик дәртләнеп кайтсам да, Кәшифәнең үзен күрүгә, хикмәт, телләрем бәйләнде дә калды. Елаудан туктавыма кайчан, Тукай шигырен әйтсәм, тагын яшь коя башлый ич инде бу бичара, дим. Икеме, өчме көн үткәч, Кәшифә сорап куйды. Сәрвиниһал, ди, җыр чагармадыңмы әле әнием турында, ди. Үзе сорагач, әйттем дә бирдем моңа Тукай шигырен. Әйтүен әйттем, татар акылы тау менгәч, дигәндәй, шунда ук телемне тешләрдәй булдым. Тагын яшь коя инде бу бичара, дим. Ходайның хикмәте, бөртек керфеге дә чыланмады, сулган йөзләренә элекке нурлары ук кунды әле. «Рәхмәт, Сәрвиниһал, ди, Ташкичү остасына әнием каберенә таш ясарга әйтеп кайткан идем, бүген ук барам да, шушы шигырьне яздырам»,— ди. Менә бит нинди ул Тукай! Нинди моңлы итеп әйтсә дә, кеше күңеленә юанычын да сала белә икән.

Әни, Сәрвиниял апа сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, чәй хәзерләп йөрде. Менә өстәлгә, парларын бөркеп, самавыр килеп утырды. Безнең яңа самавырыбыз бу. Элекке җиз самавыр инде бик искергән, борыныннан гел тамчы тамып утыра, йөзлегендәге ямалган төшләре әле аксылланып, әле яшелләнеп, чыраен сытарга гына тора иде. Монысы — ак самавыр. Матур чүлмәк сыман, иңнәре калку, биле нечкә. Йөзлекләре, әгәр башың-күзеңне, бер карaганда, кәкре кыярдай итеп, икенче караганда, соңгы таба коймагыдай уемтыклы җәлпәк итеп, үзеңнән көлеп туймаслык итеп күрсәтүен искә алмаганда, көзге күк ялтырап тора. Сүз әнә шул яңа самавырыбыз турында китте хәзер. Яңа самавырдан беренче тапкырлар чәй эчкәндә бик күңелле булса да, инде бер кызыгы калмаган икән мондый сөйләшүнең. Ул әңгәмәне тыңлаудан бигрәк, мин Сәрвиниял апа алдына ук куелган бизәкле савыттан ничек кенә итеп тагын бер мендәр конфет үрелеп алу турында уйлап утырдым.

Ләкин бер дә юкка гына булмаган икән самавыр турында болай тәмләп сөйләшү.

— Самавыр дигәннән... Икәү-өчәү булсайде ул дөньяда самавырың! — диде Сәрвиниял апа, сүз кеен аз гына да өзмәстән.

— Икәү-өчәү тагын! Монысына ирешкәнгә шөкер.

— Алай димәле син, Баһар. Шуннан әйтүем аны... Әгәренки шунда самавырыбыз икәү булса соң, тегесен, Тукай үз кулы белән шигырь язып киткәнен, җанымнан артык күреп саклар идем мин менә хәзер.

— Нинди шигырьле самавыр ул?

— Әбәү җаным! Сиңа сөйләмәдем микәнни? Фәсәхәткәме, Сәгадәткәме сөйләвем хәтердә инде алайса. Сезнең кайсыгыз белән ни сөйләшкәнне бутап та бетерерсең. Бер дә апа-сеңелләр димәссең, игезәкләр күк бит сез. Болай булды ул, җаным. Безнең җитеп кенә килә торган кыз чаклар әле. Беркөнне эти Әтнә базарыннан күңелләре хушланып кайтып керде. «Әтнә некрутлар белән тулган, шунлыктан базар бик шәп булды,— дип әнигә сөйләп утырды.— Кайтышлый шулай, күрәм, алдагы аттан бер егет сикереп төшә дә йөгерә, сикереп төшә дә йөгерә. Йөгермәссең, аягында кәвеш сымак бер нәмәрсә генә моның, өстендә дә юка гына урыс казакие, башында урыс кипкәсе. Әкөне нинди бит аның бүген, казакидан түгел, төлке тун киеп чыксаң да, сикертерлек. Шуннан, моның бер төшүендә сөйләшеп киттек. Беләсеңме, карчык, кем булып чыкты бу егет? Кушлавычның мәрхүм Мөхәммәтгариф хәзрәтнең мәхдүме икән. Киемнәре урысчарак булса да, безнеңчә шундый матур сөйләшә. Мөхәммәтгариф мулланы бик яхшы хәтерлим мин, инде дә гыйлем хәзрәт иде, мәрхүм. Бергә ашта утырган чаклар да булды. Шуны әйткәч, егетем тагы да ачылып китте. «Менә, солдатка каралырга кайттым әле. Казанда яшим», ди. «Анда нинди эштә, әллә адвокат-фәләнме?» дим. Көлә. «Юк, мин гәҗит-китап чыгару эшендә» ди. Хәзер Мәңгәргә барышы икән. «Кушлавычка да барып киләсем бар», ди. «Анда барышлый, безгә дә сугыл, чәй эчеп, җылынып чыгарсың», дим. «Бәлки сугылырмын да әле, алай этиемне дә белгәч», диде. «Менә, карчык, шундый мөхтәрәм кунак килеп чыгуы бар безгә, аң бул», диде эти.

Бу хәбәрне шул кичне үк Кәшифә ахирәткә җиткердем. «Караны, әгәр килеп чыкса, миңа да әйтми калма, минем дә күрәсем килә, алай китаплар чыгара торган кешене», ди Кәшифә.

Ярар, икеме, өчме көн үтүгә, капка төбебезгә бер ат килеп туктады. Тырантастан төшкән ят кешене шунда ук чамалап алдым. Аягында, эти «кәвеш сыман» дигәне шундый да матур шиблет икән моның, башында, чыннан да, урыс кипкесе. Барысы да үзенә чат килешеп тора тагын. Җәтрәк Кәшифәләргә йөгердем.

Әйләнеп кергәндә, әни самавыр куеп җибәргән, мич авызында өчаяк астына чыра ягып кына төче коймак салып йөри. Кунак егет ак якта эти белән сөйләшеп утыралар. Безнең этине, хәтерлисеңдер инде, күңеленә хуш килгән кешесе булса, һич кенә дә сөйләшеп сүзе бетмәс иде бит аның. Бу юлы да гел эти сөйләгәне генә ишетелә, кунак егет ара-тирә генә сүз кушкалый. Әни самавырны түр якка күтәреп чыккан арада, үрелә-үрелә күз салмак булабыз, кунак егет монда таба арты беләнрәк утырган. Кәшифә ахирәт бик елдам кыз иде бит, шунда сәке өстендәге кәрәзле бал тартмасын алды да «җиңгәй, моны да чыгарыргадыр бит», дип түр якка керде дә китте. Мин дә аннан калышып тормадым тагы. Табадан беренче тәлинкә коймак төшүгә, шуны күтәреп кереп киттем. Һаман да эти нидер сөйли, кунак егет кулына балкашык алган да, шуның сабы белән самавырга сызгалый-сызгалый, тыңлап утыра. Яулык читеннән генә күз төшереп алдым. Инде дә сөйкемле егет, Баһар җаным, йөзләре үк нурлы.

Кунак егет, юл кешесе бит, озак утырмады, китте. Без Кәшифә белән түр якка өстәлне җыештырып алырга кердек. Керсәк, Баһар җаным, шаклар да каттык. Кунак егет балкашык сабы белән самавырга сызгалап утыра иде, дидем бит. Тикмәгә генә булмаган икән, наян. Шулай балкашык сабын балавызга манып, самавыр йөзлегенә шигырь язып киткән, әй!

— Ниндирәк шигырь язган? Хәтереңдә калмаганмы?

— Хәтерләмимме соң! Гомеремдә онытасым юк. Менә болай дигән:

> И матур! Иренмәче, еш-еш кына көзгегә бак!
> Күр йөзеңне: нинди нурлы, нинди алсу, нинди ак.

— Тукай шигыре ич бу.

— Бөтен хикмәте дә шунда шул менәтерә. Без ул чакта, әйтәм ич, җитеп кенә килүче кызлар әле, дөньяда Тукай дигән шагыйрь барлыгын белми дә идек. Әти дә үз кунагының кем икәнлеген тәгаен генә белде микән? Алай дисәң, шул елнымы, әллә икенче елнымы, Арчадан бер шигырь китабы алып кайтты әти. «Габдулла Тукаев шигырьләре», диелгән иде тышында. Кәшифә ахирәт белән бергәләп, шуны укып утыра идек, бер битендә, Баһар җаным, безнең самавырга язып калдырган шигырь килде-чыкты! Яшь чак, җүләр чак диген, менә ике ахирәт ут ягып бәхәсләшәбез. «Сиңа карата чыгарган Тукай бу шигырен»,— дигән була Кәшифә. «Юк инде, мин әйтәм, төп-төгәл сиңа багышланган шигырь бу. Син бит әнә кая басканыңны белмәстән, бал күтәреп шундук түр якка кереп киттең. Мин коймак күтәреп кергәндә, шигырен язып утыра иде инде ул», дим. Кәшифә һаман үзенекен сукалый. Сиңа да сиңа. Белмәссең тагын... Әнә алай-болай юлыңда Хозер Ильяс очраса, кем белән очрашканыңны һич белмәссең, ди бит, күңелендә изге сүзләре дә якты нуры гына гомерлеккә иңеп калыр, ди. Шуның күк булды инде безнең дә. Әмма дә ләкин, әйтәм ич, самавырыбыз икәү булса, монысын җанымнан артык күреп саклар идем... Ярар, Баһар җаным, рәхмәтләр яусын тәмле чәең, якты чыраең өчен! Кузгалыйм инде мин. Ибраһим улым эштән арып кайтыр, аның да солдатка караласы елы бит, кулдан килгән кадәренчә, кадер-хөрмәтемне күрсәтеп каласым килә...

* * *

Сәрвиниял апа сөйләгән Тукай каеннарын миңа бераз үсә төшкәч кенә барып күрергә туры килде. Сүз Кырлайда кечкенә Габдулла яшәп киткән Сәгъди абзыйлар ишегалдындагы карт каеннар турында барган икән. Мин килеп күргәндә, инде каеннарның икенчесе дә корыган, ләкин монысын төптән кисеп ташламаганнар, койма тиңентен генә кискәннәр дә, шунда пыяла рамлап Тукайның зур гына рәсемен урнаштырганнар иде.

Әлекке Кызыл Юл район үзәге Яңа Кенәрдән, мари ягы авылларыннан Арча станциясенә илтә торган олы юл өстендәге урам бу. Стансада поездга утырып, Казанга, тагын әллә кайларга сәфәр тотучы атлы, җәяүле юлаучылар моннан көннәр-төннәр буе өзелми. Тукай балачагында үзе үрмәләп менеп уйнап йөргән аккаен кәүсәсе башыннан юлчыларга моңсу гына хәерле юл теләп кала...

Бөек Ватан сугышы башлангач, Тукай шушыннан үзенең күпме якташларын — «тынычта аттан артык эшләүче, сугышта юлбарыстай көчле» ир-егетләрне, «нинди нурлы, нинди алсу, нинди ак йөзле» нечкәбил кызларны изге яуга озатып калды. Шулардан күпмесе кире әйләнеп кайтмадылар...

Сәрвиниял апаның бердәнбер улы — әтисе беренче герман сугышына чыгып киткәндә ана карынында калган Ибраһим абый да кайта алмады. Мин армиядән кайтканда, Сәрвиниял апа үзе дә вафат иде инде. Фәсәхәт апа сөйләде: улының кара кәгазен алгач, сөекле улының хәсрәтле язмышы турында Сәрвиниял апа бәет чыгарган, шуны мөнәҗәт әйткәндәй көйли-көйли «өй» борынча әйтеп йөргән. Хәтерендә калганын Фәсәхәт апа миңа да әйтеп күрсәткән иде. Кызганыч, язып алмаганмын, хәтер саклый алмаган. Сәрвиниял апаның безгә килгән саен ялгап алып китеп сөйли торган очсыз-кырыйсыз мавыктыргыч озын әкияте дә хәзер өзек-өзек кенә хәтеремдә. Их, хәзерге күк, магнитофон тасмасына яза барсаң икән Сәрвиниял апаның шундый да тәмләп, матур итеп әкият сөйләүләрен!

Ә менә Сәрвиниял апаның яшьлегендә Тукайны күрүе, шагыйрьнең самавыр йөзлегенә шигырь язып калдыруы турында, ихтимал, бераз хыял кушыбрак сөйләгәнен һич онытмыйм. Онытырга хакым юк — бөек шагыйребезнең халык күңелендә ул чакларда ук үлмәс легендага әверелә баруын күрсәткән матур бер хикәят ич ул!

*Апрель, 1985.*

Розалина Шаһиева

# ТУКАЙ ҺӘМ СЫНЛЫ СӘНГАТЬ

Бөек Тукайның «мөкатдәс моңлы» музасы XX гасыр башы милли культура тарихында якты сәхифәләр язып калдырды. Дөнья әдәбиятында сирәк очраучы күпкырлы талантка ия булган әдип татар профессиональ сынлы сәнгатен — гасыр башында әле бөреләнә генә башлаган сәнгатьне тудыруга бәяләп бетергесез өлеш кертте. Гомумән, Г. Тукайның һәм шулай ук аның күренекле замандашлары Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Камалның милли «рәсемчелек»не яклап көрәшүләре күптармаклы культурабызны бербөтен итеп үстерүдә гаять әһәмиятле роль уйнады.

«Коеп куйган шагыйрь» генә булмаган Г. Тукай сынлы сәнгатьнең идея-эстетик бурычларын турыдан-туры милли үзаңны үстерүгә юнәлдерелгән көрәш белән бәйли. Беренче рәсемле сатирик журналлардан «Яшен», «Ялт-йолт» битләрендә чыккан публицистик үткен мәкаләләрен генә искә төшерегез. Әле 1906 елда ук беренче рус революциясе идеяләре белән канатланган шагыйрь «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» исемле мәкаләсендә шундый чакыру ташлый: «...милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, ...җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын...»

Милли культураны тудыруда бөтен сәнгатьләрне дә тигез үстерү зарурлыгы, безнең милләтнең дә «башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга» һ. б. ларга мохтаҗлыгы Г. Тукайның «Хиссияте миллия» мәкаләсендә аеруча ассызыклап әйтелә. Тырышлык эзсез югалмый. Акрынлап дөньяга чыккан рәсемнәрдә халык үз сурәтен үзе күрә башлый. Шагыйрьнең «Юаныч», «Алтын әтәч», «Күңелле сәхифәләр» кебек рәсемле китаплары басылу да үзеннән-үзе генә барлыкка килгән очраклы күренеш түгелдер. Балалар өчен чыгарылган әлеге җыентыклар татар китабы тарихында текстны сәнгатьчә иллюстрацияләүнең беренче үрнәкләре булып санала.

Г. Тукай китапларын бизәү Бөек Октябрь революциясеннән соңгы чорда сыйфат ягыннан бөтенләй яңа баскычка күтәрелде. Ышанып әйтергә мөмкин: шагыйрь әсәрләрен иллюстрацияләү өлкәсендәге уңышлар татар графика сәнгатенең гомуми үсешеннән аерылгысыз. Бернича буын рәссамнар И. Плещинский, Б. Урманче, Б. Альменов, Т. Хаҗиәхмәтов, Э. Зарипов, И. Колмогорцева, В. Аршинов, Н. Әлмиев һ. б. лар тарафыннан Г. Тукайның шигъри дөньясы рухына тәңгәл килгән образлар хәзинәсе тудырылды.

Татарстан сынлы сәнгате чәчәк аткан дәвердә Тукай тематикасын ачуга яңачарак килү күзәтелә башлады. «...Сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын...» Рәссамнарыбыз үзләренең әсәрләрендә шагыйрьнең әнә шундый тирән мәгънәле фикерен тагын да калкурак итеп гәүдәләндерергә омтылалар, шушы юнәлештәге эзләнүләрен тирәнәйтәләр.

Шунысы игътибарга лаек: алтмышынчы елларга кадәр Тукай тематикасы нигездә графикада гәүдәләндерелсә, хәзер ул сынлы сәнгатьнең барлык төрләрен дә колачлый. Шагыйрь иҗатының эстетик һәм гармоник гүзәллеген күрсәтүдә сурәтләү чараларына аеруча бай булган нәкыш сәнгатенең зуррак мөмкинлекләргә ия икәнлеге дә күренде. Кабатланмас шигъри байлыкларны тулырак ачарга омтылу, үз чиратында, сынлы сәнгатьнең кайбер төрләрен синтезлау зарурлыгын да китереп чыгарды.

Күп тармаклы сынлы сәнгатьтә Тукай тематикасының гаять киң колач алуы шагыйрь иҗатының халык йөрәгенә тоташуы белән аңлатыладыр. Татар халкының рухи тормышындагы яңа зур күтәрелешләр, социаль һәм милли үзаңның уянуы, чыннан да, «халык җаны»на әверелгән Тукай исеменә дә турыдан-туры бәйләнгән. Менә шуңа күрә дә Тукай иҗатының сынлы сәнгатьтәге чагылышы уникаль күренеш буларак кабул ителә. Әдәби иҗат шәхесе тирәсендә шулкадәр күпсынлы сәнгать әсәрләренең туплануы, дөресен генә әйткәндә, тулаем совет культурасы тарихында да сирәк очрый.

Игътибарыбызны портрет жанры үсешенә юнәлдерик. Әйтик, типик кануннарга таянып иҗат ителгән документаль характердагы портретларда без «композицион тигезләнеш», статика, традицион колоритлар күрәбез. Х. Якуповның «Г. Тукай», Х. Казаковның «Кечкенә Тукай» кебек әсәрләре әнә шундыйлар рәтенә керә.

Әле генә күрсәтеп үтелгән тенденцияләр «Кечкенә Тукай» портретында аеруча калку чагыла. Картина «сөйләп бирү» алымы, тормыш-көнкүреш предметларын төгәл күрсәтү юлы белән эшләнгән. Гадәти татар өе бизәлешендә халыкның күңел яктысы да чагыла. Тәрәзәдән сирпелгән кояш нурлары, әйтерсең, назга туймаган ятим малайның башыннан сыйпыйлар. Күңелгә таныш шигъри сүзләр килә: «Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?! Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем».

Е. Симбирин иҗат иткән әсәрдә без документаль портрет кануннары кысаларыннан чыгу омтылышы күрәбез. Автор теманың образлылыгын көчәйтүгә ныграк игътибар биргән. Шулай ук Х. Якуповның картинасы да үзенчә аерылып тора. Портреттагы соры-нейтраль, тыныч фонда динамизм, шагыйрьнең иҗат энергиясенә ишарә сизелә. Яшьрәк буын рәссамнар Р. Имашевның «Көзге җилләр», Ш. Шәйдуллинның «Шагыйрь» дип исемләнгән композицияләрендә фон гына түгел, ә әдипнең буй-сыны да көчле динамизм белән өртелгән. Әлеге әсәрләрдә сызыклар экспрессиясенә төсләр экспрессиясе өстәлә. Киеренкелек белән тулы полотноның һәрбер мыскалы «сулый» шикелле. Портретларның икенчесендә образ төсләр балкышы, декоратив чишелеш аша бирелгән. «Көзге җилләр» исемле портретның киеренке композицион чишелеше, аерым алганда, көзге ачы җилдә торган шагыйрьнең гәүдә тотышы, сурәтләнеше якынлашып килүче яңа социаль үзгәрешләр давылын күрсәтүгә хезмәт иттерелә.

Көзге төн, ямьсез, караңгы... Өй түрендә җил җылый;
Җил хәбәр ул: ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

Бу портретлар галереясында Ф. Әминевның «документлаштырылган» портретлар традициясендә иҗат ителгән әсәре үзенчәлекле урын алып тора. Беренче карашка фото-сурәтне хәтерләтүче әлеге портретта без шагыйрьнең тормыштагыча табигый торышын күрәбез. Әмма төсләр бирелешендә автор үзе сайлаган принциптан читләшә — реаль штрихларга декоратив характердагы образлылык элементлары өсти. Җиңелчә якты бизәкле фон, әйтерсең, шагыйрьнең саф күңеленнән нурланган. Өстәлдәге әшьяулыкның җете төстәге бизәкләренә дә образны ачарга ярдәм итүче мәгънә-төсмерләр салынган. Һәм нәтиҗәдә органик яктан бер бөтен, фотографик сурәтләүдән ерак торган камил образ күз алдына килә. Шул ук вакытта әлеге портрет ышандыручанлыгы, күренмәс нечкә җепләре белән социаль тирәнлеккә бәйләнгән булуы ягыннан аерылып тора.

Шагыйрьне гражданин буларак формалаштырган социаль җирлеккә игътибар юнәлтү, әйе, әсәрнең әһәмиятен бермә-бер арттыра. Мондый портретлар байтак. Әмма сынлы сәнгатебездә Г. Тукайның рухи эволюциясен, шагыйрь яшәгән заманның тулы бер социаль панорамасын күрсәткән әсәрләр сирәк очрый. Дөрес, теманы үзләштерүнең беренче этапларында шуңа охшашлы картиналар күренгәләде. Әйтик, И. Хәлиуллованың «Крестьяннар авыру Тукай янында», В. Кудельнинның «Тукай Кырлайда» исемле әсәрләрен шундый полотнолар рәтенә кертергә мөмкин. Эчтәлек ягыннан шактый киң мәгълүмат бирсәләр дә, аларда чиктән тыш детальләштерү һәм декоратив ярлылык сизелә. Бүгенге көндә иҗат ителә торган әсәрләрдә исә «өстән-өстәнлек»кә китерүче гомумиләштерү белән чамадан тыш мавыгу күзәтелә башлады. Мондый портретларда чор рухы да, образ тирәнлеге дә җитәрлек ачылмый (мәсәлән, И. Әхмәдиевнең «Казан», В. Аршиновның «Кабан» әсәрләре).

Тукай тематикасын үзләштерүдә Х. Казаковның «Тукай Печән базарында» исемле картинасы үзенчәлекле казаныш булырга хаклы. Әлеге әсәрнең сюжетындагы иллюстрация-лелек, персонажларны сурәтләүдәге схемалылык композицион чишелешнең әдәби нигезгә корылган булуы белән аклана.

Бер заман бардым Печән базарына,
Шунда мин таптым азык язарыма.

«Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасы геройларын Г. Тукай турыдан-туры тормышта очраткан кебек, рәссам да, шагыйрь принцибына ияреп, үзенең картинасын шундый ук сюжетка кора һәм шушы ук әдәби әсәр геройларын җанландыра. Реакцион ишаннар, фанатик муллалар, йөрәкләрен май баскан сәүдәгәрләр, надан шәкертләр, һәрвакыт искәнеп йөрүче җантимерләр... Әлеге социаль типлар картинада шагыйрь билгеләгән мохитта сурәтләнә. Композиция үзәгендә — үз юлыннан тайпылмыйча атлаучы, берниндә эзәрлекләүләргә дә бирешмәүче туры Тукай. Кулына шагыйрь китабын тоткан яшь җилкенчәк Тукай идеяләрен киләчәккә илтүче символик герой буларак кабул ителә. Шул рәвешле рәссам темага эчке социаль-философик мәгънә бирүгә ирешкән.

Тагын шуны кабатлап әйтик, Тукай темасын үзләштерүдә реалистик җирлектәге тарихи полотнолар әлегә бик аз күренә. Бүгенге көндә лирик-поэтик һәм философик линия төп юнәлеш буларак кала бирә.

Шагыйрь образының идея-эмоциональ, философик эчтәлегенең традицион кысалардагы портретларга гына сыешмавы катлаулырак формалар, әйтик, портрет-картина (Ш. Шәйдуллин, Р. Имашев) тууга гына китерми, ә сюжетлы тематик картиналар өчен ятрак булган эксперименталь чишелешләр эзләүгә дә этәрә (Х. Казаков, Ә. Фәсхетдинов). Югарыда телгә алынган жанрларны һәм шулай ук картина-пейзаж, «картина-җыр» кебек

тәрләрне, Шүрәле, Су анасы кебек шагыйрь хыялындагы әкияти затларның төрле сурәтләнешләрен берләштергән стилистик бербөтен идея-тематик цикллар күренә башлады. Тукай темасын актив үзләштерүчеләрдән саналучы Ф. Әминев нәкъ менә шундый синтезны якынрак күрә. Ленинградта яшәүче әлеге рәссамның нәкыш әсәрләрендә, тематик картиналар һәм портретларында тормыш дөреслеге белән шигъри күзаллама, документаль нигез белән иҗади фантазия үзара табигый рәвештә кушыла («Тукайның балачагы», «Сабан туе», «К. Насыйри әсәрләрен уку» һ. б. лар). Рәссамның «Тукай Кырлайда» исемле картинасы шагыйрь образын новаторларча гәүдәләндерүе ягыннан аерылып тора. Биредә образ шигъри фольклор җирлегендә, «Шүрәле» әсәрендәгечә, әкияти табигать хозурлыгында сурәтләнә. Шундый ук принцип кечкенә Габдулланы каенлык арасында күрсәткән картинада да дәвам иттерелә.

«Шүрәле урманы» картинасы Ф. Әминевнең иң уңышлы әсәрләреннән санала. Полотнода кара урман стихиясе, кабатланмас Шүрәле образының «ватаны» бөтен тулылыгы белән ачыла. Тукайны әдәби геройлары арасында гәүдәләндергән картинада исә әкияти образлар шагыйрь хыялы призмасы аша күрсәтелә. Халык авыз иҗаты образларына — шагыйрь иҗатында еш очрый торган геройларга да рәссам сынлы сәнгатьнең күптөрле сурәтләү чаралары ярдәмендә үзенчәлекле гәүдәләнеш бирә. «Сак-Сок»ны гына алыгыз. Милли чигү үрнәкләрен уңышлы файдалану әсәргә үзгә җанлылык өсти.

Кабатланмас осталык белән эшләнгән икенче бер әсәр — Кырлайга багышланган триптихта Ф. Әминев шагыйрьгә бетмәс-төкәнмәс илһам биргән реаль табигать күренешләренә таяна. «Кырлай». Триптихның беренче өлеше. «Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным булганга...» Шагыйрь истәлекләрендәге шундый сүзләр күңелдә яңара. Рәссам белән бергә без дә Кырлайга изге-мөкатдәс урын итеп карыйбыз.

...Елгага алып төшүче сукмак «котырып үскән» үлән һәм чәчәкләргә күмелгән. Иңенә бизәкле кәүнтә салган кыз һәм чәчәкле күлмәк кигән кызчыкның кояшта янган йөзләре, сыгылып торган зифа буйлары табигать гүзәллегенә аерылгысыз рәвештә кушылып китәләр шикелле. Картинада өстенлек алучы алтынсу якты төс шагыйрьнең хыялына канат биргән авылның кадерле булуын басым ясап аңлатырга булышкан.

Триптихның икенче өлешендә гамьле-уйлы Былтыр сурәтләнә. Шушында ук без аның авыр тормыштагы таянычы — ак атны да күрәбез. Чынлыктагы Кырлай урманы тоныкай яктысында төрле әкияти затлар яшеренгән карурман булып гәүдәләнә. Әлеге полотноларның барысында да табигатькә әкияти караш, турыдан-туры фольклор белән бәйләнеш сизелә. Мондый тенденция әсәрләрнең исемнәрендә дә күренә: «Салкын чишмә», «Су буе»... Бу картиналарда шигъри образларның эчтәлеге бөтен тирәнлегендә ачылган.

Соңгы елларда теманы үзләштерүдә, сюжетлы картиналар белән беррәттән, яңа формалар да, аерым алганда, катлаулы, «күп катламлы» картиналар — метафорик һәм аллегорик әсәрләр күренә башлады. Мәсәлән, А. Абзгильдинның «Тукай төше», Ә. Фәсхетдиновның «Тукай оныклары» кебек әсәрләре тыгыз, күп сыйдырышлы образларга бай булулары белән игътибарны җәлеп итәләр. Шулай ук И. Әхмәдиевнең «Тәфтиләү» исемле картинасы да образлы чишелеш ягыннан шактый кызыклы. Биредә шул исемдәге әдәби әсәр уяткан эмоциональ уй-фикерләр шәрыкка хас нечкә декоративлык рәвешендә чагылыш тапкан. Шагыйрь образын сурәтләүдә автор контрастлыктан оста файдаланган.

«Әгәр Поэзияне һәм аның асылын аллегорик рәвештә сурәтләрлек зур дивар булса, мин мондый катлаулы монументаль мәсьәләне чишәргә бик теләп алынып идем... Безнең бөтен буын Тукайлы поэзияне укып үсте...»

Дивар рәссамнәренә тартым әсәрләре белән тынылган нәкышче һәм монументалист А. Абзгильдин шагыйрьне ихлас ярату белән әйтелгән әлеге сүзләренә һәрвакыт тугрылыклы булып калырга омтыла. Рәссамның әлеге Тукай темасына багышланган полотнолары композицион һәм техник чишелешләре ягыннан бик үзенчәлекле. «Тукай төше»н искә төшерик. Шагыйрь гомерендәге кайбер әһәмиятле вакыйгаларны чагылдырган күренешләр әсәрдә бербөтен композициягә берләштерелгән. Тукай төшләре... һәрберсенә тирән мәгънә салынган. Бирелеп гармунда уйнаучы малай... Җиңелчә баш әйләнүне хәтерләтеп, борынгы Казан силуэтларының һавада тирбәлүе... Атлар... Чәчәкләр... Шагыйрьнең хыял-төшен «өзелүдән саклап торучы» хатын-кызлар... Әдипнең үткән юллары, иҗат мирасының киләчәге турында уйланулар менә шулай реаль картинага әверелә.

«Тукай һәм Шүрәле» дип исемләнгән әсәр дә безне үзенең гадәти булмаган колориты белән җәлеп итә. Биредә шагыйрь һәм «табигать иркәсе» серлелек белән тулы төнге пейзаж фонында ,рәтләнә. Картинадагы җете зәңгәр төстә әллә нинди әкияти тирәнлек чалымлана. мтаклы Эль Греко персонажлары хәтергә килә. Геройның көчле кичерешләре йөзенә чыккан... Гомумән, фантастик гәүдәләнештәге киеренкелек образны философик һәм драматик яктан тагын да тирәнәйтә.

Күренгәнчә, сынлы сәнгать алдындагы катлаулы мәсьәләләрне чишү юнәлешендәге эзләнүләр табигый рәвештә иҗат алымнарының катлаулануына, сурәтләү чараларының синтезлашуына да китерә. Мондый тенденция, бер яктан, нәкыш һәм графиканың үзара

кушылуында күренсә (И. Әхмәдиев, Ф. Әминев), икенче яктан, нәкыш белән монументаль сәнгать арасындагы синтезлашуда күзәтелә (А. Абзгильдин). Менә шул рәвешле Татарстан сынлы сәнгатендә «күзгә бәрелеп торган» образны гына түгел, ә иҗат шәхесенең аерым гомер этапларында кичергәннәрен дә үтәли чагылдыручы яңа типтагы картиналар күренә башлады. Мондый күренеш, һичшиксез, сәнгатебезнең тагын да баюына китерә.

Тукай тематикасын үзенчәлекле рәвештә киңәйтүче пейзаж картиналарының бер төрләре конкрет тасвирлау һәм иллюстрацияләүгә корылган булса, икенче төрләре шагыйрь язмышының асылы турындагы уйлануларны чагылдыралар. Аларны пейзаж-күренешләр дип тә исемләргә мөмкиндер.

Пейзаж остасы Н. Кузнецовның нәкыш-миниатюраларында Тукай истәлекләрен кадерләп саклаучы Кырлай, Кушлавыч, Өчиле, шулай ук Казан, Җаек (Уральск), Әстерхан күренешләре сурәтләнә. һәрбер пейзаждан илаһи бер яктылык сирпелә. Колоритлылык ягыннан аерылып торган әлеге картиналарда сөекле Тукаебызның халык йөрәгендә яшәве ачык чалымлана.

Икенче бер пейзажчыбыз С. Лывин полотносында Сәгъди абзый йорты эмоциональ, «ярсу» буяулар белән гәүдәләндерелә. Алтынсу-яшел һ. б. төсләр көчеше ярдәмендә автор теманың драматизмын көчәйтебрәк күрсәтергә омтыла. Сәгъди абзый йорты... Әлеге картинага Тукай үзе аңлатма биреп тора төсле: «Сәгъди абзыйның йорты, басу капкасыннан кергәч, күп ерак түгел икән; аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә, салам түбәле бер өйгә туктадык...»

Кырлайга багышланган пейзажлар башкачарак чишелештә иҗат ителгән. Әлеге әсәрләрдә беренче чиратта киңлек күзгә ташлана. Кырлай якларын рәссам шагыйранә илһам чыганагы — Тукай күңеленә гомер буена җитәрлек хис-тәэсирләр иңдергән төбәк итеп күрсәтүгә ирешкән. һәм, гомумән, С. Лывин пейзажлары Тукай тематикасының полифоник яңгырашын көчәйтүгә хезмәт итәләр.

Скульптура югары гражданлык, фидакарьлек идеяләрен гәүдәләндерүче калку образлар — тегәлләнгән чишелешле «күзгә бәрелеп торучы» образлар белән эш итә. Скульптурада Тукай образы нәкъ менә шундый нигездә, халык бәхете өчен көрәшүче шагыйрь-гражданин буларак сынландырыла (И. Новоселов, А. Әбдрәшитов, В. Маликов һ. б. лар иҗат иткән бюстлар). Шагыйрьнең кабатланмас шәхесе, көчле иҗат ялкыны һәм рухи энергиясе салкын мәрмәр үтәли бәреп чыга.

Скульптор С. Ахун тарафыннан иҗат ителеп, 1958 елда Казанның Куйбышев мәйданына куелган Тукай һәйкәлен[1] күз алдына китерегез. Шагыйрьнең киеренке йөз чалымнары безгә күп нәрсәләр турында сөйли. Кара материалдан эшләнгән постамент композициягә катгыйлык һәм шул ук вакытта бөеклек биреп тора. һәйкәлнең классик стильдәге торышына тирәлек, аерым алганда, Тукай иҗатында бик еш телгә алынган Кабан күле дә җанлылык өсти. Бу җәһәттән шуны әйтеп үтәргә кирәк: С. Ахун тарафыннан иҗат ителгән әлеге һәйкәл шәһәребездә шагыйрь образын гәүдәләндергән бердәнбер зур монументаль әсәр буларак санала. Ә калган скульптура әсәрләре әлегә «камерный-лык»тан уза алмыйлар шикелле.

Аксакал рәссам һәм скульпторыбыз Б. Урманче тарафыннан эшләнгән мәрмәр бюстта шагыйрь шәхесендәге лирик башлангычны, «мөкатдәс моң»ны бирергә омтылу күренә. Әсәр безне шул ягы белән җәлеп итә. Образны гүзәллекнең классик идеалларына туры китерергә омтылу да төсмерләнә. Антик скульптурага якынлык бюстның материалында да, портрет моделировкасының формасында да сизелә. Шулай да автор әлеге әсәрендә модельнең кабатланмас милли индивидуальлеген ачуга ирешкән. Шушы максатка омтылуда аңа шагыйрьне табигый торышта — Тукайның рухи тирәнлеген чагылдыручы үзенчәлекле («милли») позада күрсәтә алу ярдәм иткән. Шагыйрьнең бераз гына иелгән башы аның халык гаме, үз милләтенең киләчәге турында туктаусыз уйланулар белән яшәвенә ишарәли. Гомумкешелек һәм милли сыйфатларны үзара органик рәвештә куша белү осталыгы әлеге әсәрне идея-эстетик кыйммәте ягыннан күренекле скульптура үрнәкләре рәтенә куя.

«Тукай — халык шагыйре»...Үзенең бер композициясен В. Маликов әнә шулай атаган. Биредә автор туры Тукайны, аның карагруһчыларга, милли буржуазиягә каршы аяусыз көрәшүен ныграк басым ясап күрсәтергә тырышкан. Шагыйрьнең ярымфигурасы гәүдәләндерелгән материалның монолитлыгы композициягә бөтенлек, форма тыгызлыгы һәм пластик ачыклык бирергә ярдәм иткән.

Алтынсу агачтан эшләнгән бюстта исә (Н. Адылов) шагыйрь халык күңелендәге уйгамьнарне, моң-зарларны бик нечкәләп тоя алучы лирик буларак сынландырыла. Тукай тематикасын скульптор Г. Зяблицев үзенчә дәвам иттерә. Керамикадан эшләнгән композициядә Г. Тукай поэмасының кульминацион моменты — бүрәнә ярыгына Шүрәленең

[1] һәйкәл Мәскәү скульпторлары Л. Кербель, Л. Писаревский һәм архитектор Л. Павлов белән берлектә эшләнгән.

бармаклары кысылып калу мизгеле сурәтләнә. Әлеге сюжетта Былтырның куркусызлыгы һәм зирәклеге бөтен тулылыгы белән ачыла.

Шүрәле... Әлеге әкияти зат бик күп рәссамнарның игътибарын тартып торучы «магик герой»га әверелде. Мондый уникаль күренешне Г. Тукай үзе дә алдан сизгән: «Өмид юк түгел әле: бара торгач, үз арамыздан маһир рәссамнар чыгып, шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кыйлынган урманнарны — һәммәсен тәрсим кыйлап чыгарырлар».

Соклангыч күренеш: бүгенге көнгә «Шүрәле» поэмасына йөзләрчә иллюстрация ясалды. Октябрь революциясеннән соңгы чорларда шагыйрь әсәрләрен рәсемнәр белән бизәүгә ниндидер бер очрак уңаеннан гына алынсалар, соңгырак елларда үз иҗатларын бөтенләе белән диярлек Тукайның шигъри дөньясына багышлаган рәссамнар барлыкка килде. Алар нигездә өчәү: Б. Альменов, Ф. Әминев, Б. Урманче. Әлеге мөхтәрәм осталар Шүрәленең үзгә «генеалогия»сен тудырып, образны интерпретацияләүгә гаять зур өлеш керттеләр. Алар тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр, һичшиксез, махсус рәвештә өйрәнүгә лаек.

Шүрәле һәм башка шундый әкияти затларны Т. Хаҗиәхмәтов, В. Аршинов, Н. Әлмиев, А. Туманов кебек чагыштырмача яшьрәк рәссамнар да үзләренчә җанландырдылар. Аларның әсәрләрендә яңалыкка омтылу шактый көчле сизелә. Шулай ук Су анасы образын сурәтләүдә дә В. Карамышев, Ю. Каспина кебек рәссамнар үзенчәлекле штрихлар өстәделәр. Тукай тематикасын үзенчә үстерүче И. Колмогорцеваның да шагыйрь мәсәлләренә ясаган иллюстрацияләре шактый кызыклы, Тукайга бәйле урыннарны чагылдырган М. Мавровская, «Исемдә калганнар»ны иллюстрацияләгән Ф. Хасьянова рәсемнәрендә дә иҗат алымнарын һәм сурәтләү чараларын баету юнәлешендә эзләнү күзгә ташлана. Бу уңайдан шуны басым ясап әйтергә кирәк: Т. Хаҗиәхмәтовның шагыйрь әсәрләренә, аерым алганда, аның балалар өчен чыгарылган китабына ясаган иллюстрацияләре республика китап сәнгатенең казанышына әверелде.

Тукай иҗаты — иксез-чиксез дөнья... Тукайның шигъри дөньясындагы бетмәс-төкәнмәс байлыклар тагын да камилрәк сурәтләү формаларын көтәләр. Гомумән, шагыйрь мирасын үзләштерү рәссамнарыбызны чын мәгънәсендә халыкчан сәнгать белән өзлексез бәйләнештә яшәтә. Күп тармаклы татар сынлы сәнгате Тукай иҗаты аша халкыбызның рухи потенциалы, гасырлар буе туплана килгән эстетик һәм этик байлыгы тирәнлекләренә төшүен дәвам иттерә.

# ПЕЧӘН ӨСТЕ



...Клара Булатова шигырьләрен кайта-кайта укыйм. Һәм гаҗәп хәл: укыган саен, алар үзләренең яңа яклары белән ачылалар. Югыйсә, гап-гади алар — аяктан егарлык чагыштырулар да, оригинальлеккә омтылып язылган ясалма юллар да юк. Геройлары да шушы үзебезнең җирлек кешеләре — председатель Алмаз, җөйче Гөлсем, укытучы Галимәләр... Иң беренче чиратта нәкъ менә шул гадилеге, тиз аңлаешлы булулары белән дә җәлеп итәләр икән ул шигырьләр.

Үзенең бер мәкаләсендә шагыйрь Гамил Афзал аны «башы-аягы белән авыл шагыйрәсе» дип атаган иде. Бу урында танылган шагыйребез белән бераз бәхәскә керәсе килә. Чыннан да, шагыйрәнең күпчелек шигырьләре авылга, авыл хезмәтчәннәренә багышланганнар. Тик авыл шагыйрәсе генә дип әйтү К. Булатова иҗатын артык тарайту булыр иде. Себергә, Кырымга, Әлмәт шәһәренә багышланган циклларны кая куясың?! Биредә бер әйбер ачык: сандугач талга кунып сайраса да, каенга кунып сайраса да, барыбер сандугач булып кала!

Клара Булатова шигырьләрендә күзгә бәрелеп торган иң беренче матур сыйфат — аларда күңел кичерешләренең табигать мизгелләренә тыгыз бәйләнеп бирелүе. Ул шушы Җир кызы, шигырьләренә дә шушы яктан, шушы туфрактан килеп керә. Китап исемнәренә генә күз салыйк: «Җәйләр җитсә», «Язлар алда», «Гел кояшка карап», «Печән өсте» (соңгысы быел Татарстан китап нәшриятында басыла). Күргәнебезчә, шагыйрә өчен шушы як кадерле, чөнки «мәтрүшкәләр монда хуш ислерәк, ромашкалар монда эрерәк».

Шушы яктан, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата,—

кебек юлларында шагыйрә туган якның матурлыгын җырлый, аның белән горурлана.

Шагыйрә иҗатында тагын бер калку сыйфат — ул да булса хатын-кыз кичерешләрен һәрьяклап ачу. Күп кенә шигырьләрендә ул Ана булып та, бала булып та уйлый. Шуның белән шагыйрә буыннар бәйләнешен ныгыта, үткәнне киләчәккә тоташтыра. Әйтик, бер шигырендә: «Әнкәй, сиңа ак чәчләрне күрсәтмим мин, алар өчен оят миңа синең алда»,— дип әнисенә мөрәҗәгать итсә, шунда ук улы турында сөйләүгә күчә һәм аның рәсем ясаганын күреп болай ди:

Дәфтәренә бала чиста язны,
Якты Майны куйган күчереп...
Сакла, тормыш, бөтен шул дөньяны,
Вата күрмә аны, кешелек!

Бала психологиясен гади һәм шул ук вакытта оста итеп ачу шагыйрәнең «Марс китабы»нда ачык чагыла. Бу китап балалар тарафыннан да, олылар тарафыннан да җылы каршыланды һәм К. Булатованың балалар поэзиясендә дә уңышлы эшли алу мөмкинлекләрен күрсәтте. Моңа шагыйрәнең укытучы булып эшләве һәм һәрчак балалар арасында яшәве нигез булып тора. Балалар өчен язучы шагыйрьләребезнең азлыгын исәпкә алганда, шагыйрәнең бу юнәлештә дә актив иҗат итүен теләргә кала.

Клара Булатова иҗатында тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә калган тагын бер тема — ул Бөек Ватан сугышы темасы. Балачагы сугыш елларына туры килгәннәр исеменнән сөйләнгән шигырьләр аның «Һәрвакыт янымда» дигән җыентыгында күп урын алган иде һәм азмы-күпме һәр китабында кабатланып килә.

Песи борчаклары чүпләп йөрдем
Җимерелгән читән буенда.
Килмәсен лә, мәңге килмәсен лә
Мондый дәһшәт килер буынга,—

дип, ул үз буыны кичергәннәрне бөтен драматизмы белән күрсәтеп бирә һәм киләчәк буын сугышсыз яшәсен иде, дип борчыла.

Шагыйрәнең күпләр яратып тыңлый, укыганда күзләрдән яшь китерә торган «Сиңа кайтам» дигән шигыре бар. Югыйсә темасы һич тә яңа түгел бу шигырьнең: әдәбиятта борынгыдан килә торган тема — мәхәббәт. Шигырь нинди сыйфаты белән алдыра соң? Автор бирердә кайберәүләр кебек «ах, яшьлегем үтте» дип сыкрамый, ә тәүге мәхәббәтнең, беренче хисләрнең матурлыгын шигъри детальләр, отышлы табылган чагыштырулар аша укучыга күрсәтеп бирә. Ул аны шулхәтле эчкерсез, шулкадәр самими итеп сөйли ки, шигырьне укыганда син үзең дә геройның «хәлен»ә керәсең, ул булып уйлый башлыйсың. Поэзиянең көче дә шундадыр, мөгаен.

Мин К. Булатованың һәр тапканы алтын дип әйтергә җыенмыйм. Беренче язганнары белән үк поэзия сөючеләрне дә, өлкән шагыйрьләребезнең дә игътибарын җәлеп иткән шагыйрә иҗатында бер урында таптану, баштагы уңышлардан бераз артка чигенү булып алды. Бу хәл бигрәк тә җитмешенче еллар уртасына карый. Шагыйрәнең шушы чордагы иҗатында төшенкелек мотивлары яңгыраган, вак шәхси кичерешләргә генә корылган, сентименталь шигырьләре дә күренгәләде. Тик бу чор да шагыйрә өчен эзсез үтмәде: елдан-ел аның тавышы ныгый барды, һәм сиксәненче еллар башында инде без үз шәхесеннән дөньяви мәсьәләләр, илкүләм мөһим вакыйгалар турында җитди уйлануларга чыккан шагыйрәне күрәбез. Клара Булатова һәр шигырьгә үз темасы, үз образлары белән килә, вакыйгаларны үзенчә күрә һәм сурәтли белә. Шагыйрәнең «Кешегә мәдхия» дигән шигырен карап китик:

Син, табигать, безсез —
Телсез, төссез.
Синдә аккан сулар салган эз,
Синдә үскән урман,
Төшкән томан
Нигә кирәк булсын кешесез?
О, бәхәссез!
Синең ташлар ярыр,
Тау актарыр кыргый көчең бар.
Ул көч җиргә бәла булыр иде,—
Ярый әле шуны җиңә белгән,
Эшкә җигә белгән кешең бар.

Бу юллардан без К. Булатованы шәхси кичерешләре эченә генә бикләнеп ятмый торган, ә фәлсәфи-хисси шагыйрә итеп күрәбез.

Ул үз шигырьләрендә халык авыз иҗатын киң куллана. Халыкчан интонацияләр белән өртелгән «Кыз җыры», «Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Бию көе», «Сабан туе иртәгә» кебек шигырьләрдә сөйләм телебездә инде онытылып бара торган матур тәгъбирләрне, сүз уйнаткычларны очратабыз.

Асылмалы күпер, асылмалы,
Алты үттем күпер аркылы.
Алты үттем, күңелем басылмады,
Басылмаска кушкан, ахры.

Күпер төбе генә зәңгәр капка,
Тугыз гына түгел, ун такта.
Капка бавын ятлар тарткан чакта
Үз дигәнем йөри еракта.

Инде җырга әйләнгән бу юлларда без өлгергән, җитди шагыйрәне күрәбез һәм шунлыктан аннан тагын да матуррак шигырьләр көтәргә хаклыбыз.

Шагыйрәнең шигырьләре тыңлаучыларга (бигрәк тә үзе укыганда) ничек тәэсир иткәнен карап торганым бар. Әйе, йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып җитә диләр. Шулайдыр, шагыйрьнең үзе турында аның шигырьләреннән дә көчлерәк итеп әйтеп булмыйдыр...

Өндәү билгеседәй туры
Калырга күпме тырыш —
Сорау билгесе шикелле
Бөгә дә куя тормыш.

Калмады бугай күрмәгән
Шул тормыш юлларында.
Яшәүдән шулай мин мәгәр
Туярга уйламыйм да!

Болай дип тормышның ачысын да, төчесен дә күргән, кичергән кеше генә әйтә ала.

Алтмышынчы еллар уртасында поэзиягә килеп, күпләрнең игътибарын җәлеп иткән Клара Булатова да үзенең печән өстенә — илле яшенә җитте. Бу еллар эчендә ул авыр балачак та кичергән, югары белем дә алган, Әлмәт шәһәрен төзүдә дә катнашкан, мәктәптә балалар да укыткан, кияүгә чыгып, үзе дә малай үстергән, эти-әнисен караган... Һәм шул ук вакытта шигырьләр язган! Ә бит кешеләр күңелен яуларлык шигырьләр иҗат итү өчен хатын-кызга икеләтә кыюлык, чын мәгънәсендә батырлык та кирәк әле!

Менә егерме елга якын инде ул урта мәктәптә укыта, укучыларда ана теленә, әдәбиятыбызга мәхәббәт тәрбияли. Аның укучылары арасында без югары белемле инженерларны да, укытучыларны да, төзүчеләрне дә, эшче-колхозчыларны да очратабыз. Бүген Әлмәт районындагы Колшәрип, Яңа Кәшер, Сөләй, Югары Мактама мәктәпләрен тәмамлаучыларның күбесе «безне шагыйрә Клара апа укытты» дип горурланып әйтә икән, моңа да гаҗәпләнергә кирәкми.

...Клара Булатова иҗатында чын-чынлап печән өсте. Аның әле без күрмәгән, матбугатта чыкмаган, бары үз күңелендә генә йөрткән матур-матур шигырьләре күп, иҗат ниятләре зур. Шагыйрә үзе бу турыда болай ди:

Утлардан — суга, сулардан
Утына кирәсе бар.
Аласын алган бу җиргә
Әле күп бирәсе бар.

Атлас ГАФИЯТОВ.

# Клара Булатова

## ХӘТЕР ТӘРӘЗӘЛӘРЕ

Колшәрип басуларына
Зәңгәрләнеп таң инде.
Таңнарны шул басуларда
Каршылаган бар иде.
Шул якка карый тутырып
Палата тәрәзәсе.
Таңнарда качыпмы чыгып
Әллә бер әйләнәсе...
Бар әле, күңел, эзлә әле,
Табылмас микән шунда
Яшьлекнең тирән эзләре —
Сай Дөмәй елгасында?
Җәяү дә йөри идең син,
Җайдак та йөри идең,
Яшь идең, ару-талуны,
Авыруны белми идең.
Яз булса чәчүчеләр дә,
Җәй булса уракчылар
Көтәләр иде үзеңне:
«Кайчан,— дип,— килеп чыгар?»
Телләрең җырны-шигырьне
Гел көйләп торгангамы,
«Тургай» дип йөртте үзеңне
Әшерәп Галимҗаны.

...Бүген дә әле урының
Колшәриптәдер кебек.
Дөмәйдә күчмә вагоннар
Гәҗит көтәдер кебек.
Ярышлар нәтиҗәсен дә
Куясы бардыр элеп.
Кил әле, Галимҗан абый,
Тимеркүгеңне җигеп.
Мин үзем йөргән алаша
Үлгән диделәр күптән,
Картаеп үлгәндер инде,
Әллә сагынып микән?
Сагыныр... аңа атлансам,
Күпме кыр урый иде.
Аңласа-аңламаса да
Җырымны тыңлый иде.
Бер җырлый белми идем мин,
Гел җырлап йөри идем
Үзем уйлаган җырларның
Үзем чыгарган көен.
Син шуңа мине «тургай» дип
Атаган идең көлеп...
Кил әле, Галимҗан абый,
Тимеркүгеңне җигеп,

Кырчылар килеп җиткәнче
Газетны куйыйк элеп.
Кем нинди урын алган да,
Кем нигә артта калган? —
Саннарын гына бир миңа —
Барын да җырга салам.
Кайсы хак, кайсы нахагын
Укырлар, тикшерерләр.
Ә Назил белән Разил
Барыбер кичерерләр.
Ә Назил белән Разил
Ярышның уртасында.
Аларның һаман я берсе,
Я берсе алдын чыга.
Бу ике егет, ике дус
Көндәшме эштә генә? —
Кем белсен, аның серләре
Калды яшьлектә генә.
Таңнарда шул кырга чыгып
Килә бер әйләнәсе.
Шул якка карый тутырып
Хәтерем тәрәзәсе.

## Өмет җыры

Яңадан килде бу язлар,
Җемелди күлләвекләр.
Тибрәнә күктә тургайлар,
Йөгерә гөрләвекләр.
Йөгерә-ага кар суы,
Челтерәп ага көлеп.
Ачыла уҗым басуы
Ямь-яшел хәтфә кебек.

Кар суы, туктат юлыңны,
Тукта да җиргә сыен.
Җиргә сал шифа-дымыңны,
Шул булыр безгә сыең.

Җәйлектә басу ашлыгы
Сусаудан кибәмәсен.
Таңнарны төнгә ялгаучы
Игенче көенмәсен.

Кал безнең җирдә, кар суы,
Җир куены иркен безнең.
Ямь-яшел уҗым басуы
Сап-сары булсын көзен,
Шауласын алтын башаклар,
Шауласын кырлар тулып.
Безнең эш кайтсын зур уңыш
Һәм матур җырлар булып.

## Сугыш чорындагы балачактан

Кол Галидән калган шигъри сүрә,
Борынгылар язган берәр дастан...
Кайта-кайта төшкә шулар керә
Сугыш чорындагы балачактан.

Мич буенда олы яшел сандык,
Әни өскә палас шәлен япкан.
Көйле әсәр укыйм, ятлап алып
Кулга килеп кергән һәр китаптан.

Җыелалар кичен солдаткалар,
Безнең өйдә якты — бишле лампы.
Күз яшьләре белән тыңлый алар
Көйләп мин укыган һәр китапны.

Кулларында орчык, кем җеп каткан,
Биш инәсе кемдер алып килгән,
Атар өчен җайлы автоматтан —
Бияләйләр ике бармак белән.

Мич буенда олы яшел сандык,
Яшерен байлык анда — китап тулган,

Яттан бикләп, берәм-берәм алып,
Көйләп-сөйләп кичен мин утырам.

«Ләйлә-Мәҗнүн» анда, «Таһир-Зөһрә»,
«Изге Йосыф», тагын әлләниләр,
Мәктәптә дә беркем ишетмәгән
Низамилар, Сәгъди, Фирдәүсиләр.

Әниемнең Олы, Бай бирнәсе
Мирас булып миңа шуннан күчкән,
Шул бәһасез сандык хәзинәсе
Балачактан мине шагыйрь иткән.

Ул әдипләр яши: дәресләрдә
Әсәрләрен бүген сөйлим яттан...
Ә төшемә яшел сандык керә
Сугыш чорындагы балачактан.

●

Риза булса җаның бүгенгеңә,
Канәгатьлек тулса күңелеңә,
Китәм димәс телең — торган җирдән,
Кайтам димәс — туган илеңә.

Кайнамаса төптә үткәннәрең,
Өндәмәсә өстә иртәгең —
Син кайда да янмый-көйми генә
Күзәтерсең Гомер үткәнен.

Тамырыңны әмма, Дәвамыңны
Уйларында йөртсәң, фикердә —
Оныта алмассың Туган Туфрагыңны,
Таба алмассың Бәхет чит илдә.

●

Кошлар өчен, биек очар өчен
Һава гына кирәк, канат бар,
Минем өчен — үсәр, очар өчен
Кирәк әле терәк канатлар.

Күңел кошкайларым талпына да
Каурый-канатларым талчыга,
Шул чакларда өндәр юлдаш булып
Килеп чыксаң иде каршыма.

●

Гаҗәпләнеп шуны карап торам,
Чагыштырып тыңлап утырам.
Диңгез йоклый алмый иза чигә,
Таулар айный алмый йокыдан.

Ә үзләре мәңге янәшәдә.
Без дә шулар кебек ахыры,
Синең җанда таулар тынычлыгы,
Минем җанда диңгез ярсуы.

●

Үзеңне күрепләр күзем туймый,
Иркәләп-сөепләр кулым туймый,
Исемеңне күңелем, телем куймый —
Синеңчә, бу ни соң сөю булмый?
Синеңчә, нәрсә соң бу сөю булмый?

Үзеңне күрепләр күзем туймый,
Янымда күңелем сине уйлый,
Син юкта күңелем сине уйлый,
Синеңчә, бу ни соң сөю булмый?
Синеңчә, нәрсә соң бу сөю булмый?

Үзеңне күрепләр күзем туймый,
Янымда син барда җырым тынмый,
Син юкта сагыштан җаным тынмый,
Синеңчә, бу ни соң сөю булмый?
Синеңчә, нәрсә соң бу сөю булмый?!

●

Көн алмашкан, юл адашкан —
Кире кайткан җилләре.
Күбәләк кар, уйнаклап кал,
Мартның соңгы көннәре.

Кем күзәтә: ни үзгәртә
Табигатьнең гадәтен?
Күбәләк кар, уйнаклап кал,
Җиткән соңгы сәгатең.

Вакыт — Алдар, бу килгән яз
Кире чигәр дисеңме?
Алданма, кар, гомерең аз
Безнең яшьлек шикелле...

Агарган тыш, яңадан кыш
Кайтуына ышанып.
Күбәләк кар, уйнаклап кал,
Соңгы тапкыр очынып.

●

Зәңгәр күзләр җырлап яшьлек үтте,
Зәңгәр хыял җебен сүтә-сүтә...
Зәңгәр төсләр күптән уңып бетте,
Соры күзгә карап гомер үтә.

Аккан судай агып үтә еллар,
Туңтау белми тормыш җиле исә;
Үз дәвамым булып, тупырчындай
Кара чутыр тере малай үсә.

●

Агачлардан яфрак өзәм,
Саклаганын җәй төсен.
Шул бер учма яшеллектән
Күңелләргә җәй иңсен.

Көзен җанга моңсу икән
Үзең бер ямь бирмәсәң,
Язлар үткән, инде күптән
Җәйләр өчен көрәшәм.

Әле бүген көзләр моңын
Нәрсә дисәм киметкән —
Бер сөенер көн икән бу,
Сезне күрер көн икән.

Юкка гына әйтелгәнме:
«Бер күрешү — бер гомер».
Тибри күңел, бәлки әле
Гел үк көз дә түгелдер.



*Шагыйрь Әхмәт Рәшитовка 50 яшь тулды.*

*Әхмәт Әхәт улы Рәшитов 1936 елның 25 мартында Буа районы Яңа Чәчкап авылында туа. Тугыз яшьтән тулы ятим калган Әхмәт кардәшләре гаиләсендә тәрбияләнеп үсә; башта туган авылында укый, аннары Буада М. Вахитов исемендәге урта мәктәпне тәмамлый. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда, Казахстанга китеп, бер ел Төркестан-Себер тимер юлында (Семипалатинск шәһәрендә) эшли. Университетны 1960 елда тәмамлагач, ул Апас районы газетасы, Казан һәм Лениногорск телестудияләре, Казан радиосы һәм «Социалистик Татарстан» газетасы редакцияләрендә хезмәт итә. 1976 елдан башлап, ул — Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубы директоры.*

*Ә. Рәшитов иртә яза башлый: авылда шагыйрь саналып йөртелгән, сугышка кадәр спектакльләр куеп, әдәби-музыкаль кичәләр оештырган әтисе йогынтысында ул яшьтән культура тормышында катнаша, комсомол эшләрендә башлап йөри.*

*1952 елдан аның исеме республика матбугатында күренә башлый: башта район газетасы, аннары «Чаян», «Ялкын» журналлары, өлкә газеталары... күмәк китаплар...*

*Шагыйрьнең «Хатирә» (1972), «Сәяхәтнамә» (1978), «Киек Каз юлы» (1982), «Күңел кыңгыраулары» (1986) исемле татарча һәм «Млечный путь» исемле (1983, Мәскәү) русча китаплары дөнья күрде. 1983 елда ул нәниләргә багышлап «Кояшлы ил — бәхет иле» исемле китабын бастырып чыгарды.*

*Ә. Рәшитовның аерым әсәрләре украин, казах, латыш, каракалпак, чуваш һ. б. телләрдә дә басылды; үзәк матбугатта — журнал һәм газеталарда да шагыйрьнең исеме еш күренә килде. Ул тәрҗемә өлкәсендә дә көчен сынап карады: Абай һәм Әҗинияз шигырьләрен татарча яңгыратуга иреште.*

*Шагыйрь публицист буларак та актив эшли, әдәби мәсьәләләргә бәйләнешле мәкаләләр язып, матур әдәбиятны, каләмдәшләре иҗатын пропагандалауда катнаша.*

*Күп санлы укучыларыбыз исеменнән юбилее белән котлап, бу санда шагыйрьнең «Автопортретка штрихлар» исемле яңа әсәрен тәкъдим итәбез.*

**Әхмәт Рәшитов**

# АВТОПОРТРЕТКА ШТРИХЛАР

## I

*Казанский сирота,*
*Җырлата да елата...*

Җыр.

Ә ул көнне Идел моңсу иде,
Ике күзем тоташ дымсу иде,
Утлар йота-йота акчам юкка,
Утырдым да ап-ак пароходка,

Бәхет эзләп чыктым ерак юлга —
Бәләләргә ничек тарымыйсың?!
Билетсыз да көе ак бәхеткә
Ак пароход алып барырмы соң?
Егет «борнап» килгән чая вакыт —
Кыз, кыз, диеп күңел өтәләнә;
Их, күн итек киеп, костюм киеп
«Форсить итсәң» иде шулай әнә...
Их, туйганчы бер ашасаң иде —
Юк, тәм-томнар түгел, ипи генә.
Гел үләннән торган комплекс аш
Күз алдыннан һаман китми менә.
Җыр юатты мине, кояш сөйде —
Күңел нечкә, заман каты иде.
Мөлаем һәм кырыс юлбашчыбыз
Безнең өчен уртак әти иде.
Бөтен күзләр аңа төбәлделәр —
Әйтерсең, ул — бөек хәзинәче.
Тар-мар килгән шәһәр-авыллар һәм...
Без булганбыз илнең хәзинәсе.
Яланаяк көе... һәм яланбаш...—
Беренче кат шәһәр урамында;
Саумы, Казан — хыялларым таҗы,
Миндәй ятим күпме тора монда?!
Базарында Тукай арзан булган
Халкың улларына бәхет эзлә!
Сугышлардан калган мирас булып
Йөри, әнә, күпме әтисезләр.
Безгә үгет бирер кешеләр юк —
Шпанага мөмкин кушылырга...
Ә хыял — саф, ә йөрәктә — шигырь
Прелюдия гүя изге җырга.
Прелюдия сыман бүгенемә —
Яшәү дәрте шундый көчле иде,
Назлы анам булып яшьләремне
Сөембикә сөртер төсле иде.

II

*Ятим бала күңеле тула,*
*Күгәрчен гөрләсә дә.*

Җыр

Күз яшьләрен бары еллар сөртте —
Уйлаганым чыкты чын дөрескә;
Сыкрый-сыкрый гына нокта куйды
Үҗәт заман кырыс көнкүрешкә.
Буйлар үсмәсә дә, уйлар үсте —
Университетка рәхмәт инде!
Тормыш белән бергә икәүләшеп,
Алар тәки кеше итте мине.
Белмим, кайсы күбрәк өйрәткәндер —
Университеттырмы, тормыштырмы?
Язмышыма хөкем чыгар мәлдә
Мине яклап Идел сүз кыстырды.
Ә ул белә: йөкләр ташыганда,
Трапларның сыкрап шыгырдавын,

Усиягә[1] килер баржаларны
Кетә-кетә йөрәк чымырдавын.
Гел Маркизда[2] гына ятасы бит,
Чибәр кызга гына күз атасы!
Хәтер, хәтер! Үткәннәргә кайтып
Яраларны нигә кузгатасың?!
Булды... Булды... Пәһлеваннар сынды,
Пәһлеваннар калды авырсынып;
Кырыс чынлык әкияттәге сыман
Сорау куйды: ныкмы кавырсының?
Борын канаганнар байтак булды —
Кемдә азарт тумый ярышканда?!
Бу — яшәеш өчен изге көрәш —
Алыштан да иде, салыштан да...
Ә йөрәктән минем кичкән иде
Инде күпме тормыш сәмумнары,
Ә җилкәмә баржа трюмында
Нинди генә йөкләр салынмады?!
Рәхмәт сиңа, Идел, мең-мең рәхмәт
Бездәйләрне чит-ят итмәвеңә,
Боек чакта сөеп юатканга,
Синдә тапкан хәләл икмәгемә.
Рәхмәт сиңа, дөнья, мең-мең рәхмәт,
Утта-суда мине сынавыңа,
Шул чыныгу бәлки сәбәпчедер
Минем бүген рухи сынмавыма.

## III

*Исән булсак, бер кайтырбыз,*
*Кошлар кебек әйләнеп.*

Җыр

Киткән идек авыл юлыннан без
Каршысына башлар күрәсенең,
Рәнҗеп киткән идек, булмасмы, дип,
Куерагы тормыш өйрәсенең.
Юллар алып китте үргә таба,
Юллар алып китте еракларга.
Сагышлары юшкын булып ятты
Сәйярлыкка дучар йөрәкләргә.
«Бер кайтырбыз...» диеп китте кемдер,
Тик сәламе килде... җилләр аша...
Инде таш һәм таллар картайдылар
Якташларын илгә дәшә-дәшә.
Ә миңа ни калган? Ник ашкынам
Авылыма, күңел моңсу чакта?!
Бар дөньядан эзләп табылмаган
Изгелекләр мәллә монда ята?!
Нигә монда сабый чактагыча
Бар уйлар пакь, хисләр янә садә?

---

[1] Казанның элекке елга порты урнашкан җирләрне Усия дип йөртәләр иде. Русларның «Устье» сүзеннән алынган.
[2] Маркиз утраулары Казан халкының ял итү урыны иде. Куйбышев сусаклагычы төзелгәч, Идел төбендә калды. Автор.

Нигә әле күңел урын барлый
Анам кабере белән янәшәдә?
Авылымнан рәнҗеп киткән идем —
«Бер кайтырбыз» диеп әйттем микән?!
Әмма кайттым — кайттым күп тапкырлар,
Хәтта күчтәнәчләр төйнәп «читтән».
Төркестан һәм Себер арасында
Товар поездлары озата йөреп,
Салкын сеңгән тәнгә сихәт эзләп
Туган якка кайттым, «кошлар кебек».
Туган якка кайттым, җырләр урап,—
Һәр кайтуым — татлы төшеммени!
Ни бар монда миңа? — ятимлекне
Кабат уйлап елар өченмени?!
Картлар белән зурлап кул бирештек,
«Тәки кеше булдың...» — диде халык;
Сөендердем кайчак якташларны,
Шөгыльләрен шигъри телгә салып.
«Син кайтасың менә...» — диләр алар,—
«Безнекеләр генә вакыт тапмый».
Беләм... беләм... очрый кайберләре —
Һәм миңа да алар бер юл сапмый.
Аяныч бәлки... Туган җирдә
Рәхәт күрер чакта, михнәт чигеп
Адашып ла йөри күпме җаннар
Иманнарын җуйган манкорт кебек.
Кабат кайтыр өчен юлга чыгам —
Барыр юлым аллы-гөлле түгел,
Мәңге яшәү серен аңлатырдай
Хакыйкатьләр эзли сәйяр күңел.

## IV

*Бөдрә тал...*
*Чит җирләргә чыгып гыйбрәт ал!*

*Җыр.*

Сингапурда бөркү. Шундый бөркү!
Урам — эссе салган мунча ташы;
Йоклый алмый йөрим төне буе —
Төрле уйдан чатнар кебек башым.
Иркенлеген уйлыйм туган илнең...
Урманчеда күргән гүзәл сынны...
Уйлыйм ерак кырлар уртасында
Гомер сөргән моңсу авылымны...
Монда халык көн-төн акча саный,
Ике сүзнең берсе: мани[1]... мани...
Найт маркетта[2] чибәр «күбәләкләр»
Каш сикертеп уза:
— Һелло, җаный!
Монда бөтен дөнья ябырылган —

[1] Мани (инглизчә) — акча дигән сүз.
[2] Найт маркет — Сингапурда төнге базар.

Бер уч җирдә күпме байлык ята!
Сингапурны кемнәр сагына икән? —
Күпләргә ул вакытлыча Ватан.
Монда фимиам[1] һәм дуриан[2] исе,
Һәрнәрсәгә монда китә исең,
Күз камаша монда һәр нәрсәдән —
Базар димн аны, нәрсә дисең?!
Тик маташма, дөнья, безнең белән —
Барыбер илгә урап кайтасы без;
Кызыктырма — безне алалмассың! —
Байтак безнең ныклык запасыбыз.
Раслый алам кире кагылмаслык
Унлап, йөзләп, меңләп дәлил аша:
Ил дигәндә халкым бил бирмәгән —
Колгалидән алып Җәлилгәчә.
Әнә үзе!.. Портка кереп бара,
Белгән төсле аны әзләсемне;
Нихәл, «Җәлил», нихәл, якташ кораб,
Әле һаман илләр гизәсеңме?!
Моабиттан чыккан көннән сине
Шигъриятең җирдә илче иткән;
Кеше чакта сине күрми калдым,
Кораб чакта күрү насыйп икән!

Ялаларны, гайбәтләрне җиңеп,
Мин хәтерлим илгә кайтканыңны,
Яңгырады шулчак яңа аваз,
Хакын даулап изге ал каныңның.
Син юк чакта моңнар аз иде шул,
Такмаклар да кайчак ярадылар...
Өстән генә караучылар кисәк
Күтәрелеп өскә карадылар.
Классиклык дәгъва иткәннәргә
«Ура!» сүзе пароль иде җырда —
Аңлыйсыңдыр, Җәлил, бар иде бит
Туфансыз һәм Есенинсыз чор да.
Тел тидермим, юк, юк, өлкәннәргә —
Алар миңа шигъри иман бирде;
Иләһи сүз кайчак чатак булса,
Заманасы аның шундый иде.
Рәнҗемәсен рухы Мөдәрриснең,
Әнвәр, Зыя, Гали абыйларның[3];
Саф җаннары өчен мин аларга
Гашыйк идем...
Ләкин табынмадым.
Ут уйната иде әле алар.
Ә мин артык горур идем, шуңа
Шигыремә толкач кирәктә дә,
Тотынмадым алар чабуына.

...Мин дөньялар урап кайттым шулай
Безнең шигъриятле иркен кырга,
Татар хәятыннан аерылмыйча
Мунча кебек эссе Сингапурда.

---

[1] Фимиам — гыйбадәтханәләрдән тарала торган хуш исле һәм әчкелтем төтен.
[2] Дуриан — исе сарымсакны хәтерләткән, ләкин үзе искиткеч тәмле җимеш.
[3] Шагыйрьләр Шәрәф Мөдәррис, Әнвәр Давыдов, Зыя Мансур, Гали Хуҗи.

## V

*Утлар яна учакта;*
*Замананың авырлыгы*
*Килде безнең яшь чакка.*

Жыр.

Еллар кичкән саен күңел нечкә.
Уйдан кичерә-кичерә барын... барын...
Хыялымда инде ничәнче кат
Урап кайттым яшьлек урамнарын.
Урап кайттым, кайттым бүгенемә —
Карап торам менә сәерсенеп;
Күп хәлләргә шаһит тыкрыклардан
Эзлә хәзер берәр хәерчене!
Табып кара, язмышларын каргап,
Көн күрүче тол һәм ятимнәрне!
Наив диеп көлмә, яшь замандаш,
Бу көн сезгә бушлай тәтемәде.
Истә әле Тәтеш баскычлары
һәм Иделнең Усияле яры,
Усал заманнарның ачы җиле,
Усал заманнарның яңгыр-кары,
Сез үскәндә инде яшьләр кипкән,
Яралар да инде җөйле иде,
Пластинкада җырлар алышынган —
Йөзләр көләч, тормыш көйле иде.
Алда — гомер. Алда яшисе бар,
Утка-суга кат-кат керәсе бар.
Ярты гасыр гомер үрләреннән
Коерыклы йолдыз[1] күрәсе бар.
Ул йолдызны тагын бер күрергә
Хыялланган иде Хәсән абый.
Юраганнар бер юш килер диеп,
Гомер буе шагыйрь йолдыз саный.
Яшәсә дә җирдән аерылмыйча
Күңелендә мәңге космик чатыр;
Безнең хыялларның орбитасын
Санап-үлчәп тора alma mater[2]
Карап торам менә сәерсенеп —
Таныш та бу җирләр, юк та кебек;
Пәһлеван йорт күккә баш терәткән,
Тәрәзәләре карый матур көлеп.
Адым саен күңел очар төсле,
Адым саен арта рәхмәт хисе;
Ятлар көнләшерлек бөек илне
Бәхет иле, дими — нәрсә дисең?!
Аның белән бергә төйнәп учка
Күңелләрнең бөтен сабырлыгын,
Аның белән бергә күтәрдек без
Авыр чорда — дөнья авырлыгын.
Шуңа якын миңа һәр җиңүе,
Үткәне һәм киләчәге аның;

---

[1] Коерыклы йолдыз — татар халкы Галлей кометасын борын-борыннан шулай атап йөрткән.
[2] Alma mater — университет күздә тотыла.

Шуңа җырлыйм, җырлыйм горурланып
Тиңсез Ватанымның алсу таңын.
Сукалы һәм чабаталы чордан
Вәкаләтле вәкил булган өчен
Мин сәламлим Яңа заманны,
Мин куәтлим илнең куәт-көчен.
Дары һәм пар чоры артта калды.
Серләр чытырманын ера-ера
Бара торгач, килеп җиттек менә
Атомлы һәм ракеталы чорга.
Килеп җиттек, шигырьне дә хәзер
Формулалар белән язар чаклар;
Киләчәктә миллион кояшларга
Гомер бирер батыр «Токамак»лар.
«Токамак»лар булып кайный хисем,
Ракеталар булып оча уем;
Җир шарының асыл кыйтгасында
Бүген җиһан бәйрәм итә туен.
Ә мин барам карап киләчәккә,
Терәк булып илем теләгенә,
Алга әйди шигырь байрак булып —
Миллион кояш яна йөрәгемдә.

*1984 — 1985*



**Р. Г. Галиев,**
КПССның Әлмәт шәһәр комитеты
беренче секретаре

# НЕФТЬЧЕЛӘР ҮЗӘГЕ

1951 елга кадәр Әлмәт — зур гына авыл хуҗалыгы районы иде. Үзәгендә берничә артель, таш кибетләр, урта мәктәп һәм больница була. Районда йөзгә якын колхоз исәпләнә. Кешеләре иген игәләр, терлек асрыйлар. Төп ярдәмчеләре ат һәм үгез санала. Шуңа күрә дә көлтәгә бәйләнгән игеннәрне кыш буе суктырырга туры килә.

Әлмәт авылының тарихы, халык авыз иҗатына караганда, XVII гасырдан башлана дияргә була. Бирегә иң элек Әлмөхәммәт исемле кеше килеп урнаша, аннары Иван Грозный заманында чукындырылган татарлар һәм башкортлар килә. Кострома ягы крестьяннары да, авыр салымнардан качып, җир эзләп, бу якларга күчкәннәр. Алар хәзерге Урсала («урыс ала» дигәннән) авылына килеп утыралар. Әлмәт исеме — Әлмөхәммәттән кыскартып алынган булса кирәк.

Әлмәт яклары яшь Совет республикасының беренче көннәреннән зур кайгыртучанлык тоеп яши. Халыкара интервенция һәм эчке контрреволюция чолганышында калган ил өчен иң кыен чорда В. И. Ленин бу якларга ышаныч белән карады. Татарстан тарихын бик яхшы белгән В. И. Ленин ягулык кытлыгы булган бер мәлдә нефтьне Идел буеннан эзләргә киңәш итә. Фашизмга каршы хәлиткеч сугыш чорында — 1943 елда Совет Армиясе танклары шушы яклардан чыгарылган ягулыкны куллана башлый. Нәкъ шушы елда ук Совет хөкүмәтенең Әлмәттә театрга нигез салырга карар итүе гаять кызыклы факт.

Гомумән, Әлмәт төбәгенең бүгенге бәхетле язмышында партия һәм хөкүмәт кайгыртучанлыгы бик ачык күренә. Халык моны тирәннән аңлый. Совет иле үзенең бөек юлбашчысы В. И. Ленинны югалту кичергән көннәрдә әлмәтлеләр аңа булган чиксез мәхәббәтен 1924 елны «Известия» газетасында басылып чыккан түбәндәге юлларда белдерә: «Коммунистлар партиясе һәм эшчеләр сыйныфының бөек юлбашчысын, остазын һәм армас-талмас революционеры В. И. Ленинны югалтуы турындагы авыр хәбәр Татарстанның ерак почмакларына да килеп җитте... Безнең Әлмәттә митинг һәм кайгы демонстрациясендә бу авылның гына түгел, тирә-күрше авылларның һәммә крестьяны да катнашты. Митингтан соң ул крестьяннардан 30 кеше РКП(б) сафларына керергә теләк белдерде...»

Бүгенге Әлмәт районы республикабызның Азнакай, Сарман, Лениногорск, Бөгелмә, Зәй, Түбән Кама, Чистай, Чирмешән, Яңа Чишмә районнары белән чикләнә. 156 мең гектардан артыграк мәйдан били, шуның 112 мең гектардан күбрәге сөрү җире. Әлмәт урманнарга да бай. Ул 73 мең гектар тәшкил итә. Районда урман ел саен 450 гектарга кадәр мәйданда тулыландырыла.

Әлмәт җире илгә ике төрле уңыш бирә: ашлык һәм нефть.

17 колхоз һәм 10 совхоз. Алар зурлыклары ягыннан төрле-төрле. Әйтик, кошчылык фабрикасы булган Колшәрип авылында 33 меңгә якын кеше яши. Шуның җиде меңләбе авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә, ә 10 меңгә якыны промышленность предприятиеләрендә эшли.

Район территориясендә «Әлмәтнефть», «Елховнефть», «Сөләйнефть» һәм «Ямашнефть» идарәләре урнашкан. Миннебай газ эшкәртү заводы бар. Ике кирпеч заводы эшли. Район авыллары аша Бөгелмә — Круглое Поле тимер юлы уза.

Авыл һәм шәһәр эшчәннәре арасында дуслык һәм хезмәттәшлек элемтәләре ныгыганнан-ныгый бара. Чәчү чорында, урак өстендә, авылда йортлар салуда шәһәр кешеләре зур өлеш кертәләр. Бүген күпчелек промышленность предприятиеләренең ярдәмче хуҗалыклары бар. «Әлмәтнефть» идарәсенең «Нефтяник» совхозы терлекчелек продуктлары җитештерү буенча дан тота.

Республика нефтьчеләренең башкаласы Әлмәт шәһәре нигездә районның казылма байлыклары хисабына үсеп чыкты. Чупай ташыннан, мәсәлән, бик күп йортлар, промышленность объектлары һ. б. төзелде. Бу хакта Әлмәттә яшәүче шагыйрь Әдип Маликовның мондый юллары бар:

Бар иде ди Чупай тау,
Бәркет ял иткән куныл.
Эзләмәгез, тапмассыз,
Күчкән ул шәһәр булып.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң әлмәтлеләр кулларына корал тотып гражданнар сугышында, ак чехларга, кулакларга, сәнәкчеләргә каршы көрәшләрдә актив катнашалар. Шул чорда батырларча һәлак булган коммунистлар И. Швыткин, И. Бахорин, Е. Груздев, М. Тавабилов, Ш. Әхмәдиев, активистлар В. Горбунов, И. Кәримов, М. Исхаков, З. Гобәйдуллин, Д. Артемьев, К. Гыйләҗетдинов, Җ. Габдрахманов кебек каһарманнарның исемнәре әлмәтлеләр хәтерендә мәңге сакланыр.

Әлмәтлеләр Бөек Ватан сугышы елларында фронтта һәм хезмәттә зур батырлык күрсәттеләр. Биредән 17732 кеше фронтка алынды, шуның 340 ы хатын-кыз иде. Районның Фрунзе исемендәге колхоз члены Мотыйг Әхмәдуллин һәм Кәләй авылыннан Никита Токарликовка Ватан азатлыгы өчен күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Меңнәрчә сугышчыларыбыз хөкүмәтебезнең орденнарына һәм медальләренә лаек булдылар. Сугыш явында 6045 кеше мәңгегә ятып калды, алар арасында 10 хатын-кыз да бар.

Бөек җиңүне тизләтү өчен тылда калган Әлмәт халкы фронтка азыктөлек, җылы киемнәр белән ярдәм итеп торды. Җиңү көнен якынайту өчен үз акчаларын бирүчеләр дә аз булмады. «Комбайн» колхозы члены Габдрәхим ага Габдрәшитов танк һәм самолет төзүгә 100 мең сум бүләк итте; шушы уңайдан аңа Башкомандующий И. В. Сталинның рәхмәт хаты килде.

Әлмәтнең мактауга лаек уңганнары күп. Район хуҗалыклары нигездә мөгезле эре терлек, сарык, дуңгыз һәм кош асрыйлар. Ит җитештерүче «Кичуй» совхозында гына да елына 14 мең баш мөгезле эре терлек симертүгә исәпләнгән комплекс эшли. Кичуйлылар кайбер елларда дәүләткә 4 әр мең тоннадан артык ит саталар. Һава шартлары иң начар килгән 1984 елда да биредә гектарыннан 25 әр центнер уңыш җыеп алынды. Әлеге хуҗалык соңгы алты елда Бөтенсоюз социалистик ярышында — бер, Бөтенроссия социалистик ярышында биш тапкыр җиңүче булды. РСФСРның атказанган зоотехнигы Зөфәр Газизович Шәйдуллин җитәкчелегендәге бу совхозның еллык саф табышы миллион сумнар белән исәпләнә.

«Ярыш» колхозы район хуҗалыкларын нәселле таналар белән тәэмин итә. Ел буена биредән меңнән артык сыер озатыла. Сөт һәм ит җитештерү һәм хәзерләү буенча колхоз алдынгы урыннарның берсен тота. Колхоз председателе РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы работнигы Самат Сираевич Әхтәмов хуҗалыкта һәр эшне белеп оештыра, халыкны алда торган бурычларны уңышлы үтәүгә оста туплый белүе белән район партия-хуҗалык активы арасында абруе зур.

«Акташ» совхозы директоры Константин Константинович Терехин, «Путь Ильича» колхозы председателе Нотфулла Хәсәнович Хәсәнов кебек оста җитәкчеләр бар районда.

Терлекчелектә һәм игенчелектә зур уңышларга ирешкән маяклар күп. Район савымчылары ярышын «Чулпан» колхозыннан үз эшенең чын остасы Суфия Исмәгыйлова җитәкли. Районда алтмыштан артык савымчы 3 меңчеләр рәтендә бара. «Акташ» совхозыннан дуңгыз караучылар Ольга Владимировна Загуменнова һәм Таисия Андреевна Кочкурова кебекләр гел

мактап телгә алыналар. Җәнлек асрауда бөтен көчен биреп эшләүче Әлфирә Тимеркәева чәшке тиреләре тапшыру планын йөз утыз-йөз кырык процентка җиткереп үти.

Район авыл хуҗалыгы алдынгыларының исемнәрен тагын да күпләп санарга булыр иде. Әмма шуны әйтү дә җитә: 1984 ел күрсәткечләре буенча 17 терлекчегә, механизатор һәм игенчегә үз һөнәрләре буенча мактаулы исемнәр бирелде.

Кыскасы, әлмәтлеләр Азык-төлек программасын үтәүгә үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр. КПССның XXVII съезды карарларын тормышка ашыру буенча да әлмәтлеләр үз сүзләрендә нык торырлар.

Район мәктәпләре укыту-тәрбия эшендәге мәгълүм реформаны тормышка ашыру өчен тырышалар. Халык ихтирамын казанган педагогларыбыз күп. Т. А. Егорова, З. М. Әхмәтова, М. А. Сафина кебек укытучылар СССР мәгариф отличнигы дигән исемгә лаек булдылар. К. С Мөхәмм әтшина, Л. Г. Скворцова, Ә. Ш. Шәмсетдиновлар хөкүмәтебезнең орденнары белән бүләкләнделәр. А. З. Шәрәпов, Г. Л. Рәхмәтуллина, Т. В. Вәлитов кебек педагогик коллективны мактаулы эшкә оста туплый белә торган директорларыбыз бар. Хәзер районда бөтен уңайлыклары булган 38 урта һәм сигезьеллык мәктәп исәпләнә. Укучылар гомуми белем алудан тыш механизаторлык, машина белән саву һөнәренә дә өйрәнәләр. Шуның уңай нәтиҗәсе буларак, егет һәм кызлар, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, авылда эшкә кала.

Яшьләрнең культурага булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен без райондагы барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышабыз. Районыбыздагы театр һәм Язучылар союзы бүлеге эшчәнлеге бу юлда аеруча зур таянычтан саналалар.

Әлмәт районы авылларында туып-үсеп, иҗат илһамы алган язучылар шактый. Алар арасыннан Елховой авылыннан Ләбиб Гыйльми, Габдрахман авылыннан Афзал Таһиров кебек әдипләрне күрсәтергә була. Миннебай егете Шамил Бикчуринның исеме илдә танылды. Шушы төбәктә ул үзенең «Каты токым» романын иҗат итте. Без нефтьче-галим, язучы коммунист Үзбәк Саттаровның исемен зур ихтирам белән искә алабыз. СССР Язучылар союзы члены, техник фәннәр кандидаты, РСФСРның атказанган нефтьчесе, сугыш һәм хезмәт орденнары кавалеры үзенең әсәрләрен яшь буынны тәрбияләүгә багышлады. Шушы ук темада яратып иҗат итүче, балаларга гына түгел, олыларга да бик күп шигырьләр бүләк иткән Энҗе Мөәминова да — шушы районда туып үскән педагог һәм шагыйрә.

Нефть чыга башлауга, Татарстанның бер төркем язучысы, бөтенләйгә төпләнеп калырга дигән ният белән, Әлмәт якларына килеп урнашты. Алар арасында дары исе сеңгән шинельләрен әле генә салганнары да, бу якларның үзгәрешләре белән яңа гына рухлана башлаганнары да бар иде. Рафаил Төхфәтуллин белән Юныс Әминов Брянск юнәлеше, Литва — Польша һәм Воронеж — Полтава — Будапешт — Вена — Прагалар аша үткән утлы фронтлардан, Әдип Маликов көнчыгыш фронтыннан, Сахалиннан ук урап кайтты. Алар сугышчан коралларын тыныч эшкә хезмәт иткән үткер корал — каләмгә алыштырды. Тыныч, шанлы хезмәтнең беренче разведка мәгълүматларын туплар өчен Әлмәт төбәгенә Ибраһим Гази белән Сибгат Хәким, фронтта өйрәнгәннәренчә, әледән-әле иҗат «десантлары» ясап тордылар. Хәсән Туфан да Әлмәт язучылары янына еш килеп-китеп йөрде. 1955 елда Әлмәттә Язучылар союзының аерым бүлеге ачылды. Биредә Гамил Афзал белән Гариф Ахунов үз иҗатларына бай хәзинә таптылар, Мөсәгыйт Хәбибуллин белән Шамил Бикчурин эшчеләр, нефтьчеләргә багышланган әсәрләрнең «каты токым»нарына кадәр төштеләр. Саҗидә Сөләйманова, Энҗе Мөәминова һәм Клара Булатова нефтьче каһарманнарга илһам чәчәкләрен бүләк иттеләр. Мәхмүт Хәсәнов, Хәниф Хәйруллин, Җәмит Рәхимов, Равил Фәйзуллин һәм Марсель Зарипов «гадиләргә гимн» җырладылар. Альберт Хәсәнов, Фәрит Гыйльми, Роберт Рәкыйпов, Дмитрий Матвеев, Азат Ганиев, Изаил Зарипов һәм дистәләрчә яшь әдипләр бүген «нефтьне сәнгатькә әверелдерү» белән мәшгуль. Әлмәт язучылар оешмасы җаваплы секретаре, М. Горький исемендәге Бөтенсоюз әдәби конкурсы лауреаты Әхәт Гаффарның проза һәм драматургиясе бөтенсоюз укучысына ирешә. Әлмәт төбәгендә алты язучы Татарстанның атказанган культура работнигы исеменә лаек булды.

Әлмәт язучылар оешмасына кергән язучыларның үз укучыларын куандырырдай уңышлары бар. Партиябезнең ике съезды арасында гына да аларның Казан, Мәскәү һәм илебезнең башка нәшриятларында ике дистәдән артык китабы дөнья күрде, пьесалары сәхнәгә куелды. Әлмәттә Тукайга багышланган традицион шигырь бәйрәменә тагын бер тантана — күренекле шагыйрә С. Сөләйманова иҗатына багышланган Шигърият кичәсе өстәлде. Язучылар нефть чыга торган Сарман, Лениногорск, Азнакай, Баулы кебек төбәкләрдә әдәбият көннәре һәм очрашулар оештырып, хезмәт ияләре алдында чыгышлар ясыйлар. Аларның әсәрләре исә хезмәт кешесенә дан җырлыйлар.

Әлмәт язучылар оешмасына кергән СССР Язучылар союзының 19 члены нәкъ менә шундый максат белән иҗат итә, язучыларның яшь алмашын тәрбияли. Бу — зур иҗади көч.

1984 елны Әлмәт дәүләт драма театры үзенең 40 еллык юбилеен билгеләде. Бу зур иҗат юлында театрда РСФСРның атказанган артисты Камил Вәлиев, ТАССРның халык артисткасы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Дамирә Кузаева кебек осталар үсеп чыкты. Коллективның тәҗрибәсе яшьләргә күчә бара.

Соңгы елларда әзлекле төстә колхоз-совхоз эшчәннәре арасында үзешчән сәнгать осталары ярышы уздырыла. Бу кичәләрдә 3 яшьлек Альбинадан алып 80 яшьлек оста гармунчы Әбелгата бабайга хәтле, барлыгы 3 меңгә якын кеше катнаша. Авыл кешеләре тарафыннан эшләнгән әйберләрдән күргәзмәләр оештырыла. Һәр авылның үзенә генә хас талантлы кешеләре ачылды. Колхоз һәм совхоз җитәкчеләре халыкка культура хезмәте күрсәтүне тагын да яхшырту буенча бик күп эш башкаралар. «Ярыш» колхозы, мәсәлән, үзешчән сәнгать өчен 25 мең сумлык кием-салым тектерде. Бүген һәр хуҗалык үзәгендә культура йортлары бар. Аларның күбесе авыллардагы культура-масса эшен әйдәп бара. Татарстан АССРның атказанган культура работниклары Җәүдәт Икътисамов, Александр Грушин, Хәлиулла Әхмәтшин бу тармакта башкаларга үрнәк булып торалар. Елховой авылында халык музее бар. Аны карарга илебезнең төрле якларыннан кайталар.

Ләкин безгә әле һәр культура йортын хәзерлекле белгечләр белән тәэмин итү өчен бик күп эшлисе бар. Кечкенә авылларда кино күрсәтүне җайга салу таләп ителә.

Халык сәламәтлеген саклау юнәлешендә дә шактый эш алып барыла. Хәзер авылларда — участок больницасы, 5 амбулатория, 55 медицина пункты эшли. Әлмәт врачлары да даими рәвештә авылларга барып торалар. Авыл халкына шәһәр медицина учреждениеләрендә урын түрдән бирелә. Теш куючылар да авылга барып эшлиләр. Авыл җирендә яшәүчеләрнең барысы да диярлек даими профилактик тикшерүгә тартылган. Бу эшләрнең уңай нәтиҗәсе — күз алдында: район кешеләрендә инфекцион чирләр сизелерлек кими бара. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, СССРның атказанган врачы Г. Ибраһимова, «Халыклар дуслыгы» орденына ия Н. Гамирова, шулай ук врачлардан Э. Сабирова, Л. Әхмәтова, О. Гришина кебекләр авыл халкы арасында зур ихтирам казандылар. Елховой авылы фельдшеры Саибә Касыймова Ленин орденына лаек булды.

Халыкка сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтүне тагын да яхшырту юнәлешендә әзлекле эш алып барыла. Хәзер авылны авыл белән асфальт юл тоташтыра, йортларга даими газ һәм су кертелә. Бу эшне район буенча 1990 елда тәмамлау күздә тотыла. Районда торак һәм көнкүреш объектлары төзү киң колач алды. Хәзер авыл эчендә шәһәрдәге кебек бөтен уңайлыклары булган яңа авыл барлыкка килә. Фрунзе исемендәге, «Дружба», «Ярыш», «Авангард», «Татарстан», «Россия», «Заря» колхозлары, «Кичүй», «Победа» совхозлары һәм башка хуҗалыкларның үзәкләрендә бер-ике гаиләлек коттедж тибындагы йортлар авылга ямь биреп торалар. Аларда белгечләр, механизаторлар, терлекчеләр һәм авыл интеллигенциясе яши. Бүген өендә телевизоры, суыткычы, кер юу машинасы булмаган гаилә бик сирәктер. Эшкә үз машинасына яки мотоциклына утырып йөрүчеләр гадәти бер күренешкә әверелә. Таза, мул яши бүген Әлмәт кешесе. Киләчәгебез тагын да матуррак.

# Мария Елизарова

# БӨГЕЛМӘ ЕГЕТЕ

Соңгы вакытта мин еш кына Бөгелмә шәһәренең 20 нче еллардагы хәлләрен искә төшерәм. Аның ул чактагы бөтен промышленностен «Умарта» дигән сәер исемле остаханә белән шәраб заводы тәшкил итә иде. Чын магънәсендәге эшчеләрне тимер юл депосында гына күрергә мөмкин. Үзәк урамны иске-москылар сата торган базар биләгән. Анда халык мәж килә. Дөрес, күпчелеге сату-алуга битараф. Сатучылар исә үз товарларын киракоенүчене аулыйлар.

Ачлык-ялангачлык, ятимлек безне балалар йортына куып китерде. Монда да хәл җиңелләрдән түгел. Һәркөнне сыек кына солы боткасы ашаталар. Аның өстендә кибәкләр йөзеп йөри. Аларны да чәйнәгәндәй итәсең, тик йотып җибәреп булмый. Төшен кичкенә генә ипи телеме белән кишер чәе эчәбез.

Киемнәр бөтенебезнеке дә бер үк төрле. Аякка юк. Идән шактый салкын булса да, яланаяк йөрибез. Көндез караватларга утырырга ярамый. Тәртип шундый.

Тәрбиячеләр лекция-фәлән сөйләгәндә, без тигез сафларга тезелеп басабыз. Аларның сүзе беткәч, үзебез белгән әкиятләрне уртаклашабыз. Җырлар җырлыйбыз. Мин балалар йортының кимчелекләреннән көлеп такмаклар чыгара идем. Малайлар аны халык көенә җырлыйлар. Әллә шул такмак чыгаруымнан, белмим, тәрбиячеләр мине сәләтле балага санаганнар, күрәсең, укырга җибәрергә уйлаганнар.

Мин шәһәрдәге икенче дәрәҗәле мәктәп бусагасын атлап, тәү мәртәбә укырга килгәндә, октябрь иде инде. Класс кар базы кебек салкын, барысы да бишмәтләрдән утыралар. Миңа иң әүвәл укытучылар бүлмәсенә керергә кушылган иде. Язуымны директорга суздым. Ул, елмаеп:

— Ник уку елы башында ук килмәдең?— дип сорады.

— Белмим...

— Һе! Үзеңне бик сәләтле бала, дип язганнар, син укуларның кайчан башланганын да белмисең.

Күземә яшь тулды.

— Ярый, ярый! — Директорның тавышы йомшап калды.— Мин бит болай гына, бар, класска кер! Сәләтеңне киләчәк күрсәтер.

Мин бусагадан атлаганда, балаларның күбесе урыннарына утырган иде инде. Берничә малай гына кара такта янында маташа. Кап-кара чәчлесе тактага карикатура ясаган да бөтен классны көлдерә. Аяк тавышына әйләнеп карадылар.

— Бу нинди карачкы тагын? — диде теге малай.

Минем карачкыдан артык җирем юк иде, әлбәттә: аягымда олы ботинкалар, юлдагы пычрак аның җете сары йөзен каплап куйган, яңа чакта ак булган оекларның да нинди леген аерыр хәл юк; өстемдә клеенка сыман ялтыравыклы нәрсәдән буйга сырып тегелгән бишмәт. Мондый бишмәт балалар йортында биш-алты гына, без аны алмаш-тилмәш киябез. Мәктәпкә китәргә булгач, үземә атап бер күлмәк биргәннәр иде. Ул бик озын булып чыкты. Бераз кыскармасмы дип, мин аны билдән буып куйдым. Башымда — киң кырыйлы күн кепка.

Шул кыяфәт белән ишек катында басып калдым. Малайлар, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, миңа мыскыллау сүзләре яудыралар. Шул чак берәү:

— Җиттегез инде!— дип кычкырды.— Тимәгез, балалар йортыннан ул.

«Шып» булдылар. Ул арада укытучы да килеп керде.

— Яңа укучымы? — дип сорады ул миннән.— Исем-фамилияң?

— Елизарова Мария.

— Яхшы. Уз! — дип, ул миңа буш урынлы партаны күрсәтте.— Утыр!

Күршем тактага рәсем ясап торучы кара чәчле малай иде. Мин, аңардан шүрләп, партаның читенә генә килеп утырдым. Малай:

— Курыкма, тешләмәм,— дигән булды. Үзе һаман миннән көлә.

— Әйттем бит инде, Астафьев! Житте сиңа! — Тагын бая мине яклаган тавыш яңгырады.

Укытучы аның ник тавышланганын белмичә калды.

— Логинов! — дип кычкырды.— Син миңа яңа тема аңлатырга комачаулыйсың, чык әле тактага!

Минем хакта элəкте моңа, дип, уңайсызланып куйдым. Менә ул тактага чыкты. Пөхтә киенгән, өсте-башы чиста. Укытучы аңардан мисал яздыртты.

— Чиш! — диде.

Малай шактый озак уйлап торды. Укытучы журналга нилəрдер яза башлады. Бераздан Логинов та мисалын чишәргә тотынды. Берничә минуттан аның эше беткән иде инде. Укытучы да тынычланды.

—Утыр, Логинов. Тагын кемнең чыгасы килә? Яңа мисал чишәбез,— диде.

Мин дә кулымны күтәрдем. Укытучы рөхсәт итте.

— Яле, яле! — диде.— Чык әле, яңа кыз!

Барысы да «чыш-пыш» сөйләшергә тотындылар. Мин бишмәтемне салып куйдым, кепканы сыдырып аттым. Тифтән соң тигезсез үскән чәчләрем, тузгып, иң өстемә төштеләр. Кыяфәтем тагын да сәеррәк булып калгандыр, мөгаен. Шулай да укытучы анымоны сиздермәде, мисалын әйтте. Монысы Логиновныкыннан катлаулырак иде. Бер яздым, ике сыздым дигәндәй, шактый баш ватарга туры килде. Ниһаять, чишеп бетердем. Укытучы да бик озак тикшерде. Ахырдан:

— Әйе, болай чишәргә дә мөмкин,— диде.— Хәтта кызыклырак та! Син моңарчы кайда укыдың?

— Балалар йортында.

— Яхшы, яхшы. Ярый, бар, утыр!

Урыныма кергәндә мин Логиновка карап алдым, ул елмая иде. Беренче имтиханны уңышлы тотуыма канәгатьлек сиздерде кебек. Мин дә елмайдым. Логинов белән танышлыгым әнә шуннан башланып китте.

II дәрәҗәле мәктәптә озак укый алмадым мин. Комсомол конференциясендә мине кантон комитеты бюросына сайладылар. Ризасызлыгымны да белдереп карадым, чөнки укыйсым бик килә иде.

— Канткомда бик житди эшләр бар,— диделәр. — Син дә карышсаң, кем генә башкарып чыгар аларны?

Күп тә үтми, кантоннар районнарга үзгәртелде. Мин комсомол райкомында пионер вожатыйлары белән эшләргә тиешле хезмәткәр итеп билгеләндем. Район күләмендә уздырылган бер җыелышта без Михаил Логинов белән кабат очраштык. Ул пионер вожатые икән. Активлыгы әллә кайдан сизелеп тора, чыгышлар ясый, сораулар бирә, тәкъдимнәр кертә.

Аның бу сыйфатын партиянең район комитеты җитәкчеләре дә сизеп өлгергәннәр икән. Берсендә безнең эш бүлмәсенә райком секретаре килеп керде.

— Хәлләр ничек? — ди.

— Муеннан эшкә чумдым, ничек чыгармын,— дидем.— Утырыгыз!

— Утырып торырга минем дә вакыт юк шул. Җитмәсә, эшләр әле өстәлергә генә тора. Авыл мәктәпләрен тикшереп чыгарга кирәк булачак.— Ул Стрижов фамилияле инструкторга борылды.— Миңа Михаил Логиновны табып китер әле, авылларга чыкканда аны да үзем белән алырга уйлыйм.

Логинов чакыртылганнан алдарак та килде. Кулына үзе ясаган дәфтәр тоткан. Секретарь Свиридов аңардан:

— Бу ни тагын? — дип сорады.

— Дәфтәр ясадым. Юлда күргәннәремне язып барырга исәп,— диде Логинов.

Алар чыгып киткәч, Стрижов миннән:

— Райком секретаре үзе белән ник Логиновны алды икән? — диде.

— Ул балаларны бик ярата, шуңа күрәдер,— дидем.

Соңыннан мин Миша белән райком секретаре Свиридовның юлда ничек йөрүләре турында барын да белдем. Башта алар сөйләшми генә барганнар. Көз. Болытлы көн. Яңгыры да сибәләп тора. Юлга кызыллы-сарылы яфраклар түшәлгән. Ат шәп кенә юырта да юырта икән.

Беренче авылга килеп керәләр. Каршы очраган кешедән: «Мәктәбегез кайда?»— дип сорыйлар. Иске генә бер өй икән. Тәрәзәләре такта белән кадакланган. Калайлары какшаган түбәдә көзге җил улый.

Эчкә керәләр. Караңгы. Күптән акшарланмаган пычрак стеналар бу шомлы караңгылыкны тагын да куерталар. Эреле-ваклы ватык парталар аркылы-торкылы куелган. Өстәлдә иске китап ята: «Алтын балык турында әкият».

Свиридов, бүлмәдәге шапшаклыкны күреп, хәйран кала:

— Мин укыганда, мәктәпләр моннан да начаррак иде, тик хәзер, революциядән соң, моңа ничек чыдап торалар — шунысы гаҗәп? — дип куя.

Логинов аңа ачыктан-ачык җавап кайтара:

— Район үзегеннән күрсәтмәле язулар җибәреп кенә яхшырмый бит алар.

— Анысы да хак.

Свиридов балаларның мәктәп стенасына ясаган рәсемнәренә сокланып карый. Елмаюдан аның җыерчыклы йөзе балкып китә. Логинов әле генә әйткән сүзләре өчен уңайсызланып кала. «Бу бит бик күпне күргән коммунист, мин аңа акыл саткан булам»,— дип уйлый. Сүзен төзәтергә ашыга:

— Райкомол хезмәткәрләренә авылларга ешрак чыгарга кирәк!— дип өсти.

— Дөрес. Аларга гына да түгел, партия райкомы кешеләре дә мәктәпләрне онытмаска тиешләр. Өлгерүе генә кыен.

Шул чак мәктәпнең ишеге ачылып китә дә, илле яшьләр чамасындагы хатын килеп керә. Свиридов аңа текәлә.

— Сез кем буласыз инде, апа?

— Ник, белмисезмени? Җыештыручы «Дарья түти» инде мин.

— Ә-ә, бик яхшы. Алайса, мәктәп укучыларын чакырып китерегез әле, зинһар.

Ул чыгып киткәч, Логинов көлеп җибәрә: «Белмим, бу түти тиз генә йөреп чыга алыр микән?»

Әмма озак та үтми, мәктәп балалары җыела башлый. Район вәкилләре аларны: «Керегез, кер!»— дип, каршы алалар.

— Исәннәрмесез?! — Кызыксынулары йөзләренә бәреп чыккан балалар бер тавыштан сәлам бирәләр.

Свиридов аларның хәл-әхвәлләрен сораша башлый:

— Балалар, сезнең парталар гел шулай аркылы-торкылы куеламы?

— Юк, Дарья түти, идән себергәндә, шулай иттереп бетерә.

— Соң, сез төзәтә торган булыгыз!

— Хә-әзер! — Сипкелле малай башлап тотына. Аңа ярдәм итәләр.

Ул арада балаларның яңа төркемнәре дә килеп җитә. Логинов:

— Сезнең кайсыгыз җитәкче соң? — дип сорый.

— Кирилка!

Анысы парталарны тезәргә беренче башлап тотынучы малай икән.

— Кирилка, килмәүчеләр күпме?

Малай, җыелганнар өстенә күз генә салып ала: «Дүртесе юк».

— Сезнең укырга теләгегез бармы соң, балалар?

— Теләк бар, укытучы юк безнең, абый. Ташлап китте, калага качты.

— Ал-а-ай. — Свиридов тагын сорый, — Әтисе сугышта һәлак булганнар бармы? Шундыйлар торып бассын әле!

Балаларның барысы да диярлек күтәрелә. Бер мәлгә сүзсез калалар, аннары Свиридов, боегып утырырга ярамавын аңлап:

— Укучылар!— дип сүзен ялгап китә. — Ни өчен сез үз мәктәбегезне бу кадәр ташландык хәлдә тотасыз? Пычрак. Идәннәрен, тәрәзәләрен юып, стеналарга плакатлар элеп кенә куйсагыз да күңеллерәк булыр иде.

— Соң, абый, укытучы киткәч, безне монда бөтенләй кертмәс булдылар бит...

Аннары Свиридов белән Логинов мәктәпкә килми калган балаларның өйләренә китәләр. Беренче башлап Осиповларга керәләр. Ике малай мич башында утыра. Сәкедә сукыр лампа яна.

— Нишләп көндез ут яндырып утырасыз?

— Шырпы юк безнең. Әни утны сакларга кушты.

— Үзе кайда ул?

— Урманга утын урларга китте.

— Мәктәпкә ник бармадыгыз?

— Өскә юк бит абый! Әле әни ыштанны да яшереп киткән, урамга чыкмасыннар, дип. Икебезгә бер пар чабата бар. Мәктәпкә дә чиратлап кына йөрдек без.

Авылның мәктәп хәлләре белән танышып бетергәч, Свиридов Логиновка карап әйтә:

— Бу авылга синнән дә кулайрак кеше табып булмас, кал син монда!

Партиянең райком секретаре күрше авылга ялгызы гына китеп бара. Логинов исә үз җаваплылыгына кабул итеп алган мәктәпнең киләчәген хәл итү өчен авыл Советына юнәлә. Аның бинасы мәктәпнекеннән дә искерәк, тик монда чисталык, тәртип күзгә ташлана. Язуы да матур итеп элеп куелган, баскычлары да кырып-кырып юылган. Тәрәзә төбендәге яраннар — шау чәчәктә.

— Рөхсәтме? — дип килеп кергән Мишага күтәрелеп караучы да юк. Түрдәге язу өстәле янына утырган кеше үзалдына «дулый».

— Һе! Телефоннан өйрәтергә рәхәт ул! Кооперацияләрнең политик тәрбия мәктәбе икәнлеген мин синнән башка да беләм. Тоз бир син безгә! Керосин, шырпы бир! Халык синең яхшылыгыңа ышансын! Монда спекулянтлар тирәңне каезлыйлар. Үз балам кечә әнисенең яулыгын бер уч тозга алмаштырып кайтты. Мин инде бөтенләй тозсыз ашауга күчтем...

— Бөгелмә белән киңәшергә кирәк! — дип, Логинов аның сүзенә кушылып китә.

Алар шуннан соң гына танышалар.

— Кем соң әле син? — Председатель аптырап кала. — Танымый торам.

— Мәктәп мөдире иттеләр мине. Логинов Михаил Логинович. Кая, күзлегегезне рәтләп бирим әле, борыныгызга төшеп җәфалый.

— Карале, күктән эзләгәнне җирдән бирде, дигәндәй, кем җибәрде сине, ә?

— Свиридов. Беләсезме шундый кешене?

— Белмәгән кая! Акларга каршы бергә сугыштык. Күрсәң, сәлам әйт! Василийдан, диген.

— Әтиегезнең исеме ничек соң, танышыйк инде!

— Мирон углы булам. Мироныч. Син Васька дип кенә йөрт! Без Свиридов белән дә гел шулай эндәшешәбез. Син иртәгә Бөгелмәгә баргач, авылга товар кайтарту турында сөйләшергә уйласаң, сак бул! — Ул аягының протезын сузып җибәрә.— Җүнсез бәндәләр оялаганга охшый анда.

— Истә тотармын. Мин әле сезнең белән башка нәрсәләр турында да киңәшергә телим: комсомолларны җыярга иде! Ярдәм итә алмассызмы, Василий ага!

— Хәзер җыябыз аларны. Кичкә безгә килерсең, сөйләшә-сөйләшә кунарбыз. Аннары үзеңә дә бер фатир табарга булыр.

— Ярый, Василий Миронович. Рәхмәт!

Мәктәп мөдире янына авылның өч комсомолы килә. Логинов аларга:

— Егетләр, безгә бу мәктәпне үз көчебез белән рәтләргә кирәк булыр,— дип аңлата. — Башка һичнинди мөмкинлек тә юк.

— Эштән курыкмыйбыз ла анысы,— диләр егетләр.

— Алайса, әйдәгез, тотындык!

— Чүкеч-фәлән алып килик инде.

— Әйе шул. Барыгыз! Берәрегездә кара лак табылмасмы, такталың төсе киткән. Аны да яңартыр идек.

Егетләр өйләрендәге «байлык»ны барларга киткәч, Логинов, дәфтәр битләрен ябыштырып, өндәмә яза башлый. Комсомолларның берсе Ленин портретын табып килә. Аны да элеп куялар.

Мәктәптә эш барганны ишетеп, авылның башка яшүсмерләре дә килә. Бина эче яктырып, сафланып, чистарып кала. Икенче көнне дәресләр башлана.

Михаил яшүсмерләр белән бергә, авылның элекке поп йортын төзәтеп, клуб ачарга кирәк, дигән фикерне күтәреп чыга. Өмәләргә өлкәннәр дә катнаша. Шулай итеп, ташландык бина шактый иркен клубка әйләнә.

Клубта авыл яшьләре концертлар, спектакльләр куялар. Комсомол җыелышлары да шунда ук үткәрелә. Өлкәннәр дә клубка бик теләп йөриләр. Логинов аларга киләчәк турында лекцияләр укый. Кеше хезмәтенең киләчәктә бик нык җиңеләячәгенә, аны машиналар башкарачагына ышандырмакчы була. Халык көлә: «И-и, Миша, бераз гына чама белеп сөйлә инде!»— диләр. — Үзе ура, үзе суга торган машина буламыни?»

Логинов авылда күмәк хуҗалыклар оештыруда да башлап йөри. Бер төндә аның ишеген шакыйлар. Ачса, авылның беренче комсомоллары — Дима, Коля һәм Василий икән.

— Логиныч, безнең эшләр шәптән түгел,— ди Дима. — Әние кулаклар котырткан, колхозга керергә теш-тырнагы белән каршы. Сыерны суярга җыена.

— Минеке дә кулаклар җырын җырлый башлаган.

— Безнең әни, кешеләр нишләсә, шул булыр, тик үзем башлап кермим, ди.

Михаил уйга кала. Нишләргә? Аннары:

— Без, егетләр, халыкны җыйыйк! — ди. — Барын да уртага салып сөйләшербез.

Җыен бик гаугалы үтә. Район вәкиле, комсомоллар күмәк тормышның уңай якларын хуплап сөйлиләр. Бәхәс куера. Шул вакыт авыл башыннан күмәк хуҗалыкка кергәннәргә ярдәм итү өчен җибәрелгән трактор кайтып керә. Картлар шаккаталар. Хатыннар аны капшап-капшап карыйлар. Тракторның беренче буразна сызуын җыелыштагыларның барысы да карап тора. Тикшеребләр.

— Карале, нинди тирән сөргән!— дип сокланалар.

Бу көнне бик күпләр колхозга языла.

Авылга беренче радиоалгыч кайтартуда да Логинов һәм башка комсомолларның

тырышлыгы зур роль уйный. Аны халыктан акча җыеп, уртагыннан сатып алалар. Мәктәпкә урнаштыралар. Иң башта радионы балалар ишетә.

— Балалар,— ди Логинов.— Сез бүген Мәскәү тавышын ишеттегез. Барыгыз, кайтып әти-әниләрегезне җибәрегез инде, алар да тыңласыннар!

Мәктәп авылдагы тәрбия эшләренең үзәгенә әйләнә бара. Әйдәп йөрүчесе Логинов була, әлбәттә. Ул укучылар өчен дә, яшь укытучыларга да лекцияләр укый. Үзе кебек үк гомуми эш өчен янып-көеп йөрүче яшь кадрлар әзерли. Аннары ул үзен Кызыл Армия сафларына җибәрүләрен сорый. Үтенечен канәгатьләндерәләр.

Армия хезмәтеннән соң аңа педагогик эшен дәвам иттерергә мөмкинлек булып ала. Ә 1941 елны Михаил Логинов Бөек Ватан сугышына китә.

Ул пехотага эләгә. Фронтта нинди шартларда сугышуын аңлату өчен, мин аның хатына мөрәҗәгать итмәкче булам.

«...Минем командалыктагы укчылар взводы иң алгы сызыкта иде,— дип язды ул бер хатында.— Бездән алда бер генә траншея да юк. Без бер адым да артка чигенмәскә ант иттек.

...Таң алдыннан дошман ягында мотор гөрелтеләре ишетелә башлады. Тавышлар безгә таба якынлаша бара. Аннары дөнья кинәттән тынып калды. Сугышчан әзерлек белдердем. Танкка каршы куллана торган гранаталар, яндыргыч сыеклык тутырылган шешәләрне барладык. Үзебез белмибез әле: нәрсә килер безгә каршы, танклармы, әллә пушкалардан атачаклармы?

Көн яктысы сирпелде. Сандугач тавышы яңгырады. Һәм кинәт... гүя күк гөмбәзе шартлап ярылды, җир дерелдәргә тотынды. Авыр снарядлар тавышы бигрәк котсыз инде. Тирә-юньне туфрак, төтен, ялкын каплады. Траншея буйлап йөгерәм. Исән калганнарны дәртләндерергә тырышам, дошман алдында җебеп калмаска чакырам. Дошман солдатлары шактый якын ук килеп җиткәннәр. Без дә ут ачтык. Кул пулеметлары, мылтыклар... Күрше ротадан ярдәмгә килеп җиттеләр. Аларда станоклы пулемет та бар. Шундагы сугышчыларның берсе минем укучым Кирилка булып чыкты. «Ничек болай?— дим.— Кай арада монда килеп өлгердең?»

— Логиныч!— Ул сүзен әйтергә дә өлгермәде, минем аша дошман солдатына ташланды.— Мә, ал!

Тагын миңа нидер әйтмәкче иде, дошман пулясы Кирилканы аяктан екты. Кулларыма алдым. Йөрәген тыңларга телим. Тавыш юк, җан юк...

Тирә-юньдә тынычлык урнашкач, мин кабат Кирилкамның гәүдәсе янына бардым. Тыела алмый, елап җибәрдем.

— Лейтенант, әллә улыгызмы? — дип сорыйлар.

— Укучым ул минем...

Сугыш елакларны яратмый. Алдагы сугышларда үч алырга ашкынам...»

1944 елның августында Михаил Логинов:

«...Латвияне азат иттек,— дип, шатланып язды.— Бу юл тәмугка кереп чыгу белән бер булды. Бик эссе чак иде. Сусауга чыдар хәл юк. Хуторлардагы халык, куркып, әллә кая качып беткән.

Хуҗалыкларда печән бик күп. Немецлар шул кибәннәргә яндыргыч пуля аталар. Бөтен дөньяны ялкын каплый.

Сугышчы хезмәте төрле-төрле. Оборонада да торабыз, походта да булабыз, разведкасы да эләгә. Кайчак тәүлекләр буе йокы тими. Шулай да аңысына түзеп була. Иң авыры — иптәшләрнең һәлакәте. Нишләмәк кирәк, аңысын да кичереп җибәрергә туры килә. Шунсыз мөмкин түгел, ярамый. Өйрәндек: безгә куркып калырга, чигенергә, тез чүгәргә ярамый!..»

Логинов Бөек Җиңүдән соң да Совет Армиясендәге хезмәтен дәвам иттерде әле. Бөгелмәгә 1946 елны гына кайтып төште. Күңелендә һаман яшьләрне тәрбияләү проблемалары иде.

«Кара әле, Мария Николаевна, минем сугышта кичергәннәрне китап итеп чыгара алсак, яшь буынга нинди зур гыйбрәт булыр иде,— дип язды ул бер хатында.— Ярдәм итсәгез иде!»

Аның кульязмасын Казанның М. Горький музее каршындагы әдәби берләшмәдә карадык. Мин аңа иптәшләрнең фикерләрен түкми-чәчми язып җибәрдем. Хатыма җавап булмый торды. Ул бит мәктәптә эшли иде. Бөгелмәнең 8 нче мәктәбендә егерме өч ел буе физика укытты ул. Директор итеп тә куйдылар, район мәгарифе бүлеге инспекторы вазифасын да үтәде. «Халык мәгарифе отличнигы», «Татарстанның атказанган укытучысы» исемнәренә лаек булды.

Көннәрдән беркөнне миңа аның «Фронтта күргәннәрем» исемле китабы килеп төште. «...Комсомол елларыбызның истәлеге булсын!» — дип, автограф язган. Бу сүзләр күңелдәге иң кадерле хатирәләрне яңартып җибәрде. Бөтен гомерен яшь буынны бәхетле итүгә багышлаган педагог турында башкаларга да сөйлисем килде.

Сәгыйдулла Хафизов

# «ЯШЕЛ ЕЛАН»ГА КАРШЫ

Яшел елан... Аракы-хәмерне халык нилектән шулай атый икән? Яшькелт, чалмалы шешәдәге шул сыекча елан агуы кебек зәһәр, һәлакәтле булган өченме?.. Халык әкиятләрендә елан еш кына кыяфәтен үзгәртергә сәләтле юха рәвешендә була. Яшь, карап туймаслык гүзәл кыз, я булмаса мәхәббәтле хатын җенесе булып кешене сихерли, үзенә тарта һәм аны тәмам һәлакәтле бер хәлгә төшерә. Эчкә кергән аракы-хәмер дә шундый ук хасияткә ия түгелме соң?

Рус совет язучысы М. Алексеев «Чияле чоңгыл» романындагы бер чигенештә аракыхәмернең нәкъ әнә шул сыйфатына ишарә ясап үтә: «Бер чәркә генә салам да, шундук шылам дигән нийт белән керә кеше эчә торган җиргә. Әмма шуны төшерү белән ул бөтенләй башка адәмгә әверелә. Монысына шулай ук бер чәркә кирәк була. Аны салгач, бу адәм тагын да тәвәккәлрәк өченче бер адәмгә әверелә. Тылсымлы әверелеш бик тиз дәвам итә һәм инде өстәл артында баягы тыйнак, исәпле кешенең эзе дә юк — бөтен булмышы белән бер гайрәт иясе утыра. Ул «Эх, беткән баш беткән... дип шәрран яра һәм кесәсеннән бөтәрләп акчалар тартып чыгара...»

Татар язучысы Ф. Шәфигуллинның «Сыерчык бураны» исемле юмористик повестендагы салырга яраткан Кадери исә, эчмәс борын ук, аракының үзендә нинди үзгәрешләр ясаячагын яхшы белә:

«Хәзер, менә хәзер кәгазь стаканга аз гына хәмер салып эчүгә, ул ис тә юкка чыгачак. Гомумән, тирә-юньдә бер генә татлы ис тә калмаячак. Ылыс исен дә, үлән исен дә, чәчәк исен дә йотачак хәмер исе. Күз алдындагы буяулар да, җәй төсе дә югалачак. Ул гына да түгел, бөтен тирә-юнь, бөтен дөнья үзгәрәчәк. Урман аланын ясалма зәңгәрлек, күңелне битараф рәхәтлек томаны билэп алачак».

Әйе, аракы-хәмернең кешене аздырган иң зур хасияте елан кебек юхалыкта. Хәмер эчеп, көчсез гайрәтле була, йомыкай тел бистәсенә әверелә, сагышлы кайгысын җуя, акыллы юләрләнә, ә әйбәт кеше исә шуңардан золым иясенә әйләнергә мөмкин. Кыскасы, җырлата да, елата да аракы. Г. Тукай әйткәнчә, үз вөҗүде, үз асылы белән бөтенләй ярашмаган ялган бер халәткә куя ул кешене:

Бераз вакыт шатлык таба исерек кенә,  
Үз-үзенә ачы агу эчереп кенә;  
Әмма дөнья нинди кызык, нинди хозур,  
Бу дөньяда кемнәр бар, дип миннән дә зур!

Ләкин аракы-хәмер елан кебек юха булу белән беррәттән, тагын бер олы мәкергә ия. Кеше аны дөрес һәм анык итеп таный алмау гаҗизлеге кичерә. Бу нисбәттә «яшел елан» чын-чынлап хамелеон — ул төсләре, рәвешләре белән алдый, саташтыра, күзне, зиһенне буа һәм нәтиҗәдә кемнәргәдер начар, ямьсез күренгән төс-рәвешләре кемнәргәдер хозурлык, ямь булып тоелырга да мөмкин. Хәлбуки, югары рухи культуралы халыкләр тормышы бик борынгыдан шуны раслый: эчкечелек нинди генә формаларда, кайсы гына шартларда да хезмәт иясе массаларының карашында хуплау тапмый, анда ул әхлакый бозыклык, түбәнлек булып гаепләнеп килә. Алай гына түгел. Халык этикасы, фольклоры һәм язма әдәбияты бу яман социаль чирне золым буларак кыю фаш итә һәм аңа каршы дәвамлы көрәш тә алып бара.

Татар халкының язма әдәбиятында, мәсәлән, эчкечелеккә каршы көрәш XIX йөзнең соңгы чирегендә, ягъни анда суфичылык дәвере бетеп, мәгърифәтчелек этабы башлан-

гач аеруча нәтиҗәле төс ала. Моннан йөз еллар элек энциклопедист галим һәм әдип К. Насыйри эчкечелеккә карата зур-зур мәкаләләр язып бастырган. Бу авторның төрле аспектлардан килеп хәмер эчүнең сәламәтлек, холык-әхлак, матди көнкүреш өчен зур бер афәт, зыян икәнен гыйльми дәлил, логик эзлеклелек белән исбатлавы хәзерге көндә дә тирән ихтирамга лаек.

К. Насыйри үзенең фикерләүләрендә «аракы дигән эчемлек адәми зат өчен кулланылган бер агудыр» дип нәтиҗә ясау белән бергә, эчкечелек фәлсәфәсен, ягъни көнкүрештә хәмер куллануны акларга маташуны фаш итүгә аерым зур игътибар бирә: «Бу аракы вә эчемлек эчүнең сәбәпләре бик күптер ки, кайгы булса — эчә, шатлык булса — эчә, кыш көне туңса — җылыныр өчен эчә яки бер әр авыру өчен төрле үлән яки бер төрле тамыр белән төнәтеп эчә. Ах алла, бу ниндәен гаҗәп дәва имеш, төрле-төрле файдасы бар имеш... Эчемлек куәтне торгызу түгел, бар куәтне бетерәдер. Ул... бары тик арыган атны чыбыркы белән сугу кабиленнәндер ки, арыган ат чыбыркы белән суккач, бар куәтен җыеп, бар көче белән тартып егылганчы барадыр». Ягъни, әдип карашынча, аракы һәр очракта кеше өчен һәлакәтле бер чара. Шул уңайдан К. Насыйри эчү белән мавыгуның аерым ямьсез нәтиҗәләрен дә турыдан ярып әйтеп, күрсәтеп үтә.

Аракы кебек шундый нәҗес нәрсәнең көнкүрешкә сый булып керүе К. Насыйрины гаҗәпләндерә, хәтта логикага сыймаслык бер эш булып тоела һәм ул бу мөнәсәбәттә бүгенге көннәрнең аш-су, табын культурасы өчен дә бик актуаль яңгырашлы фикер белдерә: «Уйласаң, бик гаҗәп тоеладыр ки, әй ия се үзенең кунагын кыстап-кыстап эчертәдер ки, кунагына күреп зарар кыладыр яки тизрәк үтерергә, яки бер-бер төрле авыруга дучар булуына сәбәп ачадыр. Аннан гаҗәбрәк берәүгә-берәү чәркәгә салып аракы сузса, ул кеше аны алып «сезнең сәламәтлегегез өчен»,— дип эчеп йибәрәдер. Бу аракы вә эчемлек белән сыйлашулар эчемлекнең зарарын фәһем итмәенчә күрелгән бер ахмаклыктыр. Ул эчемлектән пәйда булган зарарны фәһем иткәннән соң кыстап эчертмәк түгел, кунакның алдына китереп куймак ояттыр вә гаеп эштер. Бәлә торып кунакка явызлык кылудыр».

Узган гасыр реалистик әдәбиятының җәүһәрләреннән саналган «Зур гөнаһлар» романында З. Бигиев исерткеч эчүне әхлакый һәм этик бозыклык кына түгел, ә җинаятькә этәргән сәбәпләрнең иң зурысы итеп тә күрсәтә. Начар мәдрәсә шартларында шәкерт Габделгафур эчәргә өйрәнеп китә. «Габделгафур әфәнде аракыга шул кадәр һәвәс кылды ки, һәр көн иртән дәрес алдыннан, дәрес вакытында мөназар кылмага гайрәт бирсен дип, берәр чәй чынаягы илә аракы эчмәккә гадәт кылды», диелә әсәрдә. Шәкертнең бозыклыгын фаш итеп, аны мәдрәсәдән куалар һәм Габделгафурның җуликлар чолганышында караклык белән башланып киткән җинаяте кеше үтерүгә кадәр барып җитә. Яшь кеше исереклек аркасында кылган гамәлләре белән төрмәгә эләккәнен дә сизмичә кала.

Талантлы сатирик Ш. Мөхәммәдев тарафыннан тудырылган Галиакбәр («Җәһаләт яки Галиакбәр агай»), Батыргали («Япон сугышы яки Батыргали агай») эчү җәһәтеннән аеруча талымсыз һәм комсызлар. Галиакбәрнең, мәсәлән, «ычкынып китеп берәр атна качып китә торган гадәте бар». Мондый чакларда ул «шәһәрнең астын-өскә китереп, беренче класс рестораннан башлап түбән дәрәҗәдәге кабакка кадәр һичбер зиярәт итмәгән җирне калдырмай». Әфлисун төсендәге зур борынлы, мичкә юанлыгы корсаклы Батыргали исә бер утырганда шешә артыннан шешә бушата, акны карадан аермас хәлгә килә, һәм башка да килмәслек юләрлекләр, хулиганлыклар кыла башлый... Мондый типтерүләрнең азагы байлар өчен бик күңелсез бетә. Капитал хуҗасы Галиакбәр тәмам бөлә, урам хәерчесе хәлендә кала. Исән-сау йөргән Батыргали юләрлеккә төшә. Шуның өстенә аларның начар үрнәкләре тагын бер бәла булып, яшь байбичәләр Миңлебай, Хәсәншаны да юлдан яздыра, харап итә.

Мәгърифәтчелек әдәбиятындагы мондый кире геройлардан аермалы рәвештә, уңай ларында исерткеч эчемлекләр куллану дан тәмам азат булган кешеләр сурәтләнә. Мәсәлән, Р. Фәхретдиновның «Әсма» повестендагы көтүче Сәлим бабай турында болай диелә: «Исерткеч эчмәк түгел, исерткеч эчкән кеше белән хәтта мәҗлестәш булмас иде. Исерткеч эчмәк — агу эчмәк кадәр зәһәрле вә һәртөрле хәстәлекләрнең баш сәбәбе идегене бер доктордан ишетеп тәмам канәгать әйләмеш иде».

Ш. Мөхәммәдевнең «Яфрак асты яки Мәкарҗә ярминкәсе» хикәясендәге капиталист Гали Акчурин исерткечне үзенең авызына алу түгел, хәтта халык эчкәнгә дә чиксез нәфрәтләнә: «Гаҗәп безнең татар халкы: дөньядагы барлык ләззәтне, рәхәтне ахырысы шул төн буенча трактирларда... ашап-эчеп исереп, галәмгә рисвай булып йөрүдә генә диеп белә торгандыр... Намуслы фамилияләр үз йортларында семейный вечерлар ясап, әдәп берлә зәвык-сафа кылалар. Яки китапханәләргә кереп буш вакытларда яңа чыккан китап-газета укып бер фикер алалар. Әмма безнең Казан мөселманнарында мондый эшләр бик аз. Моның сәбәбе наданлык вә фанатизмдыр».

Ләкин чын капиталист әлеге Гали Акчурин кебек итагатьле һәм миһербанлы идеме соң? Һич юк! Әнә иске тормышның типик картиналарын җанландырган Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестендагы десятник Исак, хуҗасының боерыгын үтәп, бер кулына

аракылы чиләк, икенчесенә кружка тотып, промыселдагы эшчеләрне исерткеч белән сыйлап йөри. Балык аулау уңышлы барса да, бәйрәм-мазар булса да, зур игелек кылган кеше төсле, шул шөгыленә керешә ул. Ә авызлары аракыга тиеп, кызышып алгач, эшчеләр кесәләрендәге соңгы тиеннәренә чаклы эчәргә керешәләр һәм, Шәрәфи карт әйтмешли, «күз тигән бәпкәләр кебек чукыша», канга батышканчы сугышалар. Эшчеләрнең бу кыланышлары никадәр генә ятышсыз күренмәсен, алар бары капитал хуҗалары файдасына. Исерткеч сыекчадан кергән табыш — сәүдәгәрләр файдасына, эшчеләр сафында мораль таркалу — промышленник, буржуа файдасына. Түбән әхлаклы пролетариатны эксплуатацияләү бермә-бер җиңеләячәк...

М. Гафури үзенең 1909 елда язган «Исерек» шигырендә эшчеченең кызгынач, ямьсез кыяфәтенә игътибар итеп болай ди:

Фикер беткән, үзеңдә калмаган хис,
Күзең сүнгән, яныңда бер начар ис.
Үзең ямьсез, киемнәрең начардыр,
Сине бозган фәкать бер нәрсә бардыр...

Шагыйрь шул «бер нәрсә»не тәгаен хәмер дип исәпләсә, эшчече, киресенчә, шул хәмердә «дару» күрә:

Кәсеп юк, балалар күп, хәлемне күр,
Шул хәсрәтләр эчәргә итте мәҗбүр.
Хәмерсез һич бу хәсрәтләрем басылмый,
Өмет өзгән күңелләрем ачылмый.

Шигырьдәге «Дарумыни... Дару булгач, ничөн бозган тәсеңне, зәгыйфь итеп ничөн алган көчеңне?» риторик соравы эшчеченең социаль сукырлыгына көенү, хәтта шелтә булып яңгырый. Бу сукырлыктан котылу өчен шәхескә мораль-әхлак югарылыгына күтәрелү кирәк. Әмма кешене кеше эксплуатацияләгән, гаделсезлек тантана иткән җәмгыятьтә моңа ирешү ансатмы? Ф. Сәйфи-Казанлының революциягә кадәрге сезонлы эшчеләр тормышын тасвирлаган бер төркем хикәяләрен анализлап, Х. Хисмәтуллин бу нисбәттә мөһим фикер раслый: «Бу әдип «капитализм» җәмгыятендә гади, вак кешеләрнең тормышы, мораль һәм әхлак тәзеклеге турында һичбер кайгырту булмавын, аларның барлык шатлык һәм кайгыларын фәкать аракы белән юып, нәтиҗәдә «тормыш төбенә» төшәргә мәҗбүр булуларын йөрәк әрнеткеч рәвештә сурәтләде».

Күрсәтелгән сыйфатның бер үк вакытта Г. Тукай, Г. Камал, М. Гафури, Ш. Камал, С. Рәмиев, М. Фәйзи кебек олы әдипләребезнең иҗатына карата да бик туры килүен әйтергә кирәк. Ш. Камалның берничә хикәясенә генә игътибар итеп үтик. «Козгыннар оясында» хикәяләнгән шахтерларның тормыш итү рәвешен тач ике өлешкә аерырга була. Берсе — иртәдән-кичкә чаклы корт шикелле күмер катлавы кимерү. Икенчесе исә «исергәнче аракы эчү, җыр, көй тарту һәм шул арада кычкырышу, кыйнашудан гыйбарәт» булган «бәйрәм». Шундый бер «бәйрәм» артын язучы җирәнгеч картинада күрсәтә: «Казарманың эче коточкыч фаҗига хәлендә иде: ватылган савыт, ташланган азык, ауныган урындык, җимерелгән өстәл, пычранган әйберләр арасында кешеләр кайсы косык эчендә ауный, кайсы укшый, кайсы сәке астына башы белән тыгылган, кайсы йөзе белән чүплеккә капланган». Ә хикәядә тасвирланган иң олы фаҗига шунда: алар әхлакый гарип Садрыйга ияреп, кызык эзләп, бер гаепсезгә саф күңелле, намуслы хатын Мәрьямнең гаилә тормышын, гомерен харап иткәннәр. Эшчеләр ямьсез шартларда әдәп, оят, итагатьлек кебек кешелек сыйфатларын җуеп, козгыннарга әверелә башлаганнар.

Әлеге әсәрләр, безнең карашка, XX йөз башы татар әдәбияты өчен бик гыйбрәтле әсәрләр. Критик реализм иҗатында, бер яктан, капиталистик шартларда эчкечелекнең хәл ителмәгән социаль каршылыкларга реакция төсендә үсүе күрсәтелсә, икенче яктан, «яшел елан»ны эчкә үрләтүнең ни кадәр хәтәр эш икәнен, моның һәлакәтле фаҗигалар чыганагына әйләнүен сурәтләүгә дә кыю омтылышлар ясалды. Соңгы темага нисбәттә Ф. Сәйфи-Казанлының «Двор өендә» хикәясе аерым үйланулар кузгата. Аның төп герое хакында әдип болай ди: «Җиһаншаның белмәгән, эшләмәгән эше юк. Ул шахтада күмер казыган, сабын заводларында сабын кайнаткан, пароходларда мич яккан... Читтән карагандa киң җилкәле, озын буйлы, таза тәнле бу кешедә тауларны күчерерлек ирек-көч бар дип уйларсың». Әмма буйдак бу ирнең йомшак, зәгыйфь бер ягы бар икән. Эчкече ул. Эчкеченең дә иң хиресе — «авызына аракы гына тия күрмәсен, әгәр дә берничә тамчысы ирнәнә тия калса, акылын җуя»...

Җиһаншага аракы да, акча да бирмиләр. Әмма эчкечедә исерткечкә хиреслек, сусау шул кадәр көчле була ки, «күзенә өстәл өстендә аракы шешәсеннән калган бөке күрен-

гәч, ул ач этнең иткә ыргытылуы шикелле ыргылып, бөкене чәйни, суыра башлады». Адәм рухи мондый мәгънәсез көчәнүләргә түзә алмый. Җиһанша өянәге кузгалып егыла.

Л. Н. Толстой: «Вино кешеләрнең тән сәламәтлеген какшата, акыл һәм сәләтен юкка чыгара, гаиләләрнең иминлеген бетерә һәм иң яманы — кешеләрнең җанын, нәселен һәлак итә» дигән.

Билгеле инде, социаль һәм әхлакый яктан таркалган эчкече белән чын кеше, көрәшче төшенчәләре күк һәм җир арасы кебек ерак мәгънәләр. Үзгәнә иҗтимагый идеал, азатлык, бәхет өчен көрәшкән халык каһарманнарын куйган татар совет әдәбияты элеккеләргә караганда менә шушы хакыйкатькә ныграк игътибар итә төшә. Биредә эчкече тибына карата нәфрәтле, җирәнгеч караш көчәя. Г. Ибраһимов, һ. Такташ, Ш. Камал, Ә. Фәйзи, Ф. Бурнаш, К. Нәҗми кебек әдипләр иҗатында исерткечкә мөнәсәбәт геройларның әхлакый кыйммәтләрен билгеләүче мөһим критерийга әйләнә. Хәтта кайбер очракларда бу әдипләр шул нисбәттәге саран гына штрихлар белән дә аерым характер-язмышлар тудыруга ирешәләр. Менә Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романындагы Давыт. Әсәр башында революционерлар мохитенең булдыклы һәм кыю гына бер вәкиле рәвешендә кабул ителсә дә, ахырында ул көрәштән читләшкән, тормышта кыйбласын югалткан кеше тәэсире калдыра. Әдип Давытның түбән тәгәрәвен тәфсиллап, аргументлап матавмый. Иң башта җырчы Сәхип Хәдичә тутидән «Давыт бик эчә» дигән хәбәр ала. Бераздан җырчы Сәхип үзе үк Давытны исерек килеш бик ямьсез эчү компаниясендә күрә. Мондагыларның «күзләре үлгән, куллары калтырый, йөзләре җәһәннәмнән чыккан шайтанны хәтерләтәләр. Үзләре хәлсезләр, гәүдәләрен тота алмыйлар, аяклары кушканны тыңламый, чалыш атлый, көзгегә карыйлар да:

— Бит чабата төсенә кергән икән! — дип ава-түнә киенә башлыйлар».

«Безнең көннәр» романының икенче бер каһарманы эшче Габдулла да заманында нык кына сала. Исерткечтә кайгысын җуя, юаныч китерә торган чара табарга тели ул. Әмма үткен акылы михнәттән чыгу юлының аракыда түгел, ә аеклыкта, социаль активлыкта һәм көрәштә икәненә вакытында төшенә. Габдулла зур максаты, ачык карашы булган большевиклар арасында, көрәштә шәхес буларак үзен нык һәм ышанычлы сизә, аның тормышы мәгънә һәм ямь белән тула.

Олы, якты идеал — коммунизм идеалын хезмәт кешесенең интим тормышына мәгънә һәм ямь бирүче илаһи көч итеп раслау К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романындагы Мостафа образында аеруча уңышлы гәүдәләнгән. Язмыш тарафыннан ишле гаиләсе белән шәһәргә куып китерелгән Мостафа капиталистик тормыш рәхимсезлекләре астында интегә. Иелгән башны кылыч кисмәс, язмыштан узмыш юк, дип тәкъдиренә буйсынган Мостафаның тормышы ялыктыргыч, эчпошыргыч бер эздән бара. Тик аерым көннәрдә егылганчы эчеп, җыелган үч, ярсуын якыннарына түгә ул. Әмма айныгач, бу эшләренә үзе үк үкенә:

« — Ниткән тормыш бу? Бер тамчы якты юк, бер чеметем шатлык юк. Тоташ караңгы төн. Шул кайгыдан эчтеңме, үзең дә ерткычка әйләнәсең...»

Һәр кешедәге кебек, Мостафаның тормышында да мөһим бер сайлау мизгеле була. Зур гәүдәле, көчле бәдәнле бу кешедәге горурлык хисе, хәтәр булса да, яктыга, бәхеткә юнәлгән революцион көрәш юлын сайлый. Ул юл эшченең мораль-әхлак дөньясын баета, кешелек сыйфатларын ямьләндерә. Мостафаның гомере түбән ләззәтләр белән вакланмый, заяга узмый, ул иҗтимагый прогресс өчен көрәшкә багышлана.

Бу — революцион чынбарлыкның олы гуманистик асылын, заман хакыйкатен гәүдәләндерү иде. Әйе, якты идеал белән балкыган изге көрәш юлы Мостафа кебек меңнәргә, миллионнарга тормыш мәгънәсе, дәрт, яну, ашкыну бирде. Бу юл яңадан-яңа фидакарьләрне, батырларны, геройларны тудыра.

Партиябезнең, халкыбызның аеклык һәм сәламәт тән, сәламәт акыл өчен башлаган көрәше, һичшиксез, күпләрнең мәнфәгатен гәүдәләндерүче гуманистик омтылыш. Туйды, тәмам ялыкты халык исерткеч-золымнан. Моны без соңгы еллар татар әдәбиятының аерым әсәрләренең рухыннан да бик ачык тоябыз.

Г. Гобәйнең алтмышынчы еллар башында дөнья күргән «Ләйсән яңгыр» повесте, безнең карашыбызча, татар совет әдәбиятында эчкечелек-бозыклык күренешен җитди планда гәүдәләндерүче әсәрләрнең берсе. Повесть художество эшләнеше, бигрәк тә вакыйга һәм образлар үсешендә логик эзлеклелек сакланмавы белән аксаса да, җинаятьче типларын кояш яктысына чыгаруы, фаш итүе белән кызыклы иде.

Т. Миңнуллин драмаларында да бозыклык чыганагы аракы-хәмергә каршы чыгу пафосы көчле. Мәсәлән, «Кырларым-тугайларым» драмасының герое Солтан эчкече хатыны Мөслимәне күздә тотып, әрнеп болай ди: «Азмы андыйлар — адашканнар. Җир шарының иң биек урынына менеп кычкырасым килә. Адаша күрмик, егетләр, адаша күрмәгез кызлар, дип ялварасым килә. Адаштырмагыз аларны, дип яныйсым килә. Кеше булып туганбыз икән, кешеләрчә яшик, кешеләрчә үлә белик дип мең миллион тапкырлар кабатлыйсым килә».

Шул ук драманың икенче бер персонажы Ләбибә хатын-кыз эчкечелегенә нәфрәтләнеп кычкыра: «Авылда көпә-көндез урам буйлап исереп йөргән хатын-кызны кем күргән? Сез хәтерлисезме? Юк бит. Егерме биш яшь- үзенә — алкоголик. Хатын-кыз бит, кыз бала — алкоголик!»

Г. Бәширов, А. Расих, Т. Миңнуллин, Х. Сарьян, А. Гыйләҗев, Ф. Шәфигуллинның соңгы елларда дөнья күргән әсәрләрендә, М. Мәһдиев, В. Нуруллин прозасында бу социаль күренеш әхлакый, рухи мәгънәләр яктылыгыннан килеп тирән фаш ителә. Билгеле булганча, теге яки бу социаль типны уңышлы гәүдәләндерү өчен аның психологиясен яхшы белү, аңлау мөһим шарт. Бүгенге көннәр татар әдәби иҗатында кызганыч һәм хурлыклы эчкече хәленә төшкән кешеләрнең сәнгатьчә дулкынландыргыч зур бер төркем образлары тудырылган икән, бу, һичшиксез, әлеге таләпне ныклап тормышка ашыру нәтиҗәсе. Бу нисбәттә безнең хәзерге әдәбиятта эчкеченең характер сыйфатлары, язмышындагы аерым борылышлар турында җитди уйлаткан әсәрләр аз түгел.

Менә Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повестендагы Раббани. Мәһисәрвәр апаның өлкән малае Раббани үз гомерен бик ямьсез чикли — эчкечелектән үлә. Тәнкыйтьче Р. Мостафин Раббаниның булдыксыз, мораль яктан таркалган, хәтта җирәнгеч сәрхүшләргә бөтенләй охшамавын күрсәтә һәм аның фаҗигасендә аракы сатудагы йөгәнсезлек, культурасызлык, яшьләй әчертү кебек чит факторларны төп сәбәп итеп саный. Алай гына түгел әле. Безнеңчә, Раббани түбән тәгәрәүче һәрбер эчкече тибына охшаган. Беренчедән, үзен бик нык яраткан кеше буларак, җиңел, кәсепле эш эзләп коллективтан, халыктан аерыла.

Икенчедән, Раббани, һәрбер исерткечкә бирелгән кеше кебек, бик зәгыйфь характерлы, ягъни характерсыз кеше. Әнә бит туганнары үтенгәч, бик әйбәтләп дәвалыйлар аны. Доктор кат-кат кисәтә: «Безнең дәваның синең гомер буена җитәрлек көче юк. Ул көч үзеңдә. Эчүдән тыелсаң — үзең тыеласың, тыелмасаң — кәкрәеп катарсың...» Әмма юк, Раббаниның рухы көрәшкә өйрәнмәгән. Социаль һәм кешелек тойгылары түгел, хайвани теләкләр баш аңа. Раббани тагын исерткеч эчә башлый, үз ирегендәге ирексезлек белән һәлакәткә атлый.

А. Расихның «Сынау» романы. Инсафлы, ачык күңелле Әлфия үз идеалын күп яктан хезмәттәше — кош фабрикасының баш белгече Фәриттә таба. Әмма тирән алдана ул. Юк, Фәритнең инде хатынлы, ике балалы ир икәнен белгәннән түгел — Әлфия бер-берсенә булган олы тойгылары хакына алдауны гафу итәргә дә әзер — бу кешедәге аныксызлык, куркаклык, ваклык хәтта аз гына да юнь булмауны, эчкечелеген күреп алданганлыгын аңлый кыз. Менә Фәритнең Әлфиягә пычак булып кадалган соңгы запискасы:

«Нинди сәбәпләр аркасында соң мин шундый көнгә калдым? Яраткан эшемне югалттым, дусларны югалттым, балаларымны югалттым. Нидән килеп чыкты бу? Ни сәбәптән, кем гаепле моңа? Моңа син гаепле, Әлфия, бары син, син, син!.. Нәләт төшсен сиңа, гүзәл елан! Әйе, елан син, чөнки син мине генә харап итмәдең, минем балаларымны да ятим калдырдың. Менә шул».

Бу — һичшиксез, эчкече авыру факты. Мондый авыруда эгоизм тойгысы чамасыз көчәя. Эчкече-эгоистның башына «бәлки мин үзем гаепледер, диган уй беркайчан да килми», ул үз-үзен тотышларына тәнкыйть күзлегеннән карауга сәләтсез, дип билгели А. Расих. Әдипнең фикерен врач сүзләре дә дәлилли: «Гаиләдәге күңелсез хәлне ул (алкоголик — С. Х.) һич кенә дә эчкечелек белән түгел, ә уңышсыз өйләнүе белән аңлата. Аның фикеренчә, ул — төрле ыгы-зыгы, талаш корбаны. Аның бәлагә төшүендә ул үзе түгел, ә башка кешеләр гаепле: дуслары, администрация — менә кемнәр аны шундый түбәнлеккә китереп җиткергән» (И. Г. Ураков. Аракы яраткан — акылын тараткан. Уфа, 1981, 29 бит.).

М. Мәһдиевнең «Каз канаты» романының журнал вариантында шундый эчкече, доцент игътибарны җәлеп итеп калган иде. «Үз фәнен белә, студентлар аны ярата, хатын-кыз артыннан чапмый, имтиханда гадел», дип характерлый автор аны. Әмма монда эчкеченең яңа бер фаҗигасе ачыла. Аракы яраткан, акылын тараткан кеше икән: «Лекцияләрен газап белән, үзен дә, студентларны да җәфалап сөйли башлады. Шәп кенә күтәреп җөмлә башлый да ахырын йота. Өр-яңа фикер әйтәме дисәң, аны әйтми калдыра, берәзлексез күзлек алмаштыра».

«Каз канаты» романының икенче бер персонажы Миңнулла да иҗтимагый гөнаһсыз мәхлук тәэсире калдыра. «Бер кешедән бер тиен акча алмый. Салып биргәнне эчми. Эчкәндә дә кибеттән үз акчасына гына. Колхоз председателе Ленар нишә тапкыр җыелышта аны оялтып карады, үгетләде, әмма каты бәрелмәде. Җыелышларның берсендә аның турында сүз чыккач, Миңнулла кызмача хәлдә тел ачты.

— Үз акчама эчүдән ник тыясыз? Демократия шул буламы?»

Чынлап та, Миңнулланың репликасында мәгънә юкмы? Эчсәләр — үз акчалары, сәрхүшлекләре дә үзләренә. Алардан кемгә зыян соң? Бәлки мондый тип исерекләр хакында тавыш куптару да урынсыздыр... Хәер, шулай микән соң ул? Әнә Г. Бәшировның «Җиде-

гән чишмә» романындагы Ризван Чурмантаев, һәркемнең янәшәсенә матур итеп кунаклап, тәртипле тостә тостлар кутәрергә, гомумән, бик әйбәт мәҗлестәш кыяфәтен алырга мөмкин. Ләкин аек карашлы, принципиаль фикер йөртә белүче әдип аңарда, «кызыл муенда», ике зур иҗтимагый золым күрә.

Беренчедән, психологик нигезләнгән хәл: үзе эчкән кеше башкаларны да кыстап эчертә. Ә Ризван Чурмантаев колхоз рәисе — авылдагы һәрбер мәҗлесне диярлек үзе ачып җибәрә:

«... Күтәрәбез мөлдерәтеп хуҗалар хөрмәтенә! Кыстатып утырмыйбыз, тамчысын калдырмыйбыз. Утлар уйнап торсын табын өстендә, эшләгәндәге шикелле, яратам батырларны эштә дә, табында да! Даваегыз!»

Чурмантаевка авырыйм, исәнлегем юк, дип каршы килүчеләр табыла. Әмма беренче рюмкадан дәртләнгән тамаданың (начармы-яхшымы житәкче кеше дә бит!) мондыйларга «һөҗүме» нәтиҗәсез калмый. Эчә кеше, «кылкына, кызара, укшый, күзләреннән яшь килә, шулай да стаканны аудара».

Үзе салырга яраткан Ризван очрак чыккан саен аракының зыянсызлыгы хакында фәлсәфә кора. Яшьләргә йога. Һәм менә шул җитәкче кулыннан гомерендә беренче рюмкасын кабул иткән Гайнан исереп, яшь хатын Язидә каршында мәсхәрәгә кала. Шулай итеп, исерткеч белән мавыккан кешенең халык арасында эчкечелек вирусын таратуы бәхәссез факт.

Икенчедән, Чурмантаев эш кешесе булып ничаклы гына күзгә төтен җибәрергә тырышмасын, әдип аның фидакарь хезмәт иясе түгеллеген фаш итә. Аракы яраткан һәр кешедә газаплы каршылыклар яшәгән төсле, Чурмантаев та эчке көрәштән азат түгел. Җитәкчелек тойгысы белән исерткечкә омтылыш тарткалаша аңарда. Укучы каршында бик табигый итеп Ризванның хатыны врач Тәнзилә ачып сала аны.

— Шундый эчке мәҗлесләрдән соң күпме механизаторың эшкә чыкмыйча кала? Бәйрәм көннәрендә больницага авызы-борыны җимерелгән, кул-аягы имгәнгән күпме исерекбаш килә? Шуларның берсе дә уйландырмыймыни? — дип, чираттагы кунактан кайткач, иренә бик урынлы сорау бирә ул.

Әлбәттә, Тәнзилә сорамаса да яхшы белә председатель: эшкә эленке-салынкы карaш, прогул, өзеклек, бәхетсезлек очраклары аракыдан, аеруча мәҗлес ясап ачыктан-ачык, егылганчы эчеп утырулардан килә. Җитәкче булып, халыктан таләп итәр өчен иң элек үзенең эчүен ташларга икәнен дә күптән аңлаган ул. Белә, аңлый, әмма эчүен дәвам итә. Димәк, эш кешесе, җитәкче булудан бигрәк, эчкече ул. Аңа эчкече психологиясе баш булган. Димәк, ялган иминлек, эчүгә булган омтылыш бу кешене дә алдарга, икейөзлеләнергә, хәтта һәртөрле әшәке тәвәккәллекләргә дә китерергә мөмкин.

Күренә ки, «яшел еланның» тормышта һәм кешедә гәүдәләнгән хамелеонлык рәвеше нинди генә төс һәм формада булмасын, барыбер ул куркыныч. Бу куркынычлык, иң беренче чиратта, «яшел елан»ның табигатьнең иң зур, иң гүзәл казанышы — кеше табигыйлегенә, кеше асылына һөҗүм итүдә, аны таркатуда, бозуда, хәтта һәлак итүдә күренә. Әхлак сагында торган безнең язучылар кыю һәм тәвәккәл рәвештә, «яшел елан»ның шул мәкерен фаш итәләр. Алай гына түгел. Безнең гуманистик әдәбият кешегә ярдәм кулы сузу пафосы белән көчле. Аны Т. Миңнуллинның «Ир-егетләр» драмасындагы колхоз председателе Мәрвән тарафыннан эчкече Әхтәмгә әйтелгән сүзләр конкрет ачып сала: «Бел, ишет, агай-эне, алып чыгам мин сине хак юлга, якаңнан сөйрәп алып чыгам. Тыпырчын, сүген, әллә ниләр әйт, барыбер алып чыгам. Кеше синең кебек яшәргә тиеш түгел, хакың юк».

Золым һәм явызлык белән көрәштә кыю, үтемле көрәш алымнарына ия булган совет әдәбиятының эчкечелеккә каршы көрәше дә чиксез әһәмиятле иҗтимагый чара.

«Туйдырып бетергән үгет-нәсихәткә караганда сәнгать теле белән әйтеп бирелгән идеяләр бик күпкә көчлерәк тәэсир итә. Кайвакыт берәр фильм яисә китапның бөтен бер буын кешеләренә гаять зур йогынты ясавы мөмкин. Без, врачлар, шундый фильм һәм китапларны көтәбез»,— дип яза Геннадий Блинов «Бер авыруның тарихы» исемле популяр китабында.

Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин К. Цеткин белән булган әңгәмәләренең берсендә болай дигән: «Пролетариат — үсеп баручы сыйныф. Ул... исерүгә мохтаҗ түгел. Аңа җенси тотнаксызлыктан исерү дә, алкогольдән исерү дә кирәкми... Ул үз сыйныфының хәленнән, коммунистик идеалдан көрәшкә бетмәс-төкәнмәс көч ала. Аңа ачыклык, ачыклык һәм тагын бер кат ачыклык кирәк. Шуңа күрә... бернинди дә йомшаклык, көчләрне әрәм итү һәм юк итү һич булмаска тиеш. Үз-үзеңне кулда тоту, дисциплиналы булу — коллык түгел». (В. И. Ленин. Коммунистик әхлак турында. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982 ел, 281 бит).

Безгә көрәшче асылыбызны, үз табигыйлыгыбызны саклар өчен бу сүзләрне һәрчак истә тотарга кирәк!

# ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

**«Казан утлары»ның быелгы 2 санында журнал укучылар Р. Сафаров, Л. Леронов хатлары буенча тәрҗемә турында сөйләшү башланып киткән иде һәм редакция тарафыннан берничә сорау да куелган иде. Бу санда сөйләшү дәвам итә.**

## Мәҗит Рафиков:

1. Эчтәлек тулылыгын саклау, милли колорит, метафоралар төгәллеге һ. б. шундый таләпләр — барсы да тәрҗемәнең нигез ташлары инде ул. Бәхәссез таләпләр. Әмма минемчә, тәрҗемә процессына барып җитүдән элек тагын бик әһәмиятле момент бар — ул да булса теге яки бу әсәрне тәрҗемә итәргә алыну-алынмау мәсьәләсе.

Тәрҗемә хакында да һәркем үз тәҗрибәсеннән чыгып фикер йөртә булыр, шуңа күрә фикер шактый субъектив тоелуы да ихтимал. Тәрҗемә ителәсе әсәр минем рухыма, күңелемә, гражданлык хисләремә, эстетик зәвыкларыма чын-чыннан якын булуы кирәк. Миңа калса, ул әсәрнең минем күңелне биләп алырдай эчке бер моңы булырга тиеш. Һәм ул моң минем үзәгемне өзәрдәй нечкә һәм кайнар булса, минем өчен ул җанымны бирердәй кадерле булса, бигрәк тә яхшы. Әйтик, Шәриф Камалның «Матур туганда» романында бу моң Мәдинә белән Фәтхиләрнең, Нәсимә белән Чуртан Халикларның, җаннарын аямыйча яңа тормыш төзүче коммунистлар, комсомол яшьләрнең катлаулы язмышларыннан туа. Алыгыз тагын Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять»ен, бүтән әсәрләрен...

Әсәрнең эчке моңы бик кадерле нәрсә ул минем өчен. Моң бит ул тормыш чынлыгыннан туа. Чын хәлләр, чын язмышлардан, тормышның ачы һәм татлы гыйбрәтләреннән. Шул ук вакытта моң ул тормыш турында тирән уйланулар, сәнгатьчә гомумиләштерүләр нәтиҗәсе дә. Әсәрнең эчке моңы аның идея пафосында да, образлары, характерлары, пейзажларында да, эмоциональ кайнарлыгында, әсәр уята торган хисләр-кичерешләр дөньясында да, әсәрнең аерым җөмләләрендә, тәгъбирләрендә, хәтта күп синонимнар арасыннан сайлап алынган аерым сүзләрендә дә чагылмый калмый. Моң бит ул, борынгы җырлардагыдай, гел кайгылы, гел авыр хәсрәтле, сагышлы гына булмый. Моңның аның, әсәрләренә күрә яктысы, куанычлысы да, кырысы да һәм башка төрле яңгырашлылары да бар. Әсәрнең моңы, минем тоюымча, аның эчке аһәңенә, яңгырашына, эчтәлеге белән форманың гармоник нисбәтләренә турыдан-туры бәйле.

Әгәр дә оригиналь әсәрне күңелемә, рухыма чын-чыннан якын күреп, яратып тотынсам, мин аны инде икенче телнең үзем белгән бөтен чараларын эшкә җигеп, үземнең бөтен тырышлыгым, үҗәтлегем белән рус укучысына җиткерәм. Тулы килеш, кайнар килеш, дәртле, куәтле килеш. Нәкъ үзем яратып күңелгә кабул итеп алган килеш. Хыянәтсез, хилафсыз. Һәрхәлдә кулымнан килгәнчә камиллеккә якын килеш җиткерәм.

Тәрҗемә процессында оригиналның әлеге эчке моңын, яңгырашын мин күңелем белән җөмлә саен тоя, ишетә килэм, һәм шушы моң тойгысы мине дөрес юлда тота, читкә чыгармый, ялгыштырмый. Фәкать мин менә шушы моң яңгырашын колактан ычкындырмыйча, әсәрне баштанаяк бер тын белән тәрҗемә итеп чыгарга тиеш. Шул вакытта аның эчтәлегенә дә, форма якларына да үзем сизеп алырдай зыян килмәячәк. Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повестен, Әмирхан Еники, Ибраһим Гази, Рафаил Төхфәтуллин һ. б. кайбер әдипләребезнең хикәяләрен мин рус теленә нәкъ шушындый хис белән тәрҗемә иттем. Гөнаһларым да бар: ара-тирә кул астыннан бик үк өнәп җиткермәгән әйберләр дә узды. Кемгәдер яхшы буласы килгәндер. Чынлыкта исә вакланырга һич тә ярамый.

Бик ихтимал, бүтән тәрҗемәчеләр хәтта бер үк әсәрне дә, минем кебек, аның әлеге эчке моңы ягыннан түгел, бәлки бөтенләй бүтән ягыннан — әйтик, мавыктыргыч кызыклы вакыйгалар ягыннан, яки образлары, пейзажларының төсләре-төсмерләре ягыннан тотып аладыр. Шулай бит ул: кемнеңдер күзе үткенрәк, кем өчендер әсәрнең кинәт бөтереп алып кереп китә торган маҗаралы вакыйгалары үз стихиясе кебек якын һәм үз, ә кемдер, оста драматургларча, әсәрне иң әүвәл темпераментлар, хисләр, кайнар дәртләр бәрелеше ягыннан, хисләр-кичерешләр ягыннан элэктереп алырга яратадыр. Билгеле инде, боларның берсе дә тәрҗемәченең җитешсезлеге түгел, киресенчә, фәкать көчле ягы. Минемчә, һәр тәрҗемәче үзенең көчле ягына таянып иҗат амплуасын да билгели булыр. Кемгә нинди әсәр ошый бит!

Тәрҗемәче ул сүз сәнгатенә мәхәббәттән туа. Тәрҗемә минем өчен чын сәнгать, югары сәнгать, изге эш. Ул — күпмилләтле илебезнең рухи бердәмлегенә куәт өсти торган сәнгать.

2. Тәрҗемәнең уңышлы килеп чыгуын хәл итә торган нәрсәләр хакында бераз әйттем дә бугай инде. Минемчә, тәрҗемәче милли язучы иңләгәнне иңләргә, ул күтәргәнне күтәрергә, ул үз укучыларына җиткергәнне икенче тел укучыларына җиткерергә тиеш. Тәрҗемәче, сүз остасы һәм художник буларак, милли авторга торырлык булырга тиеш.

Әмма тәрҗемәче өчен иң кирәк нәрсәләр, минемчә, сизгерлек белән чама хисе. Чөнки бөтен хикмәт тә шунда: тәрҗемәдә милли язучының уй-фикерләре дә, сурәтләү чаралары да, сүзнең дәрте-кайнарлыгы да, интонация нечкәлекләре дә — барысы да, барысы да икенче телдә төгәл бирелергә тиеш. Арттырмыйча-шыттырмыйча да, киметмичә, бозмыйча да! Ә сизгерлек белән чама хисе — нәрсә була ул? Талантмы, сәләтме, бусы инде икенче мәсьәлә.

Кыскасы, гомер буе тәрҗемә ит — гомер буе ике телнең мең төрле нечкәлекләренә үтеп кер, гомер буе осталыкка өйрән! Ә ләззәте — чын иҗат ләззәте.

Чама хисе, төгәллек дигәннән, автор белән тәрҗемәче арасында нинди аерма бар, булса, ул аерма нәрсәдән гыйбарәт дигән сорау туу ихтимал. Минемчә, бар ул аерма һәм, әйтергә кирәк, бик бар. Ул аерма драматург белән артист арасындагы аермага бик охшый. Әйтик, Шәүкәт Биктимеров исемле мәшһүр артистыбызны тормышта барыбыз да үзе килеш таныйбыз. Сәхнәдә исә Шәүкәт Биктимеровның «Ш» хәрефе дә калмый! Театрга бер барганда, без Шәүкәт урынына янып-ялкынланып яшәгән Ленинны күрәбез, икенче барсак — Әлмәндәр картны, өченче барсак — әби-бабайларыбыз заманыннан бик хәйләкәр һәм шактый азгын ишан хәзрәтне... Тәрҗемәче дә артист җанлы иҗатчы булырга тиеш. Шәриф Камалның «Матур туганда» романын тәрҗемә иткәндә, мин аны рус телендә нәкъ Шәриф Камалча бирергә тырыштым, Әмирхан Еникинең «Туган туфрак», «Язгы тамчылар»ын — нәкъ Әмирханча, ә Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повестен тәрҗемә иткәндә әсәрнең кырыс хакыйкатен нәкъ Нәби Дәүли стилендә төгәл җиткерергә тырыштым. Бу тәрҗемәләр Казанда һәм Мәскәүдә инде кабат-кабат басылып чыктылар, һәм хәзер үзем дә күрәм, әшне шактый дөрес тотканмын. Шул ук вакытта минем бит әле үземнең дә повестьларым, хикәяләрем дөньяга чыга тора. Менә монда инде мин фәкать үзем генә. Шәриф Камал да түгел, Әмирхан ага да түгел, Нәби Дәүли дә түгел. Үз тематикам, үз стилем, үз моңым. Һәм үземнең әйберләрне дә әле татарчадан бик рәхәтләнеп русчага тәрҗемә итеп чыгарам, минем үз әсәремне дә рус телендә яратып укыган укучыларым бар.

Тукайның прозасын рус теленә тәрҗемә итү эше кузгатылгач, мин, ике уйлап тормыйча, авторлык темаларымны читкә куеп, янә тәрҗемә эшенә тотындым. Бөек Тукаебызны рус телендә чыгару — үземнең авторлык иҗатымнан күп югарырак, мөһимрәк дип күрәм.

3. Тәрҗемәнең югары максаты да шул инде — оригиналның бөтен байлыгын биреп җиткерү. Шуңар омтылмасаң, эшеңнең ни кызыгы кала?

Тәрҗемәгә бирелми торган әсәрләр юк дип саныйм. Әмма авыр, хәтта бик читен моментлар очрый. Бигрәк тә милли үзенчәлекле текстларда. Әйтик, «Айкалмасын, чайкалмасын китергән суларыгыз», дигән юлларда ни кадәр образлы гүзәллек, никадәр музыка бар! Тәрҗемәдә исә, әшкә фәкать сүз ягыннан якын килгәндә, алдан ук күренеп тора: шигъри формага бер дә сыярлык түгел. Хикмәт сүздә түгел шул. Хикмәт — текстның образлы моңында. Күрәсең, оригиналның милли колоритлы эчтәлеген икенче телнең образлы иҗат чаралары белән бирәсе була. Ачкычын тапсаң, булдырасың.

4. Милли телне белмәгән тәрҗемәчегә оригинал әсәрнең бөтен үзенчәлекләрен икенче телдә бирү шактый читен дип уйлыйм. Әмма подстрочник ярдәмендә эшләнгән уңышлы тәрҗемәләр дөньяга чыга тора. Күрәсең, тәрҗемәче үзенең художниклык интуициясе белән алдырадыр, милли автор белән якыннан аңлашып, киңәшеп эшлидер.

Сүзнең нечкәлекләрен яхшы тоя торган, чама хисе үткен тәрҗемәче булганда, турыдан-туры телдән-телгә тәрҗемә итү отышлырак дип саныйм. Әгәр тәрҗемәче үзе дә чын художник булса.

5. Подстрочник ярдәмендә дә безнең язучы һәм шагыйрьләрнең дистәләрчә китаплары дөньяга чыга тора. Югары бәя алган, илгә танылганнары да юк түгел.

6. Русның бер мәкале бар: «Одно дело — лыко драть, другое дело — лапти плесть». Минемчә, бу мәкаль подстрочник ясаучы белән әсәрне шигъри калыпка кертүче арасындагы мөнәсәбәтне бик әйбәт күрсәтә. Дөрес, подстрочник ясаучы милли әсәрнең специфик үзенчәлекләрен аңлатыбрак бирсә, эшнең файдасы артачак, билгеле.

7. Тукайның прозасы белән Такташның поэзиясенә тукталам. Икесе дә — бөек

милли горурлыгыбыз. Бөтенсоюз мәйданында әйбәт тәрҗемәдә чыксалар, бөтен ил укучылары сокланып, яратып кабул итәрлек. Әмма моңарчы чыккан тәрҗемәләрне караганда, кайвакытны кызарырга туры килә. Иң еш очрый торган кимчелекләр нәрсәдән килә? Тәрҗемә эшен — сүзгә-сүз аударып бару дип аңлаудан. Әйтик, Тукай гомере буе иске уку-укыту тәртипләреннән ачы көлгән. Менә бер мисал. «Исемдә калганнар»да ул, абыстайга йөргәндә шаян кызлардан «Кәлиматен тайибәтен...» такмагын ишетеп алуын әйтә дә болай дип өсти: «Ишетелмәгән сүз һәм күрелмәгән нәрсә һәрберсе гыйлем булганлыктан, табигый, мин дә бу сүзне яратып отып алдым. Һәм шуны үземнән надан малайлар каршында тәкърарлап, аларны көлдереп йөрер булдым». Тукайның менә шушы шаян такмакны гыйлем дәрәҗәсенә үк күтәреп җибәрүе һәм үзен инде гыйлем иясе кебегрәк хис итеп, надан малайлар каршысында кабатлаулары белән бераз гына борын чөюендә үзенең абыстайда укып йөрүеннән ничек көлүе ярылып ята түгелме! Ә тәрҗемәдә укыйбыз: «Каждое новое слово и каждая вещь, которую доселе не видел, хорошо запоминается, поэтому, естественно, я запомнил и эти слова, а потом повторял их перед мальчиками, менее грамотными, чем я,— смешил их». Ә ирониясе кайда калды? Бу очракта ирониясез Тукай — Тукай да түгел.

«Халык әдәбияты»ның тәрҗемәчесе «Жизнәкәй» җырындагы җизнәкәйне хәтта чукындырып та җибәрә! Оригиналда җизнәкәй балдызын да «никахлап алып, ике кардәшне бергә җыймакчы була». Тәрҗемәче исә «...пытается обвенчаться с ней...» ди. Татарчадан русчага тәрҗемә итәм, дигәч тә, татарларда булган традицион никахны русларда булган традицион венчание белән алыштырырга ярамый лабаса.

Такташ, минем аңлавымча, лачыннар затыннан. Югары, кыю, киң, тигез очышлы кош. Дөньяга карашы киң, күзе үткен. Әсәрләренең төзелеше, көйләнеше шулай. Әйтик, «Мокамай»ны, «Мәхәббәт тәүбә[иле]н укыганда сюжет, композицияләрен сизми дә каласың. Такташның гармония тойгысы шулкадәр камил, хәтта бөтен татар поэзиясендә гармония хисе анык[ыд]ай үткен булган икенче бер шагыйрь бар микән? Аның образлы фикер йөртүе чиксез иркен, үткен, чая. Бөтенесе үтә дә аңлаешлы, үтә дә табигый. Сокланмаска мөмкин түгел. Такташның шигъри интонациясе белән тәэсирләнеп, аныңча шигырь язып караган яшь шагыйрьләр бихисап. Әмма беренче юлдан соң ук, кая барырга белмичә югалып та каласың (Баштан кичкән хәл!). Ә Такташның исә беренче юллары — беренче канат кагынуы гына икән. Бер-ике генә кагынып ала да гаҗәеп бер җиңеллек белән иксез-чиксез биеклекләргә очып менә дә китә. Бер очып туйгач, кинәт кыйгачлап килеп төшә дә әсәрдәге коллизия дигән нәмәстәкәйнең иң үткен «төшен» тибеп кенә ала һәм шунда ук янә биекләргә очып менеп тә китә...

Такташны русчага тәрҗемә итәргә алынучы берәр көчле шагыйрь табылса, мин аңар Такташ стиленең менә шушы кабатланмас бер үзенчәлеген аңлатып бирүне кирәк дип санар идем. Русның атаклы шагыйрьләреннән Такташка иң якын торганы Есениндыр кебек. Такташны да Есенинны яраткан кебек үк яратып укысалар икән!

10. Әйткәнемчә, чын тәрҗемәчеләр сүз сәнгатенә мәхәббәттән туалар. Безнең татар яшьләреннән ике төркем, Мәскәүгә барып, Максим Горький исемендәге әдәбият институтының тәрҗемә факультетында дүртәр ел укып, дипломнар алып чыктылар. Боларның хәзер кайсысы тәрҗемә белән даими шөгыльләнә соң? Арадан язучылар чыкты, редакторлар чыкты, ә тәрҗемәчеләр?.. Ә анда укымаган махсус дипломсыз Азалия Бадюгина, Эльбрус Ваһаповлар әсәр артыннан әсәр, китап артыннан китап тәрҗемә итеп чыгара торалар. Эшләренең сыйфаты да начар түгел... Димәк, эшкә бирелгәнлекне хупларга кирәк.

1960 нчы еллардан башлап безнең Союз каршындагы тәрҗемәчеләр секциясендә бер төркем рус теленә тәрҗемә итүче яшьләр җыелган иде. Бер алты-җиде ел буе еш кына җыелышып, нык кына эшләп алдылар алар. Җыелган саен яңа чыккан татар хикәяләрен тәрҗемә итәргә бүлешеп алалар иде, җыелган саен яңа тәрҗемәләренең сыйфат ягын тикшерәләр иде. Ел саен татар хикәяләреннән үзләре тәрҗемә иткәннәрен кечкенәрәк кулда булса да берәр җыентык чыгаралар иде — китап нәшриятыбыз бу эшне хуплый иде. Азалия Бадюгина шулар арасыннан күтәрелгән тәрҗемәче, хәзер ул СССР Язучылар союзы члены. Димәк, юкка кайнашмаганбыз.

«Комсомолец Татарии» газетасы үткәргән шигъри тәрҗемә конкурслары да бер нәтиҗәсез калмады. Яшь талантлар, яшь сәләтләр күренде. Димәк, бераз тәҗрибәбез бар, учакка утын өстисе кала. Рус телендә лаеклы тәрҗемәләрен чыгарасы әдипләребез, шагыйрьләребез күбәйгәннән-күбәя.

Минемчә, безгә Язучылар союзыбыз каршында эшләп килгән тәрҗемәчеләр секциясендә даими эшли торган махсус тәрҗемәчеләр мәктәбе булдырырга кирәк — татарчадан русчага тәрҗемә итүче кадрлар тәрбияләү мәктәбе. Ике телне дә белүче сәләтле

яшьләрне секциягә җәлеп итеп, иҗади эш белән кызыксындырып, аларга үсү мәйданы ачарга. Үзебезнең «өйдә» үзебез тәрбияләп үстергән тәрҗемәчеләр — иң ышанычлы осталар булырлар дип уйлыйм.

## Равил Кукушкин:

Тәрҗемә, һичшиксез, әдәбият сәнгатенең башка бөтен жанрлары кебек үк гаять җитди, иҗади һәм җаваплы бер өлкәсе. Авторның укучы алдында тоярга тиеш булган бар җаваплылыгын тәрҗемәче дә тулысы белән үз өстенә ала. Мәгълүм булганча, элеккерәк заманнарда Көнчыгыш һәм татар әдәбиятында назирә традициясе яшәп килгән, бер үк темада һәрбер яңа буын әдипләре үзләренең шигъри көчен сынап караган. Әле яңа чор татар әдәбиятында да, әйтик, К. Насыйри, Г. Тукайның ирекле тәрҗемәләрендә дә, без әлеге иҗади поэтик ярышу тенденциясен бик ачык төсмерлибез. Шуңа аларның мондый рухтагы күп кенә әсәрләре тәрҗемә дип кабул ителми дә: ирекле тәрҗемәне оригинал әсәр белән бер дәрәҗәгә куеп карау — бүгенге тәрҗемә жанрының элгәреләренә зур хөрмәт күрсәтү, аларның мөстәкыйль яшәеш алган югары сәнгать көче алдында баш ию дигән сүз.

Дөрес, бүгенге көндә тәрҗемәнең мәгънәсе шактый үзгәрде һәм тарайды. Бүген ул мөстәкыйль әсәр булудан бигрәк, төп нөсхәнең күчермәсе рәвешендәрәк йөргән, оригинал белән бәйләнешен югалтмаган һәм аның белән берлектә яшәгән әдәби сәнгать төре исәпләнә. Укучы алдындагы төп җавапны автор үзе тота, ә тәрҗемәченең бурычы — әсәрнең икенче телдә төгәл яңгырашына ирешү. Ул — тәрҗемәче генә. Әмма, күрүебезчә, элекке «ирекле тәрҗемәчеләр»дән аермалы буларак, бередә аңа икенче бер яңа җаваплылык та өстәлә — ул оригиналга турылыклы калырга тиеш. Яңа телдә авторның ул тулы хокуклы илчесе. Әсәрнең бу телдә ни дәрәҗәдә яшәеш табуы аңа бәйле. Ул — тәрҗемәче! Язучының уңышлары һәм кимчелекләре өчен дә укучылары алдында ул җаваплы.

Тәрҗемәче иҗатында иң мөһим этапларның берсе — тәрҗемә ителәсе оригинал әсәрне сайлап алудыр, күрәсең. Тәрҗемәченең бу әсәрне яхшыртылырга тиешле дип аңламавы, аңа югары сәнгать әсәре итеп каравы да, билгеле, гаять мөһим факторларның берсе. Моның өчен, әлбәттә, әсәрләрнең дә шундый бәя-хөрмәткә лаеклы булуы кирәктер. Хәлбуки, соңгы вакытта көндәлек иҗат продуктлары, әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан бик үк хуплап каршы алынмаган һәм вакыт сынавын узмаган әсәрләребез дә рус матбугатында, шул исәптән Мәскәү нәшриятларында да, шактый еш күренә башлады. Алар белән беррәттән, һичшиксез, классик язучыларыбызның әсәрләре дә тәрҗемә ителә. Бередә без бер кызык парадокска тап булабыз: оригиналдагы күрексез генә әсәрләргә тәрҗемәчеләр тарафыннан азмы-күпме җан кертелә, ә шундый үк «изге теләктәге» эшкәртелүләргә дучар булган классик әсәрләребез шактый гына тоныкланып кала. Әнә шундый күпмедер «тигезләштерелгән» әдәби продукция Союз укучысына тәкъдим ителә. Әмма бу «изге ниятле» тәрҗемәчеләр колагына ничектер ишеттерәсе иде: классик әсәрләр бернинди үзгәртелү-яхшыртылуларга да мохтаҗ түгел, тәрҗемәченең аларга бердәнбер күрсәтердәй хөрмәте-изгелеге шунда — аларга ул үтә сак килергә, һәрбер кечкенә булып күренгән образ-детале өчен дә укучы алдында үзен җаваплы тоярга тиешле. Кызганычка каршы, практикада моның нәкъ киресе күзгә ташлана. Рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрдә, бигрәк тә классикларыбыз тәрҗемәләрендә, әлеге саклык һәм төгәллекнең җитмәве еш кына безне аптырашка калдыра. Ерак бармыйча, бөек Тукаебыз әсәрләренә генә күз салыйк. Менә аның А. Ахматова тәрҗемәсендәге һәркайсыбызга мәгълүм «Пар ат» шигыре:

Вдруг, открыв глаза, я вижу незнакомые поля,
И разлуку с отчим краем всей душой почуял я.
Край родной, не будь в обиде, край любимый, о, прости,

Место, где я жил надеждой людям пользу принести!
О, прощай, родимый город, город детства моего!
Милый дом во мгле растаял — словно не было его.

Тукта, тукта, ничек итеп «отчий край?», ничек итеп, «край родной?», ничек итеп «родимый город?». Кем турында һәм нинди шәһәр турында сүз бара соң әле бередә? Бу күтәренке романтик рухлы шигырен Тукай 1907 елның язында Җаектан Казанга кайтуын хыялый күзаллап яза түгелме соң? Шигырь шул елның маенда Уральскида «Фикер» һәм «Әлгасрелҗәдит»тә дә басылып чыга. Ә Казанга шагыйрь, мәгълүм булганча, көз көне кайтып төшә. Җаегын Җаек, әмма тик ни өчен «родимый город?». Без, хәтеребезгә генә ышанмыйча, оригинал текстка мөрәҗәгать итәбез:

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин болай, шулай итәм дип, тәрле уй корган җирем.
Хуш, гомер иткән шәһәр! инде еракта калдыгыз;
Ah! таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.

«Торган җир» дигән ич,— «туган җир» димәгән, «гомер иткән шәһәр» дигән. Тукай безгә кабат әйләнеп кайткандай була. Юк шул, Тукай «жил надеждой людям пользу принести!» дип тупас итеп, газета теле белән сөйләмәс. Ул: «Мин болай, шулай итәм дип, тәрле уй корган җирем»,— дип әйтә ич әнә! Инде моннан соң без тәрҗемәне өр-яңадан укып дөреслә́п барырга керешәбез:

Я с родными разлучился, жить несносно стало мне,
И по милым я скучаю, как по солнцу, по луне.

Монысы ни тагы? Нинди туганнары белән конфликтка кереп газаплана шагыйрь? Оригиналны укыйбыз:

Сездән айрылып, туганнар! — җайсыз, уңгайсыз тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.

Тәрҗемә белән татарча текстны аралаштырып укый торгач, лирик геройның Казанга барып керүе дә инде безне әллә ни сөендерә алмый:

Здесь деянья дедов наших, здесь священные места,
Здесь счастливца ожидают милой гурии уста.

Татарларның «изге җир» дип гадәттә Шәһре Болгар я булмаса Мәккә-Мәдинә якларын атауларын белгәнгә күрә, Тукай Казанны да шулай атаганмы икән? дип кабат оригиналга кайтабыз. Ә шагыйрь үзе хур кызларының иреннәренә сусап Казанга ашкынган «счастливец» булып чыгамыни инде болай булгач?

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Шөкер, Тукай алай димәгән икән. Шул елны «Китмибез!» дигән бөек шигырен язган авторга Казанда бабайларның «түрләрен, почмакларын» күрү «изге җир» белән чагыштырганда да кыйммәтрәк булуы бер дә гаҗәп түгел. «Түрләре, почмаклары» сүзендә татар халкының тулы бер трагик тарихи язмышы гәүдәләнә. Күрәбез, биредә тәрҗемә төгәлсез, начар чыккан дип кенә бәяләү аз. Тәрҗемә Тукайның идея-эстетик чынбарлыгын турыдан-туры боза, җимерә, вата, сындыра... Ә бит бу тәрҗемә Тукайның русча чыккан җыентыкларында соңгы елларгача китаптан-китапка күчеп басыла килә!. Бу урында хөрмәтле бер өлкән тәрҗемәчебезнең гыйбрәт итеп күрсәтергә яраткан һәм шулай ук китаптан-китапка күчеп барган «Птицы южные вернулись зимовать в родных краях» юллары искә төшә. Әйе, бу «Мәктәптә» шигыренең дә авторы Г. Тукай һәм тәрҗемәчесе А. Ахматова. Бу очракта да тәрҗемәче автор фикеренә төзәтү кертергә тиеш тапкан.

Әлбәттә, тәрҗемә әсәрләреннән һәрвакытта да мондый тупас хаталар эзләү дөрес булмас иде. Кимчелекләрнең күпчелек өлеше эстетик белдерү чараларына, образ-детальләргә карый. Тукайның дүрттомлыгын (Казан, 1975—1977) ачып җибәргән «Мужик йокысы» (1905) шигырен искә төшерик. Белгәнебезчә, шагыйрь аны рус шагыйре А. В. Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?» шигыреннән файдаланып яза. Шунысы гаҗәп, әдәби тәнкыйтебездә бу әсәрнең тәрҗемә икәнлеге искә алынса да, Тукайның иҗтимагый-социаль карашлары бу шигырьдә мәгърифәтчелектән узмавы ассызыклап үтелсә дә, ни өчендер аның шигъри осталыгы, художниклык таланты кебек аспектлар игътибар үзәгеннән читтә кала килә. Кызганычка каршы, әдәби тәнкыйтебездә идея-тематик, социологик анализлар белән генә мавыгу, әсәрләрне эстетик-структураль һәм функциональ анализ яссылыгыннан чыгып өйрәнү җитмәве бүгенге көндә үзен бик нык сиздерә әле. Тукай әсәрләренә генә түгел, бөтен классикларыбыз иҗатына да нечкә эстетик һәм психологик анализ кирәклеге көн кебек ачык югыйсә.

Алда искә алынган мисалга кайтыйк. Әйтик, бу шигырьдә Кольцовта булмаган — шигырьгә Тукай үзлегеннән өстәгән «синең йортта аш юк туярлык таракан» дигән юллар бар. Ә бит шушы бер җөмлә аша да Тукайның художниклык талантын бик ачык күз алдына китерергә мөмкин. Әйе, бер караганда, игътибар итәрлек әллә ни зур нәрсә дә юк сыман биредә. Тукай бу җөмләсе белән мужикка «синең ашарыңа да юк» дигән фикерне әйтә. Әмма детальләр ярдәмендә сәнгатьле итеп уйлый белгән, конкрет образлар аша зур гомумиләштерүләр ясарга сәләтле Тукай бу информацияне белдерү белән генә чикләнми шул. Дөрес, монда бу фикерне дә ул гипербола ярдәмендә көчәйтеп, зурайтып

ассызыклап куя һәм шуңа ук кушып образга өстәмә мәгънә дә бирә: ашарына булмаса да, өе тулы таракан икән әле... Тукайның сәнгатьчә конкрет фикерләвенә әнә шундый кыйммәтле үзлек, потенциаль көч-энергия салынган. Мондый «яшерен потенциаль зарядлы», чын мәгънәсендә зур талант көчен күрсәтүче «микро-образлар» Тукай иҗатында аз түгел. «Батырлыктан торган җиде еллык иҗат гомерендә» (С. Хәким) шагыйрь аларны йөрәк каны аша уздырып, берәмтекләп җыйган. Ә аның тәрҗемәләрендә исә мондый «кечкенә детальләргә» әллә ни зур игътибар бирелми, тәрҗемәдә ничектер алар «эретелә», «эти малы жәл түгел» дигәндәй, шагыйрьнең тупланган бу потенциаль көче сибелә-таркатыла, шагыйрьнең поэтик куәте сүрелеп кала. Монда бер нәрсә ачык: тәрҗемәчеләргә, димәк, идея-тематик яктан гына түгел, ә бәлки эстетик эшләнеш, образ һәм детальләр системасының тулылыгын саклау юнәлешендә дә без үзебезнең кырыс таләбебезне куярга тиешбездер.

Инде өченче сорауга җавап биреп үтик. Билгеле, «эчтәлек-форма берлеге» кебек абстракт төшенчәләр белән генә эш иткәндә әлеге сорауга җавап табуы бик авыр булыр иде. Әмма эстетик форма, сәнгатьле фикерләүнең үз эчендәге структураль-функциональ закончалыклар белән конкрет эш иткәндә, образлар ясалышының психологик һәм физиологик нигезләрен күзаллаганда — сорау алай ук кыен тоелмый. Шагыйрь яки язучы үзенең әсәрләрендә, әйтик, конкрет атамалы логик образларга таянып иҗат итә икән, һичшиксез, аның әсәрләрен башка телгә тәрҗемә итү күпкә җиңелрәк. Чөнки бу очракта бер телдәге сүзләрне икенче телгә гади «аударганда» да логик фикер, шул исәптән логик образ да димәк, зарарсыз кала. М. Җәлил тәрҗемәләренең русча чагыштырмача әйбәтрәк яңгыравы, минемчә, нигездә шуның белән бәйле дә. «Җырларым» шигырен генә искә төшерик:

Песня меня научила свободе,
Песня борцом умереть мне велит.
Жизнь моя песней звенела в народе,
Смерть моя песней борьбы прозвучит.

Күрәбез, биредәге һәр сүзнең логик образ системасында төгәл үз урыны бар һәм бу система икенче телгә күчергәндә дә үзенең сүзлек составын бөтенләй үзгәртми диярлек. Метафоралы, чагыштырмалы образ-шигырьләр хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Без моны алда китерелгән мисалда да ачык күрәбез — «гомерем минем моңлы бер җыр иде, үлемем дә яңгырар җыр булып».

Мондый логик һәм метафоралы шигырьләрне үз эченә алган уңышлы тәрҗемәләрне без Тукай җыентыкларында да очратабыз:

Вовеки нельзя нашу дружбу разбить,
Нанизаны мы на единую нить.
Как тигры, воюем, нам бремя не бремя,
Как кони, работаем в мирное время,
Мы — верные дети единой страны,
Ужели бесправными быть мы должны?

(«Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре»).

Ә инде менә телдәге төрле фразеологик берәмлек-идиомалардан, синтаксик, морфологик, фонетик чаралардан, милли деталь-орнаментлардан оешкан, башлыча хис-эмоция дулкынына көйләнгән халәт картиналарын, андагы нечкә аһәң, поэтик рухны адекват төстә түкми-чәчми икенче бер телгә алып барып яңгырата алу — чыннан да, күпкә авыррак. Тукайның күп кенә шигырьләрен, Такташ һәм Туфан поэзиясен, шулай ук Дәрдмәнд һәм Ф. Кәрим әсәрләрен дә мин әнә шундый тәрҗемәгә авыр бирелә торган — кабатланмас милли аһәңле рух шигърияте дип атар идем. Тәрҗемәчеләрдән биредә татар культурасын тирән белү, зур әдәби-теоретик әзерлек, югары художниклык сәләте, ярату һәм түземле хезмәт сорала. Кызганычка каршы, бу шагыйрьләр әле чын мәгънәсендә русча укыла дип әйтеп булмый. Мисал итеп Такташтан Л. Мартынов тәрҗемәсендәге ике өзек китереп узыйк:

Идет по снежной улице Алсу,
Такой красавицей,
Такою недотрогою,
И так строга,
Но присмотритесь ближе —
Окажется, что вовсе и не строгая!

Монысы «Алсу» тәрҗемәсенең икенче варианты (Казан, 1971), беренче вариантында «так обаятельна, так молода и так горда собой» (Москва, «Советский писатель», 1955).

Эх!
Вьюга февральская выла на поле вчера
еще.
Тонкий и стройный сегодня к нам март
пришел.
Слушаю мартовский ветер, снега
пожирающий.

Беренче карашка, бөтен образ-детальләр саклана кебек тоелса да, юк, без белгән «Нәни разбойник», без белгән Тукай түгел бу. Безнең Тукай нечкәрәк, моңлырак, хыялыйрак, шаянрак, кыюрак, музыкальрәк, шигърирәк, ялкынлырак:

Их!
Кичә генә әле февраль иде,
Бүген давыл кырга кар ташый;
Март аеның нечкә билле җиле,
Сузылып ятып җиргә, кар ашый.

Иң соңгы бер юлны гына чагыштырып карагыз («Слушаю мартовский ветер, снега пожирающий») — аерма кечкенә түгел...

Редакция тәкъдим иткән башка сорауларга да җаваплар эзләп карыйк. Әмма иң элек мин, аңлашырга җиңелрәк булсын өчен, иҗат процессын ачыграк күз алдына китерер өчен, шартлы төстә генә булса да тәрҗемә итүне дүрт аерым этапка бүлеп карар идем:

1) оригиналның текстын үзләштерү;
2) оригиналның идея-тематик, эстетик-психологик системасын барлау, ассоциатив байлыгын күзаллау;
3) тәрҗемәнең беренчел — механик текстын барлыкка китерү;
4) яңа — тәрҗемә әсәр иҗат итү.

Күрүебезчә, әлеге дүрт этапның икесе оригиналны үзләштерүгә, соңгы икесе — яңа телдә барган иҗат процессына карый. Бу схемадан сорауларда телгә алынган «подстрочник ясаучы»ның һәм «әсәрне шигъри калыпка кертүче»нең тәрҗемәдәге ролен күзаллау кыен түгел: «подстрочник ясаучы» биредә беренче (текстны уку), өченче (текстны «аудару») һәм өлешчә икенче пунктны (әсәрнең эчке рухын күзаллау) үти; оригиналны үзләштерүдә һәм аңа яңа телдә яшәеш бирүдә беренчел әзерлек эшләрен башкара; «калыпка кертүче» — тәрҗемәче исә, нигездә, алдагы өч пункттан файдаланып (беренче һәм өченче пунктларга кыю таянып, икенче пунктны өйрәнеп һәм аңа ориентация ясап), дүртенче пунктны тормышка ашыра — үзенең тәрҗемә иҗат әсәрен тәкъдим итә.

Минемчә, тәрҗемә процессында «подстрочник ясаучы»га да, «калыпка кертүче»гә дә уртак булган иң четерекле һәм иң йомшак урыннарның берсе — икенче пункт. Нәкъ менә шушы тел, текст аспектыннан әсәр системасына — аның рухын үзләштерүгә күчеш ясалган этапта шактый гына нәрсә төшеп юкка чыга да. Биредә «подстрочник ясаучы»ның биреп җиткермәве, «калыпка кертүче»нең алып бетермәве көн кебек ачык. Әмма бу минем «подстрочниклы» тәрҗемәне кире кагуым түгел. Әйтүебезчә, әлеге төр кимчелек оригиналдан турыдан-туры үзе «калыпка салган» тәрҗемәчеләр иҗатына да карый. Бу уңайдан, мин әлеге ике төр тәрҗемәчеләр арасында әллә ни зур аерма күрмим. Димәк, бу негатив күренешне киңрәк итеп — бер этаптан икенчесенә әзерлексез, ашыгып, җиңел багаж белән күчү бәласе дип аңларга кирәктер. Бөтен хикмәт, күрәсең, бу ике төр тәрҗемәләрнең дә үзләрен әдәби тәнкыйтьче, әдәбият белгече — галим итеп тоймауларында. Әйе, тәрҗемә «чиста жанр» түгел. Телисеңме син, юкмы, оригиналга бәя бирергә, аны җентекләп анализларга (димәк, таркатырга, сүтәргә, яңадан җыярга) тиеш буласың, ягъни әдәбият һәм әдәби иҗат теориясенең конкрет законнарына таянып, практик яктан әдәбият галиме, тәнкыйтьче башкарган эшләрне үтәргә тиеш буласың. Дөрес, болар тәнкыйтьтәгечә язма текст аша белдерелми, ә бәлки күңелдән эшләнә һәм иҗат процессында төп юнәлеш бирүче — корректив көчкә әверелә, димәк, бу фәнни системалар әдәби текст коруның төп проектына әверелеп яши. Күрәбез, тәрҗемәдә фәнни анализ һәм художниклык аерылгысыз. Аның уңышы да беренчесенең тирәнлегеннән, икенчесенең осталыгыннан барлыкка килә түгелме соң?! Гомумән, иҗатта «логик анализ»ның әһәмияте ул кадәр үк зур да булмаска мөмкин, автор үзенә иҗат импульсын зур тормыш эченнән ала, өстәвенә акыл, хис, интуиция белән ирекле эш итә, ә тәрҗемәче алдында — әзер, камил әсәр. Аны башка телгә иҗади һәм төгәл итеп күчерә алу өчен йөрәк белән генә тою аздыр, күрәсең. Боларга өстәп, тәрҗемәчедән рациональ фикерләү — анализ ясау сәләте һәм авторга, аның әсәренә якынаю өчен тиешле күләмдә белем, кругозор киңлеге, зур культурага ия булу да сораладыр. Чөнки тәрҗемәче текст белән генә түгел, ә бәлки текстка кермәгән башка бик күп факторлар белән дә эш итә бит. Тәрҗемәче иҗат импульсын оригиналдан чыгып тудыра. Кыскасы, чын тәрҗемәче оста

телче, стилист һәм художник кына түгел, ә бәлки күпкырлы галим, редактор да булырга тиеш.

Минем уемча, бүгенге тәрҗемәләрдәге (хәер, бу үткән еллардагы тәрҗемәләргә дә карый) төп кимчелек икенче этапны тиешенчә үтәмәүдән, тәрҗемәчеләрнең аны өстән-өстән генә һәм «күңелдән генә» кичереп йөгереп үтүләреннән, тирән әдәбият белгече булмауларыннан килә. Мин моны тәрҗемәчеләрнең шигъри талантларына контраст куеп әйтәм, чөнки тәрҗемәдәге аерым кисәкләрнең яңгырашы тәрҗемәчеләрдәге шигъри талантның җитәрлек булуы турында сөйли. Төп бәла шунда — оригиналдагы психологик, эстетик системаның тулылыгы, ассоциатив байлыгы икенче телгә барып җитмәүдә, ягъни тәрҗемәче тарафыннан икенче телгә күчереләсе — «минимум»ның үтәлмәвендә. Әлбәттә, әсәрдәге бөтен табыш-байлыкны 100 проценты белән тәрҗемә итү мөмкин эш түгел. Тел аерымлыгы, милли культура аерымлыгы, художестволы фикер аерымлыгы һ. б. тәрҗемәдә үзен сиздерми калмый. Әдәби әсәр әнә шундый үзгә культуралы, үзенә бер космик системасы булган икенче телдә тулы хокуклы яшәеш, яңгыраш бирү өчен, һичшиксез, «тексттан» күпмедер читкә китү сорала, бу телдә яңгыраш тапмаган образ-детальләрне алмаштыру сорала. Әмма бу тәрҗемәченең яңа космик системада үз авырлыгын бөтенләй югалтып бетерүе диган сүз түгел, билгеле бер «минимумны» ул теләсә нинди шартларда да саклап калырга бурычлы.

Монда «күрә караудан», игътибарсызлыктан, җавапсызлыктан килеп чыккан югалту белән иҗаттагы табигый котылгысыз югалтуны бергә бутарга ярамый. Чөнки биредә сүз дүртенче этап турында түгел, ә бәлки нәкъ менә икенче этапның үтәлеп җитмәве турында бара. Мица калса, бүгенге тәрҗемәнең сыйфатын яхшыртыр өчен эшне нәкъ әнә шул икенче этапка куелган таләпләрдән башларга кирәк. Подстрочник ясаучымы ул, тәрҗемәче үземе, барыбер — әгәр бу этап тиешле фәнни дәрәҗәдә үтәлми икән — тәрҗемә уңышлы чыкмаячак. Тәрҗемәченең «илаһи» таланты гына биредә эшне төзәтә алмый. Шунысын да истән чыгармыйк, әзер тәрҗемә әсәреннән инде бернәрсә дә таләп итеп булмый, аны бәяләп кенә була, аны хуплап яки кире кагып кына була. Ә менә икенче этапның үтәлеш дәрәҗәсен фәнни яктан да, эстетик зәвыкъ ягыннан да әле шактый төгәллек белән «мыскаллап» үлчәргә дә, аны баетырга, тулыландырырга да, аңа һәртөрле ачыклыклар кертергә дә мөмкинлекләр бар. Ул әле безнең кулдагы — очмаган кош. Аерым бер подстрочник ясаучы яки тәрҗемәче әсәрнең күп якларын күрми уздырырга да мөмкин. Ә фәнни эшкәртелгән бу яңа төр подстрочникның тулы, камил булмый чарасы юк. Ул — документ, ул — тәрҗемәчегә бирелә торган визит карточкасы. Тәрҗемәче дә, һичшиксез, аның белән санашмый булдыра алмый — соңгы иҗат продукты чөнки әнә шул фәнни таләпләр югарылыгыннан торып бәяләнәчәк.

Минемчә, классикларыбызның һәр яктан камил булган әсәрләренә әнә шундый фәнни подстрочниклар әзерләү һәм фәнни контроль оештыру зарури бер эш. Һәр изге эшнең җаваплы бер хуҗасы була. Һәм аның таләпләре дә ачык куелырга тиешледер. Шуңа да мин Язучылар союзы каршында нечкә психолог һәм эстетик зәвыгы булган, иҗади практикасы һәм теоретик әзерлеге булган әдип-галимнәрдән тәрҗемә эшен җайга, тәртипкә салу өчен фәнни-тәрҗемә комиссиясе (штабы) төзергә тәкъдим итәм. Ул әлеге катлаулы иҗат эшендә контроль (фильтр) хезмәтен генә түгел, ә бәлки җитәкче бер көч һәм үзәкләштерелгән диспетчерлык ролен дә башкарыр иде. Һәм, әлбәттә, тәрҗемә эшләренең торышы өчен җавап та бирер иде.

Бүгенге көндә тәрҗемә эшен оештыру аерым бер әһәмияткә ия. Киләчәктә исә аның роле тагын да үсәчәк. Шушындый актуаль проблеманы кузгатуы һәм бу җаваплы темага сөйләшергә чакыруы белән «Казан утлары» редакциясе, минемчә, мактаулы адым ясады.

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

**Журнал битләрендә тәрҗемә турында сөйләшү дәвам итә. Сездән кызыклы хатлар һәм мәкаләләр көтәбез!**

библиография

# ЕЛЛАР ҺӘМ ҖЫРЛАР

Композитор Хөснулла Вәлиуллин җырларын инде берничә буын вәкилләре тыңлап үскәндәр. Халык мәхәббәтен казанган әсәрләре белән ул татар музыка сәнгатендә хаклы рәвештә күренекле урын алды. Мөхтәрәм аксакаллар рәтендә йөрүче музыка остасының күңелгә якын җырларын төрле буын артистлар яратып башкаралар: Р. Ваһапов, У. Әлмиев, З. Хисмәтуллина, А. Аббасов, Ф. Насретдинов, И. Шакиров, Э. Җәләлетдинов, Ф. Тимерова, Х. Гыйниятова, Г. Ильясов, М. Галиев...

Иҗатының барлык этапларында да Х. Вәлиуллин җыр жанрына тугрылыклы булып калды. Уңышларының шактые нәкъ менә җырга бәйле. Композитор шуны яхшы аңлый: әйбәт җыр язу, әйтик, симфоник һәм инструменталь әсәрләр тудыру кебек үк авыр.

«Сөй гомерне, сөй халыкны,
сөй халыкның дөньясын...»

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Х. Вәлиуллинның тууына 70 ел тулу уңаеннан чыгарылган «Еллар үтә» исемле җырлар һәм романслар китабы белән танышканда сөекле шагыйребез Г. Тукайның тирән мәгънәле шундый сүзләре күңелдә яңара. Халыкчан һәм халыктан... Иҗатчының бик күп әсәрләре турында без ышанычлы рәвештә әнә шулай әйтә алабыз.

Зөһрә җыры... Драматург Х. Вахитның «Соңгы хат» драмасы өчен язылган әлеге җырны кемнәр генә белми икән?! Ягымлы көй күңелләргә дә чишмәдәй чылтырыйчылтырый агып керә шикелле. Әлеге җырда композитор иҗат иткән иң яхшы лирик әсәрләрнең күркәм сыйфатлары чагыла. «Миләүшәнең туган көне» драмасыннан (Т. Миңнуллин) Миләүшә җыры, «Юллар һәм еллар» пьесасыннан (Ф. Хөсни) «Кошлар тынды», шулай ук «Онытырга мөмкин түгел» (Р. Әхмәтҗанов) кебек җырлар да популярлыкларын җуймыйлар.

Кайвакыт уйлап куясың: озын гомерле җыр ничек языла? Монда нниндидер «сер» бар төсле. Композитор Х. Вәлиуллин нәкъ менә шушы серне беләдер кебек тоела. Үзенең һәрбер җырына ул «йөрәк парәсе» итеп карый. Бөтен сер шунда. Художникның интеллигентларга хас нәзакәтле натурасы ихласлык ташып торган көйләрдә бигрәк тә ачык күренә. Композитор үзенең иҗатын лирика белән генә чикләми. Әсәрләрдә хезмәт темасы да лаеклы чагылыш таба, сугыш һәм тынычлык турындагы җырларга да җитди игътибар бирелә. Музыкаль лениниананга да ул күренекле өлеш кертергә өлгерде. Әлеге мөһим тематикага багышланган әсәрләр арасында «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле җыр (С. Хәким) идея-эстетик гармониялелеккә ирешүе ягыннан аерылып тора. Гомумән, композитор шигъри сүзнең аһәңен яхшы тоя, үзенең вокаль әсәрләрендә шигырь белән музыканың органик бөтенлегенә омтыла. Мәсәлән, С. Хәким шигырьләренә язылган «Киң бу дөнья», «Урал суы буенда», «Синең саф мәхәббәтең», «Өзелгәнсең сиреньнән» кебек лирикфилософик җырлар шундый камиллеккә ирешкән әсәрләрдән санала.

Композиторның иҗат стилендәге төп үзенчәлек, мөгаен, музыкаль фикерне гади һәм табигый рәвештә яңгыратудан гыйбарәттер. Көйнең аңлаешлылыгы һәм яктылыгы Х. Вәлиуллинның халык телендә сөйләшә белүеннән, халык иҗатына якын торуыннан килә. Күп кенә җырларның халык сүзләренә язылган булуы да әнә шул хакта сөйли. Мондый очракта музыка халык рухына бигрәк тә ятышлы булып агыла. Кайбер көйләрнең халыклашып китүе дә бик табигый. Менә шундый җанлы интонация патриотик яңгырашлы җырларда да ачык сизелә. Тыңлаучылар күңеленә хуш килгән «Ленин юлыннан» (халык сүзләре), «Без — совет кешеләре» (Х. Вахит) һ. б. үрнәкләр совет массовый җыр сәнгатендә мактаулы урын алдылар.

Композитор Х. Вәлиуллин белән драматург Х. Вахит арасында кырык елдан артып киткән иҗат дуслыгы күп кенә күркәм әсәрләр тууга китерде. «Дуслык җыры», «Яз айлары», «Зөһрә җыры» кебек әсәрләр авторларның иҗат казанышлары буларак кабул ителде. Рухташлар буларак алар берсенберсе яхшы аңладылар, татар музыка сәнгате мәсьәләләре нечкәлекләрен белеп эш иттеләр. Үзара аңлашуга нигезләнгән иҗади хезмәттәшлек музыкаль-сәхнә жанры өлкә-

сендә дә уңыш казанырга ярдәм итте: алар бергәләп «Самат» һәм «Дим буенда» операларын тудырдылар.

Көй һәм сүз берлеге турында уйланганда, Л. Утесовның мондый фикере хәтергә килә: «Җырдагы сүз һәм музыка, кешегә йогынты ясар өчен үзара «кәрәшеп», тәэсир-көчләрен икеләтә арттыралар... Җыр массовый төстә таралу мөмкинлеге ала — артист башкаруында аны ләззәт белән тыңлап кына калмыйлар, аны халык үзе һәркайда җырлый башлый...» Композитор Х. Вәлиуллинның күп кенә җырлары әнә шундый бәхетле язмышка ия булдылар.

Иҗат эшчәнлеген күпкырлы юнәлештә алып баручы композитор героик-патриотик рухлы балладалар да язгалый. Шундый жанрдагы әсәрләр арасында «Чапай турында баллада» (С. Хәким) иң яхшы традицияләр җирлегендә булуы белән аерылып тора. Милли стиль стихиясе белән баетылган әлеге традицияләр йогынтысы Н. Арсланов һәм Х. Вахит сүзләренә язылган «Туган илем» һәм «Җиңүчеләр килә» кантаталарында да сизелә.

Олыгайган саен — йокылар сак.
Үткәннәргә Хәтер еш кайта.
Таңнарның да алсулыгы кайчак
сугыш яраларын кузгата...

Шагыйрь Р. Фәйзуллин сүзләренә язылган «Хәтер» балладасының музыкасы җыентыктагы лирик рухлы җырлар белән контрастлаша шикелле. Якты моң... Каршылыклы булып тоелган шушы төшенчә әсәр тукымасында ачык һәм тәэсирле гәүдәләнеш тапкан.

Китапка кертелгән яңа җырлар һәм романсларда художникның тормышка һәм табигатькә якты күңел күзе белән каравы сизелә. Әйтик, «Арышларым» җырында икмәк темасы авторның туган йортка һәм кадерле дусларына карата күңел түрендә сакланачы мәхәббәт призмасы аша ачыла. Кыска көй рухындагы заманча халык җырына тартым «Туган җирдә» әсәре дә (Ә. Ерикәй) күңелдә яшәү дәрте уята.

Татар дәүләт академия театры спектакльләренә музыкалар язу Х. Вәлиуллин иҗатының үзгә бер сәхифәсен билгели. Композитор утыздан артык спектакльне музыкалаштырды. «Миркәй белән Айсылу» (Н. Исәнбәт), «Беренче мәхәббәт», «Кайда соң син?» «Соңгы хат» (Х. Вахит), «Шаулыйлар дулкыннар» (Р. Ишморат) пьесалары өчен язылган көйләрне тамашачы яхшы хәтерлидер. Кайбер спектакльләр инде репертуардан төштеләр, ә җырлар яшәүләрен дәвам иттерәләр.

Спектакльгә музыка язуның кыенлыклары турында Х. Вәлиуллин менә нәрсәләр сөйли: «Спектакль режиссеры белән эшләү кызыклы һәм катлаулы... Музыка язу өчен композиторга әзер текстлар тәкъдим ителә. Музыка язучы исә, сәнгатьчә интуиция, югары зәвыкка ия булу белән беррәттән, сәхнә кануннарын да, аерым алганда, геройларның характерын, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, спектакльнең драматургик юнәлешен дөрес тоярга тиеш...»

...Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!..

Патриот-шагыйрь М. Җәлилнең әлеге шигъри сүзләрендә җыр гомере турында гаять акыллы итеп әйтелгән. Өлкән композиторыбыз Хөснулла Вәлиуллин да әлеге хакыйкатьне яхшы аңлый. Татарстан китап нәшриятында басылган җыентыгы исә аның күңелендә яңа әсәрләргә күчәчәк «көч һәм ялкын»ның бетмәс-төкәнмәс булуын раслый.

**Маргарита ФӘЙЗУЛЛАЕВА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# СЫНЛЫ СӘНГАТЬ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Татарстан китап нәшрияты чыгарган китап[1] авторның озак еллар буе архивларда эзләнүе, фәнни хезмәтенең гүзәл җимеше дип саналырга хаклы. Китапның төзелү принцибы мондый: СССР Художниклар союзында торучы һәр рәссам, скульптор, кино һәм театрга оформлениеләр ясаучы, декоратив — кул эшләре остасы, шулай ук һәр сәнгать белгеченә махсус очерк багышланган. Хәтта Союзга әле соңгы вакытта гына кабул ителүчеләрнең дә иҗатларын автор читләтеп үтмәгән. Һәркемнең иҗади йөзен тулаем ачып биргән мондый хезмәтнең әле моңарчы дөнья күргәне юк иде.

Чыннан да, Художниклар союзының оешуы республикабызның культура тарихында зур эз калдырган, яңадан-яңа сәнгать әсәр-

[1] Червонная С. М. Совет Татарстаны художниклары (Сәнгать осталары). Казан, 1984. (Рус телендә.)

ләре килеп чыгуга шартлар тудырган бер вакыйга булып тора. Ләкин автор бу дәверне Татарстан сынлы сәнгатенең башлангычы дип атамый, киресенчә, шундый киң колач алган сәнгатьнең буш урында килеп чыкмаганын фәнни рәвештә исбатлый. Татар халкының милләт буларак яшәү тарихы, аның Болгар заманында, Казан ханлыгы дәверендә культурасы нидән гыйбарәт булганлыгына махсус тукталу; күнчеләр, көмешчеләр, чигүчеләр, тукучылар, хаттатлар (матур язучылар) һ. б. иҗатчылар эшләп чыгарган традицияләргә сокланауын белдерә.

Шул ук вакытта автор объектив рәвештә болай дип фикер йөртә: «Татар халкының сәнгате нинди генә үзенчәлекле милли бизәкләргә бай булмасын, ул барыбер башка халыкларның сәнгатеннән бөтенләй аерылып, үзбашына гына яшәмәгән, бәлки мөселман Көнчыгышы белән дә, христиан Көнбатышы белән дә аралашып, катлаулы мөнәсәбәтләр тәэсирендә яшәгән һәм үскән; үзара бәйләнеш иң якын күршеләр булган Идел-Җаек буенда яшәп яткан төрки һәм угро-фин халыклары (башкорт, чуваш, мари, удмурт, мордва) һәм, ерак булса да, җирле культура өчен аерым дәверләрдә нык тәэсир иткән гарәп (IX-XI йөзләр), Урта Азия (XIII-XIV), борынгы рус (XVI йөздән башлап) культуралары белән дә аралашып үскән».

Бу китапта XVII-XIX гасырларда Казанда яшәгән рус рәссамнарына да зур игътибар бирелә. Нәкъ әнә шуларның вакыт узган саен ныграк активлашуы 1895 елны Казанда сәнгать мәктәбе ачылуга китергән дә инде. Торa-бара ул мәктәп сәнгать үзәгенә әверелә: 1911 елдан башлап ел саен укучы һәм укытучылар ясаган рәсемнәрдән күргәзмә оештырыла, нәкыш әсәрләре шунда туялана башлый. Гәрчә Бөек Октябрь социалистик революциясенә хәтле татарларны сәнгать мәктәбенә якын җибәрмәсәләр дә, бүтән шәһәрләрдә белем алучы, хәтта әле Петербургтагы Сәнгать академиясенә чаклы барып җитүче татар рәссамнары булганын бәян итә автор.

Сәнгать белгече Казандагы рәссамнарның бердәм оешмага тупланганчы төрле исемдәге («Подсолнечник», «Всадник») берләшмәләрдә торганлыкларын әйтеп, ул заманны бездә эшләгән мәшһүр сәнгать осталарын телгә ала: Н. И. Фешин, П. П. Беньков, П. А. Радимов, К. К. Чеботарев, П. Е. Корнилов, П. М. Дульский һ. б. Чорга характеристика биргәндә автор ТатАХРР белән ТатЛЕФ (моңа ияреп татар иҗатчылары да Сулф — Сул фронт оештыралар) яшәп килгәнен, ягъни иҗат көчләренең үзара көрәш белән мавыгып, эшкә зарар китергәнен, партия Үзәк Комитетының 1932 ел, 23 апрельдә чыгарган «Әдәбият-сәнгать оешмаларын үзгәртеп кору турында»гы карарының бу таркаулыкка чик куйганын укучыларга төшендереп бирә. Татарстанда да иҗат көчләрен бергә туплау эшләре нәкъ әнә шуннан башлана. 1935 елны партия өлкә комитеты бюросы республикада совет рәссамнары союзын оештыру хакында карар кабул итә.

С. Червонная бу иҗат союзының эшчәнлеген оешкан көненнән башлап тасвирлый. Шул заманны тулаем күзаллау максаты белән үзәк һәм җирле архивларда гаять күп эзләнә, бөтенләй югалган, онытылган, матбугат битләрендә беркайчан яктыртылмаган, сәнгать белгечләре белмәгән һәм язып чыкмаган фактларны актарып чыгара. Шуның белән бергә, автор бу фактик материалны фәнни яктан нигезләп, укучыга аңлашылырлык итеп язып чыга. Нәтиҗәдә сәнгать осталарының биографияләрен, кайда һәм нинди педагоглардан махсус белем алганын, иҗаты ни рәвешле үскәнен, кайсы күргәзмәләрдә катнашканын һәм иң камил әсәрләре кайда саклanганын тулаем күз алдына китерергә мөмкин булырдай характеристика — очерклар хасил була. Шунысы игътибарга лаек, йөздән артык мондый очерк һич тә бер-берен кабатламый, бәлки, бер максатны күздә тотып язылганга, Союзның илле ел эчендәге бөтен эшчәнлеген тулаем күз алдына китерерлек зур бер картинаны гәүдәләндерә. Һәр останың индивидуаль йөзе билгеләнеп, уңышлы яки уңышсыз хезмәтләренә объектив профессиональ бәя бирелә.

Әйтик, РСФСРның халык рәссамы Бакый Урманченың милли сынлы сәнгатебезне үстерүдә нинди урын алып торганлыгы аермачык күренә. Күпкырлы иҗат иясенең кайсы жанр өлкәсендә кайчан һәм нинди уңышларга ирешкәнлеге тулы күз алдына килә. 1926-1929 елларны, Мәскәүдә Сәнгать академиясен тәмамлап кайткач, рәссам милли кадрлар тәрбияләү максаты белән педагоглык хезмәтенә кереп китә; нәкъ шул дәвердә бөтен Европа сәнгате биеклегеннән торып бәяләнергә хаклы гүзәл картиналарын яза; нәкыш өлкәсендә Урманче, гомумән, иң беренче буларак профессиональ югарылыкта эшләп китә; аннан соңгы утыз ел эчендә рәссам әнә шул иҗат юлын дәвам итә; Мәскәү, Алма-Ата һәм Ташкентларда яшәп, 1958 елны кабат Казанга кайтканнан соң бу останың иҗатында яңа этап башлана — Бакый ага скульптура өлкәсендә гаять олы уңышларга ирешә һәм халкыбызның мәхәббәтен яулап ала.

Автор республикада сынлы сәнгатьнең барлык жанрларына да лаеклы бәя бирә һәм аларның кайсы кайчан һәм ни рәвешләрәк үскәнен тасвирлый, шул ук вакытта сюжетлы тематик картиналарны игътибар үзәгенә ала. Чөнки мондый хезмәт, беренчедән, халыкның тормышында билгеле бер урын алып торган вакыйганы гәүдәләндерсә, икенчедән, рәссамның әзерлекле булуын, искиткеч зур көч куюын таләп итә. Татарстан рәссамнарының төп казанышын бөтен ил күләмендә үткәрелгән күргәзмәләрдә нәкъ әнә шул жанр

билгели. Бу өлкәдә игътибарга иң лаек әсәр итеп автор объектив рәвештә Лотфулла Фәттахов белән Харис Якуповның уртак хезмәтен — «В. И. Ленинның ТАССР оешуы турындагы декретка кул куюы» дигән әсәрне күрсәтә. Китапта бу хезмәтнең республика сәнгате үсешенә зур тәэсир ясаганы әйтелә.

Китапта Әмир Мәҗитов белән Илдар Зариповның туган як табигатен яратып һәм тирәнтен аңлап язган картиналарына идея-художество ягыннан югары бәя бирелә, талантлы рәссамнарыбызның әсәрләрендәге психологик тирәнлекне тулырак итеп күзалларга мөмкинлек туа. Скульптура өлкәсендә зур уңышка ирешкән В. Маликов, В. Рогожин, Н. Адыловларның хезмәтләренә дә ышандырырлык итеп анализ ясала. Автор шулай ук театр өлкәсендә эшләүче рәссамнарыбыз иҗатына матур-матур очерклар багышлый. Халыкны эстетик яктан тәрбияләүдә монументаль әсәрләрнең нинди зур урын алып торганын исбатлый. Яшьләрдән З. Гимаев, Р. Сафиуллин кебек рәссамнарның милли сәнгатебезгә яңа рухи байлык өстәүче талант ияләре икәнлеген дәлилли.

Һәр әсәргә бәя бирер өчен, аның хакында мәгълүматың булырга тиеш. Ә бит сугышка чаклы иҗат иткән күпчелек рәссамнарыбызның хезмәтләре онытылган. Бигрәк тә инде сугыштан әйләнеп кайтмаган кешеләрнең иҗатларына үз вакытында бәя бирелмәгән. С. Червонная Бөек Ватан сугышында ятып калган батырларыбызның язмышларын һәм иҗади байлыкларын ачыклауны, аларга бүгенге көннең сәнгать казанышлары күзлегеннән чыгып бәя бирүне үзенең максаты итеп куйган һәм шундый авыр эшне уңышлы башкарып чыга алган. Бу китапта архивларда гына сакланган шактый материал китерелгән. Китапның гыйльми аппараты, гомумән, игътибарга лаек, җентекләп өйрәнелгән, җиренә җиткереп эшләнелгән. Биредә рәссамнарның төп әсәрләре исемлекләре китерелеп, аларның даталары ачыкланган, дәресләнгән, кемнең нинди күргәзмәдә катнашканлыгы турында тулы мәгълүмат бирелгән, библиография, исемнәр күрсәткече төзелгән.

Бу китап милли республикада эшләүче сәнгать белгечләренә, бер яктан, үрнәк була алса, икенче яктан, алар алдына яңа бурычлар да куя.

Татарстан Художниклар союзының илле еллыгына атап чыгарылган шушы китапның сыйфаты яхшы булуында, әлбәттә, китап нәшриятының, тау чаклы материал арасыннан иң кирәклеләрен сайлап ала белгән таләпчән редакторның хезмәте зур. Кыскасы, бу китап — Союзның көмеш юбилеена бик тә лаеклы бүләк.

**Лилия САТТАРОВА.**

*Яңа әсәр укыгач*

# МӘХӘББӘТ ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Соңгы елларда татар шагыйрәләренең күзгә күренеп ишәя баруын матур күренеш дип бәяләргә кирәктер. Әдәбият сөючеләрне кызларның шигъри табышлары куандыра, уңышсызлыклары борчый. Аларның һәр яңа җыентыгын бөтенсоюз шигърият мәйданына чыгарлык түгелме дигән өмет белән кулга аласың. Менә мин дә «кызлар җыры»на үз өлешен, үз моңын өстәргә омтылган бер яшь шагыйрәнең беренче китабы турындагы кайбер фикерләремне уртаклашмакчы идем.

Шәмсия Җиһангированың «Төсле моң» исемле җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, 1985 ел) хакында сүз бара. Китапның исеме дә, тышлыгы да матур. Укырга тотынмас борын шигъри ачышлар, рухи ләззәт, җан азыгы вәгъдә итә торган. Шәмсия үзе дә китабының беренче битендәге шигырендә үк: «Сезнең белән бүген җыр теленда, төсле моң телендә сөйләшәм...» дип, укучыларның күңелен ымсындырып куя. Китапка мәхәббәт турында язылган (бу төшенчәнең киң мәгънәсендә), туган илгә, туган телгә, олы буынга, кешеләргә чын ярату хисләре белән сугарылган әсәрләр тупланган. Автор «Тормышка карыйм да» шигырендә:

Тормышка карыйм да — сокланам,
Шатлыктан матур җыр көйлимен,
Бар бит, дип, куанам, минем дә
Үз илем, үз җирем, үз телем,—

дип үзен биләгән якты уй-тойгыларны укучы күңеленә төкми-чәчми җиткерергә тырыша. Һәм, әйтергә кирәк, әлеге шигырь поэзия сөючеләрне битараф калдырмас. Бу коры ярату гына түгел: шагыйрә дөньяга, җиһанга мәхәббәтен гражданлык тойгысы белән, ил язмышы, ил иминлеге өчен шәхси җаваплылык хисе белән бәйләп бирә.

Миңа калса, Ш. Җиһангированың әнисенә һәм гомумән өлкәннәргә багышланган шигырьләре уңышлырак. «Әнидән хат», «Җибәрмим», «Күгәрченнәр ашата бер ана» кебекләре хатын-кыз шагыйрьгә генә хас нечкәлек, табигый моң белән өртелгән. Ә инде «Татар карчыгы» исемлесен тулысы белән күчереп алмыйча түзә алмадым:

Бер әбине күрдем әле:
Иңнәрендә мамык шәле,
Аягында чиккән читек,
Әй, елмая матур итеп.

Кулында йоклый оныгы:
Кетеп алган горурлыгы.
Күзем алалмый карчыктан,
Көнләп куйдым картлыктан.

Әйбәт шигырь! «Бабай чәй эчә» дигәне дә матур гына башланып китә. Бер картның «Керт-керт кенә шикәр кабып, шүрдә шүр өреп кенә» чәй эчеп утыру күренешен җылы юмор белән, җанлы итеп тасвирлый да шагыйрә, бабай чәен эчкәч «иплэп алып кесәсенә салып куйды... тешне дә» дип очлый шигырьне. Менә бусы инде — тешләрне кесәгә салып кую — бер дә күңелле тәэсир калдырмый.

Кызганычка каршы, авторга карата канәгатьсезлек тудырырлык әсәрләр тагын очрый. Кайбер шигырьләргә яңа фикер, шигъри ачыш җитенкерәми.

Башым иеп, сәҗдә кылыр идем
Һәр башакка, тирәк-гөлләргә;

яки:

Идел кебек ашкын йөрәгемнең
Тынып торган чагы бар микән?

яисә:

Көязләнә белә каен кызы:
Ефәк шәле гел-гел алышына —
Әле кайчан гына яшел иде,—
Ак шәл ябып чыккан каршыма,—

шикелле юллар, минемчә, укучыга яңалык алып килми, рухи ләззәт тә бирми. Бер шигырьдә «яз кояшы», икенчесендә «май кояшы» төсле чагыштырулар да, еш кабатлана торгач, укучыны ялыктыра башлый. Авторга үз йөзен табу юнәлешендә әле эшләргә кирәк.

Ш. Җиһангированың әлеге җыентыгында мәхәббәт лирикасына, сөйгән ярларга зур урын бирелгән. Алар безгә авторның күңел дәфтәрен ачып салалар:

Яшерен моңнан йөрәгемне генә
Татлы сагыш, бетмәс моң алды.

«Төсле моң»дагы уңышлы шигырьләр белән танышкач, безнең шагыйрәгә зуррак таләпләр куярга да хакыбыз бар. Мәсәлән, алдагы иҗатында шагыйрә логик эзлеклелекне үстерү, сүзгә карата игътибарны арттыру буенча тагын да активрак эзләнсен иде... Әнә шул вакытта аңа күбрәк һәм яңа шигъри уңышлар юлдаш булыр...

**Илдус ДИНДАРОВ,**
Ленинград шәһәре.

Афзал Шамов

# ҮТӘЛМИ КАЛГАН ТЕЛӘК

1944 ел, январь. Беренче Балтик буе фронты.

Газетабызның редакторы майор Минһаҗ Гыймадиев фронт политуправлениесенә барган иде, шуннан бик күңелле хәбәр алып кайтты: редакциябез штатын тагын бер кешегә арттырганнар. Димәк, моннан соң бишәү булачакбыз: редактор, өч корреспондент (шуның берсе яңа алыначак) һәм корректор. Болай булса, эшләр шактый җиңеләя. Югыйсә ялны белми эшлибез, рәтле төн йокысы күргәнебез юк. Кайчак типографиядә генә черем итеп алабыз. Газетаның бөтен авырлыгы Абдулла Әхмәт белән минем өстә: хәбәрләрне дә, репортажларны да, очеркларны да үзебез язабыз, аңа кирәкле материалларны да ут эченнән үзебез алып кайтабыз, рус теленнән тәрҗемә итеп басарга кирәк булган Баш командование приказларын да, әһәмиятле мәкаләләрне дә, барысын да үзебез тәрҗемә итәбез. Бөтен кара эш безнең кулда. Кыскасы, гармунчы да, җырчы да, биюче дә үзебез.

Әле ярый, хәзер машинисткабыз бар. Рәйсә Вәлиева исемле эшлекле, акыллы кыз. Күптән түгел генә Казаннан үзе теләп килде. Татарстан дәүләт нәшриятына да рәхмәт! Машинка бүләк итте. Рус телендәге материалларны хәзер турыдан-туры машинисткага әйтеп торып тәрҗемә итәбез. Бусы башаягы белән минем өстә. А. Әхмәт кулына каләм тотса гына тәрҗемә итә белә,— башкача юк.

Газетабыз болай атнага ике генә чыга. Сугышка чаклы мондый газетада егермегә якын кеше эшләгән. Ә без әлегә дүртәү генә. Инде бишәү булачакбыз. Бу шатлыктан бер биеп алмыйча булмый. Яңа кеше алынгач, сугышлар барган урыннарда да ешрак булырбыз, яңа хәбәрләрне дә күбрәк алып кайтырбыз. Һәр газетаның бик матур бер сыйфаты бар: «Кичә...» дип башланган хәбәрләрне ярата. Тик корреспондент итеп кемне алырбыз, кемне чакырырбыз икән? Бусы редактор ихтыярында. Кеше табу эше аңа тапшырылган. Редакторыбыз яхшы безнең. Мондый эшне безнең белән киңәшмичә эшләми: бер акыл яхшы, ике акыл аннан да яхшырак, ә өч-дүрт акыл тагын да күркәмрәк.

Без, шул хакыйкатьне истә тотып, алдагы санга кирәчәк материалларны туплап бетергәч, үзара киңәшкә утырдык. Һәркайсыбызның күңелендә күптән истә тотып йөргән ике кеше бар: берсе Фатих Кәрим, икенчесе Габдрахман Әпсәләмов. Бераз киңәшкәннән, уйлашканнан соң газетабызга корреспондент итеп Фатих Кәримне алырга дигән фикергә килдек. Барыбызга да таныш егет, шагыйрь, редакцияләрдә эшләгән, тәҗрибәсе зур. Шуның өстенә күршедә, Өченче Белоруссия фронтында гына. Еракта түгел,— бездән берничә йөз километрда гына. Ә Габдрахман еракта, Карелия фронтында. Ишетүебезгә кара-

ганда, анда да татар газетасы чыгарга тора икән. Бәлки, Габдрахманны шул газетага алырлар.

Бер-ике көннән редакторыбыз, Фатих Кәрим турындагы характеристиканы һәм башка кирәкле кәгазьләрне кулына тотып, фронт политуправлениесенә китте. Без аның кайтуын түземсезлек белән көтә башладык.

Редакторыбыз төнлә генә кайтып керде. Йөзенә карау белән үк юлының уңмавын сизеп алдык. Ни булган? Нигә кәефе кырылган?

Политуправлениедә Гыймадиевкә әйткәннәр: «Үзебезнең фронттагы теләсә кемне бирәбез. Кирәк икән, бүген үк чакыртып китерәбез. Әмма икенче фронттан бирәүне дә ала алмыйбыз. Бу эш безнең ихтыярда түгел»,— дигәннәр.

Бу хәбәрне ишетеп, барыбыз да бик күңелсезләндек. Инде нишләргә? Тагын нинди чара күрергә? Әгәр Мәскәүдән Кызыл Армиянең Баш политуправлениесеннән үтенеп карасак? Ләкин мондый үтенечне рапорт буенча, ягъни фронт политуправлениесе аркылы, аның рөхсәте белән генә җибәрергә мөмкин. Башкача берничек тә эшләп булмый. Хәрби тәртип шундый. Шулай да без, әйләнеч юл табып, тагын бер талпынып карарга булдык.

Фронтларда чыга торган татар газеталарына юнәлеш биреп торучы кешеләр бар Мәскәүдә. Аларның кайберләре белән редакторыбыз яхшы таныш. Шуларга үтенечебезне төрле яктан дәлилләп хат яздык... Кызганычка каршы, бу юлы да максатыбызга ирешә алмадык, алардан да күңелсез хәбәр килде: сержантларны, кече офицерларны бер фронттан икенче фронтка күчермиләр икән. Шулай итеп, никадәр тырышсак та, Фатих Кәримне Беренче Балтик буе фронтында чыга торган, «Алга, дошман өстенә» газетасы редакциясенә хезмәткә ала алмадык.

Моннан бер ел элек тә без аны редакциябезгә алырга теләгән идек. Анда да максатыбызга ирешә алмаган идек.

Без бу мәсьәләне тормышка ашырырга тырышып йөргәндә, эшебез уңышлы барып чыкмыйча торып, бу турыда Фатихның үзенә хәбәр итмәскә булдык. Моны иптәшләребезнең дә колакларына тукыдык. Әгәр үтенечебез узган елдагыча тагын кире кайтарылса, аңа бик күңелсез булыр, кәефе кырылыр дип уйладык. Шуңа карамастан, бу хәбәр нинди юллар беләндер Фатихка барып ирешкән икән. Ул 1944 елның 9 маенда Ш. Мөдәррискә язган хатында моны ачык итеп әйтә («Совет әдәбияты», 1959, № 1): «Мин ул Прибалтиканы («Алга, дошман өстенә» газетасы редакциясенә хезмәткә алуны — А. Ш.) бик көттем, ләкин частьта вакытта чакыру булмады. Әгәр мөмкин булса, бернәрсәгә карамый хәзер шунда китәр идем. Язасы килә, монда аның өчен вакыт бөтенләй юк. Мин әдәби иптәшкә очрау ягыннан уңышсыз булдым. Монда берүзем... Гомумән, Шәрәф, миңа бу соңгы җиде елда каләмдәш иптәшләрдән һәм әдәбияттан яртылаш аерылып торырга туры килде...».

Бу юлларны укыгач, миңа моңсу да, үкенечле дә булып китте. Йөрәгемне нәрсәдер чеметеп алды. Аны редакциягә хезмәткә җибәрүләрен кыюрак, батыррак үтенергә кирәк иде дигән фикергә килдем. Ләкин шундук тыныч заман кешесе булып әверелүемне, сугыш шартларын, хәрби тәртипне оныта башлавымны сизеп алдым. Шулай да Фатихның бу хатын укыгач, күңелемдә әрнү калды, үкенү калды, сагыш калды.

1933-1937 елларда мин Фатих Кәрим белән бергә Татарстан дәүләт нәшриятында хезмәт иттем. Икебез дә редактор идек. Тик ул яшьләр-балалар әдәбияты редакторы, ә мин зурлар өчен чыгарыла торган матур әдәбият редакторы идем. Эш урыныбыз дүртенче катта, 84 нче бүлмәдә иде. Безнең белән бергә шул ук бүлмәдә И. Гази, Н. Баян, М. Әмир дә эшли. Алар да редакторлар.

Фатих 1937 елның урталарыннан алып, 1941 елның декабренә хәтле арабыздан югалып торды. Без аны күңелләребездән чыгармасак та, янына барып, үзен күрә алмадык, хәлен дә белешергә мөмкинлегебез булмады.

Бер заман, 1941 елның декабрендә, салкын, күңелсез көннәрнең берендә Фатихыбыз көтмәгәндә, уйламаганда безнең янга, 84 нче бүлмәгә килеп керде. Башта күзебезгә ышанмый тордык. Кем бу? Фатих түгелме соң? Барыбыз да урыныбыздан сикереп тордык, кочаклашып күрештек. Баштарак хәлләребезне сүзләр белән түгел, ә гаҗәпләнеп, рухланып китеп, кыска-кыска әйтелгән нидалар, күз карашлары белән генә аңлаштык шикелле. Аннары әкренләп сөйләшә башладык, исәнлеген, хәл-әхвәлен сорашырга керештек.

Өсте-башы нык, пөхтә. Электәге пальтосы белән электәге костюмы. Күлмәге дә, гадәттәгечә, ак якалы. Галстугы да килешеп тора. Бер дә үзгәреш юк шикелле. Әмма җентекләбрәк карасаң, үзгәреш бар: ябыккан, яңаклары суырылып кергән. Чигә чәчләренә дә чал керә башлаган. Шулай да карасу күзләре ут шикелле яна, шатлыгы йөзенә чыккан. Хәлләребезне бик кызыксынып сораша: кемнәр Казанда да кемнәр фронтта? Фронттагылардан хат киләмә? Соңгы елларда нинди яңа әсәрләр иҗат ителгән?.. Аның өчен барысы да яңа, барысы белән дә кызыксына.

Бераз янибызда басып торганнан соң ул үз өстәле янына барып утырды, аның тартмаларын ачып карады...

Сугышка киткәнче ул безнең янга берничә тапкыр килеп китте. Һәр килгән саен үз өстәле янына барып утыра иде. Күрәсең, өстәлен, әдәби хезмәтне бик сагынган иде шагыйрь.

1942 ел. Январьның беренче көннәре. Тышта зәмһәрир суык. Матбугат йорты тәрәзәләре бозланып каткан. Тәрәзәләр генә түгел, хәтта кайбер көннәрне өстәл өстендәге карабыз да бозга әверелә. Без аны каләмебез очына эләктереп алабыз да, тыныбыз белән эретәбез. Тик шуннан соң гына редакцияләү эшенә керешәбез. Берничә атнадан бирле өстебездән пальто төшкәне юк. Үзебез генә түгел, күңелләребез дә туңа шикелле. Мәзәкләргә, шаярырга яратучы тиктормас Ибраһим Гази да соңгы вакытларда җитдиләнеп китте. Кирәкмәгәнгә көлми, шаярмый. Шулай да тәненә салкын бик үтә башласа, кайчак ул, алдындагы эшен ташлап, урыныннан тора да, бәйдән ычкынган кәҗә тәкәседәй сикергәләргә керешә, безне дә урыныбыздан кузгата. Шулай итеп, бераз җылынып алабыз да яңадан эшебезгә керешәбез. Эшебез аз түгел. Башка сектор кулъязмаларын да редакциялибез. Чөнки иптәшләребезнең күбесе фронтта, сугышта, инде кайгылы хәбәрләр дә килгәләде.

Менә шундый күңелсез, салкын көннәрнең берсендә Фатих Кәрим безнең янга елмаеп килеп керде. Өстендә өр-яңа шинель, башында кызыл йолдызлы бүрек, аны егетләрчә кыңгыр салып кигән, аягында киез итек, билен каеш белән кысып буган. Кием-салымы өстенә ятып, килешеп тора. Килеп керү белән үк ул шатланып кычкырып җибәрде:

— Иптәшләр, ниһаять, мин дә сугышка китәм!

Без, аны котлап, берәм-берәм кулын кыскач, үзен, бүлмә уртасына бастырдык та, кияү егетен тикшергәндәй, әйләндерә-әйләндерә карый башладык. Шинеле калын, җылы. Эчтә пөхтә генә итеп тегелгән сырмасы да бар. Киез итеге дә таза, нык. Туңарлык түгел.

— Күлмәк-ыштаным да андый-мондый гына түгел, ә ефәк материалдан тегелгән,— диде Фатих.

Без, беркадәр гаҗәпсенеп:

— Нигә ефәктән? — дидек.

— Җылы булсын өчен,— дип җавап бирде шагыйрь.

Аның бу җавабы күңелемә аеруча утырып калды. Хәзер дә, бик күп еллар узганнан соң да мин аның бу сүзләрен аерым ачык ишетәм кебек: «Җылы булсын өчен». Чыннан да, ефәк күлмәк-ыштан биргәннәр идеме аңа, әллә һәр солдатка бирелә торган бәз күлмәк-ыштан гына идеме,— анысын тикшереп тормадык, сүзенә ышандык. Чөнки бу сәгатьтә аның күңеле, җаны, бөтен торышы җылы нур белән тулы иде. Ул, кулына корал тотып, илебезнең азатлыгын, бәйсезлеген саклап калыр өчен изге сугышка бара, җаны, вөҗданы кушкан эшкә бара. Моңа чын күңеленнән шатлана иде ул.

Безнең яннан ул шундый җылы, ашкынулы хисләр белән чыгып китте. Без аның дошманны җиңеп, исән-сау әйләнеп кайтуын теләп калдык, язы-

шып, хәбәрләшеп торырга сүз бирдек. Кем белә, бәлки, без дә озак тормабыз, без дә китәрбез. Бер якка, бер үк фронтка эләгүебез ихтимал. Хәер, кая барсаң, кайларда йөрсәң дә бер-беребезнең сәламәтлеген белешеп торырга кирәк. Сугыш! Төрле хәлнең булуы мөмкин.

Ул чыгып киткәннән соң без, үзара сөйләшмичә, беребезгә бер сүз әйтмичә, бераз тын утырдык. Аның бүлмәбезгә шатланып килеп керүе, безнең белән саубуллашып, рухланып чыгып китүе күңелебезне ничектер җылытып, рәхәтләндереп җибәрде. Үзебез генә түгел, хәтта бүлмәбез дә җылынып, киңәеп, яктырып киткән сыман булды.

Берәр вакыйга турында сөйләшкәннән соң күп очракта нәтиҗә ясарга күнеккән Ибраһим Гази бу юлы да сүзен әйтмичә калмады:

— Илебез өчен авыр, сынаулы көннәрдә кемнең кем икәне ачыграк күренә,— диде ул.— Фатих турында әйтүем. Менә ул Фатих! Чын Фатих! Шигырендәге Фатих!.. Ә кемнәрдер аның саф, пакь күңелле кеше икәненә ышанып бетмәгәннәр иде. Юк, кеше булган кешегә ышанырга кирәк! — Аннары ул, бүлмә буйлап әрле-бирле йөрүеннән туктап, минем каршыга килеп басты да: — Хәтереңдәме, Афзал,— диде,— язучыларның беренче съездыннан соң ясалган банкетта бер шагыйрь Фатихка бәйләнгән иде. Хәтерлисеңме икән?..

Хәтеремдә, хәтеремдә ул вакыйга. Әлеге шагыйрь тәнәфес вакытында, фойеда, Фатихны, әле күтәрелеп кенә килә торган шагыйрьне, «иҗатыңда ялганлыйсың син, чын күңелдән язмыйсың», дип гаепләгән иде. Фатих Кәрим, моны ишетеп, бер мәлгә катып калды, аннары, әлеге шагыйрь янына килде дә, якасыннан борып тотты: «Ни сөйлисең син?! — диде аңа.— Ни сөйлисең! Мин ач-ялангач йөрермен, үләрмен, тончыгырмын, әмма иҗатымда ялганламам! Ялганламам! Бел, син моны! Шагыйрь булган кеше беркайчан да ялганламый!» Безгә, Ибраһим белән икебезгә, аларны аерып алып, икесен ике якка алып китәргә туры килде.

Ибраһим сөйләвендә дәвам итте:

— Чын шагыйрь ул Фатих! Адәм балаларының йөрәкләрен айкый ала торган лирик шигырьләр яза белә ул. Чын кеше! Әнә сугышка ничек бара! Туйга барамыни.

1942 нче елның җәендә без аның белән тагын бер тапкыр очраштык. Сугышта яраланып, Казанга, госпитальгә кайткан иде ул.

Казанда, Ленин районында, «Кызыл йорт» дип атала торган бер бина бар. Элеккеге укытучылар институтының ярдәмче хуҗалык бинасы. Кайчандыр ул, Ленин районы барлыкка килгәнче, кыр уртасында бер ялгызы моңсу гына утыра һәм узган-барган юлчыларга ерактан ук күренә иде. Хәзер ул биш-алты катлы йортлар арасында калган, әллә ни күзгә чалынмый. Шулай да аны Ленин районында яшәүчеләр ниндидер бер ихтирам белән һаман «Кызыл йорт» дип атап йөртәләр. Чөнки ул райондагы беренче таш йорт. Сугыш башлану белән үк аны һәм башка шуның кебек биналарны госпиталь иттеләр. Ф. Кәрим менә шул госпитальгә кайтты, шунда дәваланды. Ул анда күпме яткандыр, анысын хәтерләмим, әмма аның шунда «Саратский яшел гармун» (китабында «Кыңгыраулы яшел гармун»), «Идел егете» поэмаларын һәм башка күп кенә шигырьләрен иҗат итүен яхшы хәтерлим.

Бервакыт без, июль аенда булса кирәк, Фатих терелеп җитәрәк, ягъни ул үз аягы белән йөрерлек хәлгә килгәч, госпиталь начальнигына махсус хат язып, яралы иптәшебезне Язучылар союзына чакыртып алдык та, үзара кечкенә генә очрашу мәҗлесе үткәрдек. Фатих бик теләп килде, госпиталь начальнигы аңа гаиләсе янында да берничә көн торырга рөхсәт итте.

Күп түгел идек без ул чакта Казанда, берничә язучы гына: Ш. Камал, Т. Гыйззәт, Г. Кашшаф, И. Гази, К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Разин (Г. Бәширов), Ф. Хөсни, Г. Гобәй һәм тагын берничә кеше. Мәҗлесне чәй белән, ягъни берике кабарлык азык белән, әгәр мөмкин булса, кеше саен берәр «кечкенәне» дә куеп үткәрергә булдык. Кызганычка каршы, теләгебез барып чыкмады. Акчабыз булса да, табынга куярлык сый тапмадык, максатыбызга ирешә

алмадык. Күп кирәкми иде безгә: кеше саен 200 грамм кара ипи белән 20 грамм чамасы ак май, берничә кашык чөгендер винегреты,— шуңа бик канәгать! Артыгы кирәк түгел. «Кечкенәсе» булмаса да ярый Ансыз да көнлелле итеп үткәрә беләбез. Кызганычка каршы, берсе дә барып чыкмады. Өебездән алып килә алмадык. Мөмкинлегебез юк. Кеше башына карточка белән нибары 300-400 грамм ипи алабыз. Шуннан башка берни дә бирмиләр диярлек. Тик, әллә нигә бер генә, балалар карточкасына бераз май, ярма, шикәр комы кебек нәрсә биргәлиләр. Кайчак ай башында ук нәшриятта, эштән соң җыелыш ясап, безгә карточка белән бирелергә тиешле булган азыкларыбызны (икмәктән башкасын) йә фронт файдасына, йә Казан госпитальләрендә дәваланып ятучы яралылар файдасына, йә булмаса, Ленинград блокадасындагы ачлар файдасына бүләк итәбез дип, карар чыгарабыз. Шулай итеп, кайбер айларда шикәр, май ярма карточкаларын кулыбызга да алмыйбыз. Ит мәсьәләсенә килгәндә, анысы карточка белән планлаштырмаган. Акчаң булса, базардан сатып ал. Ләкин бик кыйбат: хезмәт хакы акчасы җиткерерлек түгел. Итсез аш ашыйбыз. Маебыз булганда казанга, ягъни барыбыз өчен пешерелгән ашка (гаиләмдә алты җан), бер-ике бал кашык май тамызабыз. Бу инде бик тәмле аш санала. Балаларым бик яратып ашыйлар, ә минем күземә яшь килә, тамагыма нидер тыгыла. Балаларымны шуннан яхшырак ашатырлык хәлем юк. Безнең генә түгел, барыбызның да хәле шундый... Маебыз булмаган чакларда шулпабызда бер-ике бәрәңге кисәге белән бераз ярма яисә токмач бөртекләре буталып йөрсә, аңа да канәгать. Карынны тутырып, ашыйсы килүне бераз басып торырлык аш кына булсын! Без барысына да риза, барысына да канәгать. Нишлисең, сугыш, мисалы булмаган зур сугыш, аяусыз сугыш. Түзәбез, чыдыйбыз. Тик дошманның гына муены сынсын!

Фатих Кәримне Союз идарәсендә сый-хөрмәт белән каршы ала алмавыбызның сәбәбен яза торгач, сүзем озаккарак сузылды. Дөресе, соңга калып булса да, аны тиешенчә кунак итә алмавыбыз өчен акланасым килеп китте...

Ярар, очрашуның бу ягын читтә калдырып, аның әдәби өлешенә әйләнеп кайтыйк.

Г. Тукай клубының бер башына, өстәл әйләнәсенә тезелешеп утырдык. Казандагы язучыларның күбесе килгән иде диярлек. Нәшрияттан да бер-ике кеше бар иде. Утырышны алып бару эшен миңа тапшырдылар.

Караңгы төшеп килә, тәрәзәләребез калын кәгазь пәрдәләр белән капланган (материядән тегелгән пәрдәләребезне ике тапкыр урлап чыктылар, хәзер кәгазь пәрдә генә корабыз), урамнан караганда якты-фәлән күренерлек түгел. Хәер, өстәл өстендәге лампабыз да сүрән яна. Шәһәрдә электр энергиясе кытлыгы. Сугыш башланганнан бирле бөтен квартираларга, шулай ук учреждениеләргә дә, билгеле күләмдә лимит бирелгән. Шуннан артык ягарга хакыбыз юк.

Фатих, яралы булуына карамастан, тазарган, яңакларына ит кергән. Күңеле күтәренке, шат, иптәшләренә игътибарлы, тыйнак. Тик тавышы гына бераз моңсу, көчсез. Яраланганнан соң көч кереп җитмәгән булса кирәк.

Башта ул үзенең кайсы фронтта сугышуын, ничек яралануын һәм Казан госпиталенә ничек кайтуын сөйләде.

— Шигырьләрем алып кайтты мине монда,— диде ул.— Һәркайда да шигырьне, әдәбиятны яратучылар бар. Язучыларны да ихтирам итәләр... Сугыштан җибәреп торган шигырьләремнең һәркайсын диярлек мин походларда иҗат иттем. Колоннада барасың, иңеңдә автомат, аркаңда бөрмәле капчык, анда бик саклап тотарга бирелгән азыгың, кружка белән кашыгың, бик кадерле дәфтәрең аннан да кадерлерәк патроннарың, гранаталарың... Кыскасы, шактый авыр йөк. Җәй булса, аяк астыбыздан тузан күтәрелә, кыш булса, буран уйный. Ә күңелемдә шигырь юллары. Мин аларны аяк җаена берәм-берәм иҗат итеп, күңелемнән ятлап барам, ягъни һәр юлны хәтеремдә сакларга тырышам. Аннары йә привалларда, яисә окопта, «тыныч» минутларда, кәгаземне автомат түтәсенә куеп язам. Кайчак итегемне салып, балтырын

«өстәл» итеп тә язам. Кул астында такта кисәге булса, зур бәхет. Тезеңә куясың да сызгалыйсың... Окопта да иҗат итәргә тырышам, ләкин анда барып чыкмый. Анда һәрвакыт эш, һәрвакыт сугыш, нервларың киеренке, фикерне башка мәсьәләгә туплап булмый... Ә менә болары, хәзер укыячакларым монда, Казанда, госпитальдә язылды...

Шигырьләрен оста укый иде ул. Күбесен күңеленнән белә. Әдәби кичәләрдә тамашачылар алдына беркайчан да кульъязмасын тотып чыкмый, болай гына укый, тотлыгып, уйланып тормый.

Мәрхүм Һади Такташ та бик матур, бик оста укый иде. Ул әсәрләренең шигъри көче, аһәңлелеге, тирән эчтәлеге белән генә түгел, ә үзенең оста укуы, артистлыгы белән дә тыңлаучыларның күңелләрен сихерли иде. Шулай ук Г. Кутуй белән Сирин дә оста, матур укый иде. Фатих болардан түгел, ә Һ. Такташтан үрнәк алган булса кирәк. Ул да сәхнәгә, халык алдына чыккач, Такташ сыман, башын иеп, бераз уйланып тора. Тик шуннан соң гына, башын күтәреп, кычкырып укый башлый.

Әле генә, берничә минут элек кенә тынып, бераз дулкынланып басып торган шагыйрь, үзе дә сизмәстән, шигыре көченә бирелеп, аның белән бергә яна, ялкынлана, карасу күзләре чаткылана, йөзе дә алсуланып китә. Бу минутларда ул шигыренең эчтәлеге, поэтик көче белән генә яши, аның белән бергә каядыр ашкына, каядыр омтыла сыман... Шулай да ул үзенең халык алдында икәнен онытмый. Дикциясе яхшы, тавышы көр, матур. Тик кечкенә генә кимчелеге бар, кайбер авазларны борыны аша чыгара.

Өсте-башы матур, костюмы яңа, килешле, галстугын җыйнак кына итеп бәйләгән, тулы кара чәче генә киреләнеп, тырпаеп тора. Шагыйрь үзенең шигыре белән, оста укуы белән бөтен залны буйсындырып тора. Тамашачылар аны яратып каршы алалар, алкышлап озаталар.

Ул безгә югарыда телгә алган поэмаларын һәм фронтта, госпитальдә язган шигырьләрен укыды. Сәхнәдәге кебек хәтердән түгел, ә кульъязмасыннан карап укыды. Тик кайбер мизгелләрдә генә ул, онытылып киткән сыман, кульъязмасыннан күзен алып, күңелдән генә укый башлый, аннары аңына килгәндәй, күзләрен яңадан дәфтәренә теки, һәм шигъри юллар салмак кына агуында дәвам итә. Бу әдәби кичә түгел, ә идарә утырышы, фронтовик шагыйрьнең әдәби отчеты. Безгә шагыйрьнең күрмичә укуы, артистлыгы кирәкми — шигыренең эчтәлеге, мәгънәсе, ни дәрәҗәдә сугышчанлыгы кирәк. Без аның әсәрләре турында фикеребезне әйтергә тиешбез.

Тиз генә әйтмәдек фикеребезне. Ул укуыннан туктагач, бер мәлгә тынып калдык. Чөнки барыбыз да әле генә укылган шигырьләрнең сихри көченнән айнып җитмәгән идек.

Башлап кем сүз алгандыр, анысын хәтерләмим, әмма шунысы бик ачык исемдә калган: барыбыз да бер сүзне, бер фикерне әйттек. Шагыйрь үскән, шагыйрь яңа баскычка күтәрелгән дидек, бик кирәкле, әһәмиятле, тирән эчтәлекле әсәрләр иҗат иткәнен әйттек, аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары теләдек; авыр сугышларда батырлык, кыюлык күрсәтеп, явыз дошманны җиңеп, исән-сау әйләнеп кайтуын аеруча теләдек.

Матбугат йорты алдына чыгып басканда инде төн уртасы җиткән, урамда кешеләр азайган иде. Тик ара-тирә генә безнең яннан берән-сәрән узгалап китәләр. Караңгыда безгә аларның үзләре түгел, ә кара шәүләләре генә чалынып кала да, беркадәр вакыт аяк тавышлары ишетелеп тора, аннары алар да тына, югала. Без, өебезгә кайтырга ашыкмыйча, таралышмыйча, Матбугат йорты янында бераз туктап басып тордык. Фатихка ниндидер җылы, йомшак сүз әйтәсебез килә иде безнең. Андый сүзләрне бары зур, изге эшне башкарырга китүче иң якын дусларыңа, туганнарыңа гына әйтәсең.

Таралыштык. Минем якка таба кайтучы кеше юк. Мин караңгы урамнар буйлап бер ялгызым кайтам. Урам фонарьлары янмый, бер йорттан, бер тәрәзәдән дә яктылык әсәре күренми, караңгы, бары күк йөзендә генә меңнәрчә йолдызлар җемелди дә, тулган ай үзенең моңсу нурын сибә. Йолдызлар беркайчан да сүнмәсен, ай да шулай көмеш нурларын җир йөзенә мәңге сипсен иде! Сугышлар бетеп, дошманны җиңеп, дөньяда тынычлык урнашсын иде!

Мин караңгы урамнар буйлап, шулай уйлана-уйлана, үзем генә барсам да, ялгыз кайтмыйм. Минем белән бергә күңелемдә Фатих та кайта, аның шигырьләре, моңнары да кайта, яңгыравык тавышы да кайта. Әле хәзер дә, бик күп еллар үткәннән соң да аның:

Ватаным өчен —
Гомерем, көчем.
Төзәлде ярам,
Данлы сугышка
Яңадан барам! —

дигән юллары колагымда чыңлап тора сыман.

Югарыда китерелгән истәлекнең канваларын мин 1944 елның февралендә, фронтта, онытылмасын, хәтеремнән чыкмасын дип, газета кәгазеннән тупас кына ясалган блокнотыма ашыгып-ашыгып сызгалап куйган идем. Ул көннәрдә Ф. Кәрим исән иде әле. Хәзер арабызда юк инде шагыйрь. Ул 1945 елның 19 февралендә, Бөек Җиңүгә ике ай да егерме көн генә калды дигәндә, илебезнең азатлыгы, бәйсезлеге, шанлылыгы өчен батырларча һәлак булды.

Февральнең карлы, буранлы көннәре иде ул чакта. Балтик диңгезе буе табигате үзенекен итә, кайбер көннәрдә кар аралаш яңгыр да ява иде. Менә шундый көннәрдә Өченче Белоруссия фронты гаскәрләре гитлерчы фашистларны, Көнчыгыш Пруссиядән тар-мар итеп куып чыгарып, калдыкларын Балтик диңгезенә себереп түгү максаты белән каты сугышлар алып бара иде. Мин хезмәт итә торган Беренче Балтик буе фронты гаскәрләренә дә ул көннәрдә шул ук бурыч йөкләнгән иде.

Фашистлар бөтен Көнчыгыш Пруссияне, аеруча шәһәрләрне, аларга таба бара торган юлларны, тауларны, таучыкларны, фортлар, дотлар, блиндажлар белән бик тырышып ныгытканнар иде. Немец-фашист генералларының һәм хәрби белгечләренең сүзләренә караганда, цементлап-тимерләп корылган бу ныгытмаларны бер снаряд та, бер бомба да җимерә алмаячак булган икән. Алар немец хәрби фәненең иң соңгы казанышлары нигезендә шундый итеп корылган һәм урнаштырылганнар ки, Кызыл Армия частьлары анда үзләренең үлемен табачак, имеш. Гитлер генераллары һәм фашист пропагандачылары без Германия чиге ныгытмаларын җимереп кергәнче шулай мактанганнар, шулай лаф органнар иде. Әмма бөтен дөнья халыкларын үзенең көче, батырлыгы белән таң калдырган Кызыл Армия частьлары Көнчыгыш Пруссиядә дә фашистларның барлык ныгытмаларын җимереп, тетеп, «җиңелмәс» дивизияләрен диңгез ярларына таба бик тиз кысрыклый башладылар.

Менә шундый каты, дәһшәтле сугышлар дәвам иткәндә, хәрби пруссакларның үзәк шәһәре булган Кенигсбергка җитәрәк, полк командованиесе кече лейтенант Фатих Кәримовка җаваплы бурыч йөкли: ул үзенең взводы белән 37,8 биеклектән фашистларны тар-мар итеп куып чыгарырга һәм, шунда ныгып урнашып, һөҗүм итеп баручы батальоннарга юл ачарга тиеш.

Фатих Кәрим үзенең взводы белән бу мөһим бурычны каһарманнарча үти, биеклектәге фашистларны тар-мар итеп куып чыгара, батальоннарга алга бару өчен юл ача. Кызганычка каршы, бу сугыш Фатих Кәримнең, атаклы шагыйрьнең, куркуны белмәс солдатның, офицерның соңгы сугышы була — ул шунда һәлак була.

Шагыйрьнең соңгы көне, соңгы сәгатьләре турында татар матбугатында, истәлекләрдә тәфсыйллы мәгълүматлар юк. Шулай да, Ф. Кәрим һәлак булганнан соң, ул хезмәт иткән часть политбүлегеннән Татарстан Язучылары союзына килгән кайгылы хатта бу турыда кыскача гына булса да, кайбер мәгълүматлар бар. «Кече лейтенант Ф. Кәримов, аңа нинди мөһим хәрби бурыч йөкләтелгәнен яхшы аңлап, үзенең взводы белән дошманга каршы кыю рәвештә сугышка ыргылды,— дип язылган ул хатта.— Аның взводы, үзен-

нән берничә мәртәбә көчлерәк булган дошманны кырып, тар-мар итеп, биеклекне яулап алды һәм шунда ныгып урнашты. Фашист бандитлар, аз санлы бу батыр егетләрне биеклектән куып төшерергә теләп, биш тапкыр һөҗүм иттеләр, әмма бишесендә дә, зур югалтуларга дучар булып, кире чигенергә мәҗбүр булдылар. 18 февральдән 19 февральгә каршы бер тәүлек дәвам иткән бу сугышта фашистларның 45 солдаты һәм офицеры үтерелде, 120 кешесе әсир итеп алынды».

Югарыда китерелгән юллар кече лейтенант Ф. Кәримнең һәм аның сугышчан дусларының тиңсез батырлыкларын, кыюлыкларын, Ватаныбызның азатлыгы, бәйсезлеге өчен каннарын да, җаннарын да кызганмаганлыкларын бик ачык күрсәтәләр.

Ф. Кәрим турындагы кайбер мәкаләләрдә каян алынганлыгы билгеле булмаган тагын бер мәгълүмат бар: әгәр дөрес булса, бу сугышта ул ике тапкыр яралана. Беренчесендә дошман пулясы тиеп егылса да, җирдә озак ятмый, шундук урыныннан торып, ярасын кысып тоткан хәлдә взводын алга, әлеге биеклеккә таба алып баруында дәвам итә. «Ур-ра!» кычкырып, биеклеккә барып менәләр, дошман солдатларын штык белән, винтовка-автомат уты белән, гранаталар белән кыралар, калганнарын биеклекне ташлап качарга мәҗбүр итәләр.

Ф. Кәримнең, батыр егетнең, атаклы шагыйрьнең бу сугышта ничек һәлак булуын тәфсилләп сөйләп бирүчеләр юк. Шулай да мин аның характерын, җанын, рухын белгән кеше, бу һәлакәтне болай күз алдына китерәм: Фатих, һөҗүм сугышы барганда икенче тапкыр каты яраланып егылгач та, үләр хәлдә дә аягүрә торып, алга таба тагын бер-ике атлагандыр, тик шуннан соң гына, иптәшләренә алга барырга, дошманны юк итәргә, кырырга команда биргәч кенә, ике кулын җәеп җибәреп, җирне кочкан хәлдә ятып калгандыр дип уйлыйм. Талантлы, саф йөрәкле патриот шагыйрьнең, куркуны белмәс батыр офицерның сугыш кырындагы үлемен мин башкача күз алдына китерә алмыйм.

**Тәуфикъ Әйди**

# ДӘВЕРЛӘРНЕ БУЙЛАП — КИЛӘЧӘККӘ

Мөҗәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры фойесы диварына төшерелгән сурәтләрнең берсендә биюче кыз белән егет гәүдәләндерелгән. Уйнак хәрәкәтләр, җилкенгән тойгылар, яшьлеккә хас күтәренкелек, яктылык мул бу күренештә. Алмагачлары шау чәчәктә, күге аяз. Рәсемгә караган тамашачылар үзләре дә ирексездән сөенечле хисләр кичерми калмый. Сурәтләрнең икенчесендә түгәрәк йөзле уйчан егет курай уйный. Ул бар дөньясы белән көй сихеренә бирелгән. Алсу битле, нәфис бармаклы, зифа буйлы кыз көй тәэсирендә онытылып, курайчының уйнавына әсәрләнеп, кулларын күкрәгенә куйган. Тыңлаучы егет йөзендә дә тылсымлы моңнарның көчле тәэсире сизелә. Өченче рәсемдә — китап укучы ике кыз. Бакчада инде алмалар өлгергән, кызлар да бу җиһанның серенә төшәргә әзер. Алар, кызыксынып, шагыйрь иҗаты белән таныша, ә алгы планда шул кызларның сурәтен ясаучы егет утыра. Аларның илһамланган йөз хәрәкәтләрен тотып алырга һәм киндергә күчерергә ашкына егет.

Әлеге рәсемнәрдә сәнгатьнең төрле тармаклары, гүзәллек дөньясына аяк баскан замандашларыбыз тасвирлана. Алар Чыңгыз Әхмәрев кулына хас гаять нәфис сызыклар, бәйрәмчә якты төсләр бәйләме белән сурәтләнә. Хәрәкәтләрнең салмак нәзакәтлелеге, ритмнар байлыгы сокландырмый калмый. Бизәкле камзул-читекләр, итәкҗиңе, изүләре милли чигешле күлмәкләр, алардагы төсләр гармониясе рәссамның татар халкы тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, казанышларын яхшы белүе турында сөйли.

Әхмәрев сурәтләренең фойе архитектурасын ачып һәм тулыландырып торуын бер карауда тоясың: массив баганалар, салмак сыннар белән бизәлгән карнизларга күз төшкәндә, күңелдә якты, күтәренке кәеф тамыр җәйсен өчен, Әхмәревнең нәкъ менә шул очам-очам дип торган биючеләре, безне тирбәтә һәм йөздерел алып китә торган моңнар таратучы курайчысы, чыраенда нур балкыган башка каһарманнары, яшьлек һәм тормыш билгесе булган шау чәчәктәге алмагачлары кирәк икән ләбаса!

Рәсемнәр бик матур һәм әнә шуңа күрә дә күңелдә сорау туа: кем соң ул Чыңгыз Әхмәрев?

Бервакыт Венеция-Триест поездының пассажирлары да хозурланып тәрәзәдән карап барган калын кашлы, купшы мыеклы, ялтыр маңгайлы ирнең сәгатенә күз салу белән, тынычсызлана башлавын күреп сәерсенгәннәрдер. Чөнки ул пошаманга төшкәннән төшә барып, бер заман поезд чапкан якка күрсәтә дә: «Венеция? Венеция?» — дип сорый. Кыяфәте белән коеп куйган итальян тоелса да, пассажирлар аның адашкан чит ил кешесе булуын шунда гына аңлап алалар. Кунакның СССРдан — Үзбәкстан республикасыннан булуын, милләте татар икәнлеген ачыклагач, алар поездның Югославиягә таба баруын аңлатып, сәер пассажирны якындагы станциядә төшереп калдыралар.

Италия табигатенә гашыйк булган «синьор» Чыңгыз Әхмәревнең чик буена юнәлеп, халыкара конфликт чыгара язуын ишеткән отель хуҗасы мажара иясенә торак өчен кырык мең урынына егерме мең лир генә түләтә.

— Сез ялгышмыйсызмы, Марио әфәнде? — ди турист.

— Юк, синьор Әхмәрев, — ди хуҗа. — Сез гади турист кына түгел, гүзәл рәсемнәр авторы, сәнгать сөюче итальяннарның мәшһүр кунагы да. Шуның өчен ташлама ясыйм, тагын рәхим итегез!

...Чыңгыз Габдрахман улы Әхмәрев 1912 елда Троицк шәһәрендә туа. Аның атасы заманына күрә яхшы ук укымышлы, Төркия, Согуд Гарәбстаны, Мисыр кебек мәмләкәтләргә бер сәүдәгәрнең йомышчысы булып йөреп байтак дөнья гизгән, Риза Фәхретдин белән фикер уртаклашкан, күренекле

төрек язучысы Әхмәт Мидхәт белән әңгәмәләшкән кеше була. Ул кульязмалар, борынгы китаплар җыя, хаҗи булуына карамастан, улының рәсем белән мавыгуын тыймый. Чыңгызда шәрык халыклары мәдәни мирасына, татар тарихына кызыксыну уятырга тырыша. Үпкәсе чирләү аркасында ул коры һавалы җир эзләп 1927 елда Каршы шәһәренә күчеп китә. Булачак рәссам да менә шулай Үзбәкстан җиренә тамыр җибәрә.

Чыңгыз шушы ук елда Пермь сәнгать училищесына укырга керә һәм монда сәләтле татар егете Фәйзерахман Әминев белән бергә белем ала. Каникулларын ата-анасы янында уздыра, Урта Азия халыкларының тормышы, сәнгате, һөнәрчелеге белән кызыксына, базарлар, кәрвансарайлар, архитектура һәйкәлләрен карап йөри һәм беренче эскизларын иҗат итә. 1930 елны сәнгать училищесын тәмамлагач, ул гаиләсе белән бергә Сәмәрканд шәһәренә күчеп килә. Аның иҗаты Үзбәкстан хәятенә, үзбәк сәнгатенә бәйләнеп үсә.

Чыңгызның Казандагы опера һәм балет театрына рәсемнәр ясарга керешүенә аның шундый ук бинаны Ташкентта сурәтләп зур уңыш казануы сәбәп була.

Ташкент театрында үзбәк милли традицияләренә нигезләнгән дивар рәсемнәрен нәфис һәм тормышчан рухта иҗат итү бурычы куела. Нәваи исеме белән аталган залны аның әсәрләрендәге вакыйгалар нигезендә бизәү күздә тотыла. Бу шартларны канәгатьләндерерлек югары профессиональ әзерлекле һәм сәләтле рәссамны табу җиңел саналмый. Ниһаять, бу эшне башкалада белем алган, инде байтак тәҗрибә туплап һәм үзен уңай яктан танытып өлгергән Чыңгыз Әхмәревка тапшырырга карар бирәләр. Аның бөек шагыйрь дастаннарын яшьтән үк укып, күп кенә юлларын ятлап үсүе дә искә алына, әлбәттә.

Озакламый Чыңгыз беренче эскизларын архитектор игътибарына тәкъдим итә.

Уңыш җиңел генә килми, чөнки Әхмәрев үз алдына элек иҗат иткән рәссамнардан аермалы стиль барлыкка китерүне максат итеп куя. Моңа ирешү өчен борынгы миниатюраларны җентекләп өйрәнә, аларның нечкә серләрен ачарга тырыша. Рәсемнәрне кат-кат караудан тыш кульязма мирасны да укый. Менә шуның аркасында аның яңа әсәрләре үзенең тормышчанлыгы, сәнгатьчә ачышы, композицион төзелеше, гәүдәләндерелгән образларының чынлыгы җәһәтеннән куәтле ятышлы, ышандырырлык һәм камил булып дөньяга килә.

Рәссамның Нәваи исемендәге театрны бизәү эше өч ел чамасы дәвам итә. Ул беренче каттагы үзәк фойеда шәрыкнең дүрт гүзәле образын гәүдәләндерә. Искиткеч нәфис, нәзакәтле тасвирланган алиһәләр йөзендә сәнгатьнең төрле тармаклары чагылдырыла. Бу гүзәлләрнең берсе бии, икенчесе саз уйный, өченчесе рәсем ясый...

Икенче каттагы залда да Нәваи әсәрләре сюжетына шулай ук дүрт рәсем ясала. Аларда вакыйгаларның иң күерган җирләре сурәтләнә — «Фәрһад белән Ширин», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Искәндәр ныгытмасы», «Җиде планета» дастаннары каһарманнары күз алдына бастырыла. Әхмәрев бу сурәтләрдә шәрык сәнгате традицияләрен уңышлы дәвам итә һәм үстерә. Бу — вакыйгалар агышының иң кайнар ноктасын сайлауда һәм шәрык миниатюрасы стилен иҗади файдалануда күренә. Чыңгыз эзләнүләренең дөрес юлда булуын соңрак археологлар Афросиаб, Туфраккала һәм башка хәрабәләрдә тапкан сәнгать һәйкәлләре дә раслый.

— Мин үз әсәрләремне һичкайчан миниатюрага формаль охшатырга тырышмыйм,— ди автор. — Ләкин гаҗәеп иҗади мәктәпләр барлыкка китергән Камалетдин Бәһзат, Кацусика Хокусаи кебек бөек сурәтчеләрнең миниатюра әсәрләрен бик-бик сөямен, кадерен беләмен, өйрәнәмен. Миниатюра сәнгате мине буяуларның гармонияле ярашуы, чынбарлыкны тормышчан төстә гәүдәләндерүе, эчкерсезлеге белән әсир итә. Ул минем өчен сәнгатьнең иң югары, барлык үрләрдән дә калкурак, иҗатчыны һаман үзенә күтәрелергә чакыра, өнди торган биеклек. Миниатюра сәнгате минем өчен Италиянең бөек кыл-каләм осталары Джотто һәм Мазаччолар иҗатына тиң.

Традицияләрне тирән үзләштерү белән бергә Әхмәрев миниатюра казанышларын хәзерге заман сынлы сәнгате ирешкән реалистик табышлар хисабына баета.

Миниатюрада каһарманнарның хәрәкәте, бер-берсенә мөнәсәбәте, хис-тойгылары ишарә һәм шартлы алымнар белән ачыла. Чыңгызда инде реалистик алымнар өстенлек итә, шунлыктан идея һәм эчтәлек психологик тирән, җанлы һәм тормышчан ачыла. Нәваи каһарманнарын чагылдырган күренешләр шагыйрь шигърияте төсле нәзакәтле һәм музыкаль тасвирлана. Рәссамның илһамланып эшләгән бу гүзәл сурәтләре 1947 елда СССР Дәүләт премиясе белән бүләкләнде. Әхмәрев хезмәте Үзбәкстанның гына түгел, бөтен совет сәнгатенең зур уңышы буларак кабул ителә.

Аспирантураны тәгәлләгәч, Ч. Әхмәрев Ташкенттагы Хәмзә исемендәге гыйльми-тикшеренү институтында Үзбәкстан дивар бизәү сәнгатен барлау эшенә керешә. Республика шәһәрләрендәге архитекторлар — халык осталары иҗаты белән таныша һәм озакламый «Хәзерге заман үзбәк архитектурасы сәнгатендә халык дивари рәсемчелеге» дигән монография яза. Тикшеренү XIX гасыр ахыры — XX гасырның беренче яртысын эченә ала.

1953 елда Чыңгыз Мәскәү метросының Киев станциясен бизәргә чакырыла. Монда ул халыклар дуслыгын чагылдыручы

«Кызыл мәйданда демонстрация» темасына ясалган мозаик күренешне барлыкка китерүдә катнаша. Аннары СССР күләмендә танылган оста бүтән күренекле сурәтчеләр белән бергә Мәскәүнең «Украина» кунакханәсен бизәргә бара.

Әхмәрев иҗаты үргә атлый. Аның яшьләрнең һәм студентларның VI Бөтендөнья фестивалендә катнашучылар образларын сурәтләве аеруча игътибарга лаек. Чыңгыз анда империализмга, колониячелеккә каршы көрәшүче Африка халыклары вәкилләрен җанлы, тормышчан, үзенә хас холыклы итеп тасвирлый. Хыялга баткан суданлы егет, эчкерсез әңгәмәгә кушылган тоголы кунак, ал төстәге тукымага уралган горур негр егете азатлык сөючө халыкны ачык күз алдына бастыра.

М. Шәехзадәнең «Морза Олугбәк» трагедиясенә акварель белән ясаган иллюстрацияләре Әхмәревнең тарихи темага һәм конкрет шәхескә багышланган беренче тәҗрибәсе була. Монда ул стиль, төсләр уены, ритм һәм форманы гадәттәге миниатюра яки халык сәнгатендәгечә итеп түгел, безнең чор нәкышына хас рәвештә эшли. Морза Олугбәк һәм аның сөйгән яры Фирүзә, Хуҗа Әһрар һәм дәрвишләр, сарай хезмәтчеләре, биючеләр һәм аларның өйрәнчекләре, халык вәкилләре реалистларча гәүдәләндерелә. Төсләр сайлауда саранрак эш итсә дә, сурәтче ярым төсмерләрне урынлы файдаланып, образларны җанлы, рухлы бирүгә ирешә.

Әхмәрев соңрак «Олугбәк йолдызы» нәфис фильмын иҗат итүдә катнаша — эчтәлекне ачарга булыша торган романтик күтәренке рухтагы титр рәсемнәрен, геройларның кием эскизларын ясый. Эскизлар тарихи дөрес, милли үзенчәлеккә ия, образны гәүдәләндерергә ярдәм итәрлек булганлыктан, хуплап каршылана.

Әхмәрев Олугбәк тормышы һәм иҗатын яктыртуны киләчәктә дә дәвам итә. Сәмәркандта галимнең музее өчен сигез композиция ясый, анда каһарманны дәүләт эшлеклесе, остаз һәм бөек гыйлем иясе буларак тасвирлый.

«Олугбәк музеена эшләгән нәкышларында рәссам оста портретчыга хас күзәтүчәнлеккә, югары художество зәвыгына ия икәнлеген, Урта Азия тарихы һәм этнографиясен тирән белүен һәм тарихи жанрның үзенчәлекләрен нечкә тоюын исбатлады»,— ди аның турында сәнгать фәннәре докторы Рафаил Тахташ.

Нәваи исемендәге музей диварларында Чыңгыз авторның газәлләрендә тасвирланган каһарманнарны барлыкка китерә. Яшьнәп-күкрәп торган табигать кочагында чибәр кызлар, матур егетләр, чәчкәләр, куаклар. Әхмәрев монда да инде ачык белгән үз стиленә турылыклы. Хатын-кыз портретларын ул мәгълүм дәрәҗәдә идеаллаштырырга һәвәс. Аккошныкыдай муен, тал чыбыгыдай зифа буй, беләзек кидерерлек нечкә бил! Кайбер рәссамнарның бастырыктай беләкле, дыңгычлап тутырылган капчыктай гәүдәле каһарманнарын күреп күнеккәнгәме, Әхмәрев сурәтләрендәге нәфис кызлардан күп аерылмаган егетләргә күз салгач, түзмәдем, авторга:

— Ирләрне болай нәзберек итеп ясавыгыз аңлашылмый, тормышчанлык югала ич!— дидем.

Якташым тыныч кына елмаеп әйтте:

— Әнкара университеты ректоры да: «Әхмәревнең егетләре кызларына лаек түгел»,— дигән икән. Мин шәрык классик шигърияттен яратам, анда кызларның гына түгел, егетләрнең дә матурлыгы җырлана. Суфичылык шигъриятендә дә шулай. Менә шул сәбәптән мин ирләрне үземчә гәүдәләндерәм. Нәфислек рухи матурлыкны калкурак ача сыман.

Әхмәрев иҗат кешеләрен аеруча яратып һәм бирелеп тасвирлый. Менә «Шагыйрә Зөлфия» портреты. Аның күз карашы, елмаюы туачак образлары әсирлегендә булуын искәртә. Бәхетле чорның хатын-кызларына хас рухи гүзәллек, үз язмышына канәгать иҗатчы турында сөйли шагыйрә портреты. Андагы сызыклар нәфис, буяулар якты-келсу, саргылт, ак төсләр нур чәчә.

Яисә шагыйрә Надирә портретына күз салыйк. Сурәтче башта аның әсәрләрен укый, галимнәрдән сораша, музейда документлар өйрәнә. Рәсемнәренең берсендә ул аны сарай ханәләренең берсендә иптәшләре арасында дутар чиртеп утырган хәлдә сурәтли. Монда зәңгәр буяулар аша чагылган хисләр дулкынландырырлык дәрәҗәдә тәэсирле.

1971 елда сурәтче шагыйрәнең тагын бер портретын ясый. Монда ул аны затлы кием, кыйммәтле ябынгыч бөркәнгән яшь кенә кыз рәвешендә сурәтли. Геройда уйчанлык, ниндидер моңсулык, борчылу сизелә. Чөнки ул шаһ сараена беренче мәртәбә килә. Яңа мохиткә аяк атлаганда, фаҗигале хәлне уйлап, күңеле шик-шөбһә белән тулу табигый.

«Яктылыкка», «Үзбәк биюләре», «Хуш киләсез», «Индонезия тәэсирләре», «Җиде гүзәл»... — Чыңгыз Әхмәрев илле елдан ашкан иҗат чорында барлыкка китергән барлык әсәрләрне санап чыгу гына да бик күп вакытны алыр иде.

Якташыбыз иҗат иткән шәрык гүзәлләре — җиде сарайда Баһрам әңгәмә алып барган җиде гүзәл — әсир иткеч төстә тасвирланган. Бу камиллек гүзәлләрнең холыклары, милли үзенчәлекләре, күзләре, йөз сызыклары, нәфис кулларының назлы хәрәкәтләре һәм киемнәренең төрлелеген-

дә күренә. Бер сүз белән әйткәндә, Чыңгыз Әхмәрев бөек шагыйрьнең үлмәс шигырьләренә тиң образлар барлыкка китерүгә ирешкән. Ул образлар хәзер Әнвәр Ногманов тарафыннан тәлинкәләргә күчерелгән. Ташкент чынаяк заводы күплап житештерә башлаган көнкүреш әйберләре аша да якташыбыз иҗаты, шулай итеп, халыкта матурлык тойгысы тәрбияләүгә хезмәт итә.

Әхмәрев бүгенгедә үткәннең тотрыклы сызыкларын ачу белән бергә, тарихтан заманчалык табарга да омтыла. Моңа мисал итеп җәмәгатьчелекнең мәхәббәтен казанган «Гөлестан» туристик базасы бизәлешен китерергә мөмкин.

Мәгълүм булганча, Якын Көнчыгыш илләренең тормыш-көнкүрешендә соңгы дәвергә кадәр кискен үзгәрешләр булмаган иде. Аларның хуҗалык итешендә, гореф-гадәтләрендә урта гасырчылык иркен хөкем сөрде. Мәскәү, Ленинградларга, Италиягә сәяхәткә барган чакта Яңарыш дәвере осталары Леонардо да Винчи, Микеланджело, Боттичелли, француз импрессионистлары мирасы, замандашлары Андри Матисс, Диего Ривера иҗатлары белән танышудан тәм тапкан Әхмәрев, тарихи темаларны яктыртыр алдыннан шәрык белән танышу файдалы булыр, дип исәпли һәм Гарәбстанга сәфәр чыга.

— Рәхмәт, барысын да күрсәттегез,— ди ул Гыйрактан кайтыр алдыннан хуҗаларга. — Бары тик атаклы Багдад караклары очрамады да, күрсәк бик генә күрергә насыйп булмады. Беренчесенә юлыкмавыма бик шатмын, әмма икенчесенә...

— Иртәгә төнге уникедә әзер торыгыз, машина килер,— ди гид.

Кәефханәгә аларны автомат аскан швейцарлар тентегәннән соң гына кертәләр. Коралды кунаклардан саклаHалар икән.

Бер заман күрергә ашкынган сихри Багдад тамашасы башлана. Симез гәүдәле биюче хатын (гарәпләр юанны ярата икән) шәрә дип әйтерлек хәлдә залга килеп чыга да өстәлгә сикереп менеп биергә тотына. Каһарманнарын баш түбәсеннән алып тәпиенә кадәр киендереп сурәтли торган әдәпле Чыңгыз Әхмәрев, кышлаклардан килеп, Сәмәркандта беренче тапкыр балет тамашасын караучылар төсле, башын аска иеп утырырга мәҗбүр була!

Иҗат кешесе өчен монысы да гыйбрәт, әлбәттә. Шул темага махсус композиция ясарга ниятләгән рәссамга исә ул бигрәк тә кирәк.

Осталыкка илтә торган юл һәрвакыт озын, сикәлтәле була. 1928—29 елларда иҗат иткән берничә рәсемен «Яңа юл» журналына җибәргәч, ул редакциядән «күчереп ясалган сурәтләрне кабул итмибез», дигән кош теле кадәр җавап хаты ала. Берничә елдан соң Ташкентка аяк баскач кына сурәтенең редакциядәгеләргә бик ошавын, әмма аларның мондый җитлеккән рәсемне яшь егет үзе ясавына шикләнеп, «йомып» калдыруларын ачыклый.

Гүзәл корылмаларга бай Сәмәркандта халык гамәли сәнгате үрнәкләре Чыңгызга шифалы тәэсир итә. Атаклы чигүче, чүкүче, зәргәр, чүлмәкче, борынгы бизәкләргә җан өрүчеләр яши монда. Яңа ачылган «Сынлы сәнгать фабрикасы»нда байтак сәләтле осталар эшли. Аларның иҗатына Чыңгыз дикъкать белән күз сала, беренче рәсемнәре белән игътибарны җәлеп иткән егет үзе дә шунда хезмәткә урнаша. Сурәтчеләр заман вакыйгаларын массага җиткерү өчен стена газетасы, «мактау тактасы» макетлары, стендлар, плакатлар әзерлиләр. Әмма Чыңгызны бу гына канәгатьләндерми, хәзер инде ул дивар рәсемнәре ясау белән мавыга башлый.

Дивар рәсемчелеге сәнгать тармаклары арасында иң борынгылардан санала. Мисыр, Һиндстан, Яңарыш дәверендәге Италия, урта гасырлардагы Европа һәм Урта Азиядә бик күп гүзәл әсәрләр иҗат ителә. Гел кеше күз алдында торганлыктан, мәһабәт рәсемчелек шул ук вакытта гадәттән тыш халыкчан да. Дивар сурәтләре зур мәйданлы, бина архитектурасы стиленә, үзенчәлегенә аваздаш булу белән генә түгел, алган темасы, тасвирланган күренеше, вакыйгаларның, яратылган образларының, алар аркылы үткәрелгән фикер һәм идеяләрнең байлыгы, эчтәлегенең тирәнлеге, вакыт узу белән әһәмиятен, фәлсәфи кыйммәтен җуймавы белән дә аерылып тора. Шуның өстенә дивар рәсемнәре нык, буявы дәвер узу белән уңмый торган материаллар кулланып эшләнә.

Мәһабәт сурәтләр иҗат итү, гадәттә, эскиздан башлана. Рәссам анда булачак әсәренең темасы һәм идеясен гәүдәләндерүче сюжетны, әсәрнең буяуларын, тасвирланачак предметның күләме һәм урынын ачыклый. Эскиз канәгатьләнерлек хәлгә килгәч, рәссам аны зуррак кәгазьгә күчерә. Чөнки дивар рәсемнәре сыланган өслеккә пыяла яки вак таш түшәп ясалганда, аны соңыннан төзәтү, үзгәртү кыен, кәгазьдәге сурәт исә аны төп өслеккә ясауны җиңеләйтә.

Әхмәрев иҗатының беренче адымнары илебездә мәһабәт сәнгатьне үстерү өчен киң мөмкинлекләр ачылган чорга туры килә. Социализм җиңүләре аның нык җирлеге була. Олы-олы биналар калку, төзелеш көчәю дивар рәссамнарына да мәйданны киңәйтә. Шушы чорда Үзбәкстанда Б. Хамдами, А. Волков, У. Тансыкбаев кебек рәссамнар беренче мәһабәт рәсемнәрен барлыкка китерә. Чыңгыз Әхмәрев тә ВХУТЕМАСның мәһабәт сәнгать бүлеген тәмамлаган В. Савин белән бергә шәһәр, кышлакларны гизеп,

күп кенә этюд, эскизлар ясый, тәҗрибәле иптәшләре белән фикер уртаклаша. А. Волков исә дивари сәнгать серләрен ачып, Чыңгызның кызыксынуын тагын да дөрләтеп җибәрә. Урал Тансыкбаевның «Басмачыларны кулга төшерү», «Сельмаш», «Җәйләү» кебек мәһабәт әсәрләре аңа аеруча көчле тәэсир итә. Күз явын алырлык борынгы буяу, мозаика каплаган, сырлап бизәкләнгән, парчалы ефәк киемнәр кигән архитектура һәйкәлләре дә Чыңгызны көчен сынап карарга дәртләндерә һәм ул эшкә керешә.

Бу чорда Чыңгыз иҗат иткән дивар сурәтләре балалар бакчасы, клуб, кызыл чәйханәләрне бизи. Мисалга, чәйханә диварындагы рәсемдә ике колхозчы — бер ир белән бер хатын китмән күтәреп трактор артыннан баралар. Ул рәсем гадилеге, тыгыз оешуы, кечкенәлеге һәм бер яссылыкта бирелеше белән Гражданнар сугышы чоры плакатларын хәтерләтә. Шул ук вакытта анда шәрык дивар сәнгате традицияләре дә чагылыш таба. Бу декоративлык, бина сызыкларына туры килү һәм тасвирны бер төрле буяу — күе яшел төс белән бергәндә балчык стена төсен җирлек сыйфатында урынлы файдалануда күренә.

1935 елда Әхмәрев Мәскәүгә килә һәм мәшһүр сурәтче В. Фаворскийга эшләрен күрсәтеп, югары белем алырга хыяллануын белдерә. Фаворский аның әсәрләрен ошатып, Суриков исемендәге Мәскәү художество институтында икенче курстан башлап укырга мөмкин, дигән фикерне әйтә. Чыңгыз монда өч ел графика бүлегендә белем ала, аннары нәкыш бүлегенә күчә. Дүртенче курсны инде ул институтның мәһабәт рәсемчелек факультетында дәвам итә. Монда ул И. Грабарь, Н. Чернышевлардан сабак ала, зур һәвәслек белән Веронезе, Микеланджело, Рафаэль, Рублевлар иҗатын өйрәнә һәм үз стилен эзли. Файюм осталары миниатюралары, болгар-татарның кабер таш язмалары, дагстанлыларның көмешкә чүкеп ясаган әсәрләре, шулар арасында бигрәк тә шәрык халыклары гамәли сәнгате, шигърияте һәм музыкасы Әхмәревнең зәвыгын тәрбияләүдә күренекле роль уйный. 1942 елда диплом эше буларак «Үзбәкстан кылычы» триптихын иҗат итә. Ватанчыллык хисләре тәрбияли торган бу уңышлы әсәр сурәтченең осталыгы арта бару хакында сөйли.

Менә шулай иҗатчының үзенә хас юлы, темалар даирәсе, яраткан сюжетлары барлыкка килә. Озакламый аның рәсемнәре үзбәк совет сәнгатендә вакыйга буларак кабул ителә башлый. Уңышның сере беренче чиратта шәрык мәдәнияте традицияләренә яңа сулыш өргә бәйләнгән була...

1965—69 елларда Әбү Рәйхан Бируни исемендәге Көнчыгышны өйрәнү институты фойесы стеналарына төшерелгән рәсемнәрдә инде сурәтченең иҗади осталык үренә күтәрелүе бик көчле гәүдәләнә.

Бу институтта көнчыгыш халыкларының гасырлар буе җыйган тәҗрибә һәм акыл җимеше — бик күп борынгы кульязмалар, китаплар саклана. Шуңа күрә дә рәссам композициясендә китап аша халыкларның тәҗрибә, белем хәзинәсе өлкән буыннан яшенә тапшырылуын, бөлдергеч сугышлар вакытында китаплар һәм кульязмалар яндырылуын, алар белән бергә кыйммәтле фикер, белемнең дә юкка чыгарылуын, сугыш чорында культураның харап ителүен, тыныч чакта аның чәчәк атуын гәүдәләндерергә карар кыла. Алтмыш дүрт квадрат метр мәйданда алебастрга темпера белән эшләнгән рәсемдә яшәү белән үлемне, кеше хәятенең сабый чак садәлеген һәм картлык камиллеген, адәм баласының иҗади кодрәтен илбасарлыкка капма-каршы куярга тели.

Композиция гарәп язуы кебек уңнан сулга үсеп китә. Менә шәһәргә килеп кергән кәрван мәдрәсә яныннан узып бара. Юлаучыларның кулларында кучтәначләр, берсенекендә — татулык нияте белән килүләре хакында язылган язу. Шәһәрдә дә иминлек: бәхетле гаилә, китап укучы онытына сокланып торучы карт, биюче кызлар, күк йөзе картасына төбәлгән галимнәр, музыка тыңлаучы хатыннар, чәчәккә сузылган бала, остазлары биргән үгеткә колак салып торучы төрле кавем арасыннан җыйналган белемгә һәвәс шәкертләр. Соңгылары — шагыйранә рухлы, ак күңелле, эчкерсез җанлы, өлкәннәр киңәшенең кадерен белә, хикмәтле сүзләреннән илһам ала торган — кыскасы, эчке дөньясы да, тышкы кыяфәте дә гүзәл яшьләр рәвешендә сурәтләнә. Шагыйрь үзенең шәкертләрен язгы купшы киемен бөркәнгән бер куак янына алып килә дә, аның бер чәчәген өзеп алып:

— Менә шушы гүзәл чәчкәне гападги туфрак үстергән шикелле, сез дә иң гадәти сүзләрдән шигърият барлыкка китерергә тиеш,— ди сыман. Ул Әхмәревнең яраткан шагыйре Дәрдмәнд кебек:

Матур гөлләргә бул былбыл, нәзакәт багына сакчы,— дип үгет бирәдер шикелле. Сурәтченең бу композицияне нәкъ менә шул юллар тәэсирендә иҗат итүе игътибарга лаек. Кайгыртучан, таләпчән, үз иманына җаны-тәне белән бирелгән садә күңелле Хәсән Туфанны да хәтерләтә аларның остазы. Әгәр Чыңгызның утызынчы елларда ук шагыйрь әсәрләренә гашыйк булуын, Туфанга хат язуын да искә алсак, бу охшашлык тагын да көчәя төсле!

Менә икенче манзара. Кара козгын өередәй ябырылып яу якынлаша. Китапханәләргә ут төртелә, стенасына «Белемгә омтылу һәркемгә фарыз» дип язылган мәдрәсә яндырыла, агач куышына китап яшереп куярга тырышкан галимгә кара сугышчы ук ата, гүзәл биналар пыран-заран китерелә, хәрабәләр ишәя, шәфкатьсез үлем канатын җәя, ялкын чорнаган кульязманы дошман сөңге очына кадап байрак урынына күтәргән, вәйран ителгән коточкыч тормышны күрәсе килмәгәнлектән, дәрвиш күзен йомган, зиратта яңаданяңа кабер ташлары күренә.

Өченче күренештә иҗади башлангычның, тереклек көчләренең сугышны җиңүе сурәтләнә. Корылмалар төзәтелә, бакчачы нәни онысы белән бергә куак утырта, архитекторлар яңа бина макетын тикшерә, балалар төзүче булып уйный, бакчалар чәчәк ата, гашыйклар сәхрә чигә, гаиләдә яңа сабый туа. Илдә тынычлык рухы көчәя, хезмәт һәм иҗат тантана итә башлый.

Бу сюжетка салынган идея әлеге күренешләрне тоташтырган арык һәм көрван ярдәмендә калку ачыла. Су агышы, көрван йөрүе — тормыш агышын, табигать капма-каршылыгы көрәше, үзгәрешләре аша алга баруны гәүдәләндерә. Бер буын эшен икенчесе дәвам иттерә, китап кешегә балачагыннан алып картлыгына кадәр юлдаш була, яктылык караңгылыкны, яхшылык яманлыкны, тынычлык сугышны җиңә, ди рәссам. Әхмәрев бу композициясендә дә хезмәт ияләренең гүзәллеген җырлый.

Әсәрнең тасвир чаралары, чагылдыру ысуллары һәм стиле заманыбыз сәнгать теле мөмкинлекләре белән яңартылган художество традицияләренчә бирелгән. Әмма гадәттәге перспектива кагыйдәләре кулланылмау, тасвирланган вакыйгаларның бер мизгелдә һәм бер урында бармавы, күренешләрнең янәшә сурәтләнүе, бу манзарадагы куаклар, гөлләр, кошлар һәм хайваннар, биналар һәм төрле корылмалар кайбер борынгы дивар рәсемнәрендәгечә шактый шартлы ясалу, композициянең аһәңдәш ритмы, сызыкларның музыкальлеге электән калган сәнгать мирасы әсәрләрен, аларда кулланылган канун һәм алымнарны хәтерләтә. Әхмәрев шәрык осталары сөеп кулланган зәңгәр, шәмәхә, ал, көрән, ачык яшел буяуларны урынлы файдалана. Бируни исемендәге институт диварындагы әсәрдә киемнәр һәм кораллар, каһарманнарның йөрешторышлары, милли холкы миниатюралардагыча табигатенә, яшәеш рәвешенә хас рәвештә бирелә. Халык авыз иҗаты, шәрык язма әдәбиятында тасвирланганча, сурәтче үз геройларын түгәрәк йөзле, зур кара күзле, каләм кашлы, зифа буйлы итеп, әмма анатомия үлчәмнәре һәм нисбәт кануннарын бозмыйча гәүдәләндерә, кичәяләрне шартлы күрсәтми, эчке тойгыларны, рухи гүзәллекне, баһадирлык сыйфатларын, кичерешләрне җанлы һәм тормышчан итеп ача.

Әхмәрев тарихи үткәнне яктыртканда да чын заманча иҗатка ия. Чөнки заманчалык рәсем эчтәлегендә генә түгел, бәлки замандашыбыз хисләренә, гүзәллек төшенчәсе таләпләренә хуш килә торган рәвештә гәүдәләндерә белүдә дә ич әле. Заманыбыз өчен актуаль идеяләрне чагылдыруда да.

«Көнчыгышны өйрәнү институты диварларында зирәк, хикмәтле остаз сурәтләре. Мин сезне нәкъ менә фикер иясе, философ һәм остаз буларак таныйм»,— дип хат яза авторга тамашачыларның берсе. «Сезнең картларыгыз олы җанлы, миһербанлы. Базарлардагы сәүдәгәрләрегез дә философ шикелле. Рәсемнәрегезгә, гомумән, шигърият, рухлану хас»,— ди икенчесе.

Әхмәрев, чыннан да, картларны сурәтләргә ярата. Алар милли киемнәре, хикмәтле, нурлы кыяфәтләре белән рәссамга шигърият чәчәк аткан урта гасырларны хәтерләтә. Шул ук вакытта якташыбыз каһарманнарына кеше рухын олылый торган сыйфатлар бирергә, аларны артык индивидуальләштерүдән бигрәк шартлы хосусияттә, фәлсәфи-гомумиләштерелгән төстә гәүдәләндерергә һәвәс. Романтик халәттәге затларны идеаллаштырылган гүзәллек дәрәҗәсенә җиткереп, әмма гомум кешелек рухын чагылдырырлык рәвештә күз алдына бастыра.

Әйтергә кирәк, илленче еллардан башлап ук инде Әхмәрев әсәрләренең күчермәләре күп санлы күргәзмәләрдә куела, китапларда һәм вакытлы матбугатта басылып, меңләгән сәнгать сөючеләргә килеп ирешә. Бервакыт шулай ике яшь язучы Әндиҗан тирәсендәге тауларга күтәрелгән һәм шунда ял итеп алыр өчен тау башындагы бер чәйханәгә кергән икән. Карасалар, бүлмәнең бөтен диварларына Чыңгыз Әхмәрев рәсемнәренең күчермәләре ябыштырылган. Үтә кырыс шартларда яшәүче хуҗа карт:

— Мин бүтән рәссамнарны яратмыйм,— дип белдерә.

Сурәтче «Ике тел дастаны» фильмына кием эскизлары ясау тапшырылгач, урта гасырлардагы шәрык мәдәнияте белән җентекләп танышыр өчен Төркиягә һәм гарәп илләренә сәяхәткә китә. Истанбулда, Каһирәдә ягымлы мөнәсәбәт күрсәткән хуҗаларга истәлеккә рәсемнәрен бүләк иткәч, алар:

— Рәхмәт! Искиткеч гүзәл сурәтләр!— дип соклана. Багдад рәссамы М. Гариф әфәнде исә авторны болай дип хәйран

калдыра: «Бер әсәрегез миндә бар иде инде, журналдан кисеп алган идем!»

Рәссамның танылуы турында илебезнең төрле почмакларыннан килгән күп санлы заказлар да ачык сөйли. Әхмәрев, җае чыккан саен, әледән-әле берничә шәкертен ияртеп, ерак сәфәргә чыгып китә. Нәтиҗәдә Днепропетровскида культура сарае, Кемеровода драма театры, Сәмәркандта «Йолдыз» чәйханәсе, Красноярскида «Баһор» кафесы, Сочида «Үзбәкстан» шифаханәсе диварларына да Әхмәревнең тылсымлы кулы кагыла. Картонга төшерелгән сурәтне диварга күчерү эшен автор үзе башкармаска да мөмкин. Әмма Чыңгыз ага җаваплы өлешләрне һәрвакыт үзе ясарга тырыша. Чөнки күчерү процессында җирлегенә карап буяулар я сыек, я куерак чыгу ихтимал, моны автор үзе генә яхшырак исәпкә алып, вакытында төзәтергә мөмкин.

Сочида «Үзбәкстан» шифаханәсенең ял итү залын бизәү тапшырылгач, Әхмәрев анда ясалачак рәсемнәрдән якты сибелүе; гөлләр иленең тыныч рухы җанны иркәләве урынлы булыр, дип уйлый. Елның дүрт чорында табигать һәм кеше хәятенең мәңгелек агышын — картинаның өске өлешендә ел фасылларын гәүдәләндергән традицион хатын-кызны, аста яз, җәй, көз, кыш күренешләрен сурәтләргә карар бирә.

Залның дүртенче стенасы пыяладан булып, аннан тау киртләчләре, диңгезгә төшә торган сукмак күренә. Рәссам ясарга уйлаган сурәтләр, шулай итеп, тышкы дөньяга бик килешле тоташып китә.

Ел фасылларын диварда сурәтләү хыялы Әхмәрев күңелендә күптән борынлаган, тик ул аны кая ясыйсын гына белми аптыраган була. Чөнки, аның уенча, мондый сюжет тормышны фәлсәфи гомумиләштереп чагылдырырга мөмкинлек бирә.

Менә ул пәри кызы рәвешендә очып килүче яз образы — яшь, нәфис, матур. Өрфия күлмәгенә әле бизәкләр кунарга да өлгермәгән — изү, итәк-җиңнәрендә генә каймалар бар. Кулында җир йөзенә сибәргә алган тәлинкә тулы гөлләр. Табигать уянган — җылы яктан кошлар килә, балалар кышкы торгынлыктан соң онытылып уйный, тирә-як яшел юрганын ябынган. Җимеш агачлары шау чәчәктә. Агач күләгәсендә кошлар сайравына колак салып кырын яткан шагыйрь безне табигать хозурына чакыра:

Яз. Чәчәктә гөлләр,
яшелләнде бакчабыз,
Килегез, гәп корып, дуслар,
күңел ачабыз!

Менә җәй күренеше. Шушы чорга хас бай, матур киемнәрен кигән кызның уң кулында яңа өлгергән җиләк-җимеш, сулында — иҗатының иң биек ноктасына күтәрелгән шагыйрьгә бүләккә ниятләнгән яшел ботак. Тереклек тантанасы. Аргамагында очып килгән ялкынлы егет тормыш агачы күләгәсендә мәгъшукасына мәхәббәтен аңлата. Мәшһүр шагыйрьнең тау түбәсендәге ак чатырына төрле халыкларның иҗатка һәвәс егет-кызлары менеп бара. Данлыклы сүз остасының тормышка мәдхия укый торган газәле яңгырый:

Җәй фасылы: сөйгән ярлар, дуслар
сизми вакыт узуын...

Менә өченче күренеш: яфраклар саргая, чәчәкләр сула, җимешләр коела. Көз билгесе — табигать өлгерткән бар байлыкны үзенә җыйган гүзәл кыз бер кулына җамаяк күтәреп, икенчесе белән йөзем, алма, анар, груша һәм башка җимешләр өеп куелган подносны, кувшинны кочаклап, безне соңгы мәртәбә бәйрәмгә чакыра сыман. Бәлки ул тормыш давылларын исән-сау кичкән, ботаклары шәрәләнгән агач астында таякка таянып торган шагыйрьнең гомер узуына уфтанып чыгарган моңлы шигыренә колак саладыр?

Аһ, саргая дөнья, көлә көз
йөземә карап,
Корыган ботакта калган, диеп,
ялгыз яфрак.

Соңгы күренештә җиргә чал төс кергән. Салкын буяулар табигатьнең йокыга талуын чагылдыра. Аксыл яулык бөркәнгән, зәңгәр киемгә төренгән кыш пәрие тереклек символы булган утны кулы белән суык җилләрдән ышыклап, яңа елга алып китеп бара.

Аисыз төнгә көмеш карын
сибә кыш,
Караны ак белән каплап
килә кыш.

Яз — яшьлек гүзәллеге, җәй — адәм баласының җитлегүе, көз — җан иярәренең картаюы, кыш — кеше тормышының сүнүе. Әмма композиция оптимистик рухлы, чөнки кыш әле тереклекнең бетүе түгел, ул яңадан чәчәк ату, мәйданга кешеләрнең яңа буыны килүнең алшарты гына. Рәссам идеясен ачуда кояш та мөһим роль уйный. Язын ул чыгып кына килә, җәен — баш очында, көзен — батышка тәгәри, кышын — офыкка елышкан.

«Ел фасыллары» рәсеме чынбарлыкны гомумиләштереп һәм образлы чагылдырып җиһанның матурлыгын ача, аның кадерен белергә кирәклеген искәртеп, тамашачыда олы хисләр уята.

Әхмәрев соңыннан архитектор Батыр Усмановның үтенече буенча ян диварларга

да сюжетны тулыландыра торган рәсемнәр төшерә. Сочига дәваланырга килүчеләр «Ел фасыллары»н һәрвакыт соклануп карый һәм үзләрендә ирексездән пәйда булган күтәренке тойгылар, якты өметләр сәбәпчесе Әхмәревкә олы рәхмәтләрен белдерәләр.

«Чыңгыз абый мәһабәт сәнгать һәм графиканың чын остасы. Борынгы шәрык миниатюрасын терелткән, аны үстергән Әхмәревнең кулын бер-ике сызыгыннан ук таныргa мөмкин. Үзбәкстанда барлык классик әйберләр аның катнашында эшләнә»,— ди Хәмзә премиясе лауреаты язучы Әсгать Мохтар.

Якташыбыз 1968 елда «Татар кызы» портретын яза. Чыңгыз ага кулына хас нәфислек, зәңгәр төс муллыгы. Җиңелчә алсу йөз, карлыгач канатыдай кашлар, җыйнак борын, куе озын керфекләр, чия иреннәр, салынып төшкән толымнар. Уйга баткан кызның артындагы диварга Дәрдмәнднең:

Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад,
Бер янып ат алдылар.
Мин гарип мең кат янып та,
Яндыга саналмадым,—

дигән юллары язылган. Димәк, гыйшык утының шәүләсе төшкән икән аның алсу яңагына, мәхәббәт шөбһәләренең зәңгәр күләгәсе ягылган икән аның күзләренә. Кыяфәтендә нинди матурлык, җыйнаклык!

— Бар да әйбәт, тик менә калфагы гына,— дидем мин кыенсынып авторга,— калфагына йөзем чугы төшергәнсез икән. Безнең якларда — Татарстанда үсми ич ул җимеш.

— Реализм дигән булып, артык җиргә төшкән, утилитар хакыйкатькә омтылган, чамасыз натуралашкан рәсемнәр ясарга ярамый,— диде сурәтче.— Бу примитивлыкка илтә. Үзенчәлекле гомумиләштерүгә омтылырга кирәк. Аннары... халык баскан мәйдан Татарстан белән генә чикләнми ләбаса...

Сүз барышыннан Бакый Урманче, Тахташ, Туфан, Шамил Анак, Равил Фәйзуллин һәм башкаларның әсәрләре хакында иркен фикер йөртүче рәссамның үзен һәрвакыт туган халкының аерылгысыз бер өлеше итеп санавын тою кыен түгел иде. Хәер, якташыбызның иҗаты да нәкъ менә шуны раслап тора. Каюм Насыйри портреты, Фатих Әмирхан китабына ясалган иллюстрацияләр, биюче якташыбыз Галия Измайлова, «Яралы сугышчы» сурәтләре... Соңгысында Идел дәрьясы буенда кылычы сынган, күкрәгенә арттан яшеренеп килгән хаинның дәһшәтле өч угы килеп кадалган пәһлеван. Халык ирege, ватаныбызның бәйсезлеге өчен көрәшкә чыгып, дошманнарына курку сала торган батыр давылларда сынган имәнгә таянган, киемнәре рәхимсез сугышта теткәләнгән. Баһадирның күкрәгеннән кан тама, горур рухы инде башны туры тотарлык дәрманга ия түгел... Фаҗиганың тирәнлегенә ишарә ясап, күктә кояш тотыла!

Рәсем гаять образлы, каһарманның янар йөрәклелеге саран чаралар белән киң колачлы, фәлсәфи тирән гәүдәләндерелгән.

Чыңгыз Әхмәревнең Тукай шигъърияте темасына мөрәҗәгать итүе дә очраклы түгел. Чөнки аның атасы Габдрахман ага татар матбугаты, шулар арасыннан бигрәк тә «Аң» журналы белән дә даими танышып бара. Аларның гаиләсендә Дәрдмәнд, Фатих Әмирхан әсәрләре белән бергә Тукай шигырьләре дә күңел түрендә саклана. 1912 елның язында кымыз эчеп дәваланырга Троицкига килгән шагыйрь Габдрахман аганың өендә дә кунак була. Чыңгыз әунап үсәчәк сәкегә мендәр салып ял иткән арада булачак рәссамның апалары Тукай шигырьләрен шагыйрьнең үзенә яттан сөйләп бирәләр. Үзлегеннән күп укыган илгизәр Габдрахман ага балаларында да татар әдәбиятына, моңына мәхәббәт тәрбияли, вакытсыз һәлак булган шагыйрьнең «Без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик... җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик», «безнең милләт тә... чын мөхәррирләргә, рәссамнарга... мохтаҗ» дигән сүзләрен әледәнәле кабатлый тора.

Акчарлаклар очкан Идел буенда Казан елга вокзалы күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Шәһәребез кунаклары аның диварына эшләнгән мозаик сурәтләрне аеруча яратып карый. Рәсем, татар халык традицияләренчә, күнне кисеп теккән шикелле, бизәкләнеп эшләнгән. Яшел төсләр өстенлек иткән кечкенә генә мәйданда иген кырлары, алма бакчалары, зөбәрҗәт урманнар, зәңгәр дулкыннарда тирбәлеп йөзгән көймәләр, күккә буй сузган нефть манаралары, башкалабызның тарихи һәйкәлләре, опера театрыбыз, кыскасы, Татарстанның бүгенге бай гүзәл тормышы сурәтләнгән. Күзне иркәли торган бу якты күренешләрне шулай ук якташыбыз Чыңгыз Әхмәрев иҗат иткән. Ул безгә еракларган сәламнәр җибәреп кенә калмый, менә шулай кылган гамәле белән, хуҗа шикелле Казан кунакларын каршы ала һәм аларны республикабыз тормышы белән таныштыра.

Шәрык шигъриятенең фәлсәфилеген, миниатюра сәнгатенең шартлылыгын һәм гомумиләштерү сыйфатын, Европа рәссамнарының реалистик осталыгын бергә

туплап һәм синтезлап, мәһабәт сурәтчелек өлкәсендә үз мәктәбен барлыкка китергән Әхмәревнең шәкертләре арасында төрле милләт вәкилләре — үзбәк рәссамнары Әбдиҗаббар Ходайназаров, Тимер Сәгъдуллаев белән янәшә Илдар Фәтхуллин, Хөсния Астанова, Сәлим Коршинов шикелле архитектор якташларыбыз да бар. Алар остазларыннан үткәннең сәнгатенә хөрмәт белән карарга, культура тарихын тирән үзләштерергә, армый-талмый осталыкка омтылырга, иҗатта кыю һәм кабатланмас булырга өйрәнәләр. Шул ук вакытта Чыңгыз абыйлары алар өчен барлык милләтләргә якын һәм кадерле затка, үз халкының горурлыгына әверелүдә матур үрнәк тә.

1969 елда Татарстанда үзбәк әдәбияты һәм сәнгате көннәре уздырылды. Шул вакыт Казан тамашачылары игътибарына Үзбәкстан рәсем сәнгате үрнәкләре тупланган күргәзмә тәкъдим ителгән иде. Аны караучылар аерым бер игътибар белән Ч. Әхмәрев әсәрләрен күздән кичерде, татар матбугаты аның иҗатына хаклы рәвештә югары бәя бирде.

СССР Дәүләт премиясе лауреаты, Үзбәкстанның халык рәссамы һәм Хәмзә исемендәге Республика премиясе лауреаты профессор Чыңгыз Әхмәрев бүген дә илһамланып яңа әсәрләр иҗат итә. Хәзер ул «Фатих Әмирхан каһарманнары» сериясе өстендә эшли. Халкыбызның олылыгы турындагы сүзләрен ул әнә шулай гамәле белән дә ышандырырлык итеп раслый.

*Казан — Ташкент*

# МОҢ ЧИШМӘСЕ

Мең тугыз йөз сиксән бишенче елның көзе. Шаулап яфрак коелган чак. Җил иркенә бирелгән өрәңге яфраклары укшым-укшым кан шикелле. Дерелди-дерелди җиргә төшкән каен яфракларына лимон сарысы сеңгән. Имәнекеләр киртләч-киртләч күгәргән калай кисәкләрен хәтерләтә. Яфраклар мозаикасына әчкелтем усак ысы өстәлә.

Гомеренең җитмеш өченче көзен каршылаучы Рокыя ханым Ибраһимова җир өстенә бихисап төсләрдән тукылган келәм булып җәелүче яфракларга озак карап торды. Алар Рокыя ханымга кешенең гомер дәфтәреннән ертылган сәхифәләр төсле булып күренде. Һәр яфрак үзенә бер музыкаль аваз чыгарып төшә, ә берничәсе бергә көй тәшкил итәләр иде сыман.

Яфраклар җырына җылы якларга сәфәр чыккан торналарның кыйгач сафларыннан ишетелгән моңсу авазлары кушылгандай тоелды. Яфраклар зары һәм канатлы сәяхәтчеләрнең саубуллашу аһәңе тәэсирендә гомерен музыкага багышлаган кешенең күңел эчкәресендә яңа бер көй ярала башлады шикелле.

Шушы халәт аның уйларын үз-үзен белә башлаган беренче көзенә — унтугызынчы-мы, егерменчеме елгы көзгә алып китте. Ул көздә кызчык тәүге тапкыр үзе өчен илаһи булган гармунга кагылды.

...Казанның дәрәҗәле бай сәүдәгәре Әхмәтҗан Гыйззәтуллинның кара өендә, беренче катта яшәгән чаклары. Рокыяның әтисе Габдерәхим абзый — гомере буе кара эшче. Әнисе Сәхип апа — сәүдәгәрләргә кәләпүш чигә. Икенче катта гади эшче Галимулла Сабиров һәм аның хатыны көн итәләр. Аларның балалары юк. Шуңа күрә бала җанлы, киң күңелле бу кешеләр Рокыяны бик үз итәләр.

Рокыя исә үзе Галимулла абыйларына керергә атлыгып тора. Ник дисәң, икенче катта яшәүче абыйның гармуны бар. Ул шуны бик оста итеп уйный. Йөрәкне парә-парә итә. Бер көй тыңлыйсың, үксеп елыйсы килә. Икенчесен сыздырып җибәрә — ярсып җырлыйсы килә башлый. Әллә нишләтә кешене ул гармун моңы! Шунлыктан, кызчыкның өске кат күршеләр белән әти-әниләренең уфтана-уфтана нидер сөйләшүләрендә гаме дә юк. «Революция» диләр өлкәннәр, «Гражданнар сугышы» диләр, «Совет чыккач, иншалла, хәлләребез җиңеләймәсме инде», диләр. Рокыя-сабый боларны аңламый, ә менә гармун... гармун сихерле аны.

Балакайның, дөньясын онытып, мөлдерәп карап торуына чыдамый эшче Галимулла. «Мә-ле, бәләкәчем, үзең кычкыртып кара әле шушы моң тартмасын!» дип, Рокыя кулына гармунын тоттыра. Аннары баланы күтәреп урындыкка утырта. Кызыйның аяклары идәнгә җитмичә кала.

Ни хикмәт! Беравык әзек-төтек авазлар чыгарып маташканнан соң, зәгыйфь кенә итеп булса да, авыл көен кысып чыгара бит кызый. Галимулла абзыйсы да, хатыны да, үз әти-әнисе дә шаккатып, бот чабалар, хәйран калалар. Ә кызчык, тел очын иреннәре арасында йөртә-йөртә, какча гәүдәсен сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәтләндереп, әченнән көйне моңлый-моңлый, уйный бирә...



Рәсемдә: баянчылар Рокыя Ибраһимова һәм Мохтар Әхмәдиев.

Рокыя Галимулла абыйсына гомерлек рәхмәтле. Кызгана белмәде гармунын, гел биреп торды Рокыяга. Сабый яңа бер көй җыештырган саен үзе дә балаларча куана иде: «Вәт бит, кызым! Вәт бит, кызым! Болай булса, син әллә кемнәрне узып китәрсең әле. Ай-яй-яй!..»

Ел үттеме икән, Рокыяның даны, «Габдерәхимнең гармунчы кызы» дигән исеме тирә-күршегә генә түгел, Яңа Бистәгә таралды. Шуның нәтиҗәсе буларак, бәләкәй гармунчы тиздән сәүдәгәрнең мөхтәрәм кунаклары алдында «имтихан» тотты.

Хикмәт шунда иде: Әхмәтҗан Гыйззәтуллин атаклы Фәйзулла Туишевны кунакка чакырып, байтак көйләр уйната. «Күрегез, янәсе, минем мәҗлесемә кем өндәүле! Дөньяны шаулаткан Фәйзулла-гармунчы үзе минем заказларымны үти!»

Үз бәясен бик белгән Фәйзулла, артык озакларга уйламыйча, «Кичен концерт бирәсем бар», дип кайтып китә. Әхмәтҗанның да кикерик шиңә, мәҗлес халкы да музыкасыз калудан боега. Ничарадан бичара дигәндәй, Габдерәхим абзыйның гармунчы кызын алып киләләр. Һәм шушы учка сыярдай кечкенә гәүдәле, ябык кызчык атаклы музыкантны тыңлап ләззәтләнгән кунакларны әсир итә, сокландыра.

— Һай, бала! Бәхетләрең генә булгыры!

— Күз генә тимәсен бичаракайга! — диешәләр дәрәҗәле кунаклар. Аңлашылса кирәк, хуҗабикәнең дә кәефе бик килә. Ул гармунчы кызны саранланмый сыйлый. Бай абзыйлардан кайтканда җиргә басканын тоймый Рокыя. «Өнемме бу, төшемме?» дип икеләнә.

Рокыяның беренче концерты шул булды. Шул көнне аның өчен «күк капусы» ачылды. Шул көннән башлап кызны бәби туйларына, мәҗлесләргә өндәүчән булып киттеләр.

Гомер сәхифәләре... Аларны укый китсәк, 1927 елда Казанда оештырылган гармунчылар ярышында ундүрт яшьлек Рокыя Ибраһимованың җиңеп чыгуын һәм бүләккә... гармун алуын белербез. Шул көннән инде ул гармунлы Рокыя! Аннан соң театрларда эшләгәндә, филармония музыканты булганда, Татарстан радиосының төп музыканты сыйфатында көч куйганда нинди генә баяннарда уйнамады (Вараксин үзе ясаган гармунда да күп әйттерде!), мәгәр ярышта җиңеп алган гармунынннан да кадерлерәк уен коралы тапмады.

Әлеге ярышта җиңгәннән соң, Рокыя Ибраһимовага музыкаль белем бирү зарурлыгы турында җитди сүз кузгала. Укытучысы Хәдичә апа, үз кызым дип алып барып, музыка мәктәбенә кертә. Педагог Гаврилова аны фортепиано классына кабул итә. Әмма... мөлкәтсезгә җил каршы: алдан булса — тезе туңа, арттан булса — оны туза дигәндәй, өйдә фортепиано юклыгы (каян килсен, ди!) кызны аяктан ега. Ул музыка мәктәбеннән китә һәм, полиграфия өйрәнчеклеге мәктәбендә укыган хәлендә, музыканы үзлегеннән өйрәнүгә керешә.

1933 елда Казанга артист-комик Хуҗа Шонкаров труппасы килә. Иҗади труппа башлыгы Рокыя Ибраһимованың да концертларда катнашуын үтенә. Азакта музыкант кызны труппага алалар. Әмма бу коллектив озак яшәми. Аның бер өлеше — Мамадышка, икенчесе Чистайга китә.

1935 ел. Минзәлә театрының дәүләт театры булып формалашкан елы. Иҗади коллектив җитәкчесе, талантлы артист, күренекле режиссер, сәләтле оештыручы (кирәк икән, хәтта шофер да!) Сабир Өметбаев Рокыя Ибраһимованы үзләренә эшкә чакыра һәм күндерә. Кешеләр белән эшләүдә гаять оста җитәкче яшь талантка гөлгә караган төсле карый. Аны кечкенә генә уңышы белән дә канатландырып җибәрә. Һәр адымын күзәтеп бара, ярдәм кулын суза. Шушы театрда Рокыя үзенең музыкаль сәләтен үстерүгә ныклы җирлек таба.

1938 елда Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә уздырылган Бөтенроссия колхоз-совхоз театрлары фестивалендә минзәләлеләр, Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар»ын күрсәтеп, әйтүле уңыш казаналар. Спектакльнең музыкаль оформлениесен эшләүгә Рокыя Ибраһимова күп көч сала...

Гомер сәхифәләре... Аларны актарганда, татар хатын-кызларыннан беренчеләрдән булып танылган Рокыяның атаклы артистлар, композиторлар, музыкантлар белән якыннан аралашкан булуын күрәсең һәм милләтебез горурлыгы булган кешеләрнең аңа шифалы йогынтыларын сизәсең. Ул шәхесләр арасында Заһидулла Яруллин, Салих Сәйдәшев, Асия Измайлова, Гөлсем Сөләйманова һәм башка бик күп танылган осталар бар...

Бөек Ватан сугышы алды еллары. «Комсомолка Гөлсара»ның, «Катюша»ның, «Яшь егетләр, яшь кызлар»ның, «Өч танкист»ның өзми дә куймый да җырланган чагы.

Ил чигенә дошман килсә,
Каушамас безнең куллар,
Мылтык алып алдан чыгар
Яшь егетләр, яшь кызлар.
Э-эх...

Шулай да яшьлек беркатлы, самими бит ул. Рокыя да безнең ил өстенә ниндидер кара көчнең ябырылуын күз алдына китерергә теләмәде. Дөрес, Халхин-голда япон самурайлары чиккә танау тыгып караганнар иде, Кызыл Армия аларның арт сабагын укытты. Хасан күле буенда да безнең йодрыкны нык татыдылар. Безнең гаскәр ак финнарның да тәүбәләрен әйттерде. Тик... тик газета битләре шомлы хәбәрләр белән тулы чыга...

Һәм... меңләгән, миллионлаган Рокыяларның хыялларын, планнарын чәлпәрәмә иткән көн килде. Кояш тотылгандай булды. Ил кан һәм күз яше фаҗигасенә уралып калды. Газеталарның беренче битләрен эре-эре хәрефләрдән торган утлы сүзләр иңләде: «Безнең эшебез хак. Дошман тар-мар ителер. Җиңү безнең якта булыр!» Багана башларындагы көчле репродукторлардан Совинформбюро хәбәрләре һәм сугышчан маршлар өзлексез яңгырап торды.

Рокыя бу вакытта Татар дәүләт академия театрында эшли башлаган иде. Музыка көчен Туган илгә мәхәббәт, ил баскыннары — фашистларга нәфрәт итәргә кирәген төшенде ул. Театр тылга һәм фронтка хезмәт күрсәтү өчен монолит көч булып оешты.

Рокыя ханымның хәтерендә: 1942 елда театр сәхнәгә драматург Таҗи Гыйззәтнең «Ялкын» драмасын куйды. Аңа үзе уйнап, үзе җырлый торган роль тиде. Режиссер Ширияздан Сарымсаков Ибраһимовадан тамашачыга бик тиз барып җитәрдәй, моңлы да, дәртле дә халык көе сайлап табуын үтенде. Рокыя, эзләнә торгач, «Озату», «Кыз озату» көйләрен тәкъдим итәргә булды. «Озату»ны сайладылар, һәм ул көй «Ялкын» исеме белән халык арасына таралды (ә «Кыз озату» көенә Зифа Басыйрова сүзләр сайлый һәм көйне туган ягы шәрәфенә «Мөслим» дип атап җибәрә).

Шул елны Рокыя Ибраһимова «Су буйлап» көен халыкка тарата. Ул зур концертлар программасына кертелә, радиодан күп тапкырлар яңгырый, шул рәвешле, тыңлаучыларның мәхәббәтен казана.

Үзенә күрә тарихы бар ул көйнең. Рокыя ханым аны Чистай якларына гастрольгә барганда пароходта җырлаучылардан отып ала. Тик сүзләре тематик берлектә булмый. Татар җырларының теләсә кайсын җырлыйлар әлеге көйгә.

Нота, байтак көннәр чемоданда йөреп, Казанга кайта.

Кабат су юлы белән Чаллыга килгәч, Рокыя авылыннан, әнисе яныннан читкә китәргә җыенучы бер кызның җырына колак сала. Ихтимал, шушы сүзләрне алырга кирәктер, дип уйлый. Шулай ният кылганда, Минзәлә районына барып чыгалар һәм Калмыя авылында Әнвәр Корбангалиевнең җыр дәфтәрендә агымсуга кагылышлы ике текст табалар. Шуларның берсе сайлап алына һәм «Су буйлап» көенә җырлана башлый.

Рокыя Ибраһимованың гомер дәфтәре сәхифәләренә сугыш елларында шәһәр һәм авыл хезмәт ияләренә җан азыгы, рухи җим өләшү юлындагы күп санлы чаралар гына түгел, госпитальләрдәге фидакарь хезмәт тә теркәлгән.

Ватан азатлыгы өчен дәһшәтле сугышларда каты яраланган сугышчыларның рухын күтәрүгә өлеш кертү — үзе зур батырлык ул. Яралылар татар халык көйләрен, композиторларыбызның әсәрләрен баянчы Рокыя Ибраһимова башкаруында йотлыгып тыңлыйлар. Бик күбесе кул чабу мөмкинлегеннән дә мәхрүм. Рәхмәтләрен телдән әйтәләр һәм: «Тагын бер генә көй уйнагыз инде! Тагын бер генә җыр җырлагыз инде!» — дип гозерлиләр. Ничек итеп уйнамасын да ничек итеп җырламасын ди!

Госпитальләргә шефлык итү чорыннан Рокыя Ибраһимова сәерлек дәрәҗәсенә җиткән очракларны да искә ала.

Маяковский урамындагы тулай торакка урнашкан госпитальдә, мәсәлән, концерт вакытында ул бер егетне күрә. Каты яраланган, өстәвенә, бик көчле контузия дә алган. Сугыш аяусыз бирткән егетнең нервылары соң чиккә җитеп какшаган. Аны тынычландырырга теләп, һәммә чараларны сынап караганнан соң, бик тузынган чакларында кулларын бәйләп куюга җитәләр икән хәтта. Менә шушы сугышчы музыка тыңлагач тынычлана икән. Тынычлана һәм гадәти хәленә кайтып, үзенең үтенечен әйтә: «Сез, мөмкин булса, тагын килегез әле», ди. Гади үтенү генә дә булмый бу. Чын-чынлап ялвару, инәлү була.

Әлеге фаҗигане йөрәгенә бик якын кабул иткән Рокыя Ибраһимова госпитальгә кат-кат бара һәм бер дә иренмичә махсус шушы егет өчен баянда уйный.

Концертларның берсендә баянчы Ибраһимова бик каты яраланган солдат кыз — зенитчы белән очраша. Кызның ике аягы да ампутацияләнгән. Рокыяның уйнавын бик бирелеп, бик ошатып тыңлап торганнан соң, әлеге яралы туташ медицина персоналы аркылы музыкант белән сөйләшәсе килгәнлеген әйттерә.

Рокыя ханым фаҗига күләнә чумган бу кыз-солдат белән бик теләп сөйләшә, әлбәттә. Медиклар алдан ук кисәтеп куялар: «Сез берүк аның фикеренә каршы килә күрмәгез, зинһар. Җаена гына тора күрегез»,— диләр.

Авыр әңгәмә була бу. Кыз, госпитальдән савыгып чыккач та, музыкант булу турында хыяллана икән. Моны ул Ибраһимовага туп-туры әйтә: «Сезнең кебек баянчы буласым килә!» — ди.

Рокыя ханым аптырашта кала. Беренчедән, ул бу сугышчының музыкага сәләте барлыгын белми. Икенчедән, баян кадәр баян ике аяксыз кызга бик авыр инструмент булачак. Сау-сәламәт Рокыя пот авырлыгын үз тәҗрибәсендә күп татыган кеше бит!

Яралы кызга музыкант апасы иң әүвәле нота гыйлеме алу кирәк булачагын әйтә. Аннары бик сак кына баянның аның өчен авырга киләчәген аңлата. Оркестрга керә торган теләсә кайсы инструментны сайларга мөмкин булачагын төшендерә.

Мондый очрашулар яу тынганнан соң ни гомерләр узгач та Рокыя Ибраһимованың төшләренә кереп йөдәтә икән, каһәрле сугышның кешеләр йөрәгенә салган яраларның ни дәрәҗәдә авыр икәнен аңлавы кыен түгел.

Рокыя Ибраһимова госпитальләрдә биргән концертларда Салих Сәйдәшев белән чыгыш ясауларын иң җылы истәлекләрдән итеп хәтерли. «Старая клиника»дагы госпитальдә Сәйдәшевнең яралылар белән әңгәмәләре аның хәтеренә тирән уелган.

Шул чактагы иҗади элементлардан файдаланып, Рокыя ханым халкыбызның сөекле композиторыннан «Галиябану» увертюрасының гармун партиясен яздырып алуын һәм композитор үзе дирижерлык иткән концертларда оркестр составында шул партияне башкаруын сагынып искә ала.

Кешелек тарихында күрелмәгән авыр сугыш дәвам итә, ләкин музалар тынмый гына түгел, торган саен дәртлерәк яңгырый.

Балетмейстер Гай Таһиров һәм музыкант Рокыя Ибраһимова сәнгать түгәрәкләре көче белән бию сюитасы хәзерлиләр. Уңыш казанган бу сюитаны 1943 елның октябрь азагында ВЛКСМның 25 еллык тантанасы уңаеннан Мәскәүнең Зур театры сәхнәсендә күрсәтәләр. Анда алган югары бәя яңа сюита иҗат итеп, янә илебез башкаласы сәхнәләрендә чыгыш ясарга рухландыра. Бу коллективны Кремль янында кинога төшереп, тасманы фронттагы сугышчыларга күрсәтергә җибәрәләр.

1944 елның яз башы Рокыя Ибраһимова өчен шулай ук бик истәлекле чор. Бу вакытта Рокыя Ибраһимованы фронт концерт бригадаларының берсенә кертәләр. Бригадада шулай ук Асия Мәсәгутова, Рәшидә Тәминдарова, биюче Хәйруллин, опера театрыннан Артемов булалар. Конферансье — Петровская.

Концерт брагадасы үзенең программасын иң элек — Казанда, аннары Мәскәүдә күрсәтә.

Башкалада чакта, татар артистлары фронтка бара дигәнне ишетеп, кунакханәгә алар янына генерал-лейтенант Якуб Чанышев килә. Ул бригада членнарының һәммәсе белән якыннан кызыксына, үз итеп сөйләшә, уңышлар тели. Рокыя ханым Ибраһимова халкыбызның легендар кешесе хөрмәтенә татар халык көйләрен уйный.

Ниһаять, бригада Беренче Украина фронтында. Землянкаларда һәм ачык һавада концертлар. Ватан азатлыгы өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшүчеләр, бигрәк тә якташларыбыз, сәхнә осталарының чыгышларын бик зур канәгатьләнү хисе белән кабул кыралар. Тиз арада әмәлләп куелган сәхнә күперчекләренә артистларны кат-кат чакырып чыгаралар, ихластан рәхмәт укыйлар.

Концертларның берсендә гаҗәпләнерлек хәл була. Конферансье баянчы Рокыя Ибраһимованың сәхнәгә чыгасын игълан итүгә, сугышчылар арасыннан мәһабәт гәүдәле бер гәү күтәрелеп, музыкантка якынлаша. Рокыя үз күзләренә үзе ышанмастай хәлдә кала: каршысына Минзәлә театрының художество җитәкчесе һәм директоры булган Сабир абыйсы Өметбаев кочак җәеп килә. Язмыш күңел әрнетүле хәлләрне генә түгел, гомер ахырына кадәр истә калырлык күңелле очрашуларны да бирә икән!

Сугыш кырында, Украинаның хәзерге Хмельницкий өлкәсендә, Горынь елгасы буена урнашкан Славута шәһәрендә, фронт концерт бригадасы әгъзалары «Ватан өчен» газетасында эшләүче татар язучылары белән дә очрашалар. Алар арасында драматург Риза Ишморат, шагыйрьләр Гали Хуҗиев һәм Мөхәммәт Садри, балалар язучысы Госман Бакиров булалар.

Әдәбият-сәнгать әһелләренең мондый шартларда берничә генә сәгатькә булса да очрашуларыннан туган тәэсирне күз алдына китереп була инде. Китә сорашулар, китә сөйләшүләр, йокы һәм ял онытыла. Шул чакта Рокыяның өздереп баянда уйнавы үзе бер бәхет, әйтеп бетергесез олы ләззәт була.

— Бик хатирәле очрашу булган иде ул,— дип искә ала бу хакта күренекле драматург, әдәбиятыбыз аксакалларыннан берсе, сугыш елларындагы майор Риза Ишморат.

Язучылар фронт концерт бригадасының чыгышлары турында «Ватан өчен» газетасында мәкалә урнаштыралар. Газетаның бу мәкалә басылган саны әле дә булса Татар дәүләт академия театры музеенда саклана.

1951 елдан Рокыя Ибраһимова филармониядә эшли башлый һәм 1968 елда лаеклы ялга киткәнче шунда була. Иҗатының бу чоры гаять зур активлык белән аерылып тора. Әлеге дәвердә танылган баянчы берничә бригадада эшли. Татарстан районнарында, күрше республикалар һәм өлкәләрдә була. Усман Әлмиев, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Габдулла Рәхимкуловлар белән бергә халыкка культура хезмәте күрсәтә.

Бу чорда да Рокыя ханым халык җырларын язып алу һәм эшкәртүгә, аларны яңа халкыбызга бүләк итүдә тау чаклы эш башкара. Аның үз кулы белән төзегән бер исемлектә җырчылар репертуарына тәкъдим иткән дистәләрчә җырлары теркәлгән. Шул рәвешле, ул атаклы җырчыларыбыздан Гөлсем Сөләйманова, Гайшә Камаева, Мәрьям Рахманкулова, Зифа Басыйрова, Әлфия Авзалова, Разия Тимерханова, Илһам Шакиров, Сөләйман Йосыпов, Габдулла Рәхимкуловларның репертуарларын баетышуда катнаша.

Шушы сокландыргыч җыр осталарының репертуарларындагы һәммә көйләрне бергә күз алдына китерә калсак, һич арттырмыйча расларга мөмкин, моң диңгезе хасил булыр иде.

Баянчы Ибраһимованың гомер сәхифәләрендә яңа дә бер үтә истәлекле вакыйга бар. Ул да булса, Римма Ибраһимова, Илһам Шакиров, Марат Әхмәтов, Марат Сиражетдинов, Айрат Арслановлар белән бергә, Финляндиягә гастрольгә баруы. Ул бу сәяхәттән гаҗәеп рухланып, дәртләнеп кайткан иде.

Рокыя Ибраһимованың, танылган хатын-кыз баянчы буларак, тормыш һәм иҗат юлы күпләр сокланырлык. Туган халкына армый-талмый фидакарь хезмәт итүе белән бик бәхетле ул.

**Рәүф ХӨСНЕТДИНОВ.**

# ХАЛЫК ДӨНЬЯСЫН СӨЕП

Күренекле композитор, ТАССРның халык артисты, Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Александр Ключаревның арабыздан китүенә инде ун елдан артык вакыт үтте, әмма аның тормышка мәдхия булып яңгыраучы оптимистик җырлары һаман да безнең белән яшиләр. Аларны эфирдан да, сәхнәдән дә еш ишетәбез. Композитор үзенең җырлары белән күп төрле бәйрәмнәребездә дә даими катнаша. Татарстан радиосының чакыру авазында да аның моңы көн саен ерак киңлекләргә тарала. «Туган җирем — Татарстан», «Яңа Казан», «Мәңгелек яшьлек», «Идел дулкыннары» кебек әсәрләр республика җыр сәнгатенең чын мәгънәсендә классик үрнәкләренә әверелделәр. Бу шигъри юллар нәкъ менә аның моңы белән күңелләребезгә сеңгән:

Идел ярларына нурлар сибеп,
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты Туган илем,
Бәхет биргән җирем — Татарстан.

Композиторның иҗат язмышы шактый ук кызыклы. Үзенең иҗат эшчәнлеген ул уналты яшендә Оренбургтагы кинотеатрларның берсендә пианист-иллюстратор буларак башлый. Биредә күренекле фольклорчы һәм этнограф А. Затаевич белән таныша. Халык җәүһәрләрен җыючы галим Александрда музыкаль фольклорга мәхәббәт, иң әһәмиятлесе, иҗатка дәрт уята.

Татар театр техникумында, Йошкар-Оладагы мари театрында һәм Мәскәү татар эшчеләр театрында музыкаль бүлек мөдире һәм башка вазифалар башкарганда, А. Ключарев халык җырларын җыеп өйрәнә, аларның эшкәртелгән үрнәкләрен төрле спектакльләрдә яңгырата. Бер үк вакытта ул музыкаль белем алу теләге белән дә яна. Башта Казан музыка училищесының фортепиано классында, аннары Мәскәү дәүләт консерваториясенең композиторлык факультетында укый. Югары профессиональ белем алганнан соң бөтен көчен музыкаль фольклор үрнәкләрен җыю һәм өйрәнү эшенә бирә. Нәтиҗә озак көттерми: татар халык җырларыннан тупланган ике җыентык дөнья күрә. Әлеге басмалар күп еллар буена «өстәл китабы» булып хезмәт иттеләр.

Халык җәүһәрләрен җыю белән беррәттән, А. Ключарев иҗат өлкәсендә дә актив эшли. Күп кенә җырлар һәм симфоник оркестр өчен әсәрләр яза. Шулай да ул чын композитор булып 1948 елда гына, Ленин комсомолының 30 еллыгына багышланган «Мәңгелек яшьлек» җыры яңгырый башлагач кына танылa. Композиторның зур уңышы саналган әлеге җырда татар музыкаль фольклорына караш новаторларча гәүдәләнеш таба, милләте буенча рус булган авторның халкыбыз иҗатына мәхәббәте үзенчәлекле рәвештә кристаллаша.

Җырлары белән танылган музыка остасы башка жанрларда да актив эшләргә омтыла: сәхнә әсәрләре, аерым алганда, «Тау әкияте» балеты, С. Сәйдәшев һәм Т. Гыйззәтнең музыкаль драмасы нигезендә «Наемщик» операсы, шулай ук симфоник һәм камера-инструменталь әсәрләр иҗат итә. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә озак еллар буе эшләү композиторның иҗат биографиясендә бик әһәмиятле роль уйный. Башкорт халык биюләре ансамбле белән дә ул иҗади хезмәттәшлек элемтәләре урнаштыра.

Шулай да җыр А. Ключарев иҗатында өстенлек алучы жанр булып санала. Композитор нәкъ менә шушы юнәлештә киңрәк ачыла, художник булып танылa. Замана агышына аваздаш булып яңгыраучы җырларда аның гражданлык кредосы да ачык чагыла, һәм әлеге жанрда ул үз стилен тудыра. Нечкә зәвыклы музыкант, оста импровизатор-пианист талантына ия булган А. Ключарев, татар халык җыр-

ларын тирәнтен белү белән берләттән, халык башкаручылары — җырчылар, курайчылар, гармунчылар, скрипачлар сәнгате үзенчәлекләрен дә яхшы аңлаган.

Композитор А. Ключарев җырларының озын гомерле булулары, мәгаен, татар халык җырлары мелодикасы үзенчәлекләрен яңа милли жанр чыганакларына куша белүдән киләдер. Бу юнәлештә ул С. Сәйдәшев традицияләрен яклый һәм шул ук вакытта татар җырына сугышка кадәрге рус җыр-маршлары үзенчәлекләрен, аларның киң колачлылыгын, «фанфаралы интонацияләр»ен алып керә. Авторның мондый омтылышы «Коммунистларча гына», «Безнең маяклар», «Хезмәт батырлары», «Яңа Казан» кебек «кайнап торган», күтәренке рухлы маршларда аеруча калку гәүдәләнә. Композитор үзенең лирик җырларында, элегия төсмерләрен көчәйткән хәлдә, XIX гасыр рус романсының метроритмик чалымнарын зур осталык белән яңгырата («Яз җыры», «Идел турында җыр»). Республикабыз композиторлары арасында беренчеләрдән буларак, ул үзенең вокаль әсәрләрендә джаз бизәкләрен кыю файдалана («Синең хакта» һ. б. җырлар), әлеге жанрның татар җырлары белән табигый рәвештә синтезлаша алуын раслый.

Татар җыр сәнгатен башка тугандаш халыклар музыкасы элементлары белән баетуга А. Ключарев бигрәк тә зур игътибар бирде, шулай итеп, татар музыкасының сурәтләү чаралары хәзинәсен киңәйтү мөмкинлекләрен ачуга зур өлеш кертте. Әйтик, үзбәк һәм казах халык җырларына хас бизәкләрне куллану композиторның «Бохара-Урал», «Җайдак казах кызына» кебек җырларына бөтенләй яңача яңгыраш бирде.

Оста музыкант, композитор, фольклорчы Александр Ключарев замандашлары хәтерендә мәхәббәт, зыялы, тыйнак һәм ярдәмчел кеше буларак саклана. Ул үзешчән сәнгать коллективларына, һәвәскәр композиторларга бик теләп ярдәмгә килә иде. Районнарга еш чыкты, музыка сөючеләр белән даими очрашып торды. Яшь композиторлар иҗаты, аларның музыка фольклорына мөнәсәбәте аны аеруча кызыксындыра иде. Татарстан Композиторлар союзы пленумнарының берсендә А. Ключаревның мондый сүзләре яшьләргә васыять буларак яңгырады: «Әгәр һәрбер композитор моңарчы безнең фольклорчылар игътибарыннан читтә калган, хәзергә билгесез саналган ике-өч кенә борынгы халык җыры табуны һәм язып алуны максат итеп куйса, бик яхшы булыр иде. Шунысы бик аяныч: халык иҗатының күп җәүһәрләре табылмыйча һәм халыкка кире кайтарылмыйча кала бирә! Эзләүне ашыктырырга кирәк, югыйсә алар бөтенләйгә юкка чыгарга мөмкин».

Бүгенге көндә республикабызның җыр өлкәсендә эшләүче композиторлары, эстрадага ярашлы лирик монологларга күбрәк игътибар итеп, яшьләрчә күтәренке, «гайрәтле» җыр-маршлар язудан күпмедер читләшә төштеләр шикелле. Тыңлаучыларны «Мәңгелек яшьлек», «Хезмәт батырлары» кебек күтәренке рухлы, чын мәгънәсендә канатлы җырлар сагындыра башлады. Хәзер шундый әсәрләргә ихтыяҗ артты. Яшәү матурлыгы турында бөтен тавышына көчле итеп җырлаган композитор Александр Ключаревның күпкырлы иҗат мирасы, бу яктан, хаклы рәвештә лаеклы үрнәк, җыр сәнгатен бәяләүдә югары өлге булып хезмәт итә.

**Земфира СӘЙДӘШЕВА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# БЕРЕНЧЕ РУС РЕВОЛЮЦИЯСЕНДӘ ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

Көнкүреш, гаилә өлкәсендә күп еллар буенча дәвам итеп килгән иске мөнәсәбәтләргә каршы фикерләр XIX йөз уртасында татарлар арасында да күтәрелә башлый. Г. Кандалый татар әдәбиятында беренче буларак чынбарлыктан алынган поэтик образлар аша крестьян хатын-кызларының фаҗигале тормышын, гаиләдәге хокуксызлыгын күрсәтте. З. Бигиев һәм Ф. Халиди әсәрләрендә хатын-кызларның азатлыгы мәсьәләләре үзәк урынны алып тора. Мәсәлән, «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле әсәрендә З. Бигиев татар хатын-кызларының да башка алдынгы милләтләрдәге кебек азат һәм культуралы булуларын тели, аларның хокуксызлыгы турында ачынып яза. XIX йөзнең соңгы чирегендә хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсе яңа баскычка күтәрелә. Мәгърифәтчелек идеяләре белән рухланган бу чор язучылары татар хатын-кызларының тоткын хәлендә яшәүләренә каршы чыгу белән бергә, аларның ирләр белән бертигезлеген дә яклыйлар. М. Акъегет, Г. Ильяси шәхси ирек өчен көрәш башлаучы Хәнифә һәм Маһитап образларын бирәләр. Үз чоры өчен типик булмасалар да, бу образлар заманының алдынгы хатын-кызларына уңай тәэсир итәләр. XX йөз башында Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхметов, Ф. Әмирханнарның иҗтимагый тормышта демократик идеяләрне алга сөрүләре халык массаларын, шул исәптән, татар хатын-кызларын уятуда зур роль уйнады.

Россиядәге революцион көрәш илнең төрле төбәкләрендә яшәгән һәм үсеп килә торган яшь татар пролетариатын да үз эченә ала. Сембер губернасындагы Акчурин һәм Дебердеевларның сукно фабрикаларында эшчеләрнең шактый өлешен татарлар һәм, шул исәптән, татар хатын-кызлары тәшкил иткән. 1880 елларда ук, алар, рус эшчеләре белән берлектә, забастовкалар оештырып, эш хакын арттыру, эш шартларын яхшыртуны таләп итеп чыгалар.

1897 елгы халык санын алу материаллары Казан губернасында гына да 4—5 мең татар эшчесе булганы турында сөйли. Моңа тагын Баку, Донбасс, Урал һәм башка промышленность үзәкләрендәге татар эшчеләрен дә өстәргә кирәк. XX йөз башында Казан губернасы предприятиеләрендә эшче хатын-кызларның саны да шактый арта. Губернадагы фабрика инспекциясе документларына караганда, 1902 елда аларның саны 2937 гә җиткән була. Алафузов фабрикасында эшчеләрнең яртысын хатын-кызлар тәшкил иткән. В. И. Ленин «Россиядә капитализм үсеше» дигән әсәрендә фабрика производствосында хатын-кызларның катнашуы прогрессив күренеш булуын әйтә[1]. Мондагы эш шартлары сыйнфый бердәмлек, коллектив аң үстереп, хатын-кызларны революцион көрәш сафына бастыра.

Эшче хатын-кызларның революцион хәрәкәте Казанда да эшчеләр хәрәкәтенең состав өлеше буларак барлыкка килә. Архив материаллары һәм истәлекләр забастовкаларда, демонстрацияләрдә, полициягә каршы чыгышларда эшче хатын-кызларның ирләр белән иңгә-иң торып көрәшүләрен раслый. Профессор Р. И. Нәфиковның архив материаллары буенча язылган «Тайны революционного подполья» исемле хезмәтенә күз салсак, XIX йөзнең соңгы чирегендә үк инде татар хатын-кызлары арасыннан да милли чикләнүләрдән, дини хорафатлардан азат булган, бай кардәшләре белән араны өзеп, царизмга каршы көрәшкә чыккан Өммегөлсем Солтан кызы Алкина кебек шәхесләр үсеп чыкканын күрербез. Ул Нижний Новгородта А. М. Горький белән дуслашкан. Шунысы кызыклы: А. М. Горькийны кулга алганда аңарда Өммегөлсем-

[1] Ленин В. И. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 3 т., 480 б.

нең фоторәсемен табалар. 1887—1889 елларда В. И. Ленин Казанда чакта Өммегөлсем Казан революцион подпольесы белән элемтәдә торган[2].

Ә XX йөз башында инде татар эшче хатын-кызлары да рус һәм башка милләт эшче хатын-кызлары белән бергә митингларда, маевкаларда катнашалар. Алафузов фабрикасы чиновнигы фабрикалар инспекторына 1904 елның 15 мартында шундый рапорт җибәрә: «Бүген, 15 мартта, хезмәт вакыты үткәч, кычкырып эшчеләрнең бер өлеше, күбесенчә яшүсмерләр, хатыннар, татарлар һәм татар хатыннары, фабрика йортында туктап калып, хезмәт хакын арттыруны сорадылар... тәрәзәдәге 9 пыяланы ватып киттеләр»[3]. Шул елның апрель аенда бу чыгыш зур забастовкага әверелә. Башлап туку бүлеге, аннан эрләү һәм башка бүлекләр кузгалып, стачкага 1500 ләп эшче катнаша. Аны оештыручылар арасында рус хатын-кызлары П. Кузнецова, А. Хрисановалар белән бергә тукучы Сабира Низамова, эрләүчеләрдән Бибихалисә Яруллиналар да була[4].

Татар пролетариаты арасында марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалау, эшчеләрне оештыру һәм революциягә хәзерләү эше 1905 елга кадәр үк башлана. 1904 елның башында РСДРП(б)ның Казан комитеты татар эшчеләре арасында агитация һәм пропаганда эшләрен көчәйтеп, аларны революцион көрәшкә хәзерләүгә зур игътибар бирә. Эшче татарлар арасындагы политик түгәрәкләрнең эше киңәйтелә. Хатын-кызлар, шул исәптән татар хатын-кыз эшчеләре өчен аерым түгәрәкләр оештырыла[5].

Башында Хөсәен Ямашев торган түгәрәк РСДРП(б)ның Казан комитетының листовка һәм прокламацияләрен татарчага тәрҗемә итеп бастыруны җайга сала. Прокламацияләрне гектографта басып күбәйтүчеләр арасында Әминә һәм Мәдинә Терегуловалар, Рабига Габитова, Гарифә Арсланова була.

Гафур Коләхметовның апалары Суфия һәм Шәмсекамәр 1905—1907 елгы революциядә актив катнашканнар. Шәмсекамәр Коләхметова квартирасы татар большевикларының очрашу һәм элемтә урыны булган. Суфия Петербургта югары курсларда укый, курсисткалар забастовкасында да катнашуда гаепләнеп укудан чыгарылса да, прогрессив рус җәмәгатьчелегенең басымы астында 1911 елны яңадан кабул ителә һәм 1912 елда укуын тәмамлап Казанга кайта.

Казан комитеты тарафыннан яшерен рәвештә чыгарыла торган «Рабочий» газетасы 1905 елның җәендә Казандагы эшчеләрнең авыр тормышын, түбән хезмәт хакы алуларын, каты изелүләрен һәм бөтенләй хокуксыз яшәүләрен күрсәтеп түбәндәгеләрне язды: «Хатыннарның һәм кызларның хәле бигрәк тә авыр, алар көн саен мастерлар тарафыннан ясала торган төрле пычрак тәкъдимнәргә каршы көрәшергә мәҗбүр булалар. Һәртөрле кимсетелү һәм хурлау картиналарын сөйләп бетерү авыр, менә аларга үз гомерләренең күп өлешен шулар арасында үткәрергә туры килә» («Рабочий», 1905, 3 июль).

Патша Россиясендәге хатын-кызлар хәле турында В. И. Ленин: «Россиядә хатын-кызларның хокуксызлыгы яки тулы хокуклы булмавы кебек түбәнлек, әшәкелек, кабахәтлек юк»,— дип язды[6]. Иң түбән эш хакы хатын-кызларныкы була, аларның хезмәтенә ирләрнекеннән 30—40 процентка кимрәк түләнә. Әле аның да шактый өлешен төрле «гаепләр» өчен штраф тәртибендә тотып калалар.

1905 елның 9 гыйнварында Петербург эшчеләренең ерткычларча аттырылуы турындагы хәбәр Казанга килеп җитү белән РСДРП(б)ның Казан комитеты рус һәм татар эшчеләренә Петербургтагы вакыйгаларның политик әһәмиятен аңлата һәм гомуми стачкага чакыра. «Иптәшләр! Түзәр хәл калмады,— дип яза РСДРП(б)ның Казан комитеты «Эшчеләргә һәм эшче хатын-кызларга» дигән прокламациясендә.— Чыдап тора алмаслык изелүдән уянган Петербург эшчеләре баш күтәрделәр. Күп кенә шәһәрләрнең эшчеләре аларны яклап чыктылар. Без дә гомуми стачка игълан итик. Казандагы эре һәм вак предприятиеләрнең эшчеләре һәм эшче хатын-кызлары! Гомуми стачкага хәзерләнегез!»

Бу чакыруга җавап итеп, 20 гыйнварда Алафузов фабрикасындагы җеп чорнау бүлеге хатын-кызлары эш ташлый. «20 гыйнварда,— дип хәбәр итә «Волжский листок» (1905, 98 сан) газетасы,— Алафузовларның Ягодный төбәгендә 250 эшче хатын-кыз эш ташлады. Төштән соң калган эшчеләр дә, эш сәгатен кыскартуны һәм эш хакын арттыруны таләп итеп, аларга кушылдылар».

[2] Нәфиков Р. Эзләнүләр дәвам итә.— «Азат хатын», 1972, 1 сан, 5 б.
[3] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 1153 ф., 1 тасв., 1217 эш.
[4] «Азат хатын», 1930, 23—24 саннар.
[5] Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. 7 т., 282 б.
[6] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 33 т., 31 б.

«1905 елгы январь стачкасында,— дип яза үзенең истәлегендә Алафузов эшчесе Кафия Гыйматдинова,— Алафузовларның фабрика, заводларында эшләүче эшчеләрдән 3 меңләп кеше эш ташлады... Ул вакытта безнең сорагаңнарыбыз шулар: 8 сәгатьлек эш вакыты, хатыннарны бала табу алдыннан 6 атна һәм 6 атна соңыннан эштән туктатырга, эш хакын арттырырга һәм башкалар. Менә шушы сораганнарыбыз үтәлмәсә эшкә чыкмыйбыз,— дидек. Безнең эшләмәгәнне күреп, фабрика администрациясе безнең янга надзирательне чакырды. Надзиратель озак еллар эшләп килгән эшче хатыннарны берәм-берәм конторага чакыртып, эшләргә димләп караса да, аңа сатылучы булмады. Алай да булмагач, ул, эш ташлаган хатыннар арасына килеп, эшләргә өнди. Без үз соравыбызда торабыз: «Безнең сораганнарыбыз үтәлмичә, без эш башламыйбыз! — дибез. Фабрика эчендә эш ташлау берничә көнгә сузыла... Ул вакытта актив хатын-кызлардан истә калганнар: Пескова Соня, Нәгыймә Мөхәммәтжанова, Миңсылу апа, Әсма Зәйнетдинова һәм Исрафил абзый хатыны...»[7]

1905 елның көзендә, эшчеләрне гомуми стачкага ныграк хәзерләү өчен, Казан большевиклары университет һәм ветеринария институты студентларының митингларыннан киң файдаланалар. Университет митингларында һәм Казанда барган октябрь, ноябрь көрәшләрендә татар хатын-кызларының катнашуы турында «Казан мөхбире» (1905, 18, 19 саннар) газетасы да язып чыга.

1905 елның 19 октябрендә, Казан шәһәре баш күтәргән халык кулына күчкәч, аны саклаучылар арасында берничә эшче хатын-кыз да була[8].

Казан большевиклары эшчеләр массасын, шул исәптән татар эшчеләрен революцион көрәшкә хәзерләү белән бергә, эшче хатын-кызларны политик яктан тәрбияләү эшенә дә зур игътибар бирәләр. Нәтиҗәдә, хатын-кызларның үз араларыннан да политик агитаторлар җитешә. «24 ноябрьдә Алафузов театрында булган митингта,— дип яза «Волжский вестник» газетасы (1905, 319 сан),— бер социал-демократ хатын чыгыш ясап, хатын-кызларга үзләренең политик һәм экономик хәлләрен яхшырту өчен, ирләр белән бер сафта көрәшү кирәклеге турында сөйләде».

Пролетариатның революцион чыгышлары тәэсирендә 1906—1907 елларда Чистай, Буа һәм башка күп өязләрдә аграр хәрәкәт киң колач ала. 1906 елда Буа өязе Каракитә авылы крестьяннары күтәрелешендә татар хатын-кызлары да актив катнашалар. Ике хатын каты яралана. Көрәшчеләрнең алгы сафында флаг күтәреп барган Хәят Хәсәнованы ерткыч казаклар кылыч белән тураклап үтерәләр[9].

Революцион көрәш демократик татар матбугатын җанландыра. Демократик интеллигенция карашларын чагылдырган «Фикер», «Азат», «Азат халык», «Әльислах» газеталары, «Әлгасрел-җәдид», «Уклар», «Карчыга» журналлары патша хөкүмәтенә, феодализм калдыкларына, милләтчеләргә, кадимче карагруһчыларга каршы нәфрәт белән чыгалар. Бу көрәш реакция елларында да сүнми. «Фикер» газетасы, мәсәлән, авыл хатын-кызлары политик яктан тәрбияләүне, аларны ирләр белән тигез хокуклы итүне үзенең бурычы итеп саный. «Ханымнар! — дип мөрәҗәгать итә газета.— Үз хәлегезне һәрвакыт язгыз. Җитәр инде фанатик руханилар, надан ишаннар, юан корсаклы җаһил карт байлар аяк астында изелүегез, Сез дә хайван дәгел, инсан икәнегезне белергә вакыт». («Фикер», 1907, 1 сан).

Татар демократик интеллигенциясенең алдынгы вәкилләре әсәрләрендә хатын-кызлар азатлыгы проблемасы үзенең бөтен социаль тирәнлеге белән куела. Моны исбат итү өчен Г. Тукай иҗатына мөрәҗәгать итү дә җитә. Шагыйрь татар хатын-кызларының гаиләдә һәм җәмгыятьтә һәртөрле яклау һәм таянычтан мәхрүм булуы, аның бөек хәзинәсе — мәхәббәт дигән олы хиснең тапталуы турында җан ачысы белән язды. Ул мондый тупас тормышның сәбәбен капитализмның рәхимсез законнарында, байлык иялрендә күрде.

Атылган кош, адаштырган эттәй,
Үткәннәргә мәэюс карыйсың;
Күрәм, ике ирнең селкенәдер:
Кайсы татар баен каргыйсың?

Г. Тукай һәм башка революцион-демократларның иҗаты, бигрәк тә аларның җәмгыять прогрессын хатын-кыз азатлыгына бәйләп аңлатулары төрле социаль катлаулардагы алдынгы татар хатын-кызларына зур тәэсир ясады, аларның политик аңын үстерде. Моны раслау өчен шагыйрә Маһруй Мозаффариянең Г. Тукай үлеме уңае белән язылган «Габдулла әфәнде Тукаевның хатын-кыз галәменә тәэсире» дигән мәкаләсенә күз салу да җитә.

[7] Гыйматдинова Кафия. Үткәннәрдән — «Азат хатын», 1928, 22 (40) сан, 2 б.

[8] Татарстан АССР тарихы. Казан, 1970, 269 б.

[9] Кузнецов И. Д. Национальное движение в период первой революции в России. Чебоксары, 1935, 205 б.

«Габдулла Тукаев хакыйкый халык шагыйре иде... Миллэтебез эчендэ згыйфь саналган хатын-кыз таифэсенэ дэ башлап күз салучы Габдулла эфэнде Тукаев булды... Аның аз гыйбрэле, күп мэгънэле хатын-кыз галэменэ даир булган берничэ сатыр шигыре безнең йөрэгебездэ ялкын кебек тээсир итте. Безне кузгатты, безнең башкалар кебек хокуклы инсан идекебезне үзебезгэ аңлатты, хатыннар авызыннан хокук җырын җырлата башлады. Шул шигырьлэр тээсире белэн безнең сүнгэн хиссиятебез баш күтэрде, балкыды. Инде ул, янар, ул мэңге сүнмэс...» — дип яза шагыйрэ.

Г. Тукайны күмү көнендэ татар хатын-кызларының зур кыюлык күрсэтеп ирлэр белэн бергэ зиратка бару факты үзе генэ дэ күп нэрсэ турында сөйли.

Г. Тукай үлүенэ ел тулу уңае белэн 1914 елны «Аң» журналында Рокыя Ибраhимиянең «Китте шагыйрь» дигэн эсэре дэ, беренчедэн, бөек шагыйребезнең бай иҗат мирасы тэсирендэ кулларына калэм алган татар хатын-кызларының саф йөрэктэн чыккан хислэрен, аңа булган мэхэббэтен чагылдырса, икенчедэн, аларның фикер ягыннан үсэ баруларына, яңа югарылыкка күтэрелүлэренэ дэ дэлил булып тора.

Эйе, илдэ күтэрелеп барган революцион көрэш, революцион-демократларның хатын-кыз азатлыгы өлкэсендэге эшчэнлеге төрле социаль катлаулардагы алдынгы татар хатын-кызларын да матбугатка алып килэ. 1905 елга хэтле татар матбугатына килгэн хатын-кызларның беренчелэре итеп Галимэтелбэнат Биктимерова, Хэнифэ Гыйсмэтуллина, Галимэ Рэхмэтуллинаны күрсэтергэ мөмкин. Аларның иҗатларында нигездэ уку-укыту, мэгърифэт hэм эхлак мэсьэлэлэре күтэрелэ.

Беренче рус революциясеннэн соң татар көндэлек матбугаты барлыкка килгэч, татар халкының политик аңы үсэ, иҗтимагый хэрэкэте дэ җанлана. Татар хатын-кызлары арасыннан да ялкынлы публицистлар җитешэ. Шундыйларның берсе — Фэрханэ Алушева. Аның дөньяга карашы Ф. Эмирхан hэм аның тирэсендэге демократик интеллигенция вэкиллэре тээсире нэтиҗэсендэ формалаша. Ул инде хатын-кызларны ачыктан-ачык көрэшкэ чакыра: «Хөр булуны телэсэгез, кичекмэстэн үзегез иркенлек алырга тырышыгыз. Патша думасыннан, буржуазиядэн азатлык көтү — ялгыш хыял ул,— ди.— Дума депутатларыннан азатлык турында hичбер нэрсэ көтэргэ ярамый, hичбер бай хезмэтчесенең файдасына вэ hичбер бояр крестьян тормышының яхшыруына тырышмый[1]» («Фикер», 1906, 26 сан).

Татар хатын-кызларыннан политик хокук өчен көрэшергэ чакыручылардан Хэнифэ Урманова белэн Зөhрэ Таhированы да күрсэтеп үтэргэ кирэк. Алар икесе дэ 1905—1906 елларда чыга башлаган «Фикер», «Вакыт», «Казан мөхбире» газеталарында мэкалэлэр бастыралар, хатын-кызларны революцион көрэшкэ өндилэр. Алар Көнбатыш Европадагы алдынгы хатын-кызларның политик хокукы, парламентларда үзлэренэ урын алу өчен көрэшүлэре турында сокланып язалар («Фикер», 1907, 3 сан; «Казан мөхбире» 1905, 13—19 саннар).

Беренче рус революциясе елларында hэм аннан соңгы чорда эдэбият мэйданына чыккан Маhруй Мозаффария, Мэхмүдэ Мозаффария-Урманчиева, Зэйнэп Сэгыйдэ, Мэхбүбҗамал Акчурина, Фатыйма Фэридэ иҗатлары бүгенге укучыларга таныш. Профессор М. Гайнуллин «Татар эдиплэре» (Казан, 1978) исемле китабында аларның тормыш юлын яктыртуга зур урын биргэн. Шулай ук 1905 ел революциясе дулкыннары тээсирендэ уянып, кулына калэм алган hэм азатлык өчен көрэшкэ басккан күренекле хатын-кызларыбыздан берсе булган Заhидэ Бурнашева (Гыйффэт туташ)ның «Татар хатын-кызлары хэрэкэте тарихыннан» исемле хезмэте 1971 елда дөнья күрде. Эле тормыш юллары hэм иҗатлары өйрэнелмэгэн, мираслары ачыкланмаган хатын-кыз язучыларыбыз да бар. Аларның эдэби мирасы шул вакытта чыккан көндэлек матбугат битлэренэ — «Вакыт», «Идел», «Таң йолдызы», «Йолдыз», «Өлфэт», «Кояш», «Аваз», «Тормыш», «Сибирия» газеталары сэхифэлэренэ сибелгэн.

Иреккэ сусаган алдынгы хатын-кызларыбыз шигырьлэрен бастыру өчен төрле юнэлештэге газета-журналлардан файдаланалар. Мэсэлэн, Галимэтелбэнат Биктимерова (1876—1906) үзенең шигырьлэрен «Өлфэт» газетасында бастыра, (1906, 51 сан), э Хэдичэ Сэнгатьзадэ (1875 — 1939) «Сөембикэ» журналында (1915, 7 сан) басылып килэ. Сүз уңаена эйтергэ кирэк, 1913 елда чыга башлаган бу журнал, сэяси каршылыкларына карамастан, үз чоры өчен прогрессив роль уйный. Анда татар хатын-кызларының демократик эчтэлекле күп кенэ мэкалэлэре басылган. Татар буржуазиясе мэктэп, тэрбия эшлэрен кичекмэстэн үз йогынтысына алырга, үз файдасына хезмэт иттерергэ тырыша. Менэ шушы шартларда татар хатын-кызларының алдынгы вэкиллэре хатын-кызны укыту, агарту, рус халкына hэм аның алдынгы культурасына хөрмэт тэрбиялэү өлкэсендэ үз бурычларын намус белэн үтилэр. Бу эшне башлап җибэрүчелэрнең берсе Хэдичэ Эхмэрова була. 1901 елда ул Казанда кызлар өчен русча-татарча мэктэп ачуга ирешэ. 1906—1907 елларда бу мэктэпне тэмамлап 30 дан артык хатын-кыз гимназиягэ керэ. Укучыларның социаль составы да берк адэр үзгэ-

ре. Бу өлкәдә Фатиха Аитова да күп эшли. Аның тырышлыгы белән 1908 елда Казанда кызлар мәктәбе ачыла.

Бу укыту, агарту хәрәкәте, әлбәттә, Казан губернасы белән генә чикләнми. Сәгъдия Хәсән кызы Булатова Касыйм шәһәрендә 1900 елны шундый мәктәп ачуга ирешә. Ул анда яңа ысул белән укытып дөньяви фәннәр кертә. Сәгъдия Булатова большевиклар белән элемтәгә кереп, революцион прокламацияләр тарата, ярлы халыкка сыйнфый көрәшнең нәрсә икәнен аңлата. Ул үз тирәсенә алдынгы фикерле татар яшьләрен туплап, спектакльләр куя, җыелган акчаны большевикларның Мәскәү комитетына тапшыра.

Касыйм шәһәреннән Сара Шакулова Франциядә Сорбонна университетының математика факультетын тәмамлап, Мәскәү университетында математика кандидаты дәрәҗәсе ала, мәктәпләрдә математика укыта.

Ул елларда югары белем алган татар хатын-кызларының берсе Разия Котлыярова-Сөләйманова. Ул 1891 елда Петербургта хатын-кызлар өчен югары мәктәпне тәмамлап, врачлык дипломы ала. 1905—1907 елларда ул Оренбургта врач хезмәте белән бергә, кызларны дәүләт мәктәпләренә хәзерләү, алар өчен курслар ачу эшләрен җәелдереп җибәрә. Татар кызы Әминә Батыршина да югары белем алып, Бакуның күренекле врачы булып җитешә. Ул Бакуда рус телендә чыга торган «Каспий» газетасында хатын-кызлар азатлыгы темасына тәрҗемә һәм оригиналь мәкаләләр бастыра. «Каспий» газетасы ориенталист О. С. Лебедеваның Римда французча басылган «Мөслимәләр хөррияте» исемле хезмәтен Ә. Батыршина тәрҗәмәсендә тәкъдим итә. Бу әсәр 1906 елда татарчага тәрҗемә ителеп «Казан мөхбире» газетасында да басыла.

Татар буржуазиясе хатын-кызлар мәгарифен, культура хәрәкәтен тормыш таләпләреннән читкә борып, ислам, шәригать киртәләре белән чикләргә маташа. Иске фикерле муллалар, карагруһчы байлар хатын-кызларның укуына бөтен көчләре белән каршы торалар. Бу өлкәдә нинди генә әшәке чараларны кулланмыйлар алар! Мөгаллимәләр өстеннән полициягә доносnúmлар язып, мәктәпләрне яптырту кирәкме, мөгаллимәләрне авыл куштаннары, староста, урядниклар ярдәме белән авылдан кудыру, яисә алар турында гайбәт таратумы — боларның барысы да эшкә җиңелә. Ләкин кара реакция һәм жандармериянең кысулары да, кадимче руханиларның котырынуы да аларның эшен тоткарлый алмый.

«Татар кызлары һәм мөгаллимәләрнең алдынгы катлавы,— дип яза Г. Ибраһимов,— эшче-крестьяннар белән бер сафта революция дошманнарына каршы көрәшәләр. Революция вакытында бу хәрәкәт — солдаткалар, эшче-крестьяннар арасыннан чыккан мөгаллимәләр хәрәкәте булды»[10].

Бөек Октябрь социалистик революциясендә актив катнашкан Абруй Сәйфи, Кояш Вәлитова, Нәфисә Казакова, Мәрьям Ибәтуллина, Җиһан Җәмлиханова, Әминә Алимбекова һәм башкаларның көрәш юлы 1905—1907 еллардагы революция тудырган мөгаллимәләр хәрәкәте белән тыгыз бәйләнгән иде. Әйе, Алафузов эшче хатын-кызларының 1905 елгы революцион традициясе 1917 елның январь, февраль айларында да кабатлана. Чәчелгән орлыкларның җимеше исә Октябрь революциясендә күренә.

Тарих сәхифәләрен актарганда бу данлыклы, үзләрен революция эшенә багышлаган хатын-кызларга сокланасың. Аларның гүзәл образлары яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүдә үрнәк булып тора.

**Мөнир ЮСУПОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

[10] Ибраһимов Г. Татар хатын-кызының тарихи үсүе — «Азат хатын» 1928. 2 сан.

## Салисә Гәрәева

# ТОРМЫШКА ГАШЫЙК

Безнең Ильяз Зиннуровны белмәгән кеше дә юктыр инде. Ул үзенең тынгысыз эшчәнлеге, металлургия өлкәсендәге уңышлы эзләнүләре һәм бигрәк тә тормышның катлаулы сынавы каршында югалып калмавы белән бөтен илгә танылды.

«Правда», «Советская Россия», «Известия», «Комсомольская правда» газеталарында да аның турында тирән эчтәлекле язмалар басылды. Мин дә, үзе белән бер шәһәрдә яшәсәм дә, аның турында газеталар аркылы гына таныш идем. Очрашырга гел җай чыкмый торды. Уйламаганда Ильяз Юнысович миңа үзе шалтыратты. Ул Чиләбе металлурглар Культура сараенда татар-башкорт тамашачылары өчен кичә оештыру мәшәкатьләре белән йөри икән. Киңәшү өчен мине өенә чакырды.

Мин килгәндә, Ильяз әле эштән кайтып җитмәгән иде. Ишекне аның хатыны Флюра ханым ачты. Болыт кебек дулкын кара чәчле, зур кара күзле, зифа буйлы мөлаем хатын. Ул мине залга кертте дә үзе аш-су бүлмәсенә чыгып китте.

Кунак бүлмәсен күздән кичерәм. Күзгә бәрелгәне — китап киштәләре. Өч кенә бөртек канәфер чәчкәсе алып килгән идем. Флюра ханым аларны вазага утыртып пианино өстенә куйды да: «Чак кына үзегез юаныгыз инде»,— дип, кабат ялгызымны калдырды. Мин ике стенаны каплап алып, шыплап тутырылган киштәләргә төбәлдем. Арада Тукай, Такташ, Туфан, Хәким, Еники, Әпсәләмов китаплары да бар.

Бераз-берәм балалар кайта башлады. Башта — Мәдинә, аннары, төпчек кыз Данияне ияртеп, Гөлнара. Минем белән тыйнак кына исәнләшеп чыктылар да, үз бүлмәләренә кереп, тынып калдылар. Нәни кыз Даниянең генә яңгыравык тавышы ишетелә.

Ниһаять, хуҗа кеше дә кайтты. Озын буйлы, киң җилкәле, күпереп торган куе бөдрә чәчле. Елмаеп күрешә. Сынаучан, акыллы һәм хәйләкәррәк караш... Менә нинди икән ул Ильяз!

Ул берничә ел инде китап сөючеләр иреккле җәмгыятенең Чиләбедәге Металлурглар районы оешмасында, җәмәгатьчелек тәртибендә, председательлек вазифасын башкара. Аның мондагы төп эше — политик һәм техник әдәбиятны пропагандалау, тик Ильязның матур әдәбиятны да читтә калдырасы килми. Шуңа күрә ул татар һәм башкорт телендә укучылар өчен әдәби-музыкаль кичә үткәрүне дә планлаштырган. Үзешчән сәнгать коллективлары белән дә килешеп куйган. Әдәбият әһелләреннән кемнәрне чакыру турында киңәшләшеп утырдык.

Кичәбез уңышлы үтте. Кеше бик күп килгән иде. Китап сату да оештырылган. Килгән тамашачылар, күп рәхмәтләр әйтеп, бик канәгать булып таралдылар. Мин исә бу кичәдә үземә яңа дус таптым.

Ильяз Татарстанның Чистай ягыннан икән. Уйлап куйдым: туган якларында аның нинди каһарман икәнен белмиләрдер дә әле. Олы йөрәкле, киң эрудицияле, эшлекле һәм искиткеч сәләтле Ильяз Зиннуров белән якташларымны таныштыру теләге туды.

Ильязның әтисе Юныс абзый Зиннуров гаиләсе Чистай районы Зирекле (хәзер бу авыл Яңа Чишмә районына керә) авылыннан. Гаилә, Ильяз кечкенә чакта ук, Чиләбе өлкәсенең урманлы-таулы җирендә, исемсез бер тимер юл разъездына килеп урнаша. Ата-ана эшкә киткәндә, балалар өйдә үзләре генә калалар. Икмәк, бәрәңге чутлы. Бернәрсә дә күктән яумый... Ильяз һәм аның ике туганы, тормыш авырлыгын бала чактан ук татып, икмәк һәм игелек кадерен яшьли белеп үсәләр. Беркөнне шулай балалар өйдәге ярты кирпеч икмәкне бер утыруда ашап бетерәләр. Алай да тамаклары туймый. Ильязга да, абыйсына һәм сеңлесенә дә әлегә әниләреннән. Шул юклык заманында сабыр, намуслы булырга өйрәнәләр алар. Өй эшләрен, әниләре кайтканны көтеп тормыйча, үзләре башкаралар. Буш вакытта кулларына нинди китап эләгә — шуны укыйлар. Ильяз бигрәк тә кызыксынучан булып үсә. Тимер-томыр арасында кайнашу аеруча ошый аңа.

Ул чагында Магнитогорск корыч кою осталары — Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Зиннуров, Владимир Захаров, Иван Семенов турында газеталар, радиолар,

шаулый. Их, менә шулар кебек корыч кою остасы булсаң иде! — дип хыяллана Ильяз. Шушы хыял Ильязны Магнитогорск каласына, индустрия техникумына алып килә. Зур тырышлык белән корыч серләрен, корыч коючы һөнәренең нечкәлекләрен өйрәнә Ильяз. Илнең металлургия флагманы булган Магнитогорск корыч кою комбинатында практика үтә, техникумны уңышлы тәмамлый. Яшь белгечне Чиләбе шәһәрендә металлургия заводына (хәзер комбинат) эшкә билгелиләр.

1957 ел. Кесәсендә — диплом. Алда яңа, мавыктыргыч зур тормыш, матур хыяллар. Егет Металлурглар районындагы тулай торакта яши башлый. Үзе сайлаган һөнәргә малайларча гашыйк Ильяз эрегән металлны олы «чүмеч»ләргә агызу бригадасында эшли. Озакламый аны мартен цехына смена мастеры итеп билгелиләр. Ильязның күңеле тагын да үсеп китә. 19 яше яңа тулган егет — утка чыдам эшләр мастеры! Шәп яңгырый! Үзе нинди җаваплы эш бит бу! Димәк, егеткә ышаналар. Һәм ул булдырачак!..

Цех җитәкчеләре бу озын буйлы, имәндәй нык гәүдәле, тузган чәчле татар егетенә, чыннан да, зур өмет баглыйлар. Сынатмый егет. Сәгать санап эшләми: иң алдан килә, соң гына китә. Һөнәренең бөтен нечкәлекләрен, катлаулы җиһазларның серләренә төшенү өчен бернәрсәдән дә тартынып тормый. Берсендә хәтта металл чыгару ялгашына төшә, әле суынып та җитмәгән мартен мичена керә. Мичне төзәткән чакта аның бөтен ягын белергә кирәк саный.

Мартен цехының яшьләре Ильяз Зиннуровны комсомол секретаре итеп сайлап куялар. Тере, хәрәкәтчән, һәр кеше белән уртак тел таба белүче бу ачык йөзле егетнең бәхете менә шулай ачылып китә.

Җиденче мартен цехында 8 нче мичнең корыч чыгаручы кече ялгашын иртәнге сәгать дүрттә беркеттеләр. Ильяз, мастер буларак, һәр хәрәкәтне күзәтеп тора иде. Ялгаш үз урынына утырып җитмәгән. Ул, иелеп, ялгашны яңадан карады. Чак кына күтәрергә кушты. Чылбырны тарттылар. Ильяз кранчыга кул изәде.

— Чак кына төшер!

Ниһаять, ялгаш нәкъ үз урынына килеп утырды. Һәм шул секундта... Ильяз басып торган бетон мәйданчык алты метрлы биеклектән аска томырылды. Бу хәл күз ачып йомган арада булды. Ильяз үз өстенә дәһшәтле авырлыгы белән төшеп килүче бетон япманы шәйләде һәм... онытылды.

Аңына килгәч тә авыртуны бөтенләй сизмәде Ильяз. Дөнья тынгандай иде. Куркыныч тынлык. Кинәт ул аякларын баскан бетон яссылыкны күрде, аны куллары белән этәргә теләде. Авырлык урыныннан да кузгалмады. Ильязның коты очты. Бөтен дөньяда япа-ялгыз калгандай куркыныч. «Үлем» дигән уй миен көйдереп узды. Ул җан ачысы белән кычкырып җибәрде. Авыртудан түгел, авырту әле аның зиһененә килеп җитмәгән иде!

Менә аның янына иптәшләре җыелды: агарынган, куркынган таныш йөзләр. Ильязга рәхәт булып китте: үзе генә түгел! Тирә-якта — кешеләр. Үлсә дә, ялгызы түгел! Калганын хәтерләми... Сагышлы үкенеч тойгысы тәэсирендә ул караңгылыкка чумды.

Күтәртмәгә салып цехтан алып чыгып барганда ул яңадан аңына килде.

— Гаҗәп: шул мизгелдә,— дип искә ала Ильяз,— бөтен гомерем күз алдымнан узды. Дөнья белән бәхилләшү, дип уйладым. Курку хисе юк иде. Үзәкне иң өзгәне: «Шушы цехка, ут дөрләп торган мартеннарым янына мәңге кайта алмам инде», дигән уй булды. Күзләрем шуңа яшьләнде...

Бер танышып алгач, без еш очраша башладык. Менә тагын аның өч бүлмәле квартирасында утырабыз. Бер читтә шомартылган такталар өелгән. Китапларга урын җитмәүдән зарлана Ильяз. Коридорга киштәләр ясамакчы икән. Балта-пычкыга, ышкыга кулы ятып тора аның. Өйдәге ремонтны да Флюрасы белән икәү ясыйлар. Кызлар да кул арасына кererлек булып килаләр.

Ильяз белән сөйләшү дә рәхәт. Ваклыклардан арына барасың кебек. Тездән югары ике аягы да киселгән кеше һәр сүзе белән сине көчлерәк итә сыман. Шат ул, көләч, гайрәтле. Үз-үзен шул кадәр нык тота алырлык ихтыяр көче каян килә аңа!?

Операция бик озак барды. Ике аягының да сөякләре чәрдәкләнеп беткән иде. Операция вакытында дистәләгән кеше, телефоннан шалтыратып, аның хәлен сорашып торды. Ишек төбенә кан бирергә әзер дуслары тезелгән. Бүлмәдәш егете Николай Овчаренко операция беткәнче ишек төбеннән китмәде.

Ул күзләрен ачты. Бүлмә ап-якты. Кояш нуры күзенә төшкәннән уянган икән. Тукта, әле генә цехта иде бит ул! Эрегән корыч ташкынын чыгарырга ашыга иде. Кинәт куркудан йөзе агарынган иптәшләре күз алдына килде. Аягына басмакчы булып, юрганын ачып җибәрде. Ah!!! Алар урынында ак марляга уралган кыска гына бот сөяге... Рәнҗүле ыңгырашу күкрәген ярып чыкты һәм Ильяз, яңадан аңын югалтып, урынына ауды.

Операция нәтиҗәсенең авырлыгын ул ялгызы кичерде. Күңеленә: «Үлсәм, яхшырак булыр иде!» дигән үкенечле уй оялады. Кемгә кирәк инде мин? Карт әнигә имгәк кенә!»...

Врачлар: «Депрессия»,— диделәр. Өметсезлек, үкенеч, сагыш — бөтенесе бергә

кайный, хәтта күздән яшь тә чыкмый. Бу халәттәге кешене дәвалау да мөмкин түгел. Ильяз, өметсез күз карашын стенага төбәп, сүзсез ята. Әнисе улына карап тора:
— Балам... — ди дә, юатыр сүз таба алмыйча, елый башлый. Сеңлесе дә елый. 19 яшендә ике аяксыз калган егетне ни дип юатасың инде?

Егетнең хәлен белергә иптәшләре алмашлап больницага йөриләр. Бөтенләй таныш булмаган, элек аралашмаган кешеләр, олылар, яшьләр килә. Күчтәнәчләр, чәчәкләр... Ә Ильязның күңелендә аяусыз караңгылык. Ул чакта цехның партбюро секретаре Анатолий Андрианович Власов иде. Еш килде ул Ильяз янына.
— Син үзеңне безнең белән хис ит, Ильяз!— дип юата иде.
Цех операторы Мария Баранова берсендә:
— Кара әле, Ильяз, аяксыз да яшиләр бит кешеләр,— диде.— Сугыштан күпме аяксыз егетләр кайтты. Эшләделәр, яшәделәр, гаилә кордылар. «Повесть о настоящем человеке» китабын укыганың бардыр бит?!
Палата сестрасы аңа радио тыңлар өчен колак аппараты китереп бирде. Бу бүләк аның күңелендә борылыш ясады кебек. Бигрәк тә кичке якта, палатада авыр уйлар белән ялгызы калганда, радио тыңлау аны дәртләндерә иде. Иркен сулышлы музыка яңгырый. Аның тормышы да шушы музыкадай якты, бәхетле башланган иде... Кинәт якты музыка агымына чит, караңгы, кискен авазлар тулды. Гүя җил чыкты, давыл башланды. Яктылык белән Караңгылык, Яхшылык белән Явызлык кылычка-кылыч килеп бәрелешәләр. Әллә кайдан, ерактан якты авазлар кабат ишетелә башлады. Алар торган саен көчәйделәр, бөтен дөньяны тутырып тирбәлә башладылар.
Бер көнне палатага, шаулашып, бер төркем яшьләр килеп керде. Бусы инде комсомол комитетыннан. Анатолий Вяткин эше. Көлешәләр, уен сүзләр әйтәләр, гүя берни дә булмаган. Ильяз ихтыярсыз елмаеп җибәрде:
— Әллә инде җыелышны минем палатада үткәрмәкче буласыз?
— Әйе шул! Шуның өчен килдек тә! Көн тәртибендә бер генә мәсьәлә: синең алдагы эшләрең...
Бер тавыштан карар чыгардылар: Ильяз Зиннуровка тизрәк терелергә, белемен күтәрү һәм тизрәк эшкә кайту турында уйларга кушылды.
Иптәшләре чыгып киткәч, Зиннуровның уйлары җитдиләнеп китте. «Баш исән бит әле! Җебеп калды түгелме соң әле ул?! Яңадан аякка басарга иде!»
Чиләбе металлургия заводы үтенече буенча, Мәскәүнең катлаулы протезлар ясау фәнни-тикшеренү институты Ильяз Зиннуровны үзенә чакырып алды.

Ильязны Мәскәүгә мартен цехы партоешма секретаре Виктор Тимофеевич Афонин озата барды. Ул авыруларны кабул итү бүлмәсенә Ильязны аркасына атландырып алып керде. Ильязның күңелен тагын: «Их, бу көнгә калганчы, үлгән генә булсамчы!» дигән үкенеч көйдерде.
Больницада бер-берсенә игез балалардай охшаш көннәр башланды. Дүртенче катта дүрт кешелек җыйнак кына палата. Ильязның хәле, бүлмәдәшләренеке белән чагыштырганда, иң авыры.
Ниһаять, аңа дигән протезлар әзер. Инде, аларны киеп, басарга, йөрергә өйрәнергә кирәк. Беренче тапкыр протезларын киеп аягына баскач, ике ягыннан ике сестра тотып торуга карамастан, Ильяз шартлап идәнгә егылды. Булмый икән!.. Күтәреп, аны урынга салдылар. Ильяз стенага борылып ятты. Аның берәүне дә ишетәсе дә, күрәсе дә килми. Калдырыгыз аны, калдырыгыз!
Кемгә кирәк ул? Карт әнисенә имгәк. Аннары уйлары яктыра башлый. Юк, ничек тә өйрәнергә кирәк! Маресьев өйрәнгән бит! Ильяз, синең үз законың булырга тиеш! Зиннуров законы! Бирешмәскә! Үз-үзеңне кызганмаска!
Икенче көнне иртән үк ул гәүдәсенә протезларын беркетте. Басты, авыртуга чыдый алмыйча, кабат шартлап ауды. Иреннәрен тешләп яңадан басты, койкасына тотынып беренче адымын атлады, тагын, тагын... Бүлмәдәшләре аны дәртләндереп, куәт биреп тордылар. Сестра култык таяклары кертте, ярдәмләшеп торды. Бер-ике адым ясагач та, туктатты: бүгенгә җитәр. Акрынлап өйрәнерсең, сабыр ит!
Ильяз төннәрен аякларына үзе массаж ясады, иртән кабат массаж... Яңадан протезларын беркетте, күтәрелде, басты. Миен үзәк өзгеч авырту ярып үтте.
«Бер! Ике! Өч!..» Иреннәрен тешләп, Ильяз адымнарын саный. Үз койкасы яныннан күрше койкага барып җиткәнче 7—8 минут үтә. «Маресьев булдырган, мин дә булдырырга тиеш!»
Ниһаять, аңа больница бакчасына һава алырга чыгарга рөхсәт иттеләр. Ильяз дүртенче катта лифтка утыра, парадный ишек алдындагы баскычларны үтеп, җиргә баса. Бер сәгать эчендә култык таяклары белән 7—8 адым ясый. Гүя бер ел тоела шул вакыт. Ә авырту — анысы һәр күзәнәктән кычкыра, бөтен тәне, күңеле, йөрәге ялвара:
— Кызган! Тукта, ятып тор!
Тагын бер адым. Авыртуга чыдый алмыйча, ул авыр гәүдәсе белән лапылдап җиргә ава. Ә акылы боера:
— Атла!!! Алда — гомер! Үзең үтәсе гомер! Атла! Кая синең «үз законың?» Атла!!
Айлар үтә торды. Ильяз ике култык таягы белән йөрергә өйрәнде. Беркөнне клиника бакчасының иң аулак почмагында култык таякларын ташлап карады Ильяз.

Врачлар әйтә: иң авыры — куркуны җиңү. Егылу, авырту — бер хәл. Шул авыртуны җиңеп, үзеңне кабат басарга мәҗбүр итү искиткеч авыр!

Ильяз санап бетергесез мәртәбәләр егылды. Култык таякларын ташлап, мәстәкыйль адым ясарга ымсындымы — гөрселди дә ава. Авырлыгы 80 килограмм, киң җилкә, киң күкрәк. Җир аңа күз йомган арада үзе һөҗүм итә кебек! Иреннәрен канатканчы тешләп, үзен торырга, култык таякларына таянып басарга, алга атларга мәҗбүр итә, тагын газаплы адымнарын саный башлый. Протезының каешлары тәненә кызыл тасма булып батып керә, аягының протезга терәлеп торган җөйләреннән кан саркый. Әле палатага җиткәнче дүрт катның баскычларын үтәсе бар. Вахтер карт, Ильязны күрүгә үк, лифт ишекләрен ачып җибәрә:

— Монда гына кер, улым!

— Рәхмәт, агай, үзем меним әле!— ди ул һәм мең газап белән сәгать буе дүртенче катка менә, койкасына ава.

Берсендә Ильяз коридордан барганда, каршысына врач килеп чыкты. Ильяз бик хөрмәт итә иде аны. Фронтта врач булып йөргән, өлкән яшьтәге бу рус хатынының да бер аягында протез. Ләкин аның протезлы икәнен сизмисең дә!

Врач аны күрү белән исәнләште, аркасыннан сөйде дә:

— Ну-ка, Илюша, таягыңны бир әле!— дип, култык таякларын алды.— Менә шулай. Ярый, хуш. Бар, атлавыңда бул!

— Таяксыз булдыра алмыйм.

— Ә син тырыш! Булдырып кара! Атла әле, я!..

Ильяз стенага тотынды, аннары авыртуны, куркуны җиңеп, бер атлады. Тагын бер адым, тагын...

Ильязны Мәскәүдән алып кайтыр өчен институтка заводтан Борис Ландер килде. Алыптай кешене, мөгаен, кирәк була калса, Ильязны күтәреп тә йөртер дип җибәргәннәрдер. Борис Ландер лифттан дүртенче кат коридорына чыкты һәм, шаккатып, туктап калды, каршысына ышанычлы адымнар белән Ильяз Зиннуров үзе килә иде!

Кочаклаштылар. Икесе дә еладылар. Ильязның авырлыклар аша килгән татлы җиңүе иде бу.

Әле Чиләбедә больницадан чыгуына ук завод аңа бер бүлмәле квартира биргән иде. Бу юлы аны җиңел машина көтә. Пенсия дә ярыйсы. Яшә генә!

Аңа көн саен диярлек иптәшләре килә башлады. Арада күчтәнәчкә «ярты» кыстырганнары да була.

Ачылган аракы шешәсен хәл белүченең кесәсенә кирedән тыкты Ильяз:

— Минем янга килергә теләүчеләргә әйт: бирәүгә дә шешәдәш буласым юк!..

Уналты яшендә үк мартен миче кайнарлыгын тойган егетне өйдә тик яту тәмам туйдырды. Ул киңәш сорап комсомолның Чиләбе өлкә комитетына китте. Анда аңа укытучы һөнәрен сайларга, Чиләбе педагогия институтына керергә тәкъдим иттеләр.

Юк, күңел металлургиягә кагылышы булмаган һөнәрне һич кабул итми иде. Ильяз Чиләбе политехника институтына имтихан тотып карарга булды. Иптәшләре дә аның уен хупладылар: «Инженер-металлург булырга бөтен мөмкинлекләрең бар,— диделәр.— Әйдә, тәвәккәллә!»

Шулай итеп, Ильяз институтның кичке бүлегенә укырга керде. Бу вакытта инде ул металлургия комбинатының проектлар бүлегендә эшли башлаган иде. Ни өчен ул бу хезмәтне сайлады? Сәбәпләре күптер, бәлки, әмма берсен аерып алып күрсәтергә була: Ильяз фаҗигасе турындагы актның соңгы юлларында мартен миченең корыч чыгару мәйданчыгы проектсыз гына төзелгән булуы искәртелгән иде.

Озакламый проект бүлегендә электр ярдәмендә корыч эретү буенча конструкторлык бюросы ачылды. Иң тәҗрибәле, белемле, зирәк инженерларны шул бюрога чакырдылар. Ильяз бу тәкъдимне теләп кабул итте. Аны сектор мөдире итеп билгеләделәр. Шуны да әйтергә кирәк: Ильяз Зиннуров эшләгән өчен хезмәт хакы алудан баш тартты.

— Пенсиям җитәрлек. Аннары, миңа иҗат иркенлеге дә кирәк. Штаттан тыш, җәмәгатьчелек тәртибендә эшләячәкмен,— диде.

Гаиләсеннән, ата-анасыннан килә торган тыйнаклык, гаделлек иде бу. Әтисе дә, әнисе дә байлыкка табынмадылар, балаларына да барына канәгать булырга кирәк, дип өйрәтә килделәр. Хезмәт хакыннан баш тарту шул тәрбия нәтиҗәсе иде.

Тормыш үз көенә дәвам итә. Ильяз көндезләрен эшли, кичләрен институтка ашыга. Гаилә мәшәкатьләре дә җитәрлек. Флюра Бакировна белән өйләнешеп, беренче кызлары тугач, бер бүлмәле фатирлары тараеп калган кебек булды.

Флюра ханым турында сүз чыккач, аңа аерым тукталып алыйк әле. Ул үзе турында болай дип сөйли:

— Минем әти сугыштан аяксыз кайтты. Хәзер дә исән әле. Әнкәй дә, мин дә әтине авырсынмый тәрбияләдек. Ильяз да миңа әтием кебек якын булды. Мин аны чын күңелдән ярата идем. Аяксызлыкның катнашы юк та монда. Ильяз — нык холыклы

егет. Хәер, әле мин аның белән танышкан чакта ул әле беркайда да эшләми иде. Бәхетсезлеккә юлыккан бер егет кенә иде.

Тормыш җиңел дип әйтмәс идем. Төрле чак бар. Акчага аптыраган чаклар да булгалады: Ильяз 1980 елга кадәр эш хакыннан баш тартты — пенсиясен генә алдык. Бу иркен фатирыбызга да берничә ел элек кенә күчендек әле. Мин үземне бик бәхетле итеп сизәм. Ильяз — кайгыртучан, әйбәт ир, ягымлы, таләпчән ата, чын кеше. Аның дөньясы — минем дөньям. Дөньябыз тулылана бара. Гаилә коргач, Ильяз институт бетерде, кандидатлык диссертациясен яклады, китаплар язды. Мин гаилә эшләре өчен аның кыйммәтле вакытын алмаска тырышам. Дөрес, үземә дә вакыт җитми, укытучы бит мин. Мәктәптә биология укытам...

Группадашлары беренче курста ук Ильязның металлургиядә тәҗрибәсе булуын, бу эшне яратуын сизеп өлгерделәр. Студентлар аны бертавыштан староста итеп сайладылар. Чиләбе металлургия комбинаты инженеры Галина Бродецкая Ильязның студентлык еллары турында бик җылы итеп сөйли:

— Безнең группага Ильязның ярдәме нык тиде. Без аңа барыбыз да гашыйк идек. Кичке бүлектә уку бик авыр. Арабызда Ильяз булмаса, укуны ташлаучылар да табылыр иде, мөгаен. Безнең группадагы иптәшләрнең берничәсе Ильяз аркасында гына диплом алып чыкты. Чөнки Ильяз һәр студент белән уртак тел таба белә. Сөйләшә, ышандыра, кирәк чакта, ачуланып та куя. Институтны ташларга җыенып, дәрескә йөрми башлаган берничә иптәшнең өенә барганы, оялтканы хәтердә...

Диплом алганнан соң аны бүлек мөдире итәләр. Металлургия фәнни-тикшеренү институтының корыч эретү проблемалары секторына проект бүлегенең начальник ярдәмчесе Лев Константинович Кузнецов кердә дә: «Сезгә яңа бүлек мөдире киләчәк, аңа карата игътибарлырак була күрегез».— дип, Ильяз Зиннуровның язмышы турында сөйли.

Бүлек бинаның дүртенче катында. Баскычлары шул кадәр текә, озын, һич бетмәс шикелле. Ильяз, үҗәтләнеп, баскыч арты баскыч үтә. Маңгаена, аркасына салкын тир бәреп чыга. Чәчләре тирләп маңгаена ябыша. Ильязга шефлыкка яшь инженер-конструктор Людмила Лядова билгеләнде. Шуңа күрә дә ул бүген Ильяз белән дүртенче катка менеп килә. Яшь хатынның, кызганудан, йөрәге кысыла. Дүртенче катка менгәнче ул да шабыр тиргә батты, алҗыды, ярдәм итә алмаудан гаҗиз булды. Ниһаять, дүртенче кат. Ильяз җиңел сулап куйды, Людмилага карап гаепле кеше сыман елмайды.

Шулай итеп эшли башлады Ильяз. Берничә көннән аның аяклары юклыгын бөтенләй онытты лар. Шаян сүзле, ачык, киң эрудицияле җитәкче инженер-конструктор белән эшләве рәхәт иде. Ул тугыз тулганчы ук килеп җитә, дүртенче катка менеп, кульманы артына утыра, эшкә чума. Иптәшләре еш кына аннан киңәш сорыйлар, үзе дә аңламаган нәрсәне сораудан тартынмый. Кичен дә Ильяз кайберәүләр кебек тота-каба өенә ашыкмый.

— Әйдә, Ильяз,— диләр аңа.— Кайтыр чак җитте.

— Сез кайтыгыз, мин утырам әле. Кызык бер фикер килде...

Институтның электр ярдәмендә корыч кою секторы конструкторлары Герасимчук, Тимофеев, Чеботарев белән берлектә Ильяз Зиннуров зур күләмле мичнең цилиндрик очлы өслеген проектлау һәм эшкәртүдә катнашты. Электр мичененң түбәсен өр-яңадан конструкцияләүне Ильяз бер үзе башкарып чыкты. Әлеге эш аңа җиңел булды, чөнки диплом яклаганда бу проблема белән очрашкан иде инде.

Зиннуров металлургия комбинаты өчен күп кенә гаять файдалы тәкъдимнәр кертте. Мәсәлән, аның дугалы электр мичләрен камилләштерү өчен ясалган конструкцияләре комбинатка миллион сумнан артык табыш бирде.

Мартен мичләрен ремонтлаган чакта, Ильяз мичнең дугаланып килгән түбәсенең ныграк януына игътибар итте. Ул илнең төрле металлургия заводларында эшләүче мичләрне тикшереп чыкты: кайда да шул ук хәл. Сызымнар, сызымнар... «Әгәр стеналарны дугадан читкәрәк этәрсәң?.. Кара, мичкәгә охшый икән бит бу?! Болай итсәң, утның тәэсире тигезрәк таралачак».

Ильяз шушы мәсьәләгә чумды. Мичләрнең эчләренә кереп-кереп карады, ремонтчылардан ашалган стенаны катлам-катлам итеп куптаруларын сорады. Лабораториядә тикшерү өчен шулай кирәк иде. Мич җимерекләре, кирпеч өемнәре буйлап күп йөрде Ильяз. Егылды, торды, яңадан эзләнеп китте.

Әлбәттә, аяклары исән булса, эш тизрәк барыр иде баруын. Әмма барыбер бәхетле минутлар кичерде Ильяз: шул ватык кирпеч өемнәренә арыган-алҗыган хәлдә килеп утырып, тирләгән маңгаен кулъяулыгы белән сөрткән чакларында да ул электр дугалы мичнең яңа төр сурәтен абайлый иде.

Ильяз сызымнарын Чиләбе политехник институты профессоры Алексей Константинович Петровка күрсәтте. Профессор укучысын хуплады, аны Ильяз тәкъдим иткән мичнең яңа өслегенең формасы кызыксындырды. Эзләнүләрне нинди юнәлештә дәвам

итәргә кирәклеген аңлатты. Ильяз институттан канатлар үскән кебек дәртләнеп кайтты.

Секторда да Зиннуровның эше зур кызыксыну уятты. Аңа югары бәя бирделәр. Бүлек җитәкчесе Константин Павлович Жаворонков Зиннуровка эшне тормышка ашыруда ярдәм итте. Яңалык кулланышка керде. Нәтиҗәсе көтелгәннән дә югары булды: моңа кадәр мичләрне 20 көн эшләгәч тә ремонтка туктаталар иде. Яңа төр мич исә 40 көнгә чыдый!

Ильяз исә үзен зур эшләр майтарырга сәләтле кеше итеп тойды. Күңеле күтәрелеп, Мәскәүгә металлургия институтының кичке бүлеге мөдире проректор Л. Е. Никольскийга да шалтыратты. Ильяз аңа үзенең соңгы эзләнүләре — электр мичләрен мичкә рәвешендәге өслекләр белән эшләтә башлау тәҗрибәсен сөйләде. Никольский кызыксынып китте, сораулар бирде һәм ахырда үзенә, Мәскәүгә, читтән торып аспирантурада укырга чакырды.

Бу турыда Ильяз үзе дә уйлаган иде уйлавын. Аспирантура бетерү начар булмас иде. Ләкин көче җитәрме соң? Аңа бит күп санлы эксперимментлар, эзләнүләр алып барырга туры киләчәк! Лаборатория шартларында түгел, ә дәүләт планын үтәргә тиешле металлургия комбинатында! Сектор белән җитәкчелек итү дә — аның өстендә. Өлгереп булырмы?

Ильязның шушы каршылыклы, борчулы, куанычлы һәм мәшәкатьле уйларына гаилә борчулары килеп кушылды. Гаилә өчен үз-үзен аямыйча тырышучы Флюра ханым авырып китте. Шунда гына Ильяз сөекле гомер юлдашы җилкәсенә нинди авыр йөк салынганлыгын аңлады. Аңлады да шаккатты! Гаҗәеп сабыр, изге күңелле, фидакарь хатын икән бит аның Флюрасы! Флюра шифаханәдә ятканда, аңа ике кызны көн дә балалар бакчасына озата йөрергә, кибеттән азык-төлек юнәтергә, өй җыештырырга, керләр юарга туры килде. Җитеш кенә! Әле ярый, әнисе белән сеңлесе килеп булышкалап киттәләр.

Ниһаять, Флюра терелеп өйгә кайтты. Ул өйдә булганда, күңелле дә, якты да, җылы да икән бит! Шул өй мәшәкатьләре белән Ильяз фәнни эзләнүләреннән читләшеп, үзенә икенче мавыгу тапты: инглиз теле белән япон телен өйрәнү турында хыялланды. Техник журналлардан металлургиягә кагылышлы мәкаләләрне тәрҗемә итә башлады. Бернichә мәкаләне тәрҗемә дә итте. Шул чагында ул төрле телләрдә чыккан техник һәм фәнни журналлардагы металлургиягә караган мәкаләләрнең картотекасын булдырды. Ильяз картотеканы бүген дә тулыландыра бара.

Үзенең яңа мавыгуы турында фәнни җитәкчесе Петровка әйткән иде, профессор шактый кырысланды:

— Син ни белән мавыксаң да ирекле, тик мин бары тик электрометаллург Зиннуровны гына беләм, ә тәрҗемәче Зиннуров турында, валлаһи, ишеткәнем юк! — диде.

Петров сүзләреннән соң Ильяз хафага калды. Чиләбе политехника институты деканы профессор Строганов белән киңәште. Строганов исә Ильяз Зиннуровны үз янына чакыртты, эзләнүләре һәм тәҗрибәләре өчен институтның лаборатория җайланмасын тәкъдим итте: эшлә, эзлән!

Диссертация, дип, Ильяз бик очынып китмәде. Бу хезмәт комбинат өчен ул кадәр үк мөһим түгел, күбрәк аның үзе өчен генә кирәк кебек тоелды. Мондый фикердә булу диссертация эшенә бераз салкынлык өстәде. Аңа яңа бурыч йөкләнде: дугалы мичләрнең атласын төзергә һәм нәшрият өчен китап итеп әзерләргә. Бу — бөтен ил металлургиясе өчен мөһим иде, илебез конструкторлары шушы проблеманы чишә алмый азапланалар иде.

Сугыштан соңгы елларда электрометаллургиядә дистәләгән төрдәге мичләр барлыкка килгән. Аларны барлап, эш ысулларын өйрәнеп, арадан иң камилен сайлап алырга кирәк. Яңа ачышларны да булган мичләрнең отышлы якларына таянып кына ясарга мөмкин ләбаса.

Ильяз Зиннуров шушы атласны төзү эшенә алына. Моның нинди җаваплы, нинди катлаулы бурыч икәнлеген соңыннан гына аңлый ул. Ләкин чигенергә ярамый. Ильяз чигенергә өйрәнмәгән. Бераздан бу эзләнүләр белән тәмам мавыгып китә ул һәм эше белән фәнни-тикшеренү институтының башка хезмәткәрләрен дә кызыктыра.

Бергәләп эшләгәч нәтиҗә дә күренә башлый. Әле бүген дә Чиләбе металлургия комбинатында бер вакыйганы горурланып искә төшерәләр: министрлыктан килгән бер иптәш трибунадан үзенең Япониядә булуы, андагы авыш электродлы мартен мичләре турында сөйли. Корыч коючылар:

— Шул кадәр акча түгеп, Япониягә барасыгыз калмаган, авыш электродлы мич безнең цехта да бар! Зиннуров проектлаган иде!..— диләр.

Атлас төзү берничә елга сузыла. Китап нәшрият планына кертелүгә, аны сорап хатлар ява! Хәтта чит илләрдән йөзләрчә үтенеч килә. Ниһаять, авторлар коллективы тарафыннан төзелгән «Атлас» чыга һәм мунча ташына сипкән судай шунда ук таралып та бетә!

«Атлас» өстендә эшләгәндә Ильяз Красноярск, Ленинград, Липецк, Запорожье, Электросталь һәм башка 18 металл кою үзәкләренең эше белән урынга барып таныша, йөздән артык электр мичененең эшен җентекләп тикшерә. «Атлас» илебез металлургларының үтенече буенча берничә тапкыр кабат басыла. Ул китапны сорап бүген дә нәшриятка хатлар килеп тора...

Бу эш Ильязда тагын да зуррак бурычларны үтәргә ышаныч та тәрбияли. Ниһаять, аны диссертация өчен алган темасы тынгысызлый башлый. Яңадан журналларда актарына, картотекасын карап чыга, тулыландыра. Журналлардан металлургиягә караган яңалыкларны тәрҗемә итә. Эзләнүләре аны «Днепроспецсталь» металлургия заводына алып килде. Монда ул производствода углеродлы блоклардан файдалану мәсьәләсен хәл итәргә тиеш иде. Максаты: синтетик шлаклар эретә торган яңа мичнең сызымнарын эш шартларында күзәтү һәм раслау иде. Заводта аны каршы алучы булмады, беркем озатып-күрсәтеп тә йөрмәде. Бөтен мичләрне ул үзе эзләп тапты, тикшерде, белгечләр белән сөйләште, бәхәсләште, фикерләрен дәлилләп күрсәтте.

Командировка планы тулысынча үтәлде. Тик бу завод цехларында җәяүләп йөрүнең, цехлардагы текә баскычлардан менеп-төшүләрнең никадәр авыр булуын Ильяз Юнысович үзе генә белә!..

Ә менә аның протезлы икәнен бу заводта белми дә калдылар бугай. Чөнки Ильяз һәрвакыт: «Минем беркемнән дә аерылып торасым килми, кешеләр минем хәлне сизмәсә, яхшырак»,— дигән фикердә тора.

Ниһаять, ул — Чиләбедә. Аның туган җире булмаса да, аны үстергән, кеше иткән, һәр адымында ярдәмгә әзер торган җанга якын кала. Монда ул комсомолдан партиягә кабул ителде. Монда хәтәр фаҗигане җиңеп, югарыга, яктыга омтылды һәм яңаданяңа җиңүләр яулады.

Техник фәннәр кандидаты исеменә кандидатлык диссертациясен ул Мәскәүдә 1980 елда яклады. Хәзерге көндә ул Чиләбедә металлургия фәнни-тикшеренү институтының проектлау-конструкторлык секторын җитәкли. Металлургиядәге казанышлары өчен Ильяз Зиннуров «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Аның «РСФСРның атказанган рационализаторы» һәм «СССРның уйлап табучысы» дигән мактаулы исемнәре бар.

Ул бүген дә элеккечә тырышлык белән илһамланып эшли. Командировкаларга да еш йөри, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, күп еллар пропагандистлык эшен дә дәвам итә. Ул җитәкләгән район китап сөючеләр җәмгыяте өлкәдә иң алдынгы булып исәпләнә: политик һәм техник әдәбиятны ул төрле ысуллар белән тарата, кичәләрне мавыктыргыч итеп үткәрә. Шул эшкә бәйләп, туган әдәбиятыбызны халыкка җиткерүдә дә ул күп тырыша.

Карап торуга Ильяз Зиннуров башка кешеләрдән берни белән дә аерылып тормый кебек. Ләкин ихтыяр көче, горурлыгы сизелеп тора. Кешеләрне, тормышны ныграк ярата ул. Тормышның кадерен белгәнгә, башкаларга ярдәмгә килергә дә һәрвакыт әзер ул.

Мин аңа илнең төрле почмакларыннан килгән күп сандагы хатлар белән таныштым. Аңа төрле милләт кешеләре яза. Аяксыз, я кулсыз калып, тормыштан бизгән кешеләр юату, ышану өмет итәләр, педагоглар тәрбия эшендә киңәш сорыйлар. Ильязга Татарстаннан, туган авылы Зирекледән дә бер кочак хатлар килгән. Бер язма авылның урта мәктәбе музеенда Ильязга багышланган бүлек ачылуы турында хәбәр итә...

Соңгы очрашуыбыз Ильязлар өендә булды. Ул коридорга китап киштәләре ясый иде. Хуш исле нарат такталары өстенә утырып озак кына сөйләштек. Урамга чыккач та Ильяз Зиннуров язмышы турындагы фикерләр куера гына барды. Аның зур фаҗига кичереп, ихтыяр көче белән яңадан аякка басуы, китаплар чыгаруы, фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә кадәр үсүе турында уйланып кайттым. Металлургия буенча дүрт китап авторы Ильяз Зиннуров бүген яңа китаплар яза. «Атлас»ны да тулыландырып яңадан чыгарырга әзерли. Яңа җиңүләргә планнар кора ул. Планнары, һичшиксез, тормышка ашачак аның.

...............

## КУКМАРАДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

21—24 январьда Кукмара районында «Татар әдәбияты көннәре» булып узды. «Илһамыбыз — сиңа, партия» дигән девиз белән үткәрелгән һәм партиянең XXVII съездына багышланган бу бәйрәмне Татарстан Язучылар союзы, республика китап сөючеләр җәмгыяте һәм КПССның Кукмара районы комитеты оештырды.

Әдәбият сөючеләр белән районның бик күп мәктәпләрендә, китапханәләрендә, клубларда, предприятиеләрдә, колхозларда очрашулар булды. Китап сәүдәсе, үзешчән сәнгать көчләре чыгышы, җирле радиотапшырулар, китап укучылар конференцияләре, түгәрәк өстәл янында сөйләшүләр һәм башка чаралар үткәрелде.

«Татар әдәбияты көннәре»ндә республикабызның танылган әдипләре Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, КПССның XXVII съезды делегаты драматург Т. Миңнуллин, прозаиклар Г. Бәширов, Ә. Еники, А. Расих, А. Гыйләҗев, Р. Кәрами, М. Насыйбуллин, шагыйрьләр Ә. Баянов, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов, тәнкыйтьче Ф. Галимуллин, яшь шагыйрьләр Р. Зәйдуллин, Г. Моратов катнашты.

## КУЙБЫШЕВ ӨЛКӘСЕНДӘ ӘДӘБИ АТНАЛЫК

12—17 январьда Куйбышев өлкәсенең Кләүле районында татар әдәбияты атналыгы булып узды. Анда шагыйрьләр Ә. Рәшитов һәм З. Мансуров катнашты. Алар татар әдәбиятында якты эз калдырган әдипләр Зыя Ярмәки, Халик Садри, Әнвәр Давыдовның якташлары — Камышлы, Иске Ярмәк, Яңа Ярмәк, Яңа Усман авыллары хезмәтчәннәре белән очрашулар үткәрделәр. Әдәби атналыкта Куйбышев язучылары В. Туманов, И. Никульшин да катнашты.

## Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

14 январьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайның 100 еллык юбилее алдыннан поэзия кичәсе булды. Анда төрле буын шагыйрьләрдән С. Хәким, Н. Арсланов, М. Садри, Н. Дәүли, Ә. Исхак, З. Нури, Ш. Галиев, Р. Харис, Р. Гатауллин, Ш. Маннапов, Ф. Сафин, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты А. Арсланов һ. б. чыгыш ясады.

Халык шагыйренә багышланган бу кичә Казан телевидениесенең әдәби-драматик тапшырулар редакциясе тарафыннан оештырылды.

В. И. Ленин исемендәге Казан дәүләт врачларның белемен күтәрү институтының кафедрасы урнашкан бинаның (элекке Клячкин шифаханәсе — Островский урамы, 11) бер бүлмәсендә Г. Тукай үзенең соңгы көннәрен уздырган. Кафедра хезмәткәрләре көче белән шул бүлмәдә кечкенә музей оештырылды. Анда Г. Тукай истәлегенә багышланган альбом, шагыйрьнең бюсты (аны Бакый Урманче бүләк иткән), татар язучыларының әсәрләреннән зур булмаган китапханә бар. Һәр елны Татарстан Язучылар союзы вәкилләре бу музейда булалар, авырулар һәм медицина хезмәткәрләре алдында чыгышлар ясыйлар.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

31 январьда Казанның Актерлар йортында язучы Нәби Дәүлинең иҗат кичәсе булды. Әдипнең тормыш һәм иҗаты турында тәнкыйтьче С. Маннапов сөйләде. Кичәдә танылган сәнгать осталары башкаруында Н. Дәүлинең әсәрләре яңгырады, язучы күп санлы сорауларга җавап бирде. Казан телевидениесе аша да күрсәтелгән бу кичәне язучы Р. Кәрами алып барды.

24 январьда Казан Дәүләт консерваториясенең Актлар залында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Алмаз Монасыйповның иҗат кичәсе булды. Кичәдә аның Татар Дәүләт филармониясенең симфоник оркестры башкаруында Беренче симфониясе һәм «Тукай ритмнары» дигән вокаль-симфоник поэмасы башкарылды. Оркестрга кушылып РСФСРның атказанган артисты Э. Җәләлетдинов җырлады. А. Монасыйпов дирижер буларак та чыгыш ясады.

## ВЕНГР ТЕЛЕНДӘ

Будапешт университеты тарафыннан чыгарыла торган «Артес популярес» («Халык иҗаты») исемле еллык җыентыкта совет музыкасы белгечләре һәм фольклорчылары хезмәтләренә дә урын бирелә. Соңгы саннарның берсендә (1985 ел, 14 сан), мәсәлән, Наилә Әлмиеваның керәшен татарлары музыкаль фольклорын өйрәнү проблемаларына багышланган зур мәкаләсе басылып чыкты. Шушында ук йола җырларының нотировкасы да бирелгән.

## ЯКТАШЫБЫЗ — КАЗАХ ГАЗЕТАСЫ ЛАУРЕАТЫ

Казахстан Язучылар союзы идарәсе органы булган «Казах әдәбияты» газетасы һәр ел ахырында үзенең битләрендә басылган иң яхшы әдәби әсәрләр һәм әдәби-тәнкыйть

мәкаләләрен билгеләп үтә. 1985 елда басылган иң яхшы хезмәтләр арасында Татарстан галиме, филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллинның татар һәм казах әдәбияты һәм сәнгатенең бәйләнешләре турындагы зур күләмле мәкаләсе дә бар.

## БӨТЕНСОЮЗ СЕМИНАРЫНДА

12—27 январьда Дубултыда язучыларның Ян Райнис исемендәге иҗат йортында балалар өчен язучы яшь авторларның Бөтенсоюз семинары булды. Анда Татарстаннан яшь язучылар Камил Кәримов һәм Рафис Корбанов катнашты. Аларның иҗаты күренекле язучылар җитәкләгән группаларда тикшерелде һәм уңай бәя алды.

## ЯҢА ТАБЫШЛАР

СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре узган ел өч археографик экспедиция оештырдылар. Филология фәннәре кандидаты М. Әхмәтҗанов җитәкчелегендәге беренче төркем Татарстанның Арча, Кукмара, Чистай районнары авылларында, Казан, Чистай шәһәрләрендә эзләнүләр алып барды. Әдәбиятчы Р. Әхмәтов җитәкчелегендәге икенче төркем тарафыннан Октябрь районы Кизләү авылы янында кызыклы болгар кабер ташы истәлеге табылды. Филология фәннәре кандидаты, фольклорчы Р. Ягъфәров Пермь, Чиләбе, Курган өлкәсендә булган дәверда тупланган 20 дән артык кульъязманы архивка тапшырды. Табышлар арасында күп кенә кызыклы истәлекләр: болгар-татар язма әдәбиятына нигез салган. Кол Галинең «Кыйссан Йосыф» поэмасының өч кульъязмасы, XVIII гасыр ахыры — XIX гасыр башында Мамадыш тирәләрендә яшәгән шагыйрь Колмөхәммәднең билгесез шигырьләре җыентыгы, «Түләк белән Сусылу» дастанының яңа кульъязма нөсхәсе һ. б. бар.

## КОМПОЗИТОР МУЗЕЕ

Казанның Вахитов районындагы 41 нче мәктәптә РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, республикабызның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Заһид Хәбибуллин музее ачылды. Музей композиторның тормыш юлын, күп жанрлы иҗатын, музыкаль һәм иҗтимагый эшчәнлеген чагылдырган материалларга, фоторәсемнәргә бай.

Биредә мәктәп укучылары республикабыз композиторлары иҗаты белән танышачаклар, совет һәм бөтендөнья классиклары музыкасын тыңлаячаклар.

## ЯҢА ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ БЕРЛӘШМӘ

Актаныш районында «Агыйдел дулкыннары» дип аталган яңа әдәби-музыкаль берләшмә эшли башлады. Берләшмәнең беренче кунаклары итеп үзешчән композитор И. Закиров, җырчы Г. Фарукшин, яшь шагыйрь Х. Миңнегалиев чакырылган иде. Ул көнне Актаныш үзешчәннәре зур концерт бирделәр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

СССР халыкларының поэтик иҗатын өйрәнүдәге һәм пропагандалаудагы хезмәтләре өчен Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты секторы мөдире, филология фәннәре кандидаты Илбарис Нурисламович Надировка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 6 ноябрь Указы белән «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан телевидениесе студиясе дикторы Эльмира Хамматовага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 12 декабрь Указы белән «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Минзәлә Татар дәүләт драма театры артистлары Роза Җиһаншинага, Рөстәм Муллинга, Венера Нигъмәтуллинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 27 декабрь Указы белән «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Минзәлә Татар дәүләт драма театры артисткасы Илүсә Бәдриевага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1985 ел, 27 декабрь Указы белән «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен һәм җитмеш яше тулу уңаеннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Һидият Солтанов, совет театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткәннәре өчен, Минзәлә Татар дәүләт драма театры артистлары Фәиз Бәдриев, Рәшит Мәрдеханов һәм режиссер Линар Садриев Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

*Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары*



## Ләис Зөлкарнәй

Ләис Зөлкарнәй (Ләис Мәүлит улы Харрасов) 1962 елның 2 апрелендә Башкортстанның Бакалы районы Саскүл авылында туган. 1979 елда Куштирәк урта мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт университетында белем ала. 1983 елдан «Ялкын» журналында әдәби бүлек редакторы булып эшли.

Беренче шигырьләре, хикәяләре «Яшь ленинчы» газетасында һәм «Идел» альманахында 1978 елда дөнья күрде. 1984 елда аның «Балачак күге» исемле шигырьләр китабы басылып чыкты.



## Фәиз Зөлкарнәев

Фәиз Мәүлит улы Зөлкарнәев 1951 елда Башкортстан АССРның Бакалы районы Сөендек авылында туган. 1969 елда Куштирәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, колхозда клуб мөдире, мәктәптә укытучы булып эшли. 1970-72 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1979 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, ТАССР Культура министрлыгының фәнни-методик үзәгендә кече фәнни хезмәткәр, аннары, 1980—1983 елларда «Ялкын» редакциясендә бүлек редакторы булып эшли. 1983 елдан ул Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә редактор.

1984 елда Татарстан китап нәшриятында яшь тәнкыйтьченең «Кешем, асылың кем?» исемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган җыентыгы чыкты.



## Солтан Шәмси

Солтан Сәләх улы Шәмсетдинов 1946 елда Биектау (элекке Дөбьяз) районының Суксу авылында туган. Шул ук районның Юртыш авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанда һөнәр училищесында укый. Аннан соң Мәскәүгә китеп, төрле заводларда эшли. Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач, Мәскәүнең Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый, аннары сигез ел дәвамында «Казан утлары» журналы редакциясендә проза бүлеге редакторы булып эшли. Хәзерге көндә — профессиональ язучы.

Ул үзенең әдәби эшчәнлеген тәрҗемәдән башлый: татар әдипләрен — русчага, рус һәм тугандаш әдәбият вәкилләрен — татарчага тәрҗемә итә; бер үк вакытта үзе дә хикәяләр язып бастыра. Татарстан китап нәшриятында аның «Көмеш чылбыр» исемле хикәяләр җыентыгы (1984) дөнья күрде.

# ӨЙГӘ ТЫНЫЧЛЫК ТЕЛӘҮ

Танылган нәкышче Илдар Зариповның без «Өйдә» дип исемләнгән ике картина иҗат иткәнлеген беләбез. Әсәрнең беренче үрнәге (1970) рәссамга шактый шөһрәт алып килде, һәм хәзер ул Ленинград Рус дәүләт музеенда күрсәтелде. Беренчесеннән соң ун ел үткәч, автор картинаның икенче вариантын эшләде. Рәссамның мондый адымын ничек аңларга? Элекке казаныштан ваз кичүме? Юк. Хикмәт — башкада.

Әсәрнең беренче үрнәге И. Зариповның программ картиналары рәтендә саналырга хаклы. Җанына якын булган авыл тематикасы буенча нәтиҗәле эшләүче рәссам биредә халык сәнгатенә тоташкан идея-эстетик концепциясен аерата тулы ачып күрсәтә, шигъри-этник детальләр ярдәмендә ана булу бәхете, дөньяны җылытып торучы гаилә учагы, тирән гасыр катламнарына тоташкан күркәм традицияләр, милли характерларның үзләренә «тарту көче» турында беркемне дә битараф калдырмаслык итеп сөйләүгә ирешә.

Җитмешенче елларда И. Зарипов иҗаты яңа баскычка күтәрелде. Тарихи үткәннәргә, бүгенге удар төзелешләргә һ. б. шундый мөһим темаларга багышланган лирик-поэтик һәм эпик полотнолар, күпсанлы пейзаж, портретлар, әдәби нигезгә корылган нәкыш-фантазияләр рәссам иҗатындагы гражданлык ялкынының көчәюен, образлардагы эмоциональ эчтәлекнең тирәнәюен, лирик-драматик кичерешләр диапазонының киңәюен бик ачык раслыйлар.

«Өйдә» картинасының икенче варианты (1980) И. Зариповның рухи-эстетик тәҗрибәсе баюын, рәссам колоризмының яңа үсеш баскычына күтәрелүен күрсәтә. Рәссам картинадагы «милли интерьерлык»ны саклап кына калмый, аңа тагын да көчлерәк шигъри-философик яңгыраш бирә. Полотнода «якты һавалы өлеш» арткан, элекке кайбер контурлар бетерелгән. Героиня йөзендәге төсләр бирелешендә дә шактый үзгәрешләр сизелә. Нәтиҗәдә әлеге вариантта үткәрелгән философик фикер элеккесенә караганда масштаблырак килеп чыккан, һәм картина гап-гади авыл өе нигезендә дөнья халыклары «өе», җир язмышы турында тирән уйлануларга этәрә.

Роза **ГОМӘРОВА**,
сәнгать белгече.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстанның халык артисткасы композитор Сара Садыйкова.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)